Аяз Гыйләҗев
Балта кем кулында?
РОМАН

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2008

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-44
Г92

**Гыйләҗев А.М.**

Балта кем кулында?: роман / Аяз Гыйләҗев; кереш сүз авт. Ф.Ә.Ганиева.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.— 320 б.— 2000 д.— ISBN 978–5–298–01673–5
«Балта кем кулында?» романында торгынлык елларында тамыр җәйгән тискәре күренешләр, төрле катлау кешеләренең тормышы, намус, әхлак мәсьәләләре үзәккә куеп тасвирлана.

ISBN 978-5-298-01673-5
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Гыйләҗев А.М., 2008

## «ВАКЫТ БЕЗНЕ ИЯРТЕП АГА»

Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Аяз Гыйләҗев, китапларын кулга алган саен, укучысына мөрәҗәгать итеп, аны кабат-кабат һәм яңача уйландырып, безнең белән фикерләшеп тора кебек. Әсәрләре дә шуңа күрә һәр буын укучысы белән яңара, куйган сораулары да үткенәя генә бара.

Гаҗәеп сизгерлек бар шагыйрь җанлы, кырыс холыклы, нечкә күңелле һәм фәлсәфи фикерләүче бу әдип-художникта. Ул җиһан, Җир шары, кешелек тарихы, язмыш турында уйлана. Яшәү дигән иң әһәмиятле мәгънәне дә Аяз Гыйләҗев Вакыт белән үлчи. *«Вакыт белән дөнья йөзендәге бер төшенчәне дә, хыялдагы бер мизгелне дә янәшә куеп, чагыштырып булмый. Чөнки вакытның башы һәм азагы юк»,*— дип яза ул истәлекләрендә. Ә кеше гомере шул Вакыт елгасының әйтерсең үлчәп-санап алган бер җебе. Үз гомеренең яртысы дип ул кырык яшен билгели, шул яшькә кадәр кичергәннәр тәэсирлерәк, хыяллар баерак, теләк-максатлар биегрәк була, күрәсең. *«Әнә шул серле сызыкны атлап чыгуга, Вакыт курьер поезды сыман ашыга башлый. Гомернең икенче яртысы ни өчен тиз үтә? Чөнки гомер елгасы кирегә ага...»*

Иҗатына күз салсак, кырык яшенә кадәр Аяз Гыйләҗев «Тәрәзәләр», «Үги ана яфраклары», «Дүртәү», «Берәү», «Өч аршын җир», «Зәй энҗеләре», «Урталыкта» кебек проза әсәрләрен, 4-5 драмасын язып өлгергән, әдәбиятта үзенә юл ярган әдип булып өлгерә. Бер кызыклы үзенчәлек хас аңа — ул санарга ярата. Әсәрләренең исемендә дә күренә бу; геройларының ничә яшьтә икәнлеген кабатлап, искәртеп бара; геройларының ничә чакрым юл үткәнлеген («Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар»), ничә көн гомере калганлыгын («Җомга көн, кич белән...») саннар белән дә сурәтли. Бу санау гади арифметика гына түгел, бу — кылган гамәлләреңне, яшәвеңнең мәгънәсен исәпләп, Вакыт үлчәменә салып, бәяләп карау. Нәтиҗәләре геройлар турында гына сөйләп калмый, безне дә уйландыра, тетрәндерә, гыйбрәт алырга өндәп тора.

Исеме белән үк игътибарны тарта, сискәндерә торган «Балта кем кулында?» романы — гаять үзенчәлекле, катлаулы әсәр. Авторның игътибары ике мәйданга юнәлтелгән: катлы-катлы баскычлардан торган, үзара хакимлек чылбырлары белән аерылмаслык булып бәйләнгән җәмгыять, аның гади кешеләр белән идарә итүчеләр катламы һәм кеше күңеле, холкы-характеры, яшәү рәвеше, максат-теләкләре. Шушы ике чикнең кайсы хәл итә кеше язмышын? Кеше үз язмышына үзе хуҗа дибез, бу чыннан да шулаймы? Әсәрдә нинди балта турында сүз бара, аңа нинди мәгънәләр салынган һәм ул чынлап та кем кулында? Һәрвакыт, һәркем өчен әһәмиятле булган мәңгелек проблема романда бик калку итеп куелган, һәм Аяз Гыйләҗев геройлары да бу турыда газапланып уйланалар, җавап эзлиләр.

Кеше характеры ни дәрәҗәдә катлаулы, үзгәрүчән, яраклашучан яки, киресенчә, яраклаша алмаучан һәм курку хисенә буйсынучан икәнлеген автор әсәрнең төп герое Нәҗип мисалында исбатлап-сурәтләп бара. Ул аны гел Нәҗип Йосыф улы Нургалиев дип, анкета телендә әйтеп тәкъдим итә. Әйтерсең аның совет чорының бер гражданины икәнлегенә, гади халыкның типик вәкиле икәнлегенә басым ясый. Автор бу героен акламый да, якламый да, аңа идарә итүче системаның рәсми мөнәсәбәтен тасвирлый. Нәтиҗә әсәр ахырында — системага буйсынмасаң, сине шундый язмыш көтә.

Ә системаны тәшкил иткән кешеләр кем соң? Аларның хәле ничек: җиңелме, рәхәтме, бер борчулары да юкмы? Төрле киштәләргә, тармакларга кереп оялаган, үрчегән һәм кешеләр язмышын үз кулларында тоткан «идарәчеләр» әсәрдә шактый күп һәм алар — кафедра мөдире Платон Платонович Захарчук, доцент Юрий Петрович Захаров, профком председателе Изил Латыйпов, партоешма секретаре Иващенко, сары йорт

«хуҗасы» Матвей Ионыч, колхоз рәисе Ихлас. Алардан югарырак баскычта *«Иван Иванович, Идел буе төбәгендә абруйлы, хөрмәткә ия зат, шәһәр башкармасын җитәкли. Ә Басыйр Бариевичның оясы бераз таррак, ул Юдинодагы тимер юл идарәсен җилкәсенә күтәргән».* Менә шундый ике аерылмас җан дус, гәүдә, кыяфәт ягыннан капма-каршы булсалар да, арадан җил дә үтми. Алардан да югарырак — төрле тармак министрлары, Мәскәү үзе.

Болар турында сөйләгәндә, аларның кыяфәт, сөйләшү һәм эш-гамәлләрен тасвирлаганда авторның иромиясе, сарказмы очкын чәчеп тора. Әсәр тулысынча Брежнев чорына, совет системасына пародия булып яңгырый. Аяз Гыйләҗев оста художникларча иң төп сыйфатларга штрихлар ярдәмендә әйтерсең карикатура ясый: министрның балык яратканын белгәч, махсус бригадалар төзеп, Советлар Союзының төрле тарафларына иң затлы балыклар алып кайтырга җибәрәләр. Зәй районының райком секретаре шулай ук зур бер «яңалык» кертә — колхоз председательләре итеп буе 187 сантиметр булган кешеләрне генә куя, аларны Кремль взводы солдатлары тигезлегендә тезеп, югарыдан килгәннәрне каршылый.

Кеше характеры, аның рухи, тирән күңел дөньясы турында хикәяләгәндә дә автор күзгә күренми торган иң яшерен серләрне фаш итеп бара, яшәү шартларына яраклашкан, власть-хакимлек «канын» үзгәрткән, агулаган типларны иҗат итә. Нәҗипнең бертуган абыйсы, колхоз председателе Сабит Йосыпович кулында матди рычаглар булып, ул шулар ярдәмендә югарыга күтәрелсә, Мәхмүт-Мудрый кешеләрнең рухын газаплап тәм таба. «*Кеше күңеленең чиге бармыни? Ай азагында ул чираттагы корбанына барып, үзенең мул яшәве, тәмле ашавы белән мактаначак, күзенә кереп тегенең бурычлы җанын уч төбендә дер селкетәчәк: күп андый бәхетсезләр дөнья йөзендә. Шундыйлар арасында Мудрыйлар гомергә рәхәт яши!»*

Роман — жанр буларак катлаулы, төрле сюжет сызыкларыннан, күп геройлар язмышыннан үрелгән күпкырлы, күләмле әсәр. «Балта кем кулында?» романында Аяз Гыйләҗев, куйган соравына конкрет җавап эзләгәндәй, күпмәгънәле төшенчәләрне укучы алдына тезеп кенә тора.

Кечкенә вакытта болыттан, яшен утыннан, күк күкрәүдән курка торган Аязны әтисе Мирсәет ага: «Курку — иң явыз көчләрнең берсе», — дип аңлатып, батыр булырга чакырган. Табигатьнең генә түгел, тормыш-язмышның хәтәр җил-давылларын кичеп, үзендә курку хисен җиңә алганга күрә Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә һәм мәкаләләрендә хакыйкатьне курыкмыйча әйтә алгандыр да.

Романда тасвирланган курку хисе — авторның фикер җебен тәшкил иткән проблемаларның берсе. Курку хисенең күп төре, сәбәпләре белән очрашабыз. Мәскәүдә курсларда укыган вакытта әсәрнең төп герое Нәҗип кинәт хәлсезләнеп, авырып китә. *«Үләм! — диде кинәт кенә Нәҗип. — Беттем!» Бу уе шулкадәр ачык һәм төгәл иде, дәү гәүдәсе куырылып, бер йомарлам булып кына калды... Утыз өч яшенә җитеп аның берчакта да үлем хакында уйлап караганы юк иде».* Курку хисе Нәҗипнең дәвалап булмаслык бер чире булып әверелә. Бу диагнозны аңа врач Фәридун Фазлыев куя: *«Сез «чир вә үлем» килеп җитте дип өркеп, уйлаганнарым барып чыкмады дип куркып, бик нык борчылмадыгызмы икән дип уйлыйм».* Чынлап та, ихтыяр көчен алган бу курку хисе Нәҗип язмышына чабылган балталарның берсе бит.

Мескен хәлгә төшкән Нәҗип кенә түгел, үзләрен тормышның хуҗалары дип санаган геройлар да курка: председательләр Сабит, Ихлас кырын эшләребез, бозыклыгыбыз фаш булмасын дип куркалар; хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич Мәскәүдән килгән министрларны тиешенчә каршы алалмабыз, күңелләрен күрә алмабыз дип куркалар, әллә ниләр кыланып бетәләр. Димәк, алар баш өстендә дә балта эленеп тора — үз урының, дәрәҗәңне югалтмаудан курку.

Шулай да курку хисенең иң яманы, кешене кимсетә, ялагайланырга, алдашырга мәҗбүр итә торганы — үзеңнән өстәгеләрдән курку. Бу хис кешене кол хәленә төшерә. Югары авыл колхозчылары — моның ачык мисалы.

Укый торгач сорау туа: бу курку хисе белән көрәшеп, аны җиңеп булмыймыни? Балта бит әле ул төзү коралы да, рухыңны саклап калучы коралга әйләнә алмыймы ул? Бигрәк тә бүгенге буын, XXI гасыр укучысы алдында сорау туа, аның күңелен кузгата, аңын уята, гыйбрәт бирә бу роман. Нәҗипнең үз хыялларын тормышка ашыру өчен омтылышы чын көрәш булып чыкмады. *«Ул үзен күпчелектән өстен санап, борын чөеп, һаваланып йөрмәдемени?»* Нәҗип кичергән чарасызлыкның бер сәбәбе шулдыр, мөгаен. Чын көрәш гаделлек өчен булганда, дөреслеккә нигезләнгәндә генә нәтиҗә бирәдер, башкаларны да уята аладыр.

Романда матур бер мисал бар — Фәридун Фазлыев. Югары дәрәҗәләре, мактаулы исемнәре булмаса да, ул үзен саклап кала алган. *«Хәйләм һәм көнчелегем юклыктан бу дөньяга чак сыеп яшим. Әмма күңелем пакь: пакь күңел җәбер-җәфа тоеп та озак яши!»* — ди ул. Чын врач икәнлеген танып алганнар аны хөрмәт итми кала алмый. Лагерьда, төрмәдә ул кешелек сыйфатларын югалтмый, «өстеннәрне» «түбән-нәрдән» аерып карамый. Җәмгыятьнең җинаятьчеләрдән түгел, гаделләрдән арынырга, намуслылардан котылырга теләгәнен аңлагач та рухы сынмый, тоткыннар арасында гаделлек вәкиле булып яши. Рухын дәвалый алучы бердәнбер кеше булганга, Нәҗип иң кыен вакытларда аңа килә, хәтта бер батырлык та эшли — үзенә бирелгән ордерның Фәридун Фазлыевка тиеш булганын белгәч, квартирдан баш тарта, ордерны докторга тапшыруларына ирешә.

Кеше характерына, табигатенә хас булган көнчелек сыйфаты турында да сүз бара әсәрдә. *«Көнчелек — кешелек җәмгыятендә көрәшне хәрәкәткә китерә торган беренче рычаг ул»,* — дип ачы көлемсерәп башлаган фикерен автор Фәридунның сүзләре белән дәвам итә: *«Әгәр гел-гел көрәш өчен яши икән, кеше*

*рәхәт күрергә дә, бәхетле булырга да өлгерми... Һәр көрәш — яңадан-яңа корбаннар дигән сүз. Йә җаны әрәм була кешенең, йә тәне».*

Көрәш идеясе XX гасырның төп лозунгысы-шигаре иде. Ләкин революция, сугышлардан соңгы чорда көрәш кем белән кем арасында бара иде соң? Ни өчен? Нәрсә хакына? Гаделлек өчен булса, нигә әле кеше үзе яшәгән җәмгыять белән көрәшергә тиеш?! Бәлки, идарә итүчеләр үз дәрәҗәләре, рәхәт яшәүләре өчен гади халыкның рәхәтен, бәхетен тартып алу өчен көрәшкәннәрдер, балта күтәргәннәрдер?! Хәер, балта сабын алар йә һәр сүзен үтәргә әзер торучы, үзләреннән түбән торган яраннары, яки берни белән исәпләшмәүче байгышлар кулына бирәләр, балтаны да, кызыл әләмнәрне дә алар күтәрә.

Зур оешмалар, кодрәтле кешеләр арасында да көрәш бара: Идел буендагы иңкүлек җирне үз кулларына төшерү өчен маңгайга-маңгай бәрелешәләр, берсенең дә баш бирәсе, юл куясы килми. Ә үзләре халык мәнфәгате, эшче сыйныфы өчен дигән өндәмәләр артына яшеренгәннәр.

Романның тагын бер әһәмиятле үзенчәлегенә тукталыйк. Әсәрдә персонажлар саны кырыкка якын, әмма араларында без гадәтләнгән герой (йә уңай, йә кире) юк. Төп персонаж — Нәҗип — вакыйгалар җебен бәйләп бара, әлбәттә. Бу мәгънәдә аны герой дип атыйбыз. Әмма ул әсәр ахырында юкка чыга *«... аны этап белән Томск ягына озаттылар. Һәм шунда аның эзе югалды».* Һәм ул гомумән дә үз эзен таба алмыйча бәргәләнеп яши дә, яшәвенең мәгънәсен аңламыйча югала.

Шулай да романда образлар тезмәсе тыгыз; күп һәм күчерелмә мәгънәләре, символик яңгырашлары белән калку итеп сурәтләнгән, кабатланып торган образлар персонажларның тормышын чорнап алганнар — йә рәхәтлек, йә михнәт символы булып гәүдәләнәләр. Мәсәлән, Нәҗип белән Наилә нинди йорт-куышта гына яшәсәләр дә, өйләре гел тимер юл буенда. *«Көне-төне тынмаган, җәһәннәм арбасыдай дөбердәүдән туймаган, өйдә чын кыямәт куптара»* торган тимер юл — бу гаиләнең каһәрләнгән язмышы, беркайчан үз өйләре, җүнле торыр урыннары булмаган гаиләнең юлдашы. Хәтта әсәрдәге төп «геройларның» берсе булган сары йорт та тимер юл буенда.

Сары йорт үзе исә — хокуксызлык, чарасызлык, кеше кадере булмауның символы. *«Исәп-хисапта булмаган, бишбылтыр сүтелгән саналган сары йорт... шәһәр оешмаларында, милициядә юк санала... Йорт та юк, андагы кешеләр дә юк. Язмыш тәгәрмәче бөтен авырлыгы белән адәм улларын сытып тигезләгән, юк иткән».*

**Югары авыл, аның юллары —** авылның бүгенге язмышы, бетеп баруга йөз тоту. Дөрес, председателе Сабит Йосыпович булган колхоз да бар. Әмма ул — алдашу, хәрәмләшү, башкалар хакын тартып алу хисабына, югарыдагыларга күз буяу өчен кирәк булганга корып куйган ясалма курчак.

**Авыл мунчасы, мичтә мәмрәп пешкән каз бәлеше —** Иван Иванович белән Басыйр Бариевичларның яшерен оҗмахлары, яшәү мәгънәләре, максатлары. Бәйрәмнең, серләр-планнар коруның югары ноктасы.

Сабитның яшерен урман аланы, ясалма күле — җирдә хуҗа булып яшәтүче бер көч. Бу «хуҗалар» тормыш тәгәрмәчен үзләре өчен генә әйләндерәләр. Нәҗип *«ярма ташлары арасына адашып килеп кергән бодай бөртеге иде».*

Һәр әсәрендә хикәяләвенең төгәллеге, аһәңлелеге белән рәссам булып сурәт ясаучы Аяз Гыйләҗев бу романында шактый кырыс. Ул үзен сокландырган матурлыкны табигатьтән генә таба, шул арада укучыны да бераз ял иттереп алуга ирешә: *«Озакламый җилнең канаты салынды, көн суытты, кояш Кашка тау маңгаен каплаган куе нарат урманының эзмәкәйле очын сыпырып үтте, төссез яшь ай урагына үрелергә чамалап азгын бер йолдыз кабынды, аңа икенчесе иярде, йолдызлар зәңгәр күктән кара ашъяулык текте... ләр».*

Романны тагын бер кат күздән кичереп, йомгак ясыйк. Нәҗип белән Наиләнең хәлен автор аяусыз дөреслек үлчәмендә, күп кешеләр өлешенә җитәрлек авырлыкларны алар җилкәсенә өеп, бер чылбыр итеп — сәбәп һәм нәтиҗәләр бәйләнеше итеп тасвирлый. Нәҗипкә бу хәленнән чыгу юлын күрсәтүчеләр, һөнәрләре белән генә түгел, иманнары белән кеше җанын дәвалаучы Фәридун Фазлыевлар очрады. Әмма Нәҗип үз чирен җиңә алмады, үз холкының да, иҗтимагый шартларның да корбаны булды.

Аяз Гыйләҗев бу әсәрендә вакыйга гына сөйләми, аның фикер йөртү офыгы киң: ул Вакыт агышын тоеп, дөнья кайсы якка борыла, тормыш ничек үзгәрә, замана татар халкын, аның гасырлар буена килгән яшәү тәртибен ниндигә әйләндерде, авыл ни хәлгә калды, кешенең кыйбласы кайда дип фәлсәфи уйлана. Автор үзенең тормыш тәҗрибәсе, дөньяга карашы, тарихи күзаллавы белән уртаклаша, әсәрендә сурәтләнгән чорны *«кырлы-мырлы, имансыз дәвер»* дип атый.

«Балта кем кулында?» романын 60 — 61 яшьлек Аяз Гыйләҗев моннан 19 — 20 ел элек язган. Балта идарә итүчеләрнең явызлары, намуссызлары кулында икәнен, тоталитар системада зур «алтын» багана — Мәскәү һәм аңа баш иярге мәҗбүр ителгән һәм үз буйсынучылары булган шәһри Казанның тормыш күчәре булганлыгын тел яшермичә ачык тасвирлаган. 20 ел эчендә җәмгыять шактый үзгәрешләр кичерде, без, укучылар да, хокукларыбызны аңлый һәм якларга өйрәнә башлаганбыздыр. Әмма әсәрнең актуальлеге аз гына да кимемәгән: идарә итүчеләрнең халыкны кайгыртып, аңа хезмәт итәргә теләүләрен, шул якка үзгәрүләрен әле шактый көтәргә туры килер.

Шул ук вакытта әсәр «балтаны» кеше характерында, үзенә һәм әйләнә-тирәгә мөнәсәбәтләрендә дә икәнлеген искәртә бит. Кеше табигате, аның психологиясе шулай ук акрын үзгәрә, иң мөһиме — бу процесс

күзгә күренми, һәм аның белән читтән торып идарә итүе бик кыен. Юкка гынамыни Аяз ага истәлекләрендә *«Дөньяда иң авыры — үз-үзеңә хөкем чыгару...»* дип нәтиҗә ясап куймаган.

Хөкүмәт тарафыннан кешеләрнең баш өстенә элеп куйган иң хәтәр балта — эшсезлек; өметсезлеккә төшерә, киләчәккә юлны бикләп куя, «син кирәкмисең» дип кешене чарасыз калдыра. Менә шул очракта кеше кулына үз «балтасын» ала — урлый, талый, җинаятькә бара.

Кешенең хәле үз рухи көченә, гаделлеге, сәләтенә, тырыш-үҗәтлегенә дә бәйле. Нәҗип тә бит әнә гаепнең үзендә дә бар икәнлеген танып, *«Характерымда бозыклык бар, ахрысы, минем»* ди. Автор бик хикмәтле деталь тапкан: Нәҗипнең кул бармакларына эт тырнаклары үсеп чыга башлый, аларны тешләп өзеп, ул кулларын канатып бетерә, яралары үзәгенә үтеп сызлыйлар. Татар халкында, рухы зәгыйфь яки авыру кешене куенында балта йөртә, диләр. Романны укыгач, үзеңне Нәҗип хәленә калдырмаска кирәк; язмышыбыз, теләк-омтылышларыбызның тамырына чаба торган балталарның кайберләре үз кулыбызда да икән бит дип нәтиҗә ясап була.

Бу роман турында язганда, олы әдипнең иң гүзәл әсәрләренең геройлары — Әдилә белән Ибраһим, Галимҗан белән Сөмәя, Бибинур карчык, Җиһангир образлары һәм, әлбәттә, Аяз аганың ягымлы якты йөзе, үткен карашы күз алдымда торды.

*Флера Ганиева*

**1**

Ул әүвәл әсәренде, аннан сискәнеп китте: моңарчы аны камаган дөнья төрле төсләрдән, исләрдән, күпсанлы әйберләрдән, хәрәкәтләрдән тора иде, шулар кинәт юк булды; колак берни ишетмәс хәлгә килеп, күз алдын тоташ кара пәрдә каплады. Әйтерсең лә язмыш аны тереклек яралмаган, җан ияләре булмаган төссез, иссез һәм шомлы тынлык хакимлек кылган бер галәм утравына илтеп ыргытты. Ул үзенең дөньяда барлыгын сынап, сул учы белән маңгаен кысып карады, маңгайның кайнарлыгын да, мул сибелгән бөрчек-бөрчек тир тамчыларын да сизмәде, димәк, аның сизү, сиземләү тойгысы да юкка чыккан. Ул, чеметеп карарга теләп, колагына үрелде, кулы кыймшанмады, уч төбе киң маңгай тиресенә суырылып ябышкан иде.

Башкала китапханәсенең егерме кешелек иң аулак уку залында тирә-ягына һич игътибар итмичә китабына йотылып утырса да, ул дөньяда яшәвен, янәшәсендәге гадәти тормыш агышын бик күп билгеләрдән чамалый иде. Уң яктагы ханым журнал битен ачуга, ул яктан кыйммәтле хушбуй исе бөркелә, ханым балдаклар богаулаган алтын кулы белән бүртмәч иреннәрен каплап иснәп ала. Сулдагы аралыктан, татлы тәмәке исе таратып, купшы мыеклы, нәзек билле кавказлы үтә. Ботинкалары шыгыр-давыннан чырае сытылган урта яшьләрдәге хәрби авызыннан җиңелчә генә коньяк исе сизелеп кала. Сак тавышлар сүнә, исләргә киртә юк, алар күзгә күренмичә аңа таба агалар, шул исләр аша да ул кемнең кем булуын, яшәү мөмкинлекләрен чамалап утыра, каләм йөгерсә дә, китап кыштырдаса да, дөньяның бер бөтенлеген, бөтенлекнең уртаклыгын, үзенең дә шул бөтенлекнең бер мөһим кисәкчәсе икәнен тоя иде. Ул бу хакта уйламый, әмма җаны-тәне белән аңлый: ул «юк» икән, бөтенлек мөкәммәл булмаячак...

Хәзер әнә шул билгеләр һәммәсе берьюлы тирән упкынга убылгандай гаип булды; ул төссез, иссез, хәрәкәтсез шомлы чумгылда бер башы торып калды. Үтә сәер, куркыныч халәт иде бу!

Мие бертынга тәмам түнеп, зиһенен соргылт-куе шәүләләр чолгаса да, ул китапханә ябылырга җиткән мәлне шәйләде, мөгаен, уку залында соңгыларның берсе булып ул калгандыр. Китапханә хадимәсе, өенә кайтырга талпынып, бер — аның иелгән киң җилкәсенә, бер дивардагы шакмаклы кара рам читләгән сәгатьнең өнсез-тавышсыз шуышкан чукмар телләренә карап-карап куядыр. Кузгалырга, кайтырга бик вакыт. Ләкин ул, җылы сумала сыланган ат сыртына менгән адәм угылы сыман талпынса да, ычкына алмый, ычкынырлык талпына да алмый иде.

Иләс-миләс башының арт чүмечендә кинәт кенә төссез, тавышсыз яшен чартлады; ул, чарасыз калып, сулгарак янтайды, бераздан исенә килде һәм моңа охшашлы хәлне кайчандыр татыганы хәтеренә төште. Кайчан иде соң, кайда булды ул хәл?

Университетның кичке факультетында укып йөргәндә, курсташына, Яльчик күле ягасына кунакка барган иде. Кичен, өреле куе кара балык ухасы ашап, сүнәр-сүнмәс янган учак тирәсендә озак кына гәп сугып утырдылар. Курсташының этисе — урманчы, Ватан сугышында сул аягын тездән өздереп кайткан Каюм абзый чәүчәләк һәм быткыч бер кеше икән, сүзен әйтә дә сикереп тора, кашыгы белән черкиләр явын куа-куа, дөнья хәлләрен сораштырып студент егетләрнең хәлен алды. Җавап та көтеп тормый, бахыр, ялгыз яшәп теле кычытканмы, сорый да сорый. «Укып бетергәч, эшкә кая җибәрәләр инде? Әйтмәсәгез дә беләм — сугыш кораллары ясарга тотынасыз. Казан каласы коралдан бүтәнне белми! Кая карама яшертен заводлар. Ни-нәмәгә кирәк ул корал? Рәсәйгә җир җитмиме? Булганның кадерен белергә бик вакыт. Нефть юкмы бездә? Күмер? Ясагыз корал, яса. Котыртыгыз тегеләрне. Үз башыгызга булмасмы! Менә аякка протез юк, каен түмәре бәйләп йөрим. Хатында тамак хастасы, пүчтәк кенә дару табар хәл юк. Ашарга такы-токы, он кайтармыйлар, ярма югалды. Өс-баш — мәсхәрә,

адәм көлкесе. Яшьләр чит илдән ташыганны кия, картларга — шымытыр! Ә ел саен ике тапкыр парад! Әй чыгалар Май бәйрәмендә тынычлык яклап, шатыр-потыр ракеталар тагып! Танклар җирнең үзеген сытып гүелди. Меңләгән әфисәр шак-шок бара, түшләр киерелгән! Тынычлык өчен көрәшәбез, янәсе. Май бәйрәмендә, язын, адәмнәрнең җаннары яңарганда, берсе-бер шәһәрне юк итәрлек ракеталар сөйрәгәч, безгә кем ышансын?! Өркетәбез дип, тегеләрне котыртабыз лабаса!.. Алар азына дип, без шашабыз! Атом заманында илләрне өркетеп ипкә китереп буламы? Дөнья ямен безнең ил башлыклары да ньк боза... Ә бер-бер сүз әйтеп кара!»

Учак янында тыелып торган акылы, гәүдәсе җылы юрган астына кереп яткач, ашыгыч-ашыгыч уйларын арлы-бирле йөртә башлады. Чырае сытык булса да, төтене туры йөри каен аякның! «Яз җиткәч, каен түмәреннән су тама!» дип арттырса да, бүтән җәһәттә картның уйлары күңелне кузгатырлык иде. Ул да ялгыз калган мәлләрдә шундый икеле-микеле уйлар тозагында тырпылдап ятмыймыни? Миллион сумнарга төшкән парадлар ни өчен кирәк? Кемгә? Алган белеме шул тирәдә булганга, ул хәзерге заман сугыш коралларының көч-егәрен картка караганда биш тапкыр ачыграк беләдер!..

Күнегелгән кагыйдәләр буенча, ул картка ак-кара димәде, кайтарып җавап бирмәде, юрган астында йодрыгын йомарлап, кемнәр беләндер бәхәсләшеп, талашып ятты...

Чарлакта уянып калкынса, иптәше торып төшеп киткән, сул яктагы вак өлгеле тәрәзә ачык, зәңгәр күккә очлы укларын сузып, биек-биек чыршы-наратларны аралап, офыктан кояш күтәрелә иде. Ул, терсәкләренә таянып, сокланып киртләч офыкка карап торды. Кояш бер нарат кәүсәсен үтте, икенчесенең артына кереп, әзгә генә югалып торды, өченче агачны тиз-тиз уза башлады. Ул күзләрен шарландырып як-ягына каранды: нәрсә бу? Нинди хәл? Кояш шултиклем тиз бара аламыни? Нигә кабалана ул шулай? Әллә күкнең иң мәшһүр җисеме үзенең мәңгелек сызыгыннан, Ходай тәгаенләгән орбитасыннан ычкынганмы? Җиргә афәт киләме? Гарасат?! Бетү! Дөнья бетәме?!

Ул туып, аңы үсеп исәйгәннән бирле карчык-корчыклар: «Алда адәм уллары вагаячак... Мич төбен ындыр табагы итеп ашлык сугачаклар. Ике меңенче елда дөнья бетәчәк», — дип, курку катыш ышаныч белән сөйлиләр иде бит, шул көн килеп җитеп, дәһшәтле һәлакәт сәгате суктымы әллә?

Күргән төшләре исенә төште, ул төне буе атом бомбалары, гайрәтле танклар, хәрабәләр, тау-тау өелгән мәетләр, мәҗрүхләрне күреп саташып ятты лабаса. Кемдер, көмеш дага сакаллы, йомшак кара кәләпүш кигән берәү, бармагын төртә-төртә, аңа гел бер сүз сөйләде: «Укып кем буласың инде син? Адәм җанын кыючы палач буласыңмы?» — дип сорады...

Йокысыннан уянып, түшәннән арынып бетмәгән иде, ул чарлакның текә баскычыннан очып диярлек төште һәм яман акырган тавышка чабып кергән иптәшенең кочагына килеп ауды. Баш түбәсенә нидер китереп суккан иде шул чакта, һушы китте, урталай ярылган ныкча ияге дер-дер калтырап, ирен читләреннән ак күбек сызылып чыкты.

Аны түмәр аяк Каюм абзый дәвалады, иртән бер чәркә аракыга бер тустаган юкә балы тугылап эчертте. Әбәттә дә шуны кабатлады, кичке аш та шул булды, кичен бер тустаган хуш исле балга аракы өч чәркә кушылды. Ходайның әмере булдымы, өч көн дигәндә ул аягына басты һәм, берни булмагандай, Казанга кайтып китте.

Уку залында утлар кимеде, почмакларга караңгылык кереп, кәгазьләре белән аны да зыр-зыр әйләндерде. Суык әрсезләнеп аяк бармакларын тешләде, җилкә чокырына үрмәләде, ниһаять, җелеккә төште. Таксига дип барлы-юклы акчаларын кармаштырганда, урамның аргы башында иренеп кыймылдаучы троллейбус күренде. Ул, тукталган шоферга кул изәп, китәргә кушты.

Вакыт соң, төн суык, җилле, кеше әз, буш урыннар байтак. Ул, кеше юк якны сайлап, артка ук барып утырды. Утыруга чалкан авып китте: ми капкачын дер селкетеп яшен чартлады, бая китапханәдәге сыман, күкрәгенә үткер уклар яуды. «Җылыдан чыгып җил күзендә озак тордым!» — диде ул, үз-үзен юатырга тырышып. Гәүдәсен көч-хәл белән турайтты, «исерек дип уйламасыннар тагын!» Утыра торгач җылынгандай булды, йокымсырады, черем итеп алды. Торак йортының биек, авыр ишегенә килеп җиткәнче, күшеккән бармакларын чак кыймылдатып, сул чигәсен уа-уа атлады, әрсез өерелгән җилгә уң күкрәген куйды.

Лифтның уникедән соң ял иткәнен белсә дә, соры салкын төймәгә баскалап, могҗиза көтте. Аллаһы Тәгалә бардыр лабаса, аның тәмам алҗып кайтып килүен күргәндер ич, бер яхшылык кылса, ни була? Ул, гасабиланып, югарыга, кабиналар аска-өскә йөри торган, тимер рәшәткәләр каймаган коега карап торды, хәрәкәт булмагач, култыксага ябыша-ябыша, чи тары көлтәсе кебек авыр гәүдәсен өскә, җиденче катка сөйрәде. Озак менде, аркасы җылынса да, куллары боз иде.

Тулай торак коридорындагы бушлык аны шикләндерде: ни булган бүген кешеләргә? Кая олакканнар алар?

Ачкычын оясында калдырып, эчкә керде, диванга тотына-тотына мыштырдап чишенде, киемнәрен кул астындагы урындыкка алак-шалак өя барды. Бүлмә уртасында бераз чайкалып торгач, иртән җыелмыйча калган урынга барып капланды, ыңгырашты...

Нәҗип Йосыф улы Нургалиевне бик хәтәр завод лабораториясендә эшләгән җиреннән Мәскәүгә, алты айлык курсларга җибәрделәр. Номерлы, сак астында гына яшәгән заводның ул эшләгән лабораториясе гади кеше күзе җитмәслек эш башкара, адәм балаларына үлем, кырылыш әзерли иде.

Яңа елны каршыларга ул гаиләсе янына Казанга кайтты. Сагынышып күрештеләр, дөнья гаме кимеп торды. Хатыны, уллары белән кавышу шифалы булды. Казаннан ул күтәренке күңел, дәрт белән аерылды. Хатыны тормыш мәшәкатьләреннән зарланмады, балалары тыйнак, басынкы йөрделәр, завод директорының урынбасары Храмов: «Чихрадзены пенсиягә әзерлибез, монда үзара мәслихәтләштек, кайтуыңа үзеңне мөдир итәбез!» — дип, Нәҗипне искәрмәс яктан сөендерде.

Яңа елның беренче көнендә җәмәгате, уллары белән сурәткә төшкән иде, кичәге почтада алар да килеп җитте. Томыраеп торган ике улын күргәч, Нәҗипнең йөрәге ихтыярсыз сыкрады. Ул монда, канлы вәхши булуы өстенә, мактанырга да яраткан Сталин заманында зуп-зур тәрәзәле, биек итеп, муллык белән салынган бинаның болындай бүлмәсендә бер башы яши, ә алар анда, Яңа бистәнең тимер юлга чыга торган иң фәкыйрь урамында дымлы, тынчу йортта интегеп яталар. Әле анда да йорт хуҗалары — Җәмилә карчык белән Тимерхан карт — нык ялындырып, назланып, шактый акча өстенә кыш корсагына биш кубометр утын түләрбез, шым яшәрбез, каршы әйтмәбез, дип, кат-кат ант эчкәч кенә сыендырдылар. Җиде-сигез метрдан артмаган, кыеш идәнле бүлмә уртасында киң итәкле марҗа булып акшарлы мич утыра, мичнең теге ягында, янәшә бүлмәдә хуҗаларның кияүгә китмәгән, бер үк вакытта кияүсез дә яшәмәгән кызлары Таңсылу яши иде. Мондагы тормышның төп көйсезлеге, көне-төне тынмаган, җәһәннәм арбасыдай дөбердәүдән туймаган, терәлеп диярлек үткән тимер юл иде. Көндезләрен бүтән тавышлар тимер юл дөбердәвен басып торгалыйлар, әмма төннәрен, бигрәк тә җан зарыккан иртәләрдә, тәнне йокы изрәтергә тиешле мәлләрдә, тимер юл дөньяга бердәнбер хуҗа булып кала. Маневр паровозлары вагоннарны төн ката арлы-бирле сөйри, вагоннар берсе өстенә берсе менәләр, тормозлар исереп чыелдый, буферлар, маңгайга-маңгай килеп, очкын һәм тәмуг авазлары тараталар. Нәҗипнең, сикереп торып, тимер юлны шартлатасы, әзгә генә тавышларны тыеп торасы килгән чаклары бик күп булды. Авыр йөк төягән составлар алар йорты турында очрашсалар, өйдә чын кыямәт башлана, өстәл читендәрәк калган савыт-сабалар сикереп идәнгә төшә, дивардагы сәгать туктый, өй бүрәнәләре җекләреннән ычкынып калтырыйлар, зилзилә куба, җир тетри. Тавышка балалар җылап уяна. «Һаман йокыга китә алмыйм!» — дип, Наиләсе сукрана. «Нигә дөмекмисез, ачарбаклар!» — дип, теге яктан Таңсылу шакылдата. Кыскасы, тимер юл — дошман, тимер юл — каһәрләнгән язмыш, тимер юл гаиләдәге талашларның сәбәпчесе иде.

Храмов өметләндереп, Наиләсе тынычландырып, балалары сөенешеп озатты аны Мәскәүгә, болай ук булыр дип кем уйлаган?!

Нәҗип йөзтүбән яткан килеш авыр йокымсырады, керфекләре кушылып ябыштылар, тәне әз-мәз җылынса да, тездән түбән ягы салкын килеш калды.

Кайчан торып утын сүндергәндер, искәрмәде, дерт итеп уянганда, бүлмә дә, зур тәрәзәгә аерылмаска сарылган дөнья да дегеттәй кара иде. Аңына уй йөгерүгә, бүлмәсенә тагын бер нәрсә — шом кереп тулганын сизенеп, сагаеп тыңлап ята башлады. Тирә-якта нидер үзгәргән, тәрәзә пәрдәсенә ябышып кара шәүләләр атына, ишектә дә, почмакларда да иләмсез күләгәләр кыймылдый иде. Бераз интегеп, җаны алмаш-тилмәш иңгән уйлар кысасында тырпылдап яткач, ул кискен үзгәрешнең үзендә, сул як күкрәк читлегендә икәнен абайлады. Күкрәккә әйтерсең лә үзле балчыктан әвәләгән салкын калкан япканнар иде. «Уф Алла, дип бер суласаң, тар сулышны киңәйтә» дигән авыл җыры исенә төшкәч, ул күкрәген ачарга, балчыктан азат итәргә тырышып калкынды, кат-кат көрсенде. Торып утырыйм дигәндә, ыңгырашып төпсез коега очты. Аяк, кул бармакларына кан барып җитмәде, кан сорап тамырлары чемер-чемер сулкылдады. Бераздан тагын исенә килде, янәшәсендәге өстәлдән кармаланып лампа төймәсен эзләде, җайсыз утырып калган термос идәнгә төште, пыяла чылтырады. «Зиһенем ачык, колагым ишетә!» дип кабатлады аның көйгән иреннәре. Сүз белән ул үзен дәртләндерергә, тәненә көч бирергә теләде.

Азаплана торгач идәнгә, җылымса чәйгә басты, килбәтсез эзләр калдырып ишек катына килде. Ишекне бикләмәгән икән, бу аны, сак, игътибарлы кешене, гаҗәпләндерде. Ул баягыдан да шыксыз, үле төсләр сеңгән казна йортының ярым караңгы коридорына чыкты. Караңгылык аны тагын да ныграк куркытты. Сулда, өч бүлмә аша, аларның уртак кухнялары, үзбәк-таҗиклардан төнге ябалаклар кайвакыт анда пылау пешерәләр, аулакта үз телләрендә сөйләшеп, күңел шәмнәрен кабызалар. Алар янына барыргамы? Кем тоткасына кагылырга?

Көздән бирле дүрт ай дәвамында бергә укысалар да, аның артык аралашкан кешесе юк, моңарчы йомыш төшеп берәүгә дә кергәне булмады. Аралашырга өнәмәгәнен сизенгән курсташлары да аның бусагасын үтеп йөрмәделәр. Нәҗипнең ничек яшәвен, кем булуын, эчке һәм тышкы дөньясын беркем белми иде. Төн уртасы авышкач, мамык аякларын көчкә сөйрәп барып керсә, аны бүген мәзәк итмәсләрме? Борып чыгармаслармы?

Ул, сулышын тигезләргә тырышып, беравык торды да идәнгә чап-чоп басып үз бүлмәсенә борылды. Чайкалып китте, косасы килде, укшытты. Кайтырга ярамый, хәле барында кемгәдер белдерергә кирәк иде. Тик кемгә?

Каршы як бүлмәдә үзе кебек үк курсант, инженер, уфалы татар Мөнир Якупов яши иде, ул шуның ишегенә килеп орынды. Авыз эче коп-коры, колак эче үтереп кычыта, бугазыннан әчегән эремчек суы тәме килә иде.

«Үләм! — диде кинәт кенә Нәҗип. — Беттем!» Бу уе шулкадәр ачык һәм төгәл иде, дәү гәүдәсе куырылып, бер йомарлам булып кына калды. «Үләм, бетәм», — дип кабатлады ул, соңгы көчен җыеп.

Утыз өч яшенә җитеп аның берчакта да үлем хакында уйлап караганы юк иде. Якыннарының, кардәш-ыруларының әҗәлен бер тапкыр да күрмәгән, берәүнең дә соңгы сулышына шаһит булмаган Нәҗип үлемне үзеннән читтә, күз җитмәс еракта йөри торган рәшә итебрәк саный иде. Шөкер, әти-әнисе исән, Зәй ягында, авылда яшәп яталар. Олы абыйсы Сабит та шул төбәктә, туган якта гомер сөрә, колхоз рәисе. Энекәшләре дә исән, сеңлесе генә еракка кияүгә китте, ул да исән-сау. Күрешмәсәләр дә, исәнлек хәбәрләре килеп ирешә. «Нургалиевләр токымы озын гомерле!» дип мактанырга ярата иде Нәҗип. Бүтән җәһәттән алдынгылыкка чыкмаса да, үлемдә беренче нәүбәт аныкы икән. Мактан менә! «Әҗәлем, актык сулышым шушы икән, Мәскәүгә әҗәлем тартып китергән икән!»

Үкенечсез үлем юк, мәгәр егеткә үләргә һич ярамый иде әле! Әҗәлетдин якадан алганда бүтәннәр теленә ни киләдер, бүген ул бер сүзне тәкрарлады: «Ярамый! Иртә ич!»

Ни рәхәт күрде Нәҗип дөнья йөзендә? Һәм ни рәхәт күрсәтте?

Балачак кыенлыклары җиңел онытыла, алары үтте-китте. Балигъ булгач, көндез эшләп, кичен укып, мең бәлане җиңеп белем алды. Бүтәннәр кебек эшендә тиз төпләнә алмады, дипломнан соң килгән заводында урыннан урынга куып йөрттеләр. Берәүләргә табигате җай килмәде, «авыр холыклы» диделәр. Икенчеләр тырыш-үҗәтлеген өнәмәделәр: «Һавалы ул, тәкәббер!» — дип, аннан ераграк йөрергә тырыштылар. Ниһаять, урнашып, моңарчы аякка кара елан булып уралган кара нужадан котылам, хатын, балаларыма муллык һәм бәхет китерәм дигәндә... Биеккә менгерә торган баскычның түбәнге аратасына аяк басканда... Аһ, нинди вакытсыз һәм үкенечле була бу әҗәл! Газраил бүтән җайлырак ризык тапмадымыни?

Бүтән балалар җай чыгуга ата-анага әз-мәз игелек кылганда, ул күктән манный боткасы яуганны көтеп йөрде. Ни рәхәт күрсәтте ул хатынына? Өйләнеп туй үткәрмәде, балалар тугач, кунак җыйнап күңел ачмады, туган көннәрендә беркемне түренә өндәмәде... Алай гынамы, никахлашкач, бүләк-санак күтәреп килгән белеш-танышларын өерләп куып чыгарды. Үкереп елаган Наиләсен юатып: «Җылама! Җиде бәйрәмгә бер туй булыр. Бер булыр — берәгәйле булыр! Тирә-як дер калтырап торыр... Күктән йолдызлар өзелеп төшәр! Түз! Түз!»

«Түз! Вакыты җиткәч! Соңыннан! Баегач! Иркенгә чыккач!» Хатынын, үзен ничә еллар шушы сүзләр белән юатты, ымсындырды!..

Ата-анасына күчтәнәч салмады, хат язмады, туганнары белән арасын кырт өзде. «Килер бер көн, дөньясы шаккатар!» — дип кабатлады.

Көткән көне шушы булып чыктымы?!

Эзең сакланырлык бер якты сукмак калдырмыйча, юньле бер игелек кылмыйча, ялгышларыңа үкенеп тәүбәгә килмичә тот та дөньядан китеп бар инде! «Көнем килә, бәхет сәгате суга!» дип, яшерен өметләр тышка чыга башлаганда, ике үксез сабыйны хатын кулында калдырып, кара гүргә кереп ят инде! Фатирсыз, акчасыз ул ничек яшәр? Малайларны аякка ничек бастырыр? Нинди тере, шук, чая аның уллары! Нинди якты күз белән карый иде ул Искәндәре белән Рөстәменә! Кинәт бөтенесе чәлпәрәмә килә, чәнчелеп барып төшә, сүнә, түнә, ава... Иренең җансыз гәүдәсен Наиләсе Казанга ничек алып кайтыр? Каян акча юнәтер? Завод китапханәсендә иренең акча көрәрен көтеп яткан хатында нинди акча булсын! Институтын Нәҗип ташлатты бит: «Эшләтмәм! Мин тапканы җитәр!» — дип кырт куйды! Уллары аның үзе кебек җәфа чигеп, такы-токыда укырлар, таяныр әтиләре булмас, аларны «ятим-ялпы» дип кагарлар, читкә тибәрерләр. Шундый каргалган язмыш әзерли идеме ул сабыйларына? Моңарчы күргәннәренә түзгән Наиләсе таң туган саен аның кабере ягына карап нәләт укыр!..

«Үләм!» — дип әйтә алды аның умырылып аска иңә барган күңеле. «Беттем!» — дип кабатлады көрмәкләнгән теле. Ни үкенеч, аның соңгы сүзен тыңлар кеше юк, хәер, ни әйтсен ул бу ят кешеләргә? Ул үзен күпчелектән өстен санап, борын чөеп, һаваланып йөрмәдемени? Менә хәзер ал әҗерен, берәрсенә кереп кара!

Уфалы Мөнирнең йокысы үтә сак иде, ул: «Баядан бирле ишектә кем тырмана икән, салмыш ярата торган Шаламбиридзе тагын кәгеп кайтканмы әллә?» — дип, ишекне ачып җибәрсә, ишеккә терәлеп торган Нәҗип Нургалиев, мәлҗерәп, аның бүлмә идәненә ишелеп төште. «Ни булды?» — диде Мөнир, җирәнеп, аны исереккә чыгарып. «Беттем!» — диде Нәҗип. «Йөрәкме?», «Үләм»,— диде Нәҗип, өзек-

өзек ыңгырашып. Аннары, күм-күк иреннәрен тешләп, тынып калды. Күз алмалары ике якка тәгәрәде, чыраеннан кан качты. Эш уеннан узган иде.

Мөнир, йөз дә дүрт килолы гәүдәсе таралып китмәсен өчен туп-туры тотып йөри торган бәндә, Нәҗип аша очып чыкты да җиденче катның ял бүлмәсенә эленгән телефонга чапты.

**2**

Хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич — җан дуслар. Берзаман Мәскәүгә барышлый икесе бер купега туры килделәр дә юл буе авызга авыз сөйләштеләр. Икесе дә ашарга-эчәргә яраталар, ризык-мазарны умырып алганнар. Юл кыскарды, сүзләр сайланып чыкты, серләре килеште, башкалага барып кергәндә мәңге аерылмаска сүз куешып, вәгъдәләр беркетеп, кочаклашып саубуллаштылар...

Белгән халык аһ! итте.

Ничек? Дуслашканнармыни? Бер-берсен ничек табышканнар? Ни якынайткан аларны?..

Инде ул очрашуга байтак вакыт үткән, күпме сулар аккан, ә хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич арасыннан җил дә үтми, гайбәт күләгәсе дә йөрми. Шәһәр һаман гаҗәпләнә, дуслыкның серенә төшенә алмый, чөнки Иван Иванович белән Басыйр Бариевич бер дә, бер дә бер-берсенә иш килгән кешеләр түгел инде югыйсә! Эш якынайта дисәң, бер-береннән ерак тармакларда хезмәт күрсәтә алар: Иван Иванович Идел буе төбәгендә абруйлы, хөрмәткә ия зат — шәһәр башкармасын җитәкли. Ә Басыйр Бариевичның оясы бераз таррак, ул Юдинодагы тимер юл идарәсен җилкәсенә күтәргән. Иван Иванович баһадир, җилкәсендә өч-дүрт сабыйны «Әпипә»гә биетергә була, тавышы таш кантар ишелгәндәй калын, авыр; яңаклары чыгынкы, киң кашы ике себерке булып ярылып ята, учларында лилипутлар чабагач белән ашлык сугарлык. Ә Басыйр Бариевич нәрсә? Камыт аяк, буе — кер бәләге, орчык ияк, ясмык тешләр, коелып беткән керфекләр арасыннан без күзләр җемелдәп тора. Иван Иванович ерак Украинадан килеп төпләнгән, чын хохол. Басыйр Бариевич — тумышы ягыннан үз ягыбыз кешесе, әнкәсе әле дә исән, Юдинодан ерак түгел, ялгыз башы урыс-улак арасында яшәп ята. Басыйр Бариевич Мәскәүдә тимерьюлчылар транспорты институтын кызыл дипломга тәмамлагач, аны Россия шәһәрләренең берсенә җибәрделәр, ул шунда чирканчык алды, чыныкты, марҗага өйләнде, телен һәм туганнарын оныткач, аны Татарстанга кайтардылар. Ни гаҗәп, әүвәл элеваторларга баш булып йөрде, горкомда эшләп алды, аннан Юдинога тимер юлга күчерделәр. Элегрәк Басыйр Бариевич җылак һәм әләкче иде, хәзер тавышы көрәйде, сүзләре бөердән генә чыга, күз карашы белән дус-дошманны үтәли тишә ала... Ул сабый чакта Идел суы авылдан шактый ерак булып, пароход тавышлары бик сирәк, анда да ул яктан көчле җил искәндә генә килеп ирешсә, хәзер су бәрәңге бакчасына килеп терәлде, җилле кичләрдә чупылдаган тавыш тәрәзәдән керә. Иван Ивановичның ата-анасы исән, үзе Басыйр Бариевичка сөйләгәнчә, хәзерендә чик янындагы шәһәрчектә бик шәпләп яшәп яталар. Ватан сугышына яше кермәсә дә, Иван Иванович илленче елларда бандеровчыларга каршы сугышкан булып исәпләнә, төнге атыш вакытында печән чүмәләсендә посып утырганда, адашкан пуля аның иңбашын сыдырып үткән, шуннан бирле ул «ветеран» санала, юбилейларда орден-медаль яңгыры яуганда берчакта да мәхрүм калмый...

Икесе ике җирдә, ике кәсептә, әле ярый икесе дә депутат, икесе дә өлкә пленумы әгъзалары, сессияләрдә, пленумнарда, утырышларда, юбилейларда, тантаналарда еш очрашалар, читкә караган булып бер-берсенә күз кысышалар, дуслыкларының дәвамын ныгытып куялар. Мондый абруйлы җитәкче затларга үзара мөнәсәбәтләрен якты дөньяга чыгарырга ярамый, Ходай сакласын! Дөрес, аларның бәйрәмнәрдә йөрешкәнен, ризык бүлешкәнен байтак кеше белә, әмма бу дуслыкның эчке серләре икесе арасыннан берчакта да читкә чыкмый! Берчакта да! Телләреннән ялгыш сүз ычкынмас — ихластыр, дуслык әнә шул чакта гына дәвамлы, ышанычлы һәм какшамас була. Дуслыкның тәүге шарты — ике арадагы серне чишмәү. Күп еллар дәрәҗәле урында утырган затлар моны бик яхшы беләләр! Чөнки дәрәҗәле затларда, аларның газиз хатыннарында гына була серләрнең төрледән төрлеләре!

«Дуслык — бәйрәм!» — ди Иван Иванович.

«Дуслык — язмыш бүләге!» — ди аны җөпләп, Басыйр Бариевич.

Ахирәтләр бу гадел хакыйкатьне күптән сеңдергәннәр, гап-гади сәфәрдән башланган якынлык еллар үткән саен ныгыган, тирәнәйгән. Бәйрәм тантаналары бергә үтә (дәрәҗәле затларда бәйрәмнәрнең сансыз-исәпсез икәнен кем белми!), очрашулар күптәннән ныклы тәртипкә салынган, кунакка чиратлашып йөрешәләр, ике як та үпкәләрлек түгел: бүген Иван Ивановичларда җыелсалар, иртәгә табынның мулы Басыйр Бариевичларда әзерләнә. Соңгы елларда дуслыкның кадерен аерата нык белә башлаган җан дуслар очрашуларны, бәйрәм табыннарын Басыйр Бариевичның туган төягенә, Идел буендагы авылга күчерделәр. Анда инде аулак дисәң дә аулак! Һәм хикмәт шунда ки, дусларның нәни, әмма гаять әһәмиятле серен ачып китик: Иван Иванович авыл мунчасын һәм мичтә мәмрәп

пешкән каз бәлешен ярата! Ә бу дөньяда иң сихәтле мунчаны, тәме атналар буе тел төбеннән китми торган хуш исле, юка камырлы, үзе авызга керергә атлыгып торган каз бәлешен Басыйр Бариевичның газиз әнкәсе Әнисә абыстайларда гына күреп-татып була. Күптәннән тол калып, ялгызлыктан тәмам гаҗиз булган Әнисә абыстай мондый дәрәҗәгә ирешкән улыннан да, аның кунакларыннан да курка, курыкса да, кунакларын, аларга ияреп килгән мәшәкать-борчуларны күркәм сабырлык белән күтәп ала. Һәр тарафтан бөек дәрәҗәләргә ирешкән улына, аннан бигрәк килене Ида Михайловнага ярарга тырыша, аш-суын бөртекләп әзерли, мунчасын җиренә җиткереп яга.

О, хәзерге ак заманда кара мунчада чабынып чыгу — белгәннәр өчен берни белән чагыштырмаслык олы бәйрәм! Хөрмәтле Иван Иванович белән кунакчыл Басыйр Бариевич (кара мунчаның тәмен белгәннән соң, Иван Ивановичлар кунак кабул итүне бермә-бер сирәгәйттеләр, нишлисең, аларда мунча да, һәйбәт тозланган, ярка-ярка башлы кәбестә арасына кунакка дип әзерләп куелган симез каз күтиге дә юк!) хәтле мунчаның бөтен хасиятен, тулы ләззәтен һәм тәртибен аңлаган кеше дөнья йөзендә тагын бармы икән?! Юктыр, валлаһи, юктыр. Булмас та! Шул сәбәпле аларның кара мунчага тирән мәхәббәтен кыскача гына шушы язмаларда беркетеп калдырырга да кирәктер, шәт. Шуны да әйтик, мунча алар өчен юыну, чабыну урыны гына түгел, икесе ике җирдә хезмәт кылалар, теләгән минутларда гел-гел очрашып булмый, ә мунча аларның сер алыша торган, планнарны барлап, күңелләрне беркетеп куя торган яшертен эш бүлмәсе дә. Ашыгыч һәм яшертен йомышлар калыкса, алар шартлы сүзләр белән телефоннан хәбәрләшәләр дә (телефон шуннан бүтәнгә ярамый!) очрашалар, Идел ярындагы мунчада иң җаваплы кадрлар мәсьәләсе карала, шәһәрнең үсеше билгеләнә, тимер юллар тирәсендә бер-бер чатак чыкса, Иван Иванович Басыйр Бариевичны һәрчак йолып ала. Басыйр Бариевич яклаган кемнеңдер түшенә орден куна, кемнәрнеңдер буйсынмас башы балта астына куела...

Кыш дәвамында атна саен мунча яктыралар алар. Әнисә абыстайның биле кузгалган очракларда бу үтә җаваплы, аерата яшертен эш тимерьюлчыларның профсоюзын күп еллардан бирле җитәкләгән Исламнур дигән иптәшкә йөкләнә. Иван Иванович баштарак: «Исламнур?.. Уңайсыз ич, үзе дә дәрәҗәле иптәш»,— дип, шиген белдергән иде, Басыйр Бариевич, үз кандидатурасын күз алдына китереп, көлеп җибәрде.

Булса да булыр икән ярдәмчел, итагатьле, кешеләргә игътибарлы, кече күңелле татар баласы! Исламнурның бары тик яхшылык кына тулган киң күкрәгенә ике ел саен орден юкка гына элмиләр шул! Һич иренмәс, үз эше ник шунда кырык җирдә кырылып ятмый, бер сызгыруда килеп җитәр, ярты сүздән аңлар, комсызлыгы юк, кылган хезмәте өчен берни сорамас, берни көтмәс, иң мөһиме — күңеле киң, тирән, диңгездәй серләр сыя аның күңеленә! Сыя да бата. Мунча ягуның эчке тәртибен, нечкәлекләрен, миллекләрнең шифасын, хасиятләрен бөтен ваклыкларына тиклем белә, Казан арты төбәкләрен җәяүләп йөреп чыккан, Мари урманнарын туйганчы ботаган, өлкәннәрдән төпчегән, сорашкан, белгәнен яшерми, ялкауланмый, иренми, эшкә тотынса, сәгатьтән күзен алмый, яга, ташлар кызып сикергәләргә тотынганчы, сохаридай шылтырап торган каен яркаларын мич авызына өстәп тора. Суның салкынын, кайнарын бер взвод кычынган солдатка җитәрлек итеп ташый. Идәнне, сәкене, утыргычларны, ләүкә такталарын кыл мунчала белән ышкып кат-кат юа, берсе каен, берсе имән, берсе карлыган чыбыгыннан бәйләнгән мул яфраклы миллекләрне пешереп куя. Ә мунча алдына куелган ике суыткычта җаның ни тели, шул бар.

Суыткычлар да гади түгел, берсе — финнардан, икенчесе Алжирдан килгән. Шешәләр тартма-тартма кереп ипләнәләр. Эчемлекнең агы, гадәттә, җиде-сигез төрле, океан артыннан килгән «Смирнофф» дисеңме, «Алтын алка», «Посольская»лар — бар да бар. Кызылны санап торган юк, мәктәптә математикадан гел бишлегә укысаң да исәбенә чыга алмассың, эчмичә үк башыңа китәр! Чехлардан, юмарт финнардан, шведлардан килгән кырык төрле сыра банкалары, поляклар җибәргән чуар-чуар кәгазьле, матур бүксәле сыра шешәләре, яңгырлы җылы еллардагы гөмбәләр сыман, күз кызыктырып бер-берсенә сыенышканнар. Кызыл мәйданга Май парадына чыккан әфисәрләр диярсең!

Мунча көнен бәйрәм түгел дип кем әйтә ала? Юк, гади бәйрәм генә түгел, тиңсез олы дуслык тантанасы! Шешәләргә ямь биреп, карауга авыздан су китерә торган кара, кызыл икра банкаларын, тәрәч бавырын, крабларны да әйтсәң, хөрмәтле Иван Иванович белән Басыйр Бариевичның нинди бәхетле икәне, шәт, аңлашыладыр... Бу оҗмахка Исламнурдан да түбән дәрәҗәле берәүне кертеп җибәреп кара син... Бәла-казасын, гайбәт сүзләрен җыеп бетерә алмассың!

Һәрчак дуслар үз машиналарында, үзләре белгән юллардан шыпырт кына килеп төшәләр. Кочаклашып күрешәләр, бәйрәм белән котлашалар. Хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич бер дә кабаланмыйча, үз кадерләрен белеп чишенәләр, учлары белән корсакларын уып көлешәләр. Басыйр Бариевичның корсагы бер учка сыеп бетсә, Иван Ивановичның җилпучтай учлары бүксәнең җидедән бер өлешен генә сыйдыралар. Дуслар бер-бер артлы иркен, киң ләүкәгә үрмәлиләр. Хезмәткә гаярь Исламнур кызган ташка швед сырасы сибә, куе салат исле пар сулышны киңәйтә, аппетитны ача. Парга күмелгән кунаклар ләүкәдә ахылдашып яталар, Иван Иванович Азия кыйтгасы

хәтле урын биләсә, Басыйр Бариевичка Апеннин ярымутравы булып бөгәрләнергә туры килә. Дустың хакына ниләр генә кылмыйсың?! Бераздан пар сыегая, Исламнур кушканны көтеп тормый, көмеш подноска утыртып, кунакларның һәр икесенә мөлдерәтеп аракы, тустаганы белән чех сырасы алып кереп сона. Үзен дә мәхрүм итми, мунча ягып, су җылытып изрәгән тәненә көч, дәрт кайтсын өчен «Смирнофф»ны йотып куя, сыра банкасын ача.

Берзаман, сәгате суккач, ләүкә-җәннәттә пәри туе башлана: Иван Иванович белән Басыйр Бариевич алмаш-тилмәш чабынырга тотыналар. О-о, монда инде чыдап кына тор! Идәннән түшәмгәчә татлы пар бөтерелеп ургыла, басымга чыдый алмыйча ишек ачылып китә, ташлар, туйга җыелганнармыни, шарт-шорт бииләр, каен, имән яфраклары мина ярчыклары сыман сызгырып очалар, карлыган яфраклары чыбыктан кубып, чап-чап тәнне үбеп, ябышып калалар.

Чирек сәгать чамасы тоташ чабынганнан соң, хөрмәтле Иван Иванович белән Басыйр Бариевич, оҗмахтан куылган шайтаннар кеби, чабып чыгалар да куян тиреседәй ак кар көртләренә гөрс итеп кереп чумалар. Иван Иванович чумган тур чүмәлә дәүмәлеге калкып торса, Басыйр Бариевичны эзләсәң дә тиз таба алмассың: чума да югала! Бераздан дуслар калкыналар, бер-берсенең җилкәсен карлы йодрыклары белән төяләр. Иван Иванович дөмбәскә белән субай суккан тавышлар чыгара, Басыйр Бариевич сак — бала сөйгән сыман чәп-чәп итә.

Ике-өч минут карда кинәнгәч, кунаклар, нәселле юргалардай пошкырып, мунчага керәләр дә Исламнур парландырып куйган ләүкәгә сузылышып яталар. Профсоюзның мөхтәрәм вәкиле җитез: чүмеч арты чүмеч шау кайнар суны ташка сибеп җибәрә, пар бии, пар идәнгә ургыла, пар күзләрне сукырайта. «Җитәрме?» — дип сорый идәнгә сеңгән унган татар баласы. «Җитәр, җитәр!» — диләр ләүкәдәге гәүдәләр.

Иң тантаналы, көтелгән минут җитәр алдыннан Исламнур мунча алдына атылып чыга, бисмилласын әйтеп, ярты тустаган акны җиффәрә, озынча ташкабакка охшаган, пеләшләнә төшкән башына калын бүрек чәпи, кулларына йон бияләй кия һәм үзенә йөкләнгән иң почетлы эшкә керешә. Беренче нәүбәттә хөрмәтле Иван Ивановичны яратып әйләндерә-әйләндерә, миллекләрен алыштыра-алыштыра озаклап чаба. Ул чаба башлауга ләүкәдән очып төшеп идәнгә сеңгән хөрмәтле Басыйр Бариевич ах-ух килеп, көч биреп, дәртләндереп ята. Исламнур әүвәл миллеген затлы кешенең җилкәсенә тияр-тимәс кенә йөгертеп йөртә, тән тиресен пар белән йомшата, әзерли. Аннан тотына каезларга, киерелеп-киерелеп тукмый, миллек чыбыкларын тач май тәнгә батырып ышкый. Имәнне каен алыштыра, каенны — карлыган. Исламнур армый, талмый, мондый кадерле җилкә чокырын чапканда көчсез күренергә ярамый! Ниһаять, хөрмәтле Иван Ивановичның кура җиләгедәй кызарган центнерлы гәүдәсе карлыгач булып ләүкәдән очып төшә. Ул Исламнур сузган бер чапчак карлы-бозлы суны башыннан коя. Басыйр Бариевич хихылдап, калак сөякләрен уйнатып, аннан бушаган урынга менеп ята, куе парда кәшәкә юанлыгы, төк каплаган ботлары күренмәс хәлгә килә. Исламнур аны баягы нәүбәт белән чаба, имән миллеге белән кабыргасын төя. Тимерьюлчының кабыргалары майланмаган вагон тәгәрмәчләредәй шыгырдыйлар, умырткасы сынардай булып сыгылып-сыгылып ала. Басыйр Бариевичның бу җәзаны туктатасы, Исламнурны ләүкәдән куып төшерәсе килә. Ярамый! Дусты Иван Ивановичтан калышалармы соң! Түзә Басыйр Бариевичның җилкәсе, чыдый; ул үзе сөенгән булып чыркылдый, Иван Ивановичка ярарга тырышып ухылдый, мыркылдый. Ләүкәдән төшкәч, авыр чапчактагы суны Исламнур күтәреп коеп җибәрә. Тимерьюлчыларның дәһшәтле җитәкчесенең чапчак күтәрерлек хәле беткән, ул соңгы көчен җыеп, бар көченә «әлә-лә!» дип кычкырып, баскан урынында тыпырданып бии. Тагын чабыналар, тагын атылып тышка чыгалар, кызган гәүдәләр комсыз чуртандай атылып көрткә барып чумганда, куян мамыгы кебек йомшак кар «чож-ж!» итеп эри.

Урын аулак, иптәшләр үзебезнеке, дуслар ышанычлы, сый мул, үз кесәңнән түгел, мунча илаһи шәп, тормышның кадерен белеп, илгә, ил хуҗаларына рәхмәт укып яшә дә яшә генә! Мондый иркен, мондый бәхетле муллык ташып торган ил бармыни дөнья йөзендә?!

Ниһаять, кунаклар, калын-калын япон халатларын иңнәренә салып, кара-каршы утырышалар. Тантана дәвам итә, тантананың рәвеше генә үзгәрә. Бәллүр чәркәләрдә «Камю» коньягы язгы таңнардагы күк төсенә кереп балкый, бала күз яше кебек ап-ак «Алтын алка» аракысында сихри нурлар тирбәлә, сыра банкалары сыпылып кына ачылалар да, алардан татлы арпа, салатланган икмәк исе бөркелеп чыга. Бераздан Әнисә абыстай мунча алды ишеген сак кына шакый. Димәк, иң зур сыйга, әле генә мичтән чыккан каз бәлешенә чират җиткән. Әнисә абыстай ак ашъяулыкка биләнгән бәлешне Исламнурга тоттыра, «балам, берүк төшереп җибәрә күрмә!» дип инәлергә дә иренми. Төшерәме соң Исламнур бәлешне! Бәйрәмнең татлы таҗыннан хөрмәтле авызларны мәхрүм итәме?

... елның көтеп алынган ундүртенче гыйнварын алар шулай икәүдән-икәү генә, гомергә онытылмаслык итеп үткәрделәр.

Хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич Әнисә абыстайда кунак булуны «коммунизм мәктәбе» дип атыйлар һәм үзләренең бөтен кешедән дә алдарак коммунизмга чыгулары белән гаять горурланалар иде. Яз-көз, кырлар ачык чакта, җир өстенә кара төн иңгәндә, Иван Иванович белән Басыйр Бариевич Әнисә абыстайның каз симертә торган биләмәләренә дә чыгып керәләр. Тимер

юлның Идел ягында буйдан-буйга урман кишәрлеге сузылган. Моннан кырык еллар элек утыртылган имәннәр, каен-юкәләр белән ярыша-ярыша үсеп, күтәрелеп киткәннәр, нygыганнар. Маңгай утларын ялтыратып әледән-әле үтеп киткән поездлардан бу як, Әнисә абыстайның җәй-көз каз көтә торган иркен биләмәләре бөтенләй күренми. Иван Иванович килгән саен: «Басыйр Бариевич, күр, кара бу имән агачларына! Без дә бу җирнең имәннәре!» — дип әйтергә ярата. «Имәннәрдәй озын гомерле булырга язсын безгә!» — дип, Басыйр Бариевич аны куәтләп куя. Урман белән авыл арасындагы кыр кайчандыр совхозныкы иде. Көнбагыш чәчеп карадылар, яшелчә үстереп маташтылар да, рәт чыкмагач, сый күрсәтмәгән кысыр кырны калдау калдырдылар. Сөрелмәгән-чәчелмәгән җир хуҗасыз байтак ятты-ятты да куе үлән, әрем-билчән белән капланды. Руслар каз асрарга яратмый, алар аның әмәлен дә, тәмен дә белмиләр. Әнисә абыстайга мач килде, элгәре бер оя асрый иде, соңгы өч елда ике ана калдыра, уңа да...

Бүген, бәйрәмнән кәефләнеп, икесе ике машинада тирбәлеп кайтырга чыккач, ак кар астында яткан караңгы кыр уртасында машинасын туктатып, Иван Иванович Басыйр Бариевичка борылып эндәште:

— Бу кырларны читләрдән сакла, әниең алпавыт, җир били, шулай булып калсын да!..

Машиналар Казан юлына төштеләр...

Дөньяның вак ыгы-зыгыларыннан азат ике дус: Җир шарында Нәҗип Йосыф улы Нургалиев яшәп ятадыр, ул менә нәкъ шушы кичтә йөрәге кагып егылгандыр дип уйлап та карамыйлар иде. Кыскасы, алар аны белмиләр дә иде.

Язмыш — аяусыз нәрсә. Ул бер-берсен бөтенләй белмәгән, белә дә алмаган җаннарның язмышын да чәлмәштереп ялгый, адәм уллары янәшә юллардан баралар, баралар да, берзаман аларның язмышлары кисешеп куя. Хәер, үндүртенче гыйнвар кичен бу затларның юл башы дип билгелик тә Нәҗип Йосыф улы Нургалиев янына кайтыйк.

**3**

Башта «инсульт» диделәр. Ныклабрак карагач, «инфаркт булмагае» дип шикләнделәр. Больницада як-яктан, эчтән-тыштан тикшергәч: «Инсульт юк, инфаркт булмаган, мәгәр организмы нык таушалган, тегесенең дә, бусының да булу ихтималы бик мөмкин»,— дип, Нәҗипне йөрәкләре удар алганнар палатасына салдылар. Мөнир Якупов Казанга, Наиләгә хәбәр итте. Наилә ике улын, Искәндәр белән Рөстәмне, Казан арты бабаларына кайтарды да алтынчы көн дигәндә ире янына килеп җитте.

Реанимация палатасыннан күчерсәләр дә, Нәҗип янына бик авырлык белән генә керттеләр Наиләне: «Дулкынландырмаска, күп сөйләшмәскә, озак юанмаска, әйберкара бирмәскә!» — дип кат-кат кисәттеләр.

Һәрберсенең караваты пәрдә белән аерылып куелса да, ярым караңгы палатага килеп кергәч, Наилә анда дүрт кеше ятуын да, Нәҗибенең нәкъ ишек каршысына урнашуын да чамалап алды. Дүрт кеше авыр тынлыкта дүртесе тиң караватларына сеңгәннәр иде. Нәҗип Наиләнең кергәнен аермады, ул чалкан ятып, ярым ачык күзләре белән билгесез бер ноктага туктап онытылган иде... Наилә Нәҗипне танымады. Шушы зәгыйфь, көчсез гәүдәме аның арысландай ыргылып торган ире? Бик күп егетләр арасыннан атылып килеп чыгып Наиләне бер сүзе, ымы, ишарәләре белән үзенә караткан бөркет шушымы?.. «Мин бүген яшәмим әле, мин алга карыйм, сине дә үзем белән матур киләчәккә, беркем татымаган ләззәт дөньясына дәшәм!» дип, кыз күңелен шаштырган җан шушымы? Аны кочкан, аның һәр буынын иркәләгән, һәр тере күзәнәген эзләп тапкан, мәхәббәт көймәсенә яткырып, кызлык чорыннан хатынлыкка алып чыга белгән куллар хәзер атылган кош канатлары кебек җансыз гәүдә янәшәсенә сузылганнар. Шул куллармы бу? Моңарчы җил-давылларга бирешмәгән корыч калкан кебек нык күкрәктән бүген чак ишетерлек сулыш чыга. Бетүеме бу Нәҗипнең?! Биргән вәгъдәләрең үтәлмәгән, кат-кат ныгытылган антлар тормышка ашмаган, өмет агачы тамырларын тирәнгә җибәреп, ботаклары белән күкләргә үрләмәгән...

«Ни булды сиңа, җаным?!»

Ул иренең күкрәгенә килеп капланды, җылы хисләре, сүнмәс дәрте, татлы тыны белән аңа көч өрергә, дәрт бирергә исәпләдеме, — озак кына аерыла алмыйча торды. Аны палатага озата кергән кизү врач арттан, аның күлмәк итәгеннән тартты, ым белән артсыз урындыкка утырырга кушты, иреннәрен чак кыймылдатып: «Саграк!» — дип пышылдады.

Алар пәрдә эчендә калдылар. Менә Нәҗип елмайгандай итте, ияге селкенде, ул күзләре белән хатынына иелергә кушты. Наилә аның кан качкан шыксыз иреннәренә колагын куйды. Нәҗип өзеп-өзеп бер җыр әйтте: «Ай-һай, дөнья, туйдым синнән... син дә туйгансың миннән! Шушы яшьләремә җитеп, ни рәхәт күрдем синнән?!» Наилә, кайнарланып, ачы күз яшьләренә буылып, тончыгып, тагын шул сүзләрен кабатлады: «Ни булды сиңа, җаным? Ничек төштең бу хәлгә? Бу көннәргә ник килеп җиттең?!»

Сөйләшергә ярамый иде, Нәҗипнең чынлап торып сөйләшер хәле дә калмаган иде, сөйләр сүзе дә юк кебек иде аның, көчсезлектән мескен булып калган учы Наиләнең тирләгән, кайнар учы белән очрашкач, ул тирән итеп бер көрсенде, телен чыгарып өске иренен ялады...

Әти-әнисе аны авылдан бер дә җибәрергә теләмәде, бригадир ярдәмчесе булып йөри башлаган Сабит абыйсын өлгегә алдылар да «китәм!» дигән авызын томаладылар. «Күр абыеңны, йомылып эшләп йөри. Басымчак, сүз тыңлаучан. Боерган булса, бригадир булып та китәр. Печәнгә, курмыга тиенербез. Син дә калхузда калсаң, нужадан котылырбыз. Каралты-кура йончыган, аларны рәтләрбез. Абыең башлы-күзле булса, мунча салырбыз. Бездән икегез дә артмассыз. Без — авыл кабартмалары, кара сөяк; укып мулла, чукып карга буласың юк, ике аягыңның берсен атлама!» — дип, үсмер егетнең күзен ачырмадылар. Ялындылар, ялвардылар, тәмле тел белән тыңлата алмагач, рәнҗеделәр, юлына хәер-фатиха бирмәделәр. Авылның һәр атламына килеп кысыла торган алап авыз Талия карчык: «Йөрсен, йөрсен! Выжлап ачка койрык чәнчеп кайтыр, күрегез дә торыгыз. Ата-ана фатихасыннан йөз чөергән бәндәнең уңганы юк әле!» — дип, учын әйләндереп каргап озатты егетне.

Нәҗип авылдан «киребеткән, алты-бишь, карама бүкәне» дигән кушаматлар ияртеп чыгып китте. Черешкәне өчен Сабит абыйсыннан аңа нык ук эләкте...

Китте егет, бәхетсезлегенә каршы, институтка үтә алмады. Авылга кайтып күренмәде, гарьләнде. Озын-озак уйламады, тотты да нәни генә механика заводының тимерчелегенә чүкеч сугучы булып керде. Эш бер сменалы, акча ару гына төшә, егетнең көче ташып торган чак. Озакламый тулай торактан урын бирделәр. Ел эшләде Нәҗип, ике ел, алдагы ике елын армиядә үткәрде, кайткач университетка укырга керде, кичкелеккә. «Эшче, солдат!» — дип, аны күтәреп алдылар. Беренче курсны тәмамлады, авылга кайтмады, икене бетерде, кайтмады, өс-башны бөтәйтәм дип пристаньда әртилгә керде. «Күрсәтермен мин сезгә алты-бишне!» — дип, авылы ягына шактый ныгыган йодрыгын күрсәтте.

Шунда тулай торакта яшәп яткан Казан арты кызы Наиләгә өйләнде.

Көзгә яңадан тимерлеккә кайтты, укуын дәвам итте. Кыш уртасында аның белән әртилдә эшләгән егетләрне кулга алдылар. Иптәш-юлдашлары Нәҗипкә сиздермичә генә шактый кара эшләр кыйратканнар икән, шул калкып чыкты. Нәҗипкә кагылмадылар, гаебе юк иде. Мәгәр милициягә чакыртып, прокурорга йөртеп, кат-кат судка чакырып теңкәсенә тиделәр. «Заводтан ял алып эшләп йөрдем, аны-моны белмим, күргәнем юк!» — дип чатнап торды егет. Заводта һәркем исәпле, шигәйделәр, бәйләнергә сәбәпләр чыгып торды. Тимер чүкүче эштән китеп тора икән, алмашың юк, чүкечең тик тора, цехлардан килгән заказлар үтәлми, бер бирделәр егеткә шелтәне, икене, гарьчел Нәҗип түзмәде: «Әһә! — диде. — Төкерәм мин сезгә!»

Авыр эштән ялыккан да иде, көне буе тимер тапаганнан соң университетның физика факультетында уку җиңелдән түгел. Көн азагына ми кайный, җилкәгә һәм күкрәккә кургаш калканнар асылына.

Эш — акча ул. Эшең юк икән, кесә тиз такырая. Нәҗипнең маясы тиз эреде, нәкъ шул көннәрдә Наиләсе бүләккә малай алып кайтты. «Тилеме әллә сез?» — дип бот чапты күргән-белгәннәр. Нәҗип укый, курс эшләрен тапшыра, ә акча юк. Наилә декретта, ары-бире талпынды да ир-ат яши торган бүлмәләрне җыештыручы булып ялланды. Ир сүзен сүз итеп институтын ташлаган иде. Завод китапханәсендә дә эшләп йөрде, мәгәр китапханәченең акчасы... Тфү!

«Түзик! — диде аңа ире, тешен кысып. — Түзик! Укып кына бетерим, дөньясын учымда биетермен!»

Аларны торактан куа башладылар. Ялынмады Нәҗип, инәлмәде, хатынын, имчәк баласы Искәндәрне алып чыгып китте дә урам себерүче булып ялланды. «Бөек кешеләрнең язмышы урам себерүдән, табак-савыт юудан башланган!» — диде ул, көлә-көлә.

Наилә, моңарчы ирен Алла итеп санаган сүзсез-өнсез хатын, бу юлы көлмәде...

Урам себерүче Нәҗип Нургалиевкә сүтәргә билгеләнгән өч катлы йортның беренче катыннан, ишеге ачылган саен суык болыты бөркелеп керә торган почмактан, бүлмә бирделәр. Бүлмә гади түгел — таракан, кыргаяк һәм сычканнар оясы иде.

«Кайт заводка!» — дип инәлде Наилә. «Юк! Илдә чыпчык үлми», — дип карышты ире. «Чыпчык булып калдык-постык чүпләп йөрергә риза була торган затмы соң син?!»

Наилә кемгә, нинди кияүгә тап булуын шәйли башлаган иде. «Күрәчәгең булса, күркә талап үтерер!» Беркөн кичкырын, үзе вакытлыча хуҗа булып алган урамны себереп маташканда, Нәҗипкә исеме белән атап кемдер эндәште: «Нәҗип авылдаш!» Күтәрелеп караса — Вәдүт! Яшьтәше. Райком секретаре. Нәҗип сер бирмәде, шакмаклы дәү картузын батырып киде дә читкә борылып танавын сеңгерде. «Кемгә дәшәсез? Я вас не знаю!» — дип, себеркесен култык астына кыстырып, утын сарайлары арасына кереп югалды. Моннан ары урамда күренеп йөрергә ярамый иде. Нәҗип эш эзләргә тотынды.

Кулай эш табу җиңел түгел, беренче карашка гына ул бөтен почмакларга игъланнар эленгән: «Килегез! Күрегез! Урнашыгыз!» Бара башлыйсың, йә ул өч сменалы, йә анда махсус белем, әзерлек сорала, сабы килсә, җәбе килми, җәбе килсә, сабы ярамый! Айга якын җайлы эш эзләде Нәҗип, тапмады, акча бетте, фатирдан куа башладылар.

Көймә комга терәлде.

Наиләнең туганнан туышкан абзасы бар иде шәһәрдә — Фәтхулла абыйсы, промбазада ниндидер мөдир булып эшли. Урыны тып-тын, базасы дәү түгел, нәни генә предприятиенеке, беркөнне, ютәл белән интеккән Искәндәрне чырылдатып, борын тишекләренә куык элеп, парлашып Фәтхуллаларга барып керделәр. Өч көн ашаганнары юк иде, «Ичмасам, сыйланып кайтырбыз!» — диде Наилә.

Әлегә аның ирен әрләп сүз дә ычкындырганы юк иде.

Асты кирпеч, өсте нарат бүрәнәдән, үз йортлары белән тереклек итеп яталар тегеләр. Тимер капка, капка төбендә үк ике эт, берсе — медалист, доберман пинчер, икенчесе — овчарка. Өрмиләр, яшькелт күзләре ут булып яна, хуҗа ымласа, өзгәләп ташлаячаклар.

Борыннары сизгән икән, табын өстенә туры килделәр Нәҗип белән Наилә: Миңсылу апалары аларны икенче катка, залга, кунаклар янына өндәде. Наилә, читенсенеп, апа янында калды, Нәҗип кыенсынып кына өскә менде. Урам себергәндә тотылганнан бирле егетнең кикриге шиңебрәк йөри иде.

Хуҗалар симертеп тана суйганнар икән, сугым ашына кунак дәшкәннәр, табын тирәсендә Фәтхулланың үзе төсле үк елгыр, үзе кебек үк тук, затлы киенгән өч ир утырышканнар иде. Тавышларының көр, чырайларының канәгать булуыннан Нәҗип кунакларның инде шактыйдан утырганнарын абайлады. Фәтхулла абыйсы аны гадәттәгедән зурлап, баш орып каршылады, утырдашларына: «Университет шәкерте! Галим! Көне килгәч, мәртәбәле зат булыр, танып калыгыз, онытмагыз!» — дип таныштырды. Тегеләр: «Бәрәкалла, дөньяда йомыш төшмәгән кеше буламы? Онытмабыз!» — дип, куен кесәләреннән алтын каләмле ручкалар, бәрхет тышлы дәфтәрләр чыгарып, егетнең исем-фамилиясен теркәп куйдылар. Адресы, телефоны, эш урыны юк иде егетнең, ул тиргә батып утырганда, Фәтхулла абыйсы бусын тиз көйләде: «Шушы арада һәммәсе булырга тиеш, ачыклагач өстәмә хәбәр итәрмен»,— диде.

Себерке коллыгыннан әлерәк котылган Нәҗипнең Фәтхулла абыйсын кочаклап җылыйсы килде, күптәннән җылы сүз ишетмәгән җан эреп китте. Фәтхулла алтын путалы чәркәләргә юмарт итеп аракы койды. Кунаклар, сүз берләшкәндәй: «Яшь иптәшнең алдагы мул, кайгысыз тормышы өчен!» — дип уртлап куйдылар. Шешә бушады, яңасы килде, табактагы калҗалар мартта яуган кар таулары кебек тиз-тиз эреде. Фәтхулланың дуслары тамакка таза икән. Нәҗип тә сынатмады, симез-симез калҗаларны тозга мана-мана бөкте генә!

Күптән аракыдан авыз иткәне юк иде аның, тиз исерде, беренче чәркәдән үк башына китте, ул бик бирелеп кунакларның әңгәмәсен тыңлап караса да, ни сөйләшкәннәрен аңламады. Алар татарча сөйләшәләр дә кебек, татарча да түгел, табындашлар ярты сүздән, ым-ишарәдән бер-берсен аңлыйлар, йә көлеп җибәрәләр, йә, чырайларын бозып, кемнәргәдер яныйлар да шикелле иде. Димәк, болар һәммәсе дә күптән төйнәлгән борынгы дуслар. Тора-бара бу мәҗлес кызыксыз һәм мәгънәсез тоела башлады, карын туйды. Нәҗип: «Эш табыгыз миңа, хөрмәтлеләр, кулай эш!» — дип чүт кычкырып салмады. Исереклеген сиздермәскә тырышып, утырган урындыгына ике кулы белән чытырдатып ябышты.

Кунаклар озак юанмады, тиз-тиз эреп таралдылар, тимер капка артында машиналар тавышы ишетелеп калды, Фәтхулла абзыйсының кунакларны озата чыкмавы гына исендә калды Нәҗипнең.

Ялгыз калдылар. «Йә, сөйлә, нинди нужа китерде сине безнең катка?» — дип сорады Фәтхулла абзыйсы, егетнең элегрәк үзеннән читтәрәк йөрергә яратканына кинаяләп. Нәҗип чишелеп китүен сизми дә калды. Фәтхулла текә маңгаен җыерып тыңлады, җавабы катгый һәм кыска булды: «Тапкан каушарлык хәл!.. Муены булса, камыты табылыр! Бер елдан пенсиягә чыгам, алтмышым тула. Бүгеннән ярдәмче итеп алам да үз урыныма калдырам». Нәҗипнең уе болганган иде, абзасын аңлап бетермәде: «Минме? Физик башым белән?.. Промбазада мөдирме?» Ул, ялварып, адашкан көчек кебек, күзен мөлдерәтеп, мәрхәмәтле абзасына карады. Фәтхулла үпкәләмәде, көлеп куйды. «Кунакларны күрдеңме? Кемнәр дип калдың инде син аларны? Торгашлар дип белдеңме?» «Белмим», — диде ныграк каушап Нәҗип. «Берсе — очкычлар ясаучы берләшмәнең директор урынбасары.— Фәтхулланың саллы алтын балдак белән авырайган симез бармагы һава сөзде.— Икенчесе — финанс институтының хуҗалык эшләре буенча проректоры. Өченчесе исә, өченчесе... Анысын кичкырын әйтергә ярамый: Черек күл буеннан!»

Нәҗип кинәт айнып китте.

«Университет дипломы белән син мондый кәттә кешеләр арасына керерсеңме, юкмы, — әйтә алмыйм, теләсәң, кулымда көч барында, замана безнеке чагында, мин сине шулар арасына ныклап

урнаштырам». Нәҗипнең тагын елыйсы килеп китте. «Әллә кай төшеңне яраттым!» — диде Фәтхулла, аларны озатканда. Балалары юк иде Фәтхулла белән Миңсылуның.

«Ә мин Миңсылу ападан әҗәткә өч йөз сум алдым»,— диде Наилә, трамвайга кереп утыргач. Искәндәр сүзсез генә прәннек кимерде. Нәҗип дәшмәде, күңеленнән генә кемнәргә күпме бурычы булуын санап барды. Санады, очына чыга алмады. Трамвайдан төшкәч, телгә килде: «Килер бер көн, — диде ул, билгесез киләчәккә йодрык күрсәтеп, — безнең урамда да бәйрәм булыр!»

Тук карыннан ваемсызланган Наилә иренә шикләнеп һәм ышанмыйчарак карады, дәшмәде.

Бәргәләнә торгач, анда-монда сугылып тәмам сөмсере коелган Нәҗип мебель кибетенә грузчик булып эшкә керде. Теге чакта пристаньда әртилдә бергә эшләгән шадра Вафаны очраткан иде, Нәҗипнең хәл-әхвәлләре белән танышкач, Вафа кычкырып җибәрде: «Кил үзебезгә, урнаштырам. Ну, парин, судта егетлек күрсәттең. Мәңге онытмам!» «Мин берни белми идем ич!» — диде гаҗәпсенеп Нәҗип. Шадра бармак янады: «Белмәгән ди! Тунадык без анда баржаларны. Ә син сатмадың. Синең белән утка-суга кереп була!»

Бер кыш шунда үтте. Күнеккән эш җайлы диярлек. Әле Казанда йортлар тәбәнәк, тимер чүкеп ныгыган беләкләргә нәрсә ул шкаф-көзгеләрне дүртенче, бишенче катка менгерү?! Кулдан-кулга очыртып кына йөртәләр. Хуҗалар белән Вафа чыш-пыш сөйләшә, акчаны да ул ала, фокусникмыни, тырышып-тырышып күзәткәләсә дә, Нәҗипнең күзе иярми дә кала. Шадра эшне оста йөртә, җеге җеккә сеңеп утыра!

Нәҗипнең риясызлыгын, авыллыгы чыгып бетмәвен аңлагач, Вафа салган баштан ачылып китте: «Биш мең сәмәнең булса, ике бүлмәле квартирны мин сиңа момент табам!» — диде. «Биш мең? Син миннән: «Күпме бурычың бар?» — дип сора». Вафа егылып көлде, ышанмады, бармагын янады. «Ну, син! Беләм! Кыланып күрсәтәсең инде!»

Бер җәһәттән нык булды Нәҗип, укуын ташламады, имтиханнарын вакытында бирде, контроль эшләрен соңлатмады, укыды.

Мебель кибетеннән китәргә кирәклеген аңа кадрлар бүлеге түгел, шадра Вафа җиткерде. «Сине эшкә мин чакырдым,— диде ул,— мин сиңа китәргә дә кушам». «Нигә?» — диде бик аптырап Нәҗип. Вак-төяк бурычлардан котыла башлаган көн иде. «Иптәшләр синнән шикләнә».— «Ник шикләнәләр?» — диде кинәт боегып Нәҗип. Вафа башын чайкады: «Аракы эчмисең, акчаның ни икәнен белмисең». «Эчәргә вакыт юк, эштән соң кая барып йөргәнне беләсез ич!» — диде Нәҗип, рәнҗеп һәм кызып. «Безгә укыган кеше кирәкми, диләр. Укыган кеше — шикле ул, һич уйламаганда таралып китүе бар. Бер елың калдымы?» — «Ел ярым»,— диде авырыксынып Нәҗип. «Ту-ты,— диде Вафа,— диплом алгач, сине кая аткаралар? Мужыт, милициягә? Мужыт, прокурор янына?» Нәҗип көлеп җибәрде: «Юкка шүрлисез, физик мин. Заводка урнашам». Шадраны аударып булмады, ул кисте дә куйды: «Китәсең дигәч китәсең!»

Гыйнвар азагында Наилә тагын бер йомры башлы малай алып кайтты, исемен Рөстәм дип куштылар. Таныш-белешләр аларга шикләнеп карады: акылдан шашканмы әллә бу Нургалиевләр? Кеше өстендә торалар, Нәҗипнең төпле эш урыны юк, фатирлары кайчан була? Бала артыннан бала ташыйлар!

Артта да сүз йөрттеләр, күз алларында да «җүләрләр!» дип атадылар.

Наилә беренче тапкыр елый-елый, маңгаен как өстәлгә бәрә-бәрә зарланды: «Туйдым бу тормыштан! Тәмам гарык!» Нәҗип, очына-очына, хатынының иңбашларын сөя-сыйпый, аны юатты: «Диплом керсен кулга. Диплом — без көткән оҗмах ишегенә ачкыч! Платон Платонович мине ярата, кафедрада эшкә калдыра. Күр дә тор, профессор булачакмын. Университет ректоры җәмәгате булуыңны көт тә тор!»

Наилә тынычлангандай кыланды, әмма иренә бөртек тә ышанмады. Олы малайны, ташбаш Искәндәрне, Казан артына, бабаларына илтеп куйдылар. Тамаксау булды бала, тавык ите ярата, алма-грушалар сорый... Әйдә, бабаларында бераз тамак үткәрсен әле!

Платон Платонович Захарчук Нәҗипнең кафедра мөдире иде. Озын буйлы, чөй сакаллы какча кеше, эре бөртекле кашлары күз читенә таба ишелеп төшкән. Карт булса да, тешләре ап-ак, моны белгән Захарчук сөйләшкәндә вакыт-вакыт авызын ерып куярга ярата иде. «Кафедрада каласың, Нәҗип Йосыпович», — диде ул кыш уртасында. «Платон Платонович Нургалиевне калдыра икән» дигән хәбәр шунда ук таралып өлгерде. Бергә укыган студентлар икегә бүленде: берәүләр эчкерсез котладылар, икенчеләрнең көнчелектән борыннары салынды, алар ачыктан-ачык дошманга әйләнделәр. Дөнья таный башлаган Нәҗип моны бу юлы бик дөрес аңлады.

Захарчук икәүдән-икәү генә сөйләшкәндә: «Лабораториядә, кафедрада калдырам. Тема аласың. Җиң сызганып диссертациягә тотынасың», — дип ычкындырды. Бу яңалыкны Нәҗип берәүгә дә, хәтта Наиләсенә дә әйтмәде!.. Атаклы профессорның шәкерте булып йөргәндә, дошманнарның шактый булачагын акылы исәйгән Нәҗип хәзер белә иде инде.

Диплом якларга атна калды дигәндә Платон Платонович Нәҗипне дачасына чакырды. «Вакытың булырмы?» — дип сорады. Остазы чакырганда вакыт тапмыймы соң Нәҗип?! «Язын анда вак-төяк эш табыла», — диде ак тешләрен җемелдәтеп профессор.

Поезддан төшкәч тә ул бакчаны бик тиз эзләп тапты. Платон Платонович: «Мин кичтән үк барып кунам, сиңа эш әзерли торам»,— дигән иде. Платон Платоновичның бакча йорты бүтәннәрнекеннән нык аерыла, шактый юан бүрәнәләрдән биек итеп салынган, такта верандасы да иркен, куе яшелгә буялган. Йортның ике кыегына эленгән ике оядан алмаш-тилмәш сыерчыклар очып чыгып, хуҗаларның табигать җанлы икәнен дөньяга чәчәләр. Йортның ишеге, хуҗаларның күңеле киңлеген раслап, киерелеп ачылган, морҗасыннан каен тузы янган тәмле ис таратып юаш кына төтен чыга. Нигәдер шигәебрәк атлаган Нәҗипнең күңеле бердән тынычланды. Бөтен җирдә — ком сибелгән сукмакларда, яшел яфраклар белән бизәлгән җимеш агачларында, тәбәнәк рәшәткәле коймаларда яз исе, яңарыш, уяныш исе.

Ул ачык ишектән сәлам биреп кергәндә, верандада ике кеше бар иде. Берсе профессорның үзе, икенчесе йөз чалымнары белән аңа охшаган, буй-сыны белән дә аңа тартым, озын куе чәчле, өске ирене тирәсенә юка төк йөгергән, олы күзле кызмы, хатынмы тагын берәү бар иде. Хуҗа да, ят хатын-кыз да аны гадәттән тыш җылы каршыладылар. «Чәче ат кылы сыман катыдыр моның?» — дип, үз-үзенә гаҗәпләнеп уйлады Нәҗип. Кафедраның котын алып торган Захарчук бүген тәкъва, юаш һәм диндар мәчет картына охшап калган иде. Баш түбәсенә чәпәп куйган мөселманча кара түбәтәй аңа килешеп тора һәм кырыслыгын җуеп, мөлаемлык, сөйкемлелек өстәгән иде. Аны-моны сорашкалап, ары-бире бер-ике сүз алышкач, чишендереп, кулын юдырып, аны җылы йөгергән эчке якка, залга чакырдылар.

Залда табын әзерләнгән икән. Табынның дача өчен мул һәм искиткеч зәвыгын Нәҗип бер карауда шәйләп алды. Аңа, моңарчы тамагын да юньләп туйдыра алмаган ир-атка, табын да, олы күзләре белән аны туктаусыз капшаган озын ханым да ошамады. «Чишендерәме әллә бу мине?» — дип уйлады ул кинәт, һәм бу ямьсез уй, шул ямьсез уй тудырган авыр тойгы күңеленнән һич китмәде. «Ат кылыдыр моның чәче!» — дип уйлады ул, тагын да ныграк борчылып. Уйларыннан качар өчен сүз сөрешен эшкә борды. Платон Платонович тешен елтыратып мактанып алгач, озак кына сөйләп ташлады: «Эшләргә өлгерербез! Көн озын! Менә Галинаның нигъмәтләреннән авыз итик, кызым бу минем, Нәҗип Йосыпович, бердәнберем, әнисе вафатына унике ел, шул гомер эчендә ул мине тәрбия итте. Ходай Тәгалә ул бирмәде! Кем улдан, кем кыздан уңа дигәндәй, гомерем белән мин кызыма бурычлы! Бакчага чакырдым чакыруын, ә монда төп хуҗа — Галина. Без ни, картлар, бүген бар, иртәгә юк. Галина минем бердәнбер варисым. Хәзер мин монда кунак кына. Ризыгын татып карыйк, Нәҗип Йосыпович, аннан эшне сезгә Галина табачак!»

Әтисенең шактый озынга сузылган сүзен Галина басынкы гына тыңлап торды, катышмады. Нәҗип профессорның һәр сүзеннән эчке мәгънә эзләштереп, аның әле күтәрелеп киткән, әле күз яшьләренә манчылып моңсуланган тавышыннан үзенең җайсыз бер хәлгә тап булуын чамалый башлады. Тел төбе чамадан тыш татлы һәм куркыныч дәрәҗәдә йомшак иде Платон Платоновичның. Мондый тел ярарга тырышканда яки яучыларда гына була.

Галина, вак-вак атлап, фарфор савыт алып керде, бүлмәгә ашказанын котыртып пилмән исе таралды. Тәбәнәк, киң чәркәләргә коньяк коеп, бер-икене йотып куйдылар. Ашарга өзмәс кыстасалар да, эчәргә Нәҗипне өндәүче булмады. Аштан соң, болай, сүз дөреслеге өчен генә бакчага чыктылар. Бер тәрәзәнең наличнигы какшаган икән, шуны каккан булдылар. Нигез тирәләренә ике чиләк ком сипкәч, эш бетеп тә куйды. Захарчук үзе бер читтәрәк булашты, Галина, юка иреннәрен бөреп, чытлыкланып, гел Нәҗип янында уралды, чүкеч алып килде, кадак сайлашты.

Гел юк-бар белән маташып гаҗиз булган Нәҗип төшке чәйдән соң китәргә җыенды, «хатын, балалар көтә» диде.

«Хатын, бала-чагалар» дигәч, Платон Платонович белән Галина бер-берсенә сәер генә карашып алдылар. Нәҗипнең баядан бирле күңелен кырып торган шиге көчәйде. Нигә әле ата кеше аны кызы белән ялгыз калдырырга тырыша? Сүз арасында гына Галина үзенең кияүдә булганын, ирдән уңмаганлыгын, аның көне-төне эчеп тәмам юлдан язганын сөйләп үткән иде инде. Галина белән киявенең ике арадагы низаглары шәһәргә саркып чыккан иде. Нәҗипнең дә бу хакта нидер ишеткәне булган икән, сөйләшә торгач, ул шул гайбәтләрне хәтерләде. Ялгышмаса, Платон Платоновичның кызы гаять холыксыз, тупас һәм усал нәмәрсә дип сөйләгәннәр иде. «Шушы кешене миңа сыламакчы буламы әллә бу карт бүре?» дип уйлады Нәҗип һәм остазын «бүре» дип атаганын абайламый да калды.

Галинаның шома битенә саубуллашканда вак-вак җыерчыклар кунган иде. Ул Нәҗипкә ике бармагын гына бирде дә кырт борылып йортка кереп китте. Платон Платонович аны бакча капкасына хәтле озата барды. Ябык капкага барып җиткәч кенә: «Сез, Нәҗип Йосыпович, өйләнгән кеше икәнсез»,— диде. «Ике балам бар!» — «Шактый йомык икәнсез, белмәгән идем».— «Нигә йомык?» — «Бер дә үз тормышыгызны сөйләгәнегез булмады». Нәҗип көлемсерәде. Ниен сөйлисең? Акчасыз, фатирсыз, эшсез җәфа чиккәннәрен чәчеп йөрсенме? Серен ачсынмы? Белми калсыннар әле!

Платон Платонович артыгын төпченмәде, сөякчел бармаклары белән Нәҗипнең кулын кыскандай итте дә, кармак сабы кебек озын, нәзек сынын туп-туры тотып, үрә катып кайтып китте.

Диплом якланды, комиссия әгъзалары Нургалиевне тоташ мактадылар, «кич укып мондый уңышларга талант кына ирешә ала!» диделәр, «хезмәт һичшиксез кандидатлык диссертациясенә нигез була ала» диде күрше институттан килгән вәкил Захаров.

Остазына тулы өмет баглаган Нәҗип Йосыф улы Нургалиев ирекле диплом алып чыккан иде.

Мөнәсәбәтләр көтелмәгән якка борылды. Ул, Платон Платоновичны сагалап, кафедра ишеге тирәсен байтак саклады, ниһаять, очраштылар. «Мин яңа кафедра ачуны күздә тоткан идем, министрлыктан җавап алдык, ул эш барып чыкмаслыгын хәбәр иттеләр. Кызганыч»,— диде ул, Нәҗипкә кырын күзен дә төшермичә. Нәҗип, кылган яхшылыклары өчен остазына рәхмәт әйтеп, Юрий Петрович Захаров янына ашыкты. Доцент Захаров урыныннан торып, хөрмәтләп каршы алды. Кул бирде. «А как же! Хәтерлим! Дипломыгыз сокланырлык иде. Сезгә шул юнәлештә эшләргә кирәк, эшләргә!» Нәҗип читенсенеп кенә рәхмәт әйтте һәм бүгенгә үзенең эшсез калуын белдерде. Захаровның алтын кысалы күзлеге төшеп китә язды. «Ә Платон Платонович?» — дип сорады ул, төкселәнеп. «Аның белән борчагыбыз пешмәде», — диде һаман хәйләгә остармаган Нургалиев. Юрий Петровичның алтын кысалы күзлеге калтыранган бармаклары арасына күчте, ул ияген алга чөеп, шытырдатып кашып алды.

«Ышанмыйм, сез талантлы егет. Киләчәктә сездән шәп белгеч чыгуы бик ихтимал,— диде Юрий Петрович, урынлы-урынсыз тамагын кыргалап,— тик шунысы бар: шәһәребезнең абруйлы, иң күркәм галиме белән борчак пешерә алмаган яшь иптәш минем белән пешерер дип уйлыйсызмы?» — «Эшләп карыйк, Юрий Петрович! — диде гади генә итеп Нәҗип.— Мин белештем: сезнең кияүдән кайткан кызыгыз юк икән!» — дип шаяртырга теләде. Захаров боргаланып-сыргаланып тормады: «Платон Платонович белән арамны бозасым килми!» — дип ярып салды.

Кылган мәрхәмәте, туры әйтүе өчен аңа да рәхмәт әләкте. Нәҗип Захаров янына әвене янып кергән иде, балтасын суга төшереп чыгып китте. Фәнни тикшеренү институтларын йөреп чыкты, төрле оешмаларга кагылды, профиле туры килердәй берләшмәләргә керде. Кай ишеккә кагылмасын, Платон Платонович исеме калкып, Нәҗип Нургалиев бар җирдән дә тартәсен кире борды. Беркем аның укымышы, әзерлеге, белеме белән кызыксынмады, һәр очраган кеше остазы белән арасы бозылуының сәбәбен белергә теләде. Захарчук кадәр Захарчук кызы өчен шулай әчелешле булып йөрмәс инде, остаз белән шәкерт арасын, бәлки, бүтән сәбәпләр бозгандыр? Ул дөресен әйтмәде, дөресен сөйләмәгәч, бар җирдә дә аннан шикләнделәр, сагаеп сөйләштеләр һәм, әлбәттә, үтенечен кире кактылар. Арадан бер иптәш, егетнең шактый михнәт чигеп йөргәнен белгәннән соң, өстәл артыннан ук чыкты, Нәҗипне аркасыннан сөеп диванга утыртты һәм, кап-кара бөдрә сакалын тарый-тарый, мәсьәләне ачыклап бирде: «Киңәшем шул: Платон Платоновичтан хәер-фатиха, ягъни рекомендация алып килмәсәгез, институтларның, фәнни оешмаларның ишеге сезгә ябык. Нишлисең, тормыш аяусыз. Захарчукның кулы җитмәгән почмак шәһәребездә юк. Йә бүтән якка юл тотыгыз, йә завод-фабрикалар тирәсеннән эзләп карагыз!»

Рәхмәтен аңа да җәлләмәде Нәҗип.

«Әллә киңәшкә өлкә комитетына кереп караргамы?» — дип, Ирек мәйданында каңгырып йөргәндә, аның турысына өр-яңа елкылдап торган кара «Волга» килеп туктады, аннан теге чакта Фәтхулла абзалары табынында танышкан иптәшләрнең берсе чыкты. Ирексездән аларның күзләре очрашты. «Безне Ходай очраштырды!» — диде кыюланып Нәҗип һәм тәвәккәлләп үз хәлен кыска-кыска сөйләп бирде. Иптәш ашыга иде, ул күзен обком ишегеннән алмады, кесәсеннән визитка чыгарып Нәҗипкә тоттырды һәм: «Иртәгә сәгать унбердә шалтырат», — диде. Кәгазь иясе чыннан да Горбунов берләшмәсенең директор урынбасары Храмов Иван Кириллович икән. Татарча үтә шома сөйләүче бу керәшен Нәҗипне дәртләндерде, ул икенче көнне кушылган вакытта урынбасарга шалтыратты.

Завод идарәсе урнашкан йортның өченче катына тыны-өне бетеп менде. Храмовның кабинетын көч-хәл белән эзләп тапты. Күзе-башы тонган иде егетнең. Фәтхулланың исеме үз эшен эшләде, урынбасар аны кемнәргәдер тәкъдим итте телефоннан кат-кат шалтыратты. «Документларыңны җый!» — диде ул ахырдан. «Алары үзем белән»,— диде егет, каударланып. «Ашыкма,— дип бүлдерде аны җитди кеше,— син безнең эшнең асылын онытма. Укыган җиреңнең спецбүлегеннән белешмә китер. Ни кирәген алар белә. Туганнарың хакында белешмә кирәк. Авыл советыннан, колхоздан. Исәннәре кайда да үлгәннәре кайсы зиратларга күмелгән. Шәт, чит илләрдә якыннарың юктыр? Ышанмә?» — «Юк, юк!» — дип кабатлады Нәҗип, сөенеп. Була калса, моннан да борып чыгарачаклар икән. Хәзер исә актыккы өмет монда, язмыш җәя бавы булып тартылган, «йә пан, йә пропал!». Оҗмах капкасын шушы кеше ачса ача, юк икән, дөньяда ник пыскып яшәргә?!

Тәки урнашты Нәҗип, кирәкле кәгазьләрен тапты, авылдан да җибәрделәр, борыны белән җир сөрде егет, мәгәр һәммәсен җиренә җиткерде. Бөтен кешедән алда килде, иң соңгы кеше булып бүлмәдән чыкты. Күрсеннәр генә аны, белсеннәр! Кушканны җиренә җиткерде, кушмаганны үзе белеп үтәде. Беркемгә каршы сүз әйтмәде, килешмәсә дә түзде, чыдады. Шимбә өмәләренә рәттән чыкты,

заводтан совхозга җибәрделәр, өч атна яңгырга-карга батып авылда ятты. Күрсеннәр генә! Стена газетасы чыгарды, бүлек мөдирләре, цех башлыкларының гына түгел, секретарь кызларның, идән себерүчеләрнең кәефенә ярарга тырышты. Директорның көнлек режимын өйрәнеп коридорда аны очратырга, бөгелеп сәлам бирергә гадәтләнде. Күрсен генә! Бөтен начальствоның туган көннәрен белеп алды, хатын-кызларга чәчәк ташыды, ирләрне телефон аша котлады. Болар белән генә алдыра алмагач, нәүмизләнеп, башын ташка орыр дәрәҗәгә җитеп, ярсып та йөргәләде.

Ниһаять, көн төште! Ул дипломында яңа энергия чыганаклары эзләү мәсьәләсен күтәргән иде, заводка шул юнәлештәге заказлар бирелде. Нәҗип Йосыф улы Нургалиев кичә үзе тәлинкә тоткан хезмәттәшләренә җилкә чокырын күрсәтә башлады, күрешкәндә ике бармагын гына бирде. Коллоквиумнарга аны җибәрделәр, фәнни дискуссияләрдә авыз ачып беренче сүзне әйтте, ул эшләгән лабораториягә илнең төрле заводларыннан заказлар ява башлады. Мәскәүдән алты айлык курсларга чакыру килеп, «кемне җибәрергә?» дигәндә, җитәкчеләр Нургалиевне атадылар. Бу инде ышану, хөрмәт казану иде. Нәҗип яшерен өметләр, усаллана башлаган канатлы хыяллар белән башкалага китте. Ул аннан бөтенләй бүтән, олы кеше булып кайтачак! Татыган газаплары, кимсетүләр, җәбер-җәфалар өчен ул кемнәрдәндер үч алачак әле! Сак булыгыз!

Гаиләдә фәкыйрьлекне, кимлекне хатын-кыз аерата авыр кичерә. Гомере буе туя ашамаган, юньле өс-баш күрмәгән Наилә, инде иренә ышанычы югалды дигәндә, җиргә басып түгел, ак болытларга утырып кына йөри башлады. Зур мөмкинлекләр яулап кайтачак ирен нинди күлмәк киеп каршылауга кадәр уйлап куйды Наилә, һич тарсынмыйча Миңсылу апасыннан өстәмә дүрт йөз сум әҗәткә алды, кунакка кемнәрне чакырырга кирәклеген барлады. Ире башкаладан мөдир булып кайтачак. Бер мөдир булып алган кеше, номенклатурага кергәч, һичкайчан төшеп калачак түгел! Күтәрeләчәк аның Нәҗибе!

Хыяллар һич уйда юкта тар-мар килде, өмет киселде, акчалар өс-баш карарга түгел, күңелсез юл чыгымнарына тотылды. Ир белән хатын арасын нығытып килгән татлы уйлар ялган, буш куык булып чыкты. Әнә, дөньяны учында кысып тотып, язмышларын күккә чөяргә әзерләнгән бәндә хәзер биләүле бала хәлендә, күзе белән ялварып, иреннәре белән актык сүзләрен әйтергә тырышып, күз көеге булып ята. Утыз өч яшендә гарип, инвалид, адәм көлкесе, аяклы каза, җәфа, бәла һәм моннан ары бары тик хәсрәт-газаплар гына китерәчәк бичара.

Нәҗипнең сул күзеннән дәү бер тамчы тәгәрәп чыкты да Наиләнең кул аркасына тамды. Ирен генә түгел, Наилә үз-үзен дә танымады, күзеннән чыт итеп яше чыкмады, ирен кызганмады ул, күңеленең кайсы төпкелендәдер Нәҗипкә ачуы ташыды. Ирен чеметәсе, үтмәс пычак белән турыйсы: «Ялганчы! Хыянәтче! Сүзендә тормаган буш куык!» — дип кычкырасы килде аның. Дөрес, бу мәгънәсез ярсулы ташкын аны әзгә генә тетрәндереп тотты, әмма ул булды, күңелгә керде. Хатын-кыз күңеленә тирән кергән тойгылар берчакта да онытылмыйлар.

Ул, акылына килеп, як-ягына каранды, ширмалар артында һәркемнең әҗәл белән үзенчә тартышып ятуын абайлап, икенче тапкыр иренең күкрәгенә капланды. Бөек хыяллар йөртүче Нәҗип Нургалиевнең атна эчендә саргайган яңаклары буйлап ике бөртек тонык яшь тамчысы тәгәрәде. Наилә дә еларга тырышып карады, елый алмады.

**4**

Өч атнага якын шифаханәдә яткырып, эчен ак, сары, яшькелт дару төймәләре белән дыңгычлап тутырып, беләкләрен, ябыккач бөршәеп калган артын төрле зурлыктагы инәләр белән тишкәләп бетергәч, Нәҗипне чыгарып җибәрделәр.

«Йөрәк шаярганны яратмый. Инфаркт юк югын, ләкин йөрәгегез нык ук зәгыйфьләнгән. Стресслар заманы, шуның нәтиҗәсе. Кыскасы, кардионевроз, миокардит, күкрәк бакасы стенокардиягә бер адым калган булган. Режимны кискен үзгәртәсез! Фән белән шөгыльләнүләрне кичектерәсез, күпкә түгел — бер елга, аннан күз күрер. Казан врачлары рөхсәт итсә, җиңелрәк эшкә урнашып торасыз, хәлегез бар икән, озаграк ял итәрсез. Бераз аруланугa, Кавказга, Кисловодскига нарзан ванналарына, тау һавасына барасыз. Даими һәйбәт тукланырга, болын һавасы суларга, чишмә суы эчәргә, борчылмаска, кайгырмаска, кабаланмаска, ярсымаска, үз вакытында шау-шусыз урында йокларга, вакытында торырга, режимны бозмаска! Сезгә, авыру иптәш, хәерле юл телибез!»

Инфаркт яшәрде, Нәҗип яткан палатадагы өч ир өчесе тиң утыз белән кырык арасындагы яшьләр иде. Бераз хәл алуга аларны бер сорау гына борчыды: хатыннарны куенга алырга кайчан мөмкин булачак?!

Бу четерекле сорау аның күңеленә килмәде, аны бүтән яклар — эш, урын, дәрәҗә, квартир мәсьәләсе ныграк талкый иде. Хатын качмас анысы, кичерер дә.

Нәҗип Йосыф улы Нургалиев, белемен яңа тәгълиматлар, өр-яңа юнәлешләр, чит илләрдә барган эзләнүләр белән нығытып, Казанның атаклы заводларының берсенә лаборатория мөдире булып кайтырга киткән җиреннән, әнә шулай, кәҗә билеты тотып, Татарстанның томанга, сөремгә, төтенгә,

көлгә, тузанга һәм шау-шуга чумган гүзәл башкаласына кайтып төште. Урыны плацкарт, аның да ян кырыйдагысы, аның да бәдрәф янәшәсендәгесе иде. Төне буе керфек какмады. Ни уйларга да белмәде егет. Кайсы якка гына уен юнәлтсә дә, уй йә упкынга очып төште, йә булмаса кара язмыш юлга чыгарып куйган таш кыяга килеп орынды. Әкияттәге кебек, каршысында әле кара урман, әле шашкын елга, әле ут ташкыны булды. Үтәр әмәл дә, яхшы күңелле сихерче биргән коткаргыч әманәтләр дә юк. Кеше аңының иң кыен мәле. Уйламыйча да ята алмыйсың, уйларыңның җебе юк, нигезе, юнәлеше. Алар сине язгы ташкындагы йомычка кебек чайкалдырып йөртәләр, яр якын да кебек, ләкин чыгар юл юк, якынлашам дигәндә генә ул тагын да ераклаша...

Поезд Бишбалтаның кырыгынчы завод корым-сөременнән түбәнгә чүккән гарип йортлары арасына барып кергәч, ул суга егерме тамчы валокордин тамызып эчте, Наиләсенә күшеккән тавык булып күренәсе килмәде.

Наилә Нәҗипне караватта яткан хәлдә генә күреп кайткан иде, вагон ишегеннән ыбыр-чыбыр тутырган иләмсез төенчек тотып чыккан килбәтсез ирен күргәч, чак егылып китмәде. Пәлтәсе иңнәрен сытып аска салынган, чалбар балаклары гармунланган, күз читләренә саргылт эрен касмакланып каткан... «Әйберләр вагонда, күрерсең. Уфалы иптәш озатты. Син кереп ал инде, миңа авыр күтәрергә ярамый».

Наилә Искәндәрне җитәкләп, Рөстәмен күтәргән иде, берсен читкә кагып, икенчесен әтисенә тоттырды да бушап калган вагонга җил-җил кереп китте. Мәскәүдә очрашканнан бирле аны бер газап биләде: «Ничек яшәрбез без? Ничек гомер итәрбез?» Вагон аша Нәҗипнең китап-дәфтәрләрен өстерәп чыкканда, ул икенче улларын, Рөстәмне алып кайтуларына үкенде: «Ичмасам, берәү генә булса икән!»

Җил мехкомбинат ягыннан иде. Казан күген кара җилпәзә, февраль болытлары каплаган, көн чамасыз җылыткан, урамнар ярым караңгы, саграк шоферлар машина күзләренә ут төрткәннәр. Алар җиденче трамвайдан төшүгә, борынга сасы тире исе, комбинат кыш буе таратып урамнарга, агач ботакларына, баганаларга, йортларга сеңдергән авыр ис килеп бөркелде. Күктән, эре-эре корым кисәкләренә уралып, җепшек кар бөртекләре төшкәли иде. Әйбер-караларны Наилә ике тапкыр килеп алды. Рөстәмне күтәреп, Искәндәрне җитәкләп, ире аны урам читендә көтеп торды. Көч-хәл белән, җепшегән карлы уйсуларда тая-тая, өйгә кайтып җиттеләр. Наилә манма су булды, пәлтә якасын чишеп җибәрде. Хуҗаларның җиргә тия язган тәрәзәләренә кырын күз сала-сала, үз ишекләренә, аргы башка үттеләр.

Мәскәүдән, мәһабәт пулатлар, Кремль йолдызлары яныннан ялгызы кайткач, Наилә өенә керергә хурланып, гарьләнеп еламсырап басып торган иде. Бүген, ике баласын җитәкләп, чирле ире егылмасын дип борчылып кайткач, аны-моны уйлап тормады, фәкыйрьлек, мескенлек аларның гаиләсенә төс кебек тоелды.

Искәндәр, күчтәнәч көтеп, әтисенең бөктәрләренә ымсынып карады. Әле ярый уфалы татар, китәр алдыннан, «улларыңа» дип, бер тартма зефир тыккан иде. Рәхмәт аңа, шуны тартып чыгаргач, малайлар, песи балалары кебек мыраулап, күчтәнәчкә ябырылдылар. Наилә бәрәңге пешереп, аны бала юрганы белән төреп куйган икән, кара-каршы утырып, озакка сузарга тырышып, шуны ашадылар, чәй эчеп алдылар.

Көн үтте, кич ашыгып килде. Нәҗип чак кына тынычлангандай булды, аңа карап Наиләнең дә эчке бураннары бераз басыла төште. Ул: «Ходай биреп, тиз генә сәламәтләнеп, ныгып китсә... тормыш элеккеге эзенә кайтмасмы әле?!» — дип, яңачарак уй беркетергә тырышты. Йокларга ятканнар гына иде, биләмнән Таңсылу кайтып керде, дөп-дөп басып ишекле-түрле йөрде: нидер аударды, шакылдатты, өстәл-урындыкларны, спектакль әзерләгән режиссер сыман, шкафларны урыннан урынга күчерде, күрше бүлмәдәге әнкәсенә Африкага ишетерлек итеп кычкырды, җырлады. Ярты төнгә шае аның үчегү концертын тыңлап үткәрсәләр, төн авышкач, станцадагы маневр паровозлары эшкә тотынды. Тәбәнәк кенә зәңгәрсу нәрсәләр киндер станының кылычыннан чыккан буй җепләре кебек тезелгән суык рельслардан, ак, зәңгәр светофорларның туймас ихтыярына буйсынып, вагоннарны арлы-бирле тараттылар. Ми шарларын түндерергә теләп сызгырттылар, багана башына мәңгелеккә менгән радиорупордан дежурный хатын-кыз кемнәрнедер өзмәс каулады, карлыккан исерек тавышлы кемнәрдер, аңа хәбәр җиткерергә тырышып, нидер акырдылар, яман сүзләр белән таңны сискәндереп сүгенеп җибәрделәр. Рельслар дөбердәде, тәрәзә, бүрәнә аша суык сыкы белән ят авазлар кереп тулды, тар караватта тырпылдап яткан ике җан, җилгәргеч иләгендә ялгыз калган ике борчак кебек, һаман бер-берсеннән ераклашалар иде. Наилә һаман: «Ничек яшәрбез без? Ничек көн күрербез?» — дип тын гына уфтанса, Нәҗип, тел астына валидол салган саен: «Алай гына бирешмәм! Эйзенхауэр унике инфаркт кичергән! Бишәр инфаркт алганнар да яши! Йөрәкне ныгытырбыз, күңелгә йомшарырга ирек бирмәбез! Чак кына ял итәргә, әзгә генә түзәргә! Һәм изүне чишеп эшкә ябышырга!» — дип, яңача иманын тәкрарлап ята иде.

Наиләнең иртәнге хәбәрләре җанны җылытмады. «Үлмәгән Захарчук, үләме соң? Декан ясаганнар үзен. Менә шул»,— диде ул, чәйнеккә су салганда. Керогаз өстеннән гөлдердәп тавыш биргән чәйнеккә кушылып, Наилә икенче бер «сөенече» белән уртаклашты: «Ә Фәтхулла абыйны яңа эшкә, югарыга

референт итеп күчерергә теләгәннәр».— «Ә ул?» — «Улмы? Бармаган!» — «Җүләр!» — диде кинәт Нәҗип. «Бу заманда кулыңда нәни генә власть юк икән, син тулы хокуклы кеше түгелсең!» — «Алай димә... Власть ике төрле була ул, берсе аның күзгә күренә, икенчесе күренми. Бездә хәзер яшертен экономика, яшертен власть бар дип сөйлиләр ич!» Нәҗип: «Кемнән ишеттең?» — дип төпченмәде, ул сорашырга җыенган арада хатыны өченче яңалыкны әйтеп, аның авызын йомды: «Ә теге, кем соң әле, шадра инде... Мебель кибетендә бергә эшләгән идегез...» — «Вафамы?» — дип сорады Нәҗип. «Шул инде, шул! Кибет директоры иткәннәр үзен!»

Дүрт класс белеме белән, русчаны түгел, татарчаны да такы-токы гына белгән Вафа — директор?! Бусы чыннан да искитәрлек иде...

Наиләнең кич алып кайткан яңалыгы аяз көнне күк күкрәгәндәй булды. Ул өйгә кызарып, ашыгып, мышнап диярлек кайтып керде: «Чихрадзе пенсиягә киткән!» — дип әйтеп салды. Нәҗип өйдә көне буе ялгыз калып, әле йөреп кереп, әле ятып, шактый тынычланган иде, дерт итеп кабынып китте. «Гайбәт! Алтмыш аңа көз көне тула».— «Көзне көтмәгән инде, сәбәбе булган». Наилә башта сәбәбен әйтмәде, балаларны берсен бакчадан, икенчесен яследән алып кайтырга кирәк иде, озак кына тарткалаштылар, соңга кала яздылар. «Белсәң бел,— диде Наилә, ярым кызып,— Чихрадзеның хатыны вафат икән...» — «Әйе,— дип җөпләде аны Нәҗип,— былтыр күмдек».— «Алар йортында күршедә ун яшьлек бер кыз яши икән, элек тә, Чихрадзеның хатыны исән чакта, аларга гел кергәләп йөргән. Хәзер дә Чихрадзе аны еш кына дәшеп ала икән. Кәнфит белән сыйлый, тәмле сулар эчертә, юк-барны сораша торган булган».— «Шуннан? Моның ни гаебе бар?» — «Бар шул! — диде турсаеп Наилә.— Көннәрдән бер көнне карт пәри, гөрҗи, кызны капшый башлаган, бер токкан, ике токкан, кыз гәүдәле икән, җитеп килә!.. Оялып башта беркемгә бер сүз ычкындырмаган, ахыр, Чихрадзе моны кыса башлагач, йөгереп чыккан да әнкәсенә сөйләп биргән. Кыз зыян-зарар күрмәгән икән! Ашык-пошык кына пенсиягә озатканнар карт иблисне!»

Хәбәр бик хәтәр иде. Нәҗипнең зиһене томаланып, башы иңкеп китте. Көзгә кадәр ул элеккеге хәлемә кайтырмын дип нык ышана иде. Ныгыр өчен ял итәргә, күңелне яңа халәткә өйрәтергә кирәк иде. «Сиңа эшкә чыгарга туры килер»,— диде Наилә туп-туры. «Шулай булыр, ахрысы. Минем айлык больничныем бар барын...» — «Заводның хәрби фәнни лабораториясен мөдирсез ай буе тотмаслар»,— диде Наилә, ышаныч белән. «Бер-ике көн түзик, миңа күнегергә кирәк, Наилә».— «Ике көн түзәрбез... Урын түзәрме? Шуны да уйла!»

«Ә Чихрадзе шыр тиле икән! Беткәнмени хатын-кыз аңа? Алай талагы ташыса, әнә безнең Таңсылу белән таныштырырга иде үзен!» — дип ычкындырды Нәҗип, ишектән чыгып барганда.

Икенче көнне ул больницага барып каралырга, киңәшергә, эшкә чыгарга рөхсәт алырга тиеш иде. Наиләсенә: «Барам, барам», — дип калган иде, бармады. Иртәдән үк көннең рәте булмады, башы авыртып торды, бертуктаусыз җепшек кар яуды, буран купты, тәрәзәләрне томалап юеш кар ябышты. Урын өстендә шактый аунагач, ул калкынып торды, киенде, кая барасын да уйламаган килеш, капка төбенә чыкты, аяк йөзен күмгән ябышкак карны ерып Яңа бистәнең Бродвее — Мәҗит Гафури урамына чыкты. Аның сагышын арттырып тегеләй дә, болай да трамвайлар үтте, пычрак чәчеп машиналар каядыр ашыкты. Кинәт хәрәкәт азайды, машиналар тизлекләрен киметеп туктап калдылар. Нәҗип шәһәр ягыннан килгән, билен киң кара тута белән буган мәет машинасы — катафалкны абайлап алды...

Мәет машинасы! Җеназа! Машинада җансыз гәүдә, үлек ята...

Кемдер дөп итеп аның күкрәгенә китереп сукты, күз алды караңгыланды, ул бер мәлгә, Мәскәүдәге кебек, яшәү белән әҗәл арасында кысылып калды. Аяк бармаклары чемер-чемер итте, бугазына кайнар кургаш тулды, сулышы авырайды. Аның бөтен күзәнәкләрен, аңын, зиһенен курку биләде. Ул, җеназага катнашкан машиналарга күзен күтәреп карарга куркып, шактый басып торды бугай, җепшек карга чумган аякларына дым бәрде, суык үтте. Аның яныннан узып торган кешеләр: «Көпә-көндез салган бу, ахрысы, исерек!» — дип борылып-борылып та карадылар.

Нәҗип Йосыф улы Нургалиев тагын бер тапкыр тормыш белән саубуллашып алды, коты ботына төште. Гүя әнә шул дәһшәтле, аяусыз кара билле машинада аның гәүдәсен салып Яңа бистә зиратына илтәләр иде. Өенә кадәр исән-аман кайтып җитә алса ярый ла!..

Шулкадәр күңелсез, шулкадәр авыр иде аңа! Офыклар кап-кара, юллар чуалган, бара-бара да әллә кая, янга каерылып кереп китә, егылмас өчен койма такталарына, капка баганаларына ябыша. Аны күреп сәерсенгән этләр дә өрмәс булдылар, койрыкларын болгап: «Кая барып бәрелер икән бу бәндә?» — дип, аны озата киттеләр...

«Беттем!» — диде аның көл төсенә кергән иреннәре, «үләм» дигән уй күңеленә сеңде, һаман ныгый, берегә барды. Ул, уеның юнәлешен үзгәртергә маташып, Наиләсе, балалары турында хәтерләргә азапланды, алар искә төшкән саен, Нәҗипнең өметсезлеге тирәнәя бара иде.

Кайтып җитте, урам капкасын ачык калдырды, кыеш баскыч төбенә җиткәч, тотка тимеренә ябышып торды. Кергәч, пальтосын иңеннән шудырды да, көч-хәл белән пычрак, юеш ботинкаларын ычкындырып, караватка менеп ятты. Аның кайтканын ишетеп, теге яктан Таңсылу килеп чыкты һәм

йөзтүбән капланып яткан Нәҗипнең арык җилкәсенә майлы, симез йодрыгы белән берне кундырды. «Тор! Күтәрәм сыер булдыңмы әллә? Ятасың да ятасың!» Нәҗип аһылдап, йөрәк турын учы белән каплап, торып утырды. Таңсылуга нәрсә: авыз мыймылдык, күз-каш тирәләре каймаланып бизәлгән, колак алкалары болыт арасында уйнаган яшендәй елык-елык килә, авызлыклап куйгач текәләнгән күкрәкләре тирбәләләр. «Йә, ни диден әле син кичә хатыныңа? Кемгә сыларга ниятлисең син мине? Әрмәнгәме, грузингамы? Сатар алдыннан товарның сыйфатын үзең бел. Ошамасам, теләгән кешеңә аткарырсың!» — «Таңсылу, дим, чакыр «ашыгыч ярдәм» машинасын!» — «Нәрсә? Ни иркәләнеп ятасың? Мин синең җебегән хатының түгел, хәзер уятырмын...» — «Үләм!» Таңсылуның халат төймәләре каптырылмаган икән, ул шәрә тәне белән сөзешергә килә башлады. «Затсызланма, Таңсылу!» — «Җебемә, хайван!» — «Чакыр врачларны... үләм... йөгер!»

Таңсылу, гөбе-гөбе ботларын ачып ташлап, татлы хихылдап, караватка ук менеп ятты, Нәҗипне стенага кысрыклады. «Ашыгыч ярдәм» кирәк, имеш. Менә мин синең ашыгыч ярдәмең! Чирләгән икән берәүләр, һай Алла! Хатыныңны алда! Марҗалар белән себерелгәнгә укуыңнан куганнар сине. Тап-таза ир, Ходаем, утыз өч яшьтә! Мәскәүдә! Тик ятканга йөз илле тәңкә акча! Кругом кызлар! Негр марҗалары белән себерелгәнсеңдер әле? Бер танышым сөйләде, аларның уч төпләренә кадәр зәп-зәңгәр, ди... Сөйлә инде! Йә! Кайнармы алар, дәртлеме? Үлгән урысны да уятырлыкмы? Йә инде!»

Нәҗип, йомык күз, ыңгырашты. «Таңсылу, күрмисеңмени? Үләм!» — «Күрмим, күрмим! Яле, күрсәт!» Таңсылуның бармаклары өзелеп калган кәлтә койрыгы булып кыймылдадылар, ул әллә кайларга кереп китте.

Ә Нәҗип чалкан яткан да, аңын югалтып, җәйрәп онытылган. Таңсылу, шашынып-акырып, чап-чоп үз ягына чыгып чапты, хушбуй исе таратып халат итәкләре җилфердәде.

**5**

Наиләне профкомга дәшеп алдылар. «Үткән елгы кәгазьләрне күздән үткәрәсе бар, әз-мәз миңа булышырсың, озак тотмам», — диде Изил Латыйпов. Латыйпов үз исеме белән горурлана, җай чыккан саен: «Исемем — Изил, әти кушкан, минем кем буласымны, җәмгыятьтә күркәм урын аласымны алдан ук белгән. «Ис-пол-няй заветы Ильича!». Мондый исем белән югалмас заман киләсен шәйләгән!»

Озын, нәзек муенлы, бәләкәй башлы төксез иякле бу кеше, ике хатын аерып, хәзер буйдаклар өеренең башы булып йөри иде. Очраган бер сөйкемле хатынга күз кыса, һәркайсысына аның сыналган шома төче сүзе бар; буфетта чират булса, ул күңеле төшкән ханымнар артына басарга тырыша, ышкына, ялгыш, дигән булып аның шәрә беләгенә кагылып китә, түшенә орына, һич тайчынмый, үзеннән шактый өлкән хатыннарның колак итен тешли-тешли оятсыз анекдотлар сөйли. Наилә бу кешенең күзенә чалынмаска, аннан читтәрәк йөрергә тырыша иде. Моңарчы теләге кабул булса да, бүгенге чакырудан баш тарта алмады. Изил Латыйповны күрергә, аннан бик кирәкле бер-ике белешмә чокып алырга кирәк иде. Нәҗипнең чирләп егылганын, Казанга кайтып төшкәнен заводта беләләрме-юкмы? Бу — бер. Икенчесе — Чихрадзе урынына мөдир булып кем киләчәк? Җитәкчеләр арасында нинди сүзләр йөри?

Изил Латыйповның дөньяда белмәгәне юк иде.

«Балаларны Нәҗип барып алыр, аңа юанырга бер шөгыль булыр»,— дип тә уйлады Наилә.

Изил кабинетына кергәч тә, бүлмә хуҗасы Наиләне атылып килеп каршылады, өстен салдырышты, «һаман чәчәк атасың, Наиләкәй! Матурлык алиһәсенең үги кызымы әллә син?» Яшь хатыннарның һәммәсенә «син» дип эндәшкән Изилгә Наилә үпкәләмәде. Тагын бер-ике төче мактау сүзе ычкындыргач, Изил, гадәтенчә, анекдот сөйләп ташлады. «Төрмәдә, бер камерада бишәү утыралар икән. Берсе караклык өчен эләккән — биш ел биргәннәр, икенчесе талауга катнашкан — сигезне ямаганнар, берсенең дә сандыгы буш түгел, ә бишенче кеше почмакта авызына су кабып утыра икән. Тегеңә унбиш ел чәпәгәннәр, ди! Кысалар тегене, әйт тә әйт, нигә шулкадәр клиндер ашаталар сиңа? Аптырагач, йөдәгәч, теге бәндә: «Өч шыртлака өчен бирделәр срок!» — ди икән. «Өч шыртлака өчен унбишне өяләрме, дурак?!» — дип бәйләнәләр икән камерадашлары. Шуннан сөйләп биргән теге. «Барам күл ярыннан, карасам, җирдә бер кирпеч ята. Бер ягына «динамит» дип язу ябыштырганнар, икенче ягында да шундый язу. Койрыгына ут төрттем дә күлгә тондырдым теге кирпечне... Карыйм, өч шыртлака һәм дүрт водолаз калкып чыкты», — ди икән теге...»

Изил көлеп туктагач кына, Наилә елмайгандай итте. Ә Изилнең борынныннан куык атылып чыкты. Суык тидергән икән атаклы профсоюз лидеры. Оятсыз Изилнең бүген кыюлыгы җитмәдеме, вакытсыз борынына кунган куык дәртен сүрелдердеме, Наиләне ярты төнгә калдырмады, майлы күзе белән капшанса да, кулын күкрәгенә сузмады. Алай да кәгазьләрне сортка аерып, папкаларга теркәп шактый утырдылар. Көн соңарды. «Изил, — диде Наилә, мөмкин кадәр тәмле телле булырга тырышып, — Чихрадзе урынына кемне мөдир итәләр?» — «Ә миңа кем булса да барыбер», — диде бераз чытлыкланып Латыйпов. «Барыбер үк түгелдер лә! — диде күз карашын аңа текәп Наилә. — Заводта

кадрлар сайлаганда соңгы сүзне син әйтәсең диләр ләбаса!» Бу юлы аткан ук туры тиде, Латыйпов урыныннан сикереп торды, тар күкрәген алгарак чыгарып, күз алмаларын тәгәрәтеп, Наиләгә таба атлады. «Анысы хак... Тырышырга туры килә. Һәрчакта да минем белән киңәшәләр. Әлегә Чихрадзе урыны буш». Бу хәбәрдән Наилә дә сикереп алды, моны үзенчә аңлаган Изил келәйле бармаклары белән аның түшенә үрелде. Нинди әрсез, аңгыра һәм буш куык ирләр бар бу дөньяда! Әгәр Изил бу минутта Наиләнең күңелен нинди уйлар өермәсе биләгәнен, йөрәгенең ничә градуслы утларда дөрләп янганын белсә... Кулы сузылуга Наиләнең хәсрәт утыннан очкын алып, кара күмер булып янар иде. Шушы секундтан Наилә бөтен эшне сукырларча башкарды, һичнәрсә уйлап, баш ватып тормады. «Тек» диде Изил,— папканы тексте. «Җый!» дип боерса,— кәгазьләрне берәмтекләп җыйды, үзе дә сизмәстән эченә-тышына кара кайгы уралган җанлы курчакка әйләнде...

Яңа бистәгә баручы трамвай бүген тәмам чукынды, юк та юк! Тылсым белән тартып китерер иде Наилә, тылсымы юк! Ярсуы белән янына сөйрәр иде, шәһәр трамвайлары Наиләнең ярсуын аңлый торган түгел шул. Яннан гына дәү-дәү кара «Волга»ларга киерелеп утырып шома-шома кешеләр үтә. Ишек пыялалары аша аларның чиртсәң кан чәчрәп чыгарлык тук чырайлары, кыйбатлы бүрекләре һәм текә күтәрелгән хәтәр танаулары гына күренеп кала. Тизрәк өйгә кайтып керергә, «урын буш!» дип, Нәҗипне дәртләндерәсе һәм иртәгәдән дә калмыйча заводка җибәрәсе бар иде. Аның Нәҗибеннән дә лаеклырак кандидатура юк, алты айлык курсларның дүрт аен тәмамлады, аның ире — елдам кеше, аласы белемне алгандыр!

Тукталышта кара болыт булып торган халыкны суык җил куып таратты, ниһаять, аргы яктан җәяү килгән бер мәрхәмәтле җан: «Юкка көтәсез, анда авария, трамвай машина белән бәрелешкән!» — дигәч, Наилә дә җәяү кайтырга җыенды. Бүтән чара калмаган иде.

Шәһәр белән Яңа бистә арасы шактый ара, караңгы, ике арада фонарьлар юк, әрле-бирле йөргән машина утлары гына шыксыз бушлыкны, җилләр уйнаган мәйданны, кар өемнәрен, боз кантарларын яктыртып уза. Сул якта әллә кайчаннан юл төзүчеләрдән калган күгәргән калай вагон тора иде, курка-курка Наилә шуңа якынлашты. Тып итеп вагон артыннан каршысына килеп чыккан шәүләне күргәч, Наилә коелып иңде, батон белән сөт шешәсе салган чүпрәк букчасы кулыннан төшеп китте. Букчаны иелеп алганчы, шәүлә кешегә әйләнде, уң кулы белән хатынның җиңен эләктереп алды. Ярсыган хатын кулында теләсә нәрсә — корал! Наилә ике аягын аерып басты да, букчасын, стадионнарда чүкеч ыргытырга җыенгандагы кебек, һавада болгый башлады, бер-ике адым чигенде. «Якын килмә!» Шәүлә һаман якынлашкач, букчаны бар көченә тегенең баш түбәсенә кундырды. Шешә ватылды, шәүләнең бүреге агарды, ул лып итеп артына утырды. Наилә җилдәй чабып аны үтеп китте, урамына кайтканчы йөгерде.

Капкадан керүгә, Тимерхан картның төнгә чылбырдан ычкындырыла торган шалбыр койрыклы алама эте — Звонок абалап өрергә тотынды. Ни булган аңа? Ул абына-сөртенә өйгә керде, бусаганы атлап узгач, тын тартырга куркып тыңланып торды. Нәҗибе дә, балалар да өйдә юк иде. Кайтып җитмәгәннәрме әллә? Кайда булырлар болар? Керогаз өстендә моңаеп утырган ятим чәйнекне капшап карады, суык. Мич тә ягылмаган. Мичне бер көнне Таңсылу, икенче көнне алар яга торган иде. Бүген алар чираты.

«Таңсылу апа!» Теге якта карават яман шыгырдады, күнеккән колак Таңсылуның бер яктан икенче якка авышуын чамалады. «Таңсылу апа!» Суык тавыш, җанны өшетеп: «Ни бар тагын?» — дип сорады. «Нәҗип кайда, белмисеңме?» — «Нәҗип?» — дип кайтарды күрше хатын, соравына нәфрәт, җирәнү кушып. «Балаларны алып кайтмадымыни?» — «Күрәсең ич, юк».— «Ни булды соң?» Яши башлаганнан беренче мәртәбә ул Таңсылу ягына чыкты. Бүлмәнең бөтен стеналары, тәрәзә арасы, гөл чүлмәкләре, урындык артлары атаклы артистларның рәсемнәре белән тулган иде. Хәтта көзгегә дә чибәр-чибәр, бөдрә чәчле, фырт киенгән артистларның рәсемнәре ябыштырылган. Утырма көзге итәгендәге киштәгә мең-миллион төрле вак-вак шешәләр тезелгән иде. Киң һәм биек караватта, каз мамыгы тавында, ботын-чатын аерып Таңсылу ята, кулында көмеш саплы нәни эскәк белән түгәрәк көзге. Чәчен тузгытып ташлаган да үз яңакларының калкулыкларын, уйсулыкларын, таучыкларын күзәтә. Бармак очы белән зәңгәр төрткеле борын очына басып нидер үлчи, нидер саный. Наилә, ни ашыкса да, бер карауда бүлмә эчендәге тәртипне, чисталыкны, пөхтәлекне абайлап өлгерде. «Нәҗип кайда?» — дип кычкырды ул җан ачуы белән. «Скорый белән алып киттеләр җебегәненне!» — диде түшләрен уйнатып Таңсылу. Наиләнең коточарлык кыяфәте аны куркытты. «Йөрәге начарланды да, мин «скорый» чакырдым». — «Ә балалар?» — «Балаларыңның кайтканы юк!»

Наиләгә ике яктан ике ут бөркелде: ике бала, икесе ике җирдә! Сәгать ничә хәзер? Ун тулып килә икән! Кая чабарга? Ничек икегә ярылырга? Җитмәсә, Таңсылу, теше сызлагандай чыраен сытып: «Мич ягылмаган, өй катып үләрлек», — дип ярага тоз сибә. «Таңсылу апа! — дип кычкырды Наилә. — Син хәзер балалар артыннан чабасың!» — «Чапты диярләр...» — «Чабасың! — дип кабатлады Наилә һәм караватянына килеп Таңсылуның ботын каерып ыргытты. — Тор!» Таңсылу дәшмәде, борын тишекләреннән, ирен арасыннан еш-еш пар-тын бөркелде. «Мин Нәҗипне юлларга ашыгам, балаларны син алып кайтасың. Берәр нәрсә ашый торырлар. Мичкә кайткач ягармын».— «Ярый инде, үзем

ягармын. Балаларың кайсы бакчада соң синең?» Наиләнең күз чокырларында ут уйнады: «Кыланма! Беләсең! Берсе мәчет янында, икенчесе мәктәп янында!» — дип кычкырды ул, аяусызланып. Таңсылу нидер мыгырдап караватандан төшә калды. Наилә йортның өлкәннәр яши торган ягына атылып керде. «Җәмилә әби! Ун сум биреп торыгыз!» — дип кычкырды. Тимерханның күгәргән бугазы калтыранды, аннан: «Әбиең туталарына китте, хаста булып егылган»,— дигән өн чыкты. «Тимерхан абзый, ун сум! Түләрмен! Бише белән кайтарырмын!» Хатынынннан башка, аның әмереннән тыш диварга кунган черкине дә үтермәгән Тимерхан карт бүген Европа күләмендә батырлык эшләде. Карчыгының үлемтекләр, нафталинлы энҗе калфаклар, көмеш тәңкәләр саклана торган сандыгын ачып, калтыранган куллары белән таушалып беткән өч өчлекне һәм бер тимер берлекне алып бирде. Наилә Гафури урамына чапты. Салкын тагын да аяусызланган, кар тоташ шыгырдый башлаган иде. Наилә аны сизмәде, беренче туктаган машинага утырып, үзләре беркетелгән шифаханәгә чапты, андагы кизү врачтан «ашыгыч ярдәм» машиналарының чирлеләрне Арча кырындагы 15 нче больницага ташуларын белде. Озакламый машина кар чәчеп шул тарафка очты.

**6**

Һәрбер хатын-кызның сере була, ә сер берчакта да тик ятарга яратмый, аның тизрәк юл саласы, дөньяга чыгасы килә. Шуның өчен һәр хатын-кыз үзенә сердәш, сер алмашырлык якын бер кешене сайлап ала. Наиләнең дә бар иде андый сердәше, якын кешесе, Гөлнара исемле. Гөлнара институт тәмамлаган, телләр белә, техник информация бүлегендә эшли, ире дә югары урында, Министрлар Советында хезмәт итә. Казанның иң мәртәбәле, иң затлы районында — Ульяновлар урамында биш бүлмәле квартир билиләр, гаражлары ишегалдында, гаражда «Волга», кай яктан килеп карасаң да тормыш дәрәҗәләрендә тигезсезлек күрәсең, әмма хатыннар бер-берсен тиз табыштылар, җиңел якынлаштылар. Наиләгә Гөлнараның шундый күркәм, атаклы кешенең хатыны булуы ошаса, Гөлнара Наиләнең басымчаклыгын, кыланмавын, кынҗырланмавын, сүз йөртмәвен, гайбәт ташымавын, гаиләдә сафлыгын яратты. Наиләгә бүтәнчәрәк, үзе берчакта да ирешә алмаслык югары катлау тормышыннан информация зарур булса, Гөлнарага, серен читкә чәчәргә ярамаган, киң һәм күпьяклы тормышта яшәүче хатынга, сер сыярлык, бушанырлык, иң кирәк җирендә генә ямансулап бер җылап та алырлык кеше кирәк иде; хатын-кыз. Күңелләр һәрчак бер-берсен эзли, зарыгышып кына булса да таба. Наиләдән: «Ничек, ни хәлләрдә яшәп ятасыз?» — дип сорасалар, әле аның шикләнмичә һәм һич икеләнмичә: «Әйбәт! Без бик бәхетле!» — дип, чатнатып җавап бирә торган чагы иде. Ә Гөлнара — Наиләдән өч яшькә генә олы хатын, тормышның сирәк кешегә эләгә торган коридор-лабиринтларын үткән, югары даирәләрдә ниләр кайнаганын, нинди бәрелешләр, астыртын көрәш барганын ире аша көн саен ныграк белә барган, тәҗрибәле, көнче, үпкәләүчән һәм гайбәтләрне итәгенә җыя торган ут күзле хатын иде. Нәзберек, һавалы, үзен дөньяда бер чибәр дип санаучы бу хатынның тормышына Наилә (әле ул ир хатыны булуның рәхәт тә икәнлеге хакында башына да китерә алмый иде!) кызыгып түгел, бары тик кызыксынып кына карый иде.

Атна уртасында Гөлнара бер көн ял ала, ул көнне республика китапханәләрендә чит ил журналлары белән таныша дип исәпләнә. Әмма Наилә белә: Гөлнара ул көнне китапханәләргә эз дә басмый, алар, биш хатын, шәһәрнең иң атаклы кешеләренең бичәләре, җыйналышып, иртәдән мунчага — саунага баралар. Шәһәрнең мәшһүр массажчысы, Кавказдан махсус чакыртылган әрмән Григорьян көне буе алар белән мәшгуль була. Мунча бүтәннәр өчен ябык, ишекләр эчтән тома бикләнгән, аулак, биш хатын, атна буе аякларына ияргән яңалыкларны кыска-кыска гына, көлешләрен пыскытып тыеп, бер-берсенә бушаталар да, Григорьян хикмәтле могҗизаларын тормышка ашыра башлый. Озак һәм оста массаждан соң ул хатыннарның тәнен балга манчып чыга, бал бөтен күзәнәкләргә, эссе саунадан соң йомшарган бөтен әгъзаларга үтеп керергә тиеш. Балга манчылган ханымнар, кәефләнеп, таралып, җылытылган мәрмәр сәкеләрдә шактый вакыт йокымсырап яталар. Балны аларга дәү-дәү алюмин флягаларда юкә урманнары күбрәк, нефть-газ исләре ераграк районнардан китерәләр.

Бал сүрүне көчле агым белән юдыртып төшергәннән соң, хатыннар бер-бер артлы сауна белән янәшә үк парлы мунчага керәләр, Григорьян аларны иренмичә, рәхәтләндереп чаба. Аннан ахирәт ханымнар гөжләп торган дәү корсаклы самовар янына утырып бик озаклап, биш кат тирләре чыкканчы чәй эчәләр. Чәй табынына һәркемнең өеннән алып килгән күчтәнәчләре, затлыдан затлырак ризыклар чыга. Дөрес, эчемлек монда Григорьянга гына, аңа да әзләп кенә, көч китмәслек итеп кенә куела. Хатыннар тулы режим, диета һәм тәртип саклыйлар, ризыкны тычкан тешләредәй вак тешләре белән вак-вак кабып, тел очларында әвәләп, җиренә җиткереп чәйнәп ашыйлар. Ашаганчы да, ашагач та шунда аларның зифа сыннарын астыртын гына сагалап торган үлчәү табасына барып басалар. Һәр ханым дәфтәр ачып авырлыгын, кан басымын язып, саннардан айлык, ярты еллык, еллык нәтиҗә чыгарып бара. Чәйдән соң йоклап алалар, йокыдан соң бассейн, бассейннан туры саунага керәләр, саунадан соң ял, ял иткәч төрле физик күнегүләр ясыйлар, табигый рәвештә тир чыгаралар, кечкә кадәр

алмаш-тилмәш тазаралар, сафланалар, көч җыялар. Кайтыр алдыннан Григорьян аларның йомшак, алсу тәннәрен хуш исле майлар белән уа, аяк, кул бармакларына өстәмә массаж ясый, тырнакларын алсуга буйый... Чырык-чырык килеп торган мунча кич соң гына бушый, шат авазлар тына, егерме бишлекләр иплəп кенә Григорьянның биш хатыннан калган хуш исләр аңкыган йөнтәс бармаклары арасына кереп югалалар...

Юк, теге мунча юлдашлары Гөлнара ханымның сердәшләре түгел, алары — көндәшләре, бары тик мунчада очрашырга гына яраган «тастымал телләр», ирләренең бер дәрәҗәдә булулары гына аларны тыгыз берләштергән, аларга сер ачсаң — беттең дигән сүз! Ходай сакласын!

Аның мунчадан соң икенче көнне сөйләшерлек хәле булмый әле. Өченче көнне ул шашынып Наиләне эзли башлый, кайвакытта эш арасында телефоннан шалтыратып чакырып ала, китапханә аулаграк булса, чабып анда килеп җитә, тын почмакларга алып керә дә мунчада булган вакыйгаларны, көндәш-иптәшләренең кыланмышларын, анда ишеткән гайбәтләрен, хатын-кызларның тәннәренә, ирләр күзе төшә торган нокталарына агулы бәя бирә-бирә рәхәтләнеп, кинәнеп, буасы ерылып беткәнче сөйли дә сөйли.

Наиләне үз итәрлек тә шул, сорау биреп бүлдерми, көнләшми, аңа бу сүзләр ерактагы Шәрык әкияте кебек кенә, тыңлый, Гөлнара сөйләгән дөнья аңа чын түгелдер кебек. Нәни генә заводның шундый аулак, яшерен мунчасы булуын да, аның җылы ак мәрмәр сәкеләрен дә, куе зәңгәр кафель белән эчләнгән, асты җен-пәри сурәтләре белән бизәлгән бассейнын да күз алдына китерә алмый.

Наиләнең бәхетле булуы, бик нәни, инә очы хәтле шатлыкны да зур бәхет итеп кабул итә алуы, бозылмаганлыгы Гөлнарага аерата ошый иде. Гомумән, бозык хатыннар саф хатын-кызлар белән дус булырга омтылалар, алар әнә шундый риясыз хатыннарның беркатлы бәхетләрен күрүдән тәм табалар иде.

Үз хәбәрләре дулкынында чайкалып, Гөлнара ханым Наиләнең күзләренә карарга вакыт җиткерә алмый иде. Кызганыч! Ул бу күзләрдә нинди дәһшәтле шәүләләр уйнаганын, танышлык көчәйгән саен шәүләләрнең җанлырак була баруын абайлаган булыр иде, шәт…

Гөлнара белән арадашлыкның тәэсирен Наилә тора-бара ачыграк сизә башлады, аның да шул биш алиһә белән саунада буласы, моңарчы ят ирләр кулы кагылмаган тәненә массаж ясатасы, балга манчылып, онытылып-онытылып ятасы килде. Һич югында, бер генә тапкыр булса да!.. Үзе саунага керә алмаса, сыңар күз белән генә шул бәхетләре ташыган ханымнарны карап торасы иде! Нәҗибе Мәскәүгә укырга китеп, телгә «мөдир» дигән сүзләр кереп ныгыгач, ул Гөлнарага ныграк тартылды, үзен элеккедәй тигез тота алмады, ике сүзенең берендә аны мактады, олылады, вак-төяк йомышларын үтәде, китапханәгә алынган китаплар исемлеген башлап аңа кертте. Кыскасы, ярарга тырышты. Гөлнара да моны сизмәде түгел, сизде, берзаман Наиләне югалтасын чамалады һәм моңа кадәр аңа җиткереп торган хәбәрләренең өлешен бермә-бер киметте. Саунага йөрүче «бишлекнең» берсе шушы араларда китәргә җыена, ирен Мәскәүгә, бик югары урынга күчерделәр, биш кулдан акча алып күнеккән Григорьян кереме кимүгә ризалашмас, азсыначак, Гөлнараларга бишенче итеп кемнедер алырга туры киләчәк. Мөдир хатыны була калса, Наиләне бер сыр югары күтәргәндә ярый, сердәшен корбан итеп булса да, Гөлнара аны арага кертер… Ә сердәш… ирең Совминда эшләгәндә, үзең затлы, бай хатын булганда рухи коллыкка төшәр хатыннар әзме әллә шәһри Казанда?!

«Бишлеккә» Наиләне әзерләргә, аны сер хуҗасы итәргә һәм серен алырга кирәк иде. Нәҗип Мәскәүгә киткәч, Гөлнара Наиләнең кылын тартып карады: «Эш пешереп буламы бу чи кабартма белән, юкмы?» «Бер ир сине күргәндә күзләре белән ашый!» — диде ул сүз арасында. Гаҗәп, беркатлы Наиләнең моңа һич исе китмәде, «Һай!» диде дә кулын гына селкеде. Икенче кат дәшеп бакты Гөлнара: «Әллә сиңа гашыйк булган инде?» Моңарчы юньле өс-баш күрмәгән, тамагына туя ашамаган, шулай да оятсыз тәкъдимнәрне, әрсез күз карашларын шактый очраткалаган Наилә «гашыйк» сүзен ишеткәч, түзә алмады, бите алланып, ике ими арасы тирләп: «Кем ул алай... тиле?!» — дип сорады. Гөлнара информация бүлегеннән бик чибәр, Нәҗиптән дә озынрак буйлы, киң җилкәле, элек, студент елларында, баскетбол уйнаган, купшы мыеклы Миша Суворовны атады. Наилә көлеп җибәрде, чебен кугандай, кулын гына селкеде. Ул Гөлнарага ышанмады, юри, сынар өчен генә Суворовның исемен атады дип уйлады. Завод хатын-кызларының яртысы Суворовка яшерен гашыйк икәнне ул бик яхшы белә иде. Ә икенче яртысы шушы еллар эчендә Суворов кулыннан үткән иде инде. Гөлнара: «Син яртылашларның кайсысына керәсең?» — дип сорагач, Наилә чын күңеленнән болай дип җавап бирде: «Мин — татар хатыны, ирем һәйбәт, улларым сәламәт, үзем тормышымнан канәгать!» — «Канәгать? — дип ярым мыскыллап көлде Гөлнара. — Син — бала! Канәгать булуның ни икәнен беләсеңмени син?» Гөлнара саксызлык күрсәтте, беренче мәртәбә сердәшен түбәнәйтте, сизенеп, тигезлекне торгызыр өчен, елмаеп Наиләне кочагына алды. «Ә син тормышыңнан тулы канәгатьме?» — дип сорарга базды Наилә. Һәм Гөлнара аңа менә нәрсәләр сөйләде.

«Үз иреннән тулаем канәгать асыл хатын-кыз була диме? Мин моны җенси яктан гына әйтмим, Наиләкәй. Яхшы хатынга ниләр кирәген аңлап бетерә алган ир-ат бармы дөньяда? Аңласа, ул гади кеше түгел, ул йә җен-пәри, йә пигамбәр! Минем ирем аларның берсе дә түгел».

Гөлнара борынын мәзәк җыерып уйга калды, сердәшенең кочагыннан чыгып, Наилә тагын сорау куйды: «Кем соң синең ирең?!»

«Минем ирем — вампир,— диде кинәт Гөлнара.— Бу сүзнең татарчасын белмим, убыр микән, аждаһа микән, вампир — кан эчеп яшәүче ярканат була инде, җан ияләренең иң кабахәте».

Наилә Гөлнараны бүлдермәде, керфек какмады, йотылып һәм йотлыгып тыңлады.

«Ул бер йолкыш студент иде. Минем әти, надан башы белән райком секретаре булып эшләгән кеше, соңра әллә шул наданлыгын яратып Верховный Совет Президиумы әгъзасы да иттеләр үзен, укыган кешеләр арасыннан кемнәрнедер ярата да иде. Киявен әти күтәрде. Без күп бала, әни бала ташыган да бала ташыган, мин — төпчек, иркә кыз, яшь чагымда үтә беркатлы, менә синең сыңар, Наилә дускаем, кая карасам да, офыкта яктылык кына күрә алган бер зат идем. Өйләнештек, күземне йомып егет сайладым, сукыр килеш кияүгә чыктым. Әти тиз-тиз квартир юллады, ирем югарыга баскыч араталарын сикереп түгел очып үтте. Карыйм һәм ни күрәм: кичәге ыштансыз студент югарыда! Яшибез, тормыш иркен, тормыш мул, һәммәсе шәп, һич ихтыяҗ юк, эчәр суны чишмәдән ташыйлар, сөт-каймак, итне авыл хуҗалыгы институтының фермасыннан китерәләр, беренче сортлысын гына ашыйбыз. Бала туды, аны ике әби, ике бабай, кардәш-ырулар уч төбендә йөртәләр. Иремә тагын да югарырак урын юрыйлар, якын араларда өлкә комитеты секретаре булачак, дип җибәрәләр. Тирәмдә йөзләрнең юргалавына карап, үзем дә шуңа ышана башладым. Иркә кыз, иркә килен, Казанның сөеклесе булып яшәп ятам. Тормыш сере һич көтмәгәндә бик гади генә ачылды да куйды... Һай, Наилә иркәм! Башта авыр булды, үләм дип торам. Беркөн шулай иртән иремә чәй ясап йөрим, кулымда ак чәйнек, Япониядән алып кайтканнар иде, бүләккә, тиктомалдан ирем башын кыйгайтты да: «Гөлнара, мин акча югалттым... Син алмадыңмы?» — дип сорый. Сүзе колагыма юньләп кермәде дә, болай гына, шаяртып: «Күпме иде?» — дип сорадым. «Илле сум иде», — ди теге. Коелып төштем, чәйнегем кулымнан ычкынып, затлы кытай ашъяулыгын буядым... «Син алгансың!» — ди бу... Китте ызгыш, купты талаш, элеп алдым теге мокытны, селкеп салдым. Җеп очы кулга тигәч, алай гына ычкындыраммы мин ир дигән хайванны?! Ирем миннән яшереп акча җыя икән! Аннан-моннан кергән ришвәт акчаларын алтмыш меңгә җиткергән бу! Саранлыгын белә идем, шул чакта комсызлыгын ачыкладым моның... Кырмыска сыярлык ярыкларга кадәр тыгылып, өйне җентекләп тентеп чыктым, саклык кенәгәләрен, кыбырсык кәнтәйләрдән килгән хатларын, көндәлекләрен табып өйрәндем. Булыр-булмас ирләр җиңүләрен дәфтәргә теркәп үтәргә яраталар, бел! Белгәннәремне аңа ачмадым, кая ул! Куанам, дускаем, шул сәгатьтә мин рухи өлгереп җиттем, ныгыдым һәм бер ачыш ясадым: гаиләдә тормышны мин алып барам икән! Мин! Тышкы яктан җилбәзәк күренсәм дә, бар авырлык, бар мәшәкать минем җилкәгә салынган икән. Минем көчем, энергиям, дәртем икебезгә дә яшәү көче, тормышыбыз чыганагы булган икән! Аллакай гынам, күрсәнә: ирем — вак, көнче, селәгәй бер бәндә, вампир сымак, убыр булып минем кайнар каным хисабына һаман өскә үрләп, дәрәҗә-орденнар алып һәм боларның һәммәсе дә үз уңганлыгы бәрабәренә килә дип масаеп, ир саналып йөри икән. О-о, гаиләдә ир ир булсын өчен хатын-кыз сансыз-исәпсез көч түгә! Ә мин ир урынына күкрәгемдә кан хисабына яшәүче убыр үстергәнмен! Шуны аңлаганнан бирле, җанкисәгем, икенче тормышым башланды. Фырт иттереп киендем дә шәһәребезнең иң мәшһүр ир хатыннары белән бер сафка бастым, мунча ширкәтенә юлыктым, иремнән сукыр бер тиен сорамадым, үзем дә бирмәдем. Үземне гаилә башы дип игълан иттем һәм аңа кан бирүдән туктадым. Өлкә комитеты тәтемәде, орденнар яңгыры кыеклап үтте, мин аны иплэп-иплэп, сиздермәслек итеп, үзенең асылына — башмак астына төшерә башладым. Мәгънәсез икән, үсмәсен ир! Эшләсен, мал тапсын, ләкин үсмәсен. Бер хәлдә, күземә карап кына яшәсен.

«Теләкләреңнең барысына да ирештеңме соң?» — дип кыяр-кыймас кына сорады Наилә, Гөлнараның ирен җәлләп. «Ирешеп киләм. Илле тәңкәсен түгел, бәйсезлеген югалтты ул! Ак магия ярдәмендә иплэп кенә мин аның барлык рухын үземә алам!» — «Ничек итеп?» — дип кычкырды тәкатьсез калган Наилә. Гөлнара көлеп җибәрде. «Мин аны сүзсез-өнсез ишәккә әйләндерәм! Ул чишенгәндә йә киенгәндә ике кулымны күкрәгемә кушырып арт ягына килеп басам да күз нурларымны җилкә тамырына, умыртка баганасына терим. Арка миен суырам! Кайчагында артына баскан килеш ике кулымны өскә күтәрәм. Үкчәм идәндә, бармак очларым һавада, ике арада яшен йөртәм, үч ташкыны үткәрәм. Ул хәлсезләнә, борылып карый, куркып кына: «Ни эшлисең?» — дип сорый. «Туңдым, җылынам», — дим мин аңа. «Минем җылымны аласыңмыни?» — дигән була, сораштыра. «Алсам, җылыңны җәллисеңме?» — дип, авызын томалыйм тегенең».

Наилә Гөлнараның бичара ирен күз алдына китерде дә, бугазына килеп тыгылган яшьләрен көчкә тыеп, әңгәмәнең сөземтәсен, мәгънәсен көтеп калды. Мондый шәфкатьсезлекне, сихер ярдәмендә ирен изүне бер максатсыз эшләмәс ич инде аның сердәше?!

Тик Гөлнара сер капчыгын азаккача чыгарып селкергә ашыкмады. Наилә, тәкатьсез калып: «Максатың ни? Ахыр чиктә син нәрсә телисең?» — дип сорарга мәҗбүр булды. «Әүвәл башта мин аның җыйган малына хуҗа булырга телим. Элегрәк: «Чит илгә алып чык, йөрт, дөнья күрсәт!» — дип инәлдем, колагына да элмәде. Әллә нинди хәйләләр тапты. Хәзер юк! Кая телим, шунда борам... Японияга алып барачак ул мине, Австралиягә! Канар утрауларында ял итәсем килә минем! Мексикада буласым килә!.. Убыр-вампир миңа хезмәт итәчәк! Үлгәнче! Тагын ярты ел, бик күпкә түзсә, ел үтсен, аның җаны учка сыярлык булып, кеп-кечкенә калачак. Кеше җанына хуҗа булу гына хатын-кызга тулы бәхет китерә, Наиләкәй!»

Озак сөйләштеләр алар ул очрашуда. Наилә, әүвәл башта юаш кына, әле сокланып, әле кызганып, әле нәфрәтләнеп, ара-тирә җирәнеп тә тыңлаган Наилә, азакта бер акыл җыйнап калды — үз тормышына, читтән торып, ят, күпне татыган хатын булып — Гөлнара булып карады.

Ул да уңга-сулга тайпылмыйча, булачак иренең шапырынулы вәгъдәләреннән исереп, башын җуеп, егетнең шашкан кочагына ташланмадымыни? Дөрес, кочагы упкын булып чыкты егетнең, кызны берьюлы суырып алды, тибрәтте, иркәләде, оныттырды. Аһ ул ширбәт айлары! Наиләне юкә балына чумдырмадылар. Ул хыял диңгезендә, өмет-вәгъдәләр океанында татыды бәхетне.

Татлы төш бер өзелә, йокыдан уянмыйча ярамый. Наилә дә уянды, ләкин айнымады. Бер-бер артлы туган уллары, иренең комсыз тырышлыгы, юлда очраган киртәләрне эзлекле җиңә баруы аның күзен ал пәрдә белән каплады. Ул аңа, аның киләчәгенә, җиңәчәгенә ышанып яшәде. Ышанды ышануын, ә алар гаиләсендә энергия чыганагы кемдә булуын эзләп карамады. Дөрес, ире эшләде, кирәгендә мебельче грузчик булды, йөз чөермәде — кулына себерке тотты, авыр чүкеч белән тимер чүкеде, алай да тормышның бөтен авырлыгы, ыгы-зыгысы Наилә кулында түгел идемени? Ире эштән, укудан арып, гасабиланып, болытлы көндәй кашларын сәлперәйтеп, телен тешләп кайтып кергәндә, бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы хезмәт күрсәткән хатын аны айдай балкып каршыламадымыни? Ире зарланды, Наиләгә зарланырга чират тимәде. Арыган ирнең җанын тынычландыру өстенә тәнен дә иркәләргә кирәк иде. Ут чәчелергә тиеш иреннәр арасыннан иркәләү сүзләре генә чыкты, көне буе талган куллар, яргаланган бармаклар ирен иркәләделәр.

Гадәттәгечә, Гөлнараның куркыныч тәҗрибәләрен Наилә үзенчә кабул итте, ышанып ук бетмәде, мәгәр бер уй, бер тойгы күңелгә очлы ук булып китмәскә кадалды, һәм Наилә аны суырып алырга, яраның ямалуын ашыктырырга теләмәде. Ук, аның мәшәкатьле тормышына татлы сызлау өстәп, күкрәккә кергән килеш калды...

Һәм беренче тапкыр ирен реанимация караватында, төбе тишек көймә хәлендә күргәч, ул аны бөртек тә кызганмады, күкрәктәге ук тагын да тирәнгәрәк үтеп керде, яра зурайды, тирәнәйде…

Ике баласы белән ирен поездда каршылаганда да күңеленә ачу хисе хуҗа булып торды...

Менә хәзер 15 нче больницага очканда, ике якта адашып калган ике баласы өчен борчылып тырпылдаганда, ул Нәҗибен балаларына кушып, бергә кызгана башлады. Моңа кадәр эчелгән нужалар алда көткән газаплар янында уенчык кына булачагын ул кар баскан шәһәр урамнарында ирен эзләп барганда аңлады. Таныш, күнегелгән урамнардан барганда да уйларның төрлесе иңә, бүген аның уйлары аяусыз, ачы һәм авыр иде.

Нәҗипне больницада нибары бер атна яткырдылар, «хәлегез түзәрлек, инфаркт юк, анализлар әйбәт, ә больницада урын җитми» дип, тайчанмыйча әйтеп бирде дәвалаучы врачы.

Тормыш тоташ газапка әйләнде. «Үлем», «әҗәл», «зират», «чир», «йөрәк» дигән сүзләрне ишетүгә, Нәҗип: «Хәзер мин дә үләм,— дип калтыранды,— әҗәлем җитте!» — дип, даруга тотынды. Валидол, нитроглицерин кесәдән төшмәде, яктыдан караңгыга, караңгыдан яктыга керә алмады. Ул ялгыз калмаска тырышты, әллә ничә шөгыльгә тотынып карады, Тимерхан карт белән ишегалларын себереште, балта-чүкеч тотып койма такталарын рәтләштереп йөрде, шифа булмасмы дип, дәреслекләрен актарды, Искәндәр белән Рөстәмен ияртеп Черек күлгә, бала-чага кайнашкан урынга барды, юк, дөньяда әҗәл барлыгын һәм шул әҗәлнең аны кара гүргә өстерәвен берчакта да оныта алмады. Булды төннәр, Наиләсе ачыргаланып, аннан-моннан гына киенеп, телефонга чапты, «ашыгыч ярдәм» икешәр тапкыр килде. «Үләм», — дип ыңгырашты Нәҗип, врачлар укол арты укол кададылар, анда да тынычландыра алмагач, Нәҗипләрнең кысан фатирында медсестра саклап калгалады. Киләләр, карыйлар, тыңлыйлар, «синус тахикардиясе» дип китеп тә баралар. Тикшерүләр, анализлар берне күрсәтә, ә Нәҗип бөтенләй икенчене, куркынычны сөйли...

Ихтыярын җуйган, кыска арада җиде-сигез килога ябыккан Нәҗип Йосыф улы Нургалиевне врачтан врачка, больницадан больницага, белгечтән белгечкә куып йөрттеләр. Наилә үз хисабына тагын ял алды, кулыннан эш төште. Иң авыры шул иде: кайткан шәпкә ире янына килгәләп, хәлен белешеп йөргән хезмәттәшләре кинәт күренмәс булдылар. Ул аптекаларга чапкан арада заводка кагылып чыкты һәм хәле Нәҗипнекеннән дә авыраеп, бетәшеп кайтты. Директор Мәскәүдә чакта бирәү белән килешенеп кайткан да, шул чакырылган кеше, техник фәннәр кандидаты, грузин хатыны

Валентина Чхиквадзе ирен, өч яшьлек улын ияртеп, төянеп килеп тә җиткән. Аны лабораториягә мөдир итеп куйганнар. Нәҗипләргә багышланган квартирны да аңа биргәннәр. Өч бүлмәлене!

Наиләне аяз көнне яшен сукты. Тип-тигез җирдә тәгәрәп егылды. Тауга менәргә җыенган урыннан тирән, тар упкынга чәнчелеп барып төште. «Чукынсын бөтен дөньясы! Кырыкмаса кырык чөе кырылсын!» — дип, поезд астына ташланырга уйлады. Сабыйларын, рухы имгәнгән көчсез ирен хәтерләп, чакырылмаган уеннан кире кайтты. Дилбегәсе чуалды хатынның, маякларын дулкын төпкә төшерде, кайда ал, кайда арт икәнен белмәс хәлдә калды.

Инде бу хәбәрне иренә алып кайтып тапшырса, ни булачак? Йөрәге ярылып үләрме? Инфаркт чалып егып гомерлек имгәк булып калырмы? Әйтми торырга да ярамый, барыбер хәбәр килеп җитәчәк, чит авыздан ишеткәнче, хатыныннан ишетсен, чарасыз чакта хатыннан да кадерле зат юк, ул китергән хәбәр шунда ук урталай бүленә — кайгының яртысын хатын үзендә калдыра, икенче яртысын хәлең җитмәсә дә күтәрәсең...

Шулай уйлады Наиләнең боек күңеле, шулай уйлап, куркынычлы очрашуга әзерләнеп кайтты. Ипләп кенә, песи сыман шым гына кайтып керде. Көн язга тарткан — кояшлы, поездлар дөбердәүләрен киметкәннәр сыман, ян бакчада талгын җилдә тирбәлеп утырган чия ботакларында песнәкләр сикерешә. Язны ашыктыралармы? Шулайдыр. Юл читләренә кара челтәрләр төшкән. Яз килә! Сөенеп кенә яшисе дә бит, юк. Җае юк, мөмкинлеге җитми, кайгы-хәсрәт ишелеп килә тора...

Гаҗәп! Хәбәрне тыныч тыңлады Нәҗип, сабыр гына кабул итте. Наилә күзен алмады, иренең чырае үзгәрмәде, күзеннән аңа мәгълүм курку галәмәте йөгереп узмады. Үзен төртеп егуларына, юлдан алып ташлауларына Нәҗипнең һич исе китмәгәндәй булды. Даруга да барып ябышмады. Квартирның бик җайсыз чакта кулдан ычкынуын да аерып әйтмәде, ирен иң нык ярсытканы мөдир булып эшкә чит шәһәрдән грузин хатынының килүе булды. Маңгаен җыерып торды да, җене котырып, хәбәрнең шул өлешен каһәрләргә кереште. «Читтән кеше җыймасалар ярамаганмы? Мин чирләп егылганмын икән, лабораториядә бүтәннәр беткәнме? Безнең директорның гел шул булды инде, татарны яратмады. Татар куярга теләмәсәң, менә дигән чуаш егете бар иде. Алемасов! Егетләрнең егете. Тырыш. Ахыр чиктә татарлардан да мөдир табарга була иде. Элегрәк тә мөдир грузин булган, аны Чихрадзе алыштырды. Хәзер тагын Чхиквадзе килгән. Бу ни хәл?»

Урыс, татар дип берчакта да кешене аерып карамаган, бөтен милләт вәкилләре белән бик тиз уртак тел таба алган иренең авызыннан чыккан сүзләр бүген Наиләне гаҗәпләндерде. Әллә шул килгән гөрҗи хатынын сүгеп, кирәкмәгән якка тәртә каерып, хәсрәтен җиңеләйтмәкчеме? Мөгаен, шулайдыр. Моңарчы милләт аерганы юк иде татар баласы Нургалиевнең.

Исең китәрлек, гаиләдәге һәр аңлаган кешене аяктан егарлык хәбәр киресен эшләде. Нәҗипкә көч бирде, күңелендә туган каршылык хисе аны урыныннан торгызды. Һәм ул кайтканнан бирле беренче мәртәбә эшенә барырга җыенды. Бу кинәтлек Наиләне куркытты, Наилә читтән-чоттан сораулар биреп аның җебен тартып карады. Ник бара, кемне күрергә тели, кирәкмәскә утын ваклап кайтмасмы тагын? Кызып китеп җүләрлек кылмасмы? Мөдир түгел икән, әйдә, чәнчелеп китсен! Лабораториясендә генә калсын! Яшәделәр, тагын яшәрләр. Наилә тынмас, подъезд юар, инде соң чиккә җитсәләр, шәл бәйләп сатар. Казан арты кызы ич, болгар токымыннан, әнкәсе бәйләгән шәлләр һәрвакыт югары бәядә йөрде. Арада Наилә бәйләгәннәре дә бар иде ләбаса!

Ул шушы дәлилләре белән ирен өйдә калдырмакчы иде, ләкин Нәҗип күзгә күренеп үзгәрде, кайта-кайта чит җирдән кеше чакырган директорның тетмәсен тетте.

«Барам. Керәм. Күрәм. Сөйләшәм! Бала-чагамы мин аларга? Чакырып сөйләшсәләр, укалары коелыр идеме?!»

Наилә, ирен заводка җибәрмәскә тырышып, капка баганасына ябышып, телен тешләп калды. «Яхшыга булсын, Ходаем!»

Кызып-янып барган шәпкә Нәҗипнең күңеленә икеле-микеле уйлар да килеп киткәләде. «Мөдирнең бүтән халык вәкиле булуына ник бәйләнәм соң мин?» — дип тә уйлады. Җавап эзләп тормады, күңеле кырылган, кимсенгән иде. Завод ишеге төбендә аны шактый озак үткәрмәделәр, таныш каравыл начальнигы килеп чыккач кына керергә рөхсәт бирделәр.

Бәхете — директор каядыр киткән булып чыкты. Әгәр Нәҗип хәзерге мәлдәге уйларын ачып салса, аны йә больницага, йә милициягә алып китәрләр иде. Явыз сүгенү сүзләрен секретарь кыз ишетмәслек итеп кабатлап, ул Храмовны эзләп китте. Ходай саклады — Храмов та Мәскәүдә, командировкада икән. Нәҗип чак кына аптырап калды, кая барып керергә белмичә коридорда айкалганда, теге баштан кәс-кәс атлап килүче Изил Латыйповны күреп алды. Латыйповның кулы буш түгел, гадәттәгечә, кәгазьләр тоткан, чырае ачык, йөзе балкыган. Нәҗип исә сөрем болыты, килеп җиткәч кул бирәсе урында, йодрыкларын йомарлады, Изилгә үтереп карады. «Тукта, Изил»,— диде Нәҗип, нык итеп. «Юк,— диде Изил, гауга чыгасын сизенеп,— вакытым юк. Халык көтә. Профком утырышы. Мәскәүдән вәкилләр бар».

Нәҗипнең маңгаена бер сыр йөгерде: тукта, нигә уен утырышта уртага салмаска?! «Мин дә синең утырышыңа керәм!» — диде ул кинәт. «Мин сине чакырмадым»,— диде Изил, көлемсерәп артка

чигенеп. «Чакырган җиргә генә йөрергә син мине кем дип белдең?» — «Нәҗип, гафу ит, ашыгам».— «Мин ашыкмыйммы?» Юк-бар бәрелешләрдән сагаерга өйрәнгән, бусагаларны җиңел үтеп гадәтләнгән Изилнең Нәҗип белән тарткалашасы бер дә килми иде. «Иртәгә тугызга үземә кил, бөтенесен хәл итәрбез!» — диде ул, Нәҗипнең иңенә дымлы кулын салып. Нәҗип кулны иңе белән кагып җибәрде: «Шомартырга маташма!» — диде һәм, ишеккә аркылы баскан Изилне бер якка этеп, утырышлар залына барып керде. Анда утызлап кеше түземсезләнеп Латыйповны көтәләр иде, алар Нәҗипкә бөтенләй игътибар да итмәделәр. Изил кереп җитте, ым белән Нәҗипкә шым утырырга боерды, утырышны ачып җибәрде. Көн тәртибен расладылар, утырышларга яратып йөри торган кешеләрнең кулы югары күтәрелде, алмаш-тилмәш чүбек чәйнәргә тотындылар... Титан ватылган — эчәргә су юк; тулай торакның бәдрәфенә җил өрә — тәрәзә пыяласы юк; пенсионер Гавриловның карчыгы үлгән — акча илтә барырга кеше юк... Тыңлап-тыңлап утырды Нәҗип, чыдамады, кул күтәреп тормады, сүз биргәнне көтмәде, Изил янына алга чыгып басты.

«Сез монда бәдрәфләр, титаннар хакында гәп куертып, эшем ияләре булып утырасыз. Ә монда, берләшмәдә, шундый-шундый хәлләр. Ярый, сугыш азагында рейхстагка байрак кадаучылар итеп урыстан һәм грузиннан сайласыннар да ди... Ә хәзер? Ни өчен берләшмәгә аяк баскан урыслар, украиннар һәм башка милләт вәкилләре ел-ел ярым эчендә кинәт кенә үсеп китәләр дә дәрәҗәле урыннарга менеп утыралар. Ә татар белгечләре, татар галимнәре һаман бер урында таптана?! Әнә грузин хатыны килеп тә җитмәгән, аның эш сыйфатларын әле беркем белми, аңа һәммәсе әзер: мөдирлек тә, өч бүлмәле квартир да, баласына бакча, бүтән льготалар... Гаделлекме бу? Мин монда директор тарафыннан милли тарлык күрәм. Кайчанга кадәр мондый хокуксызлык дәвам итәр? Берләшмә Татарстан җиренә, Казанга урнашкан лабаса? Директор татарларны яратмый, диләр. Имеш, алар фән белән тирәнтен шөгыльләнә алмыйлар, тел өйрәнеп ярты гомерләре үтә. Грузинканың килүе — шуның шаукымы. Милли тарлык кайчанга кадәр бездә яшәр икән?!»

Латыйпов, Нәҗипкә тукталырга боерып, ике кулы, иңбашлары, теле, каш-керфекләре белән меңнәрчә ым биреп караса да, Нургалиевне тыяр, туктатыр көч юк иде. Ул милли чикләүләргә багышлап тагын берничә мисал китерде, директорны — «шовинист», партоешманы — «ваемсыз», профсоюзны «чүпрәк» дип атады. Латыйпов, ул сөйләп бетергәч, бер мизгел уйланып торды һәм: «Без Нургалиевнең кызулыктан әйткән ялгыш фикерләрен беркетмәгә кертмибез, аны игътибарга алмыйбыз»,— дип йомгак ясады. «Ах, кертмисезме? Ах, игътибарга алмыйсызмы?!» — дип ярсып кычкырды Нәҗип һәм, йодрыгын йомарлап, бүлмәдән чыгып китте. Утырыштагылар аңга килгәнче, ул ишекне тагын ачты һәм: «Сез таш курчаклар булсагыз, мин фикерләремне язып парткомга илтәчәкмен!» — дип кычкырды.

Наилә белән ике көн сөйләшмәделәр. Нәҗипнең йөрәк өянәге кузгалды, ул иртәдән кичкә кадәр дарулар эчеп, уфылдап караватта ятты, тормады диярлек. Кемнәрне очратып, нинди давыл куптарганын ул хатынына сөйләмәде, ни майтарганын үзе дә аңлап бетерә алмый иде шикелле.

Ике көннән аны завод профкомына чакырып курьер килде. «Бармыйм!» — диде кистереп Нәҗип.

Иренең, бәйдән ычкынып китеп, теге көнне нидер ярамаган эшкә таруын Наилә төшенгән иде, бүген ул да аяусыз булды. «Мөдирлек кулыңнан ычкынгач, синең нәрсәдер җимерәсеңне, тар-мар итәсеңне көтә идем. Чирле башың белән ярамаган эшкә тарыгансың, хәзер күләгәдә посып калыргамы исәп? Хәзер сиңа сугыш түгел, солых кирәк. Бар, тишкәнсең икән — ямa, ерткансың икән — ялга».

Хатынының кискен хөкемен ишеткәч, ул чакырган җиргә барып кайтырга булды.

Профкомда аны ике кеше көтә иде. Изил янында утырган тәбәнәк, юантык гәүдәле ирне күргәне дә бар иде Нәҗипнең,— кул бирешеп күрештеләр. Изил Нәҗипкә күтәрелеп карамады, чакыртучының ул түгел, ят кеше икәнен Нәҗип шунда ук аңлады, көрсенеп тәрәзәгә, тәрәзәгә орынырдай булып аккан каракучкыл болытларга карады. «Сез профком утырышында, кызып китеп, хилаф сүзләр ычкындыргансыз. Партоешманы, профсоюз комитетын гаепләгәнсез. Язма рәвештә сүзләрегездән баш тартырга, «ялгышканмын» дип хатагызны танырга туры килер», — диде ят кеше. «Танымасам? Киресенчә, фикеремне куәтләп партоешмага язып кертсәм? Мин хаклы идем, фикеремне мең мисал белән раслый алам». Ят кеше белән Латыйпов бер-берсенә карашып алдылар. «Менә... мин сезгә әйттем ич!» дигән кебегрәк, Латыйпов кулларын ике якка җәеп җибәрде. Үгетләмәделәр Нәҗипне, тәртипкә чакырмадылар. «Уйлагыз алайса, төптәнрәк уйлап карагыз!» — дип озаттылар.

Нәҗип рәнҗеде, ачуы тагын да кабарды. Ул, өенә кайткач, ике бит кәгазьне тутырып гариза язды һәм, Наилә кайткалаганчы дип, гаризасын партоешма секретаре Иващенконың өстәленә илтеп салды. Ике көннән машина белән килеп Нәҗип Нургалиевне партоешмага алып киттеләр. Бу юлы бүлмәдә дүртәү утыралар иде. Теге көнне Изил янәшәсендә очраган ир дә монда. Алар басынкы гына нидер сөйләшәләр иде, Нәҗип бүлмәгә керүгә тындылар. Сүз анда да бик кыска булды. «Гаризаң белән таныштык,— диде Иващенко,— фикерләрең мәгълүм булды. Бәйләнүләрең нигезсез, фикерләрең хата дип саныйбыз. Гаризаңны кире аласыңмы, юкмы?» — «Кире алыр өчен язмадым, мин партоешманың бер-бер чара күрүен көтәм!» Бүлмәдәгеләр кузгалмадылар, алар авыр күз карашларын бер-берсенә йөртеп, Иващенкога нидер ымладылар. «Яхшы,— диде Иващенко,— җавапны тиздән алырсың!»

Көн үтте, төн, тагын бер көн, ике төн узды, хәрби комиссариаттан Нәҗип Йосыф улы Нургалиевне чакырып повестка килеп төште. Бусы һич көтелмәгән яңалык иде. «Әллә халыкара хәлләр начарланганмы?» — дип сорады Наилә. «Аның яхшырганы да, яхшырасы да юк», — диде пошынып уйлап Нәҗип. Наилә ирен юатырга тырышты: «Мөгаен, сине белгеч буларак бирәр консультациягә чакыралардыр әле!»

Военкоматның кайда икәнен дә онытканиде инде Нәҗип, көчкә эзләп тапты. «Син комиссия торырга тиеш, без сине армиягә алабыз», — диде көяз өлкән лейтенант Шумилов. «Армиягә?» — Нәҗип эчтән генә көлемсерәде: бүгенге хәлендәме? Инфарктан чак-чак үрмәләп качкан кешене утыз өч яшьтә армиягә алсыннармы?

Хәрбиләрнең сүзе кыска, армиягә тек армиягә, Нәҗип Йосыф улы Нургалиев озын исемлек тотып үз больницасына кайтты һәм врачтан врачка йөри башлады. Күзен каратты — яхшы, диделәр. Колак та сак икән, почмактан пышылдаганны ишетте. Хирург та әллә ни тапмады, невропатолог эштер-өштер әйләндергәләде, каккалап-суккалап маташмады, «годен!» дип егетне чыгарып җибәрде. Наилә белән Нәҗип тагын бер хафалы төн үткәрделәр. Иртәгесен ул беренче булып терапевт карамагына керергә тиеш. Мәскәүдән кайткач, алар Иван Илларионович белән берничә тапкыр очрашканнар иде инде. «Йөрәгеңнең рәвеше бер дә мактарлык түгел, түгел!» дип, Иван Илларионович аңа берничә төр даруны эченә тутырган капсулалар йотарга тәкъдим иткән иде. Шәт, Иван Илларионович ике сөйләшеп тормас, «негоден, чирле, йөрәге тырпылдап кына тора» дип язып бирер...

Иван Илларионович та аңа бүтән врачлар кебек үк күтәрелеп карамады, җилкәсенә авыр йөк салган йөкче кебек иелеп нидер мыгырдады, берсен берсенә чәнчегән тезләрен атындырып куйды. Мондый салкынлыкны көтмәгән Нәҗип, учына йөткереп: «Менә бит, Иван Илларионович, военкоматтан комиссия торырга җибәрделәр... Ни кыланалардыр», — диде. «Күрәм, күрәм, — диде врач, Нәҗип кулыннан кәгазьне алып, — беләм дә!» Ни белгәнен Иван Илларионович аңлатып тормады, врачларча кыеш-мыеш хәрефләр белән «годен» дип сырлап, кәгазьне Нәҗипкә таба этәрде. «Ничек? — диде дәрте сүнеп Нәҗип. — Чиремне беләсез, Мәскәүдән кайткан кәгазьләр кулыгызда иде. Дарулар яздыгыз. Бу йөрәк белән мин армиядә нишләрмен? Мин берни дә аңламыйм». — «Анда аңлатырлар! — диде врач, кулын селкеп тәрәзә белән ишек арасына төртеп күрсәтеп. — Анда карарлар!»

Чирек сәгать коридорда һушы таралып торганнан соң гына Нәҗип иң югары кабинетка — психиатрга барып керде. Көл сыман чәчләре учма-учма ак калфагы астыннан чыгып, җилкәсенә тәртипсез таралган юан, озын кеше иде психиатр. Чал, тузгыган бакенбардлары, дәү барабан корсагы, нәзек ботын кысып торган тар чалбары, кеп-кечкенә аякларына элгән чүпрәк чүәкләре аңа ышанычны киметәләр иде. Ак керфекле, ак күзле, сипкелле куллы бу врач Наум Исаакович Фогельсон булып чыкты. Нәҗип килеп керәсен алдан белгән кебек, ул аксыл, эре бөртекле кашларын яман җыерып, ишеккә төбәлеп, бармаклары белән как өстәлгә барабан кагып аягүрә басып тора иде. «Ә-ә, Нургалиев? Килеп җиттеңме? — диде ул, мыскыллы аһәң белән. — Вакыт, вакыт. Көтәбез!» Нәҗипнең Иван Илларионович янында туа башлаган шиге Фогельсонның кыланмышын күреп тагын да көчәйде. «Бала-чага әз туа, армиягә ирләр җитешми, кайбер очракларда өлкәннәрне дә чакыртып алалар, мөгаен, военкомат «Нургалиевне алырга!» дигән күрсәтмә җибәргәндер»,— дип уйлады ул.

Фогельсон егеткә чүгәләргә кушты, Нәҗипнең әкрен, сак кылануының серен сорады. «Мәскәүдә чирләп егылдым, инфаркт алды дип больницадан чыгардылар»,— дип аңлатты Нәҗип һәм ымсынып врачның чыраена карады. Психиатр Фогельсонның бакенбардлары кыймылдаудан аның яңак сөякләре уйнаганын белеп була иде. Нигә шулкадәр гасабилана ул?

Врач марш атлатты, Нәҗипнең күз алмаларын уңга-сулга йөрттерде, аска-өскә каратты, борынын чеметеп торды һәм тонык, җансыз тавыш белән: «Сезне бу хәлдә армиягә җибәреп булмый, сездә психик тайпылышлар бар»,— диде. Нәҗипнең эче җылынып китте, армиягә алмасыннар гына, тайпылыш түгел, чурт булсын аңа! «Мин сезне психоневрологический диспансерга салырга мәҗбүр-мен, сезгә дәва кирәк!» — диде Фогельсон һәм Нәҗипнең кәгазенә үрелде. Нәҗип өнсез калды. «Ничек?» — диде ул, тотлыгып. «Шулай, саулыгыгыз шуны таләп итә»,— диде Фогельсон. Нәҗип ялт итеп кәгазьне врач кулыннан тартып алды. «Мин сәламәт!» — диде ул, кызмаска тырышып. («Ходаем, монда кайнарлана башласаң, «җүләр!» дип әллә кая тыгып куярлар!»)

Исенә кылт итеп моннан бер ел элек ишеткән вакыйга төште. Яңа бистәдә, алар урамында, ике йорт аша гына Сәгыйдулла исемле кеше яши иде. Шофер иде, бичара, урамда кеше таптатып, ике елга төрмәгә яптылар. Ике елын шунда, Казанда гына үткәрде бу. Котылып чыккач, урам эскәмиясендә әңгәмә куертканда, Нәҗипне бик яхшы белмәсә дә, башыннан үткәннәрне сөйләде. «Һай, дөньяда әллә ниләр бар икән, күрергә язмасын! Җүләрләр зонасында эшләдем мин, машина йөрттем. Хәйран эшләр вәйран икән анда! Илгә, хөкүмәткә каршы сүз әйткәннәрне җүләрләр арасына илтеп тыгалар да

югалталар икән. Сау-сәламәт адәм дә тиле санала. Әгәр берәвесе каршы килеп авызын ачса, тавыш күтәрсә, уколны тыгып кына куялар, ике ай телсез бүрәнә булып ята теге... Бер мулланы очраттым, егерме ел шунда интегә икән! Арада поплар, студентлар бар дип сөйләделәр. Галәмәт инде анда хәлләр! Галәмәт!»

Димәк... хәзер Фогельсон язып бирсә... Аны да шунда илтеп тыгачаклар?! Ни өчен?

Нәҗип каушап ялына башлады: «Зинһар, дим, алай эшләмәгез инде. Зәгыйфь йөрәк белән...» Хатынын, квартирсызлыгын, балаларын телгә алды. Фогельсон кырыс кына тыңлап торды да, коридорга ишетелерлек итеп: «Юк, юк! Сорамагыз да, үтенмәгез дә! Сезгә дәваланырга кирәк!» — дип бакырды. Аннан егетне ике кулы белән почмакка этеп кертте, явыз, усал тавыш белән: «Син, атаң башы, партоешмага биргән гаризаңны кире аласыңмы, юкмы? Җыелышта әйткән сүзләреңнән кире кайтасыңмы?!» — дип пышылдады.

Фогельсон бүтән сүз әйтеп тормады, көчле куллары белән почмактан Нәҗипне этеп чыгарды да башы белән ишеккә күрсәтте.

Заводка йон урынына очты Нәҗип, трамвайдан сикереп төште, троллейбуска атылып менде, тыны-өне бетеп Изил Латыйпов янына чабып керде һәм: «Сүземне кире алам, алам!» — дип кабатлады. Иващенко янына алар бергә керделәр, партоешма секретаре алар күз алдында Нәҗипнең гаризасын аркылы-торкылы ертып ташлады. «Күптән шулай кирәк иде!» — диде.

Коридорга Изил белән алар бергә чыктылар. Латыйпов нидер әйтмәк булып бераз кысталып торды да: «Башың болай да бетте синең... Психушкада учетка алдылар сине... Әгәр андый-мондый эшең беленсә, исе чыкса, шундук юк итәрләр, белеп тор. Минем киңәшне ычкындырма, аң бул! Хатын, балаларыңны җәлләп кенә әйтүем», — диде.

Изилнең соңгы сүзләрен аңлап бетермәде Нәҗип, аны-моны сорашырга дип, икенче көнне заводка барса, аны эчкә кертмәделәр. Атна азагында аның адресына юка гына пакет килде. Анда: «Нәҗип Йосыф улы Нургалиев завод лабораториясеннән үз теләге белән эштән китте», — дип язылган иде. Нәҗип кубарылып, әллә кайларга барып җитмәк булып калкынса да, бу юлы Наиләсе чакматаш булды — җибәрмәде. «Беркая бармыйсың! — диде ул, кистереп. — Син үзең хакында гына уйлама! Онытма, синең хатының, ике балаң бар!»

**7**

Алар капка төбендә очраштылар. Нәҗип өйдән югалып тору нияте белән урамга чыгып бара иде, Тимерхан карт кайтып килә икән. Нәҗип, йорт хуҗасына юл сабып, түбәнчелек белән башын иде.

Күпме вакыт бер ихатада яшәп, бер капкадан кереп-чыгып йөрсәләр дә, Нәҗипнең Тимерханга туры караганы юк иде. Шадра икән Тимерхан, тешсез икән. Кием-салымы да таланган икән. Тимерханның байтак еллар элек кайсыдыр бер оешмада экспедитор булып йөргәнен, шактый нык хуҗалык корганын, соңыннан кыек эшләре фаш булгач, бәладән баш-аяк дип, шома гына чыгып ычкынганын буш вакытларының берсендә Наилә сөйләгән дә иде бугай. Ул чакта хуҗа турындагы мәгълүматлар бер колактан керде, икенчесеннән җиңел генә чыгып китте. Нәҗип «мөдирлек белән» яши башлагач, Тимерхан-шадра, Тимерхан-тешсез бик түбәндә, күз күреме җитмәс аста калган иде. Эшеннән куылгач, ул байтак еллар зират тирәсендә ышкынган, кабер казыган, маклерлык иткән, «уңайлы, коры, сукмаклы якта» урын вәгъдә итеп мәет ияләреннән сәмән каерган, марҗалар белән себерелгән, акча туздырган. Тора-бара кулдан мал, беләктән көч, күздән нур качкан, ары-бире кунып йөргән Тимерхан бер таңда өтәләнеп, таланып, шыр сөяген селкетеп карчыгы бусагасына кайтып егылган, тәүбәгә килеп гафу сораган. Кызы Таңсылуның үскән саен кулдан китә башлавын чамалаган карчык: «Әйдә, эт булып өрергә булса да ярар!» — дип, аны кабул иткән. Уклау белән аркылысын-буен үлчәп тәүбәгә китергән.

Акча өчен түгел, утын хакына алар Нәҗипләрне фатирга керттеләр, соңгы сүзне Таңсылу әйтте. Нәҗипнең озын буен, йомры беләкләрен, юантык ботларын комсыз күзләре белән ашый-ашый: «Керсеннәр, ичмасам, утын артыннан йөрисе булмас!» — дигән иде кыз...

Дөньяның шушы сөремле, төтенле, шау-шулы почмагын вакытлы гына дип исәпләгән Нәҗип хуҗаларны берчакта да санга сукмады, пропискага кереп, төпләнеп яши башлагач, ул аларны күрмәскә, очрашканда күрми үтеп китәргә өйрәнде. Сөйләшергә туры килгәндә сүзләрен колакка элмәде, аларны кешегә санамады, санламады...

Бүген бил үзеннән-үзе бөгелде, ирен читләренә, күз төбенә төче елмаю җәелде, ул олылап ике кулын Тимерхан картка сузды. Ул бүген картның үзен күрүен, бер булса да җылы сүз әйтүен, елмаюын, гомумән, кеше итеп санавын тели иде. Ичмасам, үтеп кенә китмәсен! Тукталсын, әпә-чәпә сөйләшеп торсын.

Яңа бистәнең иң иске, келәсе кылтырап, күгәннәре менә ычкынам, менә каерылып төшәм дип торган иң бәхетсез капкасыннан Нәҗип яңа дөньяга чыгып бара иде. Артта калган юллары юк, алар язмыш дәфтәренә сызылып килеп, бүгенгесе көнне резин бозгыч белән сөртеп ташланган кебек юкка чыкканнар. Яңа дөнья капкасын ачам дигәндә, теге яктан Тимерхан-шадра, Тимерхан-тешсез килеп керде. Ул, аптырап, үзенә җылы сузылган ике кулны тотып алды. Тырнаклары сынып, сыдырылып беткән икән картның, сул кулының ике бармагын түгәрәк пычкы кыеп төшергән икән. Мыеклары сирәк икән аның, төссез, ямьсез тырпайган мыеклар.

Тимерхан Бишбалтадан, карчыгы Җәмиләнең туган тиешле кешеләреннән кайтып килә, имеш. Агай-эне чәк кенә кәккәннәр, чәркә аракыдан соң бер-ике шешә сыра капканнар, туганнарның йомышы бар, төпчек кызларын кияүгә бирәләр икән, бирнәгә пианино алганнар, төпчек кыз музыка мәктәбе бетереп, балалар бакчасына эшкә дә килешенгән икән... Акчаны бик җиңел вәгъдә итте Тимерхан, фатирчыларның өч айга түләгәннәре юк, «шушы арада була!» дигән иде Наилә. Тимерхан, өенә кереп тормыйча, туп-туры фатирчылар ягына үтәргә, аяк терәп акчаны алып чыгарга ниятләп, дәртсенеп кайтып килә иде. Фатирчының капка төбендә үк очравы аны әз-мәз каушатып куйды, шуның өстенә акча җәһәтеннән аның ир белән сөйләшкәне юк иде шикелле. Хатын-кыз белән сөйләшү аңа җиңелрәк булса да, чыгып бетмәгән шайтан суы коткысының тәэсире булдымы, ул кыеп Нәҗипкә сүз катты, өч айга акча түләргә кирәклеген искә төшереп: «Хатының белән килешенгән идек, бүген — түләү көне. Акчаның бик тә хаҗәт чагы!» — диде.

«Акча» сүзен ишеткән Нәҗипнең башы әйләнеп китте. Ул, чыгып китәргә җыенуын онытып, кире борылды һәм мәэюс күзләре белән йорт хуҗасына карап: «Әллә әзрәк көтәсезме, Тимерхан абзый?» — диде. Тавышы җеп шикелле нәзек, ефәктәй йомшак, куян койрыгыдай калтырап тора иде егетнең. Тимерхан исә өстенлекне шунда ук сизеп алды, элгәре Нәҗип күләгәсендә кечерәеп калган камыт аяклы, черек теш төпләреннән ис аңкыган шалама карт, җәнлек эзенә төшкән сунарчы эт сыман сагаеп, тәнен дугадай киерде. «Юк, юк! — диде миендә котырынган сыра сөреме. — Күп көттек! Һәрнәрсәнең чамасы була! Булды! Бигрәк!»

Алар башта ипләп кенә, аннан кызып ук талашырга керештеләр. Бирге баштан җилтерәп Җәмилә, аргы баштан курка-курка гына Наилә килеп чыктылар. Карчыгы алдында гайрәт күрсәтергә форсат тапкан Тимерхан карт Испания корридасында яраланган Севилья үгезе кебек үкереп җибәрде. «Как так?! Не сметь! Бүген и вчё! Юкса белеш милицияләр мыж! Суд аша каерып алырбыз!» Җәмилә карчыкның колагы бу якта ни барын инәсенә хәтле белеп тора иде, ул да картын котыртып сүз учагына коры ботаклар өстәде: «Түләмисез икән, чыгып китегез!»

Бәхетсезгә гел вакытсыз дигәндәй, Таңсылу да өйдә икән, ул да, кулларын имиләре өстенә кушырып, чыгып баскан. Чәче дулкын, муенда камыт бөяте диярлек муенса, түштә нәни ташбака дәүмәлеге брошки, беләзекләре елтыр-ялтыр килә. «Түләп чыксыннар, түләп бетерсеннәр! Бер көн тормасыннар!»

Наилә җылый башлауга, көчсезлектән Нәҗипнең күкрәген тимер кыршау кысып алды, тын алырга ирек бирми, тәкате бетеп, тегеләрне эт итеп сүгәргә уйлый, тавышы чыкмый, бугазында коры төер утыра.

Сынык тырнаклы кулын бутый-бутый Тимерхан кычкыра, Җәмиләнең төсе уңган күзләреннән зәһәр коела. Таңсылуның түше бер менә, бер төшә, ә Наилә хәсрәтенә буылып җылапмы-җылый. Һәм шушы төркем уртасында басып торган ир кеше, көчсез, дәртсез, ни дияргә белмичә, адаштырган көчек сыман, ялварулы күзләрен текәп, әле Тимерханга, әле Җәмилә карчыкка карап ала. Иренең нинди хәлгә төшкәнен күреп аңына кайткан Наилә кинәт, ике йодрыгын да йомарлап, ике йодрыгы белән Яңа бистә ишегалдында яшен уйнатып, хуҗаларга тамак ертып кычкыра башлады: «Түләмибез дигән кеше бармы әллә, ай Алла! Бер-ике көн көтегез, үлмәссез әле! Түләрбез дә ташлап чыгып та китәрбез!»

Авыздан чыккан сүз — очкан кош, аны тотармын димә. Наиләнең сүзе ярсыган хуҗаларны тәмам котыртты, алар өчесе өч ноктадан, өч тавышка бәхетсез ир белән хатын өстенә зәһәр чәчәргә тотындылар.

Кинәт тавышлар тынды, Нәҗип белән Наиләне каяндыр пәйда булган бер кеше култыклап алды һәм: «Әйдәгез әле, әйдәгез! Өегезгә керегез! — диде.— Кая керергә соң?» — дип, күзләренә карады. Ят кешене хуҗалар да абайлады, тавышлар тынды, дөбердәп үткән поезд тавышлары, вагоннар котырынып бәрелешкән авазлар колакка ишетелә башлады. Хуҗалар һәм фатирчылар дөньядагы бөтен тавышларны күмеп кычкырышканнар икән!..

Өчәүләшеп кыеш идәнле, элеккедән дә шыксызрак күренгән бүлмәгә барып керделәр. Әле баярак күренгәләп торган яз кояшы яшькелт пыялалы тәрәзә турын үткән, өч аяклы аксак өстәлгә, бала караватына, тәгәрмәче өчәү генә калган уенчык арбага эңгер-меңгер кунып маташа иде...

Керүченең исеме Мәхмүт булса да, Нәҗип, Наилә белгәннән бирле аны Мудрый дип атап йөртәләр иде. Ни өчен, кем таккан, анысын, мөгаен, Мудрый үзе дә оныткандыр, мәгәр ата кушканга караганда, соңгысы, тагылганы — Мудрый дигәне аңа ошыйрак төшә иде. Урыс-улак арасында да җиңел — Мудрый и бетте-китте! Кемнең соң, уйнап кына булса да, Мудрый дип аталасы килмәс?

Чөлди гәүдә булса да, бас тавыш,— татарда сирәк очрый андый тавышлар. Явыз Иван, татар җирен басып алганнан соң, калын тавышлы, таза күкрәкле ир-атларны яшәтмәгән, дөньяга килгәннең берен кырып барган. Татар мич арасында, чоланда, мунчада, аулакта гына, анда да пышылдап сөйләшергә тиеш булган, кыскасы — Мудрый татарлардан могҗиза тавышка ия зат иде.

Керде Мудрый, Нәҗип-Наиләне беләгеннән ычкындырды, вак бәлеш хәтле авызын ерып аларга карады. Хуҗалар ишегалды бәрелешеннән аңгыраеп калган иделәр, нишләргә белмичә шактый ара телсез басып тордылар. Беренче булып Наилә исенә килде, артсыз урындыкны идән тырнатып эшереп: «Утыр, Мудрый»,— диде. «Утырам, утырам, кергәч утырмыйлармы соң? Сез һаман шушында торып ятасыз икән, мин сезне әллә кайчан шәп фатирга күчкән дип йөрим!»

Алдый Мудрый, ул Нәҗипнең күченмәгәнен дә, Мәскәүдә чирләп егылуын да, эшеннән куып җибәрүләрен дә ап-ачык белә. Нәҗипләргә төрле яктан бәла-каза ябырылмаса, ул бүген кереп тә тормый иде. Аңа кешеләрнең түбәндә, пычракта җәфаланган мизгелләре кирәк! Шөкер, юлы уңды: Нәҗип-Наиләне кая барырга белмичә бәргәләнгәндә тотты...

Кайчандыр Нәҗип белән Мудрый якын гына иптәшләр иде, бер торакта, янәшә бүлмәләрдә яшәделәр. Наилә белән Нәҗипне дә ул таныштырды. Икәүләшеп кызлар бүлмәсенә, Наилә янына кереп йөрделәр. Берсендә Мудрый каядыр киткән иде, Нәҗип кыз янына бер башы барып керде. Наилә нигәдер күңелсез, карасына батып, терсәгенә таянып, тәрәзәгә карап утырган иде. «Мудрый бүген килә алмады... Иртәгә килер!» — диде Нәҗип, кызны тынычландырырга теләп. Беравык авызына су кабып утырган кыз җәһәт кенә сикереп торды да аның муенына сарылды: «Миңа ул түгел... Миңа үзең кирәк!»

Үпкәләдеме Мудрый, көнләштеме, моны беркем дә белмәде. Егет киң күңелле, юмарт, зирәк акыллы булып күренергә ярата иде. Сирәк күрешсәләр дә, алар тыштан җылы мөнәсәбәтләрен сакладылар, йомыш-кара төшкәндә, үтечкә акча кирәк чагында еш кына Мудрый катына бардылар. Әҗәткә акча биреп торырга ярата иде Мудрый, сорамаган чакларда да килеп кереп: «Сезнең акча ягы койтымы, мәгез, миннән булсын яхшылык!» — дип әйткән чаклары да булды. Акчаны бирә, кире сорап йөдәтми, түзә, «Бер җаегыз чыкканда түләрсез әле!» — дип тынычландыра да белә.

Кеше бурычка кердеме, ул ихтыярсыздан синең колыңа әверелә. Нәкъ әнә шунысы кирәк тә Мудрыйга! Укып алдыра алмады үзе, ике ел рәттән техникумга керде, кудылар. Өч мәртәбә өйләнде, беренче хатыны ярты ел, икенчесе ике ай ярым гына түзде. Өченчесе, бер кич кунгач та, ире кибеткә сигаретка чыккан арада, күлмәк-күнчеген җыештырып чыгып качты. Сөйләделәр, Мудрый кәләшенең кайнар кочагында ятасы урында, зөфаф кичендә, керем-чыгым кенәгәсен күрсәтеп, күпме акча төшерүе, тапканын ничегрәк тотуы, кемнәрнең күпме әҗәте барлыгын ялыктыргыч озын итеп сөйләп үткәргән икән. Таңда кәләшне кочмакчы була, кәләш суынган...

Хәзер ул әнисе белән бер бүлмәле квартирда яши, әнкәсенең пенсиясен тиененә кадәр каерып ала, эчми-тартмый (тәмәкесен акча җәлләп ташлады!), таныш-белешләре акчага карта, бильярд уйнаганда алардан көлеп, мыскыллап читтән карап тора, бер тиенен исраф итми. Йоклый торган караваты терәлгән диварда шәмәхә фломастер белән байтак исем-фамилияләр язылган, анда кемгә, кайчан, нинди шартларда әҗәткә акча биреп торуы теркәлгән. Яткач ул озак-озак йокыга китә алмый дивардагы исемнәрне күзәтеп, явыз тантана белән: «Менә сез кайда утырасыз, менә!» — дип йодрыгын йомарлый. Нәҗип белән Наиләнең исемнәре диварга берничә кат теркәлгән, аны күргән саен, Мудрыйның куанычы арта. Әҗәткә кергәннәр арасында шактый күренекле кешеләр бар, бер шагыйрь, ике артист күптәннән бу кара исемлектә. Шагыйрь йолкыш кына бәндә иде, хәзер тәлинкә ялап лауреат булды. Мудрыйга биш йөз бирәчәге бар! Шәп! Акчага тыгыз килгән чакларда да Мудрый дәгъвавалмый, процент-мазар сорамый, затлы кешеләр аңа бурычлы булып яшәсеннәр! Бүген килеп керүенең сәбәбе дә шул: Нәҗипләрнең хәле соңгы чиккә җиткән икән дип ишетте. А-а, бу инде аңа иң шифалы сүз, җан дәвасы, тереклегенең тоткасы! Бөтен дөнья кораблары ярга килеп терәлсә дә, аңа сөенечтән гайре юк! Мудрый яши икән, процентларны ул үзенчә, үзенә кирәгенчә ала: аңа да кемнәрдәндер өстен булырга кирәк! Лауреатлар, артистлар аңа тез чүгеп килә! Әлегә алар, укыганнар, аннан җылы сүз көтә! Ул аларга тәүлекнең теләсә кайсы вакытында бәреп керә ала, аңа сүз әйтүче юк! Чөнки аның бу йортта, бу хуҗада алачагы бар! Үз өлеше! Җан биреп ятканда ул аларга шәфкать кулы сузды! Ул! Булгалады, Мудрыйның бер тиенсез калып, тозга ипи кыерчыгы манып ашаган чаклары булды, ә шулай да Нәҗип Нургалиев катына соранып килмәде, үтечен таптырмады. Чөнки Нургалиев өметле, үсеп бара торган кеше иде. Боерган булса, зур кеше булачак Нәҗип Нургалиев! Алла кодрәте белән цех начальнигы, баш инженер, директор булып китәр... Лауреат, депутат, бюро әгъзасы булыр... Анда да йолкыш Мудрыйдан йөз чөерә алмас, чөнки аның ничә еллардан бирле әҗәте, бурычы бар! Тора-бара кеше әҗәтенә күнегә, биреп торучы кайтарып сорамагач, түләргә ашыкмый, кешенең шул йомшаклыгыннан оста файдалана Мудрый. Бәлки, шуның өчен аңа Мудрый кушаматы такканнардыр да?!

Бүген ул белешергә кергән иде: сөйләгәннәренчә бик нык чирләгәнме Нургалиев? Үләрлекме аның хәле? Үләрлек икән, бу инде башка мәсьәлә: акчаны аяк терәп сорарга, кире кайтарып калырга кирәк!.. Үлә икән, Наиләсе кемгә булачак?.. Мудрыйның күңеленең иң ерак упкынында Наилә исеме һаман

янып, балкып йөри иде. Бәлки, шул хис тартып китергәндер аны бүген? Кеше күңеленең чиге бармыни? Ә чиксезлекне кем аңлатып бирә ала? Аны бер Эйнштейн аңлаган, ләкин дөнья халкына аңлатып бирерлек дәрәҗәгә ул да өлгереп җитмәгән. Капка какканда шулай уйлаган иде Мудрый, танышларының чиктән тыш гасабиланганын күреп, ул сүзне бүтәннәрдән, монда булмаган хәллардән башлады. «Әле Борһановны күмеп кайтып киләбез»,— диде ул рәхәт итеп, күңелле елмаеп. Наилә аһ итте. «Үлдемени?» — «Үлмәсә күмәр идекме? — Мудрый теш казналарын күрсәтеп ерылып көлеп куйды. — Утыз биш яшьтә!»

Борһанов ул чакта илдә атаклы штангистларның берсе иде.

«Тимер багана! Беләкләр! Күкрәк чуеннан коелган. Даганы дык итеп сындыра! Чумып су астында өч минут тора! Спорт гомерне озайта, диләр врачлар, пычагым да белмиләр. Минем штанга түгел, биш кадаклы гер күтәреп караганым да юк, ә мускулларны карагыз әле!» Ул, беләген бөгеп, чеби тавык күкәе хәтле генә калкынган сыек күлмәк җиңенә төртеп күрсәтте. «Тәмле ашаганнан озая гомер!»

Нәҗипнең Мудрый белән хәтсездән очрашканы юк иде. Тимерханнар белән ямьсезләшүнең шаукымы басылгач, ул аның ни өчен килеп керүен аңлады: «Әҗәтен сорарга килгән, мәет козгыны!»

Нәҗипнең хәле хәл икәнне каян иснәнгән диген... Димәк, күзәтеп яшәгән, җан бирергә егылганнарын сагалап торган! Димәк, Нәҗип гаиләсе хакында гайбәтләр авыздан авызга күчеп йөри!

Ләкин Мудрый сүзне ерактан чәлмәштереп алып китте, имеш, «Борһанов үлгән!» Штангист аларның уртак танышлары, сөйкемле һәм ипле егет иде.

Мудрый сүзе җитез аяклы, аның катында Нәҗипкә һич тә җебеп төшәргә ярамый иде, каты холыклы, нык булып күренергә кирәк бу биләмче финансистка! Ни тырышты Нәҗип, алай да, «үлгән, күмдек, зират» дигән җан өшеткеч сүзләрне ишеткәч, коелып иңде. Йөрәгә купты, ашкынып, якты дөнья белән саубуллашырга җыенган төсле кылдый-былдый дөпелдәде. Кеше үз йөрәгенең тибешен ишеттеме, аның эше харап: күз алдын кара томан сара, авыз эче кибә, хәл китә, күз, кая барып тукталырга белмичә, мәгънәсезгә уңга-сулга тәгәри башлый. Наиләне әйт, җүләр түгел диген, кай тирәгә җирләдегез, кеше күп идеме, кемнәр бар иде? дип, юк-бар сорау биреп утыра. Иренең хәлен күрмиме әллә? Таңсылу бүлмәсе ягыннан кыйммәтле хушбуй исе таратып бохар песие килеп чыкты да Мудрыйның тезенә сикереп менде. «Да, брат, кырыла халык,— дип дәвам итте Мудрый, песинең йонын кирегә сыйпап.— Зиратта карыйм: күбесе миннән яшьләр ләхеткә кереп яткан. Тәмле ашамыйлар, саранннар, акча җыялар. Комсызлык харап итә чордашларны, шул кимерә бавырларын, бөерләренә шул төшә! Менә мине ал... Иртәнге чәйгә казылык турап кыздырган биш күкәй! Аны май, кара икра белән каплап куйдым. Якын килеп карасын чир!» Мудрый буш тартмалар тутырган арба кебек шалтырап көлеп җибәрде, бохар песие куркуыннан идәнгә сикерде һәм, хуш исен чәчеп-таратып, теге якка йомылды.

Нәҗип, телен оныткан байгыш сыман, ары-бире атларга, юанырга тырышып карады, аптырагач, Наиләсе каршысына килеп басты: «Чәй куеп җибәрәсеңме әллә, карчык? Бездә икра юк югын, мәгәр бәрәңгенең иң кәттәсен — чикмәнлесен пешерербез!» — «Кирәкми, — дип баш чайкады Мудрый. — Борһановны җирләдек тә зиратны әйләнеп чыктым. Ай-һай, чебен урынына кырыла халык. Урыс-улак поминкага китте, мин, Аллага шөкер, хак мөселманмын, гаеткә йөрмәсәм дә, иманымны сатмыйм. Гаеткә барыр идең... күреп калулары бар. Алла дип бәхетле язмышымнан колак кагасым юк. Йә, ашыгам, әни бәлеш тыгып калган иде!»

Бу йортта бәлеш белән ярышырлык ризык юк иде, хуҗалар үзләре чиле-пешле бәлеш булып, аста изелеп калды, Мудрый чамасыз тантана итте.

«Син әҗәтне юллап кергәнсеңдер, Мудрый. Безнең читенрәк чак бит әле»,— диде Наилә, борлыгып. «Юк! — дип кырт кисте кунак.— Киресенчә, хәлегез шәптин түгеллекне чамалап кердем. Янымда акчам да бар! Мин акчасыз йөримме? Күпме тиеш әле сез бу ачкак адәмнәргә? Ул башын хуҗалар ягына какты.— Өч айга дидегезме?» — «Йөз илле тәңкә!» — дип ярым ыңгырашты Наилә. Мудрый куен кесәсеннән шактый калын, таушалган күн бумажник тартып чыгарды һәм утырган җиреннән үрелеп кыеш аяклы өстәлгә шыгырдап торган өч иллелекне чөйде. Уйлап-уйлап торгач тагын бер иллене өстәде. «Булгач-булгач, ике йөз төгәл булсын! Сездән артмас!» — «Мудрый! — диде аны кочаклый язып Нәҗип. — Без сиңа мең тәңкә бурычлы булдыкмы инде?» — «Булса соң! — диде, рәхәт тантанада йөзеп кунак. — Җае чыгар, көне килер, баерсыз». — «Яхшылык җирдә ятмас», — диде Наилә, күз яшьләрен сөртеп, һәм сорау белән иренә карады. Нәҗип: «Кертеп бир! Тыгынсыннар!» — диде.

Өч иллелекне эләктергән Наиләгә бүтән ым кирәкми дә иде, ул кабыл-тибел Тимерханнар ягына чыкты һәм акчаны өстәл уртасына ташлады. Тегеләр теш арасына өрек кыстырып чәй эчәләр иде, иллелекләр май каплавычы тирәсенә барып кундылар. «Расчет! — диде явызланып Наилә. — Менә! Күрдегезме? Расчет!»

Ул үз куышына чыкканда, Мудрый китәргә әзерләнгән, ишек катына, ярым караңгыга килеп баскан һәм Наиләнең чыкканын көтә иде. «Изгелегең онытылмас, җылы кулыңны нәкъ кирәк чагында суздың, Мудрый!» — диде Наилә чын күңеленнән. Кунакка әнә шул кирәк тә! Ул хуҗаларның мескенлеген, аңа

тәмам буйсынып бил бөгүләрен, ике яктан тәлинкә тотуларын күреп очынды. Кем бил бөгә диген? Зур заводта күз өстендә каш саналган Нургалиев! Кайчандыр үзеннән йөз чөергән тәкәббер Наилә! Асыл зат! Бүгенгә аңа җылы кан кирәкми, моның ләззәте, җиңү тәме әле ай буена җитәчәк. Ай азагында ул чираттагы корбанына барып, үзенең мул яшәве, тәмле ашавы белән мактаначак, күзенә кереп, тегенең бурычлы җанын уч төбендә дер селкетәчәк. Күп андый бәхетсезләр дөнья йөзендә! Шундыйлар арасында Мудрыйлар гомергә рәхәт яши!

Наилә белән Нәҗип аны озата чыктылар, балаларны иртәрәк алып кайтырга ниятләделәр. Барышлый кибетләргә кагыласы, малайларга әз-мәз төче-мөче аласы булыр... «Савык, браток! — диде Мудрый, чуен башын туп-туры тотып. — Чирләгән өчен акча түләмиләр. Чирләсәң — үл, үлмисең икән — чирләмә! — Тагын шаркылдады Мудрый һәм Наиләнең күзләренә яшерен өмет һәм әрсезлек белән карады: — Шәп әйттемме? — дип сорады.— Зират кырында яшисез, яшьләр үлеп тора, килгән чаклар булгалар, кагылырмын!»

Төнлә Нәҗипне тагын йөрәге тотты, ике тапкыр «ашыгыч ярдәм» килеп китте. Икенчесендә кардиогруппа да бар иде. Алар кардиограмма яздылар. «Җәһәннәмдә яшисез икән, тавышлар комачаулый!» — дип зарландылар, нидер шыпырт кына сөйләштеләр. Нәҗипкә әйткәннәре һаман шул ук балык башы булды: «Куркыныч нәрсә шәйләнми, ял кирәк, саф һава, яхшы ризык... Кавказга барыгыз, диңгездә су керегез! Кырым да килешер!»

Йөз сызыклары үзгәргән, күзләреннән нур качкан иренә карап Наилә төн ката керфек какмады, иртән башы авыртып, чигәләре чыңлап торды.

**8**

«Тик яткан сау кеше дә чиргә сабышыр! — дип кабатларга ярата башлады Наилә. — Тор! Йөр! Сораш! Йөргән аякка йөрем иярә! Көнозын түшәм санап акылыңнан шашарсың!»

Көн туган саен хатын җилкәне кимерә башласа, ир-атның эше харап, хатын-кыз теленнән котылмак юк. Мудрый кереп чыкканнан соң атна үтмәде, Нәҗип Йосыф улы Нургалиев эш эзләп чыгып китте. Берочтан яшәп торырга җылы почмак кирәклеген дә хәтереннән чыгармады. Бер урында: «Иртәгә кил!» — дип чыгардылар. Иртәгесен: «Юк, алмыйбыз!» — дип кире бордылар. Бу хәл байтак кабатланды, бүген елмаеп, өметләндереп каршылыйлар да иртәгесен, дөнья җимерелгәндәй кара коелып, тиз-тиз борып чыгарып җибәрәләр. Көненә өчәр-дүртәр ишек каккан чаклары булды егетнең, өметле сүз ишетмәде, якты чырай күрмәде. Исенә Изил Латыйпов әйткән куркынычлы сүзләр килеп төште. Тәмам аптырагач, ул доктор Фогельсон янына юнәлде, ике-өч сүз белән хәлен аңлатты, шиген уртаклашты һәм киңәш сорады. Фогельсон аңа күзен акайтып карады: «Әгәр минем исем белән авыз чайкап йөри торган булсаң!..» — диде ул, ишеккә күрсәтеп...

Врач яныннан ул хәленең үтә мөшкеллегенә тагын бер кат инанып чыкты... Аның психик яктан какшау икәнлеге төптә язылган да тиешле оешмаларга хәбәр итеп куелган булырга тиеш!..

Татарда кайгы — кара, сагыш — сары. Кайгыда зәңгәр күз дә карасу шәүлә белән өретелә, алсу яңаклар да казылык төргән эчәге сыман кипшереп, юкарып һәм сарыга сабышып калалар. «Ни булды сиңа, җаным?» — дип кочаклый аның юкарган иңнәрен Гөлнара. Ни әйтсен Наилә, ни әйтә алсын?.. Нәҗибе эшсез. Совет эшсезенең кабахәт буржуа илләре эшсезеннән аермасы шактый күп: ул дәүләттән пособие алмый, аны профсоюз якламый, шәфкать-мәрхәмәт ширкәтләре аны бушлай ашатып, бушлай кундырып чыгармыйлар. Капиталистик илнең эшсезе бушлай бүксәсе кап булганчы ясмык штие бөгә, икенчегә аңа нибарысы кәбестәле сосиски ашаталар! Шулай Нәҗип Йосыф улы Нургалиев, дипломлы, белемле, үзенчә егәрле кеше — эшсез. Егәрле дигәндә чүт кенә тукталып торырга кирәктер, эш табалмыйча каңгырап йөргәннән соң, тагын егәре таралып калды егетнең...

Үзенеке үзенә җиткән иде Нәҗипнең. Наиләсе аның эшсез калуын һаман-һаман искәртеп торса да, килде бер көн, ул завод, мөдирлек, дәрәҗәләр хакында бөтенләй уйламый башлады. Иртәдән кичкә кадәр аны бары тик үлем хакындагы кара уйлар гына биләделәр. Әҗәл якадан алган икән, кая инде эш турында хафалану?! Үлем турындагы уйлардан арынырга тырышып, китапларга тотынды Нәҗип, өч-дүрт бит үтүгә, китабын тотып атты. Бит саен үлем, кан коеш, үтереш, кырылыш... Наиләсе кыстагач, Калинин клубына киноларга баргалады, сеансның яртысыннан ташлап качты. Атышалар, чәнчешәләр, бугаздан буалар, мәетләрне таудай өя торган сугышлар бара. Адәм баласы туу һәм үтереш турында укырга, кырылыш турында карарга ярата шул. Табигате шундый аның, ерткыч табигате. Ике таныш гомер эчендә бер күрешәләр һәм китә сүз: фәлән кеше үлгән... рак бәреп еккан... асылынган... тегене кочләгәннәр... чукмар белән сугып башын ярганнар. Ә Васильевода... Васильевода! Бакча каравылчысы, сөяркәсе белән икәүләп, күпме адәм ите ашаганнар... Өчәү, дүртәү очрашсалар да, әллә кайчан гүр иясе булганнарның аяк сөякләрен юалар. Тормышта кап-кара эш кылганнарның да сөякләре агарамы икән? Шулайдыр, Ходай Тәгалә каршында һәммәбез дә тигез.

Тимерхан белән Җәмилә бер мәлгә тындылар, «ни булыр?» дигән сыман, шым гына җимерек диварга колакларын куеп тыңланалар. Картлар сагая икән, анда нидер булырга тиеш. Таңсылу югалып торды, бушлай путевка алып, бизәнеп-ясанып Мәскәүгә китте дә, атна-ун көн торып, белемен киңәйтеп, офыгын тирәнәйтеп кайтты. Аның беркая читкә чыкмыйча, шунда Яңа бистәнең ишегалды түренә поскан йортта бәбәй төшереп ятканын күрше-күлән белмәмешкә салышты.

Больницага барырга да ашыкмады Нәҗип, йөрәге җитмәде, «барам!» дип кичтән тәвәккәлли, иртән йөрәге кыскандай була. Караватына ава Нәҗип, көне буе шунда ауный. Наилә эшкә йөри башлады, киткәндә һәр иртәдә: «Бүгеннән калма! Невропотологка күрен!» — дип кисәтеп китте. Кардиогруппада килгән врачлар: «Невропатологка күренсен!» — дип киткәннәр иде.

Якшәмбе — Наиләнең ялы, көнозынына иренең колагына чикерткә булып керде: «Әгәр иртәгә больницага бармасаң, сишәмбедә кул-аякларыңны бәйләп врачка үзем илтеп тапшырам!»

Нәҗип сүрән генә елмайгандай итте, ияген какты, эченнән генә: «Сишәмбегә хәтле яшәргә кирәк әле!» — дип пышылдады. Егет көненә кырык тапкыр үлеп, кырык тапкыр терелә иде. Язгы җип-җиңел бишмәтен кигәндә дә йөрәге кыскандай итә, врач янына икенче катка менгәндә дә шабыр тиргә бата. Иелә алмый, егылып үләрмен дип коты чыга. Авырта йөрәк, сызлый! Ә врачлар сүз куешканнармыни, һаман бер чыгырны әйләндерәләр: «Куркырлык нәрсә юк. Тәмле аш. Саф һава. Тулы тынычлык, гаиләдә татулык кирәк».

Иренең көннән-көн ихтыярын җуеп, солы кесәленә әйләнгәнен күзәтеп, күреп торган Наилә тәмам гаҗиз иде. Нишләргә? Ни хәл итеп ирен аякка бастырырга? Гаилә тормышын ничек алгарак юнәлтергә? Квартир хакы түләр чак җитә, язга чыгып баралар, балаларга өс-баш, аяк киеме юнәтергә кирәк. Сигезенче мартта хезмәттәш хатын-кызлар һәммәсе яңа костюмнар, затлы күлмәкләр киячәк. Ә ул? Өченче ел рәттән зәңгәр күлмәген киеп барсынмы? Адәм көлкесе!

Хатын-кызның яшәү дәверендә иргә мөнәсәбәте кырыкка төрләнә. Нәҗип чирләгәннән соң әле күпме генә ара үтте, Наилә ирен бер кызганды, ул җебеп-мәлҗерәп яткан мизгелләрдә үтмәс пычак белән суярдай булды. «Шулхәтле чүпрәк булса булыр икән! — дип кыйналды ул. — Чиле-пешле арыш кабартмасына тап буласымны белсәм... валлаһи, Мәхмүт-Мудрыйга чыгар идем! Тик ятсын иде буаз бумажнигын кочаклап янымда!» Менә нинди ямьсез тиңләүләргә барып җитә хатын-кыз ачуы кызганда! Сизә Наилә, бу уйларның үз файдасына түгеллеген шәйли, ләкин, чирле ир хатыны буларак, бүтәнчә уй йөртә алмый.

Сердәше Гөлнара, иманын ачып салып, күңелен бушатты бушатуын, бер үк вакытта Наиләнең күңелен мәңгегә бозып өлгерде. Әгәр Гөлнара аны котыртмаса, Наилә ул тикле үк иләсләнмәс тә иде. Күп белү хатын-кызга һәрчак комачаулый, ир белән хатын арасындагы упкынны тирәнәйтә. Наилә уйларында гел бәргәләнә, инде генә онытылам, ирне ир итеп яшим, үзгәрәм дип күңеленә беркетсә дә, иренең тир диңгезенә чумып, ыңгырашып: «Үләм, уф!» — дип ятканын күргәч, кеп-кечкенә, әмма саллы йодрыгын йомарлый, иренең эчкә суырылган, куе төк баскан саргылт яңагына чалт итеп ямыйсы килә. Аннан ике күзе читкә борыла: «Йа Раббым, көферлек ич бу, көферлек... Аңа кыен чакта мин, аның никахлы хатыны, нинди әшәке уйлар уйлыйм!»

Каршылыклы, болганчык хисләр онытылды дигәндә, хәлсез Нәҗипнең капка баганасына ябышып торуын күргәч, тагын каны котырына Наиләнең. «Невропатолог катына бәйләп илтеп салам!» Тавышындагы усаллыкны оста яшерә, йөзенә ясалма елмаю таплары йөгерә, сабырланырга тырышып учын учка ышкый, озынча, нәфис бармакларын шартлата. Аның усалланып котырынуын Нәҗибе сизә, тик үртәшми, карышмый: «Әле ярый бармак шартлатып кына атасың, кулыңа наган керсә, нишләтер идең икән?» — дип, күзләрен яшерә. Наиләсе көлгән була, кысылган иреннәрен көчләп яза, ул сүзгә керми, бәхәс кузгалса, давыл чыгасын сизә, очлы әйберләрдән — пычак-безләрдән, тәрәзә төбендә моңарчы тын яткан үткер кайчыдан читтәрәк йөрергә тырыша. Бәладән баш-аяк!

Көннәр үтә торды, кемнәрдер дөньяга килде, кемнәрдер Гафури урамының эрер-эремәс яткан кара бозларын таптаган машина әрҗәләрендә чалкан ятып, Яңа бистә зиратына үтә тордылар. Әҗәл белән тереклек арасында адашып калган Нәҗип бүген, балаларын таратып, Наиләсен озаткач шифаханәгә барырга булды. «Бүгеннән калмыйм!» — диде сакалын кырганда. «Бүген!» — диде мышный-мышный ботинкаларын арулаганда.

Ялгыз калгач кеше үзгәрә, уйлары бүтәнчәрәк була. Сакал кырылып, ботинкалар елтырый башлагач, Нәҗип бүтәнчә уйлады. «Әҗәлең җиткән икән, ник врачларны бимазалап зар җылап йөрергә? Анда ни әйтә алырлар? Ни бәләләр алар? Әштер-өштер тыңларлар, аптекада булмаган, буласы да юк дару язып тоттырырлар. Ни файда? Дару ашап кемнең терелгәне бар? Больница — зират белән ике арадагы станцаларның берсе. Ничә барды инде ул шул күчеш нокталарына?! Үләргә икән үләргә! Кайда эшлисең, кем булып? — дип төпченә башларлар... Ну их!»

Гаҗәп, моңарчы, шушы мизгелгә хәтле, ул дөньяны кую хакында уйланса, уе һәрчак Наиләсенә, улларына килеп ялгана иде. Күңеле: «Миннән башка ничек яшәрләр?» — дип үрсәләнә иде. Бүген гүя алар бөтенләй юк та кебек, Нәҗип аларны онытты, үзе, үз язмышы, үз хәле турында гына уй йөртте. «Шулай... үлми калсам, утыз өчтә өр-яңадан яши башларга туры килә. Утыз өчтә! Бу яшьтә ир-атлар

хатынлы, бала-чагалы, фатирлы һәм дачалы була. Дәрәҗәсе, калын гына кесәсе була ирнең. Исеменә лаек мохите, дус-ишләре була. Ә минем нәрсә бар? Кашым да күзем, чирем дә үзем! Өметем дә калмады, ичмасам!»

Һәр яктан килеп үлчәгәндә хәзерге хәле болайрак: яшен суккан агач өстенә ава — качып котыла алмассың! Кыя-таудан таш ишелә — хәзер басып китәчәк! «Бәс, шулай икән, нигә пыскып ятарга? Ни пычагыма?! Хатын тапкан акчага күз текәп... Эшсез. Эш булу ихтималы да юк. Йөрәк зәгыйфь. Дөньяда хаксызлык барын тойсаң да, көрәшкә чыга алмыйсың... Үз гомерендә кыюланып бер тапкыр хак сүз әйтеп бакты, «псих» дип атадылар... Нигә яшәргә? Ни өчен?..

Үләргә, поезд астына ташланырга. Больницага барган булып тимер юлга таба атларга да... вәссәлам! Ялгыш эләгеп харап булган, дип бер җыларлар да тынарлар...»

Ул сискәнеп китте, төсләр, исләр, тирә-яктагы хәрәкәт күзгә күренмәс булды, ул шәһәр ягыннан килгән поездны шәйләде. Тепловоз, аңа ике вагон такканнар. Артта да гадәти ике вагон... Уртада елык-ялык итеп торган ят вагон. Булмагае! Нинди вагон таптаса да барыбер түгелмени? Тезләре калтыранды, бугазыннан ниндидер авазлар чыкты, шул арада көчле куллар аны эләктереп алдылар. Ул уңнан да, сулдан да болай таба йөгерешкән тимерьюлчыларны абайлады...

Милиция бүлегендә аңа гел бер сорауны биреп йөдәттеләр: «Ни өчен син хөкүмәт әгъзалары утырган литер поездга якынлаштың? Син аны нинди яшерен максат белән көтә идең? Махсус составның станция аша үтәсен син каян белдең? Кем аны сиңа хәбәр итте?!»

Нинди поезд? Нинди хөкүмәт әгъзалары? Хөкүмәт вәкилләрен түгел, поездны да күрмәде Нәҗип... «Тәгәрмәч астына ташланырга бара идем!» — дип әйтмәде әйтүен, «Больницага бара идем, чирлим, йөрәгем авырта, зиһенем таралган чак булгандыр», — дип мыгырдады. Аңа ышанмадылар, ябык машинага утыртып каядыр, югарырак оешмага алып бардылар. Төн кундырдылар. Иртән сыек кына бер стакан чәй эчерткәч тагын сорау алырга чакырдылар. Ул һаман бер сүзне кабатлады: «Больницага барырга чыккан идем. Ә больница кайда? Тимер юлның теге ягында. Тимер юл аша чыгарга кирәкме миңа? Кирәк. Поездны күрмәдем, уйларым бүтәндә иде».

Сорау алучы лейтенант иде. Менә бүлмә ишеге кинәт кенә ачылды, аннан капитан килеп керде. Ул башы белән Нәҗипкә ишарәләде дә: «Чыгарып җибәр аны... Псих икән! Учетта!» — диде.

Баш-аягы исән калуына сөенергә дә белмичә, Нәҗип өенә кайтты, җылап, шешенеп беткән Наилә аның күкрәгенә капланып бик озак үкседе.

Бер нәрсәне белми калды Нәҗип: ул тәгәрмәче астына ташланырга җыенган литер поездда, илнең тимер юллар министры дәһшәтле Илья Ефимович Шидловскийдан тыш, аның белән янәшә яшәүче, язмыш сукмаклары тиздән кисешәчәк ике гали зат — хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич та баралар иде.

**9**

Шидловскийның киләсен байтактан беләләр һәм Татарстан мәркәзе шанлы-шәүкәтле Казанда министрны тантаналы курку белән көтәләр иде... Кунак булырга ярата һәм бу җәһәттә үтә кырыс, бөртекчән һәм текә кеше иде Илья Ефимович. Озын буй, бөкре танау, икегә ярылган чыгынкы, нык ияк. Бөркет карашлы күз алмалары берчакта да як-якка тәгәрәмиләр, министр һәрвакыт алдына гына карый. Тавыш көр, тән сәламәт, ашказаны таза, министрның бер утырганда биш кешелек ашап, җиде кешелек эчә алуы да илдә мәгълүм иде.

Кунак кабул итү олы һәм акыл җитмәслек четерекле фән ул! Һәр төбәктә кунакны үз милли гореф-гадәтләренә яраштырып кабул итәләр, шул төбәк осталарының кулыннан килгәнчә сыйлыйлар да. Басыйр Бариевич, «Министр килә!» дигән хәбәр алынгач та, бер минут уйлап тормыйча, җан дусты Иван Иванович янына чапты. Алар, шәһәр советы утырышын нәкъ ике сәгать ярымга кичектереп, кабинетка кереп бикләнделәр. Әзерлекне бүген үк, нәкъ шул минутта башлап җибәрергә кирәк, соңга калу үлем белән тиң булачак. Россиянең иң абруйлы тармак министры Шидловский килә! Дәрәҗә ягыннан ул оборона министрыннан гына калыша торгандыр!

Данлы-шанлы, кояшлы-айлы Татарстанда тимер юллар әз, Казаннан Бөгелмәгә барыр өчен чит өлкәләрдән рөхсәт сорарга туры килә. Бәс, хуҗалыгың бәләкәй икән, андый-мондый чатакларны да бик тиз күреп алырга була! Аллам сакласын! Дөрес, вак-төяк чатаклар өчен көенмәскә дә була. Алай да вак-төяк өчен нигә җанга борчу алырга? Күренмәсен хаталар! Күренмәсен дисәң, башкала кунакларының күзен капларга кирәк! Ә аның кырык төрле әмәлен беләләр Татарстанда!

Тимерьюлчылар, шәһәр советы һәм башка мөһим оешмалар белән берлектә, ныклы план нигезендә кунак кабул итү кампаниясен ачып җибәрделәр. Белсен әле мәскәүлеләр татарның кем икәнен! Күрсеннәр! Кавказлылар кунакчыл, диләр, аларны куып узарга! Урта Азиядә инде ул сый-хөрмәт, диләр. Азияне дә үтеп китәргә!

Беренче нәүбәттә, әлбәттә, кунакның тамак ягын кайгырту лазем. Мәскәүлеләр ашарга ярата, ризыкның рәтен белә! Белештеләр, Шидловский асылда балык ризыкларын ярата икән. Балык дигәч тә, Каспий хамсасы белән Балтыйк килькиен ашап утырмый инде. Андыйлары ярамаган тагын пешеп төшкән социализмда яшәүче Рәчәй кара корсакларына! Татарстан балыкчыларына, елга, күл буйларында укмашкан әртил, бригадаларга ныклы боерык китте: әгәр җәтмәләргә кырпы, эре чөгә, мәрсиннәр эләгә икән, һәммәсе тимерьюлчылар карамагына тапшырылырга тиеш. Олы кунак килеп җиткәнче, кырпыларны, чөгә-мәрсиннәрне тере килеш сулыкларда сакларга!.. Майлары агып торган ыслаган сазаннар, төрек ятаганнары шикелле кәкре чехоньнар (ыслаганы гәрәбә кебек үтә күренмәле була аның! Ә исе, исе!.. Норка бүрек һәм ыслаган сазан белән чехонь ташып, казанлылар икенче аэропортларын салдылар!) бүгеннән Казанга килеп җитсеннәр! Идел-Чулман балыклары белән генә эш йомгакланамы? Илдә балык беткәнмени? Чавыча һәм башка Камчатка балыклары әзерләргә Ерак Көнчыгышка вәкил очты. Министр килеп төшәр алдыннан ул да кайтып җитәргә тиеш. Камчаткада чавыча балыгының күзен генә аерып, имән мичкәләрдә тозлыйлар икән. Тач май була, ди. Әйдә, министрның күзе тонсын, ашап телен йотсын!.. Сукыр һәм телсез министрдан да кулай кеше буламыни бу дөньялыкта?! Миногалар, омарлар, краблар, елан балыклар алырга вәкилләр Балтыйк буена, Калининградка ашыкты. Нельма, муксунише гаҗәеп балыкларны әзерләргә ике кешедән торган бригаданы Обь-Енисей бассейннарына җибәрделәр. Кызыл-кара уылдыкның иң әгълаларын, тере вә эре бөртеклеләрен алып кайтырга Салехардка — төньякның агач башкаласына ике вәкил юлладылар.

Әле болары эшнең башы гына иде! Иван Иванович белән Басыйр Бариевичның хыяллары көннән-көн яхшы чүпрә салынган камыр кебек ташыды... Казанга терәлеп торган орденлы совхозларның берсендә куе сыер сөте эчертеп кенә биш данә чучка малаен симертә башладылар. Аларны өч тапкыр һәр көн чишмә суы белән генә юып, щетиналарын тарап, Пакыстаннан килгән йөнтәс, йомшак сөлгеләргә урап кына киптерделәр. Республиканың иң атаклы ветеринария врачлары сәламәтлеген кат-кат тикшергәннән соң, аерып куелган кышлау печкән үгез белән сөттән бүтән ризыкны татып карамаган яшь бозауга да берәр врач, икешәр караучы беркетелде. Врачларны, мал караучыларны Казан врачлары белән Мәскәүдән килгән профессор кат-кат тикшерде, көнаралаш алардан анализлар алып, тәрәтен, бәвелен сынап тордылар. Малларны кем чала, кем туный, итне кем чаба — болар һәммәсе бер ай элек тәгаенләнде, алар төп эшләреннән азат ителеп «махсус бригада составына» кертелделәр һәм айлык хезмәт хакын икеләтә ала башладылар. Әгәр югары дәрәҗәдәге кунакны кабул итү утсыз-төтенсез генә үтә калса, каршы алуга катнашучыларның һәммәсенә дә кыйммәтле бүләкләр, келәмнәр, бәллүр савыт-сабалар, акча вәгъдә ителде. Мәскәүдән ярдәмгә чакырылган профессорга мехчылар исеменнән кайры тун бүләк иттеләр.

Яшелчә-җимеш, ананаслар, бананнар, кокос чикләвекләре хәстәрен күрергә биш кешелек бригада Рәчәйнең махсус режим белән ашаган Рига, Ленинград, Киев калаларына таралды. Эчемлек ягын дүрт кешелек җитез егетләр бригадасы кайгыртты. Француз, итальян, Кытай коньяклары кайтты. Атаклы «Смирнофф» аракысын юнәттеләр, Чистай аракы заводында махсус өлгерткән иссез-төссез аракыларны Васильево пыяла заводында берәмтекләп эшләнгән шешәләргә тутырдылар.

Хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич милли якны онытмадылар, Шидловскийга дип Арчада башмак чиктеләр. Кара, чын татар түбәтәе табылмагач (дефицит дисәң дә дефицит!!!), өч тәңкә ярымлык үзбәк түбәтәен алып куйдылар. (Әле ул чакта Шидловскийның баш размерын белмиләр иде, түбәтәйне бишне алдылар!)

Министр ялгыз йөримени! Аның белән биш урынбасары, ике секретаре, пешекчесе, киендерүчесе, тән сакчылары киләчәк. Кыскасы, салон-вагонга алдан-арттан тагылган дүрт вагон кеше белән шыплап тутырылачак. Аларның һәммәсенә, дәрәҗәсенә карап, сый-хөрмәт, бүләк-санак кирәк булачак. Урынбасарларның берсе — гөрҗи, икенчесе казакъ халкыннан икән. Грузиягә һәм Казакъстанга шунда ук махсус бригадалар китеп, алар яртышар вагон ул төбәкләрнең ризыгын, эчемлеген кайтарып җиткерделәр. Махсус приказ белән аларга рәхмәт белдерделәр...

Ниһаять, министрның һәм беренче урынбасарларның өс-баш, аяк размерлары тәгаенләнде. Боларны ачыклау өчен Мәскәүгә махсус вәкил барып кайтты, һәммәсе яшертен эшләнергә, илнең тимер юл хуҗалары өчен көтелмәгән гаҗәеп сюрприз булырга тиеш иде!

Милли якны уйлагач, хөрмәтле һәм зирәк Иван Иванович Әнисә абыстайның атаклы каз бәлешен исенә төшерде. «Кирәк булырмы?» — дип сорады шигәеп кенә Басыйр Бариевич. «Илья Ефимович «татар ашы?» дип сорап куйса? Бәлеш тә әзер торсын, каклаган каз да!» — дип суеп каплады Иван Иванович.

Әзерлек эшләренең башында сыналган, хуҗалар сагында җанын фида кылырга әзер, тугры Исламнур торганын зирәк укучылар әллә кайчан чамалап алгандыр дип уйлыйм. Әйе, Исламнур йокламады, ашамады-эчмәде, хатыны кырына ятмады, Татарстан даны өчен көрәш кырларыннан кайтмады.

Ниһаять, һәммәсе әзер булды шикелле. Шәһәр советының җыелышлар залында, тимерьюлчылардан кәттә иптәшләр белән берлектә, яшерен киңәшмә үтте. Һәр тарафка җибәрелгән вәкилләр, һәр тармакка

беркетелгән сыналган иптәшләр, кәгазьләргә бакмыйча гына, телдән кыска-кыска отчетлар белән чыккач, абруйлы утырыш «Кунакны кабул итәргә мөмкин!» дигән нәтиҗә ясады. Гөрләтеп кул чаптылар, кайберәүләрнең күзләре яшьләнде, алар аягүрә басып «ур-ра!» кычкырдылар.

Иртәгә Шидловский килеп төшә дигән көнне печтек кенә чатаклык булып алды: Иван Иванович белән Басыйр Бариевич министрга хәстәрләнгән бүләкләрне — тун, бүрек, эт тиресеннән тегелгән унтыларны карадылар һәм бүреккә чират җиткәч аптырашта калдылар. Буйга пәһлеван булса да, баш бәләкәй икән министрның! Нибарысы илле җиденче размер! «Баш зур һәм буй биегрәк күренсен өчен Илья Ефимович озынча, йөнтәс бүрек кияргә ярата!» — дип, шул көнне генә Мәскәүдән кайтып төшкән вәкил ачыкламаса, тәмам көлкегә калачаклар икән! Бүрекнең дә кулаен эзләп таптылар!

Казан бер төн йокламады, Казан утсыз да кайнады. Казан «сугышчан әзерлеге беренче номерга куелган» хәтәр шәһәр иде. Килде министр, ике аягын ерып, уктай карашын каршылаучыларга төп-төз төбәп күрешеп чыкты. Мондый сөенечне, чиксез олы тантананы шәһре Казан диварларының күргәне дә, ишеткәне дә юк иде. Бик кызганыч, үтә җәл, гади кешеләр аны күрү бәхетеннән мәхрүм калдылар: вокзалны урап алган йөз дә унөч милиционер, кырык ике дружинник халыкны ул тирәгә якын да җибәрмәде. Литерлы поездны ялга, аулак юлга күчерделәр, министр шан-шәүкәтле борынгы калага аяк басты. Төкле аягың белән, Илья Ефимович!

О, ул көннәр, ул көннәр! Гомергә онытылмаслык, хатирәләрдә ныгып, телләрдән телләргә, буыннардан буыннарга күчеп, легендаларга әйләнәчәк тантаналы вакыйгалар! Сый-хөрмәт, татлы сүзләр, милли туганлык, эшчеләр сыйныфы белән Мәскәү кунакларының бер сулыштан сулаулары, алкышларга күчкән кул чабулар. Шунда ук хәбәр таралды: Илья Ефимович үзе дә, аны озатып йөрүче затлы кешеләр дә казанлылардан бик тә, бик тә канәгать калганнар! Моны ишеткәч, хөрмәтле Иван Иванович «гопак»ка, хөрмәтле Басыйр Бариевич «Әпипә»гә биеп җибәргәннәр, имеш...

Ләкин, ләкин... Ах, шул ләкин! Шул «ләкин» дигән каһәр суккан сүз булмаса, без әллә кайчан коммунизмга барып җитеп, түшәмгә төкереп ята идек инде. «Ләкин» бар, шул аякны бәйли...

Бөтен ваклыклар уйланылган, җиде кат үлчәп кенә киселгән иде, юмарт күңелле хуҗалар Илья Ефимовичның бер сәер гадәтен алданрак белә алмаганнар икән...

Министр нигъмәтләргә бай мәҗлесләрдән соң татлы йокыга китә алмыйча байтак вакыт интегеп ята икән. Чалкан ята да бер өзмичә тәмәке тарта. Тәмәке төпчеген сүндереп тормый, утлы килеш черт итеп төкереп, теләсә кай якка очырта. Ә хуҗалар, туң башлар, төпчек җыярга махсус вәкил куярга искәрмәгәннәр... Куясы инде шунда Исламнурны! Мондый хәл буласын алдан шәйләсә, Басыйр Бариевич үзе саклап торыр иде министр авызыннан очкан төпчекләрне, уяулыгын югалтмас иде!

Министр очырта тора, утлы төпчекләр литерлы поезд вагонының яртылаш химиядән генә торган почмакларына барып-барып төшәләр. Салон-вагон барган шәпкә җилдә очкыннар чәчә-чәчә яна ук башлый. Китә шау-шу, китә ыгы-зыгы, төтенгәме, хәмергәме баш биреп исергән, чак тончыкмаган Илья Ефимовичны унөч кеше уттан чак алып чыгып өлгерәләр.

«Кылган яхшылыкларыбыз утта очты!» — дип кайгыра Иван Иванович.

«Беттек!» — дип зарый-зарый җылый күрше өлкә чигенә кадәр озата баручы Басыйр Бариевич.

Соңыннан мәгълүм булды: хәлләр алай ук мөшкел булмаган икән! Тугры ярдәмчеләр, җан сакчылары белән бергәләп, сәгате-минуты белән көчәйгән явыз уттан башта министрны түгел, салон-вагонга шыплап тутырылган кыйммәтле бүләкләрне — сандыкларны, чемоданнарны, бүктәрләрне, төеннәрне алып чыкканнар икән! Утта янмый, суда батмый Рәчәй министрлары!

## 10

Җүләргә чыгарып, «психушка»га тыга язганнан бирле Нәҗипнең кемдер җиңел кулдан «ак чәчәкләр» дип атаган һөнәр ияләренә хөрмәте шактый какшады: агулы, зәһәр үләннәрнең дә еш кына ап-ак чәчәк атканын белә иде инде ул! Бар ул «гөлләр» арасында да чеп-чи наданнары! Йөрәк — гади насос лабаса, йөрәкнең үзгәреш, тайпылыш законнарын да белә алмагач инде! Үзләре юньле нәтиҗә чыгара алмагач, невропатологка аткаралар!.. Барды Нәҗип докторга, барырга туры килде...

Алдан ук искәртеп куйыйк: Нәҗип Йосыф улы Нургалиев бу юлы табибның чынына, остасына тап булды. Бәхете! Врач — кулына зур хокук тапшырылган стрелочник ул, теләсә, туннельдән сине яктыга чыгара, теләсә, туп-туры зират сукмагына төшерә.

Фәридун Фазлыев кешенең тәненә генә түгел, җанына да үтеп керә алган врач иде. Кырык сигезнең егерме икенче мартында кулга алынып, Особое совещание тарафыннан бер дә юкка ун елга хөкем ителгән кеше, төрмәнең гаять истәлекле беренче төнендә үк төп сорауга җавап таба алмыйча изаланды: ник утырттылар аны? Нигә җәмгыятьтән аердылар? Кемнәр файдасына?

Черек күл камераларында озак яткырмадылар аны, өстеннән язылган донослар өч-дүрт башны кыеп төшерергә җитәрлек иде. Монда совет системасын сүгү, халыкларның бөек юлбашчысына яла ягу, хурлаулар кебек, замананың иң хәтәр гаепләре бар иде.

Фәридун Фазлыев ирektә чакта Ходай ихтыяры белән чын табиб иде, аның янәшәсендә йөзләрчә наданнар, карьеристлар, эгоистлар, төп вазифаларын онытып, почмак саен «Бөек юлбашчыбызга мәңгелек дан!» дип акырып, мактаулы исем артыннан җылыдан-җылы урын яулаганда, Фәридун Фазлыев, эштән бүтәнне белмичә, меңнәрчә авыруларга тереклек суы бирә торды. Даны президиум өстәлләрендә, биек трибуналарда түгел, халык арасында таралды. Врачларны аралап-сайлап, авырулар аңа эләгергә тырыштылар. Ниһаять, дәүләт аппараты дигән сукыр көч хәрәкәткә килде, аның туры сүзен кыек дип, изге гамәлләрен җинаять дип язып бирделәр. Ялкау-аңкаулар көндәшләреннән, янәшәләрендә эшләгән намус, әхлак сакчысыннан котылдылар.

Лагерьда да ул беравыктан врач булды. Анда да кешелек сыйфатларын югалтмады, өстеннәрне түбәннәрдән аерып карамады, «нигә тотып яптылар, нигә җәмгыятьтәге гадел урынымнан аердылар?!» дигән дәһшәтле сорауга җавапны, бик күп язмышларны очратып, бик күп яралы йөрәкләрне тыңлагач кына, меңнәрчә җәбер-җәфаларны җиңеләйтергә тырышып, әллә ничә үлемнән котылып калгач кына тапты. Җәмгыять җинаятьчеләрдән түгел, гаделләрдән арынырга, намуслылардан котылырга теләгән икән!

Тапкан җавабы аның рухын сындырырга тиеш булса да, Фәридун Фазлыевның борыны салынмады, ул риясыз рәвештә язмышлар чарпалышып актарылган мәйданга — тоткыннар арасына гаделлек вәкиле булып керде дә, пигамбәрләрчә — гөнаһлыларга да, гөнаһсызларга да бердәй тугры хезмәт итте. Меңләгән тоткыннар гына түгел, кансыз җәза осталары, лагерь хуҗалары да аны олылап «доктор» дип атап йөрттеләр. Көнчелек — кешелек җәмгыятендә көрәшне хәрәкәткә китерә торган беренче рычаг ул. Лагерьда да көнчеләр табылды. Мөртәт бөтен туфракта да яралып үсә! Исән калды Фәридун Фазлыев, илле алтынчы елның февралендә акланып, реабилитацияләнеп ирекккә чыкты, зарыгып-атлыгып туган төяге Казанга кайтты.

Теге чакта астыртын елмаеп, күңелләрдә зәһәр агу куертып аны озатып калган көнчеләрнең күбесе тымызык күлдәге кортлар кебек үрчегәннәр иде: берәүләр профессор, доцент булып беткән, иң әрсезләре министрлыкка, обкомга үрләгән, һәммәсе диярлек югары, җылы урыннарга хуҗа булган, өсләренә җылы, томанлы яңгыр булып бүләк, орденнар, мактаулар яуган. Кая карама атказанган фән эшлеклесе, лауреат та дипломант...

Ул аларны эзәрлекләмәде, күзләренә күренергә тырышмады. Елан үлсә дә, угы кала, Алла сакласын, Сталин заманнары әйләнеп кайтмас дип кем әйтә ала? Фәридун Фазлыев көнчеләр күзеннән читтәрәк булырга тырышты, эш урынын, больницаны да татар ягыннан, шакшы һавалы, сөремле Яңа бистә тирәсеннән эзләде.

Үз өстеннән язганнардан берәү, очрашкач, күзен җиргә тәгәрәтеп, аны югары катлау вәкилләре дәвалана торган шөһрәтле шифаханәгә эшкә килергә кыстады. «Үзем урнаштырам!» — диде. Фәридун Фазлыев, табигатенә тугры калып, кызыккыч тәкъдимнән баш тартты. Белеше, керфекләрен мелт-мелт сикертеп: «Төрмә сине төзәтмәгән икән!» — диде. «Күңелең таза, тәҗрибәң ныклы икән, эш кайда да бар!» — дип уйлады Фәридун Фазлыев һәм бер ай эшләгәч үк үзенең сайлавыннан канәгать калды. Коллектив дус диярлек, күпчелек татар, кай арада үз телендә сөйләшүчеләр дә очраштыргалый, аратирә тимер юлның теге ягында, бистә урамнарында, кичләрен тальян гармун сыздырып җибәрәләр, әтәчләр дә саф татарча «кикрикүк!» дип кычкыра — лагерь кысаларында үз җирен, үз телен, үз моңын чиксез сагынып кайткан иде Фәридун Фазлыев.

Ул Нәҗип Йосыф улы Нургалиевне кызыксынып каршылады...

Яшь чагында бер дә авырмаган авыл егете. Сәламәт үскән. Әти-әнисе исән, тигез. Хәзер дә, күңел төшенкелеген исәпләмәгәндә, ябыклыгын уйламаганда, сау-сәламәт күренә. Күзләрендә генә ялвару, курку моңсулыгы, гасабилык галәмәтләре бар. «Тормышым тормыш түгел хәзер, җан газабы. Шул каһәр суккан Мәскәүгә барып эләктем дә, ярамады, чир кинәт бәрде! «Үләм!» дип бик курыктым. Хәзер дә гел әҗәл хакында гына уйлыйм. Үлем-җитем дигән сүзләрне ишетә алмыйм, «ашыгыч ярдәм» сызгыртып үтә башласа, котым ботыма төшә. Иелеп ботинкамны бәйләгәндә җаным бугазыма килә кебек... Бер чиләк су китерсәм, йөрәгемә йонлы тәпиле үрмәкүч ябышкан сыман. Яктыдан караңгыга, караңгыдан яктыга үтә алмыйм, күңел әллә нишли, зиһен томалана, бөтен җирдә кортка, әҗәл дигән явыз мине сагалый төсле... Үлемнән башка бернәрсә хакында да уйлый алмыйм!»

Сөйләде-сөйләде дә Нәҗип туктап күзен күтәрде: тылсымчымы әллә бу невропатолог дигәннәре? Ап-ак кашлы, дәү шыксыз борынлы бу доктор аның авызындагы йозакны алды, түбәләмә тулган капчыкны чишеп җибәрде. Ул ни тойганын,ниләр кичергәнен докторларга түгел, Наиләсенә дә ачмаганнарын чыгарды да түкте.

Фәридун Фазлыев аны бүлдермәде, ишекнең теге ягында чират кыштырдаса да, ишек ачылып-ачылып киткәләсә дә, бу егетне кемгәдер аткарырга, өметен кисеп чыгарып җибәрергә ашыкмады. Бу авыру сирәк очрый торганнардан иде. «Мөгаен, хисле кичерешләргә бай җандыр бу ир!» — дип уйлады ул. «Шулай да чир бер сәбәпсез эзләп килми, ишекне табып, нәкъ вакытында шакый ул. Кинәт чирләвегезнең сәбәбен үзегез кай тарафта дип күрәсез? Чир тигән кеше үз авыруының тамырына үзе барып җитә ала икән — бу кеше тәненә дә, җанына да хуҗа була ала дигән сүз! Бу бик мөһим! Нинди

яман чир килсә дә, кеше үз язмышын кулыннан ычкындырмасын! Тәннең бер әгъзасы да сәбәпсез сыкранмый. Менә минем йөрәк кизүем бар. Йөрәк сездерә икән, мин даруга, коткару бөятенә барып ябышмыйм. Әүвәл «нигә авырта бу йөрәк?» дип эзләнә башлыйм, һичнәрсәне яшермәскә тырышам! Тышкы, эчке сәбәпләрне эзлим. Аракы эчмәдем. Гомумән дә эчмим. Авыр әйбер күтәрмәдем. Авыр сүз ишетмәдем. Йөрәкнең беренче дошманы — авыр сүз. Татарның рухи табиблары, «авыр сүзләр ишетсәгез, үткәреп җибәрегез!» дип, безгә изге васыять калдырган... Ниһаять, эзләнә-эзләнә йөрәк тынычсызлыгының сәбәбенә барып җитәм».— «Сез бит врач!» — диде Нәҗип, көчәнеп елмая-елмая. «Һәркем үзенә-үзе врач. Кеше организмының, тәненең нечкәлекләрен бер врач та, иң сизгер аппаратлар да белеп бетерә алмый. Сәламәтлек барыннан да элек кешенең үз кулында».— «Сез җан газапларын күздә тотып әйтәсезме?» — дип сорады сак кына Нәҗип һәм соравы белән Фәридун Фазлыевның күңелендә шик уятты.

«Барын да чишеп бетердеме бу егет?» — дип икеләнде ул, ләкин ашыгып сорашырга базмады. Үзе сөйләсен, җиңеләйсен.

Нәҗип бер врачка карап, бер ишеккә колак салып, үткәннәрен кабатлап, вакылыкларына кадәр сөйләп чыкты. Фәридун Фазлыев чишмәдә су саекканын күреп, иплән кенә болай дип йомгак ясады: «Сезнең үтәлми калган, хәзерендә җаныгызны борчып, бәгыренезне кимереп торган берәр олы максатыгыз юкмы?»

Нәҗип, алдын-артын уйламыйчарак: «Юк»,— дип ычкындырды. Врач әллә аны ишетте, әллә ишетмәде, үз соравының әһәмиятен искәртергә теләгәндәй, сорауны кабатлады. Нәҗипнең сүзсез, ияген күкрәгенә терәп утыруын күреп, егеткә җавап эзләшергә булышты. «Адәм баласының мөмкинлекләре чикләнгән,— диде ул.— Һәркемнең үз офыгы, тормыш кора ала торган мохите бар. Чама-чамага туры килергә тиеш. «Ора алмас зур күтәрер!» дигәннәр татарлар. Ора алырлык егәрең юк икән — күтәрмә! Чөнки актыктан күңеленә зур үкенечләр килер. Үкенеч — көнчелекнең әнкәсе ич ул! Алар бер-берсенә тагылып йөриләр. Көнчелек исә — иң явыз хисләрнең берсе. Аннан котылмак юк! Булдыра алмастайны алдына куйган кеше гомере буе бүтәннәрдән көнләшә. Аңлата алдыммы икән?»

Врач та, Нәҗип тә тынып калдылар, һич тә Нәҗип көткәнчә булмады бу очрашу. Фәридун Фазлыев аның тезенә суккаламады, инә төртеп колак яфрагын да тишмәде, физик күнегүләр ясатып сынамады, сөйләтте-сөйләтте дә хәзер аңгырайган сыман тик көлемсерәп утыра! Ичмасам, гадәттәгечә «тәмле ашарга, татлы йокларга» кушсын иде! Авыр тынлыкта ишетелгән сүзләр үтә сәер иде: «Мин сезгә психиатр белән киңәшергә тәкъдим итәр идем»,— диде Фазлыев, ярым елмаеп. Башта Нәҗип аң-ламыйча ук торды: ничек, психиатр янына?! Бер тапкыр барды ич ул анда! Чак бәлагә тарымады! Тагын шул котсыз Фогельсон янына барып керергәме? Куып чыгарды чыгаруын, ә шомлы нәтиҗәсен теркәгән! «Псих!» дип гамәл дәфтәренә язып куйган!

Фәридун Фазлыев егетнең күкрәгендә нинди уйлар кайнаганны аңлады булса кирәк, тавышын бераз күтәрә төшеп: «Әйе, психиатр янына кирәгез. Бу тәкъдим сезне борчымасын. Сез сәламәт дип беләм. Тагын да сәламәтрәк булыйм дисәгез, аның катына барыгыз. Бик ышанычлы, төпле, тормыш мәктәбенең авырын үткән таныш врачым бар, Огородникова аның фамилиясе. Шуның белән киңәшегез әле»,— диде Фәридун Фазлыев, уч төбе хәтле кәгазьгә бер-ике сүз язып, Нәҗипкә тоттырды.

Шөкер, Огородникова дигәннәре теге юлы Нәҗипне боргычлап чыгарган козгыннар оясында түгел, бүтән шифаханәдә эшли икән.

Март азагы. «Март башыдыр — яз башыдыр, күңелне хуш ясыйдыр». Татар тормышының һәр тарафына күзе җиткән бөек пигамбәребез Тукай шулай дигән. Авырулар язга чыкканны, авыр кыштан котылганны түземсезләнеп көтәләр. Сырхау кешегә аерата таң аттыру авыр. Җәй — авыруларның өмет таңы ул, һәр бичара: «Һай, җәйгә чыксаммы?.. Сихәтләнепләр китәр идем!» — дип ымсына.

Нәҗип тә мартны көтеп алган иде, әлегә бәрәкәте тими, менә бүген дә Фәридун Фазлыев яныннан сөмсере коелып, торбасы кыеш иске самовар кебек чайкалып, күзен җиргә тәгәрәтеп кайтып бара. Аякларга тышау салынганмыни, гәүдә көне буе чүкеч суккандагы сыман авырайган, баш исле мунчадан чыккан кешенеке кебек сулкылдый, чигәләрне өзмәс кысып тора. Көннең чалт аяз икәнлеге күренми, хәйран җылынган алай. Кояш карны, пычрак дип тормый, ашый да ашый, юл чите көртләре кәрәзләнеп шыбырдап сөрлегәләр; яз шәһәрнең кыш буе җыеп, яшереп саклаган шакшыларын ача. Анда шакшы су түккәннәр, монда көл тавы, арырак мәче үләксәсе килеп чыккан. Чип-чиста кар бөртекләренә тагылып төшкән сөрем, корым кисәкләре хәзер дымлы, җылы һава дулкыннарына ияреп яңадан өскә күтәреләләр. Җил юк диярлек. Үтеп-сүтеп йөргән машиналар калдырган кургашынлы авыр һава, язны тансыклап киңәйгән күкрәкләргә чир булып тула, бугазны әчеттерә. Яшь әниләр, аллы-гөлле чүпрәкләргә төреп, аллы-кызыллы хыял канатларына утыртып, сабыйларын шушы һава арасына — «сәламәтлеккә» алып чыкканнар. Тимер юл чатында нәни генә бакча. Өрәңгеләрнең, кайчандыр горур булган тупылларның башын тумпак калдырып кырганнар. «Нигә кырганнар, ни хаҗәте булган?» — дип сора, беркем белми. Тупылларга күрше итеп шпал башларына терәп диярлек яшь наратлар утырткannар. Ел саен күпме акча исраф итеп утырталар шуларны, җәй дәвамында наратлар корып, шыр таякка калалар. Чөнки нарат агачы шау-шуны, тавышны сөйми. Тавышка иң сизгер агачлар —

нарат белән карлыган. Кеше йөри торган сукмак янындагы карлыган куагы берчакта да җимеш белән куандырмый, алар аулак, тын почмакларда оеп утырырга яраталар. Әгәр бу тупыллар болыт-болыт ябалдашлары белән күкрәп утырса, ни булыр иде? Газны-тузанны тупыл кебек суырган агач безнең якларда юк. Тупыл башларының ни өчен кыркылганын Нәҗип, әлбәттә, белми. Уйлап та карамый, һәрнәрсәнең сәбәбе була, моннан байтак еллар элек, хөрмәтле Иван Иванович Украинадан монда килеп, шәһәр советының хуҗасы булып утыргач (Мәскәүдән шалтыраттылар, түргә аны үткәрергә киңәш иттеләр!), бик шәбәеп кенә, муенны текә тотып, ять-яшь сылукай белән машинасында тирбәлә-тирбәлә аулакка барганда, тәрәзәдән ак мамыкка уралган бер орлык очып керде дә Иван Ивановичның кыз ягындагы сул күзенә кадалды. Яшь рәис кадакка утырдымыни, — уңга-сулга янтайды, күзе әчеттереп кычытты, сызлады, туктаусыз яшь акты. Чытлык сылукайга нәрсә, авызын тыя һәм йома алмыйча, чирек сәгать шаркылдады. Больницага кагылырга туры килде, сылукайдан бүгенгә аерылырга язган икән. Ул больницадан кайтуга шәһәрне яшелләндерү бүлеге мөдирен чакырып алып... кай җирең кечи... Икенче язда ук күккә ашкан тупылларны акылга утырттылар. Черкиләрдән куркып, Сталинның Кара диңгез ярларында ничәшәр йөз ел үскән кипарисларны тунатып ташлатканын ишеткәне бар идеме хөрмәтле Иван Ивановичның, әллә Сталин белән холык уртаклыгы очраклы туры килдеме, тарихта бу мәсьәлә әлегә ачылмыйча кала бирә... Шул елдан бирле шәһре Казан күген сакларга тиешле мәгърур агачларны яз саен «сөннәткә» утырталар.

Тупыллар тоташтан башсыз. Ботакларын бер читтәрәк яндырып, көлен алып киткәннәр. Тупыл төпләре кардан әрчелгән, анда ләмгә катып буш шешәләр сибелеп ята. Менә сәләмә бушлат кигән берәү иске кәрҗин күтәреп бакчага керде дә, Нәҗипнең буен-сынын, кыяфәтен үлчәп карагач: «Бу шешәләрне җыярга рөхсәтме?» — дип сорады. «Мине шешә каравыллый дип уйладымы бу хөрәсән?!» — дип рәнҗеде Нәҗип, эскәмиянең ярылып беткән аргы башына барып утырды.

Психиатрга күренәсе килми иде аның. Эзләнер-чокчыныр да холкыңнан, фигылеңнән бер-бер чатак казып чыгарыр. Йөрәк хастасы янына тагын бер шик килеп утырса, ничек яшәмәк кирәк?!

Бакчада ул шактый озак юанды һәм гел Фәридун Фазлыев белән очрашуы хакында уйланды, «һәркем үз чиренең сәбәбенә, тамырына барып җитә алырга тиеш... Җанның кичерешләрен, тилмерүләрен бары тик җан хуҗасы гына тулаем белә ала!.. Сез берәр чакта нәфесегезне куандыра алмыйча әллә дөньяга бик нык рәнҗедегезме? Сезнең тормышка ашмас хыялларыгыз җан тынычлыгын басып китмәдеме? Вакыйгалар, тормыш шартлары кинәт үзгәреп, сезне бер юлдан икенчесенә алып ыргытмадымы?!»

Баягы сәләмә адәм кар суында шакшы шешәләрне юып маташа һәм сәер, күгәргән тавыш белән моңлы итеп җырлый:

> Тагы да шулай, бер күрергә зарыгып,
> Үтәр микән безнең гомерләр?..

Берәүнең дә сандыгы буш түгел, күңел түрендә нидер бар. Бу бичара йолкышның да бетмәс кайгы-хәсрәте бардыр. Ул да, нәкъ Нәҗип шикелле үк, кайгы-хәсрәтен бер йомгакка урый алмыйча тинтерәп йөридер. Җырның дәвамын тыңларлык хәле юк иде егетнең, ул бетмәс кайгысын бәгыренә урый-урый өенә кайтты, бусага аша көч-хәл белән атлап керде. Бәхете — Наилә эштә, балалар бакчада иде. Ул кайтканчы аңа дигән, аңа сыя торган җавапны әзерләп куярга иде. Психиатрга күренергә кирәклеген хатынга әйтергәме, юкмы? Болай да кырын күз белән карый башлаган Наилә Нәҗибеннән бөтенләй йөз чөермәсме? Көнләп түгел, сәгатьләп суына барган арага бу яңалык ни өстәр? Кичкә чаклы башын авырттырып уйланса да, Нәҗип күңеленә хуш җавап табалмады. Көндезге кебек башын аска иеп Искәндәрне бакчадан барып алды. Төпчеккә хатыны кагылырга тиеш иде. Суда ашыгыч пешкән тере ярмалы дөге боткасын ашап, шикәр шакмагын вак-вак тешли-тешли, төссез грузин чәен эчкәннән соң, Нәҗип чыгарга җыена башлады. Гаҗәп, Наиләсе бүген: «Кая барасың?» — дип сорамады, капкага тиклем озата чыкмады.

Нәҗип туп-туры Фәридун Фазлыевны эзләп китте. Ул, көндез хушлашканда: «Әгәр бик кирәгем чыкса, кил үземә!» — дип, якты чырай белән өй адресын биргән иде. Нәҗип бүген үк барасы итте, хәзер үк! Очраклы рәвештәме, төзәпме, Фәридун Фазлыев аның уйлары төйнәлгән ноктага туп-туры тидергән иде. Нәҗип докторның сорауларының очраклы түгеллеген дә, сораулар эчендә дөрес җавабы да барлыгын инде төшенгән диярлек иде.

Йортны тиз эзләп тапты. Яңа бистәдән ерак та түгел, Павлюхин тирәсендәге биш катлы йортлар арасына кысылган ике катлы, акшары купшакланган, тәрәзә пыялаларын вакыт җиле каралткан йортта яши икән врач. Өйдә булып чыкты, өс-башын җиңелчәгә алыштырган, идәнгә җылы башмакларын куеп, кыршылган диванда кырын ятып, газета укый иде. Нәҗип килеп кергәнгә бер дә аптырамады, торды, хатыны белән таныштырды, үзе янына, диванга утырырга чакырды.

«Тагын сезнең янга килдем әле, Фәридун абый».— «Мин шулай булыр дип көттем дә».— «Ничек алай?» — «Без анда сүзгә нокта куеп бетермәдек шикелле». Сүз Нәҗип уйлаганга караганда да җиңел ялганып китте. «Мине сезнең бер сүзегез борчый».— «Сүзләр байтак булды, кайсысы борчый икән?»

Әзрәк кенә тынып тордылар. Врачның җәмәгате өстәлгә ике чынаяк чәй китереп куйды, нәрсә-кара өстенә ябылган ашъяулыкны ачты. Аннан ике-өч телем ипи, шикәр һәм капламычның төбенә сыланып калган ак май чыкты. Хуҗа белән кунак шулай ук сүзсез өстәл янына күчтеләр һәм кыстамыйча да иреннәрен йомрыга тидерделәр. «Ягез, ягез!» — дип сөйләшергә кыстады хуҗа, нык ук кызыксынып. «Сөйләргә дип килдем инде! Җан тынычлыгым болай да таралган иде, сезнең бер соравыгыз туп-туры йөрәккә барып тиде». Фәридун Фазлыев дәшмәде, ияген кагып кына куйды. «Бу дөньяда каядыр омтылып, киләчәккә чамадан тыш өметләр баглап яшәгәндә, көтмәгәндә чир килеп кагылгач, корган хыялларыгыз чәлпәрәмә килмәдеме?» — дидегез сез.

Фәридун Фазлыев, текә маңгаена сибелгән сирәк чәчләрен артка сыпырып, аңа тагын да яктырак күз белән карады. «Дөньяны аңлау шактый кыен нәрсә, Нәҗип дус». Ул шулай диде, гади генә «Нәҗип» дип исеме белән атады. Соңгы көннәрдә «имгәк, тунеяд, эшсез, әрәмтамак» дигән «чин-дәрәҗә»ләрдән тилмергән җан җылынып китте. «Фәридун абый!» — диде ул, өзелеп. Егетнең тойгыларга бай, хисле булуына врач тагын бер кат ышанды. «Дөньяны әзме-күпме аңларга була! Чыганаклар күп, дөнья агышын күзәтеп баручылар бихисап дигәндәй... Үз-үзеңне аңлау читенрәк! Бәндә хатасыз, ялгышсыз, языкларсыз яшәми, бигрәк тә хәзерге заман шуңа корылган. Әгәр кеше үз-үзен аңларга тырышып карый икән, ул табигый рәвештә үзе кылган гөнаһлар, ялгышлар, хаталар турында да уйларга мәҗбүр була. Шуңа күрә без үз-үзебезне аңларга тырышмыйбыз да».

Нәҗип әңгәмәне алга алып китәргә кыймады, бер-ике сүз әйтергә өлгерүгә, моңарчы үзе хакында үзе корган фикерләренең ишелеп төшәсен сизде. Фәридун Фазлыев җиңел генә икенче якка борылып керде. Әле бу юлның кая илтеп җиткерәсен белмәгән Нәҗип сүз кыстырырга базмады. «Сигез ел төрмәдә утырдым, лагерьларда! — диде гап-гади итеп Фәридун Фазлыев.— Күпчелек акыл шунда тупланганга, мисалларым шул тормыштан була икән, үпкәләмәссез! Анда да яшәү, яшәр өчен тартыш бара... Барып төшкәч тә Казакъстанда идем. Безне төзелешкә җибәрделәр. Каравыл офицерлары өчен йортлар салабыз. Коесын казыйбыз, мич чыгарабыз һәм башка шундый күз күргән эшләр. Миңа эш — кайда да эш! Эшләп күнеккән! Кушсалар — наять итеп үтәргә тырышам. Чир китә, гадәт китми, диләр. Рәнҗешләремне онытып, җилкәмә терәлгән мылтыкны санламыйча, ни кушалар, шуны эшлим. Кая җибәрәләр, шунда барам. Күндәм ат кебек. Әгәр янәшәмдә эшкә хирыс адәм туры килсә, бетте, аннан уздырырга тырышам. Суксалар, типкәләсәләр дә, карышмыйм. Шулай берзаман шыр сөяккә калдым. Мунчага керсәм, үземне үзем танымыйм. Казакъстанда җил анда, җилгә каршы баралмый башладым. Бригадада Карпат ягыннан берәү бар иде. Мукачеводан. Илечко иде фамилиясе, Ростислав Иванович. Күңелчәк кеше иде, телләр белә, укыган. Хәйләгә дә маһир икән. Без татарлар хәйләгә оста түгел, туп-турыдан суктырабыз. Карыйм берзаман, көн туса бригадир мактый тегене: «Уңган!» — ди. Ә минем аның уңганлыгын бер дә күргәнем юк, ичмасам! Түзмәдем: «Ник мактыйлар сине?» — дип сорадым. Пырхылдап көлә теге, «шыр тиле!» дип, мине әрли-әрли шаркылдый. Чак кына ачу кабарды моңа. Ничек инде алай «шыр тиле»? — «Җүләр,— ди бу,— син бит зек, тоткын,— ботыңда, күкрәгеңдә, маңгаеңда, җилкәңдә — дүрт урында номер. Кеше түгел син — номер! Ә син кешеләрчә тырышасың. Син миннән өйрән! Эшкә килгәч тә бригада беркавым эленке-салынкы йөри, тарта, гәп суга. Ә мин килүгә эш коралы алырга чабам, корал таратучыны тыкырдатам: «Кая минем чүкеч? Кая минем балта?!» Бүтәннәр филонить итә, мин кызып-кызып эшкә тотынам! Тузаннар оча! Шуннан бүтәннәр эшкә тотына. Мин, эш кырган сыман, тәмәке пыскытырга утырам. Утырам, йомыш табып читкәрәк каерылам һәм көне буе ялкау симертәм. Көн үтә, кояш баешка бара, съем вакыты җитә, бригада капкага тартыла, конвой чыгып тезелә, ә мин ярсып-кызып эшкә ябышам! Пыр туздырам. Бригадир ашыктыра, зеклар кычкыра: «Давай, топай!» Мин иң актыккы кеше булып инструментларны тапшырам. Бригадир күрмиме шуны? Ул минем хәйләне дә белә, сукыр түгел, ләкин аңа кемнедер мактарга, кемнедер эттән алып этkә салырга да кирәк. Кем бригада күзе алдында эш күрсәтә? Мин! Тора-бара бригадир җай чыккан саен мине мактый, пайканың зурысы миңа эләгә».

Ростислав Иванович сүзеннән мин аптырашта калдым: «Алай ярамый. Бөтенебез шулай хәйләгә сабышсак, норманы кем үтәр?» — димен. «Ни өчен план үтәлергә тиеш соң? — ди бу.— Без бит — коллар!» — «Хәйлә — барыбер намуссызлык»,— дип акланырга тырышам мин. «Илдә намуссызлык, гаделсезлек өстенлек иткәндә, бер синең намуслы булуыңнан кемгә файда? — дип авызны каплый бу.— Тормышның үзәк юлы — хәйлә. Хәйлә — үсеш, алга барыш чыганагы, этәргече. Хәйләгә осталар югары дәрәҗә ала, майлы калҗаның дәве аңа эләгә. Командир, власть иясе, юлбашчы була. Әйтик, маршал Жуков, хәйләкәр булмаса, фашистларны тозактан тозакка төшерә алыр идеме?..» Мин бу чагыштырулар белән асла килешмәсәм дә, әңгәмә азагында күңелем авырайды. Мине «шыр тиле» дип атавы белән дә килештем Илечконың, әмма холкымны үзгәртә алмадым. Кол хәлендә дә тырышып, намусым кушканча эшли бирдем. Ул хаклы иде, мин берчакта да хәйләгә яраша алмадым».

Нәҗип, бик кызыксынып тыңласа да, Фәридун Фазлыевның сүз сөрешен аңлап бетермәде. Кире дә какмады, килешмәде дә. «Тормышта, кеше яшәешендә тагын бер нәрсә — көнчелек ифрат зур урын били. Көнчелек — күпләрне алга сөйри торган яшерен көч. Зарарлы зәхмәт ул, чир! Ә тигезсезлек хөкем сөргән җәмгыятьтә, мин моны сиңа курыкмыйча әйтәм, көнчелек — идеологиябез, күпчелекнең

бердәнбер иманы ул. Кара менә, бездә югары үрләгән кеше генә чын кеше булып санала. Татарда мәгънәле бер сүз бар: «урындагы кеше» диләр бездә. «Урында» икәнсең, син — башлык, начальник. Дөньяның бар рәхәте сиңа бирелгән! «Урын яулаган» кеше белән гадиләр арасы үтә ерак! Асылда алар берчакта да очрашмыйлар. Аерым ашыйлар алар, аерым ял итәләр, шифаханәләр аерым, күңел ачу урыннары аерым. Тигезлек, гаделлек булмаган җәмгыятьтә көнчелек кеше иманына тулы хуҗа булып ала».

Фәридун Фазлыевның хатыны әңгәмәгә комачауламас өчен аяк очларына басып кына тагын берәр чынаяк кайнар чәй чыгарды, кыстатмыйча аны эчеп куйдылар.

Хуҗаның фикере кая юнәлгәнен көндезге очрашуда ук аңлый башлаган Нәҗип: «Сез боларны нигә миңа сөйләдегез, Фәридун абый?» — дип төпченмичә булдыра алмады. Фазлыев, «гаепләштән булмасын!» дигәндәй, ярым елмаеп, җиңелчә-шук тавыш белән җавап бирде: «Сездә, минемчә, төрмәдәш дустым Ростислав күздә тоткан хәйлә юктыр, ә көнчелек... — Бу урында хуҗа күтәрелеп Нәҗипнең күзләренә карады, — заманча, хәттин ашкандыр дип беләм. Сез «чир вә әҗәл» килеп җитте дип өркеп, уйлаганнарым барып чыкмады дип куркып, бик нык борчылмадыгызмы икән дип уйлыйм. Җавап бирмәгез, кирәкми, чөнки җавап миңа түгел, үзегезгә кирәк. Сез үз халәтегезне аңларга тырышып карагыз!»

Фәридун Фазлыев кабат бу хакта сүз куертмады, бүгенге очрашуга һич исе китмәгәндәй, язгы һава, язын кешеләрнең кәефе кырыкка төрләнүе турында гамьсез генә бер-ике сүз әйтеп алды. Чираттагы сүзләрен кырт туктатып: «Сез читенсенмәгез, Огородникова янына сугылыгыз әле»,— диде.

Аның лагерьдан котылып чыкканнан бирле болай чишелеп китеп, һич шикләнмичә, ышанып һәм теләп җанын ачып салганы юк иде әле. Ул Нәҗип Нургалиевкә бер күрүдә ышанды. Гомере буе адәмнәргә яхшылык кына кылырга омтылган Фазлыев кемгәдер нык ышанырга, ышанычның ялгыш түгеллеген күреп яшәргә омтыла иде. Җәмәгате: «Чүегез, чәй яңартам, кайнарын китерәм»,— дип, ике-өч тапкыр талпынса да, Нәҗип, озаклап юануын шәйләп, чәйләргә читенсенде, рәхмәт әйтеп ишек бавына тотынды. Фазлыевның егеттән аерыласы килмәде, ул, каударланып, кунакны чак кына озатырга булды.

Чыктылар. Төн карасына чыгып, янәшә басып сүзсез калгач кына, Нәҗип Фәридун Фазлыевның тәбәнәк, җилкәсе нык ук бөкрәйгән икәнлеген күрде. Ул аңа өстән, югарыдан карап тора иде.

Көндезге зәһәр исле һава бераз хәл алган, талгын җил исә, җил яз исе, башлары кыркылган мескен тупыллар ягыннан кайры һәм үксезлек исе китерә иде. «Дөрес аңлаган булсам, сездә көнчелек тә, хәйлә дә юк инде, Фәридун абый?» Фәридун Фазлыев яшь тавыш белән көлеп җибәрде: «Көнчелек һәм хәйлә булса, мин шушы татар ягында, сөрем-газ арасында: өстән юеш, астан дым тартып яткан хәрабә йортта яшәп ятар идемме? Минем хезмәт хакымның күпме икәнен әйтсәм, егылып китәрсез!» Нәҗип - хуҗаларның сыйга саран чәй табыннарын күз алдына китерде һәм ияген кагып алды. «Чамалыйм».— «Ростислав вәгазеннән соң мин аның яраны булып китте дип беләсезме? Һич юк! Әгәр врач икәнлегемне белеп больницага күчермәсәләр, мин шунда, бик күбәүләр кебек, агач бушлат киеп теге дөньяга күчә идем. Хәйләм һәм көнчелегем юклыктан бу дөньяга чак сыеп яшим. Әмма күңелем пакь: пакь күңел җәбер-җәфа тоеп та озак яши!»

Гаҗәп хәл: Фәридун Фазлыев сүз сөйли башлауга, гәүдәсе калкып, биегәеп китә, әлерәк кенә баш түбәсе Нәҗипнең култык астына җитә язган кеше үсә, үсә, аның белән бер буйда диярлек булып кала. Ни хикмәт бу?..

«Утыз өч ел җирдә яшәгән кеше үзгәрә аламы соң?» — дип сорады Нәҗип, беренче мәртәбә бүтән кеше алдында үзенең көчсезлеген танып. Фазлыевның яшь тавыш белән көлеп куюына Нәҗип күнегә башлаган иде инде, бу юлы бу яңгыравыклы көлү авазларының үзенә тәэсир көчен тойды. Ул көлгәннән соң Нәҗипкә дә рәхәт булып, җиңелрәк булып кала иде. «Нигә үзгәрмәсен, бишектәге бала йөзгә төрләнсә, кеше, кабер ягасына барып җиткәнче, ел саен, чор саен ниндидер үзгәрешләр кичерә».— «Сез дә үзгәрәсезме?» — дип сорады Нәҗип, тотлыгыбрак. «Ник үзгәрмәскә?! Менә мин озак елларга кадәр кешенең яшәү формасы көрәш дип инанып яшәдем. Көрәшергә тиеш адәм баласы һәм вәссәлам! Җирнең матурлыгы өчен дә, кешелек бәхете өчен дә, бигрәк тә киләчәк өчен, кыскасы, һәммә-һәммә нәрсәләр өчен көрәшергә тиеш кеше дип санавым. Шулай дип укыдык, дөнья маңгайга бәрә-бәрә һаман шуны тукыды. «Ленин бабабыз безне гел көрәшләргә чакырган! Бәхет дигән мөкатдәс сүз телдән төшеп кала язды, аңа бары тик өзлексез көрәш нәтиҗәсендә генә ирешеп була дип ышандык, һәм бүтәннәрне дә шуңа ышандырырга тырыштык. Ышанмасалар, танклар керттек, илләр арасына таш ныгытмалар бастырдык. Без дә бит шулай: сукыр күзлеләрне җитәкли, ялкау уңганны эшкә өйрәтә».

Алар беравык янәшә бардылар. Фазлыевның тагын тәбәнәкләнгәнен сизеп, Нәҗип бераз читкәрәк кагылды. Алар ашыкмыйча, уравыч юллардан әйләнә-тулгана бардылар. Фәридун Фазлыев сөйләргә әзерләнеп тамагын кырды. «Әгәр гел-гел көрәш өчен яши икән, кеше рәхәт күрергә дә, бәхетле булырга да өлгерми. Кеше кирәкмәс җирдә дә көрәш артыннан көрәш уйлап чыгарырга мәҗбүр була. Һәр көрәш — яңадан-яңа корбаннар дигән сүз. Йә җаны әрәм була кешенең, йә тәне. Көрәшләрнең күпчелеге, изге ниятләр белән башкарылса да, көткән нәтиҗәләрне китерми! Юк! Кеше яши икән — бәхет татыр өчен

яши. Шуның өчен дөньяга туа. Бәхет! Нигә квартир өчен көрәшергә тиеш кеше?! Бер сынык икмәк өчен нигә тарткалашырга мәҗбүр? Трамвайдагы урын өчен, зираттагы почмак өчен, оят җирен капларлык чүпрәк-чапрак өчен көрәшә-тарткалаша торгач, кеше кешелеген җуя, бәхетнең тәмен, кадерен югалта. Кешенең яшәү формасы көрәш түгел, бәхетле булу. Күп илләрдә халыклар моны аңлады инде».

Фәридун Фазлыев лагерьдагы газаплы көннәрен, авыр язмышын бүлешкән иптәшләрен уйлап алды. Төрлечә уйлап, сынап карарга андагы юлдашлары ярдәм итмәдемени аңа?!

«Кайберәүләр көрәшне бәхет дип кабул итсә? Шуңа инанса?» — дип сорады Нәҗип. «Бар, андый фанатиклар очраштыра. Ләкин алар берчакта да җиргә бәхет китермәгәннәр. Наполеон китергәнме җиргә бәхет? Маркс биргәнме? Адәм баласы кояшлы җиргә бәхет татыр өчен туа!»

Юлдашы уйга калды. Фәридун Фазлыев бәхетле иде, чөнки аның күңелендә асрап, ныгып киткән фикерләре бәрәкәтле туфракка төште. Ул соңгы вакытларда гына күңеленә иңгән тагын бер акыл белән уртаклашырга булды.

«Мин элгәрге елларда «власть теләсә кемне боза» дип ышанып йөри идем. Үземчә мисалларым да җитәрлек иде! Ялгышканмын! Властька бозык күңелле кешеләр генә омтыла икән! Шәһәребездәге байтак медицина әһелләрен беләм. Күпләр гомер-гомергә ихлас эшләделәр, намус кушканча гадел яшәделәр. Беркем аларга дәрәҗәле урын тәкъдим итмәде, властька чакырмады. Кыек куллы, пычак күзле, үз мәнфәгатьләре өчен бүтәннәрне бугазлап ыргытырга әзер торучыларны власть үзе эзләп тапты. Әйтик, әлегә аның бозык күңелен берәү дә белми, песием-песием булып йөри бәндә, ә власть белә, үтәли күрә, һәм элегрәк властьның бер тармагын кулларына беркетеп өлгергән бозыклар үз ишләрен эзләп алалар! Власть чире тумыштан йоккан явызларны үз яннарына җыялар да алар. Ялгышсалар, сайлаганнары алар арасына ялгыш килеп керсә, аларча мөгрәргә өйрәнмәсә, аны шундук кабып йоталар. Власть — аяусыз көч ул, усал, явыз көч. Тоталитар дәүләтләрдә бу аерата ачык чагыла. Власть әһелләре хәйләкәр, алар битлек кигән, явызлыкларын яшерергә өйрәнгән, бөтен явызлыкны, усаллыкны власть башына үрмәли алмаган, ләкин гомер буена шул хакта хыялланган, аларга сукырларча ияргән, рухи кол булган гап-гади бәндәләр үти. Власть башында ныгыган тимер куллар, корыч күкрәкләр, таш йөрәкләр балтага берчакта да үзләре тотынмый, балта гадиләр кулында. Власть әһелләре заман үзгәрүеннән котлары очып куркалар, шуның өчен канлы эз калдырмаска тырышалар. Эзләр булып бүтәннәрнеке кала. Утыз җиденче ел приговорларында полковниклар имзасын күрәсеңме син? Майорныкынмы? Юк, «атарга, асарга» дигән хөкем карарларына күбесенчә сержантлар кул куйган, гадиләр имза салган. Менә берәүне юк кына гаеп өчен атарга хөкем кылдылар. Властьның әмере бер: юк итәргә! Власть итәгенә якынайтылган коллар гаепсезнең башын чабып өзә, уйлап, исәпләп тормый. Аңа барыбер, кулына балта тоттырганнар икән, ата-анасын һәлак итәчәк, газиз баласын суеп ыргытачак. Чөнки ул тормыштагы урыны өчен көрәшә. Ул көрәш рухында тәрбияләнгән. «Мы весь мир до основания разрушим... а затем!..» Менә аның шигаре! Палач балтасы ял итми, ул селтәнгәндә, власть ияләре кәеф-сафа корып, илнең нәни почмагына сыйган җәннәттә яшәп яталар. Ә балта тотып җан кыючылар, гадиләр, хөкем чыгаручылардан нәрсә белән аерыла? Алар ахыр чиктә җәза таягының баш-башлары... Совет власте урнашканнан бирле күпме башлар киселмәгән! Баш кисүче, җан кыючыларны без алтынга яллап чит илдән китертмәгән, алар да шушы кояш астында, шушы җәмгыять шартларында, власть хуҗаларының ихтыяҗыннан туып ишәйгәннәр. Ә шул палачларны көнгә күрсәткәннәре бармы? Юк. Андыйлар, хатын, балалары катына кайтып: «Бүген өч йөз илле адәмнең башын кых иттек әле!» — дип мактана алмыйлар инде. Власть ияләре эшче-крестьяннан качып яшәгән кебек, балта тоткан палачлар да, сукыр тычкан кебек, кеше күзеннән, халыктан читтә гомер үткәрделәр. «Кешенең яшәү рәвеше — Көрәш!» дип әнә шундыйлар кычкыра. Һәм ышандыралар да! Адәм балаларын бәхеттән мәхрүм итәләр, аларны хәерчелектә, изелүдә яшәтеп, «безнең ил — иң бәхетле ил!» дип җырлаталар.

Болай таба килүче өч ир күренде. Өч ир очраганда Казан урамнарында сагаерга кирәклеген үзләштергән Нәҗип, юлдашына ым белән урамның икенче ягына чыгарга кушып, җиңеннән тартты. Нәҗип адымын тыйса да, Фәридун Фазлыев тукталмады. Шикле өчлек алар каршысына чыкты, өчәүләшеп челәя-челәя карап, нәкъ каршыларына килеп туктадылар. Көтмәгәндә авызлары ерылды, картузлары очып башларыннан купты, Фәридун Фазлыев белән Нәҗипкә юл саптылар, дәшмәделәр. Бераз киткәч, Нәҗип борылып карады: «Сәрхушләр!» — дип сузды. «Тимиләр алар миңа,— диде көлемсерәп Фәридун Фазлыев.— Өчәү очрасалар, берәвесенең минем катка килгәне була. Белмәүчеләр туры килеп җәберләмәсеннәр дип кайчагында мине озатып та куялар. Беләм, йә караклар алар, йә үтерүчеләр. Власть башында утырып, изге саналып йөргәннәрдән алар кай яклары белән ким?!»

Алар тимер юл буена килеп җиттеләр. Уфылдап, сызгыртып тәбәнәк маневр паровозы үтеп китте. «Менә, Фәридун абый, мин кайтып җиттем».— «Тимер юлга бик якын торасыз икән!» — диде Фәридун, теге яктагы караңгы өйне караштырып. «Бәла булды инде, җәфа! Төн ката поездлар үткәнне

тыңлап, карганып, каһәрләп ятам». Фәридун Фазлыев тагын көлеп алды. «Әй син, Нәҗип дус, поездлар үтә дип уйлама… Бу вагоннарда никадәр халык, күпме кеше бәхет эзләп, яки бәхетсезлегеннән качып каядыр бара дип бел… Адәм баласы тиккә генә сәфәр чыкмый. Нужа йөртә аны! Кайгы-хәсрәт йөртә! Поездлар дөбердәп үткәндә син шул хакта да уйла. Җаныңа җиңелрәк булыр!»

Саубуллаштылар. Нәҗип кайтып кергәндә, Наилә йокламаган иде әле. Өстәл лампасын, яктысы балаларга төшмәсен өчен, одеял белән төргән, кулларын баш астында кушырып, түшәмгә карап ята иде. Нәҗип кергәч тә борылып карамады, димәк, уйлары бүтән якта, еракта йөзә булса кирәк. Нәҗип сүзсез чишенде, хатыны тәне һәм сагышы белән җылыткан урынга сузылды. Дөбердәп, йортны нигезеннән кубарып ыргытырга теләгәндәй селкетеп, озак шаулап, ишле вагонлы поезд узды. «Ничаклы кешеләр нужа куып сәфәр чыккан!» — дип уйлады күңеле йомшап Нәҗип. Дөнья бер мизгелгә тынды. Таңсылу ягыннан шешә һәм тустаган чыңлаганы ишетелде. «Йокламый,— диде Наилә, пышылдап.— Япа-ялгызы салып утыра. Бер шешәне бетерә бугай инде. Гаҗәп, дөньяда булмаган хәл: мине дә чакырган иде, кермәдем». Ике якта ике хатын... Ир югында хатын-кыз уй белән кочаклашып ята... Ни уйлыйлар икән алар? Таңсылуның нужасын чамаласа да, Нәҗип үз хатынының уйлары кай тарафларда йөргәнен белми иде. Гөлнараны чит илгә, Финляндия белән Швециягә озатып кайткан иде Наилә...

Нәҗип ике кулы белән аны кочып алды, үзенә таба тартты. Башта карышса да, Наилә ипләп кенә аның кочагына сеңде, сизде, бүген иренең кулларына бераз көч кергән, күкрәге ныгый төшкән иде.

**11**

Ул доктор Огородникованың исемен оныткан иде, кабул итү тәрәзәчегенә арты белән утырган шәфкать туташыннан сорады. Туташ өч эндәшкәннән соң гына акаеп аңа карады, тулышкан, мәмрәп пешкән ал иреннәреннән:

«Йөриләр шунда бимазалап... психлар!» — дигәнрәк сүзләр чыкты. Нәҗипнең китми торуыннан алҗып: «Фаина Марковна!» — дип акырды.

Кичә Фәридун Фазлыев сабакларыннан соң чиренә дә, үзенә дә бүтәнчәрәк караган кебек тоелды. Ул йокысыннан күтәренке күңел белән торды, Искәндәрне бакчага илткәндә, күптән булмаганча, шаяртты, көлдерде. Кире кайтып килгәндә Гафури урамындагы бер йортның капка баганасына терәлгән табут капкачын күргәч, сискәнеп китте. Тагын йөрәге какты, һәм Фәридун Фазлыев тәкъдим иткән врач янына ашыкты. Фаина Марковна икән аның исеме. Бүтән ишек төпләрендә сәдака көтеп утырган хәерчеләрдәй, байтак халык бөялеп тора, алдан килгәннәр урын эләктереп калган, соңарганнар киемнәрен акшарга буяп, диварларга сөялеп, җаннарына дәва, тәннәренә шифа көтәләр иде. «Психиатр» дигән язулы пыяла эленгән ишек каты әлегә буш иде.

Нәҗип килеп басуга, эчке яктан берәүнең, ишекне тишәрдәй булып, илереп-тилереп акырганы, аяк тибеп кычкырганы яңгырады. Әллә шул тавыштан куркып таралганмы чират? Ирнең тавышын басарга тырышкан хатын-кыз сүзләре ишетелгәли, ләкин берсенең дә ни әйткәннәрен аңларлык түгел иде. Ишек аша чыккан тавышны куркып тыңлап торганнан соң, Нәҗип кыюланып ишекне какты. Гауга бер мәлгә тынды, ишек йомшак кына ачылды һәм эчке яктан дәү гәүдәле, йомры иңбашлы, калын җирән чәчләрен юан толым итеп баш түбәсенә урап куйган, Нәҗиптән дә озынрак гәүдәле, сипкелле ханым күренде. Ак кардай халатыннан төшкән нур аның бит очындагы эре-эре сипкел бөртекләрен алтынга манып, матурлап күрсәтә иде. Бүлмәдә гауга, тавыш дәвам итсә дә, ханым тыныч һәм сабыр күренде. Нәҗипне кул ишарәсе белән үз янына өндәп, янындагы авыруга сүз тәмам икәнен аңлатты. Нәҗип каршысына зәңгәр күзләре тирән чокырларга кереп поскан, арык яңаклы, ябык муенлы бер бәндә килеп басты. Аның сөяккә калган шыр бармаклары дер-дер калтырый иде. Ул әллә сугарга ниятләде, әллә төртеп егарга, бәбәкләрен шарландырып текәлеп торды да ишеккә ташланды, ачкан ишеген япмыйча, чыгып югалды. Огородникова, һич исе китмәгәндәй, ишекне япты, кулын марля кисәгенә сөртеп, урынына утырды. «Мин сезне тыңлыйм», — диде ул, Нәҗипкә урын күрсәтеп. Аның карашының үткенлеген, гадәти түгеллеген Нәҗип кергәч үк чамалаган иде, хәзер, күзгә-күз очрашкач, сискәнеп, югалып калды. Йә, ни сөйли ала инде ул бу ят яһүдәгә?! «Фамилиям минем Нургалиев,— диде ул, битараф кына,— исемем Нәҗип».— «Ә-ә, бу сезмени? — диде Фаина Марковна, яктырып.— Фәридун Фазлыевич өйгә шалтыраткан иде».

Нәҗипнең күңеле тынычланып, арадагы киеренкелек кимеде. Ул, бер җебен дә калдырмыйча, Фәридун Фазлыевка сөйләгәннәрнең бөтенесен сөйләп бирде. Сүзендә зур бер яңалык булып, Фаина Марковнаның күзеннән ул яңалык та читтә калмады. «Характерымда бозыклык бар, ахрысы, минем, кыен ашаган саен югарыга омтылдым, югарыдан торып түбәннәрдән, аягыма тагылган нужадан үч алырга да җыена идем... Өметем шул иде минем, заводка кайтам да лабораториядә мөдир булам, аннан югарырак та үрмәлим. Бүтәнчә киләчәгемне күз алдына да китерә алмый идем! Зур иде минем теләкләр, авыз киң ачылган иде! Хәзер миңа сулаган һавамнан кабер исе килә, уйлаган һәр уемда ләхет салкынлыгы, тормышымның һич яме калмады. Әҗәлдән куркам, менә-менә үләрмен төсле!»

Нәҗипнең сөйләгәннәрен үзенә сеңдерә барган Фаина Марковнаның йөзе, утырышы, кыяфәте үзгәрә барды, ул кинәт кенә олыгаеп, тагын да җитдиләнеп калды. Ул, бүтән табиблар кебек, анализлар белән кызыксынмады. Фаина Марковна тәнне түгел, җанны дәваларга күнеккән, гомумән, ул медицинаның төп бурычы — җанга төрле яктан бик җентекле якынаю дип саный иде. Нәҗипнең үз авызыннан чыккан фикерләр аның өчен бик җиткән иде. Нәҗип сүзен бетергәч, ул тәрәзәгә төшә башлаган март кояшының кыйгач нурларына карап утырды да: «Минем янга килеп ялгышмагансыз, сез чыннан да безнең авыру! — диде. — Мин сезнең белән ачыктан-ачык аңлашырга телим, Фәридун Фазлыевич шулай үтенде... Сез кергәндә, бүлмәмдә бер кеше бар иде. Сез аны күрдегез. Тотышына, кыланышларына игътибар иткәнсездер. Минем аңа шактый битараф, салкын карашымны да тойгансыздыр. Мин монысын сезгә танарга тиеш түгел идем, мәгәр сез аның кем икәнен белмисез һәм белергә тырышып йөрерсез дип тә уйламыйм. Ләкин аны күрүегез ярап куяр! Бу сезгә тере мисал, кисәтү үрнәге. Ул әнә шул — үлемнән курку чире белән моннан алты ел элек минем яныма килгән иде. Нинди генә дарулар тәкъдим итеп карамадык без аңа, гипноз сеанслары үткәрдек, уколлар алды, санаторийга да җибәрдек, файдасы табылмады. Нигә дисәгез, ул үзе савыгырга теләмәде. Сез сәламәт. Теге төнне Мәскәүдә арыганлык сезне бәреп еккан. Сез көчегезне тигез бүлә белмәгәнсез, ашыгып-ашыгып алга ыргылгансыз!.. Максатыгыз зур һәм кызыктыргыч булган! Җигүле ат камытыннан ычкынып чыгып китсә, арбасы артта кала... Ул да җай белән барырга тиеш! Сез сәламәт. Фәридун Фазлыевич та шулай дияргә кушты. Йөрәкнең кинәт дулап куюы була. Ул хуҗасын искәртә, чаманы чамага туры китереп тыелырга куша. Гел ашыгып, кабаланып, чәбәләнеп яшәү йөрәккә сигнал биргән. Сезнең төп чирегез — курку. Йөрәк дарулары белән мавыкмагыз. Дару бер яктан дәваласа, икенче яктан бәгырьне кимерә дә! Харап итә. Сезгә куркуны җиңәргә кирәк. Тора-бара «йөрәгем авырта» дигәнне онытырсыз».— «Ничек җиңәргә?!» — диде Нәҗип, аска караган килеш. «Үзегез белән үзегезгә көрәшкә чыгарга туры килер! Сезнең бик яраткан бер-бер шөгылегез бармы?» — «Нинди шөгыль?» — «Бөтен дөньяны онытып мавыгырлык дәвамлы шөгыль. Балыкка йөрисезме?» — «Юк». — «Ә гөмбәгә? Маркалар да җыймыйсыз инде, шырпы каплары да... Чаңгы да шумыйсыз? Шахмат, бильярдны да өнәмисез? Әһә, чаңгыга баскалыйсыз икән, өзә-тотә, шулаймы? Сезгә утыз өч... Гомерегезне ни белән үткәрәсез соң сез, иптәш Нургалиев?» Фаина Марковна әрнү катыш шелтә белән Нәҗипнең чарасыз моңаеп калган күзләренә текәлде. «Эшләдем, укыдым, ике ел армиядә бушка селкенеп йөрдем. Өйләндем, бала бактым...» — «Болары һәр кеше өчен табигый күренешләр. Болардан тыш берәүне бүтәннән аерып куя алырлык сыйфатлар да булырга тиеш ләбаса! Адәм баласы кирпеч калыбыннан төшкән стандарт түгел! Менә сез импульсивный, хисле, тәэссоратларга сизгер җан. Сезгә кешелекнең гади, гадәти кагыйдәләре генә җитми, сезгә нык мавыгырга кирәк! Нык! Шул чакта сез иңбашыгызга кунган кара фәрештәне онытып тора алырсыз. Әнә сез күреп калган бичара бәндә мавыгу таба алмады, теләмәде, үз тәгәрмәче астында үзе тапталды. Чирдән котылу, кабатлап кисәтәм, үз кулыгызда».— «Балыкка йөрепме?» — диде ышанмыйчарак Нәҗип. «Анысы менә сезнең эш. Үз тарафымнан мин сезгә тынычландыру дарулары бирермен, хәзер андаксин, триоксазин дигән көчле дарулар бар. Дөрес, аларны юнәтү кыен, кирәк булгач, табарсыз. Сез хәзер һәрнәрсәгә ышанып, җиң сызганып, күкрәкне давылларга ачып көрәшергә тиеш. «Җиңәм! Җиңеп чыгам!» — дип, иртәдән кичкә кадәр кабатлагыз. Кирәк булса, гипноз сеанслары алырсыз. Веналарга магнезия уколлары кадарбыз. Сез авыл баласы бит? Мондагы атмосферадан котылып торыгыз, кайтыгыз авылга, юанычларны шунда табыгыз. Тауга менегез. Менгән саен, һәр киртләчтә туктап хәл алыгыз, аска карагыз. Күз алдыгыз киңәйсен, офыклар ерагайсын. Азаккы сүзем шул: үзегезнең рухи көчегезгә ышаныгыз! Сез сау-сәламәт. Сезгә табиб кирәкми, дәвалаучы — хәзер сез үзегез!»

Рецептка үрелгәндә аның кулы Фаина Марковнаның кулына тиеп китте, докторның кулы пешерерлек кайнар һәм коп-коры иде.

Кабинеттан чыкканда ишек тирәсенә байтак кеше җыйналып өлгергән иде. Алар Нәҗипне каш җимереп, йодрык йомарлап, дошман итеп каршыладылар, сүгеп озаттылар. Сәгатенә карагач, ул аптырап китте: врач бүлмәсендә ул төп-төгәл сәгать тә биш минут утырган икән!

Кайтса, бөтен өй пыр тузган, әйбер-каралар, мендәр-ястыклар әвәләнеп ишек катына күчкән, балаларның уенчыгы тартмасы белән ишегалдына чыгып ауган, түбәдән тамган тамчы аларны җебеткән. «Ни хәл бу?» — дип, тартма тирәсендә авыр койрыгын сөйрәп Звонок йөри. «Ни булды? Ни бар? Әллә ут-мазар чыктымы?» — дип кычкырды ул, карлыккан тавыш белән. Наилә җылый-җылый шешенгән, сүзен рәтләп әйтә алмый, ул да булмады — аралыктан Таңсылу килеп чыкты. Изүе чишелгән, бәлшерәйгән имиләре ямьсез тирбәлә, күзеннән ут, колагыннан төтен, нык кысканнан тешләре уалып, авызыннан зәһәр ташый: «Бер көн тормыйсыз, хәерчеләр, бер көн!»

Нәҗипнең кайтканын тәрәзәдән шәйләп калган карт Таңсылуның утына керосин сибәргә кереп җитте.

Нәҗипнең боек күңеле тагын да шәлперәйде. Ул, Таңсылу авызыннан чәчелгән зәһәр хатынын ялмап йотмасын өчен, ике арага кереп басты, Тимерханга юаш кына эндәште: «Озак тормабыз,

Тимерхан абзый. Сөйләшенгәнчә кышлыкка утынны без алган. Беләсез, фатир чиратында торабыз. Чирләп егылмасам, әллә кайчан бирәләр иде. Кумагыз инде!»

Саклап кара моннан болай җан тынычлыгын! Аралыктан моңарчы күренми торган Җәмилә карчык лыпырдап килеп чыкты: «Һай, шөкәтсез ялганчы! Биргәннәр ди сумашишныйга фатир! Вәйт алдакчылар!» Нәҗип белән Наилә, йөз суларын түгеп, ике сүзләренең берендә «Ходай, Тәңре» исемнәрен әйтеп: «Әзгә генә түзегез, күчәр урын табыйксана!» — дип ялваргач кына давыл тынгандай булды, зәһәр җил басылды, хуҗалар өчесе тиң күз алдыннан юк булдылар.

Наилә эшкә китәргә җыенып йөргәндә, Таңсылу кайтып кереп, аны чыгармаган, әйбер-караларны тотып тондырган, мендәр тышларын ерткан, дөге ярмасын ишегалдына чәчкән.

«Ни булган бу шашкан хатынга? Ник котырына алай?» — дип сорады Нәҗип, хатынының җавабыннан яхшылык көтмичә. Наилә кыенсынып кына ачыклады: «Әйтмәм дигән идем, түзәрем калмады. Син югында шыпан-шыпан гына Таңсылу янына ир-ат кергәли иде. Безнең бүлмә аша үтеп йөрделәр. Хәзер синнән читенсенә. Юлына киртә булдың». Шулайрак дип шикләнеп йөргән иде Нәҗип, рас икән. Мондый шашынган чакта хатын-кызны игә китерермен димә, күзенә ак-кара күренми аның, итәк кыска, табан астына җәһәннәм уты кабынган...

Йа Хода! Юка такта белән бүленгән теге якта Таңсылу ниләр кыланып ятмаган! Ә бу якта... кысрыкта, аның газиз хатыны, балаларының әнкәсе... Исәеп килгән ике улы! Ниләр күрсәтми бу фатирсызлык!

Нәҗип, хатынының башын тезенә куеп, аны иркәләргә, юатырга тырышты, электән әйтә килгән, еш кабатланган җылы, кадерле сүзләрен тәкрарлады. Хатын тынычланмады, чөнки ул иренең үзе әйткән сүзләргә үзе дә ышанмавын, киләчәкне ал буяуларга юри-марый гына бизәп маташтырганын аңлый иде. Иң аянычлысы, иң авыры шул иде: Наилә, алдагы көненең кызыксыз, өметсез икәнен уйлаганда, үткән гомеренең дә шыксыз, ямьсез булуын абайлады. Бәла килсә, озакка килә, сумалага баскан саескан хәлендә каласың: башыңны алсаң, койрыгың ябыша, койрыгыңны куптарсаң, башың ябыша. Кичкә кадәр җылады Наилә, ник җылаганын иренә белдермәде, үз язмышын каһәрләп, Нәҗипне очраткан минутларын каргап җылаганын ничек аңа белдерсен ул!

«Әллә этиләрдән акча сорап торабызмы?» — диде ул, әйберләрен җыештырып, бүлмәне әз-мәз тәртипкә китереп төс керткәч. Нәҗип авып китә язды: «Әтиләрдәнме? Үлсәм үләм, алардан әҗәткә аласым юк. Туганнарга да бармыйм! Беркайчан да!» — «Ә ничек яшәрбез соң?» — дип инәлде Наилә. Нәҗип хатынына җавап тапмады, чөнки алда ничегрәк яшәсен ул үзе дә белми иде.

**12**

Ире чирле хатынның хәле мөшкел, мәшәкатьләре ике мәртәбә арта, көн туды исә сунарчы эт кебек арлы-бирле чаба ул. «Андаксин кирәкме? Триоксазин? Әллә кайчан дефицит ич алар!» Аптека туташлары күзгә карап алдыйлар, буш кул белән килгән клиентлардан алар астыртын гына көләләр. «Дару кирәк икән берәүләргә, ә табалары коры! Майланмаган!» Белә Наилә хәзер нәзек билле, бүртмәч иренле, йомры күкрәкле аптека кызлары шоколадны, кыйммәтле ислемайларны яраталар, кул кулны юганда, затлы бүләкләрне арага кыстырсаң, Кытай женьшенен дә табачаклар, әмма даруга дигән акчаны көч-хәл белән, начила җыештырган Наиләнең кәнфит-мәнфитләрен алырлык җае юк. Йөри байгыш булып, гомерен кыскартып, ялынып, ямьсезләнеп. Йөрмәс иде — Нәҗибенә кирәк. Дару йотмыйча йокларга ятса, мендәрен изеп, эчен чыгарып бетерә.

Бүген ул дарусыз яткан иде, кичтән бирле борсалана. Наилә башын калкыта-калкыта аны күзәтә: Ходаем, тагын врач чакырырга туры килер микәнни?!

Нәҗип Йосыф улы Нургалиев төш күрә.

Әлерәк кенә аның өстенә ургып-ургып кара ташкын ага иде, аннан котылдым дигәндә, тауга кырын яткан урман ишелә башлады. Дәү-дәү иләмсез имәннәр, ботак-канатларын фыр-фыр итеп, аның өстенә авалар. Имән кәүсәсе астында калып каен, усаклар чыра кебек сына.

Бер имән иң оч ботакларын аның баш тирәсенә сузып ава, яңакларын, шәрә кулбашларын чатлы ботаклар сыдырып үтә. Яралардан каны челтерәп ага. Ул ашыгып канны кулъяулыгы белән сөртә. Кулъяулыгын күзенә китереп караса, шакката: каны кызыл түгел, сөт сыман ап-ак икән аның! «Нигә агарды бу кан?» — дип куркынып сорый да үзе үк җавабын да таба: «Эчкән дарулар каныңны агартып бетерде синең, шул дарулар сине үтерәчәк тә!»

Имән ботаклары тозагын аралап чыгам дигәндә генә баягы ташкын аны ялмап алды да вак йомычка урынына бутап йөртә башлады. И ярсыды Нәҗип, и гайрәтләнде. Һәм күрсәнә: аяк очлары җиргә тиде. Үсәргә тотынды Нәҗип, үсә, үсә, ботаклар җибәрә, гәүдәсе ныгыганнан-ныгый. Башы болытларга тиде берзаман: «Имән мин, имән!» — дип кычкырмак була — тавышы чыкмый. Түшен ышкып карый, ирennәрен каерып ача, өне юк бичараның. Янына Наиләсе килеп баскан, имеш. Ялварып аңа дәшә: «Тавышым булмагач, минем имән икәнемне кем белер соң?!»

Каяндыр тау түбәсеннән ыргылып төшкән җил Нәҗип-имәнне аударды. Нәҗип кечерәйде-кечерәйде дә йомычкага әверелде. Юныш балтасы белән чабып алынган өр-яңа йомычка! Тырпылдый торгач, ул тагын кеше шәкеленә керде, колач салып ташкынга каршы йөзә башлады. Баягы сыман аягы катыга тиде, котылам дигәндә гәүдәсе, кул-аяклары балыкчы җылымына уралды. Әй йолкына уңга-сулга, ычкына гына алмый! Ә су, дөньяга хуҗа булып өлгергән туфан, ургый-ургый котырына. «Син түгел, мин ул имән!» — дигән тавыш колагына керә Нәҗипнең... Кем ул имән? Әллә туфан имәнгә әйләнгәнме? Көнчелектән шул батырамы Нәҗипне? Җылым булып уралып аны төпкә, үлемгә тартамы? «Туфан синдәй имәнне дә екса, бүтәннәрне «эһ» дигәнче таптап узачак!» — дип, Наилә җылый. Ниһаять, Нәҗип юан агач кәүсәсен кочаклап калкына, кулына эләккән үткер пычак белән җылым җепләрен турый, кисә. «Яра! — дип кычкыра Наиләсе. — Нәҗип, яраң бар!» — «Үзем дә күрәм! — ди куанып Нәҗип. — Каным кызыл икән, яшим әле мин, яшим. Мин яшәргә тиеш! Дөньяны туфан басып китә алмасын!»

Шулай дип бер кычкырды да уянып китте.

Шадра түшәм аны сытарга теләгәндәй тагын да аскарак иңгән, су төбе сыман тонык яктылык белән тулган бүлмә суынган, бетеп барган ай урагының нурлары карындык-күгелҗем пыялалар аша чак үтеп, кыеш-мыеш идән такталарына ятып торалмыйча тирбәләләр. Иренең уянганын сизсә дә, Наилә йоклаган булып ята. Дымлы төннәрдә ютәл бумасы белән интеккән Җәмилә карчык, комганын тотып, корык-корык ютәлләп, тәрәзәгә тия язып үтеп китә. Таңсылу ягында шешә белән тустаган чәкешеп чылтырый. Нәни Рөстәм төшендә яшел койрыклы колын күреп шаркылдый. Бүрәнәләрнең черек-кара мүген коеп, өйгә тияр-тимәс үткән вагоннар маңгайга-маңгай бәрелешәләр...

Аны шәһәрнең атаклы гипноз остасы Даирский дәвалап карады, врач тырышса да, Нәҗип аңа баш бирмәде, тынычланмады, сеансларны Фаина Марковна киңәше белән туктаттылар. Уколларга йөреп карады, файдасын күрмәде, гел үлем, әҗәл турында уйлады, көннән-көн ябыкты, сарыга сабышты. Квартир хуҗалары белән ара соң чиккә, кайнау ноктасына җитте. «Ашыгызга сөләймә салам! Таегыз моннан!» — диде беркөн Таңсылу. Нәҗип шәһәрнең искерәк йортлар тирәсеннән, фәкыйрь-фокра арасыннан тукталыр куыш эзләп чыгып китте. Йөргән аякка йөрем иярә, сораша-белешә торгач, ул шәһәр үзәгендәге Миславский урамына юлыкты. Фатирчылар кертергә җыенган, биш яшьлек тиктормас оныгын очлы тез башларына кыстырган сукыр-бакыр рус карчыгы Ираида Никифоровна Нәҗиптән кем булуы, кайда эшләве, гаиләсе хакында кайта-кайта, вәзенләп-бөртекләп сорады да сансызланырга тотынган малайның артына чап иттереп берне орды, яшь аралаш үз тормышын сөтәргә кереште. Улы белән килене әнә каршыдагы бүлмәдә яшәп ятканнар икән. Улы беркайда да эшләмәгән, көндезге уникегә кадәр йоклаган, кич чыгып югалган, ярты төн авышканда гына кайтып кергән. Хатынын да бер җирдә эшләтмәгән. Нәрсә ашап, каян акча юнәтеп яшәгәннәрдер. Еллар үткән, бала туган. «Көзгә алты тула ташбашка!» (Карчык малайның артына тагын берне чәпеде.) Башта этисен, ярты айдан әнкәсен дә кулга алганнар да алтышар елга төрмәгә илтеп тыкканнар. Менә кайчаннан бирле шул тыңлаусыз бала белән җәфа чигә. «Алтысы тулмаган, тәмәке суыра башлады!» Пенсиясе әз, уллары бүлмәсенә торымнан-торымга иптәшләре кереп кунгалый иде, акмаса да тама иде. Хәзер иптәшләре калмады, һәммәсен төрмәгә тутырып бетерделәр...

«Аерым ишек, аерым бүлмә» дигәннәрен каерып ачып эчкә кергәч, Нәҗип өнсез калды: гомергә кояш нуры төшмәгән, бер тәрәзәле, рамнарын, пыялаларын үрмәкүч пәрәвезләре томалаган ярым подвалның түшәм акшары дымланып, кабырчыкланып купкан, диварлары — дөнья картасы сыман, кыйтгалар бер-берсенә тартылып йөзәләр, идән такталары почмакта череп, бала аягы сыярлык тишекләр ясалган. Ишек ачылуга, эре-эре ике күсе шул тишекләргә кереп чумдылар, мыекларын селкетеп, бөртек күзләре белән кешегә карап калдылар, курыкмадылар. Нишләргә?

Нишләргә? Ни кылырга?!

Совет эшсезе, дипломлы, өметле яшь физик Нәҗип Йосыф улы Нургалиев, шанлы-шәүкәтле Казан каласындагы шушы фатирны күреп, бер мәлгә мие түнеп калды. Нишләргә соң?! Ни кылырга?! Өйдә ике бала, хатын, хуҗалар каргап, янап куа. Атна-ун көн Нәҗипнең йөреп туктаганы юк, аяк табаннары ашалып бетте...

Ираида Никифоровна ярты еллык акчаны алдан сорады. «Шушы ачарбак белән бурычка баттым, прәннек ашый да кәнфит суыра, ничә айга квартир хакы түләмәгән, керәсез икән, ярты еллыкны алдан биреп керәсез». Озак тарткалашкач, җылашкач, кочаклашкач, ярты еллыкны өч айга калдырды Нәҗип. Бәлтерәп беткән калтыравык Ираида Никифоровна акча дигәндә тернәкләнеп китте һәм аяк терәп карулашты. «Бүген үк! — диде ул, Нәҗип Нургалиевнең балтасы суга төшкәнен, көймәсе комга терәлгәнен сизеп. — Өч айлыкны бүген үк китерәсең!»

Март ае гына булса да, кысан тартма — ишегалды җебеп аккан, борыныңны кая борсаң да авыр ис килеп бәрелә, каршы йортның подвалында төрле киек-җанварлар тавышына охшатып кемнәрдер «камыш шаулаталар». Истән качып, танавын тотып ашыгып барган Нәҗипне кар йомарламы куып җитте. Ул ярсуыннан буылып борылып караса, орчык кадәр ике юеш танау авызларын ерып торалар. Ишегалды уртасын кыеш-мыеш утын сарайлары, бәдрәфләр бизәгән иде. Бара торгач сизде: йомарлам

кар гына булмаган икән, исе чыга башлады. Ул бишмәтен салып, пичәтләнгән урынны чистарак кар табып кат-кат ышкыды. Ис бетмәде. Ул, трамвайга утырырга кыенсынып, Яңа бистәгә җәяү элдерде. Кайткач карасалар, пычрак-сасы лай эреп итәккә кадәр төшкән. Наиләнең коты очты: «Балаларны ишегалдына ничек чыгарырбыз!» — «Өйдәрәк торырлар, граф балалары түгел,— диде ярсыган Нәҗип.— Күчми кая барасың?!»

Нәҗибенең ачуы соңгы чиккә җиткәнен күрсә дә, Наилә бер сүз әйтеп карарга булды. «Нәҗип, акыллым, мондый чакта ата-анадан ярдәм сорауның һич ояты юк. Сорап торыйк әтиләрдән! Хәлләнгәч тиенен калдырмабыз, түләрбез!» Нәҗипне берьюлы ун бал корты, алты шөпшә, өч-дүрт бусан* чактымыни, яңак сөякләре калкып шытырдады, борын тишекләре киерелде, күзләреннән яшькелт очкын түгелде. Ул, җүләр кеше сыман, өзек-өзек җөмләләрне ватып озак кына кычкырынды. «Ачка үләрмен, хәер сорашырмын, әтиләрдән акча сорау түгел, алар ягына борылып та карамам! Безнең хәлне туганнар да, якыннар да белергә тиеш түгел. Барыбер үзем ерып чыгам, бер башым!»

Нәҗип ничек ерып чыгасын хатынына аңлатып тормады, Наиләсе сорамады, киенде дә шыпырт кына чыгып югалды. Алтын балдагын, ерак әбисеннән калып, әнкәсе аша аңа насыйп булган борынгы болгар беләзеген ювелирторгка тапшырып, акчаларын учына йомарлап кайтып керде һәм иренә тоттырды. Турсайган, бүселгән ир дә, кулына акча кергәч, әз-мәз җанлана. Нәҗип Наиләнең муеныннан үпте. «Бар, түләп кайт,— диде хатын.— Мин мондагыларга кертеп бирәм».— «Җитәме соң?» — «Җитүен җитә дә, шунда бетә дә!» — диде Наилә, елмаерга тырышып.

Нәҗип, дәшми-тынмый гына, ирлек горурлыгын учына йомарлап, хатынына туры карарга кыймыйча чыгып китте дә кичкырын гына кайтып керде. Наилә Тимерханнарның күңелен күргәндер, ул як тынган иде. Таңсылу кунарга кайтмады, поездларның берсе аерата дөбердәп узганда, теге якта өстәл селкенеп, идәнгә шешә төшеп тәгәрәгәне ишетелеп калды.

Иртәгә күченәбез дигәндә, Нәҗип Наиләсен ияртеп яңа куышларын карарга китте. Әз-мәз җыештырып, тишек-тошыкларга таш-мазар тутырып, идәнне юып чыгарырга иде исәпләре. Чалт аяз көн, һава җиңел, җайлы сүзләр сөйләшкәләп барып җиткәннәрен дә сизмәделәр. Ишегалды кары эреп беткән диярлек, исләр кимегән иде. Барып керсәләр, ни күрсеннәр: юылмаган шакшы идәнгә кәгазь кыйпылчыклары җәеп, дүрт таза-таза ир шау-гөр килеп кәрт сугып утыралар. Яннарында ике шешә кызыл, бөршәйгән кыяр кисәкләре, бушаган аракы шешәләре, кабыгы сытылган күкәйләр, кабыклы бәрәңгеләр тәгәрәп яталар. Авызларында тәмәке. Тонык кына булып ятим лампочка яна. Бүлмә идәннән түшәмгә кадәр аракы сасысы, зәһәр төтен һәм агулы сүзләр белән тулган. Ишек тавышына дүртесе дә борылып карадылар.

— Сез кемнәр? — дип сорады Нәҗип, эчкә кереп.

— Ә сиңа кем кирәк?

— Без иртәгә бу бүлмәгә күчәргә тиеш идек. Җыелганнар ярым көлемсерәп бер-берсенә караштылар, түрдә утырган, шәрә тәне зәңгәр сурәтләр белән бизәлгән, киң күкрәкле, кыска куллы бәндә черт итеп төпчеген почмакка очыртты. Керүчеләрнең нинди эш юллап йөрүләрен аңлагач, алар тыелгысыз көләргә тотындылар. Шәрә тән торып басты һәм бер генә җикеренде:

— А ну, канай отсюда! — диде ул, явыз янап. — Ну! Рви когти, тебе говорят! Фраер несчастный! (Караклар жаргоны: «Ычкын моннан! Үкчәңне күтәр!»)

Нәҗип белән Наилә күздән юк булдылар. Идән юарга алган чиләкне кире кереп алырга да базмадылар. Әзрәк сулышлары басылгач, биргән акчаларын алырга дип, Ираида Никифоровна янына керделәр. Керсәләр, ул теге ут борчасы белән ызгышып ята иде. «Ходам җанымны әллә кайчан алыр иде, шушы сабый хакына гына яшәтә»,— диде ул, керүчеләрне каршылап. Теге малай, почмактан күзләрен уйнатып, бертоташтан такмаклады: «Мин сине тыңламыйм! Мин синнән курыкмыйм! Син мине кыйный алмыйсың».— «Кыйнамам менә!» — диде карчык, нарат күкәе хәтле йодрыгын укмаштырып. «Әти кайтты, әти! — дип үчекләште малай.— Хәзер мин синнән акча сорамыйм, шешә тапшырам да морожный алам. Берне түгел, икене, юк, унны алам! Бөтенесен умырып бетерәм, сиңа бирмим, бирмим!»

«Акча? — диде күккә багып Ираида Никифоровна.— Бар булганын Толям каерып алды, улымны әйтәм, квартир хакын түләргә дә өлгермәдем. Әнә акчаңны эчеп утыралар. Ходаем, кемгә барып егылыйм? Ник алмыйсың минем җанымны?»

Нәҗип Наиләне Яңа бистәгә кайтарып җибәрде. «Җитәр,— диде,— дөньяның бөтен шакшысын син дә күрмә инде!» Наилә кайтып китте, карчык тәресез почмакка баш орып, укынып калды. «Анатолий Федорович? Так, так... Кайтканмы? Кайчан гына утырткан идек бәдбәхетне. Социалистик гуманизм дип безнең мине чертәләр. Каракны тотып утыртып өлгермибез, кайтып керә. Акча? Расписка алган идегезме?» — «Мондый хәл булыр дип кем уйлаган».— «Акчагызны суга салгансыз».— «Милиция ярдәм итә алмыймы?» — «Федоров белән бәйләнешкәнче эштән китәм мин!»

«Хатыныңны коча казый, кая барырсың, абзый?» — дигәннәр. Карактан милиция дә шүрләп торгач, кемгә барып егыласың?! Ул, авыр һәм калын ишекне шапылдатып ябып чыккач, ис тигән кешедәй чайкалып торды, күз аллары караңгыланды. Икмәк кибетенә барып кергәнен искәрмәде,

шунда ишек катында хәер сорап кулын сузып торган Ираида Никифоровнаны күргәч кенә, Наиләсенең: «Кайтышлый ипи кереп алырга онытма»,— диюе исенә төште. Бөтенләй сукырга сабышып, күзләрен йомган карчыкны ул чамасыз кызганды, бая убылып чыккан ачуы сүрелде, чалбар кесәсеннән егерме тиен көмеш эзләп алды һәм шушы иң соңгы акчасын мәрхәмәтсез язмыш хәер сорашырга куган ананың бөршәеп беткән учына салды.

Кесәң тап-такыр булса да, өйгә кайтмый әмәлең юк, кайтып керсә... Өйдә кыямәт! Таңсылу белән Наилә, якага-яка килеп, чәчләрен йолкышып беткәннәр. Наилә стенага аркасын терәп, сулкылдап җылап тора, күз каймалары күгәргән, күлмәгенең җиң төбе умырылып чыккан. Теге яктан Таңсылуның яшелле-мөшелле тавышы ишетелә, малайлар икесе тиң караватастына кереп посканнар. Чыгып китәргә әзерләнгән бүктәрләр кайсы кая исереп тәгәрәгәннәр.

Наилә, күз яшьләрен тыеп та тормыйча, ни булганын сөйләп бирде. «Ул минем кулымны тырнады. Әле ярый ирек бирмәдем, чырайга үрелә, дивана. Йөри торган нәмәрсәсе белән пыр тузышып кайткан. Анысы өйләнә икән. Ичмасам, без чыгып киткәнче дә түзмәгән. Шуны бездән күрә. Син бер-бер гайбәт җиткергәнсең аңа, ди. «Каһәр суккан психлар, дураклар, ач бетләр!» — дип, урамны сасытты. Әтиләре кызны тыярга чыккан иде, аларны типкәләп кертте. Балалар җылый, әллә җүләрләнгән микән ул?!»

## 13

Ул икенче көнне таңнан базарга китте. Йомышы табылыр иде, мәгәр кесәсе тап-такыр, «алайса, ник йөрисең?» дисәләр, анык кына җавап та бирә алмас иде ул. Йокысыннан торды, ашык-пошык юынды, Наиләсенең чәй кайнатканын көтмәде, чыгып китте. Җәяү барды, җәяүләде, җәяү барасы килде. Җәяүле кеше үз ихтыярында, теләсә, туктап уйлана, теләсә, бара, теләгәндә кибет тәрәзәләрен тамаша итә, күңеленә ни рәхәт, шуны уйлый, уйны уйга ялгый, кеше япа-ялгыз калганда гына үзенең чын табигатенә кайта ала. Икәү булганда ул — берәүгә, өчәү булганда икегә үк ярашырга тиеш. Безнең заманда кеше бик сирәк кенә ялгыз кала ала, күп очракларда айлар-еллар дәвамында ул бүтәннәр ихтыярында, хөкем ияләре — азчылык боерганча, өстеннәрнең күңелен табып яшәргә мәҗбүр. Нәҗипнең уйлары бүген кап-караңгы һәм очсыз-кырыйсыз иде. Шул ямьсез уйларын кая ташлап калдырырга белмичә, шәһәр белән бистә арасын ул шактый озак барды бугай. Кичә төштән соңгы җете кояш юл читенә кыш дәвамында өелгән пычрак кар-бозларын нык ук ялаган икән, су җыелган, төнлә су чираган, юка җәелгән урыннарда ул кара челтәрләр белән каймаланып каткан, үкчәләре ашалган ботинка табаннары астында алар четер-четер уалалар. Чәрдәкләнгән тавыш ишеткән саен, аның кара пыялаларны күбрәк изәсе, уалтасы, вата-вата тантана итәсе килә. Кеше кайчагында үз авырлыгы булуга сөенә, югыйсә кайгы-хәсрәт җилләре аны бу дөньядан очыртып алып китәрләр иде. Җирнең тарту көче курку хисен киметә, кешене кеше итеп яшәтә.

Юк, азык-төлек рәтенә кереп тормады Нәҗип, яшелчә-җимеш тирәсен башын түбән иеп, урап үтте. Ул бер кырыйда кырмыска оясы кебек кайнаган иске-москы сатучылар арасына барып керде. Монда борын-борыннан килә торган гадәтләрен саклаган талчукчылар очрый, буяу пумаласы, күзлек кысасы, самовар трубасы, комган, ләгән ише нәрсәләр, башка йорт кирәк-яраклары тезелеп тора. Сөннәтле сакаллы, түгәрәк мех бүрек киеп җибәргән кәкре аяклы елгыр татар агайларының соңгы вәкилләрен, актыккы буынын монда очратасың. Тире-яры почкакларыннан качып-посып теккән товарларын корсакларына урап, ыштан төпләренә тутырып, ялгышып кына базар арасына килеп кергән гамьсез кыяфәт белән йөрүче базар аристократлары да шушында чуала. Шулар арасына ерып керде Нәҗип һәм эзләгән кешесен тиз арада күреп тә алды. Әйе, шул кешене, Наиләнең туганнан туышканын, Фәтхулла агайны эзләп килгән икән ул. Элегрәк йомыш-кара төшеп колхоз базарына кагылган мәлләрдә Наилә белән Нәҗип Фәтхулла абзыйлары күзгә чалынганда оялып, шыпан-шыпан читкә таялар иде. Базар әһелләренә җирәнеп, сатып-алып йөрүчеләргә кимсетеп карарга гадәтләнгән ыштансыз аксөяк Нәҗип Фәтхулла агасының караңгы якларыннан читкәрәк тартылырга тырыша иде. Наиләсеннән ишетеп ул байтак нәрсәләрне белә иде, ә Наиләгә яңалыкларны күп сөйләргә яратучы Миңсылу апасы ияртеп җибәрә торган иде.

Эшендә мөдир булса да, Фәтхулла агай гомере буе базарны яратты. Казан базарлары тирәсендә аны белмәгән, олыламаган кеше юк. Һәркем, әле базар юлында шомарып өлгермәгән сатучылар гына түгел, алып-сатып, әвеш-тәвеш китереп сакалларына кырау төшкән чаллар да, урта кул эшем ияләре, кесә караклары, маклерлар, урлаганны җыештырып, сәгате суккач кына малны көнгә чыгаручы атаклы барыгалар да бик ерактан иелеп-бөгелеп аңа сәлам бирәләр. Фәтхулла — базарның кендеге. Ул үзе вак-төяк белән азапланмый, сатмый да, алмый да, әмма сәүдә кызган көннәрдә ул монда. Ярты сәгатькә булса да кагылып чыга ул, шул кыска арада да тау хәтле эш майтарып өлгерә. Ул — хуҗа, базарның абруе, даны-шөһрәте. Ерак Көнчыгыш тайгасыннан урланып монда килгән кыйммәтле кеш тиреләре дә, сусар, җофар мехлары, үз төбәгебездәге вак-төяк җәнлек тиреләре дә иң әүвәл аның күзе аша үтә. Илнең дүрт ягыннан Казан базарына җыйналган мехларның төп хуҗасы ул. Адашып килеп кергән мал

хуҗаларына мехны куеннан чыгаруга ук: «Ә-ә, Фәтхуллага күрсәт башта!» — дип кисәтәләр. Чәшке, сусар, су күсесе, төлке тиреләрен ул бер күрүдә таный, Фәтхулла әйтә икән, ышан, ул «юк!» ди икән, буйсын. Базарның катгый кагыйдәсе шул. Фәтхулладан хәер-фатиха алсаң — уңасың, ялгышмыйсың, аннан узып нидер кыласың икән, яңадан бу якларда күренермен димә, беттең! Моннан ары аңа буйсынган базар әһелләре сиңа худ бирмәячәк. Ул атаклы караклар, законлагы бурлар белән таныш, чит яклардан килгән каракларга ул барыгаларның адресын бирә, кайсы малны кайсы тирәдә сатарга кирәклеген ялгышусыз әйтә ала. Ул үтә ярдәмчел, әвене янганнарга зур процент белән акча биреп тора, рибачы булса да, әҗәтен түләүне ашыктырмый, процентын гына арттыра. Милиция хезмәткәрләреннән аны белмәүче юк, гаепләрлек сәбәп табылмаганга аңа бәйләнмиләр, киресенчә, милиционерлар еш кына аңа үзләре мөрәҗәгать итә, юлына аркылы төшәргә теләгәннәрне ул оста һәм беленмәслек итеп органнар кулына тапшыра да ала.

Ял итәргә, базар хәлен күреп юанырга чыккандай, бераз иелә төшеп, халык кайнаган мәйданчыкта горур басып торган Фәтхулланы Нәҗип тиз күрде, бөркет карашлы абзасы да аны ерактан ук шәйләгән икән, икесе дә бүрекләрен калкытып алдылар. Ул, үзенә ике яктан бөгелгән бүрекле башларга, дага сакалларга, елмаюлы йөзләргә игътибар итмичә, туп-туры Нәҗипкә каршы китте, халык ашыгып юл ярып, түбәнчелек белән аны озатып калды.

«Нихәл, аспирант,— диде ул, Нәҗипнең уң иңенә таза гына кундырып. — Сеңел сихәтме? Бала-чагалар сау йөриме?» Фәтхулланың беренче сүздән төрттереп алуы егетне каушатты, ул «син сорама, мин әйтмим» дигән кебегрәк җавап белән котылып калды. «Нәрсә? Күпме кирәк? Акча сорарга эзли килгәнсеңдер, шәт?» Фәтхулла Нәҗипнең аркасына кулын салып, аны кешесезрәк мәйданга адып чыкты. «Акча соңыннан...— диде Нәҗип, ашереп тә, назландырып торырга да кирәксенмичә.— Син миңа яшәр урын тап, Фәтхулла агай». Фәтхулла түш кесәсеннән көмеш савыт чыгарды, ачып, чеметеп канәфер алды, уртына кыстырды. «Сез ничәү әле? Дүртәүме?» — «Дүртәү».— «Эзләп карадыгызмы соң?» — «Әй, эзләмәгән кая! Балалар белән урнашу кыен, Фәтхулла абзый». — «Бер фатир барын... Бар!» — «Кайда ул?» Нәҗип үзе дә сизмәстән абзасының ике кулын эләктереп алды. Фәтхулла тормышның рәтен, кадерен белеп яшәүче эш кешесе иде, кайчандыр ул Нәҗип белән Наиләгә нык өметләнеп, баласы юк кеше буларак, үзенә якынайтырга да ниятләгән иде. Нәҗипнең олысымакланып читләшүе генә аны сагайтты. Хәзер үзеннән бер башка биек, утыз өч яшьлек ирнең, адаштырылган эт кебек, күзләренә ялварып карап торуын күргәч, ачуы кабарды, Нәҗипкә берне китереп орасы килде. Исен җыеп, күз кабаклары белән ачуын каплап торды, йомшады. «Ленин районында. Тимерьюлчыларның бер йорт кәмәше бар анда. Аумаган булса! — Фәтхулла көлмәс җиреннән көлеп куйды.— Шунда берәр чолан булмый калмас. Бүлмә үк димим, чөнки бәдрәф уртак, кухня кисәге өч хуҗага бер. Урыны да җайлы түгел, уңда төтен, сулда тимер юл, өстә шау-шу, аста юеш!» Тапкыр сүз әйттем дип, Фәтхулла тагын көлеп алды. «Абзыкай! — диде Нәҗип, хисләренә буылып.— Төрмә камерасыннан җылы урын бирсәләр, шунда да кереп торыр идем!» Фәтхулла куен кесәсеннән карандаш һәм дәфтәр чыгарды, бер битен ертып, ике-өч сүз тырнады. «Мә, адресы шушы. Белеп кер: адресыңны таныш-белешкә бирмисең, кайда яшәвеңне эт тә белергә тиеш түгел. Матвей Ионыч дигән кешене эзләп тап, ни эшләргә кирәклеген ул сиңа аңлатыр. Аена түләвең сиксән тәңкә булыр». Нәҗипнең тыны кысылды: «Сиксән?» — «Кеше башына егерме сум,— диде исе китмичә Фәтхулла.— Анда закон каты. Мин сиңа бераз акча биреп тора алам».— «Проценты ничегрәк соң?» — дип сорады Нәҗип, курка-курка гына. «Синнән алып тормам. Хәер, баегач үзең чамаларсың тагын».

Аның Фәтхулланы кысып-кысып кочаклыйсы, үбәсе, алдына тезләнеп: «Фәрештә!» — дип атыйсы килде. Фәтхулланың да күңеле йомшады. «Нәҗип карендәшем,— диде ул,— тонык кыяфәтеңне күрүгә, хәлең мөшкеллеген аңладым. Кем синең юлыңа төшә? Нинди адәм? Кирәк икән, юлыңнан алып ыргытабыз аны. Кушасың икән, дөньядан юк итәбез».— «Синең шундый көчең бармы?» — «Һи-и,— дип көлде Фәтхулла,— мең тәңкә алалар җан кыйган өчен. Мең тәңкә дә бер ярты».— «Юк,— диде Нәҗип,— кирәкми, Фәтхулла абзый. Дөнья гаепле! Дөнья хикмәтләрен аңларга соңга калдым... Аңлармынмы берзаман, белмим. Алга чыга алмадым, узып киттеләр, узып!»

Фәтхулла затлы кайры тунының якасын чиште һәм ак кәгазьгә урап, таза җеп белән аркылы-торкылы бәйләнгән, бүген генә законлы бурлар китереп биргән шактый калын төргәкне тартып чыгарды. «Мә, тот! Хәлең бетеп китсә, туры үземә кил».

Фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килде, Фәтхулланың төшемне умырган чагы иде. Төргәк Нәҗипнең куенын бүлтәйтеп, күңелен җирсетеп кайтты. Наилә белән икәүләп кат-кат санасалар, абзалары дөп-дөрес мең сумны бөдәгән икән! Наилә кырысланды: «Бурыч — муенга салынган элмәк дия идең, Нәҗип. Батабыз ич!» — диде. «Баш исән булсын!» — диде Нәҗип, читкә карап.

Фәтхулланың киңәшен тотып, ул Матвей Ионыч янына ике ярты аракы тыгып барган иде. Матвей Ионыч дигәннәре өч катлы сары йортның икенче катында, кырый бүлмәдә яшәп ята икән. Ул Нәҗипне бүлмәсенә кертмәде, коридорга үзе чыкты. Тәбәнәк, таза бәдәнле, калын җирән мыеклы, күз кабаклары салынган, чиртсәң каны чәчрәп чыгардай кызыл чырайлы бу кеше, «Фәтхулла» дигәнне ишетүгә, күзгә күренеп үзгәрде. Нәҗипне этеп диярлек бүлмәсенә кертте, ике якка бүлтәйгән чалбар кесәләренә

ишарәләп: «Яратам гәлифе кигән егетләрне!» — дип хихылдады. Ике сүздән Нәҗипне бүлдерде: «Беләм. Аңлыйм. Буш бүлмә бар. Пропискага бүтән йортка кертермен. Акча — сиксән тәңкә».— «Түләүне кайдагы бухгалтериягә илтергә?» — дип сорады аптырап Нәҗип. «Дурак!» — диде сыек сөт төсле күзләрен челт-челт йомып Ионыч.— Хәер, дуракларны яратам мин. Алар белән яшәү рәхәт. Дурак! Бүгеннән аллаң да, муллаң да мин. Комендант та үзем, бухгалтерың да. Дружинник та әле, җитмәсә. Акча миңа! Квартир хакыннан тыш кына ике ярты. Килештекме?» — «Аракы фатир хакына кермимени?» — диде авырыксынып Нәҗип. «Квартирдан кергәне миңа дип беләсеңме әллә? Фәтхулла кешесе икәнсең, синнән яшермим,— диде шыпыртка күчеп комендант-дружинник.— Бу йорт исәп-хисапта юк, бишбылтыр сүтелгән санала. Шикләләр иснәнә башласа, май кап. Дөнья шулай бара икән, эт муенын йоны яткан якка сыпыр. Акчасы тәтеми миңа, бар куанычым шул ярты!»

Ул мыекларын кул аркасы белән сыпыргалады, өстәлдәге сыңар стаканга аракы койды: «Эчәсеңме?» — дип сорады. Нәҗип баш тарткач, «Яратам эчмәгән дуракларны!» дип, почмакка карап чукынды да голт итеп стаканын бушатып куйды.

Нәҗип буш бүлмәне кереп карады. Яңа бистәдәге читлек белән чагыштырганда ул шактый биек һәм иркен икән. Ираида Никифоровна подвалы белән янәшә куйганда якты да, коры да иде. Идәне тигез — күкәй тәгәрәтеп уйнарлык! Аш-су пешерерлек кухнясы бар, бәдрәфе, уртак булса да, шунда коридорда гына икән... Бер нәрсә шикне арттырып, борчып, күңеленнән китмәде. «Милиция-мазар тикшерә башласа, ул — эшсез. Имгәк-тунеядларны шәһәрдән үк сөрәләр түгелме? Димәк, атлаган саен сагаерга туры киләчәк!» Тик тагын кая бара аласың? Алар Ионыч белән кул сугыштылар...

Ул сары йортка борылып карый-карый китеп барды, юлда очраган беренче йөк машинасын туктатып килешенде, алар шул сәгатьтә үк күчеп тә килделәр. Бурычларны түли-түли мең сум бетә язды, җан сакларлык кына мая калды.

«Яңа йортта урын үзгәләрбез, иртәрәк ятыйк» дип, как идәннең төрле почмакларына тәгәрәшеп кенә өлгерделәр, ишекне нык дөбердәтеп, салмыш өч ирне ияртеп, Ионыч килеп керде. Керүгә, бердәнбер урындыкны биләп: «С новосельем! — дип акырды, сөт төсле күзләрен челт-челт йомгалап: — Магарычың бармы?» — дип белеште. Юк икәнен белгәч: «Моннан болай мин кергәндә запас яртың булсын!» — дип, дөп-дөп басып чыгып китте.

Йокы качты, Нәҗип белән Наилә әйләнгәләп озак аунадылар. Көндез ашык-пошык ташынганда, нәрсә-караны урнаштырганда тирә-якта, күрше-күләндә тавыш-гауга артык ишетелмәгән иде, хәзер йортның өч каты тиң җанланды, бөтен тарафтан: астан-өстән, яннан-каршыдан төрле төстәге тавышлар агылды. Коридорда бала-чага әүмәкләште: сугыштылар, орыштылар, бәрештеләр, үкерделәр. Уртак кухняларда хатын-кызлар урын өчен даулашты. Кемдер радио акыртты. Кемдер, радио тавышын баса-баса, үзе акырды. Тыпыр-тыпыр биеделәр. Сулыгып җылаштылар. Шешәләр ватылды, стаканнар чыңлады. Кыскасы, адәм уллары дөньяда нинди тавышлар чыгара алса, монда барысы да бар, кирәгеннән артык мул иде. Стеналар юкамы, тавыш ияләре гайрәтле идеме, өч катлы сары йорт давыллы-җилле диңгездә адашып калган җүләрләр корабын хәтерләтә иде. Ята торгач бу давыл тына төште, ләкин дөньяда бүтән төрле тавышлар да җитәрлек икән бу якта! Йокыга китә алмый борсаланып яткан төнне урталайга ярып, поездлар текелдәп үтте, паровозлар, юл кырында яшәүчеләрне куркытырга теләп, тоташ акырдылар. ТЭЦ казаннары сызгырып-үкереп пардан бушанды, тимер юлның аръягындагы силикат кирпеч заводы үз тавышын таратып торды, краннар ары-бире шуышып гүелдәде, машиналар маңгайга-маңгай очрашып кычкырттылар, кайдадыр илереп-илереп гармун җылады, җылады да завод, ТЭЦ сасысыннан тончыгып туктады. Чың итеп пыяла коелып төште, мылтык аткан тавыш яңгырады. Тәрәзә ярыкларыннан, ишектәге тишекләрдән туктаусыз агылган газ, сасы һавада балалар өзлексез йөткерде. Нәҗип белән Наилә, бугазлары кычытуны баса алмыйча, торып-торып сөт эчеп килделәр. «Яңгырдан качып, кар-буранга эләкмәдекме икән без, җаным?» — диде Наилә. Нәҗип дәшмәде, сүзе юк иде.

## 14

Сары йортта атна үтте.

Гадәти шәһәр йортларында гомер буе янәшә яшәгән кешеләр күрше-каршыларын белмичә, бер-берсе белән һич аралашмыйча үлеп тә китәләр. Монда законнар, кагыйдәләр үзгә иде, бу йортка ничек юлыгуларын, кайда пропискада торуларын, күпме фатир хакы түләүләрен беркемгә чыгармасалар да, бу бәхетсез бәндәләр уртак тормыш белән яшиләр иде дисәң дә хата булмас. Тормыш дулкыннары сине монда китереп ыргыткан икән, танау чөеп, күкрәк киереп йөри алмыйсың инде! Эчә-эчә бөтен кешелек сыйфатларын җуйган гомосексуалист доцент, тавышсыз калган наркоман җырчы, ирсез хатыннар, хатынсыз буйдак-импотентлар, бозыр кебек җитез, күмер күзле кесә карагы Митя Шорохов, химиядән чәчләре генә түгел, каш-керфекләре сынып-коеп беткән, күз аслары дуга-дуга шешенеп салынган маржалар, күлмәк итәген ел саен бер тотамга кыскарта килсә дә, ир-ат күзе төшми башлаган чәч алучы

Гөлнәзирә, дөньяның әчесен-төчесен генә түгел, йөзләгән ирне татыган чегән хатыны Лорелия, бәхетсезләр, гарипләр, ятим-ялпы монда яшәп яталар, һәм барысының да тормышы күрше-каршыга көн кебек ачык иде. Нәҗип белән Наилә бер атна эчендә шушы билгесез киләчәккә таба йөзгән сары корабның пассажирларын танып бетерделәр. Бүтәннәр дә Нәҗипнең эшсезлеген, чирле икәнен тиз үк белеп алдылар. Наилә кайда эшләгәнен әйтмәде, хурланды. Күпчелекнең даими эше юк, ир-атлар — кибет, склад тирәсендә уралучылар, хатын-кызлар ашханәләрдә табак-савыт юа, подъезд чистарталар, мәктәп, китапханә кебек урыннарда эшләүчеләр монда бөтенләй юк иде. Уртак тормыш серләре тиз ачылды, монда сер саклаган булып кылану юк икән, шушы сары йортка төс икәнсең, борын күтәреп йөрмә инде, туган! Монда кәеф саклап, тәкәллефләнеп аңлашу юк, ни уйласалар, шуны турыдан-туры чәпиләр, монда рухи коммунизм һәм матди хәерчелек хөкем сөрә иде. Әйе, Нәҗипнең тормыш планнары зурдан иде, ил башына менеп утырган катлау аны үз арасына алган да булыр иде. Мөдир буласы кеше иде. Шәһәрнең дәрәҗәле ягыннан — Вишневский, Лесгафт, Ульяновлар урамнары тирәсеннән байларча фатир да эләгәчәк иде... Ә бүтәннәр ничек килеп эләккән монда? Аларның да татлы хыяллары, якын елларда тормышка ашарлык планнары булмаганмыни? Сары йортка юлыкканчы, алар Нәҗип шикелле үк, ялган хыялларга алданып яшәмәгәннәрмени?! Бер төндә өчәр-дүртәр ирнең кесәсен капшап караган Гөлнәзирәнең дә яхшылыкка омтылган мизгелләре булгандыр ич? Ябык, пычрак муенын бердәнбер байлыгы — мохер шарф белән ураган актерның да әле өмете өзелмәгән бугай. Ул кич саен сөт җылытып эчә, авызын учы белән каплап, тамагын кыра-кыра коридорда йөренә, үтәли искән җилләрдән курка, чак кына туңып кайтса да, аягын җылы сулы чиләккә тыгып утыра. Алдагы тормыш белән яшәүче бердәнбер зат ул булса кирәк. «Дважды дурак! — ди аның турында Матвей Ионыч. — А они опасны!» Бүтәннәр алдагы көн, буш хыяллар белән яшәмиләр, алар өчен бүгенге ачы язмыш хакыйкате генә бар. «Иртәгә өчен ишәк кайгырган». Сары йортның иманы бер.

Кесә карагы Митя Шороховның бурлар дөньясында атаклы икәнен беләләр. Митяның монда яшәп ятуына җыйналашып сәерсенәләр иде. Ул берчакта да үзе турында авыз ачып сөйләми, ярканат кебек очып кайта, күргәне аның шәүләсен күреп кала, күрмәгәне күрми, берәү дә артыгын төпченми. Митя көндезгәчә үлеп йоклый, тавышлар ишетми, торгач ике сәгать гимнастика ясый: гер күтәрә, коридор буйлап чаба, иелә, бөгелә, бүлмә почмагына эленгән бокс грушасын төя, тәпәли, соңыннан бозлы су белән юына. Аннары акмай ягылган ак күмәч белән бер чынаяк куе кофе эчә. Ишеге берчакта да бикләнмәсә дә, аның бүлмәсенә беркем керми, ул турдан һәркем аяк очына басып кына үтә. Митя — мондагыларның эчен-тышын белеп бетергән зирәк кеше, ул ташландык карт-корыны кызгана, үзләре дә оныткан туган көннәрен белә, йокысыннан уянгач, трусиктан гына алар янына керә, кәсебе уң барганда бүләкләр тапшыра: шарфлар, җылы кофталар, бияләйләр бирә, бүтәннәр юк санаган кәкре-бөкре корткаларны олылап, «Мария Ефимовна, Дарья Григорьевна» дип эндәшә. Чирләсәләр — ул карый, ашарларына әзерли, дарулар өләшә, чирләп больницага кереп ятсалар, көн саен ризык ташый. Матвей Ионыч белән аралары яхшы булса кирәк, очрашсалар, яхшы атлар кебек, баш иешеп кенә үтәләр. Кыскасы, сары йортта Митя каракны яраталар иде.

Бәхетсезләргә монда күңелләр ачык, язмыш уртаклыгы аларны берләштерә, карчык-корчыклар юнәткән ризыкларын юмарт бүлешәләр; эчкәч якага-яка килеп талашканнар да айныгач татулашалар, кинә саклау юк, үпкәләшләр атна буена сузылмый, сөйләмәсәң беркем синнән допрос алмый, төпченми, тырнаклары җиткән куллар белән җаныңда казынмый. Наиләне бер нәрсә генә борчый иде: алар да, шушы төркем вәкилләре кебек, борылып чыга алмаслык дәрәҗәдә адаштылармы? Болар да заманында кемнәрнеңдер кадерлесе, җәмгыятьнең киң хокуклы вәкилләре булган лабаса!.. Берәвесе доцент булган, икенчесе — атказанган артист... Ә хәзер...

Сары йорт шәһәр оешмаларында, милициядә юк дип санала. Әллә кайчан сүткәннәр дә нигезен бульдозерлар белән тигезләп бакча утырткannar. Йорт та юк, андагы кешеләр дә юк... Язмыш тәгәрмәче бөтен авырлыгы белән адәм улларын сытып тигезләгән, юк иткән. Паспортлары төрле җирдәге төрле йортларга язылган аларның...

Нәҗип завод тирәсенә эз дә басмады, хезмәттәшләренең, завод хуҗаларының, директор урынбасары Храмовның хыянәтен ул шултиклем авыр кичерде, тамактан калды, беркөнне трамвайда Изил Латыйповны күргәч, алдагы тукталышта ук төшеп калды. Ябыкты Нәҗип, Наиләсе ни кылырга, ни пешерергә, ни әзерләргә белмәде. «Иелгән башны кылыч кисми, тагын бер тапкыр барып кара. Мөдир итмәсеннәр, чукынып китсен, эшкә генә алсыннар. Кирелектән тун тегеп булмый!» — дип ялварды. Ирен җиңә алмагач: «Бармасаң, сорамасаң, тормыйм, аерылышабыз!» — дип кычкырды. Нәҗипнең күңеле портландцемент белән ныгытылып каткан иде. «Ни көтәсең син?» — дип илерде йомшый төшкәч хатыны. «Иртәге көнне көтәм»,— диде Нәҗип, томанлы гына. Иртәгәләр туды, алар эзсез-өнсез, җылы язда да күңелләрдәге бозны арттырып үтә тордылар. Бер нәрсә гаҗәпләндерде Наиләне: тормышы-язмышы сары йорт кешеләре белән тигезләшкәч, Нәҗип күзгә күренеп тынычланып калды. Чөнки монда берәү дә бер-берсеннән көнләшми, әҗәл-үлем, газраилләр турында уйлап баш ватмый. Яшиләрме бүген — яшиләр, тамаклары тукмы — ачтан үлмиләр! Юктан да рәхәт, сөенеч

таба ала торган юксыллар арасында Нәҗипкә дә күңелле иде. Ул кухняга чыгып баса, марҗалар белән гәп куерта, коридорда тәмәке пыскытучылар рәтендә дә читенсенми, монда һәммәсе дә үз кешеләр. Бер-берсен кауламыйлар, хыялланмыйлар, «ник эшләмисең?» дип ваксынучы юк, «ник эш эзләмисең?» дип төпченмиләр, тормыш сары йорт кешеләренең ихтыярыннан тыш җае белән ага иде.

«Әгәр балалар да булмаса...» дип йомгак ясады Нәҗипнең иләслектән бераз авырайган күңеле һәм сискәнеп, суыксып китте.

Балалар хакында уйламыйча ярамый иде. Алар бар, алар яши, ата-ана аларны алга илтергә, укытып, кеше итеп дөньяга очыртып чыгарырга тиеш. Сары йорт бала-чага урыны түгел иде. Монда, гомумән, балалар әз булып чыкты. Бала-чага өчен җәһәннәм базы иде сары йорт. Өлкәннәр үз язмышларын тора-бара яраштырсалар да, балалар бу тормыш белән килешергә теләмәделәр. Өйгә сыймадылар, чабып урамга чыктылар. Ә тышта... Бер яктан өзлексез поездлар улап үтеп торса, икенче яктан, тузан болытларына ял бирмичә, җәһәннәм арбалары «КрАЗ»лар чаптылар. Өй биеклеге тәгәрмәчләре белән җирне таптап-мыскыллап, тракторлар туктаусыз агылды. Алардан ургылып чыккан әче төтен койрыклары, ТЭЦ торбаларыннан бөркелгән сөрем болытларына кушылып, кояшны капладылар. Җил көнбатыштан искәндә чыдар әмәл калмады, энәләре саргаеп коелган наратлар арасына кереп утырган желатин заводыннан әллә нинди кабахәт исләр килеп җитте, тәрәзәләр томаланып, ишекләр ныгытып ябылса да, коридорга, бүлмәләргә кырыгынчы завод казанлыларга озын гомер теләп бүләк иткән агулы газ кереп тулды, бугаздан буды, тамак төбенә утырды, күздән ачы яшьләр агызды.

Сары йорт — кунакчыл йорт, якшәмбеләрдә монда кунаклар килеп тула, бирердә аларны риясыз гөрелдәп каршылыйлар, бер кыерчык ипи, бер җамаяк тозлы кәбестә янына шешәләр тезелә, кайсы кунакның кемгә килгәне онытыла, бүлмәләр берләшә, андый чакта балаларны коридорга чыгарырга һич ярамый! Саклап утырырга кирәк. Беркөн Искәндәрне, бик кысталгач, бәдрәфкә чыгарганнар иде, малайны эләктереп алганнар да көчләп сыра эчерткәннәр. Киң күңелле шул сары йорт кешеләре! Сырасы ярамадымы, эчкән савыты шакшы булдымы, бала төне буе косып чыкты. Наилә күпме ара чабып үтеп телефон-автоматка ябышты, врач чакырды. «Ул урамда андый йорт юк, байтак булды инде алдап чакырулар!» — диде кырку хатын-кыз тавышы.

Искәндәр шуннан мантымады, әле эче китте, әле тамагы шеште.

Тора-бара балалар алмаш-тилмәш чиргә сабыштылар, чирле ир янына ике сырхау бала да өстәлгәч, Наиләнең башы хәсрәттән чыкмады. Алсыз-ялсыз чаба торгач, үзе күтәрәмгә калды һәм иртәләрнең берсендә, биле сызлап кузгалырга чама юкта, балаларны авылга кайтару турында сүз кузгатты. «Әйбәт! — дип бик тиз килеште Нәҗип.— Тот та бабаларына илтеп кайт!» — «Юк инде, аппагым,— дип җәберсенде Наилә.— Чирле ике малайны картлар муенына такмам, безнең аркада болай да шактый җык күрделәр. Чирләткәнбез икән — үзебез карыйк!»

Шуны да уйлады Наилә: әгәр шушы форсаттан файдаланып Нәҗибен авылга алып кайтмаса, көннән-көн гамьсезләнә барган ир тормыш баткагына муеннан кереп чумачак! Биргән вәгъдәләрен, эчкән антларын онытачак, сары йорт бәндәләре белән тигезләшеп ярты хайванга әйләнәчәк. Нәҗип күз алдында үзгәрә: күрше бүлмәдәге сукбайларга иярде, җитен комбинатында ашханә ремонтладылар — эчеп кайтты. «Сантехприбор» ишегалдын, хуҗалык биналарын чүп-чардан арулап шактый акча төшергәннәр — Нәҗип җиде шешә сыра алып кергән. Менә сиңа күчтәнәч! Кыстап Наиләне җылатты. Тавышы көрәйде иренең, күз карашы тоныкланды, буйга биегәеп киткәндәй булды. Күршедәге сукбайлар бернинди тәкәллефсез кереп-чыгып йөри башладылар. Боларын күрмәмешкә салышты хатын, күрә калса, өйдә көн-төн талаш чыгачагын чамалады. Сүзне гел балаларга кайтарып калдырды, көннәр буе «балалар, балалар!» дип борсаланды.

Апрель азаклары иде, кардан иртә ачылган сары йорт тирәсендә күлләвекләр күбәйде, чокырлар тирәнәйде, тузан өермәләре куерды. «Кышын түздек, инде малайларны җәй дә монда тотсак, харап булачаклар»,— диде Наилә. Балаларны савыктырыр өчен нидер эшләргә кирәклеген күреп торган Нәҗип бу юлы хатынына каршы төшәргә кыймады. «Кайтыйк соң!» — дип, Наиләсен җупләде. Акча ягы койты, анысы мәгълүм, тагын бер чуалган төен килеп чыкты. Нәҗип: «Синең атаңнарга кайтабыз!» — дип кыстап-кыстап караса да, Наилә киреләнде: «Нигә сезгә кайтмыйбыз? Безнекеләрне күргән бар, нигә һаман синең эти-әниеңне читләтәбез?» — дип, иренең күзен ачырмады. «Казан артына кайтырга акча әз дә җитә...» — дип сүзен башлаган ирне Наилә шып туктады: «Эчеп йөрмиләр аны, хайван!»

Эш харап: юлга акча кирәк, Ионыч белән араны өзеп китәргә кирәк, инде Зәй ягына тәвәккәллиләр икән, ничә ел аяк басмаган ата-ана каршысына буш кул селкеп ничек кайтып керәсең?!

Бәхет көтмәгән яктан килеп чыкты. Кесә карагы Митя Шорохов соңгы вакытларда аларга кергәли иде. Керә, ипле генә утыра, дөнья хәлләрен сораштыра, чит илләрдәге яңалыкларны белешә, укырга китап ала, ертмый, пычратмый, вакытында кире кайтара, китаптагы вакыйгалар, сугышлар, орышлар турында озаклап сораша. Митя аңлы, игътибарлы һәм җанлы егет булып чыкты. Ул, бераз ияләшкәч, аларның ничек бу кое төбенә эләгүләре белән кызыксынды. «Сез — ару кешеләр, китапларыгыз бар, үзара сугышмыйсыз, нигә бүтәннәр кебек квартирлар алып, бай булып яшәмисез сез?» — «Ә син, Митя?» — диде Нәҗип үз чиратында. Митя: «Мин башка чут!.. Иманым шул: ата коммунистлардан

башлап чүп-чар халыкка кадәр урлаша икән, нигә мин тир түгеп ризык табарга тиеш? Җүләрме мин, ишәкме? Менә сез нигә череп ятасыз бу ат абзарында? Балаларыгыз бетәчәк монда. Аллергия дигән әкәмәт чыкты хәзер. Рактан да яманрак!»

Нәҗип ачылмаган иде, Наилә, сердәшсез яшәргә күнекмәгән хатын-кыз буларак, үз күргәннәрен, Нәҗипнең капылт чирләп егылуын, эшсез калуын, юк гаепләр аркасында шушы көнгә төшүләрен җылый-җылый сөйләп бирде. Сүз арасында Ираида Никифоровнаны, акчаларын талап диярлек алган игелексез Анатолийны да кыстырды. Байтак хәбәрләрне колагы яныннан үткәреп җибәргән Митя «акча», «талау» дигән хәбәрләргә игътибар иткән икән, соңыннан, сүз азагында Анатолийның кайда яшәвен сораштырды. Нәҗип белән Наилә бу әңгәмәне онытканнар да иде, Май бәйрәме алдыннан, кичкә кырын, тузанлы әңгер-меңгердә боларга бер ир-ат килеп керде. Керде дә өстәлгә бер төргәк акча куйды. Хуҗалар каушап калды. Анатолийны шәрә тән генә күргәнгә, зәп-зәңгәр татуировкаларын гына хәтерләп калганга, аны танымадылар. Керүче теш арасыннан гына үзенең сукыр Ираида улы икәнен белдерде һәм: «Сез нигә Митя белән танышлыгыгызны әйтмәдегез?! — дип шелтәләде.— Менә әҗәтне китердем».— «Кемгә рәхмәт әйтергә инде моның өчен? — диде Нәҗип, акчага үрелергә базмыйча — Митягамы?» — «Кирәкми! — диде Ираида карчыкның игелексез улы.— Митя боерганның үтәлми калганы юк. Соңыннан тикшереп йөрми ул!»

Ул төргәккә сәер бер караш ташлады да көрсенеп чыгып китте. Нәҗип төргәкне сүтеп караса-а, анда-а... Бишләтә китергән теге юньсез! Ул, коридорга атылып чыгып, баскычтан төшеп барган җилкәгә кычкырды: «Әй, әй!» Җилкә тукталып болай таба борылды. «Нәрсә бар?» — «Акчаны артык калдыргансыз». — «Анысы процент!» — дип кычкырды Анатолий, төшә-төшә. «Артканын Митяга кайтарырбыз»,— диде Наилә. Көн көтteләр егетне, ике, өч көн, Митя күзгә-башка күренмәде.

Якшәмбедә, бәйрәмнән соң, өй җыештырып палас кагарга чыккан Наилә тимер юл тирәсендәге куаклар арасында шикле хәрәкәт күреп туктап калды. Куаклар авызына милиция машинасы белән «ашыгыч ярдәм» дә килеп туктаган иде. Ак халат кигән ике таза ир агачлар арасыннан носилкага салып нидер күтәреп чыктылар. Наилә якынрак килде һәм носилкага карагач әрнеп кычкырып җибәрде. Носилкада йөзе ак киндер кебек агарынган Митя Шорохов мәете елмаеп ята иде...

*** * ***

Гомер юлының бер сызыгында ир балалар, өйләнеп, гаилә корып, аерым яши башлагач, беркавымга әти-әнидән читләшеп, аларны онытып торалар. Нәҗип белән дә шулайрак булды. Аның алдагы тормышка үргән матур-матур планнарында ата-анасына урын юк иде. Сирәк-мирәк кенә, балаларның ата-ана алдындагы бурычлары турында колакка чалынганда йә кино караганда, ул үзе туып үскән авылны, әти-әнисен кыска гына исенә кертеп чыгара иде. «Килер, көне килер! Йортларын торгызырмын, үз хисабыма диңгезгә ялга җибәрермен! Мәскәү күрсәтеп кайтырмын! Тәмле ризыклар тутырып посылкалар салырмын! Өрексез чәй эчертмәм! Акчаны мул итеп бирермен!» — дип, изге ниятләрен нығытып куя иде ул җаны уянган мәлләрдә.

Боларның берсе дә тормышка ашмады, берсе дә! Ул, битенә ыштыр ябып, бүген атасы катына кайтып бара. Кайтмас иде, ике улы чирдән котыла алмый. Баласы чирләгәндә сау калган ана буламыни! Наиләнең дә күз төпләренә каралҗым челтәр кунды, йөзе сулды, чигәләрендә беренче кырау — ак бөртекләр елтырады.

Ата-анага үз вакытында кайтарылмаган бурыч, үтәлмәгән вәгъдәләр баланы түбәнсетә. Нәҗипнең кордашлары, бер үк кояш астында яшәп, бер һаваны сулап, тормыш юлларын җайга салган күпчелек, укып, кеше булып, торымнан-торымга дәрәҗәләрен бер баскыч югары күтәрә-күтәрә балда-майда йөзгәндә, ул «чирләдем!» дип авызын бәлшәйтеп, ата-ана җилкәсенә кайтып төшәчәк. Үзе генә түгел, йончыган хатыны һәм чирле балалары белән. Нәҗип гаиләсе өчен тот та махсус шифаханә ач! Кайтырга ниятләгәч, ул Фәридун Фазлыев янына кереп чыгарга теләде — эшсез сукбай, сары йорт сандугачы икәне исенә төшеп, уеннан кире кайтты. Фаина Марковна янына кереп сөйләргә теләде — оялды. «Мавыгырлык, онытырлык шөгыль тапмагансың!» — дип әрләр кебек тоелды.

Дөресен әйткәндә, Нәҗип соңгы минуткача икеләнде: туган ягында көтеп торган кимсенүләр, гарьләнүләр аның чирен көчәйтеп җибәрмәсме? Йөрәк чыдамастан кузгалып алса? Казанда шифаханәләр, Фәридун Фазлыевлар, Фаина Марковналар бар, ә анда ни көтә?

Наилә авылга яшерен өметләр баглый иде: «Балалар белән рәттән Нәҗибе дә рәтләнеп китмәсме?» Нәҗипнең һәр сүзне кирегә сукалаганын ишетеп, ул гел бер уйны кабатлады: «Тилекәй! Авыл синең мәхәббәтең. Яңа сауган сыер сөте! Күпереп торган каймак! Йомарламы белән ак май. Катык, әйрән. Сары майда кетердәп пешкән тары коймагы. Түтәлдән өзеп кергән яшелчәләр, болыннарда кузгалак, какы, балтырган, әнис, көпшәләр! Тау чишмәләре! Урман күлләре! Инеш ярында куак саен сандугач. Инештә кәрәкәләр, маймычлар, кызылканат. Малайлар белән таңнан кармак салырга йөрерсез. Урман аланында киерелеп печән чабарсың, без малайлар белән печән әйләндерербез, күбәләрбез, чүмәлә куярбыз. Син минем авылны сагынганымны белсә идең!..»

Майның бишесенә билет алдылар.

Кеше берәүне бик нык ышандырырга теләсә, үзе дә ышана башлый. Үзе кат-кат сөйләгәннәрне күз алдыннан үткәреп, Наиләнең күңеле бөтәйде, бит очлары алланды, тәненә җиңеллек килде, тавышы челтерәп чыкты. «Әтиеңнәргә хәбәр итик!» — диде ул, сөенеченә тулышып. «Юк! — дип кырт кисте Нәҗибе. — Хәбәрсез-нисез, мыштым гына кайтып керәбез. Аэродром якын, ун чакрым ара, төшке ашка өйдә булабыз». Әти-әниләреннән йоккан хыял канатларына малайлар да утырган иде: «Мин сөтле токмач яратам!» — диде Искәндәр. «Ә мин, ә мин!.. Бабамнарга кайткач, ун морожныйны берьюлы ашап бетерәм!» — дип шапырынды Рөстәм.

Бер бау криндел, манпаси, өч йөз грамм мәк хәлвәсе, ярты кило каражимеш сатып алдылар, күчтәнәчләре шуннан артмады. «Төймә дә бүләк, дөя дә!» — дип көрсенде Наилә. Бурычтан гайре байлыгы булмаган хатын ни кылсын?! Алай да, киңәш-табыш итешеп, акчаны кат-кат санап, санаган саен төрлечә чыгарып интеккәч, Рөстәмгә өч тәгәрмәчле велосипед сатып алдылар, сала малайларының күзен ут итеп, чирәмле тигез урамнарда каз бәбкәләре арасыннан кыңгырау чылтыратып йөрсен әле бер!

**15**

О, бәйрәмнәр!!!

Тарихның гел бәйрәмнәрдән генә торган еллары була, хөрмәтле Иван Иванович белән Басыйр Бариевичның нәкъ әнә шундый тантаналы вакыйгаларга мул чоры иде. Кунак каршылыйлар да кунак озаталар, кунаклардан соң үз бәйрәмнәре җитә! Бәйрәмнәрне төрмә сакчылары белән палачлар гына яратмый: алар бәйрәмнәрдә үз хезмәт уңышлары белән мактана алмыйлар. Шәһәр башлыгы белән тимер юллар хуҗасы, киресенчә, мактаналар да макталалар.

Яңа елны каршылау, Май, Октябрь бәйрәмнәрен аерылмас дуслар бигрәк нык яраталар, бу бәйрәмнәрне алар «уңыш җыяр чак» дип атап йөртәләр.

Хикмәтле сүзләр болар, үтә хикмәтле!

Кыш буе сары йорттан әллә кая чыгып йөрмәгән, сердәшлеккә акбашлы шешәдән бүтәнне якын китермәгән Матвей Ионыч та май җилен сизә, яңагын каплаган бөдрә мүкне кырып ыргыта, башына елтыр козыреклы яшькелт картузын чәпи, сөт төсле күзләрен челт-мелт уйнатып, чите китек түгәрәк көзге каршысында бөтерелә. Каны кайный, талагы ташый. Йорттан чыга, куанычлы уйларга чумып, йортны хуҗаларча урый, нигезнең купшыган урыннарына бармагын тыгып карый, почмакларга күн итек үкчәсе белән ныгытып тибә, ах-ух килеп тузаннарны коя. «Алласына мең шөкер, йортның нигезе нык, көзге яңгырлар, кышкы бураннар, язгы сулар да аны җимерә алмаган. Тагын чирек гасырга — Ионычның әҗәленә тиклем түзәчәк бу нигез! Көтелмәгән яктан бәла килеп, йортны сүтеп кенә ташламасыннар!» — дип үзалдына укына. Ул карасу төрткеләр мул сибелгән бәрәңге танавын сеңгерә, бармакларын күн итек кунычына ышкып корыта, күзен кояшка текәп вакытны билгели һәм, мәрхүм Митя Шорохов раштуага бүләк иткән буй-буй пинжәген җилбәгәй җибәреп, тимер юлны аркылы үтеп чыга. Авыр-авыр шпалларны эре җәмкиләргә эләктереп сөйрәүче чуаш, мари хатыннарының сырган чалбар белән тарттырып куйган сыек артларына чәпелдәтә, мәзәк сүзләр сиптерә, авыр эштән җыклары чыккан бичара хатыннар җиңелеп кешниләр, коргаксыган аксыл иреннәрен чәпелдәтеп көлгәндәй итәләр. Бара-бара Левченко поселогына җитә, беркайда туктап тормый, күтәрелеп карамый, майның шәфкатьле урманына кергәч кенә адымнарын сирәгәйтә. Язгы урманны чамадан тыш ярата Ионыч! Тол-дүдәк, ялган акча ясаганы өчен төрмә-лагерьларда унике ел гомерен калдырган, чифир эчәргә хирысланып чак үлми калган кырыс җан, урманга кереп күмелгәч, бөтенләй бүтән кешегә әйләнә. Сулган коры яфракларны аралап-тишеп көнгә калкынган яшел кыяк-кылычлар, ары-бире ашыккан эшкуар кырмыскалар, ачыграк урыннарда тирбәлгән шадра күләгәләр аның кыш дәвамында каткан күңелен йомшарталар, җилкетәләр. Ул, кулларын җәеп ташлап, җылы, иркә җиргә каплана, сулышын эчкә тартып җирне исни, кибеп корыган төссез яфракларны учы белән өерләп дәү мендәр ясый да, чалкан ятып, хуш исле мендәргә башын куя. Уйлары тезелеп аны еракка, балачагына ияртеп китә. Ул яшьли уйнап үскән иптәшләрен, печәнлектә беренче аунаткан күрше кызы кылый Марфаны, әллә кайчан гүр иясе булып, бүгенгәчә догасыз тилмереп яткан әти-әниләрен өзелеп сагына...

Әтиләрен кулак дип авылдан кугач, әниләре хәер сорашырга чыккан җиреннән буранда катып үлде аның...

Бичаралар...

Марфа, Марфа! Ионычка кызлыгыңны биреп егетлеген алган кыз! Бармы син дөньяда, юкмы?

Кинәт ул еракта нәзек тавыш белән машина гөжләгәнен ишетеп алды, курчак солдаттай сикереп торды, чәч арасына кереп тулган яфрак кисәкләрен җиргә койды һәм колагын тавыш килгән якка куеп тыңлана башлады: ул көткән машина киләме?

Ионычның тән хәрәкәтләре үзгәрде. Ул сунарга чыккан ач юлбарыс кебек сыгылмалы, салмак адымнар белән тавыш ягына авышты. Машина — бер яктан, Матвей Ионыч аланның икенче ягыннан килеп керделәр. Очраштылар. Машина тынды, Ионыч җиңел сулап куйды...

Ул, кулларының дерелдәвен тыя алмыйча, өнсез генә сукранып, пиджагының эчке кесәсен каптырган булавканы озак кына ычкындыра алмыйча интекте, ниһаять, ычкындырып, иске гәзиткә ураган буаз төргәкне шудырып чыгарды. Бу юлы машинада күп еллар хезмәт итеп мең кат сыналган ышанычлы шофер юк, рульдә Басыйр Бариевич үзе иде. Ул очлы ияген каккандай итеп исәнләште, машина ишеге ялт ачылды, төргәк кулдан-кулга күчте. Очрашу сәбәпләре ашыгырга кушса да, Басыйр Бариевич сабырлыгын югалтмады, төргәкне тез өстенә куеп, тәмләп сүтәргә тотынды. Ионыч җәберсенеп, куе төкереген йота-йота: «Басыйр Бариевич!..» — дип сызланды. Басыйр Бариевич төргәкне учтан-учка йөртә-йөртә: «Тимә! Акча санаганны ярата!» — дип куйды.

Шактый күпне күргән бишлекләр, баш-башлары бөкләнгән унлыклар — бер чүмәкәй, көлеп торган егерме бишлекләр, олысымак, салмак иллелекләр икенче чүмәкәй булып өелделәр. Пыш-пыш килеп бер санады Басыйр Бариевич, бишлекләрнең почмакларын кайтарды, унлыкларны сөеп тигезләде, иллелекләрне үбәрдәй булып өстә калдырды. Ионыч акчаларны эреләтә дә ала иде, әмма аңа саклык кассаларында күренү тыелган, өч катлы сары йортта яшәүчеләрдән акча ничек килеп керсә, тиене-тиенгә туры китерелеп Басыйр Бариевичка барып җитәргә тиеш. «Ярый!» — дип мөгрәде, ниһаять, Басыйр Бариевич. Кычытып интектергән ияген кашып, Ионыч шушы сүзне көтеп зарыккан иде, «Булдырабыз без аны!» — дип, җиңеләеп, хуҗасына өмет белән текәлде. Аның баядан бирле ялманып торганын күңеле күзәткән Басыйр Бариевич арткы утыргычка ымлады: «Ал. Сиңа. Бүләк». Ионыч ялт кына арт ишекне ачты, үрелеп чүпрәк капчыкны кулына алды. Капчыкта бер шешә аракы, ярты кило чамасы үпкә-бавыр колбасасы, бер баш йомшаган сарымсак бар иде. «Каклаган каз куйдым, әнкәй күчтәнәче. Каз бәлешенең төбе дә сиңа насыйп икән, Ионыч!» — диде Басыйр Бариевич, эре генә.

Хуҗа белән тугры хезмәтче, әйткәнебезчә, бәйрәмнәр тирәсендә генә очрашалар, ешрак күрешергә ярамый. Кирәге дә юк. Озын сары йорттан ел дәвамында күпме фатир акчасы кергәнен Басыйр Бариевич бик шәп белә. Төгәллек һәм гаделлек яраткан Ионыч, әлбәттә, үзен буш итми, аның үз исәбе бар, ат аунаган җирдә — төк, акча йөргән якта мая калмыйча булмый. Берничә бүлмәне алар базарчыларга, җылы яклардан килгән кишмиш-күрәгә сатучыларга бирәләр. Басыйр Бариевич һәр бүлмәдә алты базарчы куна дип белсә, Матвей Ионыч анда уникене сыйдыра, һәр борыннан тәүлек саен ике сум! Тамып кына калмый, ага да!

Машина куркып кына фырылдады, икесе ике якка кузгалдылар. Аларның очрашканын беркем күрмәде, миллион адәм яшәгән шәһре Казанда бу күренешне тагы берәү генә беләчәк. Хөрмәтле Иван Иванович кодрәте, Басыйр Бариевичның елгырлыгы белән исән утырган бу йорт тимерьюлчылар балансыннан әллә кайчан сызып ташланган. Айлык керем тиене-тиенгә ике арада тигез бүленә. Иван Иванович йортны чит тыкшынулардан саклашкан хокук тәртибе сакчыларына өлеш чыгарса, Басыйр Бариевич үз тирәсендәге җаваплы иптәшләрне буш итми иде.

Май бәйрәме — алар өчен үтә кадерле, үтә төшемле бәйрәм. Демонстрация үтүгә, алар, Татарстанның алтын тоткалары, савылып өлкә комитеты буфетына керәләр, аягүрә басып кына бер-ике чәркә коньяк йотып, кара икра, семга телемнәре белән авызларын кинәндергәч, таралалар. Хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич аллы-артлы, һәркаюсы үз машинасында Идел буена аулакка китәләр. Акча шунда бүленәчәк. Ирләре артыннан аерым-аерым машиналарда хәләл җефетләре дә тантанага килеп кушылалар. Елгыр егет, тимерьюлчыларның профсоюз лидеры Исламнур, бүген мәҗлеснең уртасында балкып утыра. Татар да кеше ич, килсен, әйдә кинәнсен бер!

Аһ, киче гүзәл! Май киче! Талгын гына аккан чуар-чабар болытларны җиңел аралап, көмеш кош булып самолет оча. Су өстендә уйнаган вак, язгы гөнаһсыз дулкыннарны басып Идел өстенә хуш исле эңгер иңә. Бераз кәефләнеп алгач, Иван Иванович белән Басыйр Бариевич тән язарга сәйранга чыгалар. Бераз арткарак калып булса да, Исламнур аларга иярә. Җәяү йөрү бәхете сирәк эләккән затлы ил агалары җир тарту көченең рәхәтлеген тоеп атлыйлар, җиркәй депутатның да, каракның да табанын бертөсле кытыклый. Бара-бара болар тимер юлны каплап торучы тоташ стенага — агачлыкка килеп чыгалар. Каен белән ярыша-ярыша үсеп шактый ныгыган кәүсәле мәгърур имәннәр янына барып баскач, хуҗаларның кәефе тагын да күтәрелә. «Бушбугаз журналистлар: «Табигатькә куркыныч яный, Казан яны имәнлекләре бетте!» — дип лаф ора. Кәнтәйләр! Сукырлар! Килсеннәр, күрсеннәр, ничәмә-ничә чакрымга сузылган бу имәнлекләр!» Басыйр Бариевичның бу агачларга һич катнашы булмаса да, ул бүген шат, имәннәрне үзе утыртканмыни, очынып мактана, иңнәренә кагылган ботакларга асылынып уйный. Борылып караса, Иван Ивановичның үткен күзләре имәннәргә түгел, авыл белән агачлык арасында җәйрәп яткан иңкүлеккә төбәлгән. «Шушында симерә инде алайса Әнисә түтинең казлары!» — дип соклана шәһәр башлыгы. Тимерьюлчыларның лидеры аңа кушыла: «Шушында симерәләр, бәхете арткыры!» — дип куя. «Мәскәүдән алып кайткан каз ботын кимергән бар. Юк, безнең якта май җыйган кош-кортка ни җитә!.. Хәтерлисеңме, өченче ел көртлек атарга барган идек, ә!» Иван Иванович хатирәләргә кереп чумса, беттең дигән сүз. Каян сүзен, чагыштыруларын таба

диген, сандугач булып сайрый... Сүз дәвамында ул орчык башы сыман бөтерелеп тыңлаган Басыйр Бариевичны шәйләп ала һәм: «Быел ничә бәбкә чыккан?» — дип кызыксына. «Ике ояга егерме ике бәбкә!» — ди горурланып Басыйр Бариевич.

Бу күңелле сан аларны сихерли, алар егерме бәбкәне, исәйгән, үсеп казга әйләнгән кошларны күңелләреннән үткәрделәр. Якын вә ерак киләчәк аларга татлы төш булып күренә, әйдә, имәннәр үссен, каеннар шауласын, поездлар үтеп-сүтеп торсын, ил ныгысын, әмма шушы тын иңкүлек, кешесез һәм аулак урыннар үзгәрешсез калсын. Тормышның асылы үзгәрмәсен, илдәге гадәтләр шул килеш дәвам итсен, халык җитәкчеләрен зурласын, ярабби! Оҗмах диләр, күзгә күренмәгән оҗмахка керү хокукын яулар өчен күпме адәм уллары гомерләрен Гайсә пигамбәргә, изге Мөхәммәткә багышлаганнар, ярымйорты ашап, кара тиргә батканчы эшләп яшәгәннәр. Җир йөзендә дә оҗмахка тиң урыннар барын белмәгәннәрме алар? Ахмаклар, беркатлы сукырлар! Оҗмах шушы түгелмени инде?! Тагын нинди оҗмах кирәк адәм улларына?!

## 16

Нәҗип Йосыф улы Нургалиев яши-яши үз табигатендәге сәер бер гадәтне ачты. Нинди дә булса авыр, чуалчык мәсьәләне чишә алмыйча хәлдән таеп ял итәргә ятса, шулчак йокы белән уяу арасында зиһене ашыгып-ашыгып эшкә тотына, озак газапланган, чишелмәстәй күренгән сорауларга җавап үзеннән-үзе күңелгә килә. Иҗат әһелләрендә шундый сәер феномен барлыгын ул кемнәндер ишеттеме, әллә укыганы хәтердә калганмы, үзе белән шундый хәл еш-еш кабатлангач, Нәҗип куркып та йөрде. Гадәти хәлме бу, әллә табигать могҗизасымы? Лабораториядә эшли башлагач әллә ничә тапкыр сынады: баш ватып утырганда табылмаган җаваплар, урынга яткач, йокыга китәм дигәндә генә табылды да куйды. Ниятләп яткан очракларда могҗиза тумады, тинтерәткән мәсьәләләргә җавап табылмады. Аны-моны юрамыйча ятса, «күк капусы ачылды да куйды». Бу сәер күренешне Нәҗип үзе өчен шулай дип атады.

Нәҗип сәер халәтнең эчке закончалыгын ачарга тырышып карады, кайсы көнне, сәгать ничәдә, нинди шартларда күк капусы ачылганын кәгазьгә теркәп барды, схемасын төзеде. Иртә ачылганмы күк, киченме? Әмма ул төгәл генә бер модель ясый алмады, кеше аңында фән дә аңлатып бетерә алмаган күренешләр һәр кешедә үзенчә була ала дигән нәтиҗәгә килде. Соңгы вакытларда, чирләп егылганнан соң, аның бу гадәте юкка чыкты, шундый серле-тантаналы мизгелләр кабатланмады. Зиһене буйсынмый башлады, ихтыяр көче күзгә күренеп кимеде. Кеше әҗәле, үлеме хакында гына уйлау сукмагына төшсә, үлемен тизләтә, курку хисе бүтән хисләрдән өстенлекне ала, кеше аңын кимерә. Мыжыклар, дөрләп кабынучы кинәтләр, үпкәчел-көнчеләр бу дөньядан тизрәк китәләр. Җир аларны күтәреп торып арый да вакытын белеп кенә үз тәненнән кагып төшерә.

Бүген җылыкай төенчеген — төпчек улын тезенә утыртып самолетта кайтканда, Нәҗип йокымсырады. Холкы белән чәүчәләк, урын үзгәләүче Нәҗипнең самолетта түгел, икешәр тәүлек кайтып поездда да йоклаганы юк иде — бүген изрәтеп, тәнне мәмрәтеп, йокы басты. Мие түнде, күз кабаклары салынды, буыннар йомшап камырга әйләнде. Керфек араларында сәер зәңгәрсу томан хасил булды. Ул үзләре кайтасы юлны — Зәй белән Югары авыл арасын аермачык күрде. Ирнә буендагы әрәмәдән болыт булып сарык көтүе чыга икән... Ә баш очында тургайлар! Пыр-пыр килеп очалар. Сулда — төбәкнең биек маңгае Кашка тау. Аның итәген туктаусыз юып, Олы су ага... Олы су үзәнен ярып, бер тавыш яңгырый: «Нигә кайтасың син туган ягыңа, Нургалиев?» Онытылып, чиреңнән качып, авыл ышыгында посып торырга кайтасыңмы? Фәридун Фазлыев белән Фаина Марковна икесе беравыздан: «Чиреӊ тәнеңдә түгел, җаныңда. Кеше үз җанына үзе хуҗа була ала!» — димәделәрме сиңа? Ә син чир-чорларыңны, бәхетсезлегеңне сәбәп итеп карт ата-анаң канаты астына сыенырга булдыңмы?..» Сорау иңкүлек өстендәге ваемсыз кошларны куркыта-пыркыта тирбәлеп йөрде дә Кашка тау битенә туктап сеңде... Ул дерт итеп уянды, авырттырып күзен уды, күк капусы ачылган кебек булса да, уйларының йомгагы, нәтиҗәсе юк иде. «Әллә гомерем шушы минутта чикләнәме?» — дип уйлады Нәҗип, тиз-тиз уңга-сулга карады: колагына мотор тавышы ишетелмәде. Аңа курку инде. Тирә-як, һава-күк тып-тын калган иде. Ул Рөстәмен корсагына кысып, үзен түгел, улын коткарырга теләде. Кай төшкә мәтәлеп төшәрләр икән? Урмангамы, кыргамы? Ничә секунд гомерләре калды икән аларның? Бүтән пассажирлар нигә тыныч, нигә чәбәләнмиләр, кычкырмыйлар. Бер-бер чарасын күреп өлгереп булырмы? Бразилиядә апалы-сеңелле ике бала үзләре утырган креслоларга чытырдатып тотынганнар да бик биектән җиргә исән-аман төшеп җиткәннәр. Куе ботаклы агач ябылдашына тап килгән берәү вак-төяк тән җәрәхәтләре белән котылып калган. Кай турдан очалар икән алар? Чулман иделе өстеннәнме? Әгәр алар боздан яңарак ачылган сап-салкын суга барып кадалсалар? О-о, су үтергеч салкындыр әле. Өс киемнәреңнән котылсаң да, шыкраеп катарсың, чишенмәсәң, быкырдап төпкә китәрсең. Самолет турайды, мотор тавышы гөрләп ишетелә башлады, баксаң, Нәҗипнең «күк капусы ачылуы» дәвам иткән икән. Уйлары борчулы, вак-төяк шикләрдән арына алмаган кирле-мырлы уйлар.

Бүтән пассажирлар да месләгән, самолет тигез гүли, изрәтә. Нәҗипнең йөрәге моторга тиңләшергә теләгәндәй ашкына. Ул тел астына валидол кыстырды. Ис сизеп, Наилә аңа борылып карады. «Хәлең начармы әллә?» «Түзәрлек», — диде Нәҗип, күзләрен йомып...

Зәйгә барып төштеләр. Кызык, Зәй төбәгенә юмарт сибелгән татар-керәшен авылларында Зәй дигән сүз юк, бу як халкы аны «Эзи» дип атап йөртә, «Эзигә бардым, Эзидән кайттым» дип сөйләшәләр. Нигә Зәй? Эзи матуррак түгелмени?! Самолеттан төшкәндә Нәҗип шулай уйлады. Ирнә елгасы өстен иңләп килгән җил аларны куырып алды. Аэропорттан Югары авыл юлына чыгуны ныклап уйламаганнар икән, ничектер һәммәсе тиз җайланыр, Зәй — Сарман арасында йөрүче бетмәс, һич югында, сөт ташучыларга сыешып кайтырлар дип ниятләгәннәр иде. Наилә, каерган җилгә бирешмәскә тырышып, итәген тотып, аэропортны урап чыкса да, ике арык аттан һәм балчыкка чумган матайдан ары нәрсә-кара күрмәде. «Әни, кара, балчык мотоцикл, ул уенчыкмы?» — дип сорады Искәндәр. «Пычранган гына ул», — дип аңлатты пошына башлаган әниләре. Китәселәр самолетка кереп тулды, ул пыр-пыр килеп китеп барды. Җил тагын да зәһәрләнде, һавада кәнфит кәгазьләре, коры курай бөтерелде, буш консерва банкасы тәгәрәп килеп Наиләнең тубык сөягенә бәрелде, авырттырды. Алар белән очкан кешеләрнең берничәсе буш буйдак икән, кысыр сумкаларын, кулларын селкеп, Зәй ягына тәпиләделәр. Чемоданлы апалы-сеңелле ике хатынны балчык матай алып китте. Аэропорт хадиме, ишегенә авыр йозак элеп, матай болгатып киткән лайны озын кунычлы резин итекләре белән ера-ера өенә ашыкты. Нәҗип, «авыз ачып калмыйк тагын!» дип, атлылар янына чыкты. Атлыларның берсе дә Югары авыл ягына кайтмый икән, кирегә, Мәлем ягына китәләр. Нәҗип: «Олы юлга чыгарып кына куегыз!» — дип үтенде, тегеләр гармун кабыргалы «юртакларына» көрсенеп карап: «И туган, юлның нинди икәнен белмисеңме әллә?» — диештеләр. Үзле балчык ябышып авырайткан тәгәрмәчләрен җылатып-сөйрәп атлылар да кузгалды. Бикле аэропорт, пычрак мәйдан янында, җил күзендә алар дүртәү торып калдылар. «Әни, минем карыным ачты»,— диде Рөстәм. Наилә авызы нәзек җеп белән бәйләнгән төенчекне чишеп, күмәч сындырып алды, улына тоттырды. «Ә миңа?» — дип турсайды Искәндәр. Аңа да өлеш чыкты.

Ул арада Зәй ягыннан ава-түнә килүче машина күренде. Дүрт күз белән көткәнгәме, әллә юл чыннан да бик хөрти идеме, машина үтә дә озак килде. Яртылаш лайга манчылган, номерлары гына түгел, ишек тоткалары да күренмәскә әйләнгән машина яньчелгән канатлы «Запорожец» булып чыкты. Ишегеннән кәтәнә генә, йомры гына бер үсмер җиргә сикерде, лай чәчрәде. «Ибраһим абыйлар кайтмадымыни?» — диде ул. «Юктыр»,— диде Нәҗип, кулын җәеп. «Монда кеше заты калмады»,— диде Наилә, эченнән сөенеп. Малайлар алсу яңакларын бүлтәйтеп күмәч бөктеләр. Кәтәнә кунычлары кайтарып бөкләнгән кирза итекләре белән җиргә типкәләде: «Монда корырак икән»,— диде. «Юл начармы?» — дип сорады Нәҗип, кәтәнәгә ошарга тырышып. «Начар гынамы, начар ярым!» — диде кәтәнә, җилгә каршы төкереп. Төкерде дә яңакларын пычрак учы белән сөртте. «Әни, туймадым»,— диде Рөстәм, әнисе итәгенә сырпаланып. «Мин дә!» — диде, борын куыгын йотып, Искәндәр. Наилә чирдән арынмаган балаларга әрнеп карады: «Бабаңнарга кайткач ашарсыз. Тавык ашы пешереп көтәләрдер. Сизәләрдер... Ачкакланмагыз! Ачлар дөньясыннан кайткан диярләр». Нәҗип юмакай-төче тавыш белән: «Син шәп егет икәнсең, безне олы юлга чыгарып куйчы»,— дип кәтәнәгә эндәште. «Кая кайтасыз?» — «Югары авылга ла!» — «Оho!» — диде кәтәнә, итек кунычларын берәм-берәм тарткалап. Аның иң югары октава белән әйткән «Оho!»сын аңлау кыен түгел иде. «Буш итмәбез!» — дигән булды Нәҗип, җил уйнаган кесәсенә суккалап. «Эш андамыни? — диде кәтәнә, җил уңаена оста төкереп.— Ибрай абыйларга ни булды икән? Телеграммасы килде, анда тучны әйтелгән...» Нәҗип үтенечен кабатлады. Кәтәнә, үзеннән чак кына бәләкәйрәк балаларга карап: «Төягез хәзинәгезне!» — дип кычкырды. Тиз-тиз машинага кереп чумган малайлар янына бүктәрләрне, кая куйсаң да төртеп-чыгып торган хәсрәт велосипедны кертеп урнаштыргач, Наилә, итәген җыештырып, алар янына кысылырга әзерләнгәндә, кәтәнә, сытык елмаеп, аны туктатты. «Син, чибәр апасы, ашыкмый тор. Чакыру бармы әллә? Минем машина, бер кузгалса, җен урынына чаба, кузгалмый икән, үшән алаша күк тик тора. Сез, кабынганчы, икегез ике яктан тәгәрәтеп барыгыз инде».

Бүтән чараң юк, ни кыласың?! Наилә сирәк киелә торган туфли-көймәләренә, майланып-җебеп яткан чокырларга карап сулады да итәген бөрмәсенә кыстырды. Нәҗип, учына төкереп, шофер ягына чыкты. Кәтәнә утырмады, ишеген ачык калдырып, стартерга басып-басып карады да этешергә әзерләнде. Тик торган арада үзле балчыкка сеңгән иске консерва банкасы кузгалмыйча шактый тирләтте. «Кабынуга икегез ике яктан утырып өлгерегез!» — диде кәтәнә. Һау-һаулап кычкырып эттеләр, балалар кул чәбәкли-чәбәкли тәгәрәп көлделәр. Мәзәк аларга! Тәки кузгаттылар әҗәл тагарагын. Алар бәхетенә, юл авыш иде, урыннан бер купкач, машина үз җае белән балчык чәчә башлады. Бер төчкерде, ике, өч! Мотор кабынуга, кәтәнә: «Ятьрәк!» — дип акырды, үзе елдам гына руль артына сикерде. Күрсәнә, баралар!

Якын гына араны сәгатьтән артык үттеләр. Зәйгә җитәрәк юл аруланды. Нәҗип: «Син, туганкай, безне Югары авылга илтеп куйчы!» — диде. «Ибрай абыйлар икенче рейстан калмас, бензин ягы да

кәй. Туй! Өйләнәм!» — диде кәтәнә. Акча алмады кияү егете. «Якташлардан аламмы соң!» — диде. Балта сабы хәтле кияү егетенә карап Наилә ни уйлагандыр, Нәҗибенә әйтеп тормады.

Буласы булды, кәтәнә бензин юлларга китте. Алар Зәйнең Сарман ягына чыга торган очында, җилдән ышыкланып, кабык түбәле өйгә сырышып басып калдылар. Озак кына сөйләшмәделәр, күзләр дә, уйлар да юлда булды. Бер яктан да хәрәкәт күренмәде, кояш тиз-тиз күчenә, үз артыннан көннең яктысын иярттеп, офыкка таба ашыга иде.

Зәйдән егерме чакрымдагы авылда Нәҗипнең бертуган абыйсы колхоз рәисе булып эшли. Алдан хәбәр итеп куйсаң, йә булмаса, хәзер кереп шалтыратсаң, юлда калдырмас, әмәлен табар иде. Болай да чак-чак эләгеп торган аралары соңгы очрашуларында шартлап өзелде. Абыйсы партия конференциясенә килгән иде, урамда ялгыш кына күрештеләр. «Торыр җирең булмасын, эшең җайга салынмасын, бу нинди бала арты бала ташу! — дип кызды абыйсы, Наиләнең Рөстәмне алып кайтуына җене котырып.— Хәзерге заман кешеләре алдын-артын кат-кат уйлап, уйларын мең кат уйдырып яши. Әнә яһүдтән үрнәк ал. Күргәнең бармы герой-ана яһүдәне? Бала-чаганы Урта Азия ыбыр-чыбыры ташый. Ә яһүд йә профессор, йә доктор. Бала чүпрәге юып эш майтаралармы бу заманда?!»

Нәҗип абыйсын моңарчы бер дә белмәгән икән, шунда аңлады. Әнисенең хәле ничек, бәбәе сихәтме, дүрт саны тигезме? дип сорашмады партконференция делегаты, ата белән ананы эттән алып эткә салды.

Юк, юк, бүгенге хәлен ул абыйсына күрсәтмәс, белдермәс тә, Зәйдә кунса кунар, аңа шалтыратып тормас.

Абыйсының һәр якны берьюлы күреп яши торган кеше икәнен ул әзрәк белә иде. «Мин райком секретаре булам!» дип яшьтән үк киртләп куйган иде Сабит. Ул яшьли биргән вәгъдәсен онытмады, юлыннан читкә тайпылмады, юк-бар кеше белән аралашмады, туган-тумачаны үзе аралашкан түгәрәккә кертмәде, ачык чырай күрсәткән туганнарның берзаман өскә менгәч ямаулык сорап киләчәген белә иде. Шул сәбәпле колхозның үз ягыннан ерагын, иң читтәрәген сайлады, өенә бик сирәк, анда да чирек сәгатькә генә кереп чыккалады. Читтәге туганнарына карлыгач канаты хәтле дә хат язмады.

Зәйдә кунса кунар, ялынып Сабит абыйсына бармас Нәҗип!

Вакыт ашыгып акты, балалар көйсезләнде, юанычка аларга велосипедны көйләп бирделәр. Дуңгыз сөреп бетергән Зәй урамында балалар әллә ни иркенәя алмадылар, тәгәрмәчләре батып интектергәч, уеннан баш тарттылар. «Авылга кайткач, авылга!..— диде Нәҗип, тәгәрмәчләрне күлләвектә юып.— Анда инде ул чирәмле урамнар! Көмеш күлгә барырбыз, кармак салырбыз, уха пешерербез!»

Тырылдаган тавыш ишетелде. «Машина!» — диделәр алар берьюлы. Тавыш озак көттерде, күзләр тала дигәндә, урам чатыннан «Белорусь» тракторы килеп чыкты. Сөт бидоннары тутырган арба таккан, төсен җуйган трактор фырылдап килде дә, Нәҗип белән Наилә баскан турга җитеп, үзеннән-үзе туктады. «Югары авылгамы әллә?» — дип кычкырды Нәҗип. «Шунда!» — дип җавапланды үсмерлеге чыраеннан чыгып бетмәгән тракторчы. Аңа кысылып утырган чәчкәле яулыклы хатын-кыз, юлчыларга текәлеп-текәлеп караса да, танымады. «Шунда кайтып барыш ие дә,— диде тракторчы.— Кайтып җитеп булса...» — «Җитәрбез»,— диде, ярым шукланып, янындагы хатын-кыз.

## 17

Түбән очта Яңа урам бар, тракторчы Мөнир шул очның Мифтахетдин улы икән. Нәҗиптән күпкә яшь булганга, алар бер-берсен белмиләр иде. Кыска һәм тиз таныштылар. Мөнир районга сөт ташый, хатыны Халисә төрле эштә йөри. «Кая кусалар, сөрлегеп шунда барабыз инде»,— диде ул, гел көлеп, елмаеп. Мөнир юлчыларның ару киемнәренә карап уңайсызланды: «Бидоннар арасында бик пычрак инде, утырыр урын юк. Председатель кеше утыртканны яратмый, эскәмия куйдырмый»,— диде Мөнир, председатель исемен катыштырып зарланырга ярамаганлыгын белсә дә. «Ярый, ярый, балаларны кабинага сыйдырсагыз, без түзәрбез»,— диештеләр ир белән хатын. Кабинага бер малай гына, ул да көчкә-көчкә генә сыйды. Кулына ике прәннек тоттыргач, аның шыңшуы бетте, Халисә апасы аңа авылда ике мөгезле сыер күрсәтергә вәгъдә бирде. «Ялганлыйсың! — диде малай, прәннек кимереп.— Сыерның мөгезе булмый!» Трактор арбасындагы җиде бидон арасына Нәҗип, Наилә, Искәндәр менеп бастылар. Чайкала-чайкала кузгалдылар. Малайга куаныч, арба янтайган саен аның күзләре куаныч белән тулды. Бидоннар бер якка өерелеп, арба ава язганда, ул кычкырып та җибәргәләде. Ата белән ана: «Батып калмасак ярар иде!» — дип, әллә кайчан югалткан Ходаларына ялварганда, трактор аксак арбаны сөйрәп әле быкырдык чокырларга барып керде, әле, корырак юлга чыгып, күңелле генә мырлады. Ирнә болынын җәфаланып, озак һәм интегеп үттеләр. Ничәмә-ничә мәртәбә үтеп-сүтеп йөргән Нәҗип Ирнә болынының шулкадәр киңлеген элек белмәгән икән. «Болай барсак, кайтып җитәбез!» — диде Наилә, Искәндәрне җилдән ышыклап, бот арасына кыстырып. «Белгән юк...— диде Нәҗип, күзен алгарак ташларга тырышып.— Анда бер чокыр бар, Җәһәннәм

чокыры дип йөртәләр...» Хәвефле чокырга җитәбез дигәндә, трактор туктады, мотор сүнде, кабинадан сикереп төшкән Мөнир, борынын тарта-тарта, алар янына килеп басты. «Ни булды?» — дип сорадылар Нәҗип белән Наилә икесе бертавыштан. Мөнир, карлыккан гаепле тавыш белән: «Ал тәгәрмәч төшеп калган»,— диде. Ышанмадылар. Нәҗип, кабаланып: «Тәгәрмәчсез ничек бардык соң без?» — дип кычкырды. Мөнир үзе дә бу хәлгә ышанып бетмәгән иде, аңлатып тормады, кулын җәеп, башын чайкады да: «Хәзер алып киләм, сез төшеп берәр җирдә ышыкланып торыгыз инде, яме»,— диде. Картузын батырып киде дә, иске сырмасының төймәләрен төймәләп, үзләре мең бәла белән үткән юлга борылды.

Башта Нәҗип җиргә төште, аннары үрелеп, биленнән ике кулы белән тотып Наиләне төшерде. Искәндәр: «Кермим, кермим!» — дип кәҗәләнсә дә, аны, «җилдә ябышып катасың киләме?» дип, этеп-төртеп кабинага керттеләр. Рөстәм, апасының итәгенә башын куеп, рәхәтләнеп йоклый иде. Ир белән хатын, бер-берсенә карарга читенсенеп, юл кырыена, корырак урынга чыктылар. Әче җил юл буе үзәкләренә үткән иде, юка плащларының якаларын тартып томалаганда, күшеккән куллар төймә каптыра алмыйча интектеләр. «Үзем, үзем!» — дип, Наилә Нәҗипнең төймәсенә тотынды, күзләр ихтыярсыз очраштылар. Нәҗипнең киңчә борын тишекләре суланган, иреннәннән кан качкан, эшләпә читләреннән бүселеп чыккан чәчләре учма-учма җилдә җилферди иде. Наилә тиз-тиз күзен читкә борды. Үзенең кыяфәте дә әллә кем булмагандыр...

Туктаусыз ерагая барган Мөниргә карап Нәҗип үзләренең шактый ук четерекле хәлгә тарыганнарын аңлады. Нидер эшләргә кирәк иде! Тычкан исе таратып яткан эскерт төбеннән салам йолыккалап, Нәҗип учак тергезергә, Наиләсен җылытырга ниятләде. Бәхете: тартмаса да, юлга чыккан мәлләрдә кесәсендә шырпы йөртә иде. Берне кабызды — ыргылып килгән җил сүндерде, чүгәләп, шырпыны плащ итәге белән томалап сызарга маташты — кабынмады, ярты капны исраф иткәч, ут күксел, черек салам учмасына йөгерде, ак пар һәм зәһәр ис таратып чожлады. Нәҗип тузынып плащын салып ыргытты. Җил уңаена очып барган болонья плащны Наилә эләктереп алды. Искәндәр, әтисенең ут белән уйнавын күреп, ишекне ачып җиргә сикерде, мәтәлеп китте, тезе, чалбары пычранды. Иренә баядан бирле җенләнеп карап торган Наилә үчне малайдан алды, «Юньсез!» дип, җилкә чокырына бер-икене кундырып, Искәндәрне кабинага дөмбәсләп кертте. Малай шыңшыды. «Җитәр, улама!» — диде төсе танымаслык булып бозылган Наилә.

Тракторчы һаман ерагая иде. Шушы кадәр араны тәгәрмәчсез ничек үткәннәр алар?

Нәҗипнең шырпысы бетүгә барды, кап юешләнде, кул дымланды, ә салам кабынмады. Ул, күбәләк куган бала сыман, күрмәс күзе белән курай эзләп ары-бире ташланды.

Аның акайган күзен, гарипләнеп иелгән гәүдәсен, чалбары астыннан бүселеп чыккан ак күлмәгенең итәген тамаша кылган Наилә, котырына башлаган нәфрәтен чак тыеп, камылларны сыта-сыта, басуда уем-уем туфли үкчәсе тишекләрен калдырып йөренә иде. Тракторчы һаман бара, ул утырган эт дәүмәлеге генә калды. Ялкау ир! Кыл кыймылдатырга да курка! Икәү барсалар, тәгәрмәчне тизрәк алып килерләр иде. Наилә күңеленең шашынганын, кан тамырларында кирелек, үҗәтлек, усаллык дулкыны ташыганын тойды, ирен бәреп җибәрәсе, җебегән кулыннан шырпыны тартып аласы, тирә-юньгә җылы түгел, күгәрек сасы таратып яткан эскерт төбен генә түгел, бөтен дөньяны яндырасы килде.

«Кулыңнан килердәй булмагач, нигә безне интектерәсең?!»

Хатыны авызыннан шушы сүз атылып чыккач, Нәҗип әүвәл трактор кабинасында утырган Халисәгә карады. «Ишеттеме, юкмы?» Пырдымсыз җил ул яктан бәрә иде, ишетмәгәндер, ишетмәве хәерлерәк: үзеңнән алда авыл арасына гайбәтең кайтып ирешсә, хурлыгыңнан кая барыр җир тапмассың. Ул сүз кайтармады, хафасын сиздереп, Наиләгә күз ташлады. Наиләнең йөзе ертылган, күзе ят, гәүдә тотышыннан тәкәбберлек һәм кирелек чәчрәп тора иде. Сул тезен алгарак чыгарып, уң кулын бөеренә куйган хатынына астан карый-карый, ул тагын шырпысына тотынды. Наилә уе, җаны белән моннан шактый еракта йөзә иде. Ул сердәше Гөлнараны, аның әкрен-әкрен рухы сына барган җебек ирен күз алдына китерде. Гөлнараның бичара ире, мөгаен, аның Нәҗибенә охшагандыр...

Хатын-кызларның ирләренә ихлас тугрылыгына багышлап том-том китаплар язылган, тарих чоңгылларыннан бу тугрылыкка меңәрләгән гыйбрәтле мисаллар табып була. Бусы хак! Бер үк вакытта мондый нәрсә бар: хатын-кызлар яраткан ирләренең язмыш тозагына эләгеп, бичара хәлдә калуларын кичермиләр. Без, ир-атлар, ир бәхетсезлеккә юлыккан очракларда хатыннарыбыз һәрвакыт ярдәм кулы сузар дип ялгыш уйлап юанабыз. Дөньяда ничаклы хатын-кыз булса, аларның табигате дә шул санга бәрабәр. Бер-берсенә тулаем охшаган ике хатын-кыз дөньяда юк. Белегез: хатын-кызлар кыен килгәндә җебеп төшкән ирләрен аямыйлар, кичермиләр, йомшаклыкны гафу итмиләр. Алар моны алдан уйлап, әзерләнеп эшләмиләр, аларның Ходай бирмеш холыклары тумыштан шундый, уй сөрелешләре шулай корылган, ир өчен җайсыз мизгелләрдә алар ирне сынарга, йә аны чыныктырырга, йә муенсыз калган ирне бөкләп аяк астына салырга тиешләр. Наилә ирен аяп, аны җәлләп һәм яклап, ялгыш-хаталарына

аклау табарга тырышып яшәмәде түгел, байтак яшәде, байтак түзде. Ләкин аның тамырларыннан тулышып аккан канның составы үзгәреп килә иде инде...

Саламга төкереп, бушаган шырпы кабын тотып тондыргач, Нәҗип үзен гаепләмәде, бәла-казаларының асылын дөньяга сылады, тормыш шартларын каргады, юньле трактор чыгара алмаган эшчеләргә дә эләкте, юл төзүчеләрнең ата-бабаларына бер-ике татлы сүз юллады, ахыр чиктә Наиләсе алдында гөнаһсыз күренергә омтылып: «Шушы якның каһәр суккан юлларын күрмәс өчен дә кайтмадым мин авылга! Авылның каргалган язмыш кичерәсен сизенгәнгә калдым мин шәһәрдә!» — дип сукранды, Нәҗип хәләл җефетеннән, әлбәттә, юату, теләктәшлек сүзләре көтә, уртаклыкка өметләнә иде. Ялгышты, Наилә аның туган авылына кайтып баруын, чирле икәнен, төшеп калган тәгәрмәчтә һич гаебе юклыгын беркавымга онытты. Шушы зәһәр җилдә, хатынын, ике баласын җылытырлык та әмәл таба алмаган ирне гел-гел гафу итеп буламыни?! Юк, андый ук төгәл фикергә барып җитә алмады Наилә, әмма аның хәзерге яман мәлдә кемнәндер ачу аласы, кимсетәсе, үзеннән дә, үз хәленнән дә түбән итеп күрәсе килде.

«Әй син, акыллы баш, шәһәрдә яшәп ни кырдың? — дип кадады ул.— Юньле кешене дөбердәтеп эшеннән кумыйлар. Юньле ир ата-анасы, туганнары белән дошманлашмый. Юньле ирнең абруйлы дус-ишләре була. Юньле ир хатынына елга бер күлмәк яңартырлык булса да акча эшли! Дачасы була аның, квартирасы, машинасы! Ниһаять, юньле иргә «псих!» дип келәймә сугып, кала буйлап кара данын чәчмиләр!.. Юньле ир, хатын-балаларын интектереп, акылдан шашканнар белән, наркоманнар, азган хатыннар белән янәшә, җүләрләр арасында сары йортта яшәп ятмый! Без шәһәрдән качып кайтып барабыз. Безне монда беркем көтми. Көтсәләр, пычрак арбада, сөт бидоннары белән тарткалашып, шашкан җилдә аягүрә кагаеп кайтыр идекме? Балаларга тагын суык тиячәк. Горчичниклар, дарулар, йокысыз төннәр. Аны син карамыйсың бит, хәсрәт, барыгызны да мин карыйм. Мин!»

Бүлдермәде Нәҗип, колак төбеннән выжлап исеп торган җил хатынның бер сүзен дә урламады, алып китмәде, күтәрергә хәле булмады җилнең, сүзләре аның колак бөтеркәсенә авыр чуерташлардай шыбырдап коелдылар, катлам-катлам булып күңел түренә тыгызланып утырдылар. Берәр заман аларны таратыр, котылыр көн булырмы?!

Наилә тонык күз яшьләре каплаган күрмәс күзе белән Ирнә үзәненә карады, кичке кояш нурларыннан алсу, сыек төсләргә манчылган болынга кара пута булып яткан юлда Мөнир күренми дә диярлек иде.

Ниһаять, Нәҗип телгә килде. Халисәгә ишетелмәслек итеп, теш арасыннан сытып соравын чыгарды: «Ни әйттең син, явыз хатын? Ни дип син минем талкынган җанымны ашыйсың?!» Наиләнең давылы басылмады: «Бүтән нәрсә беткәч, хатын ирен ашый башлый!» — диде ул, чатнатып. «Син минем үткер хәнҗәр тотып, юлбасар булып тар тыкрыкка чыгуымны көтәсеңме әллә?» — «Алар кем-нән ким? — дип дәвам итте мәсхәрәләп Наилә.— Әнә, Митя Шорохов кесә карагы, бур, ә күпме кешегә күз алдыбызда игелек күрсәтеп яшәде».— «Урлаган акчагамы?!» — «Урламаган акчага берәр кеше яшиме бу заманда?! Тирә-ягыңа бак, сукыр! Намуслы, гадел яшәгән берәүне тап! Гадел яшәр өчен син дәрәҗәгә омтылдыңмы? Син... син! Югары белемле, намуслы, ихлас кеше, карак Митя талап җыйган акча хисабына туган ягыңа кайтып бармыйсыңмы?!»

Наиләнең тоткасы сынды, бәйдән ычкынды, ул үзе дә моны абайлады, ләкин сүз — очкан кош, тотып кире кайтарырмын димә. Баягы аклык аклык булмаган икән әле, хәзер менә Нәҗип агарынды, ул, кулларын килбәтсез бутап, ирен араларыннан сүз урынына күбек чыгарып, күзен акайтып хатыны өстенә чак кына ташланмады. Әле ярый эскерт төбендәге әрлән казыган чокырга аягы батып егылды, эшләпәсе тәгәри барып сулы чокырга ауды. Халисәдән сагаю дәвере үткән иде. Нәҗип нәзек, әче тавыш белән: «Кайтмыйм мин авылга! Мондый хурлыкка түзәрем юк!» — дип чәрелдәде. «Хурлыкка калучы да, калдыручы да үзең. Мин моны сиңа әллә кайчан әйтергә йөри идем!»

Нәҗип: «Хатын сүзенә ияреп юлга чыккан мин тиле!.. Хәлле-хәлсез килеш авылга кайтып баручы мин җүләр!.. Хатынга сүз иреге биргән мин дурак!» — дип әрнеп кабатлады. Иллә мәгәр Наиләсе тыелмасмы дип авызын ачмады. Хатын-кызның буасы ир аркасында ерылса, беттең диген сүз, ачуы ташып бетеп, күңеле тәмам бушанмаса, аның тыелачагы да, аны тыяр көч тә юк. Наиләнең шундый котырынган чагы иде. Ул, үз-үзен белештермичә, елга булып аккан яшьләренә буыла-буыла, ир өстенә бар һәм юк гаепләрне өя бирде. «Кеше булган кеше әүвәлдә бүтәннәрнең кадерен белә. Синең ни кадерең булмады, кеше дә кадерләмәдең. Мине шушы кара көнгә төшердең, балаларны бәхетсез иттең. Ни дип искә алыр алар үткән гомерләрен? Сиңа ышанып кияүгә чыккан мин исәр... Сафуанов ни ялынды, идәндә тәгәрәп йөрде, өрмәгән җиргә утыртмам, җаныем, диде. Ә мин... Сапсыз балта белән агач егарга тотынган исәрне яр иттем. Күрексез гармун, чакмасыз мылтык син!»

Наилә Нәҗипнең йөрәк ярасына учлап-учлап тоз сипте: Сафуанов Наиләнең беренче йөргән егете иде. Алар танышканда ул өтек кенә бер слесарь иде. Комсомолда җил куып йөрде, профсоюзда тәлинкә тотарга һәм түрәләр узган юлларны себерергә, эз калдырмаска остарды, өлкә комитетына алдылар,

инструктор. Бүлек мөдиренең докладларын, чыгышларын гел ул яза, диләр. Ышаныч казанган, тук, пәрәмәч чырайлы егет. Наилә яшь чагында аның курнус борынныннан, сул як казнасында өскә калкып торган тешеннән җай чыккан саен көлә иде. Беренче тапкыр аның исемен күккә чөйде. Түгелергә торган мөлдерәмә чиләккә бер тамчы су җитә, чиләк тулды, тулышты һәм ага башлады — Нәҗип эһ тә итмичә арба өстенә сикереп менде, бүктәрләрне, әйбер-караларны берәм-берәм юл кырына тондырды. Кан баскан күзе Зәй ягыннан шуып килгәндәй кыймылдаучы Мөнирне шәйләп алды. «Кайта! — диде ул. — Кайтып килә теге!» — «Кайтамы?» — дип тотлыкты баядан бирле өзмәс очкылык тота башлаган Наилә, һәм пычракта кадерсезләнеп яткан әйбер-караларны кире чөйде. Нәҗип карышмады, юлның котсыз бушлыгы, салкын офыкка егылып барган май кояшының җайсызлыгы, чит хатынга сеңеп йокыга талган чирле ике сабые аны тыйды, ачуын яшерергә мәҗбүр итте. Кая барасың? Кая бара аласың?! Төптәнрәк уйласаң, Наилә байтак яктан хаклы. Тик нигә ул гаепләү актын хәзер, өметсезлек тулган юлда, хәсрәт диңгезенә батып барганда игълан итте соң?!

Нәҗип арбадан җиңел сикереп төште, Наилә кулыннан плащын тартып алып, җиңнәрен туры китерә алмыйча сүгенеп, сажин сала-сала Мөниргә каршы китте. Яхшы булды: әллә кайда, җәһәннәмдә төшеп калган тәгәрмәчне күтәреп килә-килә егетнең иңбашлары чиләнгән иде.

Мең газап белән тәгәрмәчне көйләделәр, киттеләр. Ир белән хатын арасы көйләнде. Гаиләдә торымнан-торымга була торган ызгыш-талашларның сәбәбе кайчакта онытыла, чөнки ир-хатын еш кына бөтенләй сәбәпсез ызгышалар, ә талашу урыны күңелгә уелып кала. Бу гауганың урыны истәлекле — эскерт төбе, тычкан исе чәчеп яткан салам өемнәре, буп-буш шыксыз юл, салкын кояш, зәһәр җил күзе булды.

Озакламый җилнең канаты салынды, көн суытты, кояш Кашка тау маңгаен каплаган куе нарат урманының эзмәкәйле очын сыпырып үтте, төссез, яшь ай урагына үрелергә чамалап азгын бер йолдыз кабынды, аңа икенчесе иярде, йолдызлар зәңгәр күктән кара ашъяулык тектеләр, юлаучыларны тагын да каушатып, төн килде. Ай яктысы әле саран, йолдызлар ишәйсәләр дә, алардан коелган нурда сәйлән җыярлык түгел, юл күренми, язын-көзен казылган хыянәтчел чокырларга майлы су тулган, тигез җирме, түмгәк-кантарлымы — белеп кара, баралар ава-янтая, баралар, бәла-казаларның азагы булыр сыман күренми.

Ике-өч сәгать «бетәбез, менә авабыз!» дип кан калтырап кайта торгач, билгесезлек пәрдәсендә сыек кына утлар җемелдәште. Нәҗип сәфәрләренең азагы якынлашуын, дөрес чамаласа, Югары авылның Яңа урамына җитеп килүләрен аңлады. «Дөнья елмаерга маташа сыман», — диде ул, сүзен төрлечә аңларлык итеп. Ул Наиләсенә карамаска, аңа якынлашмаска, кагылмаска тырыша иде. Аны өзмәс бер сорау кыйнады: мондый хәлдә киленне ата-ана йортына ничек алып керергә? Шалтырап, дөнья сасытып кайтып кергән ул белән киленне картлар ничек каршылар?

Урамга кергәч, трактор озак бармады, туктады, тынды. Тавышка уянган авыл маэмайлары, ялкау авазлар биреп, бер-берсен искәрттеләр, бәла-каза килсә, ярдәмнәрен дә ышандырдылар.

Тездән лай ера-ера, су чупырдатып, арба янына Мөнир килеп басты. «Итәкләрегезне күтәрегез, балакларны сызганыгыз, тотына-тотына төшегез. Халисәдән балаларны берәм-берәм алырсыз. Бездән башка Югары авылның югары очына менә алмассыз. Без сөйләштек: Халисә белән атаңнарга озатып куярбыз».— «Һи-и, хәзер үрмәләп тә менеп җитәбез югары очка!» — диде Нәҗип, арбадан төшә-төшә. «Урам аша үтәрлек түгел»,— диде Мөнир, Наиләгә төшәргә булышып. «Мөнир, ындыр артлатып меник!» — дип кычкырды Халисә. Ул кычкырган тавышка уянган малайлар көйсезләнә, шыңшый башладылар. Наилә, туфлиларына саз тулганны белсә дә, алар янына ашыкты, йокысыннан айнымаган Рөстәмне әтисенең иң өстенә менгерделәр, Искәндәрне Наилә җитәкләде. Велосипед, вак-төяк бүктәрләр Мөнир белән Халисәгә калды. Аяк астында су чупырдады, алдан гайрәт белән юл күрсәтеп Мөнир бара, аңа Халисәсе тагылган. Алардан калмаска тырышып, кунаклар караңгылыкның күзенә кереп баралар. Җеп өзәрлек хәлләре калмыйча, югары очка менеп җитеп, тыкрыктан Йосыф карт ихатасы турына үтеп, капка келәсенә тотынсалар, капка эчтән бикләнгән булып чыкты. «Гомергә капка бикләмәгәнне ни булган боларга?» — диде Нәҗип, кабынып. Наилә дәшмәде. Мөнирләр кайтырга ашыктылар: «Бездә дә ике бала!» — диде ул. Халисә: «Берсе имидә... Күкрәкләрем яман шеште, чыдар әмәлем юк!» — дип, түшен тоткалады. Мөнир: «Өсләреннән бикләп йөрибез, бакча-мазар юк, күрше әби күз-колак булгалый. Эзигә бармас идең, ачтан үләргә кирәк, ипи кайтармыйлар, он сатмыйлар, тегермән буасы киткәнгә күпме гомер узгандыр!» — дип, кайтучыларга әзрәк аң-белем бирде.

Нәҗип-Наиләнең үз кайгылары онытылды, юлдашларын җәлләделәр, «Көне буе ими капмаган сабый ничек түзде икән?» Ә монда аларны озатышып йөрделәр. Кунаклар авылдашларына чын күңелдән рәхмәт укыдылар. «Яхшылык җирдә ятмас»,— диде Нәҗип, нидер вәгъдә иткән сыман. Озатучы мәрхәмәтле җаннар китүгә, караңгыда шүрләүчән Искәндәр нәни йодрыклары белән капканы төяргә тотынды. Эчтә мыдыр-мыдыр сүз алышкан тавышлар ишетелде. Ут кабыздылар. Тәрәзәдән сүрән агылган яктылык капка төбен дә әз-мәз яктыртты. Ишек шыгырдады. Авыр аягын шудырып кемдер капкага якынрак килде, эндәште: «Кем йөри анда?» Әнисенең тавышы! «Без идек бу, әни,— диде көтелмәгәнчә йомшап Нәҗип,— без кайттык».— «Ай Ходаем, улым, синмени?»

Ишегалдында хәрәкәт көчәйгәндәй булды, болдыр ягыннан: «Әллә балалар кайтканмы?» — дигән хәлсез сорау ишетелде. Әниләре капкага аркылы салынган, баш-башлары тимер җәяләргә кертелгән бастырыкны тартып чыгара алмыйча интекте. Ниһаять, капка ачылды, иң өстенә шәлен салган ак күлмәкле әниләре, ак ыштан балакларын салындырып болдырда басып торган әтиләре күренде. Карт таякка таянган, сул кулын каш өстенә куйган, бөтен гәүдәсе суыктанмы, каушауданмы дер-дер килә иде. Күлмәк сәдәбен каптыра алмыйча азапланган әнисе арык куллары белән улын кочып алды. «Әби, мин сиңа күчтәнәч алып кайттым!» — дип, олы уллары Искәндәр суыра-суыра чәнти бармак башы хәтле генә калган шикәр кисәген авызыннан алып әбисенең учына салды.

**18**

«Җиде бабаңны бел!» дигән татар. Бу бездә иң олы васыять. Шушы васыятьне бозып, татарлыкка хыянәт кылган мөртәтләргә «Җиде бабаңны танытырмын!» дип янаганнар. Җиде баба — җиде буын. Чорына күрә буыннарның гомере дә, багланышы да үзгә булган. Йосыф картның әтисе — Сәхәбетдин, бабасы — Нургали. Хәтерли әле Йосыф, онытмый, әтисе белән бабасы бер кулның бармаклары булып яшәделәр. Тел уртак, дин-иман бер, бер төбәктә, бер теләктә саф татар карьясында гомер кичтеләр. Тормыш бертөслерәк аккан, гореф-гадәтләр, тайпылышсыз үтәлергә тиешле кагыйдәләр буыннан буынга күчә барган, яшәү нигезе булып әнә шулар хезмәт иткән. Дин — милләтнең таянычы. Рус мәмләкәтенең уртасында торып калган татарларны милләт буларак, тел-ил берлеге генә түгел, ислам дине дә яшәткән, аларны оештырып тоткан, милли рухны саклаган. Иван Грозный Казанны яулап алганнан соң күпме кимлекләр, җәбер-җәфалар күрсәләр дә, татарлар милли йөзләрен югалтмаганнар, чөнки дин яшәгән, дин саклаган. Дин халыклар күңеленә яктылык иңдергән, белем, гыйлем китергән.

Татарның һәр очракка ярашлы бер тапкыр сүзе, мәгънәсе тирән фәлсәфи, тапкыр мәкаль-әйтемнәре булган. «Ата хакы — Тәңре хакы», дигәннәр олылар, газиз ул-кызларының башын сыйпап. «Идел йорт — имин йорт», дип беркеткәннәр.

Әй, Идел йорт, Идел йорт,
Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт,
Иелеп тәгъзим булган йорт,
Анам килен булган йорт,
Иелеп сәлам биргән йорт,
Кендегемне кискән йорт,
Керем, куңым юган йорт!

Бәрәкәтле Идел йортка, татарларның алтын бишегенә багышлап ата-бабалардан күпме акыллы сүзләр, тәгъбирләр, мәкальләр калган. Тагын бик күп, бер караганда гади, әмма тыгыз эчтәлекле законнар буыннарны буыннарга ялгаган, нәселдән тамырга җырлар тапшырылган, тел бизәкләре, язгы күркәм уеннар, «Кырау куулар», «Нардуганнар» күчкән, мөнәсәбәтләр, кардәшлек чылбырлары, мәхәббәт кануннары, нидер үзгәргән, нәрсәдер кимегән, нидер өстәлгән, әмма Идел йортка самими мәхәббәт, туган телне олылау, бер-береңне ярату, хөрмәт хисләре Бөек Болгар заманыннан ук халкыбызда үзгәрешсез кала килгән. Татарлар гаделлекне, пөхтәлекне, чисталыкны яраткан, эш, кәсеп, һөнәр сөйгән, «илләр талап түгел, җир тарап» тамак туйдырганнар. Халыкта тәртип-низам нык булган. Ил агалары, аксакаллар, укымышлылар, дин әһелләре өчен халыкны гадел юлда тоту мәшәкатьле дә булмаган, чөнки татарлар урлашмаган, хатын аермаган, хәрам суларга баш бирмәгән, сасы Америка тәмәкесен йортына якын җибәрмәгән. Ишеген бикләмичә, капкасына терәү салмыйча, теләгән җиренә чыгып йөргән татар, күңеле ачык булган, ул юкта йорт-җиргә, мал-туарга ихлас күрше-тирәләр күз вә колак булып торган. Бер-берсен яклый белгәннәр, татар дөньясына яңа кеше — бәби килгәндә тыйнак сөенгәннәр, Ходага гыйбадәт кылганнар, кеше вафат булып бакый дөньяга китеп мәңгелеккә рихләт әйләгәч, сабыр кала белгәннәр, бәйрәмнәрдә акырышмаганнар, кайгыда үкерешмәгәннәр, мәгәр «сабанда сайрашканнар».

Күп гасырлар шулай яшәгән татар. Галимнәрнең исәпләве буенча, ислам кабул иткәннән соң Идел-Нократ тирәләрендә яшәп, йөз илле миллион татар мәңгелеккә күчкән. Йосыф картка җиде бабасының җылысы әле килеп җиткән, гомер елгасы бабалары салган эздән аккан, артык болганмаган, бусагалар, таш кыялар очрап уңга-суңга сикермәгән, татарның үзе кебек сабыр һәм мәһабәт булган. Йосыфка килеп җиткәч, тормыш кинәт үзгәргән, ил, дин, җир тоткаларын — авылның иң тырыш, иң уңган гали затларын ерак Себергә — эт җиккән якларга үләргә сөргәннәр. Фин, Ватан сугышы чыгып, асыл ирләренең сөякләре чит кырларда чәчелеп калган. Сугыштан соңгы афәтле елларда, ата — улны, ана кызны белми торган болганчык дәвердә, кешеләр, авылдагы җәбер-җәфалардан туеп, күпләп-күпләп татар җирен ташлап чыкканнар. Күпчелекнең күзе комсызланган, аңы томаланган, илгә рухи афәт,

кансызлык иңеп, шәфкать, мәрхәмәт читкә сөрелгән. Татарның таянычы, гомер-гомергә сафлык чыганагы булган иманнан көлү гадәткә кергән. «Татарлык — тарлык!» дигән татарның наданнары. «Фи-и, татарның гомере бер саплам, бетә ул, бетә!» дигән укыганраклар. Андыйлар көферлеккә иманнарын сатып, чит тамырларга әйләнеп, гаиләләре белән, сәхрә дүңгәләге сыман, урыннан урынга күчеп йөри башлаганнар. Күчеп йөрү чегәннәргә килешә, ул — аларның милли сыйфаты. Күчкән татар татар булудан туктаган, чит гореф-гадәтләргә баш биргәннәре: «Татар булып Рәчәйдә яшәү читен, ичмасам, балаларым шуннан котылсын»,— дип, исемнәрен тузга язмаган кушаматларга алыштырганнар, дөньяны Айрат белән Марат баскан, Дездемоналар, Венералар, Альбиналар, Кларалар котырып үрчегән. Авылда татар карчыгы ике-өч яшьлек сабыен җитәкләп урамга чыккан: «Диздимуны, танавыңны сөрт!» Тфү, нәләт...

Шундый кырлы-мырлы, имансыз дәвергә туры килгән Йосыф белән Мәрьям татар дөньясына уллар да, кызлар да китергәннәр. Элеккечә булса, бер оя булып, гореф-гадәтләрне саклап, телгә тугры калып яшиселәр иде дә, дөнья бозылды, авыллар таралды, халыклар чегәнгә әйләнде. Авыл ятим картлар, карчыклар гына сыярлык караңгы, фәкыйрь төбәккә әверелде. Картлар, әҗәл килгәнне көтеп, балаларыннан алган открыткаларына куана-куана, үткәндәге хатирәләрне сагынып, бабаларыннан килеп ирешкән риваятьләрне ятлый-ятлый җан сакладылар.

Йосыф белән Мәрьям дә, бил турайтып ял итәсе урында, үзләрен генә түгел, туган-үскән җирләрен мәңгегә ташлап киткән балаларын да ризыкландырырга мәҗбүр ителеп, ызан белән түтәлдән баш калкытмыйча интегәләр иде. Тәмуг газаплары күрде авылның бер буыны! Ничә еллар дәвамында бәйрәмнәрдә дә аларның ял иткәннәре юк, Кырым-Кавказларны, шәһәр дачаларын күз алдына да китерә алмыйлар. Җаен-кышын дөньяның аянычлы авыр йөген һаман тарталар. «Американы куып җитеп, узып китәргә» боерык алган бичаралар тәмам бөлгенлеккә төшкән илләрен каннарын биреп яшәтергә мәҗбүрләр. Алар, гаделсезлекне сизеп, үзләренең күрәләтә коллыкта яшәүләрен аңласалар да, авыз ачып сөйләшмиләр, телнең юл азагы хәерсез икәнен беләләр! Югары авылдан утызынчы еллар башында ничә гаиләне туздырып ташладылар. Утыз җиденең ноябрендә мәктәп директоры Хәернасны юк иттеләр. Хәернас артыннан мәктәпкә педтехникум бетереп эшкә кайткан ике яшь егет — Хәй белән Фаез юк булды. Авылның сөйкемле хәзрәте Юныс картны төн уртасында җылы түшәгеннән торгызып алып чыгып киттеләр дә шуннан «Алабуга төрмәсендә атканнар икән» дигән шомлы хәбәре генә кайтты. Сиксәнне ашкан бичара картның ни гаебе булды икән?! «Хәернасны күп белгән өчен, яшь укытучыларны күп сөйләшкән өчен юк иттеләр», — дип гөман кылды куркынган халык һәм озак елларга телен тешләде. Йосыф үзеннән бигрәк балалары өчен курыкты, төрмәгә тыкканнарның бала-чагасына да шәфкать күрсәтмиләр икәнен ул күз алдындагы байтак гыйбрәтләрдән күреп инанган иде. Яшәде — дәшмәде, нужа басса да, ыңгырашмады, кайгысын читкә чыгармады, авыл куштаннарының һәммәсенә бил бөгеп сәлам бирде. Казый итеп куйсалар, ата казга да сәлам бирәсең!..

Еллар үтә торды, ничек тормыш корырга, ничек яшәргә, авыл арасында гадел хөкемгә ничек ирешергә кирәклеген Йосыф карт бер баласына да тапшыра алмады, алар күз алдында комга чәчрәгән су кебек әллә кая, читкә сеңеп беттеләр. Ат җигәргә өйрәтә алмады ул аларны, балта эшенең нечкә серләрен тапшырмады, еракта калган бабалары хакында уллары белән гәпләшеп эчен бушатмады. Аның күргәннәре, белгәннәре беркемгә дә кирәк булып чыкмады. «Берәрсе кайтып килерме?» дигән яшерен өмете дә учак төбендә пыскып, сүнәр-сүнмәс кенә ята иде инде.

Моннан дүрт ел элек Йосыфның хәле китә башлады, мунча ләүкәсенә менмәде, төз лапас өстеннән малга печән ыргытмады, башы әйләнде, ике-өч тапкыр кан косты. Шиккә калдылар. Колхоз рәисе аны бик авырлык белән Эзи больницасына каралырга җибәрде. Унике чакрым араны карт җәяүләп бик әкрен үтте, ул көнне больница чиратына элгә алмады. Шунда больница баскычы төбендә кунды, иртән беренче булып врач катына керде. Соколова фамилияле, йомшак телле, зур зәңгәр күзле, бөкре - врач карады аны. «Өч-дүрт көн ятарга туры килер»,— диде Вера Павловна. «Өч-дүрт көн? Эш өстендә кем рөхсәт бирсен миңа?» Черәеп карышты чирле карт. Вера Павловна да үзсүзле доктор иде. «Ятасың!» — диде. Картны юындырып, ак күлмәк-ыштан кигертеп, ят исләр аңкыган бүлмәгә кертеп яткырдылар. Өч көн буе тынгы бирмәделәр дисәң дә ярый, үлчәделәр, тыңладылар, әйләндереп-әйләндереп карадылар, бөтен тамырларыннан кан алдылар. Йосыф: «Кайтам, кайтам!» — дип дулагач, дару, киңәшләр биреп озатып калдылар. «Тагын киләсең булыр!» — диде картның кабалануының сәбәбен һич аңламаган Вера Павловна.

«Килмәм, Алла кушса, терелдем», — дип чыгып киткән Йосыф ярты юлда кан косып туктап калды.

Рәис хәтәр кеше иде, элек райкомда эшләгәндә, гаеп-кыегы чыгып, аны иң фәкыйрь колхозларның берсенә баш итеп җибәргәннәр. Җәзасы шул булган...

Ул больницадан кайтып килүче картны ал байраклар җилфердәгән урында, идарә янында каршылады. Врач биргән язуны ертып ташлап: «Әгәр иртәгәдән эшкә чыкмасаң, бәрәңге җиреңне кисәм, малларыңны кырга чыгартмыйм»,— диде. Канын космады бу юлы юаш карт, канын йотты, җиңе белән иренен сөртте, икенче таңда колхоз көтүен кырга алып чыкты. Сыер көтә иде ул елны Йосыф. Ала-кола сыерларны иркенгә, Тегермән тавы итәгенә тараткач, хәл таба алмыйча, төнлә

сибәләп үткән яңгыр дымландырган чирәмгә утырып, авызын учы белән каплады. Иртәдән бирле аңгыраеп торган башының әйләнүе кимеде, чишмә авызына барып битен-күзен чылатты, битен талгын җилгә куеп торды. Берзаман сыерлар шомраеп, мөгезләрен күккә күтәреп, бер якка савылып күчә башладылар. Йосыф аны-моны абайлаганчы күпчелек сыерлар мөгезләрен усал чайкап, тояклары белән җир тырнадылар, яшьрәк маллар койрык чәнчеп ферма ягына томырылдылар. Малларны туктатыйм дип, юк тамагы белән кычкырып, хәлсез кулы белән таяк болгап торган карт каршысына төлке килеп чыкты. Аның йоны иеп сирәкләнгән, пычрак койрыгы җирдән сөйрәлә, бер колагы башына ябышкан, тешләре ыржайган, авызыннан туктаусыз сары селәгәй ага иде. Куркудан Йосыфның кыска таягы җиргә төшеп китте, каушады — төлкенең котырган булуында аның шиге юк иде. Яшьрәк маллар качып өлгерсә дә, күәс-күәс имиле нәселле терлекләр әллә кая ерак китмәделәр, зәңгәрсу томан белән өртелгән күзләрен алартып төлкегә карап туктап калдылар. Кырда төлке күреп гадәтләнгән малларның исе китмәде. Төлке кинәт уңга ыргылды — бер сыерның җиленен каптырды. Сулга сикереп иң юаш, иң сөтләч сыерның сыйрагын тешләде. Йосыф карт хәтәр эшкә юлыкканын аңлап, иелеп җирдән дәү ак таш кубарып алды да төлке өстенә таба китте. Төлке аңа каршы сикерәм дигәндә, көч каян килгәндер, ташны төлкенең ике күз арасына тондырды. Туры тидерде, төлке бер урында әйләнергә, шыңшып чинарга тотынды. «Әһә, тәмсезме?!» — дип шатланды карт. Икенче таш, тимәсә дә, төлкенең аяк арасына барып төште, төлке ырылдап артка чигенде. Бая сыйрагы тешләнгән сыер, хуҗасына ярдәм кирәклеген сизепме, алагаемга чабып китте, шашкан җанварны мөгезләренә элеп чөеп тә җибәрде. Өченче ташны кубарып маташкан Йосыф карт күтәрелеп караса, төлкедән җилләр искән...

Котырган төлке, монда килешли, күрше авылның сарык көтүе уртасына чабып кереп, байтак хайванны яралаган икән. Күршеләрдә мәргән күзле атаклы сунарчы бар иде, хәлне аңа җиткергәннәр, ул җәлт әзерләнеп эз буйлап чапкан һәм бер атуда «төлке, төлке-төләйманны» атып еккан. Аны шунда, тау кашлагында күмгәннәр дә...

Күрше авыл сарыклары мәэкләнә башлауга, шау-шу куптарып, төлкене казып алып, башын кисеп, самолет белән Казанга җибәрделәр. Шул ук самолет белән башкаладан биш кешелек комиссия килеп төште. Алар килгәнче Йосыф көтүендәге сыерлар да котыра башлаган иде инде. Сыерлар яман мөгрәп, нык абзар-кураларны ватып-җимереп, биек-биек киртәләрне сикереп чыгып, кем күренсә, шуны куа, бер-берсен канга батырып сөзәргә тотындылар. Авыл халкы нишләргә белмичә хафада калганда, комиссия котырган малларны атарга, үләксәләрен яндырырга боерды. Чирле, шикле хайваннардан котылгач, кешеләрне карарга чират җитте. Кемнәр төлке кагылган мал-туар белән аралашкан да кемнәр сөт эчкән, кемнәргә чир йоккан булуы ихтимал. Котыру авыруының шундый хасияте бар икән: вегетация чоры, ягъни башлангыч дәвер үтеп китсә, беркемне коткарып, саклап калып булмый икән!

Сөт эчмәсә дә, сыерларда мәэкләр күренүгә, Йосыф карт аларны тотып ябарга, муенчак, тышау салырга азапланган иде. Аны көне-сәгате белән Эзи больницасына салдылар, казанлылар тиешле күләмдә гамма-глобулин да, Сирия әрләненең бөереннән ясалган махсус дару да алып килгәннәр иде. Йосыф картны бу юлы да Соколова каршы алды. Үзгәргән врач, йөзенә курку чыккан, тавышы корыланган. Ул Йосыф картның нужадан бөкрәйгән аркасын элеккечә кагарга бер дә ашыкмады.

Алты сәгать саен кададылар Йосыфка уколны, икеләтә арттырып кадап карадылар, картның хәле сәгатьтән сәгатькә начарланды, тамыр тибеше югалыр дәрәҗәгә җитте. Җирле табиблар да, Казан белгечләре дә аптырашка калдылар. Соколова көне-төне карт яныннан китмәде. Йосыфның йөзеннән кан качты, яңак сөякләре бүлтәеп чыкты, сулышы өзелеп-өзелеп алды, кан басымы бер өскә сикерде, бер төшеп китеп югала язды. Картның организмында табиблар белә алмаган нидер бар, аңа электән килгән чирләр куркыныч яный дигән шиккә килделәр. Вера Павловна үткәреп ни дә әйтә алмады, теге чакта ярым-йорты ясалган анализлар, картның сүзсезлеге, чирен эзләшергә булышмавы икеле-микеле фаразлардан ерак алып китмәде. Антирабик уколларны туктатырга, картның әүвәлге чирләренә борылып кайтырга туры килде. Бу юл хәтәр, хәвефле иде: элекке чирләрен эзләп төпченгән арада котыру чире бөтен нерв системасына үтеп керсә?

Нидер сизенгән, шикләнү генә түгел, курка ук төшкән колхоз председателе Соколованы аерып алып сораштырды. Вера Павловна: «Әллә Нургалиевне агулы ашламалар тирәсендә артыграк тоттыгызмы?» — дип сорагач, карасына коелып чыгып китте.

Мәрьямбикә дә картын юллап барды, «хәле әйбәтләнә, әлегә янына кеше кертергә ярамый» дип, аны борып чыгардылар. Колхоз рәисе: «Сез аның кем атасы икәнен беләсезме?! Терелтегез!» — дип боерып киткән иде, Йосыфны райком секретаре дәвалана, ял итә торган палатага күчерделәр һәм көне-төне күзәтү астында яткырдылар. Кризис үтте, котыру чире килмәде, өзлегү сәбәпләре һәммәсе өчен сер булып калды. Өч ай ярым дигәндә аны больницадан чыгардылар. Әле өй арасында йомышка-юлга ярап торган, колхоз көтүенә чыгарлык хәлле кеше булып киткән Йосыф больницадан күзе, колагы һәм хәтере начарланган инвалид булып кайтып керде.

«Бар, йөр, карал, группа бирерләр!» — диде аңа авыл укытучылары. Йосыф башын чайкады, һичнәрсәгә исе китмәде, бирсәләр, ашады, бирмәсәләр, ач карынга ятып йоклады. Берни белән кызыксынмады, сорашмады, башыннан кичкәннәрне телгә алмады. Балалары хакында элек

сөйләшмәскә тырышалар иде, хәзер алар бөтенләй телдән төште, онытылды. Картның бердәнбер юлдашы һәм сердәше булып чикләвек агачыннан ясаган шома таягы калды. Йоклаганда караваты кырына куеп ятты, йорт-курага чыкканда да алды, үзеннән калдырмады.

Истә-оста югында, инде дөнья белән бәхилләшәсе сәгать сугар дип мыштырдаганда, төн уртасында капка кактылар...

«Кем, Газраилме?» Түгел икән, ата-анасының хәер-фатихасыннан йөз чөереп чыгып киткән, икеллык солдат хезмәтеннән соң да туган төягенә кайтып баш имәгән горур, тәкәббер, һавалы уллары Нәҗип кайткан икән.

Мәрьямбикә эссе табага басты, тыпырдый, очына, оныкларының әле берсенең, әле икенчесенең аркасын барып кага, ни кылырга белми, башы тәмам миңгерәүләнде... Йосыф карт төнге ыгы-зыгыга да гадәтенчә битараф калды, кайтмадылармы — кайтмадылар, кайтканнар икән — әйбәт иткәннәр. Берара ике яктан да сораулар ишетелгәләде, әмма ләкин бу сорауларга җавап бирелмәде, — кунаклар да, хуҗалар да җавапларны аңларлык хәлгә бик озак килә алмадылар. Әбиләре туктаусыз: «Менә син, агай! Менә син, агай! — дип кабатлый да йөзенчә кат: — Ничек кайтасы иттегез?» — дип сорый.

Бер-берсенә күз иялəшә төшкәч, очрашу үз сукмагын тапты тагын. «Үзегез ни хәлләрдә яшисез?» — диде Наилә, Рөстәм кулыннан күмәчле төенчекне сиздерми генә тартып алып. Карчыкның күз яшьләре кипте, аңа эшлекле кыяфәт кайтты, тиз арада киеп алган, терсәкләре кат-кат ямаулы күлмәгенең җиңнәрен сызганды. Җиң сызганса, татар карчыгының рәте-торышы үзгәрә. Наилә, җиңе сызганулы әнкәсенә карап: «Балаларны юындырып аласы иде, әни. Аларны урынга яткырырлык түгел», — диде. «Күршеләрнең мунчасы суынмагандыр әле», — диде Йосыф карт, зиһене таралган карчыгын коткарырга теләп. «Килен! — дип кычкырды биана, ике кулына бер эш табылуына куанып.— Әйдә, барыйк. Үзең дә юынып чыгарсың». Бүктәр чишеп маташкан Наилә: «И, шулай итикче, монда чупырдап ятканчы, мунчага барыйк»,— дип, әнисе сүзенә кушылды. Күчтәнәчләрне хәзер бирергәме дип иренә карады да, аның җан кермәгән карашын очраткач, нәрсә-караларны җыештырыбрак куйды. Матавык арасында эш табылгач, биана да, килен дә бер мәлгә җиңеләеп калдылар. Наилә Рөстәмне күтәрде, әбисе Искәндәрне җитәкләде, алар «ә» дигәнче күздән юк булдылар. Нәҗип этисенең сүзсезлегенә, сорашмавына башта гаҗәпләнде, аннан рәнҗеде, соңра кызганды: ай-һай, дөнья картны сыккан икән! Тавышлар басылып, төнгә, йортка гадәти тынлык кайткач кына, Йосыф төссез, тәмсез тавыш белән: «Мунчага күршеләргә йөрибез»,— дип сүз катты. «Үзегезнең мунча ярамыймыни?» — дип, җимне эләктереп алды Нәҗип. Әтисе таягын идәнгә шакылдатты: «Шулайрак,— дип ачыклады.— Түбәсе ишелде, улым».— «Кайчаннан?» — «Дүрт ел буладыр инде,— диде карт, күңеленнән озак кына санап. — Юк, бишкә үк киткән икән». Картның бот арасына кыстырган таягы идәнгә төшеп китте. Ул таякны куып тотарга теләп талпынды, ала алмады, йөткерде, тыны бүленде. Нәҗип таякны алып биргәч тә, тиз генә игә килә алмады. Аларның күзләре очраштылар. Күзенә карап ул этисен танымады: кашы коелган, керфекләре сирәкләнгән, кабаклары җепшеп салынган күз тоньк һәм җансыз иде. Борын яфракларыннан ирен читләренә тирән-тирән җәя — нужа буразналары яткан. Муены, ияге, күптән сөрелмәгән ташландык кыр сыман, чүп-чар — ак-сары төкләр белән капланган. Гел күгелҗем таплардан гына торган кул тиреләре аша юан-юан кан тамырлары бүрткән. «Сабит кайтып мунча түбәсен дә ябып китә алмаган икән!» — дип уйлады Нәҗип, рәнҗеп. Карт тонык, җансыз күзләренә көч бирергә теләп астан өскә, аның күзләренә озак кына карап торды.

Әтисенең сүзсез серлелеген, өй эченең моңсулыгын арттырып, мич артыннан чикерткә тавыш бирде. «Мунча түбәсен Сабит яба алмый идеме?» — диде Нәҗип, бүтән уйны башына китерергә теләмичә. «Каян вакыты булсын аның?! — диде карт.— Колхозы алдынгы, андый җиргә кунак арты кунак ташыйлар. Казаннан да киләләр, имеш. Чаллысы якын, Мәскәүдән дә сыйланырга киләләр, диләр. Әллә ялган, әллә чын: хәзерге заман кешеләренең авызы ашаганда гына ачыла, имеш. Беркөн, Мәскәүдән кайткан олы кунакларны да абыеңа алып барганнар, дип сөйләп тордылар. Кем сөйләгән иде соң? Анысы истә калмаган, гөнаһ шомлыгы. Хәбәрләр йөри, сирәк-мирәк безгә дә килеп җитә, үзен бик күптәннән күргән юк. Хәзерге рәисебез — Сабит эшләгән авыл кешесе, шуннан килде, мәгәр аның безне санлап кергәне юк».— «Яхшы кешеме рәисегез?» — дип кызыксынды Нәҗип. «Кем белгән аны? Коммунистлар эшне шома йөртә, эт белгәнме аларның кем икәнен? Җылан да җылан, болар да җылан!»

Әйткәнебезчә, Нәҗип Сабит абыйсы белән хат алышмады, бүтән туганнары белән дә арадашлыкны өзгән иде. Энекәшләр, Сабитка ярарга тырышып, аның киңәшен тоттылар, икесе дә армия хезмәтеннән кайтмадылар. Берсе, лейтенант погоннары таккач ук, Ерак Көнчыгышта, Кытай чигендә Краскинода калды, икенчесе, кадерле төпчекләре, ата-ананың өмете, токымның варисы, марҗага өйләнде дә Мурманскида төпләнде. Өйләнгәннән бирле аның да күзгә-башка күренгәне юк. Сабит Нәҗипкә дә: «Кал армиядә, өс-башыңны дәүләт карый, тамагың тук. Атом сугышы башланса, бу сугышта халык

кырылып бетеп, армия генә исән калачак. Ә сугыш булачак! Америка империализмын себереп түкмичә безгә якты көн булмаячак!» — дип язган иде. Нәҗип абыйсының киңәшен тотмады, аның үз исәбе бар иде.

Нәҗип кактырып-суктырып бүтән туганнарының язмышын белешкәләде, этисенә кыска-кыска сораулар бирде, картның белгәне дә әллә кая барырлык булмады. Йә сорауны ишетмәде, җавап биргәндә дә җәелеп китмәде: «Исән-саулар бугай... Бәйрәмгә открытка салганнар ие, кайтканнары, күзгә-башка күренгәннәре юк!»

Киткәннәр мунчада хәйран юандылар, этисенең табынны караштырмавы, самоварга тотынмавы гаҗәп тә, ачу китергеч тә иде. «Кеше юлдан тук кайтамыни?» — дип пошынды Нәҗип, балаларын уйлап. Һәм уйлары таркау, җыелмаган чакта: «Кайттык әле, көн булырбызмы, ай торырбызмы, җәйне монда үткәрербезме, ныклап ял итәргә исәп!» — дип ычкындырды.

Ах, шул сүзен ашыгып әйтеп ташламаган булсачы!.. Соңыннан бик нык үкенергә, тел очын чәйнәргә туры килде Нәҗипкә.

Карт бу хәбәрдән очынмады, иягенә терәгән таягы гына атынып китте. Шактый утырганнан соң: «Алай икән, алай икән»,— диештереп ияген какты.

Өйалдыннан тавышлар килде, ак сөлгегә биләгән иркәсен күтәреп, Наилә кайтып керде, Мәрьямбикә күренде. «Йокым килә, урын җәегез! — дип, Искәндәр мыркылдады. Наилә Рөстәмен сәкедәге мендәргә илтеп яткыргач, самоварга барып тотынды. Мәрьямбикә, Искәндәргә урын җәеп биргәч, күзен күтәреп карамыйча гына, табын әзерләргә кереште. Биана белән килен ир-аттан башка гына очраша алуларына, танышуларына сөенештеләр. Мәрьямбикә карчык, улы югында, ишетмәгәндә, Казандагы тормышларын бик җентекләп, вакчылланып сораштырырга, төбенә тоз салырга ашкынса да, Наиләнең капчыгы алай ансат кына чишелмәде. Ул бик гади генә: «Яшәп ятабыз шунда... Әле тормышның җайга салынып беткәне юк... Көйләнеп кенә киләбез... Шәһәрдә ярдәм итәрлек якын кешеләрең булмаса, тернәкләнү читен...» — дип, шуларга вак-төяк өстәп, хәбәрләрен тәмамлап куйды. Нәҗипнең чирен дә, эшсезлеген дә, бүген юлда пычакка пычак килеп талашуларын да әйтеп тормады...

Мәрьямбикә шәрә өстәлгә юа-юа чит-читләре чачакланган шакмаклы ашъяулык җәйде, чоланнан балчык чүлмәк төбендә калган сөтне алып керде, юка гына ике телем ипи китереп куйды, үзе бертуктаусыз: «Кайтырыгызны белмәдек шул, кайтырыгызны!» — дип кабатлады. Өстәлгә карап, аның шушы кыска җөмләгә никадәр ачы мәгънә сыйдырганын аңлау кыен түгел иде.

Чәй кайнап чыкканны көтмәделәр, уяныр-уянмас яткан Искәндәрне табынга дәштеләр, сапсыз чынаякка сөт агызып, кулына ипи тоттырдылар. «Аша да йокларсың!» Малай телемне күз тирәсенә китереп карады да умырып капты, телен бер-ике әйләндергәч тә: «Тәмсез!» — дип кычкырып җибәрде. Наилә аңа йодрык күрсәтте, ипинең ләчтәлеген, бармакка сыланып торганын ул күреп өлгергән иде инде. «Кайтырыгызны белмәдек шул, белмәдек»,— дип оялып тәкрарлады карчык. Искәндәр ипине чәйнәмичә генә йотты да тыгылган тамагын сөт белән юып җибәрде. Аны энесе янына, сәкегә илтеп яткырдылар.

Табын шулкадәр ярлы, арык иде ки, ашап тамак та, карап күз дә туярлык түгел иде. Нәҗипнең җылыйсы килеп китте, күңеле тулды: «Бер түтәрәм каклаган казлары, бер йомарлам ак майлары да юк микәнни боларның? — дип өзгәләнде. «Сыер асрамыйсыз, ахры?» — дип сорады Наилә, сер бирмәслек күтәренке тавыш белән. «Хак, хак, килен,— диде Мәрьямбикә карчык,— сыйлы көнең сыер белән, тик менә ни, казалы булдык, сыерыбыз үлде.— Аның ireннәре өзелеп төшәргә теләгәндәй калтыранды.— Бик олы казалы булдык. Өч кыш бер кәҗә асрап чыгардык, әнә биргән сөте шунда. Каймак-май күрә алган юк».— «Кибеткә май кайтармыйлармыни?» — дип сорады Нәҗип, аны-моны уйламыйча. «Кибеткәме?— дип сорады Йосыф.— Югары авылда сыер өч кешедә калды, бүтәннәр асрамый. Май кибеткә каян килсен? Завод трубасыннан май чыкмыйдыр ла?! Сыер асрар хәлләре булганнар авылда калмады, алар май-каймак ашарга калаларга күченеп бетте». Карчыгы аны куәтләде: «Егәре барлар юк хәзер, Ходай кушкандыр инде, авыл таралды».

Сүзне ашау-эчү, табын тирәсеннән ераккарак йөртергә кирәклеген аңлаган кунаклар кабыл-тибел күршеләрне сораштыргандай иттеләр. Мәрьямбикә карчык Наиләнең әти-әнисе хакында белеште: «И дөньялар, кода-кодагыйлар белән күрешкән дә юк лабаса, ни булды икән безгә?» — дип җыламсырап та куйды. Картның йомык авызына ымсынып карап торгач, Мәрьямбикә карчык сүз җебен үз кулына алды. Югары очтан башлап түбән очка кадәр өй борынча йөреп чыкты. Кем кайда, бала-чагалары ничек, кем өйләнгән, кем аерылган, кемнәр яңадан кушылган... Кемнәр былтыргы сабан туена кайтканнар да нинди бүләкләр, күчтәнәчләр таратканнар. Кемнәрнең оныклары кайда укый, кем булырга укый — Мәрьямбикә боларның барысын да белә икән, хәтере нык икән әле карчыкның. Бөтенесен белә, хәтерле, менә үз балаларына чират җиткәч кенә, аның сүз җебе шартлап өзелеп-өзелеп китте, сөйләр сүзе калмады. Ул яңадан югары очка, күрше-каршыларга әйләнеп кайтты: «Күршең үзеңнән әйбәт икән — тормыш бара. Күршелеккә юньле адәм калмады. Өй аша Мостафалар бар иде, беләсеңме икән, Чүтинекеләр дип йөртәләр иде, шуның хатыны Гөлгенә бер чытыр арба печән урлап тотылып, өтермәнгә яптылар бичараны. Ул өтермәндә чакта Мостафасы Эзигә барып марҗага йортка

керде дә, алар әллә кая салкын якка чыгып олактылар. Өч ел үттеме икән, Гөлгенә өтермәннән кайтып төшмәсенме! Үзе генә түгел, үзе сыман чәчрәп торган бер хатын алып кайткан, тегендә ахирәтләр булып, бергә ашап-эчкәннәр диме. Алагаем чуендай кап-кара, татарча бер авыз сүз белми, якут диме, макут диме,— бер дә пырдымсыз хатыннар булып чыктылар. Күрәләтә тавык урлыйлар! Ишегалдына кер эләрмен димә, шундук юкка чыга. Күз буалармыни, оядан күкәй югала. Элгәре заманнарда капка бикләп, ишек элеп йөргән юк иде, хәзер кая ул, бетте! Чоланда он тормый, ярмаңны калдырмыйлар да калдырмыйлар. Төнгә керүгә, терәү салып, бикләнеп утырабыз. Морҗаңнан төшәрләр, шонныклар! Бәрәңге утыртмыйлар, ындырларын бакра белән билчән басты, шепкән котырды. Төн туды исә бурлыкка чыгалар, ярканатлар!» «Колхозда эшләмиләрме?» — диде Наилә, сүз булсын өчен генә. «Калхузда? Сыер саусыннармы? Ул шөкәтсезләргә кайсы сыер сөт бирсен?! Исләреннән косарлык... Тирес түксеннәрме? Түгәләр, көт! Тамакларына ничек үтәдер, урлаганнарын эчеп бетереп баралар». - «Эчәләрме?» — диде Нәҗип, авызын учы белән каплап. «Һи, эчмәгән кая! Шешә төбенә кереп утыралар. Авылда эчмәгән кеше юк, аяксызы-күтсезе шуышып йөри башлый — анысы да шешәгә үреләгөнаһ шомлыгы! Минһаҗ абзаң эчүдән үлде. Соскан, соскан, тын юлына бәрәңге барып утырган. Аның күк балта остасы юк ие тирә-якта. Һы-һы, Габделхәйне әйт, сабан туе батыры иде бит мәрхүмкәй, эчте-эчте дә, урман уртасындагы иң карт имәнгә барып асылынды. Менәтерәк! Эзли-эзли табансыз калдылар. Районнан чутсыз килде милиция, карга җыелганнан аңышып кына таптылар. Хатын-кызы эчә бит хәзер, кияүгә китмәгән кызлар аяк тибә-тибә җырлап чөмерәләр. Мәликә тутаң,— һай, бар иде сылу чаклары,— эчте-эчте, Ходай күрсәтмәсен, ботын-чатын аерып күпер төбендә аунады, кыланмаганы калмады, сумашешнийга яптылар. Чыгарсаң, ирләрнең бугазынаябыша, ди. Әллә ничә кешедә бума зәхмәте, тик торган җирдән авалар да тәгәриләр. Күрмәс өчен әҗәлеңне ашыктырырсың, валлаһи! Җыелганнарга кәмит: «Макмырлары чыга!» — дип, авыз ерып шаркылдыйлар да үзләре үк баш төзәтергә китәләр».

Йокы килү кунакларның кыяфәтенә чыкты. Нәҗип белән Наилә, авызларын читкә борып, алмаш-тилмәш иснәделәр. Йосыф картның башы аска иңеп-иңеп киткәләде. Ниһаять, Мәрьямбикә карчыкның сүз чишмәсе саеккандай булды. Саеккан саегуын, әмма ләкин бетеп җитмәгән икән, төп фикере тел төбендә икән: «Менә шулай яшәп ятабыз авылда. Ипи пешермибез, он сатмыйлар, тегермәннәрне җимерделәр. Эзидән ипи кайтса кайта, кайтмаса — юк, кайтарсалар да безнең ише карт-корыга тәтеми, хәзер арт ишектән бүлешеп бетерәләр. Берәүләр икмәк белән мал-туар симертә, безнең ишегә туя ашарга да юк. Көчленеке мал-туар белән, чучка асрый хәзер татар, ипекәйне улагын тутырып тыгындыра, чүмәлә тиклем бишәр чучка асраучылар бар! Әнә ачкүз Таҗетдиннар чучкаларына ак он болгатып тыгындыралар, ди. Ник симермәсен ул каты борын, ник көрәймәсен? Көзен, кырпак төшүгә, суялар да Әлмәткә алып китәләр. Анда да шул нефтәдән башка шымытыр да юк икән. Ит тә, май да, нефтьчеләрнең сүз әйтергә авызлары да юк, ди!»

Карчыкның хәсрәтле сүзләренә каршы төшмәделәр, хупламадылар да, сүзсез диярлек, күзләрен челт-челт йомып, ияк кагып утырдылар. Мәрьямбикә: «Сезгә чоланга җәйсәм, туңмассызмы?» — дип сорады. Улы белән килене, торып басып, тиз-тиз ризалаштылар. Чоланга икән чоланга, тинтерәгән башлар куярлык йомшак мендәр генә булсын!

Чәйдән калган кайнар суны Наилә комган белән салып торды, Нәҗип, тәрәзәдән төшкән яктыга чыгып, ишегалдында кыска арада юынып алды. Төн тынлыгын бозарга теләмәгәндәй, берни сөйләшмәделәр. Чоланда салкын толып астына тәгәрәгәч тә, бер-берсенә якынаерга теләмичә, чит-читтә яттылар. Май төне шактый суык иде, иртәнге якта җил күтәрелеп, чоланның тишек-тошыкларыннан шактый ук өрә башлады, ир белән хатын ирексездән бер-беренә тартылдылар. Наилә, йокымсырый башлаган ирен сискәндереп: «Трактор тәгәрмәчен Мөнир сазда ничек кигертте икән? Ни белән беркетте?» — дип сорады. Нәҗип, кырыс тавыш белән: «Юк-барны уйлап ятмасана!» — дип, хатынын сүздән бүлдерсә дә, хатыны сүзенең дәвамын, сөземтәсен эзләргә тотынды. «Димәк, Наилә юлда кайткан чакларны, трактор ватылып торган минутларны уйлый... Йөгәнсезләнеп кычкыруларын исенә төшерәдер... Үкенәме, юкмы? Әллә юлда дөрләп киткән ялкын монда да пыскыймы? Әтиләр арадагы салкынлыкны сизәләрдер. Ата-ана күңеле сак була! Белә калсалар, барыбызга да читен булыр. Читен, ямьсез булыр... Картларга бигрәк тә...»

Авыл патшасы әтәч кычкырды. Әтәч — авылның байрагы, таңның шаһиты. Нәҗип шул балачак тавышын ишеткәч сикереп торды, чолан ишеген тавышсыз ябып, ишегалдына чыкты. Төнлә күренмәгән тирә-ягына кызыксынып, сагышланып карады. Өй бүрәнәләре череп, муртаеп беткән, төртсәң таралырга гына торалар. Нигезниргәләр зыян күргән, алар, сары череккә әверелеп, бер-берсен сытып кергәннәр. Өй күзгә күренеп чүккән, тәрәзә борыслары чалыш-чолыш кыегайганнар.

Читәннәр йолкынган, баганалар ауган, бүрәнә башларындагы божан тишекләренә сүс тутырганнар да аннан-моннан кызыл балчык белән сылаганнар. Капка баганалары, «Без монда басып торып ардык шул» дигән сыман, як-якка авышканнар. Кичә Искәндәр дөбердәткәнгә ничек аумаган бу капка?!

Кәҗәсен савып бетереп, сөтле чүлмәген беләгенә кыстырган Мәрьямбикә улы янына килеп басты да, Нәҗипнең озынлыгыннан, күзләре ераклыгыннан куркынган төсле, читкәрәк тайпылды.

«Кайтырыгызны белмәдек шул, улым, кайтырыгызны!» — дип авыр сулады. «Белсәгез, нишләр идегез, әни?» — диде Нәҗип, кичәге очрашудан бирле шушы сүзгә әрнеп. «Бәй, коймак изәрлек он табар идек, мунча яккан булыр идек. Югыйсә күрче чалбарыңны, язгы пычрак муеныңа менеп җиткән ич!» — «Мунча түбәгез ишелгән түгелме?» — «Күршеләргә ялынып керәбез, улым, күршеләргә!» — «Мунчаны үзем ягам!» — диде Нәҗип, шунда ук дәртсенеп. Гәүдәсе җиңеләеп, очынып китте. «Әйбәт булыр, улым. Кичә ягылган мунчага утыны да күп кирәк булмас!» Карчык, эчкерсез сөенеп, утын өемен күрсәтте, мунчага кайсы яркаларның япьтәш булачагын иренмичә аңлатты.

Терәлеп торган күршеләре Фәрәхетдиннәр борын-борыннан мунча яраталар иде. «Фәрәхетдин бер яккан мунчага өч тапкыр чабынырга кирә!» — дип, күрше-күләннең шаккатып сөйләгәнен малай чакта ишеткәне бар иде Нәҗипнең. Хәзерендә, Фәрәхетдин дөнья куйгач, мунчалары ни хәлдә икән?

Ул, читән капкага эленгән бозау муенчагын суырып алып, эре ярылган каен яркаларын бәйләп иңенә салды да ындырга атлады. Ындыр капкасында дәү җәяле авыр йозак эленгән икән. Әнисе сөтен куеп, ялт кына килеп чыкты да, биленә тагылган ачкыч бәйләменнән берсен аралап алып, йозакны ачты, улын ындырга шае озата чыкты. «Онытмадыңмы?» — дип, Фәрәхетдиннәр мунчасын күрсәтте. Фәрәхетдиннәр — терәлеп торган күршеләр, алардан ары марҗасын ияртеп читкә киткән Мостафалар нигезе...

Эшләпә киеп мунчада уралырга яхшысынмаган Нәҗип яланбаш, күлмәкчән генә чыккан иде, авыл өстенә аварга торган шәрә тау өстеннән әче-зәһәр җил исте, тәнне тешләргә тотынды. Ике арадагы ызаннан төшеп, ындыр арты киртәсе яныннан мунчага борылам дигәндә, мыдыр-мыдыр сөйләшкән тавышлар ишетеп, Нәҗип тукталып калды. Әүвәл башта тез башлары касмакланып каткан чалбарына күзе төште. Оялды. Аннан, тәвәккәлләп, аны-моны уйламаска тырышып, мунчага таба атлады. Барып җиткәч тә ишек кинәт ачылды, аның каршысына бер-бер артлы ике хатын-кыз килеп чыкты. Иңнәренә берсе кара шәл, икенчесе ак яулык салган хатыннарның икесе дә шәрә тән иде. Алдан кара чутыр, башмак иренле хатын килә, дәү күкрәкләре чегән арбасына тагылган дегет лагуннары кебек чайкалалар иде. Зифа, нәзек сынлы, учка сыеп бетәрлек кенә алсу имиле арттагы хатын, Нәҗипне күрүгә чүгәләде, яулыгын алып, түшен, бот тирәләрен каплады. Нәҗип Гөлгенәне таныды. Беркавымга киеренке тынлык урнашты.

Гөлгенә аннан бер генә яшькә олы булса да, алар бер класста укыдылар. Декабрь чилләсендә салкын тидереп Гөлгенәнең әнкәсе иртә вафат булды да, ул бер кыш укырга йөрмәде, икенче көздә Нәҗип аны куып җитте. Балачактан ук чая, кыю, үткер телле булды әнисез бала. Тегермән буасына су керергә төшсәләр, Нәҗипне бала санап, һич тайчынмыйча чишенә, малай каршысына шәрә тән басып, аның төкреген йота-йота җиргә карап торуыннан көлеп, үртәп, Нәҗипнең битенә ут кабыза иде. Элеккегә караганда да чибәрләнгән Гөлгенә, аның тәненә азгын тәм, ләззәт йөгергән, бер дә утыз дүрт яшьлек хатын дип әйтмәссең. Бала тапмаган, ахрысы, эче суырылып тартылган, ботындагы җәрәхәт эзе генә яман җөй булып күңелне кайтарып тора иде...

Бу очрашу бик аз вакыт дәвам итте. Гөлгенә чүгәләгән килеш калды. Аска карап, буен сындырып, Нәҗип мунча ишегенә кереп югалды, шабырдатып утын яркаларын идәнгә койды һәм, тәбәнәк сәкегә утырып, учы белән маңгай тирен сөртте. Май җилендә дә тирләтә торган хатыннар кычкырып бер көлештеләр дә аяк эзләре тынды.

Бу дөнья Нәҗип күз алдында тотып кайткан татар дөньясы түгел иде. Гөлгенә дә ул белгән татар авылы хатыны түгел, дәшми-тынмый, затсызланып имиләрен асылындырып торган башмак иренле хатын да ят, килешсез иде. Бу манзара аның күңелен ямьсезли, түбәнәйтә, рәнҗетә иде.

«Әгәр хәзер әнисе яисә Наилә төшеп, аны шушы җайсыз хәлдә күрсәләр?» Нәҗип, башын күтәрмичә, кабаланып мунчадан чыкты, кабаланып кайтып, кулына ике чиләк тотты, бу юлы тыкрыктан, Гөлгенәләр ихатасы күренмәс сукмактан, инешкә төште.

Инеш ул балачакта аларның бәрәңге бакчаларына тияр-тимәс агып, язгы ташулар хәтәр елларда әле бер яктан, әле икенче яктан ярны ишеп каерылып, туйра-таллыклар арасына кереп югала иде.

Яр өстенә барып баскач, ул инешне танымады. Баштарак ни үзгәргәнен дә аңламады, балачактан һәр борылышка, һәр тугайга, һәр түмгәккә күнеккән күз бүген ятсынып, инешне кызганып, боегып калды. Ярлар ишелгән, тәбәнәкләнгән, теге борылыштагы тын тугай саеккан, тугай урынында бөкре таш таучык пәйда булган. Кая карама — ертык-пыртык галушлар, ватык тәгәрмәч тугымнары, каз оялары, иләк кысалары, гөбе, сапсыз бәлҗә, ылыбылар, чалгы бизләре, ураклар һәм төрледән-төрле тимер-томыр чәчелгән иде. Ике-өч урында оя-оя каз мамыгы сеңгән; төлке буганмы аларны, мур кырганмы, белеп булмый. Талларда кош тавышы юк, инеш тә тавышсыз ага, юашланган тал төпләренә, ярның уентыкларына кушуч-кушуч кара май кисәкләре касмакланып каткан иде. Фәрәхетдиннәрнең мунчасы турындагы тубырлы кабыклы карт өянке башына саесканнар сарган. Алар, Нәҗипнең күзен кискән үзгәрешләргә куанышкан сыман, үзара чыкыр-чыкыр киләләр иде. Инешнең суы болганчык, су читләре майлы лай, уртадан зәңгәрсу ефәк булып тоташ нефть ага иде. Баядан бирле ындырга чыккач та борынга бәрелгән авыр ис инештән килә икән.

Шулчак ындыр капкасыннан билен тотып әнисе чыкты, сөйләнә-сөйләнә аның янына ашыкты. «И улым! Зиһенемне заман ашады! Иртән ни уйлаганымны кич онытa торган булдым. Әткәң егылганнан бирле үзем дә сихәтлеккә туймыйм. Суны мунчага каян ташырга кирәклеген әйтеп бирмәгәнмен. Инешкә күптәннән төшкәнебез юк, өч-дүрт ел бардыр. Су урынына әллә нәмәкәй ага. Тегендә, иске тегермән урынына, дуңгыз яптылар. Өч мең баш мыркылдап ята, ди. Шуларның шакшысы ага инешкә. Кышын-язын мур кыра тегеләрне. Карау җитми, ашарларына юк. Үләксәләрен дә шунда инеш тирәсендәге чокыр-чакырларга ыргыталар икән. Нефтьчеләр Олы су башында, Карама куышта, ике җәй яттылар, нефтьләре чыкмаган, казыган тишекләреннән ачы су ургылып ага, ди. Әллә җәһәннәмгә тиклем төшкәннәр инде. Үземнең барып караганым юк, иллә мәгәр исеннән баш дөңки. Шулайдыр, шулайдыр... Элгәрге елларны каз асрый торган иек, өчәр оя калдырган елларым булды. Авыл җирендә каздан да җайлысын тапмый иек. Көздән тозлап эләсең дә җәй буе түтәрәм-түтәрәм ит ашыйсың. Уч төбе хәтле ит салсаң да, бәрәңгегә тәм керә. Өченче ел казыбыз унөч бәбкә чыгарган ие. Әтиең сырхау, мин бәрәңге бакчасында чүп утыйм, котырды ул елны чүп! Эшнең очы-кырые юк. Казларым әллә ни арада капка асты тишегеннән чыкканнар да инешкә төшкәннәр. Тавышларын да ишетмәдемсана, колакай. Исемә килеп теркелдәп төшсәм... унөче тиң су читендәге майга чумып җан биреп яталар. Ике атна күземне ача алмадым, җыладым да җыладым. Тәңре безне ташлады, Ходай шәфкатен бүтән тарафларга юнәлтте».— «Әтигә ни булды?» — дип сорады Нәҗип. «И улым, вакыт табып бер сүләрмен әле сүләвен, чыкмаган җаны белән тамагы гына калды бахырымның. Чирләде дә мантымады. Булса, ашауга таза болай, ашарга гына төткәзеп булмый. Казлар димәктән, ана казны исән килеш тартып чыгардым. Ниләр хикмәтләп карамадым, керәчин белән юдым, кер парашугы белән ышкыдым, рәтләнмәде бичара. Аннан күмдем. Җылый-җылый күмдем актыккы ала казны. Ел саен диярлек ун-унбиш бәбкә чыгара торган ие. Унөч иде ул елны. Ишчугы унысы гына күзгә керсә соң!.. Карын итле була иде! Сатасың икән, базарда каз егерме тәңкә! Хәзер әнә ике сарык асраган булабыз. Икесенә сыңар бәрән. Ел саен ике бәрән китерә торган Акмаңгай ике ел рәттән бәрән сала. Язга чыктык исә — мә! — сәмәлүт белән кырга сиптерәләр. Әтиең, ничәмә-ничә ел сәмәлүткә агу төяшеп йөрде. Әйтмәсә дә белӘм, бик беләм: шул җитте аның башына! Күрә авыл: җил чыкты исә, агу болынга оча, тауларга куна, урманга тарала. Суда да шул, юлда да, авызда да шул! Теш арасына тулып кыштырдый. Бөтен авыл сарыклары ютәлли берзаман, шоннык; көтү каршыларга баргач сүләшмибез — мал тоягына ияреп кайта, тузанга катышып оча! Күпләр сарык асрамый хәзер, умарта корты бетте, божан юк, төклетура үрчеми, дөнья тутырып чебен-черки калды. Ул нәләтне агу алмый икән! Әй, килә башлый берзаман чебен дуңгызчылык ягыннан! Муенга тула, колакка керә, хет ләхеткә кереп ят. Калмады сыер малы, улым. Кем асрасын?! Язын бозау сала, туган бозаулар селәгәй, маңкалы, ябагасы белән йоны коела. Һәй, һәй!..»

Карчык сөйли торды, инеш аның кайгы-хәсрәтен төяп шым гына ага торды. Саесканнарга рәхәт, иркенлек — бүтән кош-корт калмагач, күктә шул караклар патша!

«Ит каян ала соң авыл халкы?» — «Итме? — диде сәерсенеп ана.— Кысыр аш ашыйбыз. Бик олы кунак килсә, тавык суялар. Кайнар кысыр аш эләксә, рәхмәт диген инде. Тәңре безне ташлады. Сөтле аш та кунак сые хәзер! Хәер, без карт-корыга ни җитмәгән. Безгә күп кирәкме?» Мәрьямбикә, авыз читен кулы белән каплап, улына астан, бикерактан карап көлгәндәй итте. «Ә яшьләр ни ашый?» Бусы үзенчә Нәҗипнең шаяртуы иде, Мәрьямбикә исә бик җитди җавап бирде: «Яшьләрме? Бармыни алар? Юк ич, таралдылар. Балалар таралды дип, элгәре, әткәң белән көенә идек, хәзер сөенеп бетә алмыйбыз. Ике энең әфисәр, Сабит улым әйткәндәй, хөкүмәт киендерә, бушлай ашата. Марҗага өйләнүләренә дә исебез китми, дөньясы шуңа калгач, кая барасың! Татар булып без ни рәхәт күргән?! Күз көеге булып монда кайтмасыннар гына!»

Ул арада кояш офыктан аерылып шактый күтәрелде, көн әз генә җылынгандай булды, мунчаны кабызып җибәрергә бик вакыт иде. «Суны каян ташыйсыз соң? Көмешкүлгә үк йөрмисездер бит?» — дип сорады Нәҗип, аптыраштa калып. Бу юлы Нәҗип әнисеннән күңелле, шат җавап көткән иде. Югары авыл халкы өчен изге саналган Көмешкүл Мәрьямбикәгә дә туган ягының иң матур, иң хатирәле төбәге иде. Көмешкүл ярларыннан башланган Аклан чирәмендә сабан туйлары уза, көзге муллык җыеннарында да тирә-як халкы шунда җыела...

«Күл юк, улым, ул да әллә кайчан кипте»,— диде Мәрьямбикә, исе китмәгән кыяфәт белән. Күл юклыгына ул әллә кайчан күнегеп беткән иде инде. Нәҗип тоткан пар чиләк шылтырады. Ахырзаман диләр, шул килеп җиттеме әллә? «Кипте шул,— диде карчык, күлне әзрәк җәлләгән сыман.— Анау елны дөнья корыды, яңгыр яумады, күлгә әллә ничә басудан торбалар тыгып, җәй буе суын суырттылар. Көзгә тиклем күл төбендә ындыр табагы хәтле генә су калды дип сөйләделәр. Үзем бармадым, барганым да юк. Аяк тартмый. Җитмәсә, күл ягасына нефтьчеләр өч тишек тишкәннәр. Әллә шунда качты су, әллә кысыр җәйдә үлде. Хәзер әнә язгы сулар әз-мәз җыелып ала да, кояш ялый башлагач, бетә дә китә икән. Адәм буе сырганак, чатлы-ботлы әрекмән үсә, ди, ярларында. Суны, онытмаган булсаң, Галләм абыеңнар коесыннан алабыз. Аларның коесының суы каты. Кая барасың, күпчелек коелардан су качты, түбән оч чишмәсе корыды... Кое суының ни чәе чыкмый, ни керне

агартып булмый, эчәргә дә тозлы. Әткәң яңгыр сулары җыештырып йөри. Яңгыр суы да хәзер селтеләнә бара».

Алар сөйләшә-сөйләшә тыкрыктан кайттылар, кеше-кара күренмәде, көтү куган чак, мәгәр бу очта мал тавышлары юк иде.

Ул чиләкләрен шылтыратмаска тырышты. Урамга чыкты.

Югары авыл урамы. Аның гомер юлының башы. Балачакта бу урам хәтфә чирәм белән, янбакча киртәсе буйлары песи борчагы, карга борыны кебек үләннәр белән каплана иде. Боларның берсе дә калмаган. Урам Эзи юлы шикелле үк изелеп, җебеп, чокырланып беткән. Күз ял итәрлек янбакчалар да, миләш, шомырт, сәрви куаклары арасында балкып утырган умарталар да юк. Тракторлар, урамның, замана янбакчаларның, агу таратучы сәмәлүтләр бал кортларының, төклетураларның, зәңгәрсу божаннарның башына җиткән...

Ул, ике чиләген бер кулына алып, авам-авам дип утырган читән-киртәләргә ябыша-ябыша, Галләмнәр коесына барып җитте. Чыгырлы иске кое янына баскач, җилкапка, тәбәнәк утыртма читән аркылы хуҗаларның ишегалдына карады. Заманында карчыгы Хәдичә белән сигез бала үстергән Галләмнәр йортында да хәрәкәт сизелмәде. Ак колаклы арык эт, суга килүченең ят икәнен абайлапмы, болай, олы дөреслек өчен генәме, иренеп бер-ике тапкыр авызын ачып алды. «Тавышымны ишеттегезме?» дигәндәй, кешесез ишеккә бер карады да өй нигезе җылысына сузылып ятты, күзен йомды. Шәп-шәрә ботакларын тибрәндереп утырган шәрә сөякле корыган карама агачында ике арык чыпчык нидер бүлешә алмыйча тарткалаштылар да икесе ике якка очып югалдылар. Кое чыгырының имән багана төпләре муртайган, черегән иде. Ул чыгыр бавына бәйләп, баганаiны кулы белән тотып, чиләкне кара кое авызына төшерде. Урам сәерлеге, бушлыгы, тынлыгы белән аны тәмам йоткан иде, якынаеп килгән аяк тавышын ул әллә нинди бер могҗизадай кабул итте, ялт итеп борылып карады. Сыңар чиләген беләгенә элеп, болай таба Гөлгенә килә икән. Ул җиңел, юка күлмәк кигән, тезе ачык, изүенең пыртлые ычкынган, авызында беләк буе, кәгазьгә урап төргән тәмәке. Ялан аякларына үкчәләре кыршылып, ямьшәеп беткән резин итекләр элдергән. Килеп тә җитте, тәмәкесен төкереп тә очыртты. Төпчек кое яны дымына төшеп, байтак вакыт чыжлап, зәһәр ис таратып ятты. «Исәнме, Нәҗип,— диде Гөлгенә, чиләген сул беләгеннән уңына күчереп.— Кайтып җиттек, диген».

Нәҗип аның яшерен ымнар тулган төртмә сәламен алмады, җавапсыз калдырырга да яхшысынмады, тонык кына: «Күрәсең бит, кайттык»,— диде.

Гөлгенә, соң дәрәҗәдә кызыксынып, аулакта күршесенең эч серләрен алып калырга дип сорауларга тулып-ташып килгән иде, Нәҗипнең тонык җавабына аның исе китмәде, өйдән әзерләнеп чыккан беренче соравын бирде: «Хатыныңны да алып кайттыңмы?» — «Балаларны да»,— диде Нәҗип. Гөлгенә кинәт уйчанланды, бу халәтен Нәҗипкә сиздерәсе килмәде, юри наян, ясалма тавыш белән: «Мунчаң эссе булсын, утыныңны җәлләмә! Иптәш хатын белән мин дә юынып чыгармын»,— диде. Нәҗип аңа күтәрелеп карады: «Ник үзегез якмыйсыз?» — «Баш авырта. Кичә иптәш кызымның туган көне иде. Кичен юынасы идек, салынган, макмырга иртән юынайык дип төшсәк, кемдер суны бетереп куйган. Кунакка буш кул белән кайтмагансыңдыр, яртың булса, безгә дә өлеш чыгар. Сызгыр гына, хәзер кереп җитәрбез».— «Мин эчмим бит»,— диде Нәҗип, коры гына. Гөлгенәгә бу сүз җитә калды, куе кашлары очып китәргә җыенгандай хәрәкәтләнде: «Ә син хәсрәтеңне ничек юасың алайса? Әллә син хәсрәтсез яшәүчеләр арасына мендеңме? Тыныч кына кеше хакы ашап яшәп ятасыңмы?»

Нәҗип бер мәлгә Гөлгенәнең чая кыз чакларын хәтерләде...

Ул бер чиләк су менгезде, икенчесен. «Бусы миңа!» — диде Гөлгенә, төчеләнеп. Нәҗип чиләге, судан бушап, өченчесенә шалтыр-шолтыр килеп кое авызына кереп югалды. «Хәзер кайгы-хәсрәтсез кеше бармыни ул? Нигә эчәләр дип уйлыйсың син? Хәсрәткә даруны академиклар да таба алмый. Эчмим дип йә син алдашасың, йә син просто дурак».— «Каты әйтәсең»,— диде Нәҗип, ачыктан-ачык җәберсенеп. «Председатель утыртты мине. Мир үгезе! Авылда аның кулы аша үтмәгән хатын-кыз калмады. Дөрес, печән урлап кайттым. Урламасам, соңгы кәҗәне — Сталин сыерын сатарга туры килә иде. Рәис тотты, сагалап йөргән икән, шпион. Колхоз байлыгын кайгыртып йөрүедер дисеңме, тот пычагымны,— мине каптырырга теләгән ул, сасы көзән! Аулак әрәмәдә каршыма ук килеп чыкты. «Әгәр шушы хуш исле печәндә кочагыңа алсаң, берни булмас»,— ди. Кочагыма да алыр идем, җәл түгел, хәзинә үземнеке, телим — бирәм, теләмәсәм — кәҗә тоягы тоттырам, чибәр ул сатана, тәне шома, тәмәкенең дә хуш ислесен тарта, куллары мамык кебек йомшак, мәгәр бирелмәдем, күпме хатын-кызның күз яшен түктергәнен уйладым да күкрәгенә төрттем! Кыяфәт күркәнеке булса да, көч әтәчнеке икән! Чалкан барып төште. Бүртенде, ә мин шарык-шарык көләм. «Печән урлап кайтканда тоткан колхоз рәисен кыйнаган өчен» җиде ел ямадылар».

Өченче чиләк менде. Су күтәреп, кайтыр юлга чыктылар. Юл янәшә иде, сүз өзелмәде. «Хәсрәтем юк дисең алайса?» Нәҗип эндәшмәде. «Алайса шул: әллә кем булгансың икән, начальник! Әйтәм җирле, әнкәң очраган саен мактана иде. «Һай, минем Нәҗибем, вай, минем Нәҗибем! Мәскәүдә, Брежнев патша янында укый. Чакырып алганнар. Мавзолей янындагы йортта яши, ди, берүзенә болын хәтле бүлмә биргәннәр. Уртада трактор дәүмәлеге өстәл. Өстәлендә өч төймә. Берсенә баса — чәй

китерәләр. Шикәрлене! Икенчесенә баса — пумушнигы атылып керә: «Ни боерасыз да ни кушасыз?!» Өченчесенә баса — машинасы килеп җитә...»

Гөлгенәне тыңлау кызык иде, ул бер халәттән икенчесенә җиңел сикерә, әле карчык булып сокланып сөйли дә, үз фикерен ялгап, Нәҗиптән мыскыллап көлә дә иде сыман. «Заводка директор булып кайта икән. Ә заводында халык!.. Кара болыт белән бер икән!» Әнкәң шулай сөйләгән иде, дөрес сөйләгәнме?»

Нәҗип сүз әйтмәде, әче көлемсерәп, Гөлгенәгә карады.

«Әйдә, яшәп кал, без — беткән кешеләр. Дөнья йөзендә орлыкка һәйбәтләр калсын. Син әйбәт яшә. Әнә минем иптәш хатын. Заводта эшләгән, цех парторгыннан биш корсак төшергән. «Урлады!» — дип, өтермәнгә тыгып котылган теге кара йөз. Менә безне «әчәләр!» дип районн гәҗитенә яздылар. Гәҗитәдән пирчәткә бармакчасы хәтле генә апа килгән иде. Әй чәтерти бу, әй шыбырдый, коелмый гына. Ну, мәйтәм, лагерьда очраган булсаң, сидереп сидегеңә утырта идем мин сине! Күрер иде гадел яшәүнең нәрсә икәнен! Эчмәсәк, без нишләргә тиеш! Мине утырткан рәискә кол булыргамы? Колхозчы — кол лабаса ул! Бер сүз әйтә алмый ул, бичара. Ә мин кол түгел, тотсын кәҗәнең койрык астын! Тотсын да бөти итеп таксын. Мин кайтыр дип көтмәгән икән, ә мин, ныграк булыр өчен, иптәш кызны да ияртеп кайттым. Яртыны кыстырып кергән теге, йөрмә, дидем, икене алып кер! Икене тыгып килгән. «Кичер» ди.

Гөлгенә мәзәк кенә көлеп куйды, чиләге чайкалып суы түгелде. Нәҗип, капка төбеннән китәргә ашыкмаган Гөлгенәгә карап, «Сау бул!» дигән сүзне әйтте дә кабаланып мунчага төшеп китте. Гөлгенәнең әрсезлегеннән котылдым дисә дә, тагын ике-өч тапкыр очраштылар алар. Нәҗип юл дәвамында бер-ике сүз әйтеп туктаса, Гөлгенә, сагынган кешесен көтеп алган гашыйк шикелле, туктаусыз сайрады.

«Тутаң лагерьда ялгыз булган дип беләсеңме? Төрмәдә дә хокукы юк чибәр хатынның! Аны теләсә кем тотып ала! Конвой ялгыз калдырамы чибәр хатынны? Мин күргәнне эт тә күрмәс! Югарыдан берәр начальство килдеме — мине дәшеп кертәләр. Генерал белән кунган бар! Шампан белән аягымны юдырттым... Хак, алдасам күзем чәчрәп чыксын! Җәһәннәм кисәвенә әйләнгән инде без. Бер мин генәме? Крестьянның яшәр чуты калмаган, әллә кая китеп олага идем, шул председательнең күзенә кадалган кылчык булыйм дип кенә монда ятам. Мине күргән саен ыштаны юешләнә тегенең! Ух, күзен чукып чыгарыр идем!..»

«Нигә боларны миңа сөйлисең, Гөлгенә?» — «Сиңа сөйләмичә кемгә сөйлим? Син бәхетле җан, директор, янында хатының, балаларың... Әй, Нәҗип, ал син безне эшкә! Әгәр эш әз генә бәхет китерә икән, мин җир җимерергә әзер! Иптәш кызым минем сүздән чыкмый. Яшь бит әле без!»

Нәҗип, суын түгә-түгә, мунчага ашыкты. Йә, ни әйтсен дә нинди киңәш бирсен инде бу бичара җанга! Әнисе дә инде Наилә язган хатны түкми-чәчми, нык кына купайтып авыл арасында сөйләп йөргән икән!..

Кырык ямаулы җиз тас, баусыз чиләкләр, агач чапчаклар су белән тулгач, Нәҗип мунча мичен кабызып җибәрде...

## 19

Юка көрән чалбар, зәңгәр җирлеккә ак буй-буй төшкән сатин күлмәк киеп, шома таягын арык тез араларына кыстырып, әтисе өстәл янында утыра. Наилә балаларының күлмәк-чалбарларын юып көнгә элгән, малайларны уяткан, юындырган. Искәндәр белән Рөстәм, әбиләренең йон кабасын ат итеп, идән уртасында чабыш оештырганнар. «Булышырга чыга идем, миннән башка да ярдәмчеләр табылган икән сиңа!» — дип, Наилә хәтәр генә кадап алды. Ул Гөлгенәнең ары-бире иренә тагылып су ташыганын күзәткәләгән икән. «Су ташыр хәлем юк иде шул, бөтен буыннарым сызлый, юл изгән», — диде Наилә, каенанасына карап. Мәрьямбикәгә шул гына кирәк тә, аның үз гомерендә бер булса да килененә зарланып, бушанасы килә: «И килен, шуны әйтәсеңме, авызыңны кыеш-мыеш китереп, көне буе мыштырдап инә буе җир китәм, ә кичкә гәүдәм ындыр табагында чабагач астында калган көлтәгә әйләнә, сызламаган буын, шыгырдамаган сөяк юк. Ах-ух килеп урынга аугач, исәпләп карыйсың: эшләгән эшең бармак башы шае булган!»

Наилә, тәртибен белеп, һәрнәрсәне зур итеп күрсәтеп, күчтәнәчләрен чыгарды. Искерә төшсә дә балкып торган ак калач янына алка-алка итеп колбаса турады. Мәк сибелгән вак клиндерләрне ашъяулыкка аудардылар. Мәк хәлвәсе белән аллы-кызыллы манпаси ясмыкларын күргәч, карчыкның дымлы күзләре яшьләнде: ничә бала үстереп аның шушы кадәр күчтәнәчне күргәне юк иде. Ул дулкынланып, уфылдап кече якка керде дә чүпләм башлы тастымал белән төрелгән агач табактагы бәрәңгене алып чыкты. «Бәрәңгебез вак, кәҗә белән сарыкларга дип өй базында тотканы гына калды. Эресен көзен тышкы базга күмгән идек, язын ачып җибәрсәк, җылашып үлә яздык, базы белән тоташтан кисәүләнгән. Тазартырга көчебез җитмәс дип, базы-ние белән күмдек. Көзгә сай гына итеп булса да баз казымыйча ярамас. Кайтасыгызны белмәдек шул, сыек май алган булыр идек. Сыек май

сибеп тә җибәрсәң, вак булса да, бәрәңгебез тәмле, ярмаланып тора. Йә, кунаклар, җитешегез. Хәзинәдә бары белән».

Табакка иң әүвәл малайларның кулы кереп китте, алар ак күмәчне тиз-тиз чәйнәп, арага бәрәңге кыстыра башладылар. Йосыф карт та җанлангандай булды, ул пычак очына бер алка колбасаны эләктереп алды да томанлы күзе алдына китереп озак кына әйләндерде, шуннан соң гына капты, чәйнәп йоткач: «Колбаса да бар икән әле дөньяда, и агай!» — дип, иренен чәпелдәтте.

Борынгыдан килгән гадәт буенча, бу йортта аш-су янында сөйләшү юк иде, кечеләр үз бурычларын сабый чактан ук үзләштергәннәр, олылар дәшмәсәләр дә, бу кагыйдәләрнең үтәлешен бөркет булып күзәтәләр, түргә әллә нинди кадерле кунак утырса да, кыстамыйча сыйлыйлар, кыстамыйча тамак туйдыралар иде. Бүген иртәнге чәй тиз тәмамланды, самовар суынырга да өлгермәде. Нәҗип яшерен өмет белән кече якка карашын ташласа да, чаршау-пәрдә селкенмәде, чәй янына май-шикәр чыкмады, күпереп торган авыл ипие дә, корт та, төче катлама да, бүтән төрле сагынылган сыйлар да юк иде. Тузаны очып торган чәйне әнисе саран гына, бал калагы очына эләктереп кенә салды. Чәйне бик зурлап, берәр манпаси кабып, мактый-мактый эчтеләр. Мактау да бу йортның гадәте түгел иде...

«Карап кайтыйм әле» дигән сылтау белән Нәҗип мунчага китте, Мәрьямбикә оныкларына чыпчык оясы күрсәтергә булды. Наилә урынына кереп ятты.

Никадәрле арыган булса да, Наиләнең йокысы сак иде. Ул иренең торып чыгып киткәнен дә, каенанасының озак күрешми торган улы белән кыска-кыска сөйләшкәнен дә аермачык ишетеп ятты. Торып чыгасы, иренә күренәсе килмәде. Монда бөтен нәрсә, тирә-як, мөнәсәбәтләр үзенчә иде. Ул моны сизде. Юл газаплары исенә төшкән саен, аның җаны икегә бүленеп өзгәләнде. Гомерлек юлдашына, ике улының әтисенә, туган төягенә кайтып барганда, чарасыз, ярдәмсез калып интеккәндә, ул ничаклы авыр сүз яудырды. Гафу ителерлек хәлме бу? Йә, тормышны бүгенгәчә көйли алмаганнар икән, монда бер Нәҗип кенә гаеплеме?.. Әгәр Мәскәүгә укырга китмәгән булса... Анда барып артыгын көчәнмәсә... Күтәрә алмастайны югары чөяргә тырышмаса... Гади генә, кешечә генә яшәп китәчәкләр иде бит. Эшкә ашмас хыяллар үтәр иде... Әле менә, күз алдында, адәм уллары чамасыз кыен шартларда яшәп яталар. Кичә мунчада каенанасы Йосыф карт турында аңа бик күп нәрсәләр сөйләде. Асылда, сүз әнә шул карт, Нәҗипнең этисе хакында гына барды да бугай...

«Басымчак иттеләр Йосыфымны, яз-җәй генә түгел, көзен-кышын да ял күрмәде... Калхузның иң кара, иң пычрак эшенә җиктеләр. Сарык карады, дуңгыз көтте, ат сарайларыннан тирес түкте, урман кисеп кабык төшерде, кабыкны күлдә җебетеп, мунчала каезлады. Киндер басасын күлгә чумдырды, аны чыгарды. Баса көлтәсен күлдән чыгарудан да авыры юк, үзе авыр, үзе кара көзгә кала, үзе сасы... Мунчада өч чабынгач кына тәненнән исе китә. Барды Йосыфым, ың-шың чыгармады, эшләгәнгә бер тиен түләмәсәләр дә, бастырып сүз әйтә алмады. Калхузның колы булды инде, колы. Ташлы-комлы авыш басуларны ул сөрде, күмер яндырды, таш яндырып таш катыгы ясады, кәнсәләр бәдрәфен дә аннан тазарттырдылар. Гаилә ишле иде, кая барсын? Фермаларны таш катыгына тончыга-тончыга ул агартты... Мине дә җиктеләр инде, ире басымчак катыннарга да калхузда пачут юк, камыт кигертәләр дә куалар... Бозауларның эче китә башласа, «Мәрьямбикә, бар!», атлар күтәрәмгә калса, «Мәрьямбикә, йөгер!», «Кәбестәгә ак корт төшкән, яшелчәдә куна-төнә ят!» Балалар үсте, мәктәпкә йөрделәр, без малайларны да, кызларны да күрмәдек. Иртән ач карынга чыгып чаптык, кичен, ашарлык хәл дә калмаганда, кайтып егылдык. Мәгәр сүзебез бер иде: «Балалар, без күргәнне күрмәгез, коты калмаган бу яклардан чыгып качыгыз»,— дип тәрбияләдек. Калада анда бүтәнчәдер, фатирыгыз юк икән — булыр. Ходайдан күркәм сабырлык һәм татулык сорагыз». Бу сүзләр Наиләнең күңеленә кереп оялады...

Элек тә сантый түгел иде Наилә, бер төн эчендә ул илдәге хаксызлыкны, гаделсезлекне, халыкларның аслы-өсле сыйныфларга нык аерылганын күрде. Бер якта балга манчылып мунча керүче Гөлнаралар. Әле хатыннары шулай азына, ирләре ниләр кыланмый икән аларның?! Аерым кунакханәләрдә, ял йортларында ярты гомерләрен үткәрүче лауреатлар, депутатлар, пленум әгъзалары ниләр күрми дә ниләр күрсәтми икән?! Ә монда гомере буе буразнадан чыкмаган, тормышның иң авыр эшләрен үтәгән карт хәзер беркемгә дә кирәк түгел. «Кибеткә сирәк кенә тәм-том, сыек май кайта, безне бар дип тә белмиләр, төрткәләп чыгаралар. Ил белән азынды халык, ил белән!»

Кайчандыр тормыш терәге булган, илне ашаткан, киендергән кеше хәзер әнә кече як сәкесендә ара-тирә ыңгырашып, тавыш биреп ята. Төшендә һаман котырган төлке белән сугышамы? Әллә төшендә гайрәтләнеп үзен изгән председательләргә әр сүзе әйтә аламы?.. Кайчандыр алар да кеше булганнар ич, хәзер кисеп ташланган тырнакка да тормыйлар. Ник без үзебездән түбәннәрдән гыйбрәт алмыйбыз икән дә гел-гел югарыга үрләгәннәргә карыйбыз икән?! Югарыга карарга аны Нәҗип өйрәтте. Ә аны югарыга карарга тормыш мәҗбүр итмәгәнмени? Ни өчен аның авылга, ата-анасы катына кайтмавының сәбәбе шушымы әллә? Нужадагы этисенә ярдәм итә алмавы аның горурлыгын басып торганмы? Алай булуы да ихтимал. «Без барыбыз да заманча бозылган буын. Без үзебездән алда килгән, сугышны кичергән, берчакта да тамагы туймаган, өсте юньле кием күрмәгән буынны кадерләмәдек. Киресенчә, яши белмиләр дип алардан көлдек, мыскылладык». Ул Йосыф картның боек кыяфәтен, тонык-яшьле

күзләрен һәм аның, таш кубарып, котырган төлкегә каршы чыккан мизгелләрен күз алдына китерде... Күңеле тулды Наиләнең, күңеле нечкәрде, ул үзен, ирен, балаларын, каенатасы белән каенанасын, төрмәдә кешелегән җуйган Гөлгенәне, аның адашкан юлдашы якут кызын, тагын бик күпләрне җәлләп, әрнеп, кайнар яшьләренә чыланды.

Нәҗип мунча мичен томалап, салкын-кайнар суларны әвеш-тәвеш китереп көйләп чыккач, күңеле борлыгып, инеш буйларын тагын бер урады. Эш юктан эш тапкан булып, тыкрык башында йөрде, Наилә янына кайтып керәсе килми иде аның.

Шактый торып, эч пошуларын баса алмыйча ишегалдына кайтып керсә, әнисе өч литрлы бидон тотып ут капкандай йөренә. «И улым! — диде ул. — Әле ярый кайттың. Кибеткә сыек май кайткан, әле сата башламаганнар. Фәрәхетдин хатыны: «Картларга бирмиләр!» — дип әйтеп үтте. Улым, бар, иренмә, төшеп кара. Кунакны, олы кешене кире бормас Зәйнәп. Күпме бирсә дә ал!» Шулай әйтеп, Мәрьямбикә улының учына кулдан-кулга йөреп, мең хәсрәткә шаһит булып, изелеп, таушалып беткән өчлек белән берлекне китереп салды. Нәҗип, күзен түбән төшереп: «Барам, әни, барам!» — дип күнде. Искәндәр этисенә тагылырга теләсә дә, «Өс-башың ару түгел, тегеләре кипмәгән, урам бик пычрак!» дип, аны ияртмәделәр. Әбисе малайларга чормадагы күгәрчен оясын күрсәтергә булды, болдыр баскычына чыгып өлгергән Наилә иренең җилкәсен генә күреп калды. Эндәшми китүенә ачуы килмәде, ул Нәҗипнең җанында ниләр кайнаганын аңлады.

Югары очтан түбән очка лай изеп, Нәҗип кибеткә барып кергәндә, кибет эче кеше белән туп-тулы иде. «Картларга бирмим, дигән... монда яшь кеше бармыни?» Аның беренче уе шул булды. Гел хатын-кыздан гына торган чуар төркемгә ул уртак сәлам бирде. Алдарак, кибетчегә якынрак тартылган иң тыгыз төркем аның сәламен ишетмәде. Ишек катындагы тарау хатыннар: «Бу нинди артык тамак тагын?» — дип, Нәҗип кулындагы өч литрлы бидонга карадылар. Мөнир хатыны Халисә дә шунда икән. Ул, Нәҗипне таныса да, бүтәннәр аның сәламенә игътибар итмәгәч, сәламне алмады. Җыелганнар арасында чыш-пыш китте, хатыннар колактан-колакка Нәҗипнең кем булуын ирештерделәр. Картаеп чуттан чыккан Йосыф белән Мәрьямбикә баласына «Коммунизм юлы» колхозының кысан кибетендә чиратта ярсыган хатын-кызларның исе китмәде. Кемдер: «Һе, алай икән!» — дип куйды, кемдер: «Каладан кайтып, май теләнергә төшкән!» — дип җибәрде, бөтен күзләр сагышлы өмет белән кибетчегә төбәлгән иде. Ялыну-ялвару, инәлү, табыну, ярарга тырышу, тәлинкә тоту, ясалма төчелек һәм түбәнлек бар иде бу арыган күз карашларында, һәр күз: «Зәйнәп миңа мәрхәмәтлерәк караса ярар иде!» — дип ялвара, ягымлырак, гөнаһсызрак күренергә тырыша иде. «Сата башла инде, Зәйнәп!» — диде хатыннарның чаярагы. «Ходайдан фәрман көтмисеңдер ләса?» — «Тинтерәтмә инде»,— диештеләр бүтәннәр. Каләмен колак артына кыстырган, мул майланган коймак төсле елтыр, бүлтәеп торган битенә сыткы сибелгән Зәйнәп җеп иреннәрен кысып чут салган җиреннән күтәрелеп карады да: «Сыер савучылар кайтмыйча сатмыйм!» — дип кычкырды. Батыраеп алгарак чыккан хатыннар бу тавышка шунда ук сеңделәр, тавышлар арттагы рәтләрдән, куелыктан гына чыккалады. «Күпме басып торабыз инде? Без эшләмибезме?! Аяклар авырта, чыдайт нельзя!» — дип басынкы гына бер гөрләп алдылар да, Зәйнәп челәеп, кибеттәгеләрне берәм-берәм аралый башлауга, шым булдылар. Ул арада кибетнең арт ишегеннән кемнеңдер чуар шәлле баш түбәсе күренде, күз алдында түш киереп торган Зәйнәп «ә» дигәнче юк булды. Ул югында хатыннар кыюланды: «Булса да булыр икән мөртәт!» — диде зарланып берәү. «Шушы кыланчыкны башыбызга бәла итеп китерделәр бит!» — дип кушылды аңа бүтәннәр. Зәйнәп ак камыр кебек кыска буынлы, юантык кулларын шактый каралган чүпрәккә сөртә-сөртә килеп чыккач, күз карашлары җылынды, тавышлар тынды. Үтенү, үгетләү сүзләре шактый көткәч кенә яңгырады. «Сата башла инде, апаем,— диде өлкән яшьтәге, өстендәге ирләр пинҗәген мунчала белән кысып буган озынча, арык хатын,— балам чирле!»

Нәҗип кибеткә кайтып җиткән сыек майның сатылмау сәбәбен аңламады, үзенең юк эш артыннан йөрүен чамалап, ишек катынарак тартылды. Каранды: кибет киштәләренең яртысын төрле-төрле эчемлек шешәләре биләгән иде. Аракының нинди генә юк монда, коньяклар бар! Бик кыйбатлылары бар! Кайтаралар икән кемдер сатып ала, эчә дигән сүз. Кинәт көн ачылып киттеме, рәшәткәле тар тәрәзәгә яктылык бөркелде, киштәләрнең шешәләр тезелгән яртысы нурланып балкып, икенче яртысы фәкыйрьлеге, өметсез ярлылыгы белән күзне кисте. Кәгазьләре күгәреп беткән тоз каплары, шырпы, ике-өч балта сабы, ята-ята ала-кола тапланган радиоалгычлар... алар артында тышлыклары дымнан кабарган китаплар күренде. Иң өстә «Микрохирургия» дәреслеге ята... Ул арада шым гына арт ишек ачылды, Зәйнәп йомылып юк булды, тынчу кибетне ризасызлык авазлары күмде. Нәразыйлыкны Зәйнәп тавышы каплады: «Сез! Әллә бригадир хатынын да чиратта тотар идегезме, оятсызлар!»

Тавышлар басылды, киресенчә, мактау, хуплау сүзләре ишетелгәләде: «Ә, ул икән! Алсын, алсын! Аңа ярый! Төс!» — диештеләр хатыннар. Кеше һаман өстәлә торды, төркем тыгызланды, инде Нәҗип уртада кысылып калды. Яктылык арткач, ул бер нәрсәгә — хатыннарның тешләре юклыкка игътибар итте. Күпчелекнең теше сынып, коелып беткән, теш казналары суланып, иреннәре бөрешеп бөтенләй югалган, яңаклар суырылып эчкә кергән, сөйләшкәндә авазлар йотылып, имгәнеп чыга... «Ни булды

сезгә, авылдашлар?» — дип чак сорамады ул. Һава кызды, хатыннарның да температурасы арта бара иде, кызган халыкка ялгыш бер очкын төшсә дә, әллә ни булуы ихтимал, дәшмәвең алтын.

Беркем аны аралап эндәшмәде, сорашмады, гомумән, монда гадәттәге сәлам алышулар, кочаклашып күрешүләр, сөенешеп хәл-әхвәл белешүләр, ара-тирә көлеп куюлар беткән икән. Сытык чырай, җимерелгән кашлар, таушалган кием-салымнар, өметсезлек чокырына, тирәнгә баткан күзләр. Кергән бер кеше артка баса да, кәҗә имчәге сыман асылынган түшен бүтәннәрнең очлаеп торган калак сөякләренә төртеп, Зәйнәпкә карап тора башлый. «Читлеккә ябылган җәнлекләр кебек»,— дип уйланды Нәҗип үзалдына. Арт ишек сирәк-мирәк ачыла, кайчагында баш күренә, ара-тирә аннан кул гына изиләр. Зәйнәп терсәкләрен җитез йөртеп югалып тора. Җыелганнар «Инженер хатыны килгән», «Бухгалтер алып китте», «Завхоз кызы күршеләренә дә алган» дигән соңгы хәбәрләрне тыңлап, ләкин берсенә дә ачык мөнәсәбәт белдермичә, аякны аякка алыштырып басып торалар. Ниһаять, Нәҗипнең түземе бетте, һавасызлыктан йөрәге, башы авырта башлады. Ул югарыдан, хатыннар башы өстеннән, ирләрчә нык итеп: «Сата башлыйсызмы сез, юкмы?» — дип кычкырды. Зәйнәп дәшмәде. Нәҗип соравын кабатлады, тавышы тагын да көрәеп, усалланып чыкты. Бүтәннәр кысылышып юл сапты, Нәҗип Зәйнәпне ачыграк күрерлек итеп алгарак үтте. Зәйнәп аны танымый, ул чит авылдан китертелгән сатучы иде. «Син! — диде ул, бәбәген Нәҗипкә терәп бетереп. — Кычкырма! Май авыл хезмәт ияләренә сатыла. Идарәнең карары бар. Мин аны уза алмыйм». Мөнир хатыны Халисә, телгә килеп: «Ул Йосыф абзый малае ич!» — «Җәллисеңме?» — диде Зәйнәп. «Җәллим»,— диде Халисә, аны-моны уйламыйча. «Җәлләсәң, кочаклап ят, минем эшкә тылкышма!» Әле генә Зәйнәпне сүгеп, каһәрләп торган хатыннар аның ягына күчеп, хихылдарга, Халисәне үртәргә тотындылар, бичара хатын чиратын ташлап чыгып ук китте. Нәҗип телен тешләде. Арт ишек тагын ике тапкыр ачылып ябылды, ниһаять, төрле зурлыктагы бидоннар, шешәләр, пыяла банкалар тотып, биш-алты хатын килеп керде. Җыелганнар атынып, дулкынланып алды, соңгы кергәннәр иртәнге савымны тәмамлап кайтучылар иде. Юл ярып аларны алга үткәрделәр, Нәҗип тагын артта калды. Кергән хатыннардан борынны ярып силос, авыр сенаж исе килә, сырма өстеннән кигән кап-кара халатларына коймак-коймак сыер тизәге, салам-солам һәм чүп кисәкләре ябышкан иде.

Сыек майлы авыр бидонны Зәйнәп сыңар кулы белән генә очыртып чыгарды да озын саплы чүмеченә тотынды. Күзләр шул чүмечкә төбәлделәр. Ул сыер савучыларга май тутырды, үзе күзен шакмакландырып һаман Нәҗипне күзәтте. «Күрсәтәм әле мин сиңа! Май түгел, бүтән нәрсәңне тотарсың!»

Сыер савучыларның соңгысы, иң иске, таланган, җиң очлары чачакланган халат кигәне, озак мыштырдады. Ул озаклап Зәйнәпнең колагына нидер пышылдады, сатучының авызы ерылды. Ул, хатынның култык астыннан иске букча алып, аңа бер-бер артлы өч шешә аракы шудырды. Нәҗип яныннан үткәндә бу хатынның авызыннан көйгән самогон исе бөркелде. Җыелганнар аны да якладылар: «Аларга ярый! Төс! Аракы да эчмәсәң, безнең фермада ярты елда кәкрәеп катарсың!»

Озын саплы «алдыр чүмеч» флягага чумып югала да чупырдап килеп чыга, өлгер Зәйнәп бер тамчысын әрәм итми, читкә тамызмый, чүмеч күз ачып йомганчы бушый. Сәгать ярым басып торгач, Нәҗипнең дә чираты җитте. Шактый җылынган (ул чакыручы юкта да ике тапкыр арт ишектән чыгып керде!) Зәйнәп чыгынкы маңгаен сарган матур чәчләрен кул аркасы белән артка сыпырды да, Нәҗипнең бидонын кире этәреп: «Документың бармы?» — дип сорады. «Нинди документ?» — «Шушы авыл гражданины булуың турында».— «Мин Казанда яшим».— «Яшәгән җиреңдә аша да инде син, абзыкаем. Авыллар өлешенә кермә. Хезмәт ияләренә, совет гражданнарына болай да май җитми. Син анда балда-майда йөзәсең, диләр... Имеш, берүзең бер кантурда баш булып утырасың икән. Начальник анда син. Ә монда мин начальник. Белмәсәң, белеп кит, яме».

Сүз башында Нәҗипкә якын теләктәшлек белдереп торган хатыннар беравыздан Зәйнәпне якларга, алай гына түгел, «Хак әйтәсең!», «Ай, безнең Зәйнәп туры сүзле дә!» дип мактарга тотындылар. Эш кая барып җитәр иде, ишек түбеннән ачулы бер тавыш яңгырады: «А ну, сука!» Хатыннар шым гына тавышка борылдылар. Зәйнәпнең кырган кашлары дерелдәде. Ишек катына тәмәке суырып Гөлгенә белән аның ахирәте кереп басканнар иде. «Син, уйнашчы!» — Гөлгенә, терсәге белән чиратны нык ерып, Зәйнәп каршысына килеп басты, ике кулы белән прилавкага таянды. «Син, тишек иләк!» Зәйнәп авызын бәлшәйтеп көлде, аңа ияреп бүтәннәр дә хихылдады. «Кил, кил, Гөлгенә аппагым, сиңа чиратсыз да бирәм»,— диде Зәйнәп, юхаланып. «Син миңа бирмә, аңа бир! Председательгә бирәсең, парторгка бирәсең, аңа да бир!» Хатыннар Гөлгенәнең кай якка суктырганын чамалап, почмакларга сеңделәр: ай-һай тел! Парторгка гаеп ташлый... Председательгә кизәнә! Яшәтмәсләр бу тиле башны! Тфү, тфү, бәласе йокмасын! Кайберәүләр май аласыларын да онытып, кибеттән чыгып ук шылды. «Анда иденме, нигә Гөлгенәнең авызын томаламадың?» — дип, идарәгә чакырып арт сабагыңны укытырлар. Күрмәвең — көмеш, ишетмәвең — алтын!

Зәйнәп бушлык уртасында бидонын кочаклаган Нәҗипкә әче елмайды: «Йөрисең баш бутап, абый кеше. Мин Гөлгенә кешесе дисәң, әллә кайчан бирә идем». Тынлыкта май аккан тавыш кына калды. Хатыннар инде Гөлгенәне кыстарга керештеләр: «Син дә ал, читенсенмә, күпме теләсәң дә ал!»

Аракыдан бушаган ярты литрлы шешәгә күздән тутыргач, Гөлгенә акча чыгарып тормады, Нәҗипкә кыю күз кысып, артларыннан чыгарга ымлады да юк булды. Алар артыннан ишек ябылуга, Зәйнәп: «Май бетте. Таралыгыз, тарал. Әле рәискә кертеп чыгасы бар, парторг, ревкомиссия рәисе алмаган. Ни көтәсез тагын? Күтәрегез үкчәләрегезне!» — дип, кашын-күзен җимереп чинады. Тешсез авызлардан сүз чыкмады, хатыннар иртәгә тагын Зәйнәп катына баш орып киләселәрен чамалап тындылар, шым гына таралдылар. Югары авыл урамында саз чапылдаганы шактый вакыт ишетелеп торды. Нәҗип үзе күргән тамашадан тәмам югалып калган иде, хатыннар артыннан чыгарга атлаганда, аны кибет эченә ыргылган икенче дулкын — ирләр ташкыны өерләп кире алып кереп китте. Ирләр, бер-берсенә төртеп, киштәләрдәге шешәләрне күрсәтешеп, Зәйнәп каршысына ябырылдылар. Кибет эче күтәренке, күңелле тавышлар белән тулды. Зәйнәп сандугач булып сайрады, тургай булып канат какты, карлыгач булып очты.

Нәҗип, мөлдерәмә тулы бидонын чайпалтмаска тырышып, аяк астын күзе белән капшый-капшый, шактый озак кайтты, хәзинәсен исән-аман әнисе кулына тапшыргач, бичара карчык түзмәде, бөгелеп төште. «Менә бит,— дип такмаклады ул.— Ир-ат төшкәч, тутырып биргән. Мае өресез, чип-чиста, исе лә исе! Без ни, исәпкә бар, санга юк дигәндәй, төшсәк үртәлеп кайтып китәбез. Бирсә, әйрән тутыра, аның да яртысын үзенә апкала. Әтиең теләсә ни дисен, берәр балаң янында булса, ни әйтер идең кана?!»

Авыл кешесенең шул инде: шатлыгын уртаклаша башласа да, авызы кара кан белән тула. Һич уйламаганда, теләгән фикерен әйтеп, күңелен бушатты Мәрьямбикә. «Нигә кумыйсыз андый кибетчене?» — дип сорады Наилә. Ире артыннан ук төшеп киткән Гөлгенәләрне ул бик җентекләп карап калган иде.

Карчык, куркып-каушап, чак бидонын аударып җибәрмәде. «Әстәгъфирулла, килен, тәүбә диген. Ничек телең әйләнә? Зәйнәпне рәис ияртеп килде, килүенә партиягә алдылар үзен, авыл арасында ялгыш сүз ычкындыра күрмә берүк. Рәискә кардәш тиешлеме шунда, бүтән якынлыгы бармы. Зәйнәпне бик якын итә, диләр. Авылда бүген кибетче баш! Рәис үчегешеп, ваксынып йөрми, Зәйнәпкә карап ярты сүз генә әйтә. Парторгы да Зәйнәпне өстерә».

Яхшыга авыз ачып, соңра искәрмәстән рәис, парторгларга тел тидерүен абайлаган карчык тәүбәгә килде, белгән догаларын ашык-пошык укый башлады.

Аның ихлас хөрмәтен, олылавын, гаҗәпле шатлыгын күргәч, кунаклар сыек майның бу йортка байтактан кермәгәнен төшенделәр.

**20**

Кунакларны көнаралаш мунча ягып, вак бәрәңге һәм каты-коты ипи белән генә үткәреп җибәрергә ярамаганын Мәрьямбикә дә, дөньяда ваемы калмаган Йосыф карт та бик яхшы аңлый. Ил-күз алдында хурлык: кайтканнарына кайчан, йорттан таба исе чыкканы юк, коймак, бәлеш пешми, Гөлгенә белән аның ахирәте генә түгел, Фәрәхетдиннең паралич суккан чалыш карчыгы да, чапырыштагы Минәч карт белән аның шикәр авырулы Бәдриҗамалы да Йосыф ихатасыннан, олы кунак төшкән йорттан, тәмле исләр таралганны көтәләр. Чөнки бәлеш-мазар пешергәндә Мәрьямбикә карчыкның ятим-ялпыны, күрше-каршыны өлешсез калдырганы юк иде. Ит пешмәсә — бит пешә. Нәҗип белән Наилә, балаларны ияртеп, кипкән Көмешкүлне тамаша итәргә чыгып киткән арада, Йосыф карт, дуңгызлар яныннан кайтып килүче, шактый кәефләнгән Сөнгать арбасына утырып, идарәгә кадәр төште. Язгы чәчү барган көннәрдә колхоз, кысыр сыер, йә булмаса, кышлау үгез суеп, ир-ат механизаторларны җыеп, шәп кенә мәҗлес үткәреп ала торган иде. Быел да шул тантана якынлашуы Йосыфның мүкләнгән колагына керде. Ул рәис Ихлас янына барырга тәвәккәлләде. Кая барасын карчыгына әйтеп тормады. Гәрчә картның күңелендә ниндиерәк иләс-миләс уйлар кайнаганын ул болай да сизә иде.

Ихлас идарәдә булып чыкты, көттереп кенә ул картны үз янына дәште, сорау белән аңа күтәрелеп карады. «Ихлас туган, синең хозурыңа ифрат зур гозер белән төштем әле».— «Йә, шуннан?» — диде коры гына Ихлас. «Тамак ягы начарайды. Былтыр, беләсең, хәл юк дип тормадык, икебез дә эшкә чыккаладык. Бәрәңгебезне тышкы базга салырга соңардык, ул лапас астында көшелдә, суыкта ятты. Шуңа язга кисәүләнде дә...» — «Йә, йә»,— дип ашыктырды аны Ихлас. Йосыф сүз эзләп, фикер җыеп торды. Кыска һәм үтемле итеп әйтәсе килде аның! Ишетсен әле Ихлас та Йосыфның тавышын! Тик... гозерне, ялынычны көчле, саллы сүзләр белән ничек оештырып әйтә аласың? Хәерчедән берчакта да тук тавыш чыкмый шул... «Әз-мәз он язып бирмәссеңме дигән идем. Аннары ит... Хет ике-өч кило! Тана чалгансыз икән дип ишеттем». Ихлас, җавап биргән чакта, тоткарланып, уйланып тормый иде. «Ит — механизаторларга. Бүленеп куелган. Бүтәннәргә граммын да бирмибез. Сиңа бирсәк — ярты авыл төшәчәк. Он... кибеткә ипи кайтып тора, макарон да күренгәли. Син пенсионер, сине колхоз түгел, хөкүмәт кайгыртырга тиеш». — «Бирмисең алайса?» — «Үземнән булса, рәхәтләнеп бирер идем,

үзем мал асрамыйм, Йосыф агай. Түзәргә туры килә. Менә тормыш яхшырып, колхоз тагын да ныгып китсә, карарбыз». Йосыф кыза төште: «Күпме көтәргә була? — диде ул, әрнеп. — Миңа бүген кирәк. Бүген!» Ихлас аңа гаҗәпләнеп карады: акылыннан шашканмы әллә бу тишек галуш? Даулап төшкәнме? «Юк!» — диде Ихлас өзеп һәм җитәкләп картны ишеккә кадәр китерде...

Нәҗипләр Көмешкүл ягасыннан сүзгә саранланып кайттылар. Малайлар гына: «Әби, без кыр үрдәге күрдек!» — дип шыбырдаштылар. Картының түбән очтан, идарә ягыннан үлек төсенә кереп кайтуын да Мәрьямбикә аруга юрамады. Йосыф Казан кунакларына ачылмады, кайтты да урынына ауды, улы хөрмәтенә генә сорашып төшкәнен ул Ихласка әйтүне кирәк санамады.

Мәрьямбикәнең, Йосыф бик нык чирли башласа дип, күз карасыдай саклап тоткан, бала йодрыгы хәтле сары мае бар иде, шуны чыгарды. Беркөн бәрәңге дурычмагы пешерде — майлап ашадылар. Икенче көнне кыстыбый бөкте — аны ашарга да җитте сары май. Карты белән чышын-пышын киңәшкәннән соң алар бердәнбер бәрәннәре Бүркәне суярга карар бирделәр. Дөрес, әле ел иртә, май башы гына, бәрән арык, ите ике учка сыеп бетәчәк, көтүдә йөртеп, йортта ашлы сулар белән сыйлаштырсаң, көзгә аннан илле кадак ит чыгачак! Ләкин... йорты тулы кунак! Үзләре ничек тә җан асрарлар, ничә елга бер күрешкән балаларына яңа суйган ит тә ашатмагач, дөньясы корысын!

Көтелмәгән яктан тагын җайсызлык килеп чыкты.

Көмешкүл кипкән, Олы суда балык заты калмаган, инеш ярларына, болыннарга чыгарлык түгел. Велосипедны, аяк арасында уралмасын дип, чоланга ук чыгарып ташладылар. Нәҗип-Наилә балалары белән күбрәк өй арасында, сарык-кәҗә тирәсендә уралдылар. Ни чарадан бичара, сугыш коралларын шәбәйтергә тиешле Нәҗип мал-туар белгече булып китте. «Менә кәҗә, — диде ул, ике сырлы мөгезне тотып. — Сөт бирә, мамык. Сөте шифалы, файдалы». Кәҗә белән дуслашмадылар малайлар: әтисе ычкындырып җибәрүгә, ул Искәндәрне сөзәргә килә башлады.

Сарыклар да кырагай булып чыкты, малайларга баш иеп дуслашырга теләмәделәр, тояклары белән пычрак чәчрәтеп, капкадан лапас астына кадәр чаптылар да чаптылар. «Тавык — аңгыра кош, — диде әтиләре, — күкәе тәмле булса да, үзе аңгыра, кеше белән сирәк дуслаша».

Малайлар замат арасында сарык бәрәне Бүркә белән аралашып, аны яратып өлгерделәр. Бәрән ифрат акыллы иде, мәхәббәткә мәхәббәт белән җавап бирде. Малайлар чакырса килде, колак артын кашытты, ипи кыерчыгы бирсәләр, кыстатып тормады, бармакларны рәхәт кытыклый-кытыклый ризыкны кулдан алды.

Бүркәнең көтүдән калганын олы малай тиз аңлады, пес итәргә чыккан җиреннән йөгереп керде дә: «Әни, Бүркәне бикләгәннәр!» — дип кычкырып җибәрде. Бәрән дә үзенең тоткынга эләккәнен сизенеп, сузып-сузып мәэлди иде. Наилә ни дияргә аптырап торганда, авыл карчыгы телгә килде: «Бүркәне суябыз, улым, аш салырбыз, пилмән бөгәрбез, бәлеш ясарбыз, сыйланырбыз!» Олы малайның күзе шар булды, керфекләре леп-леп бәргәләнде: «Ничек суясыз?» — «Муенына пычак салабыз да кых итәбез. Әтиең белән бабаң суяр, сез карап торырсыз, өйрәнерсез, егет кеше сугым суярга өйрәнергә тиеш». Әбисе сүзен бетергәндә, Искәндәр идәндә тәгәри-тәгәри җылый иде: «Суймагыз Бүркәне, суймагыз! Кисмәгез аның муенын!» Әллә нинди дәлилләр кушып үгетләсәләр дә, ярсыган малайны җайга китерә алмадылар. Ул такмаклап һаман җылады, җылый-җылый шешенеп бетте. Абыйсының ник җылаганын аңлап бетермәгән Рөстәм балалык теләктәшлеге белән аңа ияреп акырырга тотынды. Нәҗипнең йөрәге урыныннан купты, Наилә ярсыды. Ниһаять, пычакка ял, бәрәнгә гомер бирделәр.

Бүркәне тау итәгендә утлап йөргән көтүгә илтеп кушканчы җылады Искәндәр.

Малайлар җиңде, гауга бетте, ә табында пилмән юк, итле шулпа бу атып пешми. Бит пешә, бит! Бит пешкәннән тамак туймый, киресенчә, эч чурлый, ашказаны кычкырып тәмле ризык сорый...

Нәҗип белән Наилә арасындагы кискенлек йорттагы киеренке шартларда кечерәеп калды, алар сүзсез генә бер-берсен аңлап, артык сүзләр сөйләшмичә генә гафу итештеләр. Карт белән карчыкның авыр тормышы, хәерчелеге аларның зар-моңнарын оныттырды. Ике арадагы каршылыклар чүп-чар, су өстендәге күбек булып калдылар. «Илдә яхшы кеше калмады инде! — диде берчакны Йосыф. — Ил белән бозылдык».

Нәҗип белән Наилә балаларга сыек май болгаткан вак бәрәңгене ашаталар да йокларга яткыралар, үзләре чолан идәнендә, толып астына кереп, колактан-колакка сөйләшәләр. Нишлибез? Нишләргә? Кая барып бәрелергә? Яшелчә, һич югында, суган кыягы өлгерер дип көтәр идең, әле җиргә җылы керми. «Җир җылына алмыйча интегә хәзер», — диде бермәлне Мәрьямбикә. Яши-яши бу фикернең олылыгын да аңладылар. Юл буйларында, кашлак урыннарда үлән баш төртте, тау битләре хәйран яшелләнде. Әле кузгалак-кукы ише нәрсәләр күренмәде.

Җомга көнне Яңа урам очында яшәүче Камалиларның сыеры күпер чыкканда такта арасына кыстырып аягын сындырган да суйганнар. Ит арттырырга чамалары бар икән дигән хәбәрне бу араларда өеннән чыгыбрак йөрергә ярата башлаган Мәрьямбикә ишетеп кайтты. Нәҗип соңгы акчасын йомарлап шунда торып чапты. Килосы җиде сумнан! Камали көч-хәл белән йөри икән, сугыштан кырык яра, кырык ямау алып кайткан кеше, карчыгы кемне күрсә дә үкереп җылый. «Кайчан сыер малына тиенәбез дә, гарип картыма ни ашатырмын? Сөт, катык ашап кына исәнлеген иплән бара иде

бит! Тәңрем, ник каргадың безне? Сыерыбыз сыер гына түгел иде, хәзинә иде!» Сатулашмады Нәҗип, җидешәр сум түләп, өч кило ит алды. Кичкә ит шулпасы пешерделәр.

Нәҗип, әдәп саклап, әнисенең киңәшләрен тотып, исән калган, сирәгәйгән күрше-каршыларга, чыбык очы агай-энеләргә тиз-тиз кереп, сәлам алышып чыккалаган иде. Күңеле күтәрелмәгәч, авыл советы, колхоз идарәсе кебек урыннарга кереп, күрешеп чыгу турында уена да китермәде. Бүген, ясканып, ипине дә эре-эре кабып токмач ашарга утырганнар иде, нык итеп ишек кактылар. Ит алып кайткач чәк кенә ачылып киткән Нәҗип тиз-тиз барып ишекне этеп җибәрде, теге якта басып торучының иңенә бәрде. «Кунакны шәп каршылыйлар икән монда?» — диде кеше, юриме, чынмы иңбашларын уып. Нәҗип кызарынды: «Гафу итегез!» Мәрьямбикә очып кына ишек катына килде: «Әйдүк, әйдүк, мактап йөрисез икән, табынга рәхим итегез, хуш килдегез!» Йосыф кузгалмаса да, әнисенең очынуына карап керүченең эре балык икәнен искәрде Нәҗип. Мәрьямбикә, «ай билем, һай гәүдәм!» дип өзмәс зарланган карчык, керүченең бер алдына, биш артына төшеп, бөгелә-сыгыла сәламләде, шуннан соң гына кунак белән таныштырырга булды: «Рәисебез бу, көтелмәгән кадерле кунак, юрасаң да болай мач килмәс. Әйдә, Ихлас улым, уз түрдән!» Гаҗәп, рәис Ихлас Мәрьямбикәне күрмәде дә бугай, Йосыфка да карамады, кумәк кыстаган хуҗаларга рәхмәт әйтмәде, өстәл белән урындык арасына баскан Нәҗипкә текәлде. «Минем Нәҗип иптәш янына кагылуым иде»,— диде ул. Нәҗип, аңа ияреп, болдыр баскычына чыкты, алар шунда янәшә бастылар. Ихлас Нәҗипнең буй-сынын, кием-салымын, тәҗрибәле җөйче күзе белән үлчәп сынап чыкканда, Нәҗип аны тагын бер тапкыр табынга чакырды: «Картлар рәнҗер», — диде. «Рәнҗемәсләр! Алар өйрәтелгән. Председательгә рәнҗемәскә кирәген беләләр булыр. Председательне яратырга гына ярый».— «Алай да... картлар күңеле уалырга гына тора»,— диде Нәҗип, тавышы йомшарып, юашланып чыкты. «Менә нәрсә, Нәҗип иптәш,— диде Ихлас, кинәт кырысланып.— Юк-бар адәмнәргә кул биреп чыккансың, идарәдә күренмәдең. Ярый. Бар, син кер, тамагыңны туйдыр. Аннан туры идарәгә төш. Мин анда».— «Төшәрмен»,— диде Нәҗип, алдын-артын уйламыйча. Кул кысыштылар.

Нәҗипнең ашавы ашау булмады, рәискә ашыгыч ризалык бирүенә борчылды. Ихласның көтмәгәндә ишек шакуы да, йомышын әйтмичә кырт борылып чыгып китүе дә, орчык булып бөтерелгән әнисенә күз салмавы да, әтисенә ләм-мим эндәшмәве дә аңа авыр тәэсир итте. Һич югында, Наиләсенә сәлам бирергә кирәк иде. Кунак ич! Йомышы бар икән, әйтсен иде монда гына!

Картлар рәиснең килүенә дә, тиз чыгып китүенә дә сөенделәр. «Табын ярлы, табын! — дип уфтанды Мәрьямбикә.— Теге, иблис сидеге булса, чыгармый идем мин аны. Иң кирәге юк! Олы кешегә бөгелмәгәннәр дә шешә каршында сыгылып төшә!» Картлар рәиснең улларын үз катына өндәвен белгәч, чиксез шатландылар, чакыруны яхшыга юрадылар. «Авыл арасында дәрәҗәң артыр! Теләсә кемне чакырмый ул безнең рәис! Аңа, улым, ярты чакрымнан бөгелеп сәлам бирәләр, анда да күп сөйләшеп тормый! Персидәтел авылда — алла, районда — мулла, Казанда да мәзин әле ул! Кулы әллә кайларга үрелә! Утыр дисә, утка утырасың, суга ташланасың. Теләсә, челләдә бәке чаптыра безнең Ихлас!»

Председатель кабинетының ишеге ачык иде. Нәҗип туп-туры шунда барып керде. Ихлас ялгыз, түрдә берүзе. Баш очында — калынкаш бабайның дәү рәсеме, ярты стенаны тутырып тора. Күкрәк бүлтәеп чыккан, алтын-көмешкә манылган орденнар чәңгелдәргә әзерләнеп, саф-саф эленгәннәр. Бая кул кысышканнар иде, бу юлы күз очлары аша сәламләштеләр. Ихлас Нәҗипнең баш өстендәге рәсем белән кызыксынуын төкәндерде: «Районда беркемдә юк мондый затлы портрет! — диде.— Художнигын Ленинградтан китерттек. Ипи калагы хәтле генә җәбрәй, рәвешен китереп койды да куйды. Шуны әйтмәкчемен: «Сабит абыең кызыгып йөргән иде, берзаманны бездән биш арттырып җибәрде!» — «Сез Сабит абыйны беләсезмени?» — «Белмичә! Дуслар! Ул минем туган авылда председатель бит. Әйтмәделәрмени?» — «Әйткәннәр дә кебек»,— диде Нәҗип, томанлы гына.

Бүлмәдә бүтән мактанырлык нәрсә табылмады. Ләкин Ихлас, җитәкче буларак, замана нечкәлекләренең җелегенә төшкән зат, бүген мактанырлык нәрсә табылмаганда, Нәҗипне кулыннан тотып киләчәккә алып кереп китте. Менә киләчәктә! Менә анда күрерсез! Анда инде болай гына булмас! Алга, киләчәккә кыю карарга кирәк! Анда безне җиңүләрдән ары җиңүләр көтә! Американы куып узабызмы? Тфү! Ул безгә бер тиен тормый. Дөрес, ул бу сүзләрне әйтмәде, ләкин сүз сөрешеннән Ихласның якты киләчәккә юл тотканын аңлады, һәм хуплады да дип ышанды Ихлас, атаклы Сабитның энесе лә ул, алма агачыннан ерак тәгәрәмәс!

«Бу авылдан китәм, китәм диебрәк йөрдем. Шаккатырырлык идарә йортын әллә кайчан балкытып куя идем... Сызымнарын Казанда эшләттем. Егерме биш меңгә төште.— Ихлас почмакта посып утырган саргылт шкафны ачып, аннан кәгазь төргәк суырып чыгарды һәм сызымнарны өстәлгә җәеп таратты.— Сез аңлыйсыз! Карагыз: индивидуаль проект!»

Алар янәшә басып кәгазь өстенә иелделәр, бераздан калкындылар. «Әй,— диде Ихлас, гадәттән тыш күтәренке тавыш белән.— Син Сабит абый белән нәкъ бер буйда икәнсең!» — «Буйлар сезнең

белән дә бер икән!» — диде Нәҗип, аны куәтләп. «Минем белән дә! — диде Ихлас, ни өчендер мактанып.— Безнең беренчене беләсең дә беләсең инде?!» — «Ишеткәнем бар!» — «Районда председательләрнең, парторгларның гел бер буйда булуына иреште бит! Бездә хәзер җитәкче кадрлар Кремльне саклаучы солдатлар төсле бөтенесе бер буйда. Кстати, беренчебез Харис Вагыйзович шул командада хезмәт иткән!» — «Бер буйда булуның ни хаҗәте бар?» — дип сорады Нәҗип, гаҗәпләнеп. «Бар аның хикмәте, бар. Утыр син, утырып тыңла. Берзаман Казаннан, югары йорттан Беренче килеп төшә. Иярткән үзе белән бер көтү кеше. Самолеттан агылып чыгалар болар. Кайсы юан, кайсы нәзек, арада бүтәкәләр бар, кәтәнәләр, колгалар! Ә без торабыз монда крепость стенасы кебек, гвардиннар! Бөтенебез бер буйда — метр да сиксән җиде. Обком секретареның күзе яна!» Ихлас, күңелле мизгелне кабат исенә төшереп, рәхәтләнеп көлеп алды. «Шуннан?» — дип кызыксынды Нәҗип. «Уйлап эшләсәң, һәрнәрсәдән мәгънә чыга! Безнең Первый шундый. Ел авыр иде, сөт кими, ит планы тулмаган, кай яктан карасаң да эш сөрлеккән. Первый Казаннан безнең хуҗаны сугансыз-борычсыз ашарга дип усалланып чыккан. Харап! Безнең ныклы сафны күргәч, йомшады егет, дусларча гына орышкандай да итте. Йөри-йөри дә: «Яле, гвардиннарны тез әле!» — ди. Безгә нәрсә? Команда гына булсын! Тезеләбез, тезелмиләрме соң?! Шундый бердәм рәткә тезелеп озаттык тегене! Көзгә хуҗага — орден! Без дә коры калмадык! Вәт!»

Сызымнарга күз ташлап, идарә проекты турында өстән-өстән сөйләшкәч, Ихлас Нәҗипкә йөзен якынайтты: «Кал районда! Сине бик хәтәр заводта эшли, диләр... Атом бомбалары ясыйсың икән!» Нәҗип көлгән булды: «Андый завод Казанда бармыни?» — дип сорады. «Буең шәп! — диде сокланып Ихлас.— Хуҗага күрсәтсәң, сине җибәрми дә җибәрми инде ул. Күркәм буй!» — «Гел-гел буйга аркаланып яшәргәме исәп?» Ихлас Сабитның бертуган энесеннән ирония көтмәде, сорауны чынга алды. «О-о, безнең Харис Вагыйзовичның башы түгәрәк, маңгае текә! Яңадан-яңаны уйлап таба торган хуҗа. Утыр син, утыр. Утырып тыңла. Шулай берзаман Казаннан бик хәтәр вәкилләр ияртеп тагын кунак килеп төште. Мәскәүдән, министрлыктан кешеләр бар. Район өчен дәрәҗә, почет! Бер үк вакытта чиксез җаваплылык та! Әзерләндек, дөнья купты. Мәскәүлеләрне буй белән генә алдыра алмыйсың. Ризык та күргән алар, хөрмәтен дә. Тоттык та бөтен район мәктәпләреннән пионерларны җыйдык. Аэропорттан Сабит абый колхозына кадәр юлның ике ягына нәни әләмнәр токтан пионерларны бастырдык! Кыз белән малай алмаш-тилмәш. Көтәбез, борчылабыз, пионерлар көтә. Кыймшанмыйлар да, керфек тә какмыйлар. Аларга шулай кушылган! Боевое задание! Самолет төшәм дигәндә генә төрекмән бүреге хәтле генә болыт килде дә Эзи өстенә эленмәсенме! Коеп яварга тотынмасынмы! Ишә генә! Балалар тора, аларга шулай кушылган! Өч мең ярым баланы җыям дисәң дә... Салкын тимәсме дигән шик-шөбһә әйтүчеләр булды булуын, совет баласына пычак булсынмы, нык ич аның нигезе! Корыч! Соңыннан яңгырга куанышып бетә алмадык. Пионерларның шәбәреп, әләмнәрен болгап, коеп яуган карлы-бозлы яңгыр астында каршылаулары казанлыларга гына түгел, мәскәүлеләргә дә ошады. «Мондый бөек патриотизмны очратканыбыз юк иде!» — диештеләр тегеләр. «Менә шушы була инде чын интернационализм!» — дип мактыйлар. Ул елны уҗымнар начар кышлаган иде, басулар ала-кола, ит планы үтәлмәгән, сөт тапшыру — утырып җыларлык, дуңгыз кырылган, үрдәк бибиләре үлеп беткән. Пионерлар сафы артыннан җитешсезлекләрнең берсе дә күренмәде. Кунаклар безне мактап киттеләр, ә көзен хуҗага — орден! Аңа эләккәндә, без буш калабызмы? Яши белергә генә кирәк. Бер нәрсә кызганыч — буйлы егетләр авылда калмый! Офицер погоннары тарта яшьләрне. Парадны карыйлар да хәрби мәктәпләргә ычкыналар!» — «Балалар чирләшмәдеме соң?» — дип сорады Нәҗип, Искәндәре белән Рөстәмен уйлап. «Һәй,— дип кул селкеде Ихлас.— Авыл баласына пычак булсынмы аңа!»

Казан хәлләрен сораштырганда Нәҗипнең югары сыйныф вәкилләрен, затлы җитәкчеләрне белмәвенә гаҗәпләнеп, хәбәрдарсызлыгына исе китеп утырган Ихлас, сүз җебен үз кулына алып, Америкадагы кабахәт, канга туймас сенаторларны, конгрессменнарны, халыкны таларга яраткан Пентагонны сүгеп чирек сәгатьлек кайнар речь сөйләп ташлады. Кинәт башлаган сүзен капыл туктатып, Нәҗипнең иңенә кулын салды. Әңгәмә кызгач, алар диванга күчеп, янәшә утырганнар иде. «Кайтасыңмы районга? Кайт, җүләр! Мондый буй белән... Яшим дисәң — дворец салдырасың. Теләсәң, хуҗалык — алпавыт утары торгыз. Нигә үз авылыгызга кайтмаска! Ата-анаңа терәк булыр идең. Иң мөһиме — абыең, Сабит Йосыпович монда. Үзара гына әйткәндә, аны быелгы конференциядә Беренче итмәкче булабыз. Харис Вагыйзовичны Казанга күтәрәбез».— «Сез сөйләгән хезмәтләре өченме?» Әле Ихлас бу юлы да Сабит энесеннән, Нәҗиптән, Казанда бомбалар ясый торган завод инженерыннан ирония, этлек көтмәгән иде, кунакның шырпысы барып ук җитмәде. Ихлас үз сүзен сөрде: «Җүләр булма, уйла! Риза икәнсең, хәзер хуҗага шалтыратам да янына алып барам».— «Ә сез Сабит абый урынына калмакчымы?» — диде Нәҗип. Ихлас маңгаен җыерды: «Андый перспектива да юк түгел!» — диде.

Нәҗип өзеп сүз әйтмәде: күңелендә икеләнү корты кыймылдады. Икеләнү минуты белән арта торды. Төрле уйлар килеп китте егет башына!

Чыннан да, шәһәрдәге мәхшәр, ыгы-зыгылар, сары йорт хәсрәте, буш кесә, кимсенүләр — һәммәсе өелеп тегендә, җәһәннәмдә калыр иде. Чиренең төп сәбәбе — эшкә ашмаган теләкләренең күплеге, өмет юлының кинәт киселүе дип уйлый ич Фаина Марковна. Фәридун Фазлыев та шуны куәтли. Картлар авылда җайлаша алмый икән, аларның заманы, чоры узган. Алпавыт утары кебек мәһабәт сарайда яшәп, тавык бавыры белән каз боты ашый башласаң, Наиләнең дә теле тыелыр иде. Аңа да рәхәт күрергә бик вакыт! Ә малайлар... малайлар! Чем-кара «Волга» машинасында черт-черт көнбагыш чиртеп Эзи мәктәбенә укырга йөрерләр. Укытучылар аларның кем баласы икәнен белеп игътибарларын арттыралар... Колхоз бүгенгә артта икән, Сабит абыйсының ярдәме белән Нәҗип Йосыпович хуҗалыкны күтәрә алмасмы? Ихлас та читкә какмас! Болар районның баганалары икән ич!

Чирләп ауганнан бирле һәрнәрсәгә шик белән карарга, берәүгә дә ышанмаска күнегеп баручы Нәҗипнең шикчеллеге өскә чыкты: «Тукта, постой, татарин,— диде ул үз-үзенә.— Шушы әтәм-сәтәм хуҗалыкны сиңа сылап, Ихлас Сабит абый авылына китеп барачакмы?! Шәһәр кунакларын, Мәскәү вәкилләрен ташыйлар икән, Сабит абыйсы эшне тәгәрәтеп алып бара торгандыр! Нигә миңа Сабит абый хуҗалыгын алып калмаска?! Нигә аны Ихласка бирергә?!»

Нигә ва-банк бармаска?! Ул шиген Ихластан яшермәде. «Тәҗрибәсез килеш бу авылга кайтырга кыймыйм. Сабит абый урынына дигәндә... уйлап карарга ярый!» Яшелле-күкле булды Ихлас, тамагына коры ризык утырган үрдәк сыман, су эзләп, як-ягына каранды... «Син, син! — диде ул, тотлыгып.— Үзеңне Сабит абыйны алыштырырлык зат дип санйысыңмы? Син аның кем икәнен беләсеңме? Алла ич ул, пигамбәр!» — «Ә сез, Ихлас иптәш,— диде юри сүзләрен сузып әйтә-әйтә Нәҗип,— Алланы алыштыра алыр идегезме? Андый көчегез бар икән, нигә безнең авыл шулай тезләнгән?!» — «Мәсәлән?» — дип сорады Ихлас, дерт итеп китеп. «Нигә шул бакыр бугазлы кибетчене тотасыз?» Баярак Нәҗипнең уенын-чынын бергә бутап ычкындырган төртмә сүзләрен дөрес аңлаган икән Ихлас, бу кеше, Сабитның кан кардәше, Казан заводларының берсендә хезмәт итүче инженер, Ихлас күнеккән әңгәмәдәшләрнең берсенә дә охшамаган иде. Юк-бар кешеләргә кергәләп, идарәгә төшмәвеннән үк күңеле бизгән иде аның Нәҗиптән. «Аның авызы тулы гайбәт! Бер дә юньле сүзе юк!» — дип, Зәйнәп килеп шикаять кылгач, ышанып та бетмәгән иде Ихлас... Ләкин Нәҗипне күрми булдыра алмады. Беренчедән, Гөлгенә явыз кайтып төшкән чак. Ул аларның парлап урамнан су ташыганнарын да, кибет сукмагында очрашуларын да ишетеп өлгергән иде инде. Ниләр сөйләштеләр икән? Теге алап авыз авыл тормышыннан нинди гаепләр табып өйде икән?.. Сагаерга, серен алырга, моның өчен Нәҗипкә якынаерга кирәк иде. Күр менә, яхшылыгыңның әҗерен ал, син аңа мактаулы эш тәкъдим итеп, аның дәрәҗәсен күтәреп утырасың, ә ул кулы белән тизәк изә, сасыны тарата... Ихлас алай тиз бирешә торганнардан түгел, әлегә ул монда хуҗа! «Әле синең шулай быткычланып, күзәтеп һәм донос ясап йөри торган гадәтең дә бармыни?» — дигәнен Ихлас сизми дә калды.

Нәҗип дәшмәде, ике тезенә ике кулы белән шап итеп сукты да аягына басты, идарә проекты сызымнарына күз ташлап, әче көлемсерәде, ишеккә атлады. Ихлас аны озатмады, киресенчә, китәргә дип ишеккә юнәлгән кунакны онытып, кукраеп өстәле артына кереп урнашты, чыраена гадәттәге кырыслык, корылык чыкты. Ни беләндер Нәҗипне таптыйсы, түбәнәйтәсе килде. Башына яңа уй килде! Бусага аша атлаган Нәҗипне аның суык, битараф тавышы туктатты. «Мин анда завхозга әйткән идем, бер кило ак май, биш кило ит төшеп алыгыз».— «Күпме түләргә?» — диде Нәҗип һәм, ваксынуын аңлап, телен тешләде. «Нинди түләү?! Сабит абый хөрмәтенә күчтәнәч».

Беркөн Сабитның әтисе Йосыф карт ит сорап ялварып төшкәч, тупас кына борып чыгаруына Ихласның кәефе кырылып йөри иде. Тупасрак кыланды шул... Карт кайтып өйдәгеләргә сөйләгән булса? Казаннан кайткан кошлар Ихлас турындагы кара сүзне башкалага ияртеп кайтып китсәләр? Йомшарырга, Сабит алдында да яхшы атлы булып, боларның күңелен дә җебетергә кирәк иде. Ул чакта кызмыйча да булмады шул! Карттан алдарак кына Гөлгенә төшеп, түргә үк кереп утырып, шук күзләрен уйнатып ит сораган иде. Соравы сорау гына булса икән, хакы бар кеше сыман төшкән төрмә кошы! «Синнән алачакларым минем бик күп әле! Өч-дүрт кило ит биреп кенә котылырмын дип уйлама!» — дип, Ихласның күзен ачырмыйча, тә-тә килеп утыра сасык!..

Нәҗип чыгып китте, Ихлас идарә дежурныен завхоз янына йөгертте. «Йосыфка ит... май бирсен!» — дип боерды.

Исемен атап кычкыргач, ул туктап борылды. Гөлгенә дәшә икән, кулындагы зәңгәр кыйгачын болгый-болгый бастырып килә. «Син кулыңны картлар кебек артка куеп йөрисең икән!» — «Бардыр инде, Гөлгенә».— «Теге иблис ник чакырткан?» — «Кайсы иблис?!» — «Беләсең ич, кыланма. Авылда әллә ничә иблис булмый».— «Ник дип, гәпләшеп утырдык».— «Син аның бер сүзенә дә ышанма. Сыңар сүзенә дә! Хәйлә капчыгы ул, алдар таз, көнче күбәләк, аның юньле кеше юлына тәбе корудан башка шөгыле юк та!» — «Колхоз ничек бара ул чагында?» — «Бер кузгатып җибәргәч, таудан таш та тәгәри, ава-түнә, туктар-туктамас бара!» — «Хәле бетеп туктаса?» — «Туктады дигәндә кемнеңдер канын суырып кузгаталар аны!»

Гөлгенә белән иңне иңгә терәп түбән очтан менгәнне Наиләсе күрсә ни уйламас? Бу арада мөнәсәбәтләре чак кына җылынып, аруланып килгәндә тагын ызгыш-талаш килеп чыкмасмы? Ул,

адымнарын акрынайтып, Гөлгенәгә сорау белән карады. Гөлгенә сизгер, шып туктады, кыйгачын ачык муенына урады. «Ярый, бар, кайт. Иблис корган тозакка төшкәч, Гөлгенә тутаңны искә алырсың, янында мин булмам. Ә синең бикәчең... булышчы түгел ул сиңа! Сиңа кыен килгәндә, кулын сузмас. Юртак ул! Табан астында ут яна аның! Күпләрне күрдем мин, җаным, бик күпләрнең языгын үземә алдым. Гаепләмә!»

Гөлгенәнең таушала башлаган чибәр йөзенә акыл чаткылары, тирәнлек, олылык һәм горурлык йөгерде. Нәҗипнең нигәдер аннан аерылып китәсе килмәде. Ләкин калырлык сәбәп юк иде. Утырып торыр урын да юк, ичмасам! Өйдә дә көтәләр булыр. «Рәис чакыргач!» колаклары шомрайды! Наилә, чыннан да, гасабиланып, арлы-бирле идән таптап аны көтә иде. «Ник чакырган?» — дигән сорауга Нәҗип кызарынды, иңбашларын сикертте: «Ачылмады. Әйтеп бетермәде».

Ит-май бирүләрен белгәч, Мәрьямбикә күккә сикерде: «Безне дә кешегә санап, якты чырай күрсәтер икән, Ходаем!» — дип такмакларга кереште. Нәҗип, картларны узындырып: «Колхозның батыр ветераннарына күчтәнәч итеп бирә», — дигән иде, өйдә хис өермәсе купты! И, адәм баласына күпме кирәк, бер кило май, биш кило ит өстенә әйтелгән бер җылы сүз кәүсәр чишмәсеннән су эчү белән тәңгәл булды. Мәрьямбикә өзмәде-куймады, киленен ияртеп, иткә-майга төшеп тә китте.

Авыл, авыл! Синең чыбыксыз телефоннарың! Юрган астыннан йөргән борчаның да эзен беләсең син! «Йосыфның Казанда министрлар белән аралашып йөри торган Нәҗибе кайткан... Моннан болай Йосыф белән Мәрьямбикәгә ит тә, май да чыгачак икән» дигән хәбәр югары очка Мәрьямбикәнең үзеннән алда менеп җитте.

Көннәр җылына төште, тук карынлы кичләр күңеллерәк үтте, майлы бәрәңге ашыйлар, төшлеккә итле шулпа пешә, беркөнне тәвәккәлләп пилмән дә бөгеп ташладылар. Мәрьямбикә карчык баш өянәген онытты, көндезләрен мендәргә баш куеп хәл җыеп тормый, тыр-тыр чаба. Ике көннән Гөлгенә нәни генә язу кисәге алып кайтып тоттырды: «Теге иблис тагын сине чакырган!» — диде ул, Наиләне күзе белән ашап-ботарлап.

Бу юлы Ихлас ялгыз түгел иде, тирәсендәге кешеләргә кырлы-мырлы бер-ике сүз әйтеп озаткач, ул Нәҗипкә ят итеп беравык карап торды да: «Иртәгә пленумга барам. Сезне Сабит абый чакырткан. Утыртып барырмын. Иртән алтыда төшеп җитегез»,— диде.

Нәҗип: «Җәй буена торырга кайттык!» — дип, әтисенә ялгыш кына ычкындырса да, алар Наилә белән икәүләп тизрәк моннан китү ягын карарга кирәклеген толып асты аулагында сөйләшә башлаганнар иде инде. Сабит абыйларының чакыруын «котылу!» дип кабул иттеләр. «Ник чакыртты икән?» — дигән шик күңелләренә килеп карамады. «Сабитыбыз Нәҗипләрне кунакка чакырган!» — дип, өй борынча мактанып йөрде иртән майлы ипи, көндез итле шулпа ашаган, күңеле бөтәйгән Мәрьямбикә карчык. Кунакка тек кунакка! Сабит турында сүз куергач, әнисе белән икәү генә калган аулакта Нәҗип әнисеннән: «Сабит абый сезгә бер дә ярдәм күрсәтмимени соң? Әз-мәз ит, он, май ише нәрсәләр кайтарып ташларга кулыннан киләдер ич?» — дип сорады. Мәрьямбикәнең иреннәре җебеде, күзеннән яшь коелды. «И улым,— диде ул, борынын сеңгереп.— Сабитыбыз алай ук кансыз түгел, бик кайтарыр иде, атаң риза түгел. Элгәре елларны түшкәсе белән ит, капчыгы белән ак он кайтаргалады. Дөге, тары ярмасы ише вак-төякне әйткән дә юк иде, әтиең борчылды. Авылда карт-коры ачыккан чакта ничек итеп урлап китергән ризыкларны ашап ятыйм, диде...» — «Урлаганны кайтармагандыр ич? Сатып алгандыр?!» — диде Нәҗип, шактый аптырап. «Ничек булса да, әтиең риза түгел. Кеше белән тигез яшисем килә! — ди... Сабитка да шуны җиткерде». — «Сабит абый ни диде?» — «Ни дисен... авызын кыегайтып көлде дә күзгә күренмәс булды. Шул».

**21**

Наилә килен, соңгы тапкыр өй җыештырып, идән-сайгак юып, балаларның кием-салымын ямаштырып, өйдә калды. Искәндәрне әбисе янбакчага суган утыртырга алып чыкты. «Җир исен иснәрсең, эшкә өйрәнерсең, әйдә, балам!» Йосыф карт бер якта, Рөстәм бәләкәч икенче якта аштан соңгы рәхәт йокыга талдылар. Татар тук корсак белән йокларга ярата. Нәҗип: «Өй арасында уралып, комачаулап йөрмим»,— дип, ындыр артларын әйләнеп кайтырга булган иде, бара-бара юлы Көмешкүлгә үк алып килде.

Юл белән бармады ул, ындыр артыннан башланып күлне каймалаган чирәмлеккә килеп җиткән сыза буйлап менде. Сыза кипшергән, чит-читләренә котырынып үлән калыккан, уентык-уентык булып кузгалак тишелеп чыккан, таш чәчелгән җылы яр ярыкларыннан шыштырдап кәлтә җыланнар йөгереп чыга. Көн аяз, күк йөзе юып чыгарылган кебек, анда-санда яз дулкыннарында тургайлар тирбәләләр.

Иртәгә кузгалырга туры килә, сәгать сукты, алда ни көткәнен әйтеп булмаса да, монда ни калачагы сукыр күзгә дә күренеп тора: әле кайчан Югары авыл сыеры күпергә чабып кереп аягын сындыра да председатель Ихласның кәефе килеп бәлтерәгән карт-корыга ит-май язуы тоттыра? Болары әкият итеп

сөйләргә генә калыр, ә ата-ана ничек яшәр? Бәрәңгеләре яңага чаклы җитәрлек түгел. Яңа урамда бәрәңге саталар ди сатуын... Ә акча?! Яхшы бала булса, акчаны хәзер Нәҗип калдырырга, нужарган ата-анасын ул коткарырга тиеш. Эх, чыгарып саласы иде мең тәңкәне! «Мең тәңкә, мең тәңкә!» — дип, радиодан җырлау ансат ул... Мең, мең... Фәтхулла абзасына мең сум бирәсе бар аның... Наилә алганнарны исәпләсәң, мең ярымга җитә. Артып та китәдер әле. Мудрый-Мәхмүткә шуннан ким түгел. Тагын кемнәргә бурычлы соң әле ул? Саный башласаң, баксаң, тирәнтен уйласаң — аның иң зур, ашыгыч түләнәсе бурычы ата-анасына икән! Читтән караганда акланырлык сәбәпләр җыела, ә кайгы-хәсрәтнең уртасына килеп кергәч, коточарлык хәлләргә тап буласың!.. Әйе, Нәҗип Йосыф улы Нургалиевкә кайгы-хәсрәт капкасы һәрвакыт ачык. Киң. «Кер, кер!» — дип, кара канатлы фәрештәләр күмәк чакырып торалар.

«Ни эшләргә? Ни кылырга?» дигән сораулар белән баш ватмады Нәҗип, өметсезлеккә бирелгән егет бу баткактан чыгу юлы юклыгын шәйли башлаган иде инде. Хәзер башны җүләргә салып, койрыкны бот арасына кыстырып, телне аркылы тешләп, Сабит абыйларына барып керүдән бүтән чара калмады. Әллә Ихласның сүзен тотып, муенга камыт киеп, районда калыргамы?! Нигә рәис, авылда бүтән эш беткәнмени? Механик булыр, инженер... Ә хыяллар? Максатлар? Көнчелек? «Көнчелек ояладымы әллә синең йөрәгеңә?» — диде бит Фәридун Фазлыев... Җөмләдән кайда икән ул хәзер? Күреп сөйләшәсе иде. Фәридун Фазлыев исенә төшкәч, Нәҗип бу дөньяда сөйләшер, аңлашыр кешеләре калмавын, дуслары юклыгын ап-ачык аңлады, ләкин хәле җиңеләймәде, авырайды гына.

Элек күл булган шактый киң чокыр шәйләнә башлагач, ул шул тарафта ниндидер томанлы шәүлә абайлаган иде, бара-бара шәүлә кеше кыяфәтенә керде. Җир буе ара калгач, шәүләнең киселгән тирәк төбендә утырган Гөлгенә икәнен таныды. Кире борылып китмәде Нәҗип, юк, киресенчә, адымнарын ешайтты, Гөлгенәне нәкъ шушы сихерле аулакта, кипкән бәхетсез күл ярында, әрсез әрәмтамаклар кисеп, төяп алып киткән тирәк төбендә очратуына сөенде. Гөлгенә аның яшьлегенең шаһиты ич! «Илдә яхшы кеше калмады!» — дип еш тәкрарлыйлар эти белән әнисе. Бәлки, Гөлгенә дә яхшы кешеләргә зарыккандыр?!

Гөлгенә ул килгән якка карап, шатлыгыннан балкып, тагын да чибәрләнеп утыра икән, очып урыныннан купты да Нәҗипнең каршысына килеп басты. «Мин чакырып китердем сине, Нәҗип», — диде. «Нигә?» — диде Нәҗип, гаҗәпләнгән булып. «Нигә? Белерсең. Яныма утыр әле». — «Сыярбызмы соң?» — «Мин синең кочагыңа керермен». Күлнең ашъяулык кадәр генә калган көзгесенә чулт итеп пар кыр үрдәге килеп кунды. Гөлгенә кулын чәбәкләде: «Кайттылар! Миннән куркып очып киткәннәр иде, хәзер әнә кайттылар!»

Алар кысылышып янәшә утырдылар. «Бик теләгәндә мин әллә нинди хикмәтләр эшли алам. Тылсымын беләм, сүзләрен. Төз атлап барган кешене керфегем тирбәтеп аяктан ега алам». Нәҗип көрсенде: «Егучылар күп...» — «Екмадым әле сине, дәшеп китердем, яныма утырттым». Гөлгенә уң кулы белән аны кысып кочып алды һәм бүтән ычкындырмады. «Син бер нәрсәгә игътибар иттеңме: авылда яшьтәшләр, безнең чордашлар калмаган. Син кайтып кергәч, кара бүкәй булып йөрсәң дә, эчем җылынды... Иртәгә китәбез без моннан! Булды, кайттык, Ихлас дигән бәндәнең канына тоз салдык. Мине очраткан саен кара коелды, мөртәт. Авыл, тирә-як аннан кан калтырап торганда, мин аның чыраен ертып кем икәнен йөзенә бәреп әйттем! Авыл ишетте, белеп калалар. Мин үлгәч, сагынып сөйләрләр! «Бар иде бер Гөлгенә, бирәүдән курыкмас иде! Алла булып кыланган Ихласка да башын бирмәде!» — диячәкләр...» — «Минем хакта ни әйтәчәкләр?» — «Синең хактамы?» Гөлгенә аны үзенә якынрак тартты, күзенә карады: «Синең хакта, аппагым, сөйли алмаслар! Чөнки син оборонный заводның почта тартмасына кереп оялаган корт!» Нәҗип куырылды: «Нигә андый аяусыз хөкем чыгарасың?» — «Болай гына,— диде Гөлгенә, Нәҗипнең тәнен көйдереп,— күрәсеңме үрдәкләрне? Оя ясарбыз дип килгәннәр, бичаралар, ясамасыннар! Мин хәзер аларны куып җибәрәм!» Гөлгенә сикереп тә торды, җирдән таш алып күлгә тондырды. Үрдәкләр таш төшеп җиткәнче үк фыр итеп очтылар. «Хәзер Галинаның туган ягына, Ижауга кайтабыз. Аны хур итеп, сөяркә итеп тоткан, соңыннан өтермәнгә тыгып котылган цех начальнигының күршесеннән фатир алып, ай буе аның канына тоз салып яшәргә исәп!.. Безне күргәч, тез буыннары калтырар тегенең!» Гөлгенә цех начальнигының кыяфәтен күргән кебек рәхәтләнеп көлде.

Нәҗип муенына сарылган кулларны кагып җибәрде. «Җирәнәсеңме, җирәнәсеңме?» — дип пышылдады Гөлгенә, җәберсенеп. Ул шашып-шашып Нәҗипне суырып үпте, Нәҗип аның ихтыярына бирелде. «Монда түгел, монда түгел! — дип, Гөлгенә күзләре белән тирә-яктан нидер эзләде. — Адресыңны бир, Казанга барырмын, мин сине әллә кайдан да эзләп табармын». — «Яңа квартирга күчәргә җыенабыз, адресым үзгәрә... Мин сиңа Ижауга, главпочтамтка хәбәр салырмын... Килерсең! Көтәрмен!»

Гөлгенәнең тойгылары аңа күчте, алар икесе бер җан, бер тән булып шактый озак аерыла алмыйча басып тордылар. Куркып очкан үрдәкләр яңадан кайтты. «Җәй уртасында күлнең кибәсен белмиләрме әллә бу сантыйлар?» — диде Гөлгенә, күз яшенә буылып. «Кайтабызмы?» — дип сорады Нәҗип. Үрдәкләр аны сихри төшләр дөньясыннан чынлыкка кайтарганнар иде. «Син атлый тор, мин әз генә

утырам әле!» — диде Гөлгенә, читкә карап. «Кыр үрдәге булып очып китмәссеңме?» — диде Нәҗип, аерылышу мизгеленә җылылык өстәргә теләп. «Нәҗип, күрәм, аңлыйм, син бәхетле түгел. Монда кайтып килүеңнән бәхетең ишәер дип уйлама. Хатының яратмый сине. Берәүне дә яратмый ул. Күрүгә мине дошман итте. Нигә? Кемгә явызлык кылганым бар минем? Беркемгә дә. Сиңа да кылмам. Син — яшьлегемнең хатирәсе. Бердәнбер тере кеше. Мин белгәннәрдән. Таралды яшьтәшләр! Күченде чордашлар. Хәбәр ит, сагынсаң чакыр. Мин почтага көн саен ике тапкыр барып йөрермен, ярыймы?» Ул кайнар куллары белән Нәҗипнең муенына сарылды, дуамал хисләренә буылып-буылып, шашып-шашып иреннәннән, муеныннан үпте, аннан җиңел генә иңбашына кагылды: «Бар, кит. Туктама, зинһар, борылып карама. Тәки капка төбегезгә хәтле ияреп барырмын да хатының алдында суырып үбәрмен!»

«Булыр бу башсыздан!» — диде Нәҗип, адымнарын ешайтып.

«Заманнар нык үзгәрде,— дип уйлады ул бара-бара.— Гөлгенә ни ди: «Председательдән дә курыкмый иде дип искә алачаклар!» — диме? Әйе, авыл кешесен әүвәлдә уңганлыгы, булганлыгы өчен мактап телдән төшермиләр иде. Чигүчеләр, җөйчеләр, биючеләр, сабан туе пәһлеваннары телләрдән телләргә күчеп ныгый иде. Хәзер әнә... кайнар хисле зимагур Гөлгенә «председатель иблистән курыкмавы белән» телгә кереп калачак...

*** * ***

Сабитның Казан кунакларын чакыруын ата белән ана яхшыга юрадылар, сөенечләрен яшермәделәр, яңадан монда кайту, җәй буе яшәү хакында сүз бөтенләй кузгалмады, әбиләре, балаларның велосипедын тотып: «Чормага менгереп куярмын, яренгә кайткач рәхәтләнеп уйнарлар. Ел да болай тормас әле», — дигәч, үзеннән-үзе аңлашылды: Нәҗипләр борылып кайтмаячак.

Өй арасындагы эшләр тәмамлана төшкәч, Наилә тирәсендә ике-өч тапкыр сәер генә уралып-чуралып йөргән карчык, авызын учы белән каплап, аңа дәште: «Килен, монда кереп чыкчы!» Алар кече якка керделәр. «Бик бай йортка барасыз, килен, буш кул белән йөрү килешмәс. Сабит абыеңнарны күргәнең юк, алар... без түгел! Ул җыелышта чакта Эзидә вакытыгыз булыр, кибетләренә кагыл, син — кала кызы, затлы берәр бүләк табарсың.— Карчык, як-ягына карана-карана, иртәдән бирле учында йөртеп тирдән җебетеп бетергән бер төргәк акчаны килененә сонды.— Берүк этиең сизмәсен. Нәҗибеңә дә әйтмә».— «Алсам оят ич, әни!» Наилә янды-көйде. «Ал, ал. Ирең төпченсә: «Хатын-кызның ахыр чиктә генә чыгара торган маясы була аның!» — диярсең дә көлеп җибәрерсең. Минем улым — йомшак күңелле бала, читне уйламас. Йомшак күңеле аркасында замана тормышына көйләнә алмыйдыр дип беләм». Наилә сүзсез генә әнисен кочаклады. «Безгә ни кирәк? — дип дәвам итте Мәрьямбикә. — Әтиең чирдән арынмый, чынкый тереләсе юк. Безнең гомер узган. Кайтырыгызны белмәдек, кайтырыгызны, чүтеки аяк киенеп торыр идек. Икенче кайтыр булсагыз, штубыты хәбәрләшеп торыйк. Ике сүздән хат язып салу читен түгелдер бит?»

Наилә шунда гына Нәҗипнең укырга киткән җирдән чирләп кайтуын, эшендә ямьсез чатак чыгуын, булды дигәндә квартирларын тартып алуларын бәйнә-бәйнә сөйләп ташлады. Икәүләшеп туйганчы җылаштылар.

Моңа кадәр басынкы йөргән малайлар, китәселәрен белгәч, кинәт дуладылар: «Нигә Кызыл тауга менмәдек? Әти төлке күрсәтәм дигән иде!» — «Кызыл тау кипмәгән, ә төлке тилергән», — диде Наилә, ахыр чиктә кызып китеп. Искәндәрнең ике күзе дүрт булды: «Минем тиле төлкене күрәсем килә!» — дип киреләнде. Төлке күрә алмаслыгын белгәч: «Балык тотасым килә, әти кармак салырбыз диде!» — дип еламсырады. Әбисе аны юатты: «И балам, балык имгә дә калмады шул, юк», — диде. Кичкә кадәр турсаеп йөргән балаларны төрткәләп йокларга яткырдылар. Йокларга яткыргач та Искәндәр тынычланмады, йөгереп кенә абзарга чыгып, Бүркәнең муеныннан кочып саубуллашып керде.

Нәҗипнең этисе белән мөнәсәбәте берчакта да төче булмады. Ул «әти!» дип өзелмәде, ата да аны кырыс яратты, улын кочакламады, үпкәне булмады, аркасыннан да бик сирәк кенә кага торган иде. Бу юлы Нәҗип түзмәде, башын читкә борып, күзен яшереп, әткәсенең шыр сөяк җилкәсенә кулын салды. «Сау яшә, эти. Инде болай озак аеры тормабыз, кайтырбыз!» — диде.

Йосыф балаларны озатып өйдә калды. Мәрьямбикә: «Идарәгә хәтле дә төшмәгәч!..» — дип тыпырчынса да, «Урам пычрак, таеп егылырсың», — дип, аны да иярмәделәр. Карчык кунакларны капка төбендә озатып калды, балаларның башыннан сыйпады, икесенә дә берәр шакмак шикәр тоттырды. Искәндәр: «Мин шикәремне Сабит абыемнарга алып барам!» — дип кесәсенә салгач, Рөстәм, лычкылдатып суыра башлаган җиреннән шикәрен тартып чыгарып: «Мин дә!» — дип кычкырды.

Идарә каршысында яшел түбәле «уазик» һәм Нәҗипләргә таныш трактор парлап гөрләшәләр иде. Тракторы таныш, рульдә утырган кешесе бүтән иде. «Мөнир ял итәме?» дип сорады Нәҗип, сәлам алышкач. Моңарчы Мөнирләргә кагылмавына үкенде, әгәр ул шәфкатьле җан очрамаса, суыкта катып юлда кунасылар икән! Ят тракторчы очлаеп торган ияген селкетеп, тәмәкесен иренендә шудыртып йөртте дә, Нәҗипкә бик өстән генә карап: «Андыйларга ял эләкми, андыйларның үз урыны бар!» —

дип чәрелдәде. Нәҗип белән Наилә сагайдылар: «Чирләгәнме әллә?» — «Беркөн Эзигә барганда арбасын аударган, көнлек савымны түккән! Тракторын алдылар да үзен чучка койрыгы юарга җибәрделәр. Бездә закон каты».— «Аның ни гаебе бар? — диде Нәҗип, борчылып. — Юллар өчен ул җаваплымы әллә?» — «Сөт түккән өчен кумадылар, аны списать иттеләр. Рәис абый белән әрепләшкән өчен алды ул җәзасын... Соң, чүп башы белән Ихлас абыйдан: «Ник ул юлларны әзрәк рәтләмисез?» — дип, дупрус алып ята икән! Көрәктән сәнәк булган!» Әллә кайчан тракторга кызыгып йөргән бур Мәҗит малае Марс Мөнирнең дуңгыз койрыгы борырга эләгүенә ифрат шат иде, шатлыгын Казан кунакларыннан да яшереп тормады. Дөньяда Ихлас абыйсын хөрмәт итүче Марс барлыгын казанлылар белеп китсен!

«Уазик» шоферын ияртеп, идарәдән Ихлас чыкты, бер оя булып бөялеп торган казанлыларга каш сикертеп сәлам юллады да: «Сыешыгыз!» — дип боерды. «Син бездән калма! — диде ул тракторчыга. — Бата калсак, җәлт килеп җит». — «Мин Мөнир түгел лә!» — диде Марс, авызын ерып.

Урта урамдагы идарәне үтеп түбән очка кергәндә нәни генә тар күпер бар. Машиналар кара-каршы очрашканда, алданрак килүчене үткәреп, күпер башында туктап көтәләр иде. Бүген «уазик» күпергә кердем дигәндә, теге яктан каршыга, пычрак чәчә-чәчә, авыр «КРАЗ» килеп туктады һәм юл таләп итеп кычкыртты. Ихласка бу бер дә ошамады, каршысында кем машинасы икәнен аңышмыймы әллә бу йолкыш?! Ихлас шоферы ишекне ачып кычкырган иде, «КРАЗ» шоферы аңа йодрык күрсәтте. Ихлас белән шофер икесе ике яктан машинадан төштеләр. Монда юл начар, лай, Ихласның чалбар балагына сыек ләпек чәчрәде. «Каршыңа кем килгәнне күрмисеңме?» — дип җикеренде шоферы, Ихласка ярарга тырышып. Ихлас та: «Кая ашыгасың? Җәһәннәмдә көтеп торырлар, кабаланма!» — дип аны куәтләде. «КРАЗ» шоферы, аю кебек дәү, тупас гәүдәле ир, машинасының әрҗәсенә ишарәләде. «Мин ашыкмас идем, ул ашыктыра». Анда ап-ак такталы табутның ике ягына җиде-сигез кеше тезелешеп утырган икән, тавышка алар да калкынып, нидер мыдыр-мыдыр сүзләшеп алдылар. «Кем ул?» — дип сорады Ихласның шоферы, бердән юашланып. «Авылдашыгыз Хәнифә булыр бу, бәбәйдән вафат. Туганнары монда алып кайтып күмәргә булганнар. Үзе дә шуны үтенгән». — «А ну, кире борылыгыз!» — дип кычкырды Ихлас шашынып. Әрҗәдән мәетне озата кайтучы туганнар коелды. Алар Ихласны танымасалар да, тавышы көрлегеннән бу якның хуҗасы икәнен чамаладылар. «Ник борылыйк без?» — диештеләр алар, аптырап. «Авылдан, эштән качалар да, үлгәч, туган авыллары искә төшә! Эшләгән, яшәгән җирендә җирләсеннәр. Борылыгыз, борыл!» — «Апаем, — диде арадан иң өлкән кеше, — син әкәмәт кеше икәнсең! Хәнифәбез: «Туган төягемә алып кайтып җирләгез», — дигән икән, без мәрхүмнең сүзен боза да, үзгәртә дә алмыйбыз». — «Тоталар да күмәргә монда кайталар. Чаллыдан да мәет килә, Ижаудан да. Свердловскидан да алып кайттылар. Юк бит, шунда гына җирләсәләр, мәшәкате, чыгымы аз була!» — диде Ихлас, һаман киреләнеп. «Хәнифәбезнең актыккы үтенече бит, туган, соңгысы. Җирдән дә, күктән дә бүтән нәрсә сорары юк». — «Ярар, берлеккә рөхсәт. Моннан ары махсус приказ белән беркетермен: качканнарны монда кайтару юк!» «Качканнарны» дигәнне ишеткәч, озата кайтучылар нидер шаулаша башлаганнар иде, өлкән ир кырыс күз карашы белән аларны тиз тыйды. «КРАЗ» артка, бер кыргарак чигенеп, «уазик»ка юл сапты. Эзигә сәфәр чыгучылар мәет салган матәм машинасын үтеп киттеләр...

Хәнифә Нәҗипнең классташы иде, Гөлгенәнең балачак дусты. Иртәнге мәшәкатьләр белән ул Гөлгенәне онытып торган иде, хәзер борыла-борыла артына карады: алар да китәбез дигәннәр иде ич... Әллә Ихлас болай иртәләп, ашыктырып алардан качып чыгып барамы? Нәҗипләр барында очрашудан курыктымы?

Шулай иде, бүген мәетне зиратка үткәрергә Ихлас рөхсәт бирәчәк түгел иде, даулашып-сүгешеп булса да ул «КРАЗ»ны кире борачак иде, әмма кичә янап чыгып киткән Гөлгенә исеннән чыкмаганга, ул ризалыгын бирде. «Киткәнче күзенә кылчык булып кадалам әле мин!» — дигән иде Гөлгенә... Милиция чакыртып, сансыз-сөмсез хатынны этап белән озаттырырга да җыенды, Казан кунакларыннан бераз шигәйде. «Кунак — Сабит энесе! Аның кем икәнен кем белгән?!»

Авыл артта калды, әлегә хәвеф-хәтәрсез бардылар, юл да беркөнгегә караганда шактый кипшергән, машина да егәрле иде, трактор күз күремендә артта калды. Үзалдына уйланып барган Нәҗип тиктомалдан: «Үлгәч кайтып монда ятарга телиләр икән, алар моннан үз ихтыярлары белән китмәгән булып чыга!» — дип сүз әйтеп алды. Ихлас ни әйтер дип көтсә дә, рәис дәшмәде, аның ап-ак якасы кисеп кергән таза, тук муены гына ныграк кызарды.

Юл кашлакта гына бераз җилләгән икән, иңкүлеккә, үзәнгә төшүгә, тәгәрмәчләр саз ярып, юлны капшап бардылар. Әгәр тәгәрмәчләр зыр-зыр әйләнеп лай тугылап тормасалар, Нәҗип Наилә белән пәрмә-пәр килеп талашкан эскерт төбе янына килеп җитүләрен сизмәс тә иде, «уазик» та бу төшне үтә алмады. Шофер, чыгып, әллә кайда ташбака кебек сөйрәлгән тракторга кул болгады. Үзе, тәмәкесен кабызып, тышта калды. Берәү дә сөйләшмәде, иртә уянган малайлар йокымсырап әти-әниләренең алларына аудылар. Шофер тросын эзләп алды, трактор килеп җитеп алга узуга, җәһәт-җәһәт машинаны такты. Трактор бер талпынуда машинаны кара лайдан сөйрәп чыгара алмады, фыр-фыр көчәнде, торбасыннан куе төтен бөркелде, бер уңгарак, бер сулга каерылды, ниһаять, машинаны тагып, бер-ике

җир буе баргач, туктады. Күз күреме кадәр җир шактый коры, тигез һәм хәвефсез күренде. Тракторны көтеп, урта юл күперендә машинаны әз-мәз юып, Ихласның чалбар балагын рәткә китереп шактый юандылар. Бер кузгалгач, Ихлас шоферга сәгатен күрсәтте. Шофер рульгә ябышты һәм барып җиткәнче башын күтәреп тә карамады... Алар ике катлы, кызыл калай белән ябылган бина янына килеп туктадылар. Райком элек тә шунда иде, хәзер дә монда икән... Ихлас, машинадан төшкәч, күзе белән як-ягын капшады да: «Сабит абый сезне үзе эзләп табар, ерак китеп йөрмәгез»,— диде. «Аның машинасы әнә теге, номеры 33–38»,— дип, шофер да сүз кыстырды һәм елкылдап торган, бер тамчы лай чәчрәмәгән «Волга»ны күрсәтте.

Машиналар килә торды, алардан нәкъ бер буйдагы, бертөслерәк киенгән, сәламәт, тап-таза, тук кыяфәтле ирләр төшә торды. Алар бер-берсе белән бик дус, якын иде, ахрысы, күрүгә кочаклашалар, чуп-чуп үбеп тә алалар, аннары эре-эре адымнар белән райкомның биек һәм авыр ишегенә кереп югалалар иде. Сабит иртәрәк килгән булып чыкты. «Ул — бюро члены!» — диде Ихласның шоферы, хөрмәт белән авызын чапылдатып.

Шоферның да, форсаттан файдаланып, Эзидәге баҗасына кереп чыгасы бар икән. Ул китәргә җыенгач, «Әйбер-караларны алып калыйк, бер-беребезгә бәйле булмыйк»,— диде Наилә. Әйберләрне күтәреп, райком алды мәйданыннан читкәрәк китеп, аулак ындыр киртәсе янына бөялделәр. Бөтене белән ипи тотып, алап авызы белән почмагыннан умырып тешли-тешли, бер ир үтеп китте, ипинең исе таралып калды. Искәндәр белән Рөстәм әниләренең Югары авылда кимәгән, күз карасыдай саклап тоткан күлмәгенең итәгеннән тарткаладылар. «Әни, карыным ачты!» Иртән тамагына ризык үтмәгән Нәҗипнең дә бурасы буш иде, ул да, Наиләгә карап: «Әллә тамак ялгап алабызмы?» — диде. Ашханәне тиз таптылар, анда иске селедка кисәкләре, пешкән күкәй һәм авылча калын-калын киселгән ипи телемнәрен алдылар.

Балалары авызына ризык кергәндә сөенмәгән ана буламы?! Искәндәр белән Рөстәмнең йоп-йомшак ухый телемнәрен төенә-төенә ашаганын күреп Наиләнең күзенә яшь килде, бер-ике телемне юлга төреп тә алдылар. Чәй, үтә күренмәле сыек булса да, кап-кайнар иде.

Наилә чиста кулъяулыгы белән иренең авыз читләрен сөрткәләде һәм төче, яшь тавыш белән аңа эндәште: «Син хаклы булып чыктың, Нәҗип. Авылга кайтып йөрисе дә калмаган». — «Нигә? — дип сорады көтмәгәндә кикереп Нәҗип. — Бер күреп килүдән ни зыян?» — «Күреп кенә булсачы!.. Күрсәтеп тә китәбез бит. Менә хәзер дә бай йортка барабыз...» — «Бай булсалар ни, туган абыем лабаса ул!» — «Туган абыйларга коры кул белән, күчтәнәчсез баралармы?» — диде Наилә тиз-тиз.

Нәҗип бик аптырап хатынына карады, тел шартлатып башын чайкады.

«Нәҗип! — диде Наилә, кыз чагындагы көмеш, иркә тавыш белән.— Болыт юк, җил юк, билетлык акчабыз бар, әллә Казанга кайтып кына китәбезме? Нигә Сабит абыйларга күренеп адәм көлкесенә калырга? Минем бер дә аягым тартмый!» — «Качыйк дисеңме?» — «Берәр заман кайтырбыз әле, гафу үтенербез, балалар чирләде диярбез!» — «Юк инде,— дип карулашты Нәҗип.— Бүген качабыз икән, яңадан күзләренә күренә алмабыз».— «Йә инде, Нәҗип,— дип сузды Наилә.— Тормышыбыз үзгәрер, сихәтләнеп эшли башларсың, баербыз, балалар исәер, шундый чакта кайтсаң да күңелле, ичмасам. Иеме?» — «Әтинең хәле авыр... Әти турында киңәшергә кирәк».

Нәҗипнең ныклыгын тикшергәч, Наиләгә кыюлык керде. Ул, уң кулы белән кадак суккан сыман, һаваны кисә-кисә: «Болай итәбез ул чагында. Сез шушы тирәдә ураласыз, ә мин кибетләрен әйләнгәләп чыгыйм. Абый йортына буш кул белән бару килешмәс»,— диде. Нәҗипнең тамак туйгач йомылыр-йомылмас күзе шардай ачылды: «Ә акча? Юкка күз кыздырып, җаныңны үртәп йөрмә, Наилә».— «Хатын-кызның...— диде Наилә, бөгелә-сыгыла,— күзгә кырып салырлык актыккы маясы-запасы була аның!» Наилә ясалма чыркылдап, сикергәләп кибет эзләп чапты, малайлар шау-гөр килеп аңа иярделәр. Нәҗип киртә баганасына терәлеп иссез-өнсез карап калды.

Нәрсә алырга? Ни алып барсаң, хуҗалар күңеленә хуш килер? Наилә җаны-тәне белән Нәҗипнең Сабит абыйсы белән якынаюын тели иде. «Кермичә генә китик!» — дип ул ирен кызганып, юри үгетләп маташкан иде. Аның моңарчы Сабит абыйсын да, килендәше-җиңгәсе Сөмбеләне дә күргәне юк. Иренең туганнары белән арасы кырку икәнне белә Наилә, тартышның сәбәбен сорап, төпченгәне генә булмады. Гомумән, Нургалиевләр затында сүз йөртү юк та бугай. Әнә Югары авылда тордылар, Мәрьямбикә карчык ул-килениәре, кыз-кияүләре хакында авыз ачып берни сөйләмәде. Сабитлар гаиләсе Казанда чактагы кебек бүген дә табышмак иде. Сабит белән Нәҗип татулашсалар, алда ни эшләргә кирәклеген Наилә белер иде!

Универмаг яңа ачылып маташа икән, Наилә кибетчеләргә ияреп диярлек эчкә керде. Кибетне бай дип тә, ярлы дип тә әйтеп булмас иде: эчемлек тезгән киштәләр сыгылган, шешәләр күз явын алып «гаскәри Чыңгыз кеби» тезелешеп торалар, Наилә бу почмактан ятьрәк китәргә тырышты. Оекбашлар, кызыллы-зәңгәрле яулык-кыйгачлар, бармакчалары ләпшердек пирчәткәләр, тузанлы киштәләрдә озак аунап төс җуйган чүпрәк-чапрак рәтендә дә озак юанмады. Савыт-сабалар тезелгән киштәләрдә дә күз төшәрлек нәрсә-кара күренмәде. Кием-салым бүлегендә карачкы иңеннән төшкән кыеш-мыеш чабулы иләмсез плащлардан, якаларына көя төшкән пальтолардан гайре әйбер юк та иде шикелле. Танышкан

саен аның өмете киселә барды. Ул үзе дә сизмәстән беренче кергән эчемлекләр почмагына борылып кайтты. Берәр шешә кыйбатлы коньяк алыргамы әллә?.. Ярамас, Сабит абыйсы капмый торган тәкъва ир булса, оятын кая куярсың?! Балалар ияртеп, шешә тотып барып керү килешмәс тә...

Бая шушы почмакка савылып керүче ирләр арасында аңа бер таныш йөз чалынган иде, шулай булып чыкты. Өс-башлары таланган, калтыравык куллы, җитү сакаллы дистә ярым ир, сыра күбекләрен өрә-өрә, баш төзәтәләр иде. Сырмасын җилбәгәй җибәргән, яңакларын бөдрә төк баскан Мөнир янындагы ике сукбайны һәм шөкәтсез бер марҗаны кыстый-кыстый сыра белән сыйлый икән. Янына барасы итте Наилә. Мөнир тракторчының чалбар кесәсеннән шешә белән аракы тартып чыгаруын күргәч, яхшысынмады, тыелып калды. Мөнирнең исерек тавышы колакны ярып керде. Шактый нык салган, ахрысы, егет. «Китәм! — диде ул, сыра кружкасын һавада йөртеп.— Түзәрем калмады... Сөйгәнемне мәсхәрә итте, түздем... Әтинең мунчасы янды — бүрәнә бирмәде. Урманнан урладым, әләкләделәр. Шуның белән ничә ел бугазыма пычак терәп торды! «Чак кына авызың ачылса да, утыртам мин сине, рәшәткә артына тыгам!» — дип янады. Утыртыр да! Закон үзенеке! Нинди кыз иде югары оч Гөлгенә! Төрмәдә биләнке ясап кайтардылар. Кем гаепле икәнен эзләп кара! Бугазыңны ботарлар! Китәм! Яшьтәшләрдән беркем калмады. Соңгысы мин. Әлерәк кенә Хәнифә апаны алып кайтып киттеләр. Үлгән бичара! Тездән суык саз ерып, көн-төн тирес ташып, ферма җилендә салкын тидерде бит ул. Врачлар бала тапмаска киңәш иткәннәр Хәнифәгә. Утызны узганчы түзгән, бичара. Үзе вафат, баласы калган. Ире — алкаш. Тагын бер ятим артты дигән сүз! Ул иблис минем Халисәмнең кызлыгын алды, җәлләп кенә аңа өйләндем! Китәм!»

Наилә, күз яшьләренә тончыгып, универмагтан чыгып китте. Малайлар тыр-тыр аңа иярделәр.

Күрмәгән-белмәгән кешегә бүләк алудан да кыены юк, бүләк-санак өлкәсендә тәҗрибәсез, үзе берчакта да бүләк алмаган Наилә кара тиргә төште. Ишек катында һава сулап торгач, киредән универмагка керде, икенче катка күтәрелеп, товар залларын ике-өч кат урады.

Ул Сабит Нургалиевләрнең тормышын күз алдына китереп карады. Җыйнак кына алты почмаклы өйдә торалардыр... Чиста-пөхтә җыештырылган. Йорт тирәли чәчәкләр. Бик күп чәчәкләр! Өйдә китап киштәләре, пластинкалар. Илһам Шакировны яраталардыр, Әлфия Авзалованы, Рәшит Ваһаповны. Әлфиянең пластинкасы бар икән — икенче катта тәвәккәлләп шуны алды. Җырлары нинди бит әле тагын: «Кәккүк», «Болын»! Кайсы татарның бу моңнарны тыңлаганда йөрәге кайнарланмас?! Пластинка биреп кенә хуҗа олылыгын бәяләп булмас шул, туганнарның очрашканнары юк, дүртәүләшеп кайтып керәләр.

Универмагның өлкәнрәк бер сатучысы баядан бирле аларга игътибар иткән иде инде, түм-түгәрәк, буйга тигез дип әйтерлек ике малайны күргән саен, аның йөз җыерчыклары куанычтан балкып китә иде. Гаҗизлектән исергән Наиләне ул дәшеп туктатты. «Җаным, сез бу якныкы түгел шикелле, кайтышмы, китешме?» — дип сорады. «И апа, — диде Наилә, җылы сүздән балавыздай эреп, — шәһәрдән кайткан идек, хәзер бер авылга кунакка китеп барышыбыз. Буш кул йөзне ертыр, берәр бүләк эзлим дә ни алырга белмим. Башым катты. Колхоз рәисләренә барабыз. Нинди бүләк килешер дә нәрсә кулай булыр?» — диде Наилә һәм барасы авылның исемен атады. Апаны алыштырып куйдылармыни?! Элек тә ягымлы караган иде, хәзер тулган айдай балкып Наилә янына чыкты, иелеп малайларның битләрен чупылдатты. «Шулаймыни, акыллым? Сабитларга барасызмыни? Ай, бик затлы кешеләр чакыра икән. Аларга лаек бүләк монда булмас, әйдәгез әле, үзем сайлашыйм». Наилә береаз шигәебрәк хатын артыннан иярде, идәннән түшәмгәчә картон тартмалар, төргәкләр, төеннәр шыплап тутырылган киштәләр арасыннан үтеп кечкенә бер бүлмәгә барып керде. Тәрәзәсе юк бүлмәнең ишеге өстендә якты лампочка яна иде. «Бик һәйбәт бүрекләр бар, биш йөзлеге бар, алты йөзлеге. Сабит абыегыз аннан арзанлыны кими». Наилә коелып иңде, кулына йомарлаган ике егерме бишлеге тирдән дымланды. Аның икеләнгәнен күреп, сатучы хатын — кеше холкының иң югары дәрәҗәсендәге белгече — планканы шундук түбәнгәрәк төшерде: «Исемә төште! Бүрекләре бар аның, бар. Беркөн япон зонтигы сораткан иде, ул чакта бездә юк иде, хәзер бик затлылары кайтты. Бәясе дә җүн — илле тәңкә. «Әлфия Мортазина табарга булышты»,— дип әйтсәгез, миңа бик җиткән. Юк, юк, акча кирәкми. Әлфия Мортазина дип әйтергә генә онытмагыз. Сез бүләкне аңа тапшырырсыз, зонтик миннән сезгә бүләк! Улларыгызны бик-бик ошаттым. Ялгыз мин, бала-чагам юк. Сайлашты диегез дә гаиләсенә бик күп, бик күп сәлам тапшырыгыз. Сөмбелә керсен, сез дә кайткан-киткән чакларда читләтеп үтмәгез, керегез!»

Наилә ялынса да, Әлфия Мортазина акча алмады, киресенчә, кергәннәре өчен рәхмәт әйтеп, телефон номерын язып бирде. Малайларга берәр кап печенье, ике шоколад һәм ике шешә баллы су эләкте. Аларга да акча алмады.

Егерме бишлекләрен эчкерәк яшереп, аптыраган-йөдәгән Наилә ирен эзләп китте.

«Хатыныңның кем икәнен беләсең килсә, сәфәргә алып чык» дигәннәр борынгылар. Наилә ирен әллә ничә мәртәбә шаккатырды бүген. Көткән арада әйбер-караларын сөйрәп китап кибетенә кергән иде Нәҗип. Бакса, артыннан хатыны да бастырып кереп җиткән. Нәҗип кулына алган китапларын куям дигәндә, аларны Наилә тартып алды. «Ядерная физика, — диде Нәҗип, — Америкада язылып

басылган, Мәскәүдә тәрҗемә ителгән, җәһәннәмдәге Эзигә килеп кереп ятачак! Башкалада бу китапны ике шәм яндырып эзләсәң дә табачак түгелсең! Монда ике томы утыз сум! Анда берсе-берсенә йөзне сорыйлар!» — «Әйдә, алабыз!» — диде Наилә кинәт. «Нәрсәгә ул?» — «Миннән сиңа бүләк!» Наилә сатучы алдына баягы җебеп беткән егерме бишлекләрне чыгарып салды. «Сабит абыеңнар китапны күрсен... Кайчагында кулдагы китап кешенең абруен нык күтәрә!» — диде хатын, сөенеченнән кабынып. Алар мәсьәләне ачыклаган арада, сатучы китапларны һәйбәтләп төреп, бәйләп, каршыларына китереп куйды.

Кибеттән чыктылар. Китап алу белән мавыккан Нәҗип, әгәр Наиләсе зонтик сабы белән кабыргасына төртмәсә, берни күрәчәк түгел икән. «Ни бу? Тагын миңа бүләкме?» — «Бусы Сабит абыйга?» — «Ә бусы?» — «Бусы Әлфия Авзалова, үземә бүләк!» Юк, чыннан да, монда Нәҗип аңлап бетермәгән сер бар иде: малайлар әниләренең сумкасына тыгылып печенье кимерәләр, шешә ачып баллы су эчәләр... Каян? Ничек? «Зәйдә ханым-әфәндегә кредит ачканнармы?» — диде ул, хатынын беренче тапкыр ханым-әфәнде итеп атап. Өйләнгән чактагы «Мин сине ханым-әфәнде дип йөртермен» дигән вәгъдәсе әллә кайчан онытылган иде. Ире чирләгәннән бирле Наиләнең чыраеннан сөенү качкан иде, аның чибәрлеген өзмәс нужа, туя ашамау, курку, икеләнүләр, шик-шөбһәләр йоткан иде. Бүген һич уйламаганда ул сабырланып, тынычланып калды, гәүдәсенә кыз чагы җиңеллеге, күңеленә тигезлек кайтты. Иренең култыгы астында «Ядерная физика» китабы, күреп егылсыннар. Япон зонтигын ачып-ябып карадылар, тавышсыз-тынсыз, шоп-шома эшли! «Кредит ачарлар да!» — диде ул, җиңелчә яңгыравык тавыш белән. — Нургалиевләр фамилиясе шактый югары дәрәҗәдә йөри икән монда!»

Хатынының күңеле күтәрелгәнен сизми калган ир буламы? Бер мәлгә Нәҗип тә үзгәрде, холкын-фигылен алмаштырдылармыни: «Әллә чыннан да шушы төбәктә, туган җирдә, Нургалиевләрнең акцияләре югары чакта калыргамы? Чукынып китсен фән, чәнчелеп китсен завод, челпәрәмә килсен эшкә ашмас хыяллар! Калырга председатель булып и вәссәлам!»

Мөгаен, Сабит белән алар бу турыда гәпләшерләр, Ихлас аңа идарәдә сөйләшкәннәрне җиткерми калмагандыр. Районның ике ягында ике Нургалиев эшләп ятыр! Нәҗип абыйсыннан өйрәнер, аннан өлге алыр, берзаман икесе дә халыкара данлы рәисләр булып китәрләр... Уртак әкияти мизгелнең шифасы балаларга да тиде, алар чыркылдашып бер-берсен куып уйнадылар. Бакчага, яфраклары күңелле ачылып килгән агачлар астына кереп утырганнар иде, көн җылытты, эссе була башлады, алар төенчекләре белән куерак күләгә эзләп күченделәр. Урамда хәрәкәт көчәйде, таныпмы, кемнәрдер аларга сәлам биреп узды.

Кәнфит суырып, прәннек кештердәтеп, куе баллы су чөмергән малайларның тамагы кипте. «Су эчәм!» — диде кече малай. «Минем дә тамагым кипте!» — диде Искәндәр. Наилә малайларны баягы ашханәгә алып барып кайтты. Аннары алар алмаш-тилмәш кысталдылар. Бәдрәфкә әтиләре алып барды. «Кунакка ач бармыйк!» — дип, ашханәгә әүвәл Наилә кереп чыкты. Нәҗипнең дә эче чурлады, ашык-пошык ул да тамагын ялгады. Инде әйберләрен төйнәштереп, бәйләштереп, райком ягына ашыкканнар иде, Рөстәмнең сандалие төшеп калган, Нәҗип аны эзләп кире чапты. Сандали йон йомгагы хәтле генә эт авызында булып чыкты, этне куып тотканчы, авызыннан сандалины алганчы, Нәҗип шабыр тиргә батты.

Ахылдап-ухылдап райком янына барып җитсәләр, пленум беткән, машиналар таралган, кап-кара «Волга» янында кара көеп Сабит абыйлары басып тора. Җиңелчә кул кысышып, уртача җылылыкта күрештеләр. Нәҗип Наилә һәм уллары белән бертуган абыйсын таныштырды.

Бүтән чакта Сабит Нургалиевнең көяз машинасы райком алды мәйданыннан иң беренче булып кузгала иде, председательләр шау-гөр килеп аны озаталар, кулын кысып калырга чират торалар, ыгы-зыгы арасында хаҗәт-йомышларын әйтергә дә өлгерәләр иде. Еш кына аны озатырга секретарьлар чыга, райбашкарма рәисе, урынбасарлар, вак-төяк ыбыр-чыбыр мөдирләр тантаналы озатудан читтә калмыйлар. Бүген тәртип бозылды, инде иң арттагы колхозларны тагын да арткарак сөйрәгән булыр-булмас рәисләр дә таралды, бүлек мөдирләре бил бөгеп, баш ия-ия аның яныннан әллә ничә үттеләр. Ул шоферына «Кузгалдык!» дип авыз ачканда энесен күреп алды. Оядагы бүтәннәргә ул сыңар күзен дә төшермәде: Сабит үзенә кирәкмәгән кешеләрне күрмәскә күптән гадәтләнгән иде. Энесенең хатынына кул сузганда ул аның кайнар, хисле бармакларына чак кына кагылды, алай да эчке бер тетрәнү белән сискәнеп китте. Ачуы кабарган чак иде, ачуы кабарганда ул аяусыз, хис-тойгыларына бәя биреп өлгерә алмый, язгы ташкын кебек вата, җимерә, кыра... Сөйләшмәде, «Утырыгыз!» дип приказ бирде дә шоферы Әхмәтзыя янына кереп чумды. Наилә белән Нәҗип очрашуның корылыгыннан каушадылар, бүктәрләрен кая урнаштырырга белмичә, малайларны урыннан урынга күчерделәр. Ашыгу кешене кечерәйтә, түбәнсетә. Сабит аларның вакланып, бик бәләкәй калып каударланып маташуларын күз керфеге белән күзәтеп торды.

Ниһаять, урнаштылар, ишекләр ябылды. Эзине чыгып, уңга борылдылар. Алар борылып кергән юл тигез, гаҗәеп матур һәм күптән түгел генә асфальтланган иде. Монда язгы пычракның эзе дә юк,

юлның ике ягына рәт-рәт итеп пөхтәләп, ныклы күз астында утыртылган яшьтәш каеннар бөреләрен ачып, дөньяга мең-миллионлаган күз белән карап, тирә-яннарына сокланып чайкалалар иде. Хуҗа сүзсез баргач, кунаклар да авыз ачарга кыймадылар. Иртә торган малайлар, тирбәлеп барсалар да, бүген йокыга баш бирмәделәр, алар да як-яктагы тәртипкә, камиллеккә сабыйларча сокланып онытылып утыралар иде. Бара-бара Рөстәмнең түземе төкәнде, кыегаеп әнисенең алдына ятты, башы итәкне күтәреп, күлмәкне сөзеп керде. Төп-төз утырып барган Сабитның күзе ялгыш кына каршыдагы көзгегә төште: Наиләнең йоп-йомры тез башлары, матур коелган тулы балтырлары күзен кисеп алды. Энекәшнең хатынына алай карау язык иде, ул моны искәреп читкә борылды, аңын томалаган вәсвәсәгә баш бирергә теләмәде. Түзмәде, көзгегә тагын бер карап алды, күрер өчен аскарак шуышып, җайлабрак утырды. Аның ач күзе кая төбәлгәнен Наилә тиз абайлады, аякларын күчерергә, читкә тартылырга әмәлен генә табалмады. Сул кулы белән тез башын томалап карады, итәкне тартып төшерергә тырышты, барыбер тезләр ачылып калды. «Күр син аны, энекәшне йолкыш кына дип йөрсәм, хатынның асылын эләктергән икән ләбаса!» Шушы уй күңеленә килгәч, Сабит көлемсерәде. Бу хәлнең нәтиҗәсе — ул моңарчы әзерләп куйган планны баш-аягы белән әйләндереп ташлады...

Гөлгенә төрмәдән кайтып бавырына таш булып утыргач, Ихласның берәр тыныч көне булдымы икән? Нәҗип кереп, булыр-булмас сүзләре белән канын кайнаткач, ул көне-сәгате белән ишеткәннәрен Сабитка җиткерде. Энесенең кем икәнен, теленә ни килсә, шуны теләсә кайда лыгырдап йөргәнен ишетсен Сабит, белсен! Кибетче Зәйнәп, берне биш, койрыгы белән куш итеп, кибеттә очрашуларын үтә ямьсез итеп Ихласка әләкләгән иде инде. «Халыкны котыртты! Май да сатмагач, нигә эшкә чыгасыз сез, ди!» Мөнирне чәнчелдереп төшерергә әллә кайчаннан кыҗрап йөргән бур Мәҗит малае Марс та нәтиҗәне үз файдасына борган иде: «Һәй, Ихлас абый! Мөнирне Казан кунаклары котырткан. Гел шулай ул, теләсә кем сүзенә ышана! Ул бит, теге, югары очның зыяндаш Йосыф малаен утыртып кайткан. Мөнир буынсызга шулар сүзе җитә калган!» «Дыр», «бугай»лар Ихлас авызында көчәйтелгәннән соң Сабитка үтә ямьсез булып барып җиттеләр. Ул энекәшен элек тә сөйми иде, хәзер җене котырды: «Гомер эченә бер авылга кайтып, монда үз тәртипләрен урнаштырырга маташамы, бушбугаз! Без урнаштырган тәртип ошамыймы аңа?!» Шул минутта ук Сабит уенда камил план туып өлгерде. Ә аның планнарын тормышка ашырмаган чагы юк!.. «Пленумнан соң энекәшне ыбыр-чыбырлары белән төяп алып кайтырга да кара-каршы утырып йонын туздырырга кирәк юньсезнең!» Бу булды бер, икенчедән, бертуган энең районга кайтып сиңа керми китә икән, күңелле хәл түгел, «Кунакка энесен дәшеп алган!» дигән хәбәр аның абруен гына күтәрәчәк. Энесе авызын тыя алмыйча дөньяны тәмам сасытканчы, алып кайтырга аны! Пеше чыбык белән сыртын каезларга! Телен тешләтергә һәм артына тибеп Казанына озатырга! Авыл хуҗалыгын белмәгән башы белән Ихласка нинди провокацион сораулар биреп маташкан бит! Имеш, колхоз-совхозлар үз-үзләрен дә туйдыра алмаганда ни дип аларны асрап ятасыз да нишләп таратмыйсыз?! (Нәҗипнең күңеленә дә, теленә дә андый сорауның килгәне юк!) Утыз өч ел яшәп тел тыярлык та акыл җыя алмаган икән ишәк! Ә еллары нинди, еллары! Яшәгән кешегә яшәрлек кенә, бәхетле еллар, рәхәт еллар! Бөке генә түгел, таш та өскә калка торган еллар!

«Әллә этиләргә кайтып, шунда чәкәләшеп алыргамы»,— дип уйлады Сабит, әти-әнисеннән яхшысынмады. Җәзага тартыр өчен кунакка алып кайтырга туры килде һәм, кайтыр юлның яртысына җиткәч, кинәт кенә планнар үзгәрде. Алда ни көткәнен дә, ни кичерәсен дә тәгаен генә белмәсә дә, ул кунакларны алай тиз озатмаска карар кылды. Зурайды аның планы, тармакланды, энекәшкә акыл бирергә кирәк анысы, шиксез, әмма мондый сылу киленне кунак итмичә дә ярамый бит! Нәҗипне эт итеп, хатынын ничек юмаларга, күңелен күрергә — анысын уйлап бетерергә тәҗрибәле Сабитның акылы җитмәде. Чөнки Наилә энесенең хатыны иде...

Юллар, кырлар монда бөтәнчә иде, сөрелгән, чәчелгән җирләр күз явын алып пар бөркеп яталар. Ерганак-чокыр тирәләрен хәстәрләп караганнар, ярларда вак-төяк чаукалыклар калкынган. Урман авызлары, юл читләре чүп-чардан арындырылган. Язгы гөрләвекләр тирәнәйткән су эзләре дә күздән читтә калмаган, талчыбыктан тәбәнәк киртә-тоткарлаучылар үреп, суның юлын бикләгәннәр. Асфальтка аркылы чыккан юлларга бөтен җирдә дә «Тракторларга керергә ярамый!» дигән кисәтүләр эленгән. Бөтен юл дәвамында коммунизмга ашыктырып өндәмәләр кычкырып утыралар. Ниһаять, Нәҗип түзмәде: «Сез башка мәмләкәттә яшисез икән!» — дип ычкындырды. Сабитның куе, тыгыз һәм коры керфекләре дерелдәп китте, Наилә алдында мактаганы өчен энесенә эченнән рәхмәт укыды. «Юлны әйтәсеңме?» — дип сорады ул, Нәҗиптән тагын да ныграк соклану көтеп. «Аны да!» — диде Нәҗип, башын уңга-сулга боргалап. «Юл шәп! — диде Сабит.—Татарстанда бер! Нефтьчеләр салып бирде. Округтан генеральный директорны депутат итеп мин сайлаттым. Карыйм: Мәскәүдән булыр-булмас берәүне сыларга маташалар. Стоп, мәйтәм! Директор депутат булды, мин — юллы. Яхшы юлың бар икән, бәхет үзеннән-үзе авызга тәгәрәп кереп тора. Аңларга гына кирәк. Ул — депутат, мин ни кушсам, шуны эшли. Элек сессиягә икра ашап, ял итәргә барып йөргәннәр, ә минем депутат министрдан министрга чаба! Имә белсәң, җир астын таларга гына өйрәнгән нефтьчеләрдән ун имчәк таба аласың!»

Берчакта беркем алдында серен чишкәне юк иде Сабитның. Бигрәк тә Ихлас: «Гафу итегез, Сабит абый, энегезнең иләге тишек икән!» — дип кисәткәч, телдә сагаерга кирәклеген күңеленә беркетеп куйган иде... Машинада Нәҗип белән икәүдән-икәү барсалар, ул, әлбәттә, авыз ачып сүз әйтмәс иде. Асылда, хәзер дә ул энесе өчен сөйләми, Нәҗип — нуль, адәм тәганәсе, хәзер аның һәр сүзе, тырышып матурлаган һәр җөмләсе Наиләгә, аның шашарлык дәрәҗәдәге матур аякларына юнәлтелгән. Оят, үз-үзен каһәрли Сабит, күзен аска төшерә, кул аркасын, беләкләрен чеметеп карый, нишләсен, күзе тагын көзгегә борылып кайта... Ул тыңласын, ул ишетсен, ул таң калсын! Сылу хатыннарны кулга ияләштерергә дигәндә Сабитның мең ысулы бар барын, тик элгәрге, сыналган ысуллар ярамый бүген, ярамый: беренчедән, Наилә — энесенең хатыны, икенчедән, очрашулар озынга тартыла алмый, ара кыска. Чибәр хатыннарны йә байлыгың, йә чибәрлегең, йә ирлегең белән бөгә аласың. Өчесе дә бар Сабитта, өчесен дә биргән Ходай. Йа Раббым, нигә бу хатынны энесенең бичәсе итеп яраттың?! Тирә-яктагы юллар, тиешле рәвешенә китереп эшкәртелгән кырлар, юл читләрендә лепердәп утырган яз киленнәре — яшь каеннар — һәммәсе бүген Сабит Йосыф улы Нургалиев файдасына хезмәт итәләр! Хәзер Нәҗип сүзне өзмәсен, сораштырсын, кат-кат кызыксынып төпченсен, аның һәр соравына җавап бары тик Сабитның дәрәҗәсен күтәрәчәк, абруен ныгытачак.

Нәҗип абыйсының мактанырга атлыгып торуын аңлады, максатын гына башына китерә алмады, Сабит көче-егәре, башкарган зур эшләре белән аны аста калдырырга тели дип уйлады.

«Кайтып җитәбез!» — диде Сабит, күңелсезләнеп. Юл, көзгедәге манзара аңа нык ошаган иде... Юлдашлар, иелә төшеп, алга сузылып яткан буш, туры юлга карадылар. Күз күреме җирдә авыл шәйләнде, шифер түбәләр, түбәләрне каймалаган уйдык-уйдык биек агачлар күренде. Түбәләрдән һәм агачлардан биек-биек булып авыл өстендә сәер бер канат оча иде. «Нәрсә бу?» — дип сорады Нәҗип, көлемсерәп. «Ашыкма!» — диде Сабит, күкрәген алгарак чыгарып. Теле ачылган Сабитның бу юлы өзеп җавап бирмәве, «күк әкәмәте»нең болытларга тия язып тирбәлүе кунакларның һушын алды. «Әллә күктә җилкән йөзә инде?» — дип сорады Наилә. Юл буе шым утырган, барлыгы да беленмәгән Әхмәтзыя бу юлы чыдамады: «Әлә-лә!» — дип куанып ычкындырды. Аның хикмәтле җилкәнгә баш-аягы белән табынуы шушы бер ымыннан мәгълүм булды.

Моңарчы үзләрен гашыйк иткән каеннар онытылды, уңга, ябык, киң ындыр табагына, йөзләрчә машиналар саф-саф тезелгән асфальтлы мәйданчыкка кунаклар әйләнеп тә карамадылар, күзләр бер булып каядыр омтылган сихри җилкәнгә текәлгәннәр иде. Җилкән, очып та, йөзеп тә китмәде, юлаучыларны мәрхәмәтле канаты астына алырга җыенгандай һаман якынлашты. «Рәсем ич бу, гап-гади сурәт!» — диде үткен күзле Наилә. «Рәсемен рәсем, әмма гади түгел! — диде тирән ышаныч белән Сабит.— Күрерсез! Карагыз!»

Нәҗип тә аермачык күрде: тирә-юньнең иң биек байрагы булып аларга каршы Леонид Брежневның портреты йөзә иде. «Нинди зур!» — диде сокланып Наилә. «Биеклеге төгәл утыз биш метр!» — диде куанып Сабит. «Ничек җил бәреп төшерми аны?» — дип сорады шаккаткан Нәҗип. «Йөз дә кырык ике мең сумга төшкән очкыч-портрет җилгә баш бирәме? Белгечләр исәпләп чыгарды: иң каты давылларда, штормнарда да исән-аман калачак. Ә штормнар безнең якта булмый да булмый. Тыныч якта яшибез, шөкер! Әле иң гаҗәбе анда түгел, алда,— чак кына сабыр итеп торыгыз».

Хикмәтле рәсемгә якынлашкан саен, машина акрынайды һәм ни гаҗәптер, якынайгач та, яныннан узып барганда да Брежнев, калын кашларын күтәреп, аларга туп-туры карап тора иде. Инде үтеп тә киттеләр, чаттан борылыр вакыт җитте. Сабит серле кыяфәт белән: «Борылып карагыз тизрәк!» — дип ашыктырды. Борылсалар, Брежнев һаман аларга йөз белән тора иде. «Ни бу? Нурларны кисештердегезме?» — дип кызыксынды Нәҗип. «Сихер!» — дип куанды Наилә. «Юк ла! — дип тантана итте Сабит.— Хикмәт шунда: рәсем үз күчәрендә йөз сиксән градуска борыла торган итеп эшләнгән. Менә сере кайда! Аны мин уйлап таптым. Ярата безнең хуҗа монда килергә! Аны рәсем яныннан дүрт-биш тапкыр үткәрәбез. Кая барса да артыннан ил хуҗасы, партия юлбашчысы күз атып, дәртләндереп кала. Шәп уйланганмы?! Рәссамны дәүләт бүләгенә тәкъдим итәргә җыенабыз. Казаннан худфондтан белгечләр чакырып китердек. Бер атна ял итеп, фикер алышып яттылар. Премиясез калмабыз дип ышанам! Игеннәрнең торышы, күрдегез, һәйбәт, көзгә, боерган булса, Леонид Ильичның үзенә чакыру җибәрәбез. Күрсен татар халкының мәхәббәтен!»

Наилә эчкерсез аһ итте. Ул беренче ишарәләреннән үк Сабитны нык куллы хуҗа, киң колачлы лидер, сүзен кайда да сүз итә алырлык гайрәтле олпат ир дип таныды. Соклануын һич яшереп тормады. Сабитның әйткән һәр фикеренә йә кашын уйнатып, йә көлеп, кул чабып, һич югында, күз нурларын мул түгеп соклануын, хуплавын һәм бәхетле булуын белдерде. Сабитка әнә шул гына кирәк тә! Ул тигез, кирәк чагында мамыктай йомшак тавышы белән һаман Наиләне сихерли, яшь хатынның туймас күзе кай ноктага төшсә дә, үзен югары күтәрерлек дәлилләр таба, хатынны үзенә таба тарта иде. Абыйсын күптәннән күргәне булмаса да, Сабитның яшь чактан ук һавалы, комсыз һәм әрсез икәнен онытмаган Нәҗипнең күргәннәренә әллә ни исе китмәсә дә, алдагы вакыйгалар аны да иләс-миләс ясады.

Машина сигнал бирә-бирә урам буйлап рәхәтләнеп тәгәри, тыкрык башын тутырып утырган ишле бәбкәле казлар каңгылдашып аңа юл бирделәр, тамак төбе белән эндәшеп, бәбкәләрен читкә чакырдылар. Чаттан борылгач, уң якта балкып күренгән зур кызыл кирпеч бина — универмаг икән, аның ишек катында тәмәке пыскытып торган милиционер, төпчеген ыргытып, үрә катып, машинага честь бирде. Машина күренгәч, кибет эчендәгеләр дә этешеп-төртешеп урамга чыгып сибелделәр, бөгелә-сыгыла машинаны озатып калдылар. Мондый олы хөрмәт Наиләнең күңелен нечкәртте, күңелле каршылаудан аның күзендә яшь күренде. Ә машина, Кызыл мәйданда парад кабул итәргә чыкканмыни, урамның нәкъ урта сызыгыннан тавышсыз гына тәгәрәде. Ишегалларында, капка төпләрендә нидер эшләп йөргән кешеләр, йөз белән борылып, Сабитка бил бөктеләр, кулларын күкрәккә кушырып рәисләрен сәламләделәр.

Сабитның шушы хәрәкәткә исе китмәве, кырын күзен дә салмыйча төп-төз утырып баруы Наиләнең күңелен аерата нечкәртте. Ул, ихтыярсыз хәлдә, каршылаучыларга кул болгап рәхмәт укып барды. Аның үзенең берчакта да игътибар үзәгендә булганы, шундый татлы бәхетне татыганы юк иде.

Урамның ике ягыннан җитешлек белән салынган зур-зур өйләр, төзек каралтылар, төрле шәкелдәге янкормалар, өйаллары, верандалар озата барды. Кыйшайган капка да, купкан койма тактасы да юк, һәр тарафта ныклы хуҗа кулы, хуҗа барлыгы сизелә иде. Капка түбәләренә ал байраклар кадалган, стеналарга, коймаларга аллы-чуарлы өндәмәләр ябыштырылган иде. «Сездә бер-бер бәйрәмме әллә?» — диде Нәҗип, аптырап.— «Бездә һәр көн бәйрәм,— диде горурланып Сабит.— Сез, хөрмәтле кунаклар, коммунистик татар авылына килдегез!»

Тирә-яктагы бөтенлекне, төзеклекне тамаша кылып килә-килә, Нәҗип як-ягын үз авылларындагы ташландык урам-тыкрыклар, керсәң чыга алмаслык юллар, бетәшкән өйләр, адәм тәганәсенә әйләнгән чирле эти-әнисе белән янәшә куеп карады.

Ул арада машина җиз кадак түбәләре белән мул бизәлгән биек һәм киң капка каршысына килеп җитте, тукталмады, капка үзеннән-үзе ачылды. Алар Олы көн сагасы тәгәрәтеп уйнарлык тип-тигез, йоп-йомшак чирәм калкынган киң ишегалдына килеп керделәр. Эчтә, капканың ике ягына, ике кеше баскан иде. Берсе, агач аяклысы, капка ябарга тотынды, икенчесе, озын итәкле халат кигәне, какчарак, зифа буйлы хатын, машинага таба бер-ике адым атлады. Дүрт ишектән дә җиргә төштеләр. Хатын Наиләгә якын ук килеп, күгелҗем вак җыерчыклар белән мул каймаланган күзләрен зур ачып карап торды да озынча, ябык бармакларын җилпәзәдәй таратып кулын сузды. «Сез, мөгаен, минем килендәшем буласыздыр инде?» — диде. Наиләнең юл буе исертеп килгән тойгылары сүрелмәгән, мәхәббәт балкышы кимемәгән иде. Ул, килендәшенең кулын эләктереп алып, аны күкрәгенә кысты. «Менә дөнья, килендәшләр үзебез, ә күрешә алганыбыз юк»,— диде ул, кайнарланып. «Сөмбелә минем исемем!» — диде хуҗа хатын. «Миңа Наилә дигән исем кушканнар, исememне яратам»,— дип көтмәгәндә чытлыкланды Нәҗип хатыны.

«Рәхим итегез, кадерле кунаклар,— диде Сөмбелә.— Юынып алырсыз, аннан тамак ялгарбыз, ачыккансыздыр. Чәем әзер».

Алар өр-яңа диярлек чуар палас җәелгән болдырга менеп, кырып ясалган баганалы култыксаларга ябыша-ябыша текә баскычтан икенче катка күтәрелделәр. Йорт эчендәге калын-калын затлы келәмнәрдән, хуш истән Наиләнең башы җиңелчә әйләнеп китте. Киленнен күзеннән ычкындырмаган Сабит шундук аның беләгеннән эләктерде, кулы Наиләнең янар таудай ут атып торган күкрәгенә тиеп китте. Аларның йөзләре якынлашты. Сабит белән Нәҗипнең йөз сызыкларында охшашлык шактый булса да, туганнарның күз карашы бөтенләй үзгә, бүтәнчә икән, Сабитның күзләре утлы күмер булып яналар, аларның тирәнлегеннән әллә нинди куркыныч, шомлы нурлар агыла иде. Көтмәгәндә Сабитның калынча, нык уелган иреннәре: «Мин сине ашарга телим!» — дип пышылдады.

Әллә өнендә ишетте моны Наилә, әллә бер мәлгә саташуы булдымы, сизми калды...

**22**

Нәҗип белән Наиләне гаҗәпләнергә мәҗбүр иткән ике нәни генә вакыйга булып алды. Иртәнге чәйдән соң хуҗалар, Сабит белән Сөмбелә: «Сезне әзгә ялгыз калдырырга туры килә, авыл кешесенең шул бетмәс эш инде...» — дип, икесе ике якка бер-бер артлы чыгып киткәч, ике малай, Искәндәр белән Рөстәм, әниләренә килеп асылындылар. «Кайчан китәбез инде?» — диде Рөстәм, шыңшып. «Кайтыйк бабайларга!» — дип кат-кат инәлде Искәндәр. Ата белән ана ни уйларга белмичә югалып калдылар. Хуҗалар шундый бай, юмарт, киң һәм ачык күңелле, алып килгән күчтәнәчләрне әз булса да зур итеп кабул кылдылар, кат-кат рәхмәт укыдылар. Йоклаган урыннары ханнарныкы кебек, ашаган ризыкларын сөйләп, мактап бетерермен димә, ә алар, маңка сарыклар... «Кайчан моннан китәбез?!» имеш...

Дөрес, кичә дә бер вакыйга аларны сискәндергән иде. Кичке мул чәйдән соң, күпсанлы утлар яктырткан ишегалдында аш сеңдереп йөргәндә, капкадан йомры бер хатын-кыз килеп керде дә: «Сабит

Йосыпович, иртәгәгә көндезге рейска алдым. Икесе зурларныкы, икесе балаларга!» — дип, председатель кулына самолет билетлары китереп тоттырды. Моңарчы бер дә читенсенмәгән, кыенсынмаган, кай тарафка сүзе керсә дә кыюлык, белем, фикер күрсәтә алган мәгърур хуҗа бер мизгелгә югалып калгандай булды. Сабитны аңларга бик теләгән Наилә генә түгел, Нәҗип тә моны сизде. Сабит хатынга күзен алартып карады да, билетларны вак-вак кисәкләргә erткалап, почмактагы чиләккә илтеп сипте. Хатын баскан җиреннән юк булды, аны күрми дә калдылар.

Бу хәлне йомшак караватта юка, мамык юрган астында йокларга әзерләнгән Нәҗип хатыны белән уртаклашмакчы иде, әллә ничек онытты, кичке аш алдыннан эчелгән француз коньякларының тәэсире булдымы, кәефе шәп иде, күңелсезлекләрне искә аласы килмәде.

Хәзер, хуҗаларсыз аулакта, ике малай ике яктан бабайларга кайтуны дауларга тотынгач, алар йомры хатынны, ертык билетларны, билетларның бүгенгә, икенче рейска алынган булуын да хәтергә төшерделәр.

Наиләнең тагын бер җитди шиге бар иде, ул аны, кәефен бозмас өчен, иренә әйтмәскә уйлаган иде, хәзер, шик төшкәч, анысын да ачып салды. «Иртән хуҗалар йоклаган бүлмә кырыннан үтеп барам, ишек ярым ачык, эчтә сөйләштеләр... «Тагын урман азгынлыгын оештырасыңмы? — диде Сөмбелә. — Тагын котырасыңмы?» Ә Сабит абый бер генә җикерде: «Молчи, дура!»

Кунакларны шиккә салган вакыйгалар өзек-өзек һәм бик нәни иде, алай да, иш янына куш өстәлгәч, алар бер булып җепкә тезелделәр һәм бай хуҗаларга килгән ярлы кунакларның кәефен кырдылар.

Малайлар, әти-әниләрен хафага салуларын уйламыйча, һаман: «Бабайларга кайтыйк!» — дип кабатлыйлар иде. Тавышлары өйгә сыймый башлагач, текә баскычтан җитәкләп төшеп, аларны иркенлеккә — ишегалдына алып чыктылар. Наилә йортның арт ягыннан, эчкәргедән чыгып килүче хатынны абайлады. Ул кунаклар белән ашыгыч кына исәнләште дә бигенә ачык йозак эленгән таш амбарга кереп китте. Нидер ниятләп, Наилә аңа иярде, артыннан керде. Хатын каушаган кыяфәт белән сүзсез басып торып аны каршылады. «Сез бу йортның кеме буласыз?» — дип сорады Наилә турыдан-туры. Хатын аңа җавап бирмәде, уйланып торды. «Ашчы булам мин»,— диде ул, ишетелер-ишетелмәс кенә. «Ашчы? — диде гаҗәпләнеп Наилә.— Ике балалары тиң Зәйдә укый, монда ике җанга махсус ашчы тоталармы?» Ашчы хатын кунакның исемен белә икән. «Ай, Наилә җаный, Сөмбелә апаның түре буш торамы? Көнаралаш кунак ич аларда!» Наилә җайлап кына кунакларның каян килүен, кемнәр булуын сораштырса да, ашчы башын чайкады. «Минем эшем учак янында. Бүтәнен белмим»,— диде. Әңгәмәне өзеп, ишек тоткасына ябышты, алъяпкыч астына кыстырган нәрсәсен (шешә булды, ахрысы) яшереп, шәүлә кебек, өй артына кереп югалды. Каяндыр лапас астыннан кичәге агач аяк күренде, иске малахаен салып сәлам бирде. Уң як чигәсендәге тирән җәрәхәт эзен томалар өчен бүрек кигәндер, ахрысы... Сәлам биргәннән соң, сөйләшмәде, кунакларны күздән дә югалтмады, ары-бире йөреп, әле аннан, әле моннан килеп чыга торды. «Әллә күзәтә инде?» — диде Наилә, шигәеп. «Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер»,— диде Нәҗип, аны котыртып.

Хуҗалар кайтмады. Нәҗип Наиләгә, Наилә Нәҗипкә аптырап караштылар. Балалар юк-бар уен табып, әз-мәз мавыгып киттеләр, бабайларга өндәү онытылып торды. Ул арада болдыр башына чыгып ашчы хатын аларны чәйгә чакырды. Чәйне теләр-теләмәсрәк эчтеләр, эчләре нык ук поша иде. Чәйдән соң диваннарга таралып кырын-ярын ятып алдылар, йокы килмәде. Йокы һәм тынычлык качкан иде. Ярый, язгы чәчү бетмәгән, Сабитның вакыты да булмасын, ди. Сөмбелә нигә юк? Нигә күзгә-башка күренми? Иртәдән дә юньле-башлы сөйләшмәде, тырт та пырт, койрыгын чәнчеп чыгып югалды. Аның «тагын урман азгынлыгы оештырасыңмы» дигән сүзе ни аңлата?

Ашчы да, агач аяк та бүтән күренмәделәр. Нәҗип икенче кат ишекләренең бикле булуына игътибар итте, тартып-тартып карады, ишекләр нык һәм тыгыз бикләнгән иде. «Әйдә, урамга чыгабыз!» — диде ул кинәт. «Дөрес! — дип сикереп торды Наилә.— Инеш буена төшәбез, зиратларын әйләнеп чыксак та ярар».— «Нигә зират?» — диде җәберсенеп Нәҗип. «Зират урманы дөньяда иң моңсу урман, ә хәзер минем күңелем моңсу».

Менә аңла син хатыннарны! Ишегалдына чыгып, капкага таба баралар иде, лапастан баягы төксе карт — агач аяк килеп чыкты. Ул, кулын артка куеп, сүзсез генә аларга текәлде. Капка бикле иде, алар сорау белән аңа карадылар. «Өйдә генә торыгыз,— диде карт, шактый нык тавыш белән.— Көтегез!»

Берни эшләр хәл юк, кунаклар тагын икенче катка менделәр, газета караштырган булып беркавым утырдылар. Астан яңгыравык аяк тавышлары ишетелде. Хуҗа кайтып килә, ахрысы, бүтәннәр текә баскычтан алай шак-шок менә алмас... Чыннан да, ишектән шат чырайлы, өр-яңа костюм кигән, ап-ак күлмәген килешле галстук белән бизәгән хуҗа килеп керде. Киң тәрәзәдән төшкән кояш нурында ул башка бер дөньядан килгән сихерле зат сыман күренде. «Җыеныгыз!» — диде ул, кыска гына.

Чакыру идеме, катгый боерык булдымы, кунаклар аңышмадылар. Нәҗип, кыяр-кыймасрак: «Кая барабыз?» — дип сорады, Наилә бөтенләй коелып иңде. Сабитның каралҗым сөрмә каймалаган ач күзләре аны үтәли тишеп-тишеп тикшерәләр иде. «Урманга!» — диде ул, кунакларны ашыктырып.

Нәҗип кабыл-тибел балаларны киендерергә кереште, моны күргән Сабитның чырае сытылды. «Балалар кала,— диде ул һәм тамак төбе белән: — Бәдәр!» — дип кычкырды. Баягы хатын юк җирдән бар булды, кушканны көтмәде, балаларны җитәкләде, колак авырттыра торган ямьсез тавыш белән боргаланырга, юхаланырга тотынды: «Әйдәгезче, былбылларым... Мин сезне бер җиргә алып барыймчы, алтын алмаларыма керпе күрсәтимче... Бакчада аларның оясы! Керпе белән бергә тәмле кәнфитләр ашарсыз!»

Җыларга ачылган авызлар җыелды, төчеләп-юмалап, Бәдәр малайларны ияртеп чыгып китте. Нәҗип белән Наилә сүз катарга да өлгермәделәр. «Безгә уникедә анда булырга кирәк! — диде Сабит, кунакларның ыкы-мыкы туруларын өзеп.— Ашыгыйк!»

«Волга» бүген ишегалдына кермәгән, ул, капка баганасына бәйләнгән ялкау ат сыман, тын гына аларны көтә иде. Биргән сәламнәренә Әхмәтзыя җавап кайтармады, ул алга карап, еракка текәлгәндәй нидер уйлый иде. Җаваплы кешеләрнең шоферы ни уйлаганны кем белгән? Утырыштылар, ишекләр ябылды. «Ә Сөмбелә?» — диде Наилә, тез астына итәген җыештырып. Сабит: «Узышлый кереп алырбыз,— дияргә уйлаган җиреннән: — Ул бүген бара алмый»,— дип ычкындырды.

Наилә ике ут эчендә калды. Сабитның «Мин сине ашарга телим!» дигән сүзе шаяру булмыйча, шушы көтелмәгән сәяхәткә барып тоташса, ни кылырсың?! Ул машинадан атылып чыкканын сизми дә калды, иренең таләпчән, чәнечкеле күз карашы гына кире борылырга мәҗбүр итте. Абый белән эненең татулашуын Наилә үзе тели түгелме? Хәзер, киреләнеп, ике араны бозып ташласа? «Сөмбелә дә барса икән!» — диде ул, көч-хәл белән, машинага утырып. «Безне көтәләр!» — диде Сабит. Наиләнең кирегә суктырып маташуы аңа бер дә ошамады. «Тәртә арасына кергәне юкмы әллә бу кырыкмыш тайның?» — диде ул күңеленнән, җене котырып.

Әле кичен генә Сабит Йосыф улы Нургалиев бөтенләй бүтән кеше иде. Сөмбеләнең Нәҗип белән Наиләне эчкерсез, чын күңеленнән каршылавы аның да йөрәген җылытып җибәрде. Өй арасы эшләреннән күптәннән аерылган хатынының гади, әмма акыллы әңгәмәсе, туганнары алдында Сабитны олылавы, этле-мәчеле яшәүләрен бер ым белән дә сиздермәве онытылып беткән хисләрне яңарткандай булды. «Күр син аны! — дип уйлады Сабит. — Без юньләп аралашмый торган арада бу хатын нык ук үзгәргән ләбаса! Сүзләрен тыңла — акыллы сукалый! Игътибарлы, тыңлый белә, алга чәчрәп чыкмый — тыйнак. Бер үк вакытта үз дәрәҗәсен төшерми, вакланмый, тормышның чүп-чарын теленә кертми, күбрәк дөнья иминлеге, балалар, аларның киләчәге турында сүз алып бара!»

Эзи белән авыл юлында күңеленә хуҗа булып өлгерә язган вәсвәсәләреннән Сабит оялып ятты, салган баштан йокылы-уяулы хәлдә Сөмбеләсенә җылы сүзләр ычкындырды бугай...

Килгән олы, затлы кунакларны өй сые белән генә сыйлый торган кеше түгел Сабит. Ул еш кына аларны аулак урман аланына алып менә, мәҗлеснең шәбе, кәттәсе әнә шунда кеше күзеннән читтә уза. Моңарчы Сөмбеләнең урман аланын күргәне дә, учак күмерендә пешкән куырдыклардан, кош итләреннән, билдәмәләрдән авыз иткәне дә юк. Нәҗипләрне урман аланына өндәр дип Сөмбеләнең башына да килмәде, Сабитыннан күргән саран җылылыктан эреп, онытылып йоклап китте. Төн уртасында ул йокы бүлмәсенә янәшә кабинеттан килгән тавышка уянды. Сабиты телефоннан кемгәдер эш куша иде. Ишекләр кысып ябылган булса да, иренең тавышыннан, ярым-йорты ишетелгән сүзләрдән Сөмбелә аңлап алды: Сабит Нәҗип белән Наиләне югары дәрәҗәдә кабул итәргә җыена икән!.. Инде бу юлы да Сөмбеләне нәүмиз итеп калдырса... Ул аяк очларына гына басып килгән иреннән: «Мин дә бараммы анда?» — дип сорады. Сабитның сүзсез килеп ятуыннан Сөмбелә барысын да аңлады. Тик бер нәрсә караңгы иде: якын туганнарыннан да хатынын яшерә икән, ни уйлый бу Сабит? Сөмбеләне калдырып ниләр майтармакчы була? Гайбәт йөри, Сабит хатын-кызларны шунда чеметкәли икән дигән хәбәрләр килеп ирешә... Ярый, шулай да булсын ди, азынсын да ди... Нәҗип-Наилә янына нигә сыйдырмый ул Сөмбеләне?.. Таңга кадәр тырпылдап ятты хатын, таң алдыннан соравын тагын кабатлады. Ире: «Молчи, дура!» — дип мыгырдагач, өмете өзелеп, сөмсере коелып, икенче бүлмәгә, аулакка чыгып китте.

Сабит туктаусыз икеләнә иде әле, иртәсе дә килә Сөмбеләне, күңеленең төпкелен нииндидер корт та кимерә... Эзи юлында уйлаган вәсвәсәле уйлары кайта-кайта хәтергә иңәләр дә аның туймас җанын котырталар, моңарчы татымаган рәхәтлекләр вәгъдә итәләр иде. Иртәнгә кадәр ул төпле карарга килә алмады. Идарәгә баргач кына, төнлә йокылы-уяулы биргән боерыгының үтәлә башлавын хәбәр иттеләр. Сугымчылар пычакларын үткенләп, бүгенге тантанага багышланган малларны машинага салып урманга киткәннәр булып чыкты. «Иртәләгәннәр! — дип сукранды ул үз-үзенә.— Андый эштә иртәләмичә дә ярамый бит!» — дип өстәде.

Асфальт күндәм чыжтырдады, мәһабәт җилкән яныннан үткәндә йөреш тагын тыйлыкты, болытларга үрелгән Брежнев сәяхәтчеләрнең оешып бетмәгән төркемен калын кашлары белән хуплап, түшендәге алтын йолдызлары белән яктыртып озатты. Үтеп киткәч борылып карасалар, калтыравык зәгыйфь куллары белән бөтен дөньяны тотып торырга тырышкан генсек йөзе белән һаман аларга

текәлгән иде. Наилә белән Нәҗип, юл башының хафасын онытып, бер-берсен бүлдереп: «Ни хикмәт бу? Ничек алай?» — дип сорашмыйча түзмәделәр. «Сихерчеме әллә сез, Сабит абый?» — дип чытлыкланды машинага кереп оегач дөньясын оныта башлаган Наилә. «Сихер! — диде Сабит.— Без Әбүгалисинаның мәгарәдәге китапларын табып укыдык.— Ул кунакларның башын шактый тинтерәткәч кенә ачыклап бирде: — Рәсем үз күчәре тирәсендә әйләнә, хикмәт шунда. Әйләндерер өчен махсус, сменалы штат тотабыз». «Бу мәшәкатьләр күпмегә төшә инде, ягъни мәсәлән»? — дип сорарга кысталса да, Нәҗип нигәдер тирәнгә керергә теләмәде. Әзгә кайтып нигә абыйсы белән бозылышырга?

Эзи юлына чыкмадылар, машина кинәт кенә сулга каерылды. Челтәрле тимер култыксалар белән бизәлгән таш күперне кичтеләр. «Колхозның утыз биш еллыгында салдык. Рим легионнарын, Гудериан танкларын чыдата торган күпер. Илдә бер, ачылышына Казаннан, Чабаксардан вәкилләр килде».

Моннан соң очраган һәр корылма, һәр бина нинди дә булса юбилей шәрәфенә җиткерелгән булып чыкты. Машина, авылны, Брежневка «Җиңү» ордены тапшырылу уңаеннан төзелгән таза ферма каралтыларын, акташ икмәк амбарларын артта калдырып, тауга үрләде. Сабит галстугын чишеп, күлмәк сәдәфен ычкындырып җилләнде, Наиләгә борылып карады — аның күз карашы таркау һәм шактый мәгънәсез иде... Күңеленә шик-шөбһәләр килә-китә башлаганда Сабит машинаның кош булып очуын ярата иде, бүген дә Әхмәтзыяга ым какты, машина әкияттәге тулпар булып алга ыргылды, «эһ» дигәнче куе, нәфис яшеллеккә төренгән урманга барып керделәр. Урман авызында дәү төп өстенә утырган милиционер, сикереп торып, честь биреп калды.

Машина язгы дым таралып өлгермәгән урын юлга төште. Монда асфальт җәелмәгән, аңда, авыл өе сыярлык чокырда, эрер-эремәс, ала сыер тиресе булып кар ята, борыннарга әчкелтем яфрак исе, язгы яңарыш, тереклек исе килеп бөркелде. «Кошлар кайтты,— диде Сабит, җанланып,— кошлар көньяк белән төньякны ялгадылар. Кош кунгач, корыган агачка да җан керә!» Шулай диде дә, тагын Наиләгә сөзеп карады.

Моңарчы Нәҗипнең көнләшкәне дә, Наиләнең көнләшерлек сәбәп чыгарганы да юк иде, бүген, абыйсының Наилә белән гадәттән тыш мавыгуын абайлап, йөрәге сызланып алды.

Озак бармадылар. Машина түгәрәк дип әйтерлек аланга барып кереп туктады. Алан тирәли яшь каеннарга аралаштырып чыршы утыртканнар. Каеннарның бәбкә йоны кебек йомшак, хуш исле, балавызлы яфраклары чыршыларның серле куелыгы белән аралашып, һәр күңелгә барып җитә торган илаһи матурлык хасил иткән иде. Машинадан төшкән кунаклар бу юлы хуҗаның өндәвен көтмәделәр. «Бар шул дөньяның гаҗәп почмаклары!» — дип беравыздан аһ иттеләр. Нәҗип белән Наилә урманда кунаклар күп булыр дип көткәннәр иде, алай булмады, аланның бу башында кеше-мазар күренмәде. Бераз күз ияләшкәч, алар аргы башта иелеп нидер эшләгән ике кешене, алар янәшәсендә кабынып-кабынмас төтәгән учакны абайладылар. Ике ирнең берсе, эшен ташлап, җитез генә юртып Сабит янына килеп җитте һәм, гаепле кыяфәт белән: «Һәммәсе дә әзер булыр, Сабит Юсупович, килерегезне тәгаен белмәдек шул!» — дип, хуҗага күтәрелеп багарга кыймыйча, әмер көтеп калды. «Киләсебезне үзем дә тәгаен генә белмәдем шул!» — дип уйлады Сабит, уен бер сүз белән беркетте: «Ашыгыгыз!» Килүче әрмән егете елдам китеп барды, аның җиленнәнме учак дөрләп яна башлады. Яз исенә кушылып, алан читләренә каен тузы исе таралды.

Сабит егетләрчә җитез кыланып пиджагын салды, аны ботакка элде, галстугын чишеп кесәсенә тыкты, җиңнәрен сызганды. Аның күңелендә өлгереп җиткән бер уе да юк иде, сүз юктан сүз булсын өченгә, аланны мактарга тотынды. «Да-а, аланыбыз дөньясында бер! — диде ул.— Килер заман, алан уртасына мәрмәр багана бастырып, монда булып киткән бик күп мәшһүр затларның исемнәрен язарлар!» — «Кызганыч,— диде Наилә, чытлыкланып.— Алар арасында без булмабыз шул!» — «Сез, Наилә килен, исемлекнең башында торырсыз!» — «Минем хатынның дәрәҗәсе арта!» — диде Нәҗип, көлемсерәп. «Чөнки,— дип аңлатты Сабит,— бу аланда синең кебек чибәр хатынның булганы юк иде». Наилә кызарып-пешеп чыкты, артык төче бәядән Нәҗип тә уңайсызланды. Сабит үзе дә берара сүзсез калды: «Нишлим мин?! — дип эченнән сүгенеп алды.— Нигә кычкырып мактарга иде? Энекәшнең хатыны лабаса ул! Хатыны!»

Шулай уйласа да, күзе чалмабаш чәчәге өзәргә иелгән Наиләнең түшенә, күлмәк ерыгына төште. Ашыгып читкә борылды Сабит, нидер исенә төшкәндәй, маңгаена учы белән сукты, башын кагып кунакларга үз артыннан барырга боерды. Алар дөрләп, эссе бәреп торган учакны, түбәләмә ит тутырган табаклар, эреле-ваклы казаннар янында тыз-быз килгән ике әрмән егетен үтеп арырак киттеләр һәм көмеш су тулган түгәрәк күл янында телсез калдылар. «Коръәндә адәм улларының иң зур хыялы — су! — дип кычкырды Сабит.— Түбәндә, елгалар шаулап аккан үзәндә, диелә анда. Без фәкыйрьләргә алан читендәге шушы түгәрәк күл дә җитеп ашкан!» Иелде дә кулы белән күл суын уятып, дулкыннар чупылдатты.

Аланда төрле шөгыль, төрле һөнәр ияләре булып китеп, аларның һәрберсе Сабитның яшәешенә, теленә, кыланышларына нидер өсти иде, рәиснең хәтере шәп, сеңдереп, отып алырга гына тора. Беренче күргәннәр, әз-мәз аның репертуары белән танышкач, Сабитның белеменә, теле җорлыгына,

фикер кыюлыгына хәйран калгалыйлар иде. Бүген ул гадәттәгедән дә хәтәррәк сөйләшә, сүзе белән кунакларын күмеп ташлап, әкрен-әкрен үз ихтыярына буйсындыра бара иде. Сылу килене генә түгел, балачактан абыйсына баш бирмәскә гадәтләнгән энесе дә аның кемлеген, агачында өлгергән җимешләрне күрсен!

Ул әрмән егетләренә тагын бер күз салып алды, ул яктан ым-шым булмагач, тагын сүз йомгагын сүтәргә тотынды: «Кабатласам, кичерерсез! Районның гына түгел, Татарстанның оҗмахы монда! Оҗмахның мөдире каршыгызда. Оҗмахта кыска арада булган бәхетлеләр яшәүнең мәгънәсен монда аңлап китәләр. Мондагы минутлар аерата хатын-кызлар өчен истәлекле була. Ни әйтсәң дә, тормышның бихисап мәшәкатьләре, очсыз-кырыйсыз ыгы-зыгысы аларның асыл иңнәренә төшә. Батыр ирләрнең куллары гына ятырга тиешле кайнар иңбашларында нужа арбасының эзләре ята. Тормыш хатын-кызларыбыз өчен әлегә бик авыр. Шуңа күрә форсаттан файдаланыгыз: оҗмах монда, монда! Бүтәненә өметләнмәгез! Тагын бер мәртәбә кисәтәм: мин сезгә оҗмах ишеген ачам!»

Сабит, басып торып, ике кулын чайкый-чайкый сөйләде. Нәҗип белән Наилә йомшак кабарган үләнгә утырып аны тыңладылар. Ике сүз генә әйтергә җыенган Сабит, өйрәнелгән гадәте буенча, тыела алмыйча, шактый кайнар речь сөйләп ташлады.

«Ничек бу дәрәҗәгә ирештең? Илнең хәле хәл чакта оҗмах төзер өчен бик зур көч-куәткә ия булырга кирәк ич! Колхозларның язмышы мәгълүм — таралырга тора алар! Ә син оҗмах дисең?»

Нәҗиптән шул сорауны көткән Сабит сорауга сорау белән җавап бирде: «Кайсы мәгънәдә сорыйсың? Матди якны күз алдында тотасыңмы, әллә мораль як кызыксындырамы?» — «Ике як та!» — диде өзеп Нәҗип.

Сабитның күләгәсе су өстендә тирбәлде. «Матди якка килсәк... Берегез — минем кан кардәшем, икенчегез — сылу киленем, кадерле кунагым. Монда сөйләшкәннәр монда калыр дип ышанам. Эзләгән егет кулына мал төшмиме, Нәҗип туганым?! Нефтьчеләр белән арадашлыкны көйләп җибәрдек дигән идемме? Шул! Күр инде, Татарстан илгә миллионнарча тонна нефть бирә. Нефть ведомстволар, министрлыклар, кыскасы, Мәскәү абзаң кулында. Ә алар... безнең җирне көпә-көндез кычкыртып талый! Татнефтьтә курчаклар утыра, рәттән! Татарстанга ни кала? Безгә? Шушы җирдә яшәүчеләргә? Беләсең, башың чайкама! Беләбез! Нефть безнең басу түрендә табылгач, мәсьәләне кабыргасы белән куйдым мин. Генеральный директор белән шушы аланда икәүдән-икәү сөйләштек. Һәм безнең җирдәге скважинаны, минем үтенечне тыңлап, консервацияләделәр. Тыңламый карасын: кем депутат итте генеральныйны?! Кем? Мин! Хәзер хәзинә безнең кулда. Татарстан файдасына хезмәт итүче җир тишеге миндә! Кирәк чакта ачабыз без аны, җир маен алабыз. Кирәк кадәр генә чыгарабыз. Бездән тыш тирә-күрше хуҗалыклар, район үзәге, больница, мәктәпләр, фермалар — һәммәбез бушлай нефть ягабыз. Бөтен котельнялар шуңа күчте. Нужара идек ягулык эзләп, тирә-якның урманын кисеп бетерә яздык, хәзер рәхәтләнәбез. Ачкыч бездә, сәрмая дә безгә ага...» — «Ә тотылсагыз?» — диде беркатлы Нәҗип. «Энекәш, энекәш! — дип аланны яңгыратты Сабит.— Син дөньяның ничек һәм кая тәгәрәгәнен һаман белмисең икән! Бабаңнар аны бишбылтырдан, хан заманыннан ук аңлаган. «Кул — кулны, ике кул битне юа!» дип васыять калдырган. Тукта, мин сиңа тагын бер хикмәт күрсәтәм. Күр, тыңла, өйрән, колагыңа киртлә: «оҗмахка үтү юлларын абзаңнан отып ал»!

Ул үкчәсе белән кара җир чыгарып кырт борылды, алан аша үтеп, кунакларын урман авызына алып китте. Кергән җирдән түгел, бөтенләй башка юлдан, тар сукмак аша урман кырына чыктылар. «Күрәсезме моны?» — дип сорады Сабит, сөрелмәгән киң генә басу өстенә кулын изәп. Нәҗип белән Наилә ялгыш сүз ычкындырудан куркып иң өсләрен уйнаттылар. Нәҗип, иелеп, яфраксыз шәрә сабакларны учына җыйды, иснәп карады. «Урылмаган карабодай басуы дисәм... сиңа төрттерү буламы?» Сабит көлеп җибәрде: «Өстенә бастың, сыер икәнсең! Инде ник урылмыйча калганын да әйтә алсаң... миннән сиңа бер бүләк!» — «Бүләге нәрсә, бүләге?» — дип сикергәләде Наилә, тагын могҗиза көтеп. «Уң колагы үзенә! — диде Сабит, кыяфәтендәге серлелекне арттырып.— Әйтә аласыңмы?» — «Юк»,— диде башын кашып Нәҗип. «Белә алмыйсың да! Чөнки без гади кешеләргә хас законнар тоткынлыгында яшәмибез. Сез, кадерле кунаклар, безне коммунизмга чыгарган иң ышанычлы юл чатында басып торасыз...» — «Карабодай игүчеләрнең даны таралган бугай... Азнакай тирәсендә игәләрме әле аны?» Сабит тыела алмыйча, бөгелә-сыгыла, күзеннән яшь атылып чыкканчы көлде. Көлеп бетергәч: «Калдау җирнең урманга һәм безнең оҗмах аланына янәшә булуы да сиңа берни сөйләмиме? Юкмы? Алайса әйт, чын ир-атлар бу дөньяда барыннан да бигрәк ни ярата?» Табышмаклардан башы каткан Нәҗип, абыйсының сүз сөрешен, фикеренең очын югалтканга, тәмам исәнгерәде, «Белмим»,— диде. «Синең иң яраткан нәрсәң бармы бу тормышта?» — «Хатын, балалар, гаилә...» Сары йортның әсире Нәҗип тагын тотлыкты. «Шөгылең бармы синең? Яраткан эшең? Хобби-ең? Онытылып, кинәнеп яшәгән мизгелләрең кай чагында була?» — «Доктор Фаина Марковка биргән сораулар ич!» — дип уйлады таң калган Нәҗип. Каян абыйсының башына килгән болар?

«Балык тотармын дип кайткан идем — күл кипкән. Инеш саеккан, быкырдык сазлыкка әйләнгән». Сабит бу гаепләү сүзләрен бөтенләй ишетмәде, ул урылмаган кыр өстендә тирбәлгән серле рәшәне, җылы дулкыннарда тибрәлгән тургайларны күзәткән булып читкәрәк китте. Нәҗипнең түгел, Наиләнең

кызыксынуы шартлар дәрәҗәгә җиткәнен күреп, аңлатып бирде. «Бу карабодай басуын урдырмыйча юри калдырам мин, махсус. Көзлектә беренче яшь кар артыннан ук бу кырларга урман тавыклары, көртлекләр кереп тула. Ә без аяз таңнарда агач ышыгына посабыз да — мә! — чүплибез тегеләрне! Көзен кыр тавыклары, көртлекләр аерата тәмле, ләззәтле була. Миңа ауга Казаннан гына түгел, Мәскәү, Ленинградтан кайталар. Бездәге кебек сусыл итле, хуш исле көртлекләр беркайда да юк икән! Европада да!

Берзаман нефтьчеләрнең генеральный директоры Кувейт принцын ауга алып килде... Ну, кеше! Кыяфәт — во! Байлык — во! Шулай да кырны күргәч шаккатты! Аудан соң миңа саф алтыннан сәгать, Сөмбеләгә энҗе муенса биреп китте. Миндә, Сөмбелә янында, бер врач эшли, Әсфәндияров аның фамилиясе. Бәлки, колагыңа чалынгандыр, былтыр мин аңа Ленин ордены тактым, Татарстанга депутат иттем. Язып та чыктылар! Әнә шул врач куыра инде көртлекләрне! Телеңне йотасың, валлаһи! Былтыр бездә корылык иде, миндә түгел, районда! Мин сусыз каламмы? Җәһәннәм тишегеннән «фрегат»лар кайтарып, болын-кырларны суга күмдем. Кругка утыз центнер алдык... Бәла килгән хуҗалыкларны карарга Сафуан Сабирович килеп төшмәсенме? Уен-муен кеше түгел — чуен муен! Татар-башкорттан хөкүмәт составына кергән беренче кеше! Районның бик күп кырларын списать иттек. Әсфәндияров куырган чучка балаларын, ул ыслаган балыкларны хәзер дә сагынып искә ала икән Сафуан Сабирович! Дөрес, ул чакта көртлек, кыр тавыгы юк иде, әгәр алар да булса, дөньясын умыра идек! Басуларны списать итеп, районны налогтан тәмам коткара идек!» — «Ә нәрсә ашарбыз дигән шик булмадымы?» Наиләсенең көтмәгәндә кыстырган сүзеннән Нәҗип уңайсызланды, Сабитның бәхәсне, төпчечүне һәм каршы килгәнне яратмавын ул төшенгән иде инде. Сабитның гына исе китмәде, ул: «Фи-и, ә Америка нигә яши? Канада? Алар тук чакта без дә ачтан үлмибез!»,— дия-дия, кипшергән үлән сабакларын кыштырдатып кыр өстенә кереп китте, балагына ябышкан сырганакларны күргәч, тиз-тиз кире чыкты. Наилә, үзе дә көтмәгәндә, иелеп каенагасына чалбарын чистартырга булышты. Сабит тагын да ныграк очынды. «Дөньяда иң авыр фән — яши белү фәне. Төрле-төрле кешеләрнең күңелен күреп, күпмесенә сыенып, күпмеләрен сыендырып яшәү уяулык, осталык, зирәклек сорый. Океаннарда адашу — бер нәрсә, кешелек диңгезендә адашмыйча йөзеп кара! Үзең яшәгән җәмгыятьтә дилбегәне кулыңа алырга теләсәң, тәвәккәллек кирәк. Сездән серем юк, сорасам, гаҗәпләнмәгез! Менә син, туганым, калынкаш бабайны яратасыңмы?» Нәҗип мыек астыннан көлемсерәде. «Ул хакта уйлаганым юк!» — диде ул бераздан. «Ник уйламыйсың, уйла! Аның калын кашын яратканга рәсемен күккә элделәр дип беләсеңме әллә! Түгел! Мыгыр-мыгыр йөргән ул бәндәне яратмыйм мин, үз урыным, дәрәҗәм, байлыгым, киләчәгем өчен тырышам! Бары шул гына. Брежнев миңа тими, теләгәнчә яшәргә, хыялларымны эшкә ашырырга җай бирә! Ходай аның гомерен озын итсен, Рәчәйдә берчакта да мондый иркенлек, рәхәт тормыш булганы юк иде, диләр белгән кешеләр. Заманча яшим дисең икән, туганым, аягыңда — сапоги-скороходы, башыңда шапка-невидимка булырга тиеш. Алары бар икән — табыныңда скатерть-самобранка булыр! Әкиятне чынга әйләндергән заманда яшибез, һәм аның шулай икәнен хәзер үз күзегез белән күрәсез!»

Алар чыккан сукмакта бая күзгә чалынып калган милиционер күренеп китте. Күренде дә юк булды. «Ягез, туганнар,— диде Сабит,— тиз йөрешле итекләрне киик! Гурген белән Самвел зарыкканнардыр!»

Сабит иркәләп кенә Наиләне култыклады, Нәҗип арттан иярде, оҗмах-аланга юлдашларны ашыктырып, борынга куырдык исе килеп җитте...

Кысан, җитешсез тормыштан кинәт ирекккә чыккан хатын-кызның күңеле әйле-шәйле яңа фикерләр белән тула, җаны очар кошка әверелә, ул нужа басып торган кара язмышыннан ычкынып күккә күтәрелә, үзен моңарчы изеп, кимсетеп килгән мәшәкатьләргә күктән торып, җирәнеп карый. Наиләнең шундый иләс-миләс чагы иде. Ул бер минутка гына үз ярын — Нәҗибен шушы уңдырышлы һәм тарихи карабодай басуында, ауда дип күз алдына китереп карады. Тарихи китапларда патшаларның, түрәләрнең ау маҗаралары хакында укыганы бар иде аның... Иренә тугры яшь хатынның ялгызы гына күккә ашасы килми иде. Ул монда да иптәшлеккә әле ирен сайлады...

Иртә. Таң сызылган. Кырпак төшкән. Дөнья көмештән коелган! Нәҗипнең өстендә кыска кайры тун, аягында җылы, җиңел ботинкалар. Кулында куш көпшәле мылтык, билен гармун күрегедәй патронташ бизәгән. Иртәнге яраүда тезелешеп, ак карга имза салып сунарчылар бара. Зирәк хатын-кыз аяк киеменнән төшкән эзгә карап та кайсы ирнең, кем икәнен белә ала. Бөтенесе бер буйда! Гвардиннар! Симез, саллы тәнле көртлекләр, йокыдан айнымасалар да, рәхәтләнеп карабодай чүпли! Кыр иркен, урын аулак, хәвеф-хәтәр юк — ак кар өстендә ят эзләр шәйләнми. Аучылар, тыннарын эчкә тартып, кошларга якынлашалар. Ваемсыз көртлекләр ризык җыя, үлем якынлашканын уйламыйлар да!.. Аучыларның күзләрендәге ут таң сызыгы белән кушылып мавыккан кошларга күренми диярлек...

Шушы урында Наиләнең кайнар сулышы бүленде. Ул ирен, байтак еллардан холкын, гадәтләрен белгәнгәме, кош аулаучы итеп күз алдына китерә алмады. Юк, юк, мылтык тотса да, кош ата алмас аның Нәҗибе! Ә Наиләнең күктән тиз генә төшәсе килми, фәрештәләр янында ул анда, аллалар

тирәсендә! Аның хыялы күкләргә сыя алмыйча тырпылдый, һәм аның күз алдындагы Нәҗип шәүләсен көтмәгәндә Сабит абыйсы алыштыра. Аны асыл тунлы итеп тә, мылтык аскан итеп тә, бөртеккә алданган кошкайларны берәм-берәм чүкеп торучы итеп тә күз алдына китереп була иде... Бөркет күзләре кысылган, нык бармаклар мылтык чакмасына сытардай сеңгәннәр; гамьсез кошлар, вак кургаш ядрәләрдән түгел, аның күз карашыннан берәм-берәм ак карга тәгәриләр, карабодай сабакларын акка төргән кырпак өсләрендә алсу кан тамчылары чәчрәп кала. Нәҗиптән аермалы буларак, Сабит абыйсының ияге чыгынкырак икән, икегә ярылып тора. Борын да зур һәм саллырак. Иң гаҗәбе, каннан, вак-төяк җәрәхәтләрдән курка торган Наилә бүген чәчрәп-чәчрәп сибелгән кош канын сокланып, сөенеп күзәтә ала, чөнки аларны шушы илнең хуҗасы, азамат ир, көчле, бөркет карашлы, бай күңелле, мул табынлы Сабит Йосыф улы Нургалиев аткан! «Нәҗип Йосыф улы...» — дип бик әйтәсе килә Наиләнең, ләкин иренең исеме бая әйткән мактау сүзләренә ябышмый, хатынның тавышы юк, теле әйләнми, чуалчык, мактаган уйлары тагын Сабит шәүләсенә барып уралалар. Дөньядагы бөтен мактау, соклану сүзләре килешә Сабит абыйсына!

Аланга кайтканчы Сабитның яхшы корычтан коелган тыгыз иңбашлары әллә ничә тапкыр аңа кагылып алды, ләкин Наилә бу мизгелдә чирканмады, мәсхәрәләнеп читкә тайпылмады, чөнки бу иңнәр аныкы — Татарстанның атаклы депутаты, олпат бер ир Сабит абыйсыныкы. Нигә аның Нәҗибе бәхеттән мәхрүм икән? Ходай туганнарны да тигез яратмаган! Әгәр Нәҗип урынында Сабит булса, кесәсендә диплом йөртеп шәһәрдә торса, ни-нәрсәләргә ирешер иде икән?.. Ә Наилә Сөмбелә белән урынын алышып авылда яшәсә... Сөмбелә кайда икән хәзер? Ни хәлдә?..

Көфер уйлар һәрчак татлы була. Ул уйлар яшь хатынның канатланган гөнаһлы күңелен кайсы упкыннарга илтеп ташлар иде икән — әйтүе кыен, чөнки йөгәнен салган хатын-кызның хыялы чиксез, аның чиген һәм төрлелеген бүгенге көнгә кадәр бер фән дә ачыклап, бер тәгълимат та нигезләп бетерә алмаган.

Алар тәмле исләргә күмелгән сихри аланга кайтып керделәр. Наилә, нурлы күзләрен зур итеп ачып, «аһ!» дип ыңгырашып алды. Бу аның гүзәллеккә гыйшкы да, бәхеттән шашынуы да иде. Сабит, туганнарча кайгыртып: «Арымадыгызмы?» — дип сорады. Наилә, тигез, энҗе тешләрен кояшта җемелдәтеп, аңа карады.

Кичәге гөнаһлы кызыгулар, төнге вәсвәсәләр күңелдән кичкәч, Сабит җиңеләеп, чистарып калган иде. Ул Нәҗипкә дә, Наиләсенә дә ачык күз, яхшы теләкләр белән карап, үзеннән дә, оештырган сәяхәтеннән дә бик канәгать иде. Табын әзер, авызга су китереп, ахак күмерләр өстендә шашлык чәкәннәре алланалар, өстәлгә ниндиен генә оҗмах нигъмәтләре таратылмаган! Кыр тавыклары юк югын, мәгәр йорт тавыклары ботларын күккә чөеп, авызга керәм, керәм дигәндәй кызыктырып чалкан яталар. «Нигә шушы кадәр ризык? Тагын кемнәр киләсе икән? Мондаен рәхәтлекне бозмасалар ярый ла...» — дип хафаланды сүзсезлекнең рәхәтен тоя барган Наилә. Үтә күренмәле юка телемнәргә туралган каклаган каз. Яшел суган кыякларында чык елтырый. Укроп, петрушка яфраклары арасында алтын беләзекләр булып казылык телемнәре яткан. Эре-эре сөякле дәү-дәү ит калҗаларында пар бии. Сарык кабыргалары алтынсу сихри төсләргә манылган. Наилә түзмәде: «Нигә кунаклар килеп җитми соң?» — дип шыбырдады. Сабит, шоңкар кош булып, табын өстеннән күз йөгертеп чыкты: «Кунаклар монда, кунаклар без инде, Наилә килен!» — дип көлеп җибәрде. Оҗмах аланга менгән чакларда болай да кәефе җиңел күтәрелә торган Сабит бүген аерата рәхәт хисләргә уралып калган иде. Аерып берәүнең дә хәтерен саклыйсы юк, бурычлар, йөкләмәләр, гамь-ваемнар бүгенгә оҗмах-аланнан читтә калган. Үз кәефеңне күреп, үз кадереңне белеп, туганнарыңны сыйлап утыр әйдә бер!

Көяз, кыска мыеклы әрмән егетләренең берсе Наилә алдына мае чожлап торган шашлык-куырдыкны китереп куйды. Наилә чак төчкереп җибәрмәде, кульяулыгы белән нәфис борынын кысып, артына борылды һәм төчкерәсе килүен онытты: көздән калган пәжегән яфракларны тишеп көнгә үрелгән яшел үлән кылычлары арасында испан ханымнарының җилпәзәсе булып шешәләр тезелеп яткан иде. Коньяклар, аракылар, көмеш башлы шампаннар, шәраблар. Наиләнең күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән дүрткел, озынча, юан бүксәле тәбәнәк шешәләр дә бар иде арада. «Өч кешегә?.. Күбрәк түгелме?» — дип уйлады ул, сөенеченә шик катыштырып.

Сабит шашлык китергән егеткә каш сикертте, егет күл буена таба китте дә, алар «ә» дигәнче гаип булдылар. «Әллә сихерле көмеш күлгә чумдылармы алар?» — дип сорады Наилә. Әгәр шул мизгелдә Сабит абыйсы, Татарстанның тылсымчысы: «Чумдылар шул, төпкә киттеләр!» — дисә, ул аңа да ышаныр иде. Бер тынга аптырашта калган кунакларга Сабит озак уйларга ирек бирмәде, ялт кына шешә ачып, коньякны киңчә төпле зур бокалларга мул итеп койды да чәкешергә үрелде. «Ягез, туганнар!» Алар киң, озынча өстәлнең ике ягына бүленеп утырганнар иде. Сабит — бер яктан, кунаклары — аның каршысында. Кыстата-кыстата Наилә чәркәне яртылады, ә Нәҗипкә тамчысын калдырырга да рөхсәт бирмәде Сабит, чәнечке җәпләренә казылык эләктереп икесенә дә кабымлык сонды. Чәркәләр мөлдерәмә тулды. «Беренчесе күрешү шәрәфенә иде, бусы туганлык өчен!» Бу юлы Сабит Наиләне дә өзми-куймый кыстады, чәркәнең төбе ачылганчы, «Бетереп, бетереп! Туганлык

җебен нығытканда тамчысын да калдырырга ярамый!» — дип күңелле такмаклап торды. Беренче йотымнардан ук тәненә ут йөгергән Нәҗип икенчесен эчеп куйганын абайламады да...

Бертын сөйләшмичә ашадылар, тамак кырган, ирен чәпелдәгән тавышлар оҗмах-аланда хуҗа булып торды. Казылыктан ерак далалар, кылган исләре килә иде. Тавыклар мәмрәп пешкән, аның вак-төяк сөякләрен теш арасына кыстырып бер-ике әйләндергәч тә йотып җибәрделәр. Сабит җәдәч сөяген кулъяулыгына төреп чалбар кесәсенә шудырды. Нәҗибенең өченчесен дә түңкәйтеп куйганын күргәч, Наилә ымы белән аңа тыелырга боерып карады. Мәҗлес кызды, чәркәләр бер орбита белән күтәрелеп-төшеп йөрделәр. Моңарчы боегыбрак утырган Нәҗип, майлы иреннәрен йонлач кул аркасы белән кат-кат сөртеп, ямьсез хихылдады, чайкалып урыныннан купты һәм ялагай, мескен тавыш белән: «Матурлык өчен! Муллык өчен! Иминлек өчен! Дан өчен! Шуларның барысына да хуҗа булып өлгергән Сабит абый өчен!» — дип кычкырды.

Йә, үзең тост тәкъдим иткәч, ничек эчеп бетермисең ди?..

Наиләнең күзеннән яшь атылып чыкты. Китте, чәркәнең төбе ачылды, Нәҗипнең башы әйләнде, ашказаны сулыгып ризык сорады. Ул суына төшкән шашлык калҗаларын чәйнәми-нитми генә тамагына шудырды. Мәҗлескә ут капты, түгәрәк алан өчен, көмеш тулган күл өчен, аланны каймалаган чыршы-каеннар өчен, рәхәт дөньяга чыгарган тиңдәшсез юмарт совет власте өчен, Наиләнең матурлыгы, Сабит белән Нәҗипнең батырлыгы өчен дә йотып куйдылар. Брежнев исеме әйтелгәч, Сабит урыныннан сикереп торды, үрә катты һәм: «Юлбашчыбыз, Ленин бабабызның иң ышанычлы шәкерте Леонид Ильичны хөрмәт итмәгән кешеләр чәркәләрендә бер тамчы булса да калдыралар!» — дип кисәткәч, Нәҗип, бер булса да юлбашчыга хөрмәтен белдерергә форсат чыгуыннан файдаланып, мул салынган чәркәне бер тында йотып бетерде.

Наиләнең күзе маңгаена менде, бер йотты да чәчәде... Ә Сабит? Аны һич танырлык түгел иде, олысымаклык, тәкәбберләнү, һавалану әллә кая китте. Ул яшел үлән кыякларын сыта-сыта биеде, учларын шап-шап чәбәкләп, чүгәли-чүгәли аланны йөз әйләнде, Наиләне биленнән кысып зыр-зыр әйләндерде, маңгаен тотып, аһылдап егыла язган хатынны сак җитәкләп кенә күләгәгә, урындыкка илтеп утыртты. Әз-мәз хәлләнгәч, Наилә күл тирәсенә атлады, кызуы сүрелә төшкән учакка карап торды, тая язып ярдан суга иелде, ботакка ябышып кулъяулыгын суга манчып, маңгаен чылатты, биек муенын юды, рәхәт булып китте.

Ул табын янына борылып кайтканда, Сабит белән Нәҗип, кочаклашып, бер-берсенә мәхәббәт сүзләре юллыйлар иде. Нәҗип, кулындагы мөлдерәмә тулы чәркәне болгап, тост әйтергә маташты, сүзенең энә-тотанагы булмады. Уйлары төрле якка чәчелгән, теле көрмәкләнгән, күзе тиле кешенеке сыман тонган иде. Наиләнең борчулы күз карашы белән очрашкач, аның түнгән миендә нәни генә аң чаткысы кабынды. Ул, яртылаш түгелгән чәркәсен өстәлгә куеп: «Мин әз генә ял итеп алыйм», — диде.

Табыннан ерак та түгел, куе чыршы ботаклары астында, одеял җәелгән киң сәке бар икән. Сабит, Нәҗипнең уң кулын иңенә салып, ярым сөйрәп аны шунда илтеп яткырды. Әйләнеп килгәндә аларның күзләре кылычка кылыч килеп кисеште. Наилә Сабитның ап-аек, янаулы кискен карашыннан берьюлы куырылып китте.

«Йокласын бераз, — диде Сабит, — ял итсен! Йомшак икән егет, солы кесәле!»

Моңарчы алар өчәү иде, өч арасында тышауланган Сабит, икәүдән-икәү калып, өстәл янына кара-каршы утыргач, әкрен генә кыяфәтен, тотышын, күз карашын үзгәртә башлады, уйлары исә аңа буйсынмыйча төрле тарафка чәчелделәр. «Нигә дип без бу исерекбашның гырлаганын сагалап утырабыз?! — дип ашыктырды аны уе.— Форсат барда нигә иркенләп урманда йөреп килмибез?!»

Аның тәкъдименә Наилә каршы килмәде. Ул, шуны гына көткәндәй, кабаланып диярлек урыныннан купты, ике куллап каенагасының таза беләгенә сарылды һәм алар шундый шигъриятле хәлдә, бер-берсенә ябышып күл тирәли атладылар.

Каршысында утырган хатын-кыз бер төрле тәэсир итсә, култыгына кергән хатын-кыз Сабитның бөтен күзәнәкләрен уятып, башын зыр-зыр әйләндерә иде. Ул, тәүлек чамасы үзен авызлыклап тотты тотуын, әмма хәзер ул читлектән ычкынган ач арыслан иде. Әле берни уйламаган тугры Наилә үзенең кыя тауны кисеп үткән төпсез упкын ярына якынлашуын сизенми иде.

Тирә-юньдәге гөнаһсыз кошларның чыр-чуы, яңарып яткан җир исен талгын ташыган җил бер мәлгә онытылды, күк гөмбәзен ябынган дөнья буп-буш калды. Шушы әкияти бушлыкны хәзерендә алар икәү генә тоялар иде шикелле. Бая, карабодай басуыннан, көртлекләр һәм әкиятләр патшалыгыннан кайтканда уена бәреп кергән сәер фикерләрен хәтерләп, Наилә үзалдына көлемсерәде. Аннан бер секундка да күзен аермаган, һәр адымын үлчәп, һәр хәрәкәтенә үзенчә бәя биреп барган Сабит кабынды: «Ник елмайдың, килен?» — дип төпченде. Кат-кат сорады. «Болай гына!» — дип кызарынды Наилә һәм шул кызыллыгы белән җавабының дөрес түгеллеген раслады. Аның тик тора алмас дәрәҗәгә җиткән күңелендә куркыныч бер теләк уянды: «Сабит абыйның тыгыз, талпынган иреннәрен бер үбеп алыргамы әллә?.. Гөлнарага кайтарып сөйләргә әкәмәт булыр иде булуын!» Үзгәргән күңеле аша Гөлнараның чуар тормышын, балга манчылып шәрә тән ятуларын, сауна рәхәтләрен, әрмәннең йонлач бармакларын үткәреп җибәргәч, Сабитның иреннәрен суырып үбү теләге

бермә-бер артты. «Иреннәре Нәҗипнеке төслеме икән? Бер кан ич аларда... Әй-лә, үбә беләмени аның Нәҗибе... Исерек карачкы!»

Бу сәер теләк сагаю, курку белән тиз-тиз алышынса да, күңелгә оялап өлгергән рәхәт вәсвәсә, шайтан аны гел котыртып, икеләндереп барды.

Күңелгә иңгән вәсвәсә хатын-кызның күз карашын, тән температурасын гына үзгәртеп калмый, аның адымы алмаша, мие түнә, әүлиядай хатыннар да иблис токымы затына әвереләләр. Наиләдәге үзгәрешне Сабит сизмәде түгел, сизде, аның нык ук уянган күңеле: «Туганымның хатыны ич... энекәшнең хәләле!» — дип сыкранды.

Күлнең аргы ягында, өч-дүрт җир буе ара киткәч, бередән күренми торган ышыкта, нәни генә, пөхтә генә йорт та бар иде, такта түбәле, бер генә тәрәзәле. Бу йортның барлыгын, аның ни-нәрсәгә хезмәт иткәнен күбесенчә хатын-кызлар белә иде. Бүген ул йортка якынаю хакында Сабит уйлап та карамаган иде, аяклар ничектер шушы тирәгә китереп җиткерделәр. Ул ишекне тезе белән төртеп ачты. Алар эчкә, күңелне били торган рәхәт караңгылыкка барып керделәр. Айный төшеп, акылга килгән Наилә бер дә аны-моны уйламады. Сабит та сабырлыгын җыеп өлгерде.

Идән уртасындагы камыш өстәлдә ике тустаган, шешәләр, капкач та йотарлык итеп вак-вак туралган ит кисәкләре, тавык бавыры, аерым тәлинкәдә симез сарык койрыгы күренде. Сабит тавышсыз гына Самвел белән Гургенны каргарга кереште: «Юньсезләр... Әйтмәгән килеш монда да табын хәстәрләгәннәр. Кеше котыртып... Күңелне аздырып! Кунак ханымның килен икәнен беләләр ич! Ахмаклар!»

Сабит Наиләнең ике иңеннән йомшак кына басып аны камыш көрсигә утыртты, үзе басып калды...

Нәҗип йокыга китә алмаган иде әле, ул сәкене каплап җәелгән йомшак одеялын җыерып уң ягына борылып ятты, һәм йокы белән уяулык арасында туа торган сәер халәте аны төрледән-төрле уй дәрьясына алып кереп китте. Ул сүнәр-сүнмәс яктырган офык уртасында үзен күрде, үз-үзенә ерактан, бөтенләй чит кеше булып карады.

Хыялларында ул үзе дә шундый иркенлекне, татлы тормышны күздә тотып яшәмәдемени? Кызганычка каршы, сукмагын дөрес сайламады, хыял-омтылышларының берсе дә тормышка ашмады. Бәс, шулай икән, нигә ул Сабит абыйсын дошман күрде? Нигә ул сайлаган юлдан җирәнде? Югыйсә ни аермалары бар аларның? Хак, берәвесе кул җитмәс биеклеккә үрләгән, атказанган, икенчесе, танавын канатып, канауда аунап ята. Рухи игезәкләр ич алар асылда, бердәйләр! Ата-ананы икесе дә санга сукмадылар. Кардәш-ырулардан йөз чөерделәр. Аерма тик шунда гына — Сабитның кемлеге хәзер ачык мәгълүм, Нәҗип үз омтылыш-тартышларын әлегәчә хатыныннан да яшереп килде. Хыяллары тормышка ашмаганга рухи имгәнеп егылганын ул өлешчә Фәридун Фазлыев белән Фаина Марковнага гына ачып салды.

Ике туганның кайсысы гөнаһлырак: Сабитмы, Нәҗипме? Утыз өч ел яшәп гөнаһсыз берәр бәндәне очраттымы ул?! Юк ич!.. Тукта, бар икән, бар! Әти-әнисе, яхшылыктан бүтәнне кылмаган изге җаннар!.. Сабит китергән ит-майлардан баш тарткан әтисе авылдашларына язган уртак язмыштан тайпылырга теләмәгән. Ул кеше булып калырга омтылган, шуңа ирешкән дә! Бер гаепсезгә читлеккә ябылган Фәридун Фазлыев... Башы нужадан чыкмаган Ираида Никифоровна... Җылы җанлы Фаина Марковна... Илнең гөнаһсыз бәндәләре җирдә-илдә Сабит ишеләр яшәгәнен тулаем белмиләр дә булыр, утыз өч ел яшәп Нәҗип үзенең кая, нинди тормышка омтылганын чын итеп шушы оҗмах-аланда гына күрде ләбаса! Илдә тигезсезлекнең елдан-ел көчәя баруын Нәҗип элегрәк тә сизенә иде... Хәзер уйлады: бәлки, шул тигезсезлек аркасында адашкан адәм уллары башларын аракыга ыргыталардыр да?! Аракы бер мәлгә кешеләрне тигезли, туганлыкның тишек-тошыгын ямаштыра. Абыйсы белән Нәҗипне дә бүген аракы тигезләде. Абыйсы аркылы тулы бер сыйныф — бер буйдагы рәисләр, парторглар, профсоюз куштаннары, активистлар, тагын күптин-күп әрәмтамаклар белән бер рәткә бастырды. Сары йорт әсире, Ионыч колы, симез көртлек атарга, чучка куырдыгы белән хушланырга яраткан власть вәкилләре белән дә тигезләнде, Нәҗип тә алар кебек, бер генә көнгә булса да, Маркс хыялланган коммунизмга чыкты. Сөен, Энгельс! Бар икән, дөнья читендә коммунизм аланнары да бар икән! Ни теләсә шуны ашый Нәҗип, машинада түш киереп йөри, шофер аңа «ләббәйкә!» дип баш ора, теленә ни килсә дә аны дурдомга япмаслар, чөнки ул тирә-якның ханы-солтаны Сабит Нургалиевнең кунагы! Хуш, хуш... Шулай да булсын ди... Ә нәтиҗә? Нәтиҗә шул: үзе моңарчы сүгеп, нәфрәтләнеп, җирәнеп йөргән партия, хуҗалык бюрократларыннан Нәҗип бер ягы белән дә аерылмый икән! Җай булса, ул шушы ялган коммунизмда гомерлеккә калыр иде! Бәс, алай икән, нигә ул әтиләре авылында - гаделлек хаклап йөргән булды? Кибеттә нәни генә булса да бунт күтәрде? Очраган кешеләрне: «Нигә бу хәлләргә түзеп яшисез?!» — дип котыртты.

Ул калкынырга теләде, гәүдәсе буйсынмады. Хәзерге мизгелдә җанына ия түгел иде Нәҗип. Җаны, күбәләк булып, оҗмах-алан өстендәге зәңгәр төтен алкаларына утырып тирбәлә иде. Кинәт җил учакны тергезде: җаны, сары күбәләк, канатлары көеп, агач ешлыгына мәтәлеп төште, тузанга әйләнде...

Капылт айныды. «Кем акчасына һәм ни өчен шулкадәр юмарт сыйлыйсың мине?» — дип, абыйсыннан сорыйсы килде. Сорарга кирәк! Кемдер сорау белән генә булса да аларны сискәндерергә тиеш лә баса! Нәҗип Йосыф улы Нургалиев абыйлары өчен корылган коммунизмда яшәргә теләми. Юк — и все!

Атаклы профессорның кияүдән кайткан кобра-кызына өйләнсә, ул бүтәнчә яшәр иде. Декан булып озак яшәмәде Захарчук, күксәү чиренә юлыгып, ай ярым дигәндә дүрт бүлмәле квартирын (Ульяновлар урамында!), дача, саклык кенәгәсендәге өч йөз меңгә якын акчасын калдырып, Арча кырына, мәңгелеккә сәфәр кылды.

«Һәркем үзенчә бәхетле була!» — дип шукланып яшәгән нык куллы Фәтхулла абзасын алыштырып промбазага кереп ояласа, Нәҗип остарып җитмәс идеме?

Бирнәле толга кол булып ялланмады Нәҗип, базага да күсе булып ояламады, нәтиҗәдә трактор арбасына утырып, кылдый-былдый юлларда шакшы сөт бидоннары белән бергә тәгәрәп, туган йортына кайтты. Кысыр сыер җилене тикле күчтәнәч кыстырып, җәй буе атасы хисабына тамак үткәрергә кайтып төште. Хәзер китәргә дә акчасы юк... Булган, Нәҗипнең дә мөмкинлекләре булмаган түгел, ләкин аларның берсе дә аның табигатенә ярашмаган, ул сагайган, саф килеш диярлек, чиста хәлдә кала алган.

Коньяк, аракы парлары, ниһаять, үзенекен итте, ул хәтерен җуеп, авыр гәүдәсенә кара канат куеп, төпсез упкынга очты...

Әле баярак Наиләне сокландырган көчле куллар ике имиен умырып тоткач, ул айныды, уң кулы белән каенагасының күкрәгенә китереп төртте. «Нишлисез сез?!» Күзен кан баскан, акылын җуйган Сабит җавап кайтармады, хатынның дерелдәгән сылу гәүдәсен почмакка кысрыклады. Шапылдап урындык ауды, аңа игътибар итмәделәр. «Наилә, сылуым, курыкмагыз! Наять булыр, аулакта ич без!» — дип, Сабит хатынны үгетләде, үзен дәртләндерде. Ләкин Наилә акылын җыеп өлгерде, котырган үгез сыман янында торган Сабитның култык астыннан шамбы балыгы сыман шуып чыкты, ул «тоттым!» дигәндә, яңагына берне чалтыратты. Сабитка бу бөтенләй ошамады, бер минутта нәфесен тыеп, омтылышын уенга алып, гафу үтенергә торганда яңактан чәчрәп чыккан ут аны тәмам тилертте. Ул: «Ник тыпырчынасың? Ул кадәр кем булдың?» — дип кычкырды. Наилә, үзенең кемлеген әзгә генә исеннән чыгарып ялгышкан, чит биләмәләргә кереп адаша язган кеше, күз ачып йомганчы чын халәтенә, сары йорт кешесенә, чирле, эшсез ирнең хатынына, каргалган язмыш иясенә әйләнде. Хәзер Сабит шашынган мир үгезе булса, Наилә кулына үткен хәнҗәр тоткан, иңенә ук-җәя аскан горур болгар хатыны иде. Ире, Нәҗибе исенә төште, аның шушы кискен тартыш барганда сәкедә җәйрәп, гырлап ятуын уйлап әрнегән хатын Сабитның икенче яңагына берне тондырды. Сабит тактикасын үзгәртте, кул хәрәкәтеннән элгәре сүзләр, кыланулар, ялган вәгъдәләр зарурлыгын аңлады, эш телгә күчте. «Ирең татлы йокыда, алтыным. Алан аулак. Без икәүдән-икәү. Алан сакта. Кошлар күрсә дә, аларның сайравын кем аңлаган?! Татар хатыны булып кыланма. Син миңа бик ошадың. Караган саен сиңа мәхәббәтем арта бара. Читкә какма, киреләнмә, бул минеке! Мин сине бәхет диңгезендә йөздерермен!» — «Кагылмагыз! — диде Наилә.— Китегез, зинһар!»

Шактый хатыннарны моннан кимрәк әзерлек белән дә кулыннан үткәргән Сабитның мондый кыргый каршылыкны очратканы юк иде. Әйе, хатыннар карышкалап та маташалар, ялындыралар да иде, идәнгә, үләнгә тезләнеп, ятып аунаган чаклары да бар иде аның, күкрәген йодрыгы белән төеп, ялган антлар эчкәне күпме, ә бу Наилә кыланмый да, шаяртып та маташмый — төрткән күкрәк тә сызлап тора! Үз гомерендә беренче тапкыр мондый хәлгә очрады. Ялындырганда, кыланганда, юри-марый буй бирми маташканда, хатын-кызны бөгәргә, сындырырга Сабит арсеналында йөзләгән ысул бар иде, ул хатын-кызларның күңелендә һәм тәнендә Ходай тарафыннан бүләк ителгән меңнәрчә хиссиятле нокталарны таба иде. Баш бирми торган юргаларны, аргамакларны берүзе станга кертеп, тавышсыз-гаугасыз дагалый торган тимерче тирә-якта бер булса, Сабит Йосыф улы шундыйларның берсе, атаклысы иде. Хәзер исә сынатты, ялынуы ялган, үгетләре буш, вәгъдәләре күз буяу булып чыкты. Дагалыйм дигәндә, чүкече ут уйнатканда, аргамагың стан араталарын ватып-җимереп чыгып китсен әле.

Бер ярсыды Сабит, бер уенга кайтарып калдырырга теләде. Хак, карышкан саен Наилә Сабитка ныграк ошады, туймас каны котырды, нәфесе җиде башлы дию булып аның назлы тәнен теләде. Ут булып янган яңагы сак булырга кирәклеген искәртте. Бу хатын көч белән алына торган затлардан түгел иде! Ашыкты Сабит, иртә котырды. Хәзер менә сүз белән җайга салып, ипкә китереп булырмы, юкмы?!

Тыелгысыз сүзләр яңа суырткан бал булып акты...

«Наиләкәй, карышуның мәгънәсез икәнен аңлыйсың. Гашыйк булуым хак. Син минем йокымсырарга мәҗбүр ителгән хисләремне уяттың. Сөмбеләне күрдең, чирле ул, иргә күптәннән хезмәткә ярамый. Синең гүзәллегең шаштырды, кызып китеп, ипсез кыланганмын икән, кичер. Ләкин карышуың юкка! Монда мин хуҗа, кулымда көч, власть. Бел: мин монда теләсә ни эшли алам!»

Тартышны ничектер көйле генә тәмамларга кирәк иде. Наиләнең күңеленә шаярту уе иңде, ул: «Ни теләсәм дә үти аласызмы?» — дип сорады. «Күктән йолдыз чүпли алмам,— диде, күкрәген төя-төя, Сабит.— Лувр музееннан Джоконда рәсемен чәлдереп үк булмас. Бүтәнчә — ни сорасаң, шуны үтим! Урман шаһит: боер. Күл суы белән ант итәм: үтим!» Ул тагын күкрәгенә сукты, күкрәгенең корыч калкандай киң, маймыл сырты сыман йонлач икәнен хатын-кызга белдерергә үлеп ярата ул. Оттырмый, җилбәзәк хатыннар шунда ук йомшак бармаклары белән аның түшен сыйпарга тотыналар. «Безгә Казанда өч бүлмәле квартир алып бирегез!» Сабит, мамонт ауларга җыенган кыргый булып, кулын бутап күккә сикерде. «Шәһәрнең кайсы төбәгеннән кирәк? Ничәнче кат? Кояшлы якмы? Наилә җанкисәгем, квартир ачкычы кулыңда дип бел!»

Биеп туктагач, ул сынын турайтты, сак, песи адымнары белән Наиләгә тартылды. Наилә, ул онытылып биегән арада, түрдән ишек катына күчеп өлгергән иде. «Бер генә үбәм... бер генә! Вәгъдәгә бер үптер инде! Үпкән-кочкан җилгә очкан! Суырып кына бер үбимче, җаным!»

Аркасы ишек тактасына тигәч, Наиләнең көче артты. Ул «Нәҗип уянмадымы?» дип тыңланып торды, ләкин тирә-як тын, якында гына бер кош сайрый иде. Аның күңеленә сәер уй килде: «Кошлар сайраша, без аларны куанычка гына сайрый дип беләбез. Аның бүтәнчә чарасы юк лабаса, җылавы да, көлүе дә бер төсле үк! Баласын җуйган сандугач берчакта да карга булып каркылдый алмый инде! Бәлки, ул Наиләнең җәтмәгә эләгә язып тырпылдавын күзәтеп торып сайрый-җылыйдыр? Аңламассың кош-кортны.»

Сабит, «эш җайланды!» дип, Наиләгә үрелгән иде, Наилә ике йодрыгын кушлап каенагасының күкрәгенә китереп орды. Аны-моны көтмәгән Сабит чайкалды, ныклыгын югалтты, бар авырлыгы белән гөрселдәп идәнгә ауды.

Наилә читлектән ычкынган кош булып тышка атылды. Туп-туры Нәҗип янына чабып барды, дөньядан ваз кичеп, тәмам җебеп-мәлҗерәп яткан иренең манма су булган чәчен тартты. Нәҗип иреннәрен кыймылдатып нидер мырылдады, мышнап борылып ятты. Хатын аннан рәт чыкмаслыгына ышангач, җилкәсенә берне кундырды да, кояшка карап алып, кайтыр юлга төште. Бая карабодай басуыннан үткәндә килгән юлны бераз чамалаган иде, күңеле сизенгән икән!

Башта ук исерек иренә рәнҗеде. Исереп, мәлҗерәп аунаган ирләр шундый мизгелләрдә хатыннарының каргышын, зарын бер булса да ишетсәләр икән! «Йолкыш! — диде Наилә.— Мәлҗерәгән! Сасы йомырка сарысы, төртенмеш, ачкак! Аракы күрмәгән бирән! Күзе тонганчы чөмерде! Йомыкый! Бәрәңге кәлҗемәсе! Сыек сыер тәбикмәге! Ач күз! Маймыл!» Иренә багышланган «сәламнәре» шунда тәмам булып, ул каргышларын Сабитка яудырырга тотынды. «Муены астына килгере! Бозык! Чукынгыры! Күрексез гармун! Тамагына таш торгыры!»

Коммунист, депутат, бюро члены, пленум әгъзасы Сабит Йосыф улы Нургалиев тагын бик күп мактаулы, шәрәфле исемнәргә лаек булыр иде, Наилә урман авызына чыгып җитте. Телендә каргау сүзләренең барын белми иде әле ул моңарчы, кайбер бәндәләр белән күчәр башлары орынганда алар, Ходай кодрәте беләнме, үзләреннән-үзләре телгә киләләр икән...

Әхмәтзыя янына бу рәвештә, күз акайтып, чәчне-башны туздырып, күбенгән сыер кебек мышнап барырга ярамый иде. Наилә шып туктады, күлмәк итәген төкерекләп сыпырды, тезе канаган икән, аны төкерекләп сыйпаштырды, тамагын кырды: шөкер, тавыш бар икән, тавышы булгач, Әхмәтзыяны көйләрлек сүзләрен табар.

Руль артында йокымсыраган Әхмәтзыя башта берни дә аңламады, аңлый алмады. «Мине авылга төшереп куегыз! — диде Наилә кат-кат.— Баш өянәгем кузгалды, миңа врач, Сөмбелә апа кирәк»,— дип өстәде. Әхмәтзыя, көнгә чыккан ябалак сыман, күзен мелт-мелт йомып: «Ә Сабит Йосыпович?!» — дип карышты. Әллә ялварып, әллә боерып, Наилә: «Кайтырга Сабит абый кушты да!» — диде, тавышы ямьсезләнде.

Якында аяк тавышы ишетелде. Наилә коты чыгып шул якка карады: фуражкасын тезенә суга-суга, милиционер монда таба килә икән. Ул Наиләне күреп шып туктады, дымлы маңгаен картуз түбәсе белән сөртергә тотынды. Наилә: «Үләм!» — дип ыңгырашты да машинага кереп чумды. Әхмәтзыя педальгә басты, башын чайкады. Ул бик нык икеләнә, курка иде. Әгәр бер-бер ялгыш җибәрсәң, Сабит Йосыпович аны тереләй тотып ашаячак... Үзеннән алда эшләгән шоферның бер кыек сүз ычкындырганы өчен дүрт ел ярымга төрмәгә тыгуларын ул бик еш исенә төшерә! Сабак! Юаш, җиде балалы Әхмәтзыя үзенең авылга түгел, җәһәннәмгә таба ашкынуын тиз аңлады: Сабит абыйсы хатын-кызны алай ансат ычкындыра торган ир түгел! Беткән баш беткән!

Сабит гөрселдәп идәнгә барып төшкәч, беравык исен җуеп, шаккатып: «Минме бу? Шушы ямьсез хәлгә мин төштемме?» — дип җәберсенеп ятты. Ни булганын аңласа да, моннан ары ни булырга тиешлеген, ниләр күрәчәген күз алдына да китерә алмады. Ярый, торыр, аягына басар, ишектән көнгә чыгар... Берәрсе аның күтәрәм сыер сыман егылып ятканын күреп калмадымы? Хуш, аны күрмәделәр ди... Ә Наиләнең аткан уктай атылып чыгуын, ире янына барып капланып, дөнья сасытып акыруын

күрмәскә сукырмы әллә алар?.. Наиләнең ире янына чабуында аның шиге юк иде. Форсат чыкканда һәр хатын-кыз тугрылыгын җанлы мисаллар белән ныгытырга ярата! Ул Наилә каядыр еракка чабар, машинага утырып авылга элдерер дип уйлый алмады...

Әрмән егетләре дәшмәс... Милиционер Вәлиәхмәт тә үз кеше... Ә Нәҗип? Дөньяда Наиләнең ире дә бар лабаса! Наилә шул боламыкка ниләр дип лыгырдар икән? Ничек итеп? Туганнарны пычакка пычак китерергә теләмәсә, берни сөйләмәс, алай да монда озак ятарга ярамый...

Сабит торды, төзәтенде. Иң мөһиме хәзер шул: Наиләне күзәтергә! Артыгын тугарылып китмәсен!

Хәзер үк барып җитәргәме? Әллә Наиләнең әз генә суынганын көтәргәме? Һәр очракта Нәҗип ни уйлар?

Ул сабыр итәргә булды, җан азыгы санап бер-бер артлы ике чәркә коньяк эчте, шешәне почмакка ыргытты, ауган урындыкны аякландырды. Фикерен бер ноктага юнәлтергә тырышып, тәрәзә каршысында басып торды. Күңеле болгана, мие кайный иде.

Әзерләнеп, гадәти битлеге белән йөзен каплап, күкрәкне бүлтәйтеп табын тирәсенә барып җитсә, беркем юк, сәкедә бөгәрләнгән энесенең өне ишетелми, көл сыман иреннәреннән сүз түгел, куе селәгәй ага. Ул күзе белән әрмән егетләрен эзләп, алардан сорашырга теләде, ләкин «күзгә чалынып йөрмәскә!» дигән боерык алган тыңлаучан әрмәннәр каядыр сеңгәннәр, күренмәделәр.

Сискәндереп күңеленә бер шик килде, ул да Наилә сымаграк тиргәнә-тиргәнә машина янына чапты. «Ах, явыз! Ах, ыштансыз марҗа! Ирдәүкә! Әләкче! Саескан!» Сабитның егәрле, нык аяклары велосипед кигиләре кебек ялтырадылар...

Ул урман авызына чыгып җиткәндә, машина калдырган ис таралган, тәгәрмәч астында сытылган үлән сабаклары әкрен-әкрен калкыналар иде. Якында гына күке кычкырды. Сабит аны ишетмәде, ачудан аның колагы, ияге белән иреннәре калтырыйлар иде. Чыршы белән каен арасында милиционерның картузы күренде. Сабит ыжгырып, ике сикерүдә шунда барып җитте. «Кайда ул?» — дип үкерде. Рәиснең төрле рәвешләрен күреп күнеккән Вәлиәхмәт, шыр җибәреп: «Кем?» — дип сорады. «Минем акылдан шашкан килен!» — «Киттеләр»,— диде, тилемсә елмаеп, аны-моны чамаламыйча, Вәлиәхмәт. «Кая киттеләр?» — «Киленегезнең утырганын гына күрдем, кая баруларын сорамадым!»

Сабит кинәт китереп орды, Вәлиәхмәт авыр көлтәдәй ауды, дөнья зыр-зыр әйләнде, күзеннән ут чәчрәде...

**23**

Колхоз председателе, КПСС члены Сабит Йосыф улы Нургалиевнең характеристикасы Советлар иленең байтак почмакларында саклана. Орден тапшырганда да язалар аны, депутат итеп сайлаганда әллә ничә җиргә җибәрәләр, әзмени лаеклы кешеләргә характеристика саклана торган оешмалар киң Советлар илендә?! «Алдынгы фикерле чын коммунист», «партиягә тайпылмас хезмәт итүче», «тугры», «принципиаль», «эшлекле», «тыйнак большевик», «тотнаклы ленинчы», «үрнәк эшләр иясе» һ.б.

Якыннан белгән, аралашкан, ризык бүлешкән, балыкка барган, сунарга йөргән юлдаш-иптәшләре, сердәш-көрәштәшләре, мөгаен, аның бу мактаулы сыйфатларына тагын ни дә булса өсти алырлар иде.

Сабит җитәкләгән мактаулы «Коммунизм юлы» кешеләре исә, рәисләре турында байтак нәрсәләр белсәләр дә, дәшмәсләр иде, чөнки ерак тарих дәвамында татар крестьянның авызы шулкадәр еш һәм нык пешкән ки, ул дәшмәскә өйрәнгән, зарланса, мич арасына кергән, йодрыгын йомарласа, җиң эченә яшергән.

Нәҗип, кайтырга җыенып, авыл турында хатынына мәгълүматлар биргәндә, абыйсы турында болайрак дигән иде: «Чибәр... Яшь чагында кызлар камалышында үсте. Иркәләнде. Эшем иясе булып күренергә ярата. Ата ялкау булса да, кеше җилкәсенә ансат менеп кунаклый. Әкиятләрдә бер зат бар ич, укыгансыңдыр: буе бер карыш, сакалы биш карыш затны онытмасаң, әнә шул бәндәгә алдар тазны да ялгасаң, Сабит Нургалиев килә дә чыга».

Тәүлек эчендә Наилә дә Сабитны үзенчә бәяләргә өлгерде, Сабитның бозык, фахиш зат икәнен дә белде. Аның мондый затсыз кешене күрү түгел, ишеткәне дә юк иде. Бәйләнчек Изил Латыйпов моның янәшәсендә гөнаһсыз бер фәрештә икән! Бер карында яралып, бер әнкәне имеп үскән туганының хатынына кул сузып маташсын инде, ахмак! Оятына ничек көч килми дә, шундый бәдбәхетне ничек җир йотмый?!

Әгәр, Ходай язганнар тормышка ашып, Газраил, Нөнкир белән Мөнкир өчәүләшеп каршыларына үрә бастырып, Сабитның үзеннән: «Кем син? Яшермә бөртеген дә, и адәм угылы, ачыл?!» — дип боерсалар, Сабит үзе дә аптырап калыр, тинтерәп җавап таба алмас иде.

Мисалга шуны әйтеп китик: Сабитның гомерендә дә төш күргәне юк, ята, мендәргә башы тиюгә йоклап китә, кай ягына ятса, шул хәлдә уяна, селкенми дә, кыймшанмый да! Арыган чагы була, борчулы чаклары, мәгәр аның йокысыз интегеп, түшәм санап, көндәлек уңышларына яки хаталарына

анализ ясап ятканы юк. Байтак квартирда, казна йортларында яшәделәр, яшьтән үк матурлыкны, гөлчәчәкләрне үлеп яраткан Сөмбелә, яңа урынга күчкән саен, гөлләр утыртып карады. Сабит яшәгән йортта гөлләр үсәргә теләмиләр иде.

Болынга, чәчәк-ганҗәләр арасына барып керсә, ул таптап үткән үләннәр берчакта да калкынмыйлар, терелмиләр, аның аягы тигән печәнне мал ашамый; ул моны белә һәм шуның өчен, намын, исемен саклап, әзер сукмаклардан йөрергә тырыша. Явыз ата казлар аңа ысылдап килми, усал этләр өреп берчакта да аңа аркылы чыкмый, машина урамнан үткәндә үк койрыкларын бот арасына кыстырып, кая туры килсә шунда, аулакка посалар. Бәбиләрне кулына алса, алар күз-кашларын җимереп үкерәләр, төнката бимазалананалар. Юкә балы чорында чүнниккә кунаклар алып барып, кызыксынып иелсә, бал кортлары очудан туктый, умарта авызына кизүгә куелган кортлар дәррәү эчкә кереп яшеренәләр. Корт чакканы юк аны, кара еланнар очраса, тәгәрмәчкә әйләнеп әллә кая ыргылалар, ул чишмә авызыннан эчәргә теләп иелсә, аның сулышы тиюгә, су тибеше әкренли, юынырга керешсә, тына, туктала.

Кыскасы, үз асылын,ниләр кылырга маһир икәнлеген Сабит үзе дә белеп бетерми иде...

Сабит, шулай итеп, чарасыз калып, сорауларның берсенә дә җавап таба алмыйча, муртайган имән төбенә барып утырды, кояшта җылынып йөгерешкән кызыл тараканнар, кырмыскалар төрле якка таралдылар, тычкан тишеге тирәсендә быжлаган төклетура, әллә кая, Карама куыш тирәсенә очып китте. Сабит кайнап бәргәләшкән уйлары белән япа-ялгыз калды.

Нәҗип Казанда чакта Наиләсенә: «Бригадирга булышып йөргәндә боздылар малайны, бакча сукаларга ат кирәк икән — аңа килделәр. Печән-салам алып кайтырга дигәндә йомышлары аңа төште. Тол дүдәк, ятим-ялпы хатыннар, ирләре бәхет эзләп читкә тайпылган киленчәкләр гел аңа ялынды. Яшьли аракыга ирене тиде малайның. Авыл бозды Сабит абыйны!» — дип аңлаткан иде...

Җиңел һәм беркатлы аңлату! Кемнең кайчан һәм ничек бозылганын белеп булса икән!.. Ярдәмчедән бригадир иттеләр Сабитны, тора-бара күрше колхозга рәис итеп җибәрделәр. Районда гына түгел, республикада иң яшь председатель иде ул! Дан алган егетне Саратовка, Өлкәара партия мәктәбенә укырга озаттылар. Курсларда да иң яше ул иде. Буй озын, кыяфәт килгән, хәтере шәп, сүз өчен бурычка кереп тормый, русчаны тиз элдерде, теттерә генә — җыеп әйткәндә, Сабит курсларның күз өстендәге кашы булды. Комиссия, тикшерү, кунаклар килгәндә аны иң алга чыгардылар, ипи-тозны аңа тоттырдылар.

Ике елдан укып кайтты, Сабитны район үзәгеннән ерак түгел Ирнә үзәненә таралып урнашкан мал-туар симертү совхозына директор итеп җибәрделәр. Элеккеге директор, чакрым баганасыдай биек буйлы, мишәр Хәлиуллин, эшен тапшыргач, вәкилләр сыйланып киткәч, егетне үз янына, кабинетның аулак чоланына дәшеп кертте. «Мин сине белмим, мәгәр, энем, бер күрүдә ошаттым. Шылай, кәбәм, олы эшкә алынасың. Бел һәм онытма, борының райком ягына борылган булсын! Шуннан нинди җил исә, белеп ала торган бул. Мин сиңа, кәбәм, учетка кермәгән унҗиде баш сыер, илле данә тана һәм дә йөз илле каты борынны калдырам. Баш саннарын өлкән зоотехник белән бухгалтер Нәҗибә генә белә. Дәрәҗәләрен, хаҗәтләрен һәм үзләренә ни бата икәнен белә торган зирәк балалар. Аларга ышан, тик күзеңнән ычкындырма! Куелыкта чакта нәзек агачны да җил сындыра алмый. Сине нык куллы, каты кеше дип танысыннар. Эшкә өйрәнгәч тә узынма. Чамасын онытмасаң, совет власте юмарт ул, кәбәм! Кешене кешедән аера бел, мине онытма! Мине Башкортстандагы дуслар чакыра, райисполком итмәкчеләр!»

Мишәр Хәлиуллинга Сабит гомере буе рәхмәт укыды. Нинди юмарт куллы, затлы кеше! Һичнәрсәне яшермәде, бер күрүдә аңа ышанды, күпме байлык, акыл калдырып китте. Әле Хәлиуллин заманында прокурордан шикләнәләр, райком секретарьларыннан, милициядән куркалар иде. Сабит заманында һәр тарафка яңа буын кешеләре килде, алар яшәеш законнарын да, властька элегрәк килеп, үзләренчәрәк яшәп ятканнарны да тиз-тиз үзгәрттеләр, үзгәрмәстәйләрдән ансат котылдылар. Районда Сабит курка торган зат калмады: симез сарык түшкәләре, таналарның ал һәм арт ботлары, бавырлары, тез башлары прокурорга да, райком әһелләренә дә, Казан кунакларына да аның кулы аша үтә торды. Рәхмәт тиңсез акыллы мишәр Хәлиуллинга! Ул биргән акылны Сабит ныгытты, маясын ишәйтте. Аның тагарагыннан ашаучылар ел саен арта бара иде.

Мал-туар хуҗалыгында күрсәткән хезмәтләре өчен ул ике ел рәттән орден алды, Мәскәүгә, авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә чакырып, «Москвич» машинасы биреп кайтардылар. Бигеш аэропорты эшли башлауга шактый яшьләре шунда киткәч, уртачалардан саналган «Коммунизм юлы» колхозына рәис итеп аны җибәрделәр. Сабит бер мәлгә шүрләбрәк калды. Райком секретаре: «Колхозыңны үрнәк ит. Алга чыгар. Дан яула. Өмет синдә!» — диде. Куркуы юкка булды, мал-туар симертү совхозында шәбәйгән танышлык, арадашлыкның һәрдаим файдасы тия башлады. Кодрәтле куллар аңа төрле яктан ярдәм яудырды. Бәйрәм алларыннан телевидениедән, радиодан, газета-журналлардан иң житез, елгыр егетләр килеп, атна буе сыйланып кунак булдылар.

Сабитның кулы юмарт, хуҗалыгы нык, кадрлары ышанычлы иде. Колхозның даны күзгә күренеп артты: орденнар, бүләкләр, мактаулар чоры башланды. Баштарак бер нәрсә бимазалады: әти-әнисе,

туганнары белән ара ераклашты. Яшәү дәрәҗәсе, аралашкан кешеләренең абруе туганнарны теләсәң-теләмәсәң дә читкә кагарга мәҗбүр итә иде. Тора-бара Сабит анысына да күнекте.

Түрен туганнардан яшерде, «вакыт юк, эш күп!» дип, чакырган җирләргә бармады, агай-энеләр дә аны аңлаган кебек булдылар.

Үсте Сабит, делегация составында Америка, Голландиягә барып фермерлар белән очрашты. Самолетта шыр җибәрә торган кеше, очсыз-кырыйсыз океан өстеннән очканда: «Исән-имин кайтып элгәшсәм, эти-әнине күреп чыгармын!» — дип нәзер әйтте. Кайткач, әүвәлгечә вакыт җиткезмәде, партактивтан пленумга, пленумнан активка чапты. Америка коммунистларын, эшсезләрне, бер хокуксыз негрларны «җәллә͏п» нотыклар тотты, ашкынып коралланучы, Совет илен хәрби базалар белән чолгаган Пентагонга адреслап нәгърә орды...

Кунакта симез итне хәтсез күп ашап, эче борып-борып авыртып уянгач, Сөмбелә биргән дарулар да ярдәм итмәгәч, шигәеп, «нәзерем тотты» дип, бик ашыгыч кына авылына кагылды. Америка, Голландиядә халыкларның, шул җөмләдән крестьяннарның да ничек яшәгәнен күреп шаккаткан Сабит этисенең турыдан суктырган соравына нинди җавап биреп котылырга белмәде. Этисе болай диде: «Улым, син йөргән якларда ярлы һаман ярлымы, әллә аларда ярлылык бөтәнчәрәкме?»

Сабит боргаланды, этисенең юаш, басынкы гына, бөкресен күтәрә алмыйча иелеп, күзгә карап торганын күргәч, алдарга базмады, күнегелгән ялганын сиптерергә көче җитмәде. Этисе Сабитны зарыгып көткән иде, имтихан алучы кырыс профессордай, өстәмә соравын да биреп өлгерде: «Мәзәк бит тормыш, улым. Ярый, сугыш, дидек. Сугыштан алда кулаклар илгә зыян салган, диделәр. Алардан соң корткычлар, троцкийчылар илнең тамырын кимергән, дип аңлаттылар. Кулакларны сөрдек, корткычларны кырдык, сугыш беткәнгә бишбылтыр... Крестьянның тамагын туйдырырлык хәләл закон чыгамы бер, юкмы? Яши башлаганнан бирле крестьянның ипекәйгә туенганы юк лабаса. Син йөргән җирләрдә хөкүмәтләр буржуйский... Алар инде крестьянга бер бөртек калдырмыйча алып бетерәләрдер. Безнең, ичмасам, юанычыбыз бар: эш башында үзебезнекеләр утыра. Эшче дә крестьян... Андадыр инде ул хәлләр! Негрлар ачлыктан бер-берсен ашыйлар дип яза гәҗитләр. Шуларны күрә алдыңмы, юкмы?» Сабит мондый туры сорауларны беренче тапкыр ишетте. Бүтәннәр сораса, ул андый пырдымсызларны тамак тавышы белән ялт тыяр иде. Этисенә каршы төшәргә йөрәге җитмәде, иле белән әллә кайчан коммунизм шартларында яшәп ятучы Голландия крестьяннары хакында дөреслекне дә ачмады. Авыл агайлары бер-берсенә хәбәрләрне җиткерергә яраталар. Этисе кемгәдер ул күргәннәрне сөйләсә... бәладән башаяк! Әнә күп сөйләгән Щаранскийны Чистай төрмәсенә тыгып куйганнар...

Туган йортыннан этисе әзерләп куйган сорауларга җавап бирмәс өчен дә читләште ул. Тик бусы юкка иде, буыны ару-талуны белмәс Йосыф карт инде бетәште, биле бөкрәйгән саен күз күреме тарайды, иелгән башы җирне һәм шул җирдә тырманган кешенең хәлсез аякларын гына күрде. Күңеле гамен, улына юнәлткән сорауларын ул әллә кайчан онытты, җиңеләйде. Элек сөзәк тау битенә чәчелгән кабер ташларын белми дә иде кебек, хәзер көн туса баш шул хәсрәтле якка каерыла... «Кара канатлы Газраил очып килмиме?!»

Бәхете юк икән — юк инде ул, аны булыр димә, крестьянга берзаман камыт кигергәннәр икән, кайсы патша яки юлбашчы салдырсын аны?! Ат белән крестьян камытын ташласа, илне кем туендырыр? Риза-бәхил, Ходаем, Йосыф белән Мәрьямбикәнең тамагы туймаса да, балалары балдамайда йөзә, ипине күкрәккә терәп кисәләр. Үз вакытында авылдан чыгып ычкындылар. Әнә хәзер китеп кара, паспорт сорап йөз ертып барсаң, кәҗә билеты тоттыралар, абзар артына барсаң барырсың, аннан ары юл киселгән.

Авылда хәзер урындагылар яшәсә яши, әнә Сабит кебек уңганнар дөньяны уч төбендә биетә. Вәт аны яши диләр! Дөрес, Йосыф картның улын барып күргәне юк, кеше сөйләгәннән чыгып кына чамалый. Татарның шул инде язмышы: «Ай-һай, ак калач тәмле икән!» — «Ашап карадыңмы?» — «Юк ла, эти Эзи базарында бер марҗаның ашаганын күргән!»

Котырган төлке белән алышканнан соң этисен больницага нинди хәлдә салуларын баш врач аңа көне-сәгате белән җиткерде. Яше олы кеше чирләмичә тормас, була торган хәл, әмма этисенең котыру чире йоктыру ихтималы аны нык борчыды. «Этисе котырып үлде» дигән хәбәр калкып чыкса, бер дә Сабит файдасына түгел иде. Тәҗел эшләрен кичектереп, киләсе кунакларына отказ биреп, больницага ашыкты. Картның һушсыз яткан чагы иде, аның катына Сабитны да кертмәделәр. Өч көннән соң тагын барды. Бу юлы баш врач аны Йосыф карт янына ияртеп керде. Килеп кергәч тә Сабит этисен күрмәде, күргәч танымады. Юкарып, арыкланып калган Йосыф караватка сеңгән, аяк-куллары хәрәкәтсез таралган иде. Юрган калынлыгы җансыз гәүдәнең этисе икәнен белгәч, Сабитның күңеле тулып, күз төпләре дымлангандай булды. «Эти,— диде ул, җебеп, балалыкка кайткан тавыш белән,— хәлең ничек?» Карт үз хәлен әйтеп бирә алмады, баш врач әйтеп аңлатырга курыкты...

Эзи белән авылы арасын Сабит капма-каршы уйларга уралып үтте. «Исән-аман котылып чыкса, берәр яры дәваланырга җибәрергә булыр... Әнә Казан янында гына Васильево бар, терәлеп тора, ашау-

эчү дә ару гына, диләр, ятсын шунда ай буе!.. Йорт-җирләрен әз-мәз караштырасы иде... Ит-ашлары да әллә кем түгелдер, Әхмәтзыя берәр симез түшкә илтеп ташласа да чит булмас...»

Эзи артта калып, ятагына тормастай сеңгән хәлсез карт ераклашкан саен, Сабит бүтәнчәрәк уй йөртте: «Үлсә, ни әйтерсең? Мондый яман чирдән әллә кеше булып чыга ул, әллә гомергә имгәк, күз күеге хаста булып кала. Кем карар аны? Үлүе — котылу, исән калганнарны коткару!»

Әйтергә кирәк, авылга кергәндә ул әткәсенең җайлы гына үлүен теләде, аның әҗәлен «ансат котылу» дип атады.

Казан табиблары, җирле врачлар Сабитның бу уйларын белми калдылар. Алар, киресенчә, республикадагы иң гайрәтле кешенең әткәсен коткарыр өчен көне-төне тырыштылар, йокламадылар. Котыру чиреннән билгеләнгән дару-дәрманның ни өчен файдага китмәвен кат-кат анализлардан соң белделәр. Аның кан косып әлерәк кенә больницага кереп чыгуы күп нәрсәне ачыклады. Еллар буе ашлык агулауда катнашып, яшелчә бакчасында эшләгәндә түтәлләргә дустны учы-учы белән сипкән, язын самолетларга гербицидлар, төрле көчтәге пестицидлар төяшкән, ни кылганын, ни сулаганын уйламаган Йосыфның организмы агудан тәмам йончыган, үпкәләре эштән чыккан, бронхларына куркыныч матдәләр кереп тулган булып чыкты.

Соңгы диагноз Сабитны аерата хафага салды. Бүтән берәү мондый чир эләктерсә, аның исе китмәс иде, авыру йә үләр, йә терелеп чыгар иде. Һәммәсе Хода кулында. Ә монда... «председатель Нургалиевнең атасы төрледән-төрле агулы матдәләр арасында уралып, минераль ашламалар чыгарып чир йоктырган, үпкәсе череп-теткәләнеп беткән!» дигән яман хәбәр халык арасында таралса?..

Сабит Нургалиев хагы-нахагы белән бергә районда минераль ашламаны кырга иң юмарт кертүче иде. Район өлешен генә түгел, уртак тимер юл станциясеннән күршеләргә дигәнне дә ул үзенә ташытып куйгалый иде. Машиналар күп, шоферлары — ул тәрбияләгән, җитез, урлашырга күнеккән. Яңа ел киче дип тормыйлар, Октябрь бәйрәме дә аларга песи төчкерүе белән бер,— чыгалар да китәләр, бүтәннәр аяк киенгәнче, ташып, тутырып та куялар. Агу юмарт сибелгән кырларда чүп үләне үсми, аның серләрен Сабит әллә кайчан белеп оныткан! Аның колхозында төзек бер әгъзасы да калмаган кешеләр бар, ләкин әле алар яшь, тазалар, аларга акыл бирүче, «Нишлисез сез? Нигә, һич югы, агу арасында уралганда халат, пирчәткәләр, респираторлар кимисез?» — диюче юк; киресенчә, сөенәләр, уч тутырып акчасын, машина әрҗәләрен түбәләмә тутырып ашлык алалар, аларның агудан челтәрләнә башлаган үпкәләрен әлегә яшергән күкрәкләренә көзләрен орденны депутат Сабит Нургалиев кадый...

Сөмбелә генә шиккә төшә башлады, авыл арасында моңарчы күрелмәгән хәлләр ешайды. Яңа өйләнешкәннәрдән берәү гарип бала алып кайтты, сабыйның аяк-кул бармаклары укмашып каткан иде. Мәк чәчәгедәй ике киленнең бәбиләре үле туды. Ашлама складларының мөдире Фәезханның колагы ишетмәс, күзе күрмәс булды. Кырык яше яңа тулган иде Фәезханның! Сөмбелә шикләрен Сабитка әйтеп карады. Сабит аңа бер генә кычкырды: «Тавышың чыкмасын!»

Ул әтисенең чирен, кан косуының сәбәпләрен беркемгә чыгармаска кушты. Казан белгечләре китте дә югалды, җирле табиблар тел тешләделәр. Тынды «ак чәчәкләр»!

Шулай итеп, Йосыфның чир тамырлары сер булып калды, фаш ителмәде, тавыш-гауга чыкмады, бар да улы Сабит таләп иткәнчә көйләнде. Бераз вакыттан соң картның хәле тигезләште, ул әнә шундый буынсыз, чирләшкә, хәтерсез Хода бәндәсенә әйләнеп калды.

Ә Сабит, изге ниятләрен, нәзерләрен тиз онытты, яңадан-яңа мәшәкатьләр туа торды, кемдер килде, кемдер кагылып чыкты, утырышлар, пленумнар, киңәшмәләр, симпозиумнар, тәҗрибә уртаклашулар, әле Казан, әле Мәскәү юллары. Унөч кешелек делегациягә җитәкче итеп аны ун көнгә Япониягә җибәрделәр. Болар янында әткәсенең чире бик бәләкәй, вак-төяк булып кына калды.

**24**

Кунаклар: «Иртән Сөмбелә кабыл-тибел чыгып югалды, юньләп эндәшмәде», — дип үпкәләделәр. Асылда, ул беркая китмәде, өйдә калды, барлыгын кунаклар белеп өлгермәгән иң эчкәрге, аулак бүлмәгә кереп бикләнде. Сөмбеләнең кайдалыгын Сабит бик яхшы белә иде, ызгыш-талашлардан соң хатыны ара-тирә шул бүлмәгә кереп кача, ишекне эчтән элеп, мендәр почмагын тешли-тешли кайгысын тараткалый иде. Дөрес, соңгы дәвердә ул иренең хикмәтләренә күнекте, исе китми башлады, чит хатыннар белән юргалавына бармак аша карады, «бөкрене кабер генә төзәтер» дигән иманга килде.

Өйләнешкәннәренә ел дигәндә, юк өчен үзара низаг чыгып, кара мунча өйалдына кереп бикләнгән хатынын Сабит чабаклап алып кайткан иде. Һай, гомерләр — теләгәндә качар урыны да булмаган Сөмбеләнең ул чаклары! Хәзер табып кара, аулак бүлмәнең ишеге имән тактадан, эчтән тимерләнгән, ачкычы үзендә генә, өй тирәсендә уралучы Бәдәр дә керми анда. Бу бүлмә — Сөмбеләнең хөҗрәсе, аның зонасы, бүлмәдәге һәр почмак аның бик күп күз яшьләренә шаһит. Сабит та канәгать — Сөмбеләнең алмаз яшьләре шунда эзсез сеңеп бара...

Сүз белән алдыра торган ирләр була, кайберәүләр буй-сын белән хатын-кызны һушсыз итәләр, өченчеләр кылган гамәлләре белән кыз-кыркынны үзенә тарта, биргән татлы вәгъдәләре белән әсир итә. Болар өстенә Сабитның күз белән алдыра торган көче бар иде.

Сөмбелә өтек кенә бу колхозда өченче елын врач булып эшли иде инде. Көзге пычракларда председатель итеп япь-яшь егетне китерделәр. Райкомның авыл хуҗалыгы мөдире җыелышта аны күкләргә чөйде, «колхозның киләчәге — газиз илебезнең киләчәге ул, ә илнең киләчәге Сабит Нургалиев кебек уңганнар кулында» дип мактады. Ходайның әмере шул булгандыр: җыелыштан соң кичке чәйгә яңа рәисне, аны озата килгән вәкилне, авыл куштаннарыннан берничә кешене Сөмбелә яшәгән квартирга алып кайттылар. Сөмбеләнең кызларча пөхтә җыештырылган дивары әти-әнисенең, туганнарының фоторәсемнәре белән чуарланган, киштәсендә китап-журналлар тезелеп яткан җыйнак кына почмагы бар иде. Чаршау-пәрдә белән бүленгән олы якта хуҗалар — әби-бабай гомер кичәләр. Сөмбеләнең уңганлыгыннан хәйран калганнар, «үзе чиста, эше пөхтә, өйне гөлдәй итеп тота, аш-суга осталыгына исең китәрлек, теле ягымлы, үзе чибәр, буе зифа...» Бабай очынып мактаганда, әби тешсез авызын мыймылдатып, күзенең агы белән генә карап куйгалый, имеш...

Юкарак озынча гәүдәле, күлмәге аша төртеп торган беленер-беленмәс күкрәкләре булган бу гадәти татар кызы кыюсыз иде шул. Әз сүзле, ягымлы ихлас врачны әби-бабай гына түгел, бөтен авыл үз итте, яратып өлгерде. Уймак авызының тулышкан иреннәре сафьян кебек йоп-йомшак, чәчләре колак тирәсендә бөдрәләнеп киткән, кашлары җемелдәп торган, кап-кара иде кызның.

Сабитның өйләнмәгән егет икәнен клубта чакта ук кызларның чаяраклары колактан-колакка сөйләгәннәр иде инде. Сөмбелә — институт тәмамлаган дипломлы врач, унбиш кешелек кенә больницасы бар, инде өченче елын эшли, кияүгә чыгу өмете сүнеп-сүрелеп куйган мизгелләре булгалый, бердән — кызның буе озын, икенчедән — врач, өченчедән — чибәр дә, ул төпләнгән авылда, күрше-тирәдә аңа тиң булырлык, тиң санап сүз катарлык егет-җилән юк иде. Сабитка күз атып чышын-пышын сөйләшкән кызлар арасында ул тып-тын утырды. Җыелышны ташлап чыгып тиз-тиз өс-баш алыштырып килүчеләргә дә игътибар бирмәде. Сабитның үз-үзен тотышында тыйнаклык, теленең матурлыгы, тавышының горур көрлеге аны беразга җәлеп итсә дә, Сөмбелә бүтәнне уйларга өлгермәде. Аны җәлт кенә партоешма секретаре чакырып алды һәм өенә ашыгырга кушты. «Сынатма, сеңел!» — дип кисәтте...

Андый «кичке чәйләр» үткәргәне булмаса да, Сөмбелә каушап төшмәде, бик ашыгыч кына пилмән бөкте, мич ягып вак бәлеш утыртты, тозлы кыяр турады, башлы суганга көнбагыш мае сибеп салат ясады, ризыкларының һәммәсен өлешләргә бүлеп, бар булганын матурлап өстәлгә тезде. Кәрәзле балны әллә ничек тылсымлап кисеп торганда, лапыр-лопыр атлап, күн итекләренә балчык төяп, ир-атлар кайтып керде. Алар күңелле гөрләшеп, мич арасында бит-кулларын юып, чәчләрен ыспайлап тарап, туп-туры табын тирәсенә сырыштылар. Аш өлгергәнне көтеп тозлы кыяр, салкын ит калҗалары капкалап, тустаганнарын еш-еш күтәрә башладылар. Пилмән чыкканда йөзләре килгән иде аларның. Яңа рәиснең тустаганга бик чамалы кагылуын, өлкәннәр сөйләгәндә алга чыкмавын, берәүне дә бүлдермичә ихлас тыңлавын өй белән чолан, чолан белән келәт арасында тыз-быз йөргән Сөмбелә күрми калмады, әлбәттә. Гаҗәпләнде, аның гел чоланга, келәткә чыгасы гына килеп торды. Келәт, чоланнарга кагылганнан соң табын тирәсенә ни булса да китерергә җай чыга иде. Яңа рәис тә әле тоз сорап алды — тозга кагылмады. «Агач кашык бирегезче!» диде — үзе калай кашык белән ашады. Ирләр ачыкканнар икән, пилмәнне өстәтә-өстәтә состылар, ак серкә китерткән Сабит аңа да үрелмәде. Инде бүтән ризыкка урын да юктыр дип чыгарган вак бәлешнең йогы калмады, комагайланып, табында ни бар, бөтенесен ашап бетерделәр.

Тамагына берни капмаган, арыган, маңгаена бөрчек-бөрчек тир сибелгән Сөмбеләне иң актыкта, китәргә дип җыенганда, кунаклар үз яннарына чакырдылар. Үзенең, арзанлы ситса күлмәге, йомшак-ягымлы карашы, татар кызларына хас мөлаем-сабыр тыйнаклыгы белән ул Сабитның күңелен җилкетеп алды. Җанының болай да язгы сулардай ташыган чагы иде, председатель булып киләсең икән, өйләнмичә ярамый, тәрҗемәи хәлләрне кәгазьгә тутырганда «өйләнгән, өйләнмәгән» дип теркиләр икән, бу инде бер дә юкка түгел, өйләнмәгән кадр — басудагы җил ул, әле генә монда, кул арасында иде, күз ачып йомганчы Карама куышка барып җиткән.

Сабитның күңел ачардай таныш-белеш кызлары шактый булса да, «Өйләнәм!» дип күз тоткан кешесе юк иде. Сөмбеләнең дүрт яшькә олырак булуы аны бер мәлгә икеләндерде дә онытылды. Күз төшеп, күңелгә дәрт ояласа, яшькә карап торалармы?

Сабит төпсез күзе һәм карашы белән алдыра иде. Сихерле, тирән иде аның карашы, кеше җанын үтәли тишә ала торган сөрмәле күз бүләк иткән иде юмарт табигать бу егеткә.

Кичлекләре калмаган хуҗалар, әтәч белән тити, әллә кайчан йоклаган булганга, кунакларын барлап озату да Сөмбеләгә йөкләнгән иде. Соңгы кеше булып ишеккә яңа председатель килде, чыгарга ашыкмады, сүз дә әйтмәде, кызның калтыранган кулларын кысып, һич көтмәгәндә аның татлы иреннәреннән үбеп алды. Иреннәрнең кызыктыргыч матурлыгына керүгә сокланган иде, аларның сусыл йомшаклыгы, кызның татлы сулышы, тыны егетнең башын әйләндерде. Ул тагын бер үбим дип

үрелгән иде, сагайган кыз, юк, ачуланмады, кәҗәләнмәде, айдай балкып башын читкә какты, бөдрәләре колак тирәсендә уйнадылар. Авызга үрелгән Сабитның иреннәре кызның юка иңбашына кагылды, йомшак икән аның тәне, канны кайната, дәртне уята торган тән икән!

Председатель булып килгәч, ул эшне тиз тотты: ике ай дигәндә алты почмаклы якты йорт җиткезделәр. Морҗадан беренче төтен ургылып чыкканда, яңа йортка авылның яңа хуҗасы килен төшерде. Яңа нигездә яңа тормыш башланды, уллары туды. Малай көткән Сабит Сөмбеләсенә тагын да ныграк якынайды. Сабит Саратовка укырга киткәнче алар хәйран матур яшәделәр. Өйләнешкән елдагы гаугалар, юк-бар арасында килеп чыккан низаглар кими төште.

Ике ел эчендә Саратовтан Сабитны алмаштырып кайтардылар. Кыяфәте, төсе-бите генә түгел, исе, кыланышлары, кешеләргә мөгамәләсе, сөйләү рәвеше, килеш-килбәте үзгәргән иде аның. Төнлә кайтып керде, бәләкәй караватта авызын чәпелдәтеп яткан йомры улына сыңар күзен төшергәч, сөенеченнән балкыган хатынына бер сүз генә әйтте: «Чишен!» Тәне куырылып, җаны өшеп киткән хатын нишләргә белмичә арлы-бирле талпынган арада тагын бер хөкемен игълан итеп өлгерде: «Моннан ары, мин көннең-төннең кай вакытында кайтып керсәм дә, иңеңдә юка халат кына булыр. Бүтән берни юк!» Сөмбелә кызмача ирнең мондый шартын көлкегә алды: «Син кайтканны хәбәр итеп торырга капка төбенә сакчы куй алайса!» — диде. «Куярмын да!» — диде Сабит һәм һаман аңына килә алмаган хатынының өстеннән чүпрәк-чапракларны умырып, йолыккалап теләсә кая ыргыта башлады. Аның корыч бармаклары Сөмбеләнең йомшак тәненә умырып, ертып керде. Сабит тыелгысыз, ач хис белән ими башларын тешләп, чәйнәп бетерде.

Шуннан террор башланды. Төнката ризасызлык, зар сүзләре, чиксез оятсыз таләпләр... Ә көндезләр — төннең дәвамы: «Нигә тәлинкәне тутырасың, бирән түгел ич мин!», «Ике көн рәттән токмач та кашык чумары! Миңа тау бүксә тагарга телисеңме?» Вак бәлеш «тавык җимеше» булды, өчпочмак — «искелек калдыгы». Сөмбелә яратып пешергән кәбестә ашы «юынтык су»га әйләнде. Гауга кухнядан караватка, караваттан аш-су тирәсенә ялгана торды, өзелмәде. Сабит хатыныннан чыкылдап торган бозыклык таләп итте. «Тәнем тартына, Сабит, кыймыйм»,— дип аңлашырга омтылган тыйнак хатынын Сабит караваттан төртеп төшерде. Нык кына салып кайткан иде...

«Ярабббым! — дип ялварды, балачагында догалы йортта әби-баба тәрбиясе күргән, күкрәгендә Ходасына, Тәңрегә ышанычы бетмәгән хатын. — Гыйлем эстәү ике елда кешене танымаслык үзгәртә алыр икән! Шул партшкола бозды Сабитымны! Нигә адәм балалары бер дә уңай якка үзгәрми дип йөрсәм, ул гыйлемлекнең кире якка бора торган хасияте көчлерәк икән!»

Иренең аяусыз коллыгына төшкән мизгелләрдә курка-курка гына әнә шулай зарланды Сөмбелә. Икенче бәбәйләре кыз булды. «Син ник бу дөньяга кыз китердең? Дөнья алардан ни файда күргән? Анабыз Хава ахмаклыгы аркасында без оҗмахтан куылган!»

Аның мондый өйрәтүләренә исе китми башлаган Сөмбелә иренең кайбер фикерләренә һаман шакката иде. «Әүвәлдә «кара халык — кара сарык» дигәннәр. Халыкның карасын сарыкка әйләндерү читенме? Тфү! И все! Хәзер менә мин, Сабит Нургалиев, «ак халык — кара сарык!» дип игълан итәм. Халык — тоташтан сарык көтүе ул, аның агартылган, белем алганы да «кара сарык». «Бусы да Маркстан отып алган фикерме?» — диде аптыраган Сөмбелә. Ире, гадәтенчә, аны мыскыллап, өстән аска карады. «Маркс тарихның бүгенге көннәрен күз алдына да китерә алмаган. Идеалист, наив, беркатлы булган ул. Мәсәлән, кем уйлаган Маркс-Ленин акылы белән туган дәүләтләр кызыл әләм болгап бер-берсенә каршы сугышка чыгыр дип? Бармы андый шик Маркста? Маркс түгел, Ленин да андый каршылыкларны күз алдына куя алмаган. Ал социалистик илләрне! Югославлар Ленинны үзенчә укый, ә албаннар үзләренчә тукый! Кытай белән Вьетнам кан коеп сугыша: ике гаскәрнең дә кулында кызыл әләм! Чехлар бер якка карый, мадьярлар — бөтенләй икенче якка. Чыгарып кара немецлардан безнең армияне, кая карап чукыныр лар икән! Дөньяда буталыш, тәгълиматлар очып-очып төшәләр. Иртәгә кем тәгълиматы өстен чыгасын, ни буласын чамалап кына әйтә алучы да юк. Шундый чакта бер төркемгә тупланган асыл ирләр сарыкларның агы, карасы өстеннән идарә итеп оҗмахка чыккан икән, минем урыным кайда булырга тиеш? Яшәп калыйк әле! Яшәп! Әйе, халыкны агартырга кирәк. Ак халык та Ленинга табынсын. Маркс-сакалбайны пигамбәр дип санасын. Һәр тәгълимат — иртәнге куе томан, томанда нәрсәләрнең шәкеле үзгәрә, төз агач та кәкрегә әверелә. Әнә шул томан таралмасын дип телә! Бичара син, надан!»

«Бичара, надан, аңгыра, томана» — Сөмбеләнең иреннән ишеткән сүзләре гел шул булды. «Бала бага белмисең, чөнки син надан, томана!» — дип, ул балаларны Эзигә илтеп ташлады. «Татарча белү абзар артына барырга гына ярый, урысча өйрәнсеннәр!», «Аш-суыңның рәте-тәме юк!» — дип, ул йорт карауны толымын көнгә биш сүтеп, биш үрә торган, кияүгә чыкмаган юха Бәдәргә тапшырды.

Ир хатынының мәшәкате кырыкка төрләнгән. Гаиләдә беренче булып таңнан ул сикереп тора, көн туса утыз-кырык чакрым җир үтеп, кулы аша тонна-тонна авырлык үткәрә, кичне каршылый һәм, өй эшләрен йомгаклап, иң соңгы кеше булып караватка ава. Ләкин хатын-кыз үзенә язган мәшәкатьләр гадел булганда җиңел үткәрә, арса да зарланмый, ирен бага, бала-чагаларын сөенә-сөенә карый. Әле

төп эшенә барырга да өлгерә, һәм көннәрдән бер көнне шушы рәхәт мәшәкатьләр Сөмбелә кулыннан китте.

«Үтүкләнгән кереңнән селте исе килә», — диде Сабит. Пешергән коймагын «Төерле!» дип юынтык су чиләгенә илтеп аударды. «Син мине агуларга телисең!» — дип җикеренеп, аш-су тирәсенә яңадан җибәрмәде. Больницасыннан чыгарырга да омтылды, ләкин бу юлы Сөмбеләне җиңә алмады.

Эш табалмаган хатын биләмгә чыга, өй серләрен читкә чәчә, ирен көн саен таптый-таптый күмә. Сөмбелә андыйлардан түгел иде: түзде, чыдады, дәрәҗәсе һаман диярлек үсә барган ирен жәлләде, балаларның әтисен кызганды. «Әзрәк сабырланмасмы, җайга төшмәсме?» дип, кич-иртәләрен Тәңрегә ялварды. Сабиты Казанга киткәнне көтеп алып, авылда мулла вазифасын башкаручы аксак Гыйльметдин абзыйны чакырып, Коръән укытты. «Ни теләкләрең бар, килен?» — диде Гыйльметдин ахырда. «Сабитымның гомере озын булсын, аны әдәп-тәүфыйк ташламасын»,— диде күзен качырып Сөмбелә. Изге Коръән аятьләре дә ипкә китерә алмады Сабитны. Инде балаларыннан да коры калгач, Сөмбелә биреште, ике бите ике карындык булып саргайды, кигән күлмәкләре чөйгә элгәндәй асылынды, күзенең нуры түгелде. Кыз чагында буш вакытында мандолина чиртә иде, ул сердәшен дә чормага менгереп ыргытты, бердәнбер юанычы китаплар һәм әнә шул почмактан почмакка өч адымлы аулак бүлмәсе калды. Килгән-киткән кешегә булыр дип эшләткән иде аны Сабит, Сөмбелә бәхетсезлегенә булган икән. Хәл эчендәге авырулар барында больницада, врач бүлмәсендә кунарга калгалады, Сабит монысын катгый тыйды, өзмәс шалтыратып хатынына тынгы бирмәде.

Хатын-кыз ни чарадан бичара иренең азгынлыгына күнегә, ияләшә, йөрәк маен сыза-сыза, күз яшенә манчылып, кара кайгыга сабышса да түзә. Аны өмет яшәтә. Күшеккән җанын өмет җылыта. Кайгысын өмет җиңеләйтә. «Менә балалар исәйсен, ныгысын, акылга утырсын... Алар, мөгаен, Саратовка партшколага тап булмаслар, Маркс-Энгельсларны укып һаваланмаслар, гади, татарча әдәп-тәртипкә өйрәнерләр. Дөнья танырлык күзләре ачылгач, Сөмбелә гомер юлында татыганнарын аларга сөйләр, күңелен бушатыр, газаплардан котылыр. Яши-яши, бәлки, Сабит та тәүбәгә килер!»

Авыл арасында «брач апаның» ничек яшәгәнен, ниләр кичергәнен беләләр идеме, юкмы — аны Сөмбеләгә килеп әйткән кеше табылмады. Ул үзе аксак Гыйльметдин белән очрашканда кызарынып, күзен аска яшерә торган булып китте, биргән сәламенә җавап көтеп тормады. Зирәк карт, Сөмбелә үтеп киткәч, борылып карый да тирән итеп көрсенә иде.

Балалары хакына түзде Сөмбелә, «әгәр алар әтиләре белән генә калсалар, канечкеч ерткыч-җанварларга әйләнерләр» дип курыкты. Халыкның агы да, карасы да кара сарык көтүенә әверелә барганны Сөмбелә куркынып, коты очып күзәтә иде...

«Казаннан хатыны белән энекәш кайтып төшкән, ярты көнгә генә аларны чакырып алмый булмас»,— дигәч, Сөмбелә югалып калды. Ул хәзер нишләргә тиеш? Кунаклар алдында ире аңа нинди урын бирә? Түрнеме, ишек катынмы? Әгәр Сабит, Сөмбелә бөгелеп-сыгылып кунак каршылар, дип көтә икән, анысы булмас! Өйдә нинди тәртип яшәсә, энекәше түгел, чурт килсә дә, шул тәртип калыр. Аш-суны Бәдәр әзерләсен, кунаклар җаеннан да ул торсын, бер самовар чәй куеп та эчертәчәк түгел Сөмбелә чакырылмаган кунакларга!

Бүлмәсенә кереп утыргач, уена бүтәнчәрәк фикерләр килде. «Әгәр дә мәгәр,— диде ул,— бертуган энесенең кайтуыннан файдаланып, өебез эчендәге шомлы хәлләрне, Сабитның явызлыгын, кансызлыгын, азганлыгын, хатынын терелә́й ләхеткә тыгуын түкми-чәчми ачып салсам?.. Ялган-яла катыштырмыйча бары тик дөресен генә сөйләп бирсәм?! Кемдер белергә, мин исән чакта белеп калырга тиештер ич аны?! Ичмасам, бертуган энесе белән аның хатыны дөнья йөзендәге биш миллиард кеше арасыннан Сабит Йосыф улы Нургалиевнең тамырын, үзәген белеп торсыннар! Аның сәяси карашлары белән танышсыннар, иманын ачыкласыннар. Сабит Нургалиев фәрештә булып яшәмәс моннан болай! Хак Тәгалә күрәдер, сул иңендәге фәрештәләр, алмаш-тилмәш өч сменалап эшләсәләр дә, ул кылган гөнаһларны теркәргә пергамент җиткезә алмыйча интегәләрдер. «Языклары өчен адәм угыллары дөньялыкта да җавап бирергә тиеш» дигән акыл бар микән Маркс томнарында?! Саратовта әзрәк шул сүзләрне дә укытмадылар микәнни? Дөньяны бутап бетергән, юл башына һәрчак канечкеч тиран менеп утырырлык сукмак, мөмкинлекләр калдырган, илләрне илләргә өстерүгә корылган бу марксистик-ленинчыл тәгълиматта кешелек сыйфатлары, шәфкать, мәрхәмәт дигән заруриятлар бер дә юктыр шул! Миллионлаган ахмаклар шуңа таянып, егерменче гасыр дәвамында миллионлаган адәмнәрнең башын кыймаслар иде югыйсә!»

Шулай уйлады Сөмбелә. Уй-фикерләренең дөреслегенә ышанып ук бетмәсә дә, шулай фикер йөртте. Ул кунакларны капка төбенә чыгып каршылады. Каенэнесе белән килендәшенең кемнәр булуын үз күзе белән күрәсе килде. Юк, Сабит кисәткәнчә хәтәр кешеләр түгел иде кунаклар, икесе дә басынкы, тыйнак, барыннан да бигрәк үзара тату, дус күренделәр. Моңарчы алар бусагасын таптаган һавалы, тәкәббер кешеләрдән нык аерылалар иде болар. Игътибарлы кешеләр, табын янына бер вакытта утырдылар, бергә калкындылар, балалары да тәртипле икән, аш тирәсендә әрсезләнмәделәр, әниләренең күзенә багып кына ашадылар.

Өс-башлары уртача, алып килгән бүләкләре арзанлы, әмма зәвыклы иде. Зонтик әйбәт бүләк, аннан бигрәк Әлфия Авзалова җырлары Сөмбеләгә көтелмәгән бүләк иде. Ул җырлар табасын күкрәгенә куеп торды да тиз үк уйната да башлады.

Бу кунаклар белән мөнәсәбәтләр үзгә иде, аларның ят-ябага шомарткан бусагасы аша туганнары, кан кардәшләре кергән иде бүген. Сөмбелә гадәтләрне үзгәртте, аш-суны да Бәдәр түгел, бүген Сөмбелә үзе чыгарды. Кичке аш күңелле үтте, табынга эчемлек кунмады, татарча, бер-берсенең күңелен табып, җай гына әңгәмә куертып чәйләделәр. Иртәнге чәй алай була алмады. Сабит кырыс иде, кара бүкәй, ашыкты, кабаланды, чәен ашъяулыкка түкте. Сөмбелә дә тиз-тиз юкка чыкты, кунакларның олысы гына түгел, кечеләр дә борлыгып калдылар, «бабайларга кайтыйк!» дип дауладылар.

Сабитның көн уртасында кайтканын, кунакларны дөбердәтеп, ашыктырып кая алып киткәнен Сөмбелә ишетеп утырды. Мисыр күгәрченe кебек гөрләп, Бәдәр балаларны янбакчага алып чыкты, һаман бер сүзне туглады. «Монда керпе оялый торган иде, кая китте икән ул? Әллә быел ояламаганмы мәхлук? Әйдәгез, балалар, эзлик». Ары бара — шул ук сүз, бире бара — телендә һаман керпе! Фу, бу нинди бетмәгән керпе инде?

Сөмбеләнең хәтеренә төште: институтта укып йөргәндә берзаман автобуста кайтып килә иде. Кич. Аннан артта теле яңа ачылырга маташкан уллары белән ата-ана утырганнар. Татарлар. Бала әтидә. Ир нык ук төшергән, ахрысы, теленең тотанагы юк, улына дәрес бирә, тормыш белән таныштыра. «Әнә, улым, күр, олы имиле булса, марҗа була инде ул... Улым, күреп кал, әнә берсе йөгерә!» Әти кеше урамнан марҗаларны өзмәс эзләп таба, эни кеше дәшми. Хәер, исерек ир янында хатынның дәшмәве отышлырак түгелмени? «Бүтән сүзең юкмы әллә ир аламасы?!» — дип ачуланып кайткан иде шул чакта Сөмбелә.

Хәзер әнә Бәдәр, саескан, һаман бер сүзне тәкрарлый... Тукта! Иренә чыккан ачуын Бәдәрдән алып маташамы Сөмбелә? Беткә ачу итеп тунны утка яга!.. Нигә бу малай актыклары «бабайларга кайтыйк» дип үкерәләр?

Ул бүлмәсеннән чыкты, төрледән-төрле назлы сүзләр әйтеп, малайларны дәртсендереп аш өенә алып керде, өстәл янына кара-каршы утыртты һәм бик юка телемнәргә турап бәрәңге куырырга куйды, җәһәт кенә төче коймак изде. Малайларга коймак та, майлы бәрәңге телемнәре дә, Сөмбелә апаларының җылы карашы, татлы теле дә ифрат ошады, алар, әвен сугып кайткан егетләрдәй, ризыкларны сыпырып куйдылар. Сөмбелә кат-кат сорады: «Тәмлеме? Төерле түгелме? Агу тәме килмиме? Әче түгелме? Йомшакмы?»

Авыз тулы коймак, чәйнәгән саен тәмләнә, малайлар Сөмбелә апаларына күз уйнатып кына җавап бирделәр, аның мазасын аңлап бетермәделәр. Кереп, ишек катында нидер мыгырдап басып торган Бәдәр, чәч толымнарын җилфердәтеп, йомылып кына чыгып тайды...

Коймакка ялгап чәй эчәргә тотынганнар иде, капка төбенә машина килеп туктады. Сөмбелә куркынып тәрәзәгә ябырылды. Капка ачылды, озак та үтмәде, аш өенә тыны-өне бетеп Наилә килеп керде. Сөмбеләнең бу хәлдә акылы җитмәде, «ничек алай бик тиз кайтасы иткән?!» дип эченнән кабатлый-кабатлый, килендәшенә текәп карады. Теле: «Ник бәйрәмне ташлап кайттың?» — дип сорады. «Сезне алырга, сине, балаларны!» — диде Наилә, авызын учы белән каплаштырып. Коньяк исен килендәшенә бер дә белдертәсе килми иде аның. «Мине алыргамы? Балаларны?» — «Әйе, сине алырга. Күңелле икән анда! Рәхәтләнеп ирек ачып, йөреп кайтыйк. — Сөмбеләнең икеләнеп, ышанмыйча торуын күргәч, Наилә ашыктырды: — Көттермик! Сабит абый «Җәһәт килеп җитегез!» дип кычкырып калды!»

Ни булган Сабитка? Тагын алыштырганнармы? Бу юлы сабакны кем бирде икән? Энесеме? Оҗмах аланына ничә ел рәттән кунак ташып, бер тапкыр да хатынын чакырганы юк иде. Туганы белән күрешкәч, әз генә күңел бозы эреп киттеме әллә?! «Ярабби, Тәңрем! Шулай булсын кана! Языклы бәндәләреңнең күңеленә дә шәфкать чаткысы, миһербанлык иңдер!» — дип кабатлады Сөмбеләнең шиңгән чәчкә төсле иреннәре. Малайлар әниләренең кочагына атылдылар.

**25**

Тимер юллар министры уттан котылса да, алар утырган затлы вагон сасы көлгә, кәкрәеп беткән тимер-томырга әйләнгән иде. Янгынның сәбәбен, нәтиҗәсен тикшерер өчен Мәскәүдән өч кешелек комиссия килеп төште. Казаннан да берәү өстәлгәч, бу гадәттән тыш төркем дүрт почмаклы булды һәм хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевичны хафага салды. Мондый төр комиссия белән эш йөрткәннәре юк иде әле аларның! Тикшерүчеләр саны арткан саен эш зурга китә, аларның күңелен табу кыйммәткәрәк төшә бара иде. Җирле кешенең комиссия составына керүе дә хәвефле, мәскәүлеләр «печән хакын» белә, алар түтәленә күпме сипсәң дә сеңәчәк вә онытылачак.

Бу өлкәдәге эшләрнең бүтән тармакларыннан да салкын җилләр искәләде. Тимерьюлчылар, ваемсызланып, рәттән өч квартал планын үтәмәделәр, пассажирлардан шикаятьләр арта торды, үзәк

газеталарның берсендә Басыйр Бариевичның хуҗалыгын аркылыга-буйга теткән мәкалә басылып чыкты. Газета корреспондентын кабул итеп, эш белән таныштырып йөргән Исламнурга хуҗасыннан шактый авыр шелтә эләкте. Исламнур акланырга теләп болай диде: «Заман борылыш ясый, Басыйр Бариевич, кайбер кешеләрне аңлап булмый! Килде корреспондент, Зимин урамындагы иң затлы кунакханәгә, футбол кыры хәтле люкска урнаштырдык. Аш ташырга, кәефен күзәтергә иң гүзәл официанткабыз Оляны куйдык. Озатканда сумкасына ысланган чехонь, симез-симез сазаннарны үзем тутырдым. Рәхмәт әйтәсе урында, күрдегез, ниләр казып чыгарган. Заман үзгәрә дип беләм».

Акылга һич сыймый торган шөбһәле уйлар Басыйр Бариевичның үзенә дә килгәли иде. Тикшерергә бу юлы килүчеләр дә бил бирмәстәй маташалар! Биргән бүләкләрне чырай сытып кына алалар! Соң, паровоз бүләк итә алмый ич инде ул аларга! Ярамаганмы затлы бүрек, тун ише нәрсәләр? Ә берсе, ә берсе... «Эшне Иван Ивановичка визит ясаудан башлыйбыздыр?» — дигәч, «Соңыннан, соңыннан!» — дип карышып катты. Хатынына бушлай путевка тоттыргач та йомшамады. Аңла син замана кешеләрен!

Җыелышларда, пленумнарда, хәтта бюроларда да гел макталып килгән Басыйр Бариевичның эче китә башлады. Хурлык, адәм көлкесе, билләһи! Иван Иванович белән очрашып «хәлне бераз төзәтер идең», ул үзе сырхау, кан басымы уйный, әле аска төшә, әле сикерә. Берәр атна ятып торырга, җаваплы эшләрдән читтәрәк булырга иде дә, кая ул — шәһәр советының сессиясе якынлаша, Мәскәү вәкилләренең соравы буенча анда тимер юлдагы җитешсезлекләр дә каралачак. Ах, бик тә вакытсыз килеп төште бу Мәскәү әрләннәре! Каян шундый кылчык бәндәләр табыла диген! Ходаем, кил, кара, тикшер — тап! Чокчып чыгар баскычның түбәнге аратасына кунган бер мәхлукның ялгыш-хаталарын! Һәйбәтләп шелтә белдерербез, бүтәннәргә сабак булсын өчен бүтән эшкә күчерербез, акчасын әз алганы өчен хатыны сыртын каезласын тегенең! Юк бит, туймыйлар ачарбаклар, югарыга үреләләр! Кемгә диген әле!.. Басыйр Бариевичка! Хөрмәтле Иван Ивановичның ахирәт дустына! Җиде орденлы җәмәгать эшлеклесенә! Ходавәндә, чокчынырга керешсәң, хан кызында да кечтек кенә гаеп табыла, диләр түгелме?

Ашыгыч чараларын күрергә, судан коры чыгарга, утка салсалар да янмаска кирәк. Судан коры чыгаручы, яман уттан йолып алучы бер нәрсә бар — акча! Иван Иванович алдына барып тезләнергә дә өч бүлмәле берәр квартир алырга. Ионыч кулына андый мал төшсә, нишләтергә белер! Кертсен Урта Азия, Кавказ ягы базарчыларын! Алар... акчаны суга! «Волга» машинасына, күз дә йоммыйча, кырык меңне чыгарып салалар икән. Әллә тимерьюлчылар фондына кайткан ике-өч машинаны шуларга бөдәргәме?.. Ник үзгәрде бу мәскәүлеләр?! Бөтенләй кәефне бозалар, кара йөзләр... Мондый стратегик мөһим мәсьәләләр, әлбәттә, кабинетларда хәл ителми, мондый җитди мәсьәләне аулакта, кеше күзеннән читтә үткәрергә мөмкин. Иван Ивановичның да Басыйр Бариевичта тәжел йомышы бар иде: соңгы вакытта ил буенча яңа бер дулкын кузгалды — кешеләр дәүләттән җир алалар да дача җиткереп керәләр. Дөрес, әлегә Иван Ивановичның да, Басыйр Бариевичның да ул җәһәттән зар-моңнары юк, теләгән чакларында югары катлау вәкилләренә аталган затлы дачаларга, Боровое Матюшино тирәсенә баралар да төшәләр. Тимер капкалар ачыла, караучылар үрә катып честь бирәләр: «Ләббәйкә, Иван Иванович!», «Рәхим итегез, Басыйр Бариевич!» Аяк табаның кычытса, әйдә, Кырымга кит, Кавказ тауларына мен, нарзан ванналарында кайна. Өлгер секретарьлар, ярдәмчеләр, урынбасарлар әмереңне көтеп кенә тора, путевканы күз ачып йомганчы китереп җиткерәләр. Шулаен шулай да, ярый ла эшең китсә гел уңайга! Әнә бит, күз алдында дөнья кайный! Үзәк газетаның өтек бер хәбәрчесе шәһре Казанның гына түгел, Татарстан җөмһүриятенең алтын баганаларына кизәнә. Иртәгә кизәнеп кенә калмас, муеныңны кыеп төшерергә дә чирканмас! Балта бүгенгә алар кулында, иртәгә йә берсекөнгә аның кулдан ычкынуы ихтимал. Кем кулына барып керә ул, балтаны кайсы якка карап селтәрләр, аны берәү дә белми. Калынкаш бабайның да сәламәтлеге начар, диләр... Имеш, дару урынына әрмән коньягын эчеп кенә тора икән...

Ике акыл — олы акыл, Иван Иванович өстәнрәк торып, Басыйр Бариевич аның авызына карап, икесе ныклы уйга килделәр: дача шаукымы дөньяга таралганчы, эте-бете уянганчы, Иделнең гүзәл почмагында, Әнисә абыстайлардан ерак түгел бушлыкта җир алырга, җәй башыннан калдырмыйча эшкә тотынырга һәм бер ел эчендә дача йортларын салырга кирәк!

Май урталары! Иң гүзәл айларның берсе! Юкка гына алма, чия агачлары шушы айда чәчәк атмый! Тургайлар шашына, күке егетләре тыела алмыйча кычкырып күке кызларын эзлиләр, меңнәрчә сайрар кошлар, барлыкларын белдереп, төрле тавышларга чыркылдашалар, оя тибәләр, бер-берсен эзләп табалар, бала чыгарырга утыралар. Мондый вакытта кавышкан Иван Иванович белән Басыйр Бариевичның тантанасының тажы инде мунча түгел. Дөрес, мунча керәләр алар, чәркәләр дә бушап тормый, әмма бүген максат бүтән!.. Тимер юл белән Әнисә абыстайның каз кәтүлекләрен аерып торган ямь-яшел урман кырындагы коры, тар сукмактан арлы-бирле йөрергә яраталар алар. Алдан ике җилпуч кулын Везувий вулканы хәтле корсагы өстендә ял иттереп, вәкарь белән тамак кыргалап, Иван Иванович атлый. Аның артыннан арба күчәреннән төшеп калган чәкүшкә Басыйр Бариевич теркелди. Теркелди Басыйр Бариевич, үзеннән алда җиле бара. Тел төбендә Иван Ивановичны мактау! Урысны мактап кына балта сабына ия булырга мөмкин икәнен татарларга моннан күп гасырлар элек Иван

патша сеңдергән. Татарның бер гореф-гадәтен дә белмәгән Басыйр Бариевичлар каян шулкадәр нык үзләштергәннәр аны? Бара Басыйр Бариевич, елан угы төсле теленнән бал тама... «Бездә, татарда, дим, хөрмәтле Иван Иванович...— Шулай башлый да Басыйр Бариевич, сагаеп: — Хәер, минем татарлыгым да инде!.. Ә мин малайларны рус дип яздырдым, әйе, рус дип!» — «Син нидер бүтән сүз башлаган идең», — дип гөрселди Иван Иванович. «Ә, исемдә, исемдә. Имән кебек ирләр, диләр... Әллә сезнең кыяфәтне, сезнең мәгърур гәүдәне күреп шулай әйткәннәрме дип уйлыйм... Хак! Имән дә имән, сез дә имән!» Иван Иванович чак кына адымнарын акрынайта, әкренрәк баса, аның Басыйр Бариевичның һәр сүзен ишетеп каласы килә. Янына ук кысылыр иде Басыйр Бариевич, нәләт суккан сукмак тар, тавышын көрәйтер иде — чыкмый, кычкырса, саескан сыман чәтерди башлый. Ул бик озаклап тимер юл буйларына утырткан агачлар хакында белешмәләр бирә, кемнәрнеңдер чүп агач — Америка өрәңгесе утыртып, хәзер шул агачның азынып, урманнарга үтеп керә башлавын каһәрли (Мәскәүдән килгән корреспондент шәхси әңгәмәдә әйткән сүзләр!). «Ә без, күрәсезме, юл тирәләрен тутырып имән утырттык. Имәннән үзебезгә үзебез һәйкәл салдык, хөрмәтле Иван Иванович! Алдагы буыннар безне гел мактап искә алсыннар. Шулай түгелмени?»

Бу әңгәмә ахирәтләрнең исендә калып, алар еш-еш юл буе имәннәрен, үзләренә тиң агачларны хәтергә төшерәләр иде. Инде шушы тирәдә җир алып куйсалар, имәннәргә карап, горурланып яшәячәкләр бит! Хак! Иван Иванович имән хакында сүз чыкканда Басыйр Бариевичның күңелен бераз кырды, инде онытылып беткән татарлык хисләренә кагылды... «Руста да бар андыйрак атама,— дип җупләде Иван Иванович,— элеккеге заманда, рус гаскәрләре татарларны кырган чакта, гаскәрләрне «дубы — могучие великаны» дип йөрткәннәр».

Бүгенге май кичендә мунча искиткеч шәп буласы иде, Мәскәүдән килгән корреспондент белән чатак чыккач, үз-үзен битәрләп йөргән Исламнур бүген үзен күрсәтеп, яхшы атын кире кайтарырга тиеш иде. Акча, җир мәсьәләләре хәл кылынып, алдагы көнгә матур планнар сызылачак иде... Үткәнендә Басыйр Бариевич Иван Ивановичны «имән» дип мактаганда, үз адресына дан сүзе чыкмагач, чак кына рәнҗеп тә йөри иде. Яшермик, Иван Иванович та, Басыйр Бариевичны берәр затлы агач белән тиңләргә теләп, аңа борылып-борылып карады. Фантазиясе бай түгел шул, чагыштыру таба алмады. Басыйр Бариевич үзе дә... Иван Ивановичка якынаям дип, сукмактан читкә, әрекмән арасына кергән... Юк, Басыйр Бариевичны бик яратса да, мактарлык сүз тапмады ул чакны Иван Иванович. Ә бүгенге очрашуда аны тамырлары тирән киткән агач белән тиңләргә әзерләнде...

Бүгенге очрашу мәҗлесе гаҗәеп шәп, нәтиҗәле һәм бәрәкәтле булырга тиеш иде.

Эңгер-меңгер тәмам куерып, әтәч белән тавыклар куначаларга менгән мәлдә, тимер юл белән параллель барган таш юлдан Әнисәләр ихатасына таба бер-бер артлы ике машина борылды. Кыр буш, кыр өстендәге һава хуш исләр белән генә тыгызлап тутырылган иде. Ләкин хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич берни күрмәделәр, ис тә сизмәделәр, алар, берсе ишелеп, берсе очып, машиналарыннан төштеләр. «Нәрсә бу?» — диде Иван Иванович, Американың явыз полицияләре йөртә торган күсәк юанлыгы бармагы белән кыр өстенә күрсәтеп. «Белмим»,— диде куркудан ыңгырчак биеклеге генә калган Басыйр Бариевич. Әнисә абыстайның көтүлекләре шакмакларга бүленгән һәм шакмак читләрендә лилипут гаскәрләре булып ап-ак, өр-яңа чөйләр җемелди иде. «Бала-чага уйнаган дисәң»... Басыйр Бариевичның авызы ачылды да ябылды. «Нинди бала-чага?! — дип күк күкрәтте Иван Иванович.— Ызаннар тигез, чөйләр күп, имәнлектән авылга кадәр иңләгәннәр! Дачалар! Дачалар! Җирне бүлгәннәр! Кайсы явызы безнең өлешкә кергән?!» — «Булмас,— диде акланырга бик теләп Басыйр Бариевич.— Сез шәһәр башлыгы, сездән башка ерып керергә кем җөрьәт иткән?»

Сүзен эш белән беркетергә яраткан Басыйр Бариевич, туфлиләренә туфрак тулуына карамастан, кыр өстенә кереп китте һәм «мисле Чыңгыз гаскәре» кебек тезелгән агач чөйләрне батырларча йолкып ыргытырга тотынды. «Бу бәладән чөй чыгарып кына котылып булмас,— диде шунда ук эшлекле кыяфәткә кергән Иван Иванович.— Бу зур мәсьәлә! Кемдер безнең юлга агач аударган дигән сүз. Кем?!» — «Кем генә булмасын, чарасын күрергә! Танавын канга батырырга кирәк аның!» — дип чырылдады саескан Басыйр Бариевич. «Канатырбыз да, кирәк икән, төрмәгә тыгарбыз! Илдән кудырырбыз!» — дип җитди йомгак ясады Иван Иванович.

Ике дус ай нурына чумган кыр өстендә кылыч уйнаттылар, йодрыклар йомарланды, үкчәләр җирне төйде, тигез рәтләр булып шым утырган агач чөйләр дер-дер калтыранды. Мондый хәлдә мунчаның тәме буламы? Ризыкның ләззәте каламы? Хөрмәтле Иван Иванович белән хөрмәтле Басыйр Бариевич ашык-пошык чабындылар, коньякны кырлы стакан белән голт-голт эчтеләр. Коньякны, унбиш ел буена таш мәгарәдә өлгереп яткан затлы эчемлекне, кырлы стакан белән?! Бусы Исламнурның акылына сыймады, ул өнсез калды, аны очкылык тотты, ямьсез очкылык тавышына куначаның иң биегенә менеп йокымсыраган әтәч җиргә егылып төште. Айлы төндә кара болыттай каралган кунакларны машиналар шым гына алып киттеләр. Иван Иванович кайтып керүгә телефонга ябышты, көтеп зарыккан хәләлен шик-шөбһәгә төшерде: мунчадан соң һәрчак ул хатынын куенына ала торган иде. Әллә чит итәк янынннан кайтканмы бүген ире?! Хатын төнката йокламады.

Леонид Брежневның югары сыйныфларга үтә мәхәббәтле күренгән, түбән катлау вәкилләре арасында меңнәрчә анекдотка сәбәп булган калын кашлары янынннан үткәндә, машина, өйрәтелгән гадәте буенча, йөрешен әкренәйтте. Ул ара да булмады — рәсем-җилкән каршындагы капка ачылды, аннан, «ур-ра!» кычкырып, эреле-ваклы җиде малай атылып чыкты. Әхмәтзыя, уңайсызланып һәм бераз горурланып, Наиләгә баш какты: «Минем ташбашлар!» — «Әйдәгез, аларны да аппарабыз!» — диде Наилә кинәт. Сөмбелә эндәшмәде, Әхмәтзыя аяк терәп каршы килде. Наилә сүзен сүз итте, малайлар машинага кереп тулдылар. Тугыз малай бергә килгәндә тынычлык каламы? Китте үчекләшү, танышу, урын өчен кычкырышу, чыр-чу... «Бу машина этинеке!» — дип мактанды малайларның берсе. Искәндәр уйлап-уйлап торды да: «Ә минем эти атом бомбасы ясый!» — диде. Авыл малайлары тактиканы шундук үзгәрттеләр, Искәндәргә ярарга тырыштылар. «Безгә бер бәләкәйрәкне ясап бирсен инде, ә?» — дип ялындылар. Машина урманга якынлашты.

* * *

Нәҗипнең күптәннән болай үлеп йоклаганы юк иде; ниһаять, уянды, чак кына айнып исенә килсә... Ул шыр ялангач килеш күл ярындагы юан чыршыга ябышып тора, чалбар балакларын, җиңнәрен сызганган әрмән егетләре сыңарышар чиләк тотканнар да, күлдән су чумырып алып, алмаш-тилмәш аның өстенә коялар иде. Шактыйдан маташалар, ахрысы, Нәҗипнең аяк астында күлләвек ясалган, ярга якын су болганган, җир җебегән. Ә тәне күгәрчен тәпиедәй күгәргән иде.

Ул иң әүвәл әрмәннәрнең нәфрәт тулы күмер күзләрен күрде. Исерекбаш татарга алар шундый җирәнү, кимсетү белән карыйлар иде ки, бу суык караш сап-салкын судан ныграк тәэсир итте, ул дер-дер калтырап, күзен уып: «Җитәр, егетләр»,— диде. Әрмәннәр, чиләкләрен атып бәреп, икесе ике якка киттеләр, берсе учакны тергезергә тотынды, икенчесе табынны калдык-постыклардан чистарта башлады.

Чиләкләрнең берсе Нәҗип аяк очыннан тәгәрәп күлгә барып төште. Ул иелеп чиләкне алам дигәндә, сынын тота алмады, чулт итеп күлгә капланды. Егетләрнең берсе, йөгереп килеп, быкырдап яткан Нәҗипкә кулын бирде. Җебегән тавык, күшеккән күркә, диләр. Нәҗип нәкъ шул хәлдә иде хәзер. Кабаклары салынган, чит-читләре шешенгән күз ярыклары әз-мәз ачылгач, ул урман юлыннан тиз-тиз монда таба атлап килүче Сабитны күрде. Ул кулындагы ботаклы таяк белән юлындагы куакларны аяусыз кыйный иде. Нәҗип як-якка карангалап ыштанын эзләде, бәхете, тиз тапты. Сабит кулындагы таякның кайсы төшне яратканын ул балачактан ук бик яхшы белә иде. Яра иде аны Сабит малай чагында, икеле алса да кайтып тукмый иде, кызларның берәрсе кырын караса да, Нәҗипне җәзалый иде. Суык мунча миченә энекәшен башы белән тыгып торганы да бар иде явызның...

Сабит бу төбәктә власть иде. Тирә-якны дерелдәтеп тоткан Исмәгыйль соңгы кичтә Хәлил белән ничегрәк очрашкан булса, Сабит Исмәгыйльдән мең тапкыр артыграк котырынган иде. Мин-минлеге, Сабитлыгы изелгән иде аның. Хәзер юлында кем очраса, ул аны таптап, сытып китәчәк иде. Таудан тәгәрәп төшүче биниһая авыр таш иде ул. Власть кешесенең ачуы берчакта да үзеннән-үзе сүрелми, аны җәза, кан, җәберләү тәме аша гына төкәндереп була. Әгәр әүвәл башлап аңа әрмән егетләре очраса, ул аларны изеп ташлаячак иде.

Вәлиәхмәт вак җанвар иде, кол, билендә наганы атынса да, шөһрәтле колхоз рәисе, депутат, бюро, пленум әгъзасы булган атаклы ир алдында ул көя күбәләге, вак черки иде. Хәзер Сабит-сунарчыга эре җәнлек кирәк, кыр тавыгы, көртлек каны гына аның ачуын юып ала торган түгел, әгәр юлында бүре очраса, ике дә уйлап тормастан аңа ташланачак Сабит, юлбарыс читлегенә коры кулдан барып керәчәк.

Юеш тәненә трусигын кия алмыйча азапланган энекәшен күз карашы аша үткәргәч, ул, йодрыкларын йомарлап, нигәдер янтая төшеп, аңа якынлашты. Сугарга күтәрелгән кул һавада калды. Нәҗип күрелмәгән җитезлек белән тайпылып өлгерде. Туганнарның күз карашлары кисештеләр, корыч чыңлаган тавыш чыкты, һавада яшеннән соң була торган ис таралды. «Син, йолкыш! — диде Сабит, авыр тавыш белән. — Урам себерүче! Түш киереп, оборонныйда эшлим дип йөрисең, бозау! Син бит гап-гади җүләр баш».

Нәҗип тә Йосыф Нургалиев малае, анда да власть уянды, теләгенә ирешә алмаса да, анда да шул властька омтылыш бар иде ич. Әнә шул Нәҗип, Наилә яраткан, омтылышлы, кырыс Нәҗип уянды Сабит бәхете өчен казыткан көмеш күл янында. «Йолкыш булсам да, мин ирекле җан. Ә син Брежнев һәм аның яраннарының колы. Безнең илдә Брежнев кебек җүләр юлбашчының булганы юк иде, булмас та. Ул синең эше ялагайларга таянып тора. Синең эшеләр крестьянны бөлгенлеккә төшерделәр, аны җирдән качарга мәҗбүр итте. Без — бер буйдагы читән казыклары... Дөрес, син — өстә, мин — аста. Дөньяның асты өскә килүе бар. Онытма шуны, депутат!»

Сабитның сүзе бетте. Уйлау сәләте баш миеннән йодрыгына күчте. Ул, үзен-үзе белештермичә, алагаемга киерелеп туганының ипи шүрлегенә менәм дигәндә... күзеннән утлар күренде, ул чәчрәп җиргә барып төште, бер түгел, биш әйләнде. Күзен кан басты, кан тамырларына ут ачысы кушылды. Ул читкә чәчрәгән таягын алып бер селтәнгәндә, юлда бала-чага чыркылдашкан тавышлар ишетелде. Грузчик булып йөргәндә, буш араларда шадра Вафа бокс серләрен өйрәткәләгән иде, Нәҗипкә шул ярап куйды: ул, үкчәсен җиргә терәп, астан аперкот белән җан көченә бәргән иде. Балалар тавышы аның колагына да керде, аягына баскан Сабитка тагын берне өстәргә йомылган йодрыгы язылды, күзе ныграк ачылды.

Юлда әүвәл башлап милиционер Вәлиәхмәт күренде. Ул нигәдер абына-сөртенә арты белән килә, бала-чага урап алган Наилә белән Сөмбеләгә нидер аңлатырга тырыша иде. «Сөмбеләгә монда ни калган? — дип уйлады Сабит, таягын читкә атып бәреп.— Ни кирәк аңа? Аны кем чакырган? Кайтып бөтенесен чишеп ташлаганмы әллә теге пырдымсыз зат?!» Сөмбеләнең елмаюын очраткач кына, ул Наиләнең тапкырлыгына, үткенлегенә хәйран калды, аңлады. Юк, утыз өч яшькәчә тормышын көйли алмаган Нәҗипкә әрәм мондый затлы мал! Чибәрлеге өстенә тапкырлыгы, зирәклеге дә җитәрлек икән. Карасына коелган Сөмбелә бала-чага төяп тыелган аланга менгән икән, бу инде Наиләнең көче, аның хикмәте дигән сүз. Бүтәнчә түгел.

Вәлиәхмәт, хуҗасы адаштырып калдырган эттәй, Сабитка карады. «Сабит Йосыпович! — дип җыламсырады ул. — Бу тирәгә бала-чага китерергә ярамый, дип мең кабатладым». Наилә үтә мөлаем, изгелекле тавыш белән аны бүлдерде: «Нигә ярамасын ди? Алан киң, ризык мул, вакыт иркен. Рәхәтләнеп ял итик!» — диде.

Сабит, күз карашына җылылык өстәп, аның ягына карады. «Котылдым! Коткарды бу чәчби мине!» Наилә таң йолдызы кебек балкып иренә карады: «Син йоклаган арада, мин балаларны төшеп алдым!» — диде ул, мактанган тавыш белән. «Ничек оста итеп ирен коткарды!» — дип уйлап өлгерде Сабит, сокланып.

Сөмбелә кыюланды, үзенә моңарчы сер булып килгән аланны тиз-тиз караштырып, табындагы артыкларны — буш һәм тулы шешәләрне җыеп алды, кай арада ут тергезеп, шашлык куырып өлгергән егетләр өстәлгә итле таякларны китереп өйделәр. Малайлар, аларга ияреп олылар да корсаклары кап булганчы сыйландылар.

Көн шулай, һич көтмәгәндә, берсе дә күз алдына китерә алмаганча, татулык белән үтте. Урманнан кайтышлый Сабит: «Эш тә бар ич әле дөньяда!» — диештереп төшеп калды. Алар, Наилә белән Нәҗип, Сөмбелә җитәкчелегендә кичке чәй янына җыелдылар, йөзләр яктырды, телләр ачылды. Кунаклар якты күңелле Сөмбеләгә бар булган хәсрәтләрен һич яшермичә, арттырмыйча, киметмичә сөйләп бирделәр. Сөмбелә һәр хәсрәтне үзенеке итеп тыңлады, балаларның сары йортта нинди шартларда яшәвен белгәч, кызганып ихлас яшьләрен түкте. «Малайларны җәйгә бездә калдырыгыз, июнь башында ялга чыгам, минем беркая барганым юк. Эзидән Марат белән Гөлбостан кайта, туганнар ич алар, очрашсыннар, белешсеннәр, һич иренмәм, карармын»,— дип кат-кат үтенде. Наилә белән Нәҗип ризалаша язганнар иде инде, Сабитның корылыгын, кискен холкын уйлап, бала-чаганың җайсыз якларын исәпләп, уйларыннан кире кайттылар.

Балаларны йоклаттылар, табак-савытларны җыештыргач, өч-дүрт кат рәттән Әлфия Авзалованы җырлаттылар. Нәҗип читкә борылып еш-еш иснәштерде. Ятарга вакыт булса да, Сөмбеләнең аларны тиз генә кулдан ычкындырырга исәбе юк иде шикелле. Сабит соң кайтты, ашамады, бер тустаган катык сорап алды, эчәргә ашыкмады, уртлап куйгач, кунаклардан бигрәк Сөмбеләсенә карады. «Сабит,— диде Сөмбелә, шактый көр тавыш белән,— заманы шулдыр, туганнар белән аралашу кимеде. Сине дә, үземне дә гаепләргә җыенмыйм. Ходаның рәхмәте төшеп, энекәшең кайтты, хатынын күрдек, балаларын. Мәскәүдә укыганда Нәҗип чирләп егылган икән! Чирле кешене эштә яраталармы? Мин моны врач буларак әйтәм, беләм, яратмыйлар!» Сабит тустаганын ирененә тидереп алды, катыгын йотмады. Аңа шөгыль, әңгәмәдән читкә каерылырлык бер-бер эш кирәк иде. «Фатирга чиратлары җиткән, бирмәгәннәр. Ахыр чиктә эшеннән үк чыгарганнар». Баштарак ул хатынын юньләп тыңламады, сөйләгән сүзләре аңына авырлык белән барып җитте. Әле ул Нәҗипне урам себерүче дип кенә ишеткән икән, баксаң, менә кая таба киткән эшләр!.. Көндезге вакыйганы көлкегә калу дип исәпләгән Сабитның эче яктырды: «Димәк ки, Наиләнең эшләре кәкәй?! Ир аста, нужада икән, аның хатыны да шунда барып төшкән була түгелме?» Нәҗипнең нужаруына ул, яшермик, сөенде.

Ирләре бәла-казага юлыккан, нужарган хатыннарны аерата ярата Сабит, аларга мөнәсәбәттә аның сыналган ысуллары, ышанычлы әмәлләре бар. Ирен саздан тартып торгызасың икән, хатыны синең кочагыңа керде дигән сүз. Ул, урман маҗарасын хәтерләп, тагын бер ачынып алды. Ах, бу хәлләрне анда барганчы ишеткән булса! Энесенең шундый нәзакәтле, гүзәл хатынны ипи-чәйдә, такы-токыда тотуын белсә, эшне бөтенләй кире яктан башлап җибәрер иде. Әле дә соң түгел, ул йокымсырапмы, йокыга салышыпмы утырган Нәҗипне кабинетына чакырып кертте: «Нигә син боларны элегрәк хәбәр итмәдең?» — дип ырлап ябышты. «Шуннан ни үзгәрер иде?» — диде сүрән генә Нәҗип. Ул Наиләсенең ачылып китүен дә, Сөмбеләнең сүзне шул якка алып керүен дә өнәмәгән иде. Нәҗип

саклыгын онытты, чире исенә төшеп тә карамады. Сабит болай да аны исерек чучка хәлендә күрде. Әле моннан соң да тормыш итәсе бар, Наиләнең Югары авыл юлында тел тозагыннан ычкынган сүзләре кайчан исә бер калкып чыгачак. Нәҗипнең моңарчы шундый шәп, дәрәҗәле Сабит белән аралашмавы, инде аралашам дигәндә мәлҗерәп аунап ятуы да телгә керәчәк. Нигә һаман-һаман Сабит өскә чыга соң әле?!

Нәҗип, гарьлегеннән әрнеп, ишек тоткасына ябышты. «Туктап тор,— диде Сабит.— Тотканы каерып чыгарма! — Аннары өч телефонның берсенә — зәңгәренә төртеп күрсәтте.— Казанны мин турыдан-туры җыям. Көт бераз!»

Нәҗип, тирләгән ишек тоткасын ычкындырып, тыелып калды, сөйләшмәде. Сабит сул кулы белән маңгаен кашый-кашый номер җыйды, менә аның кырыслыгын елмаю алыштырды, ул нindидер Иван Иванович белән якын туганнарча хәбәр бүлешергә тотынды. Мондый тавышы да бар икән Сабит Нургалиевнең, болай да сөйләшә ала икән ул! Ятьрәк чыгып югаласы килә Нәҗипнең. Ишек нәни генә шыгырдауга, Сабит, күзен-кашын сытып, аңа туктарга куша. Тагын тавышы үзгәрә, кенәри булып сайрый, тук песи булып мырлый, ара-тирә күркә сыман кабарынып та ала. Бүлмәне тутырып көлеп тә җибәрә! Теге якта язып алырга ниятләделәр бугай, ул иҗекләп әйтеп тора башлады. Нәҗипнең исем-фамилиясен атады, холкын мактады, «эшлекле, ышанычлы!» дип, күкләргә чөйде. Трубкасын куйгач, әле генә мактап бетергән Нәҗипкә сыңар күз салмыйча, аны бетереп, үз өстенлеген раслап, тәрәзә аша төнгә карап утырды. «Ну кыланчык!» — дип уйлады Нәҗип, абыйсын үтереп ташларга теләп.

Хатыннар янына чыксалар, алар белән нидер сөйләшеп, урындыкны ишек катынарак тартып китереп, җирән кыска чәчле, киң калын җилкәле, ныкча кыска муенлы бер кеше утыра иде. Сабит Сөмбеләгә карады, кашлары җыерылды: «Бу бәндә минем рөхсәттән башка түремә кереп утырган! Ни хәл бу? Йомышы ни?» Тегенең йомыш юллап йөрүе кыяфәтенә чыккан, иңбашлары салынган, күлмәгенең сул якасы бөкләнеп муенына кергән, галстугы бозау чәйнәгәндәй таушалган иде. Карый торгач Сабитның исенә төште: «Ба-а, бу бит, бу... Хәлиуллин! Баганадай мишәр нигә болай таушалган икән? Исеме Әхсән бит әле, әйе, Әхсән Сәхәпович бугай. Әйе, әйе, мал-туар симертү совхозын Сабит аның кулыннан алып калган иде. Рәхмәт төшкере, әллә аның да эвене янганмы?!» Күрештеләр. Сабит хәзер күтәренке, наян авазлар белән сөйләшергә керешә: «Йә-йә, Әхсән Сәхәпович, ни хәлләр?! Чәй белән сыйлыйкмы, әллә мәе дә батамы?» — «Юк, юк! — диде ике кулы белән битен каплап, артка тайчынып Хәлиуллин.— Ир башына шул шайтан сидеге җитә! Тамчысын да капмыйм. Чәйләп торырга да соң. Минем, Сабит Йосыпович, сиңа тәҗел йомышым бар. Рәхмәт, кәбәм. Әйдә, бер сүләшикче. Төнката йөрүемә рәнҗемә. Син кунак-төшемсез яшәмисең, беләм. Кичерерсең».

Сабит төсен үзгәртте, телә-теләмәс кабинетына керде, ишекне ачып торып Хәлиуллинны үткәрде, ачык ишектән Нәҗип тә аларга иярде. Хәлиуллин күзе белән урындык эзләп табып, авыр гына килеп утырды, Сабитны якыны санап, йомышын сөйләргә дә тотынды.

«Совхозда синең җылы кулыңны кысып аерылганнан соң, кәбәм, Башкортстанга барып чыктым мин. Райбашкарма рәисе итеп якташлар чакырып алган иде. Эшләдем. Бер-бер чатак чыкты димим, чыкмады. Чыгып өлгермәде! Әмма ләкин чыгу ихтималы бар иде. Әүвәлдә башкорт кем иде? Иркен дала улы иде! Баймакта яши иде ул, Урал буйларында. Хәзер башкортның яңа буыны калага тартылды. Туйды даладан башкорт баласы, аңа шәһәр кирәк, шәһәрдә җылы урын кирәк. Урын таләп итәргә хакы да бардыр... Кыскасы, аркама суык бәргәч тә уйландым мин: «Туган төягең, Татарстаның юкмы синең? Ашык, Хәлиуллин!» Гариза тапшырдым, сессиядә кычкырып укыдылар, мактап озаттылар».

«Ала-ай,— дип сузды Сабит,— котлыйм!» — «Тукта, кәбәм, кабаланма.— Хәлиуллин маңгай дымын корытканчы сөртте.— Кайттым Эзигә, кердем хуҗа янына. Тамырым монда, рөхсәт булса, үгә кайтырга исәп, димен. Харис Вагыйзович карап-карап торды да үлчәү колгасына терәп бастырды мине!» Сабит чак пырхылдамады. Нәҗип тә елмайды.

«Мәчегә көлке! — дип кычкырып җибәрде Хәлиуллин. — Нәкъ алты сантиметрга буй кыскарган. Җир тартканмы, Ходайның каргышы төшкәнме!» — «Нилектән алай булды соң?» — дип сорады Сабит, бу юлы көлүен яшермичә. «Бүксә калынаймасын дип тегендә гер чөя идем, торам да штанга күтәрәм. Янәсе, сакланам... Харис Вагыйзович мине элеватор директорының урынбасары итмә кели. Мине, овсюгны, урынбасар?.. Сыйфат тамгасы сугылган татарны урынбасар итәргәме? Юк, мәтәм, Харис Вагыйзович! Барсам, рәис булып кына барам, кәбәм. Белгән булсам әгәр, тотыныр идемме гергә? Врач киңәшен тотып, штанга күтәрәм, җитмәсә! Унар, егермешәр мәртәбә! Алты сантиметрга җиргә иңгәнмен!.. Сүләш әле, Сабит Йосыпович, хуҗа белән. Синең сүзең үтәр. Бүксә үссә үссен икән, буй бәләкәйләнмәсен, буй!» — «Мин киңәшеп карармын,— диде Сабит, эре генә.— Тик, ай-һай! Харис Вагыйзович председательләрнең, парторгларның буен квартал саен үлчәтә. Квартал саен! Нигә башка бер районга кагылып карамыйсың, Әхсән Сәхәпович? Теләсәң кайсы районга шалтыратам».— «Кәбәм,— диде җыламсырап Хәлиуллин.— Бата башлаган кешене күргәч, аркан ишәргә тотыналармы? Эзигә мин ярты гомеремне салган. Син кем җилкәсенә басып күтәрелдең? — Ул йонлач, дәү йодрыгы белән әче тузан очырып җилкәсен төйде.— Мин сиңа учетка кермәгән күпме сыер малы, таналар, симез-симез чучкалар калдырдым. Төз сының, хатын-кызларны шаштыра торган күзең өчен

калдырдыммы мин аларны?! Юк, кәбәм, дөньяның һәркемгә бер үзгәрәсен белгәнгә, егыласы җиремә салам җәеп куйдым. Хәзер син шул саламга ут җибәрмәк келисең. Әйтимме тагын бер сүз?» — «Әйт! Икене әйт!» — «Көзгә районда хуҗа булып син каласың. Шул чагында килсәм, колхозыңны миңа бирәсеңме?»

«Юк,— диде Сабит, өзеп.— Юк, Әхсән Сәхәпович, бирә алмам. Харис Вагыйзович өлкә комитетына күтәрелә. Ул китүгә мин аның тәртипләрен боза башласам, кем булам?! Ул председательләрнең буен кварталга бер үлчәтә! Ә мин ай саен үлчәргә кушачакмын! Ай саен!» Хәлиуллин тузан чәчеп ике тезенә ике йодрыгы белән китереп орды да ялт кына торды: «Бер күрүдә мин сиңа ышандым... Нигә дисеңме? Әйтәм, кәбәм. Син миннән бер көтү мал алып калып, чыраеңны да сытмадың. А-һа, бу бала ерак китәр, дидем. Синең яшьтә андый ук чаялык юк иде миндә. Күтәрелдең, ләкин бер нәрсәне истә тотмыйсың икән... Бүген мин сиңа мал калдыра алмыйм, малым юк, бүген мин сиңа шик калдырам — суын эчкәч, коега түкермә. Бата башлаган кешенең бәхете булса, су төбендә аяк басарлык түмгәк табыла аңа. Бүтән районга барырга җүләрме мин?! Анда да үз размерың, үз үлчәвең кирәк».

Сабит энесенә сүз катмады, чыгарып та җибәрмәде, — димәк, ул бу спектакльне Нәҗип өчен дә уйнап күрсәтте. Ни кисәтергә теләгәндер, нинди акыл бирергә җыенгандыр, ә Нәҗип Хәлиуллинны бик нык кызганды, шап-шоп тезен төеп, гасабиланып утырганнан соң, саубуллашмыйча да чыгып барганда аны туктатасы килде. Холкы волейбол тубы сыман бер яктан икенче якка күчеп торган Сабит телендә «ярдәм», «квартир» дигән сүзләр тирбәлгәч, Нәҗип абыйсы әллә әз-мәз ипләндеме дип җылынган иде, хәзер алданган, ымсынган үксез бала сыман нәүмизләнеп калды. «Каты күңелле син!» — диде ул абыйсына, җылы сүзләрнең әллә кайдагы Иван Иванович белән әңгәмәдә генә кулланышын уйлап. «Катымы, түгелме икәнен иртәгә унда белерсең», — диде Сабит. Нәҗип: «Унда Ходайдан фәрман иңәме?» — дип чеметеп алды. «Синең хәстәреңне кайгыртып нәкъ унда Иван Иванович шалтыратачак. Ишеттең бит, мин аннан сиңа эш эзләшүен үтендем!»

Соң иде инде, куначада беренче әтәчләр кычкырды, сүзләр кыскарды, юрган астына кергәч кенә Нәҗип Наиләгә абыйсы белән булган әңгәмәнең кыскача эчтәлеген сөйләп бирде. Сөйләмәсә яхшырак буласы икән, Наилә төне буе керфек какмады, Нәҗипне дә юньләп йоклатмады.

Алар торып чыкканда, Сабит эшенә китеп барган, Сөмбелә дә, утка баскандай кабаланып, кузгалырга җыенган иде. «Больницага пычкыга киселгән баланы китергәннәр, үз җаегыз белән чәйләгез инде», — диде ул, гафу үтенеп. Нәҗип белән Наилә иртәгә китәселәрен белдергәннәр иде, иртәгә Сабит та Казанга барасы булгач, шәт, безне үзеннән калдырмас, дип, хуҗалар белән юл, билетлар хакында сүз кузгатмадылар. Балалар уянды, чәйләделәр, журналлар актардылар, күзләре гел сәгатьтә булды. Тугыз тулды, ун, әбәт якынлашты, Сабит та, Сөмбелә дә кайтмадылар. Бәдәр аш җиткерде, ашны, итле бәрәңгене аннан-моннан капкаладылар. Нәҗип Наиләне юатырга тырышты. «Абыйның коры куык, бушбугаз икәнен сиңа аңлатырга теләгән идем, хәзер аңлатып торуның кирәге дә калмады!» — диде. Урамнан уйнап, Әхмәтзыя малайлары белән сугышып кергән малайлар: «Әйдәгез урманга, төтенле ит ашарга! Тегеләрне ияртмибез!» — дип тыкырдаттылар. Ачу килгәндә аяк астында уралган бала кәефне боза, малайларны пыркытып чыгардылар. «Икесенең берсе булмасмы дип тә уйлыйм!» — дип юрады Нәҗип. «Булмас,— дип кырт кисте Наилә.— Безнең заводта гына ике мең кеше фатир чиратында торганда каян тапсыннар ди безгә?» — «Эт оясы хәтле генә куыш булса да яшәп торыр идек торуын. Үзебезнеке булсын иде!» — дип һаман өметләнде Нәҗип. Инде чыдарлыгы калмаганда, өметләре өзелгәндә Сабит кайтып керде, урта бармагын изәп Нәҗипне кабинетка чакырды. Наилә коелып төште, Сабит ашыкмады, зур эш кыргандай стакан арты стакан «Шифалы су» эчте, кереш сүзсез-нисез энесенең тетмәсен тетәргә ябышты. «Син,— диде ул, нәфрәтенә җирәнү дә өстәп,— гомер эчендә бер кайтып авылда юк-бар лыгырдап йөргәнсең. Ихлас әйткәннәргә ышанмаган идем. Баксаң, диссидент икәнсең син, тиле-миле Сахаровлар сыңары! Хыянәтче! Сатлык Синявский, Даниэллар белән бер җырны җырлыйсың икән. Җәбрәйләргә сатылдыңмы? Бик теләсәң, мин сине Щаранский янына Чистай төрмәсенә илтеп тыгам! Эш тә табылыр, квартирлы да булырсың! Менә нигә алмыйлар икән сине эшкә! Телең авызыңа сыймаганга куганнар ич сине заводтан! Татарда диссидент юк, без басынкы халык дип йөрсәм, бар икән ул юньсезләр, бар! Кем диген әле! Юньләп тормыш кора белмә, властьны сүгәргә тотын! Вәт тинтәк!»

«Ялган!» — дип кычкырасы килде Нәҗипнең, теле көрмәлде. Каян бер төн эчендә Иван Иванович дигәннәре Нәҗипнең кара тамгасын белеп өлгергән диген! Хәер, Изил Латыйповка гына шалтыратсын, бии-бии сатып җибәрер... Чит илләрдә бөтен гражданнарга әзер досьелар бар дип шашына газеталар, үз башыңа төшкәч беләсең икән. Нәҗипкә дә хөкем әллә кайчаннан әзерләп куелган инде! Ул май ае яшене кебек көтмәгәндә чәчрәп яшьнәде: «Әллә мин ялган сөйләдемме? Яла яктыммы? Безнең илдә хаксызлык, гаделсезлек бер дә юкмы?! Кода-кодагыйлык, коррупция, ришвәтчелек чәчәк атмыймы? Ил башында түшен калай белән тутырган ахмак утырмыймы?! Ике сүзне кушып әйтә алмаган бәндә дөнья белән идарә итәргә ашкынмыймы? Теге чакта гаризамны кире алуыма үкенәм. Өлкә комитетына язасы иде аны! Мәскәүгә, хөкүмәткә!.. Хәер, Брежневка язып ни файда?! Синең ишеләр бар чакта аңа җил-

яңгыр тимәс! Берләшкән Милләтләр Оешмасына язсаң гына инде! Барыбер файдасы булмас! Кырым татарлары әнә омтылып карыйлар, шул сәгатьтә авызлыклыйлар тегеләрне! Тышаулыйлар! Щаранскийлар сыман үткәреп бер сүз әйтәсе иде әле, тел җитми! Көч юк!»

Сабит, төкерекләрен чәчеп, Наилә дә, балалар да ишетерлек итеп акырынды: «Җитәр сиңа, селәгәй. Телеңне кисеп, дурдомга, Арча кырына ябуларын телисеңме? Минем өемдә тының чыкмасын! Мин — коммунист! Тагын бер сүз ычкындырсаң, этап белән озаттырырмын! Телефонны күрәсеңме, зәңгәрен, мин аннан хөрмәтле Иван Ивановичка гына түгел, генерал Бичуринга да шалтырата алам. Ул да мине бик яхшы белә. Сине дә беләләр икән, рәхмәт, танытып өлгергәнсең!»

Сөмбелә дә кайткан икән, тавыштан куркышып, балаларны җитәкләп кабинетка алар килеп керүгә, Сабит тынычланырга тырышты, өстәл башына утырды, аякларын йомшак кына биетә башлады. Сөмбелә тез арасына Искәндәрне кыстырып, иркәләп иренә дәште: «Йә, хәлләр ничегрәк анда, Сабит?!» Сабит Наилә ягына борылды: «Наилә ханым, ичмасам, сез акыллырак булыгыз. Мин биргән вәгъдәмдә торам. Кайтуыгызга шәһәр советына барыгыз, шушы номер белән астан шалтыратыгыз. Нишләргә кирәклеген әйтерләр анда. Сезгә яңа салынган йорттан ике бүлмәле квартир бирәләр. Өченче кат, кояшлы як. Әгәр бу тиле тәүкәл егет Шомбай сыман бүреген кыңгыр салып йөрмәсә, эш тә табарлар. Зинһарлап сорыйм, катышмасын сәясәткә! Төрмәләрнең ишеге ябылганы юк... Кирәк икән, дурдомга илтеп тыгарлар. Шундый мөмкинлекләр ачылганда!.. Яшә дә яшә генә!..»

Наилә кычкырып җылап җибәрде һәм, хәле бетеп, каенагасының муенына ташланды. Аннан Сөмбеләне кочып, үбеп кат-кат рәхмәт укыды.

Хуҗа иртәнге рейска билетлар да алып кайткан икән, тагын бер тынгысыз төнне үткәреп, Сөмбелә белән аерыла алмыйча сөйләшеп, чөкердәшеп иртәне җиткерделәр. Бераз таушалган «уазик»та Әхмәтзыя аларны аэродромга илтеп тә куйды.

Сәфәрчеләрнең сөйләшеп сүзләре бетмәде. «Күчешегезгә бездән бүләк!» — дип, Сөмбеләнең мең сум акча, балаларга ару кием-салымнар, күчтәнәчләр җибәрүе аларны аерата дулкынландырган иде.

«Туганнар белән аралашу кайчагында бер дә начар түгел икән!» — дип йомгак ясады Нәҗип, самолетка кереп утыргач. Кайткач та этиләренә берәр посылка салырга Наилә белән сүз берләшеп куйдылар.

Эзи районыннан сессиягә депутатлардан тыш колхоз рәисләре, совхоз директорлары, авыл хуҗалыгы белгечләре бара дигәч, самолетта тыгыз булыр дип пошынганнар иде, нибарысы алты җан очып киттеләр. Күтәрелеп, мотор тавышы тигезләнгәч, тәрәзәгә ябырылдылар. Май кояшы күмгән якты кырлар, күпереп килгән яшькелт болыннар өстеннән очканда, олы юлдагы гаҗәеп хәрәкәт-манзараны күреп хәйран калдылар: Зәйдән Казанга таба сансыз-исәпсез машиналар чылбыры чыгып килә иде. Шактый баш тинтерәткәч, Нәҗип бу җанланышның да серенә төшенде. Әйе, һәр җәһәттән ныклы тәртип яраткан Харис Вагыйзович зәйлеләрне әнә шулай, тантаналы демонстрация ясап сессиягә алып бара иде. Энесен, киленен, бала-чагаларын төяп Казанга кайтара алыр иде Сабит, мәгәр райком секретаре урнаштырган тәртип буенча, машиналарга чит кеше утыртырга ярамый иде. Һәр депутат, һәр рәис, һәр директор үз машинасында ялгызы Эзигә килә дә, алар башкалага тоташ кортеж булып, күмәк көч булып кузгалалар. Алдагы сөт төсле ап-ак машинада Харис Вагыйзович бара. Капотына нәни генә кызыл әләм кадалган. Үзе бара! Үзе! Хуҗа! Аның артыннан, дәрәҗәсен белеп кенә, бүтәннәр тезелә. Сабитның машинасы әлегә бишенче! Көзге конференциядән соң, Харис Вагыйзович өлкә комитетына авыл хуҗалыгы бүлеген җитәкләргә киткәч, байраклы беренче машинада Сабит Йосыф улы Нургалиев барачак. Ихлас әле унөченче генә!.. «Коммунизм юлы» дип аталган, исеме җисеменә тап килә торган күргәзмә колхозның рәисе булырга бик теләсә дә, Әхсән Сәхәпович Хәлиуллин килә алмаячак. Буе бәләкәй. Уставка җавап бирә алмый торган буй. Ә бу җанлы чылбыр булып шатлыклы тәгәрәгән машиналарда нәкъ бер буйдагы — йөз дә сиксән җиде сантиметрлы егетләр, ил露 топкалары, пешеп өлгергән социализмның һәм Брежневның төп таянычлары бара. Буйлары шуңа җитә алмаган байтак егетләр витаминлы ризыклар ашап, биеклеккә, югарыга сикереп, турникта озак асылынып торып, болында мәтәлчек атып гәүдәләрен шул хыялый сызыкка җиткерергә тырышалар. Дөрес, бу иркен дөньяда үз буеның озынлыгын бәяләмәгән ахмаклар да бар. Сирәк булса да очрыйлар! Әнә берсе — Нәҗип Йосыф улы Нургалиев — хикмәтле һәм хөрмәтле Иван Иванович кулыннан яшәргә хокук-урын һәм эш дауларга кайта... Кермәсә, утыз өчтә дә акыл керми икән!

Аклы-каралы кортеж Чаллыга барып җитеп, аннан чыккан тагын да шәбрәк, тагын да озынрак колоннага кушылды. Нәҗипләр самолеты тирбәлә-тирбәлә авыл хуҗалыгы батырларын, данлыклы эшче сыйныф вәкилләрен сәламләп узды. Мамадыш, Балык Бистәсе, Питрәч, Биектау кәрваннарын да күреп үтте безнең сәфәрчеләр. Машиналар чылбыры, сигезаяк кармавычлары сыман кыймылдап, шәһәрне имә, суыра һәм үзләре дә шунда кереп сеңә бара иде.

Сары йортка алар беренче тапкыр таксида утырып кайттылар, кесәгә мең тәңкә кергәндә, яңа квартир хуҗалары булабыз дигәндә, өч тиенлек трамвайда кысылырга теләмәделәр. Машинага кереп утыргач, Искәндәр: «Эх, тәтенле ит ашарга бара алмадык!» — дип, әти-әнисен көлдерде. Выжт иттереп, сары йортның ишек катын сарган карчык-корчыкның күзенә тузан сиптереп кайтып керергә ниятләгәннәр иде, машинаны читтәрәк туктатырга туры килде, — ишеккә якын барырлык түгел, анда кара болыт булып халык сарылган иде. Ни хикмәт бу? Әллә йортны сүтәләрме? Бу галәмәтне күреп кызыксынган такси шоферы да аларга ияреп чыкты һәм, аяк очларына басып, халык арасына кысылырга маташкан хатыннан: «Ни булды монда, бабуся?» — дип сорады. Карчыкның җавабын ишетергә теләп, Нәҗипләр дә тукталдылар. «Ой, касатик! — дип сузып җибәрде карчык.— Лизабыз бар иде. Байтактан монда яши иде. Бәбәй тапкач: «Бала миннән түгел!» — дип ире кугач, күченеп килгән иде бичара. Баласы сәламәтлеккә туймады, астма иде кызында. Интекте сабый, буыла-буыла тилмерде. Шундый тере кыз иде үзе тагын, шундый чая, үткен. Тик бер дә төс кунмады, бите тимгел-тимгел алланып торды. Туктаусыз җылады Лизабыз, күзенең коры чагы булмагандыр. Өч көн элек биш яшьлек сабыен буып үтергән дә үзе бер шешә куе серкә эчкән. Ике көн янып-көеп интеккәч, вафат булды мескенкәй. Гәүдәләрен безгә бирмәскә маташалар, әллә каян ире табылган. «Үзем күмәм!» — ди. Кая ул! Бөтенебез бер булып күтәрелдек, прокурорга барып җиттек. Бүген менә Лизаның теләген үтәп, икесен бер кабергә куябыз, Хода кулына тапшырабыз». Карчык белешмәләрне биреп бетереп, озын күлмәгенең киң итәгенә абына-абына читкәрәк чыкты. Тыгыз төркем урталай ярылды, корсагы өстендә ике куллап тәре тоткан юантык хатын алга чыкты. Ирләр иңендә буялмаган ике табут тирбәлде. Берсе олы, берсе кеп-кечкенә генә. Халык арасында нәразыйлык авазлары яңгырады. «Безгә каһәрләгән язмыш, ә алар... балда-майда йөзәләр!» — «Без күселәр белән чуплектә, а алар пулатларда!» — «Оятлары калмады анда, туймас тамаклар...» — «Һаман талыйлар».

«Мондый сүзләрне соң чиккә барып җиткән сары йорт кешеләре генә әйтә аладыр»,— дип уйлады Нәҗип. Нәфрәтнең кая төбәлгәнен ул бик яхшы аңлады. Аңа кагылып диярлек Ионыч үтте. Ул аларны күрмәде, кызарган күзләрен уа-уа ташкынга йотылды.

Өйгә керсәләр — харап! Ишек бикле, тәрәзә тыгызлап ябылган булса да, идәндә, тәрәзә төпләрендә, киштәдәге китапларга бармак калынлыгы соры тузан яткан. Ишек яңагына элгән халатын танымады Наилә, ятсынып кулына алган иде, әче болыт бөркелеп, борын тишегенә тулып төчкертә, йөткертә башлады. «Астмалы бала түгел, монда сәламәте дә чихут алыр!» — дип сукранды Наилә һәм зарлана-зарлана идән сайгакларын юарга әзерләнде. Нәҗип җәһәт кенә бер чиләк су алып керде. Икесенә дә нидер эшләргә, ничек булса да мавыгып онытылырга, туган якка ясалган сәфәрнең авыр хатирәләрен онытып торырга кирәк иде. Нәҗип, комачауламас өчен, малайларны кибеткә алып чыгып китте, сөт, катык ише нәрсәләр алып кайтты. Наилә, идәнне юып чыгаргач, пычрактан, шакшыдан, тузаннан озак кына зарланып утырды. Бүген хатыны җаеннан гына торырга тырышкан Нәҗип: «Күпкә түзгәнне әзгә түзәрбез», — дип ычкындырды. Хатынын тынычландырырга теләгән иде, киресе килеп чыкты: «Ышанмыйм мин аның вәгъдәсенә! — диде Наилә. — Үрдәк биреп каз алырга яраткан Сабит абый ниемә дип безнең өчен тырышсын? Бездән ни көтә ул? Нәрсә алырмын дип өметләнә!» Нәҗип хатынын куәтләде: «Бүген Казанга киләсе булгач, Иван Ивановичка шалтыратып маташуы да мәзәк инде. Спектакль уйный, кылана!.. Бер табышмак ачыкланды: якын араларда миңа эш буласы юк икән!»

Тузан басылса да, өйдә зәһәр әче ис калды. Җил кирпеч заводы ягыннан исә иде. Сөмбелә күчтәнәчләре белән ашыкмыйча чәйләделәр, иртә уянган малайлар башны башка куеп караватка тәгәрәделәр. «Әллә бармыйммы шул Иван Иванович катына?» — дип шиген уртаклашты Нәҗип. Наилә авыр сулады, дәшмәде, кулы белән балаларга төртеп күрсәтте. «Ә алар?» — «Мин бүгеннән эш эзли башлыйм», — диде Нәҗип. «И Нәҗип, Нәҗип... Тинтәк инде син, беркатлы. Эше барга бирәләрме квартир?.. Чәнчелеп китсен дөньясы, син генә ак калырга димәгән... Дөньясы шул ич аның... Гөлнара исемле танышымны әйткәнем бар бугай... Мин белгәндә генә бишенче квартирларын алыштылар инде, бишенчесен!»

Борынгы болгар бабаларыбызда, аннан соңра татар илендә түргә сөенеч узганда яки ишеккә кайгы-хәсрәт ябырылганда, дөньяга яңа җан — бәби туганда, үлем-җитем булып иңгә кара кайгы сарылганда, тирмәләрдән чыкканнар да иярсез атка сикереп менеп җан-фәрман чаба торган булганнар. Иделкәйнең текә ярларына басып җырлаганнар, җир тетрәтеп тыпыр-тыпыр биегәннәр, хәсрәткә баш бирмәс өчен бал эчкәннәр.

Ни кылсын Нәҗип бахыр, менәр аргамагы юк, бабаларыннан калган бәрәкәтле җирләрне сасы заводлар биләгән, җырлап җибәрер иде, моңы юк, аптырагач, бер башы чыкты да китте! Әйе, әлегә анык кына берни дә белми ул, тинтерәгән: кем ул Иван Иванович?! Еракта торып Сабит абыйсы үз кубызына аны биетә ала икән, алар ике чабата бер киемдер! Чукынып китсен Иван Ивановичы! Сабит эшне нигә шулай тизләтте соң?.. Бусы бик шикле иде. Нәҗип гади булса да абыйсының комсыз күзләрен күрде, Наиләгә чиләеп карап утыруларын сизде... Әгәр хатынга бер-бер оятсыз ишарә ясаса, Наилә дәшми калыр идемени?! Изил Латыйповның күзе елтырауларын, икеле-микеле оятсыз тәкъдимнәрен һич яшермичә кайтып сөйли алган хатын ич ул!

Наиләнең тычкан исе белән тынчыган салам эскерте төбендә укыган зәһәр хөкеме кылт итеп исенә төште. Аяусыз хөкем чыгарды хатын, ләгънәт укыды, каргады... Бер уйласаң, ул хаклы түгелмени? Авылга кайтып ул үзенең көчсезлеген раслап килде бит! Ярый әле чирләмәде, хисләргә тулышып, мие томаланып җирдә тәгәрәмәде... Кайчагында көчсезлек чирне җиңә дә ала икән...

Нәҗип бүгеннән булмаса да, иртәгәдән, берсекөннән яңача яши башларга тиеш, бүтәнчә, замана законнарына буйсынып, заман кешеләренә яраклашып. Әгәр Иван Иванович дигәннәрендә әз генә шәфкать, мәрхәмәт сыйфатлары бар икән, ачы язмышын нигә аңа ачып салмаска? Бәлки, ул Нәҗип язмышының кылдый-былдый юлларын яхшы якка үзгәртергә туган фәрештәдер?..

Тукта, кая килеп җиткән ул? Шәһәрнең бу ягына нигә килгән?.. Әйләнеп-әйләнеп карагач кына, ул үзенең Фәридун Фазлыев яшәгән йорт каршысына килеп җиткәнен, шуның тәрәзәсе турында туктап торуын абайлады. Троллейбуска утырган, трамвайга күчкән, шәһәрне бер яктан икенче читенә үткән, үзе шуны сизми дә калган. Әллә тагын чире яңардымы, инде бүтәнчә яши башлыйм дип ант беркеткәндә, искәрмәс яктан бәреп кереп аяк чаламы?! Уйлар упкынына батып шушы кадәр җир килгән Нәҗип, уянып, Фәридун Фазлыев яшәгән йортны күзәтте. Язын, әле дөньяның ертык-пыртыклары кар астыннан чыгып бетмәгәндә, Фәридун яшәгән йорт ярыйсы ук нык тоелган иде, хәзер сылавы купкан нигезе, рамнары череп чалшайган кыйшык тәрәзәләре, тоташ күгелҗем мүк сарган шифер түбәсе, дүрткелдән трапециягә әйләнгән ишек авызы, хуҗасызлыкка корылган һәйкәл булып, аның каршысында сураеп баскан иде. Иван Иванович турында уйлап нигә ул Фәридун Фазлыев катына килгән әле? Аны кем китергән? Кем мәҗбүр иткән?.. Хәзер кирәргә дә шик-шөбһәләрне сөйләп бирергәме?.. Бәлки, шәфкать-мәрхәмәт Иван Иванович ягыннан түгел, Фәридун Фазлыев ягыннан көтеләдер? Соңгы көннәрдә, авыл сәяхәте вакытында, Нәҗипнең үтә нык сизгерләнгән күңеле кайсы якка борылып баш орырга кирәклеген ачыграк беләдер?.. Кайчагында сукыр күңелгә дә ышанырга кирәк. Әйе, кирәргә дә сөйләп бирергә! Ул күңелен бүген ачса ача ала, иртәгә ул яңача яши башлый, яңа кеше булып... Нинди кеше булыр, ахыр чиктә анысы кирәк тә түгел... Сөенеченме, көенеченме уртаклашырга дип күңеле бүген Фәридун Фазлыевны сайлаган икән, ул бүген генә аның белән күзгә-күз очраша ала, иртәгә Нәҗип аның янына килә алмас инде. Фәридун Фазлыев белән ике арадагы тигезлек билгесе моннан соң бетәчәк. Моңарчы Нәҗип күз алдында тамыр җәйгән гаделсезлекне сүгеп, каргап авыз тутырып сүз кыстыра ала иде. Хаксызлык, бер төркем югары сыйныфның, бюрократларның илне имеп, халыкны изеп яшәве, тоташ караңгылыкта тотуы аны рәнҗетә иде... Бәхете идеме бу, бәхетсезлегеме? Ул бу авыр сорауга җавапны иртәгәдән соң гына таба алачак. Чөнки ул яңача яши башлый, Иван Ивановичка кул бирә, астан өскә аңа ялагайланып карый, ул ни кушса, шуны үтәргә әзер тора. Ул Сабит абыйсының хаксыз өстенлеген таный, аның колына әверелә. Әгәр ач күз Сабит: «Миңа беразга Наиләңне биреп торчы!» — дисә, Нәҗип Наиләсен кочып машинага утырта, ике бүлмәле кояшлы як квартираның балконыннан кул болгап кала. Моңарчы тарыгып яшәгән малайлар, гамьсез җаннар, пыр тузып идәндә, йомшак келәмдә мәтәлчек атып уйныйлар, туп тибәләр!

Абыйсы аны «диссидент» дип атады, ямьсез кешеләр, Сахаровлар белән тиңләде. Юк шул, юк! Булсын иде Нәҗип шундый көр тавышлы кеше, дөньяның аклыгын яклап сүз әйтә алсын иде! Бер сүз! Гадел сүзләрне белә ич ул, әйтми, дәшми, дәшә алмый. Менә күрегез, барачак ул Иван Иванович катына, тезләнеп ялварачак, эш тә сораячак. «Кичерегез, теге чакта ялгышканмын!» — дип инәләчәк. Чөнки аның иртәгесе киртәгә терәлгән, аның иртәгесеннән хатыны, ике улы карап, яхшылык көтеп тора. Әгәр ул бүгеннән Наиләсе белән арасын көйләмәсә, яшәү газапка әйләнәчәк. Кеме бар аның хатыныннан башка? Хакыйкать шул: ул балалары, Наиләсе хакына җанын сатарга да, заман белән вәгъдәләшергә дә әзер. Чукынып китсен!

Ул үзе дә аңлап бетермәде, бу — аның үткән гомере белән, үткән гомерендәге хак сүз белән, чынлык аша аны баеткан Фәридун Фазлыев белән мәңгегә хушлашуы иде. Дәҗҗал мәлгуньгә җанын сатуы иде бу аның. Инде иртәгәдән соң бу төбәккә аяк атламас, чөнки ул моннан ары бөтенләй яңа кеше, замана кешесе булачак. Әй мактар инде аны Фәтхулла абыйсы! И сөенер инде үз авылында рәис булып ятучы Ихлас исемле мөртәт!

Нәҗип алай ук тинтәк түгел. Гаделлекне яклап, авыл агайлары белән махра көйрәтеп, каравыл өе алдындагы бүрәнәдә гәп куерту әле егетлек түгел, гаделлек өчен нидер эшләргә, үзеннән дә өлеш кертергә кирәк. Бу өлеш үз авызыннан өзеп бирелгән булырга тиеш!

Урнашкач, бәләкәй генә тернәкләнгәч, әти-әниләренә посылка салыр! Беренче нәүбәттә шул! Алдагы җәйдә кайтып өйләрен сипләргә, утын китерергә, сарык-кәҗәгә печән чабарга туры килер. Әтиләр хуҗалыгына кулы кергәч, ул Сабит белән дә икенче төрле сөйләшәчәк! Сабит балаларын, Сөмбеләне кунакка чакырырга... Туганнар белән хат алышырга!.. Ниһаять, аның да тотрыклы адресы була, кешегә күрсәтерлек квартиры! Кояшлы як, өченче кат... Иван Иванович белән якынайсалар, телефон да кертерләр. Утырсын Наилә ахирәтләре белән әпә-чәпә сөйләшеп...

Фәридуннарга барган чакта, ул бер иде, сары йортка кайтып кергәндә, Нәҗип бүтән иде инде. Буе тәбәнәкләнде, авызы олайды. Бик каты чир кичергәннән соң адәм баласының авызы зураеп кала. Җан чыгарга җиңел булсын өчен иреннәр йомшаралар. Кайтып керсә, дагалы итекләре белән идәнне төеп

Ионыч утырган, яланбаш, чалбар төймәләре каптырылмаган, кипкән иреннәре белән төпчеген чәйни. Йокымсырый иде, айныды, карлыккан ямьсез тавыш белән, косык исе чәчеп Нәҗипкә ябырылды. «Нигә поминкада булмадың син? Ник зиратка бармадың? Урыс үлде дипме? Зиратта аерма булса да, табутта аерма юк, анда һәркем тигез. Без бит ике фәрештәне — гөнаһсыз җаннарны куйдык. Нигә син йортның кайгысын уртаклашмадың?» Нәҗип, кыенсынып кына: «Без бүген генә кайтып төштек, Ионыч!» — дип акланырга сүз ачкан иде, Ионыч икенче яктан элдереп алды: «Ник кайттың син, дурак? Нигә? Ник яшисең син бу дөньяда? Нишләп пыскып ятасың бу сары йортта?! Сабыйларыңны ни йөзең белән апкайттың?! Болай да сау түгел алар, ютәлләп колакны тондыралар иде. Хәзер аларга астма йогачак. Чехотка! Аллергия дигән нәмәрсәне беләсеңме син, инженер? Яшим, күрәм, бер кыш чыккан балалар да саргаеп күксәүгә әверелә. Олы авыру — фурункул чыга, каннары бозыла. Колаклары ага. ТЭЦта гына гаеп түгел, тимер юл гына да зыян салмый, силикат кирпеч заводы черетә адәм балаларын! Заманында бу район шәһәр чите булган, хәзер завод уртада калган... Иван Иванович янына барып сөйләшеп карадым. Кем мин аңа? Тотыныр тоткасы булмаган дүңгәләк... Тамырсыз, көчсез нәрсәкәй. Тигәнәкнең дә ябышыр чаты бар, ә дүңгәләкнең юк... Бер быел ничә мәет озаттык без моннан? Дүрт кеше үзенә кул салды. Ә син... үгез җигәрлек башың белән монда тынчыйсың. Дур-рак! Авылдан балаларны кайтаралармы?! Без яшибез инде, без — беткән кеше. Язмыш баш очына козгын утырткан... Син дә беткән кешемени?.. Ионыч кайгысын йомарлап кергәндә утырып эчәргә яртың да булмый бит синең!» Нәҗип сүз кыстырырга тырышмады, сүзе дә юк иде бугай. Ионыч шак-шок басып ишек катына килде, борылып карады: «Июнь аеннан фатир хакы йөз тәңкә! Мин киленгә әйттем».— «Нигә алай күп?»— дип сорады Нәҗип. «Сәвит акчасы бер тиенгә дә тормый. Кыйммәте юк, шуңа күрә күп!» — «Безнең бик авыр чак иде бит, Ионыч»,— диде Нәҗип, җәберсенеп. Ионыч, суган исе бөркеп, Нәҗипкә йөзен якынайтты: «Үзеңә генә әйтәм! — диде ул.— Лиза үзенә һәм баласына кул салып безнең йортны телгә кертте. Хәзер кайберәүләрнең авызын томаламасак, квартирлардан колак кагуыбыз да бик ихтимал! Санаша торган чак түгел! Синең барыр җирең бармы?» — «Әлегә юк!» — диде Нәҗип. «Минем дә юк! — дип күтәреп алды Ионыч. — Акча гони!»

Нәҗип иртүк шәһәр советына чапты, калтыранган, көчсез тавыш белән Иван Ивановичны сорады. «Ул сессиядә», — диделәр. Көн тагын сары йортта үтте. Хәзер ул иртә таңнан шәһәр советына чаба торган «даими клиент» булып китте, секретарь ханым аны тавышыннан таный башлады. «Сез миңа йомышыгызны белдерегез, мин Иван Ивановичка җиткерермен. Ул сезгә көн, вакыт билгеләр», — диде ханым. Нәҗип югалып калды: йомышын бүтәннәргә әйтергә ярыймы аның, юкмы? Байтак интектергәч, ханым аны ачыктан-ачык пешекләргә керешә. Нәҗип, кыяр-кыймас: «Сабит Йосыпович Нургалиев рекомендациясе белән шалтырата идем мин»,— диде. Ханым тагын да ныграк орышты: «Нигә башта ук шулай димисез? Иртәгә тугызынчы яртыга килеп җитегез!»

Аны иртәгесен дә серле Иван Иванович янына кертмәделәр, гәрчә ул аның шәһәр советында иң дәрәҗәле кеше икәнен белеп алган иде инде. Ярдәмче ханым кырыс елмаеп каршылады да: «Фәлән урамда йорт җимерелде. Сез шул йортта яшәүче аварийщиклар исемлегендә. Квартирлар бүлүче отделга төшегез. Анда Фомин дигән иптәш булыр. Формальностьлар эшләнгән. Ордер алыгыз да тизрәк күченегез»,— диде. «Шулай тизме?» — диде ни әйтергә белмичә Нәҗип. Ханым дәшмәде, ни уйлагандыр, күз карашы усал, аяусыз иде.

Нәҗипнең үз гомерендә мондый кыйммәтле документ алганы юк иде: туу турында таныклыгы бар — чүп! Паспорт алырга ярый ул кәгазь. Паспорт — чепуха! Диплом — адәм көлкесе! Аның белән гадел яшәсәң, тамак та туйдыра алмыйсың... Ордер! Бу инде орденнардан да кыйммәтрәк, дипломнан да кирәгрәк. Ордер — сине кеше рәтенә кертә, яшәргә хокук бирә. Ордер — квартир. Квартир — крепость. Моннан ары Нәҗипнең тормышына Тимерхан, Җәмиләләр, Ионычлар, Ираидалар, Фәтхуллалар катнаша алмый, аның хатыны белән ничек йоклаганын, ни эчкәнен, ни ашаганын берәү дә тикшерә һәм күзәтә алмый. Яңа квартирга барып кергәч, ул, әлбәттә, ялантәпи бер биеп җибәрәчәк. Рәхмәт мәрхәмәтле, ягымлы, игътибарлы, кулыннан эш килә торган чиновник-бюрократка! Алар арасында да чын кешеләр бар икән!

Беркатлы, тинтәк Нәҗип, әлбәттә, Сабит белән Казан шәһәре башлыгын ни берләштерә алуын уена китерә алмый, тимер юллар министрын каршылауга тотылган байтак чыгымнарны Сабит күтәргәнен, бүтән чакларда да аларның аралашканын, Сабитхан биләмәләрендә кыр тавыгы, көртлек, Мостафин урманы күлләрендә үрдәк ауларга йөрүчеләрнең иң активы шушы кеше икәнен белми иде.

Ул шәһәр советыннан чыкканда, Кремль сәгате нәкъ икене сукты. Ул шул якка борылып карады, зәп-зәңгәр күктә манараның алтын йолдызы йөзә кебек тоелды. Аның ике иңенә дә канатлар үсте, чир-чорлар, өметсезлекләр онытылды, моңарчы аякка тагылган богаулар чишелде, күзе ачыграк һәм ераграк күрә башлады, алдагы тормышы Идел аръягында тирбәлгән Ослан таулары сыман гүзәл, серле һәм мәһабәт булып тоелды.

Уңда Җәлил калды, сулда — музей. Ул Казансу елгасының аръягына, Ленин районына, сары йортка тизрәк кайтып җитәр өчен үрдән аска ташланды, машиналарны узып, троллейбус тукталышына очты. Һәм авыр сулап, кулларын артка куеп, кара кайгыга батып менеп килүче ир затын чак кына таптап үтмәде.

Тыелып туктады, килүче таныш булып күренде. Аның кырында, очкан озын гәүдәгә юл сабып, юаш елмаеп, Фәридун Фазлыев басып тора иде.

«И язмыш! Без белмәгән нинди кодрәтләрең бар синең?!» — дип, мең кат уфылдады ул соңыннан. Фәридун Фазлыев елмаюын йомып җитдиләнде, ике кулын бирде. «Мин сезне авылда дип торам. Ни эш кыдырып йөрисең?» Нәҗип Фәридунның иңнәрен кочып алды. «Фәридун абый! — дип кычкырды. — Менә квартир алып йөрим!» — «Котлыйм! — диде Фәридун табиб, елмаюына көч биреп. — Котлыйм!» — «Ә сез, Фәридун абый?» — дип сораса да, Фәридун сүзләренең эчтәлеге әле Нәҗипнең сөенечтән томаланган акылына барып ирешмәде. Шул булды — ул Фәридунга ияреп өскә менә башлады. Халык үтеп-сүтеп йөри, тар баскычта тору уңайсыз иде. Фәридун баскычтан бик акрын һәм шактый ук озак менде. Җәлил һәйкәле кырына, таш эскәмиягә барып утырдылар. Фәридун, дымлы маңгаен, битен сөртеп, тынын туплагач, төшендерде: «Ниһаять, миңа да квартир бирергә тиешләр иде. Ике ай төеннәр өстендә утырдык. Йортны тапшырдылар, күченәселәр күченеп бетте, диделәр. Инде ордер алам дигәндә, истә-оста югында, Иван Иванович чакыртты. «Көт көзгә кадәр! — ди. — Мәскәүдән белгеч чакыртып алдык, сиңа багышланган квартирны аңа бирергә туры килде», — ди... Тагын бер-бер бүтән сүзе юкмы дип аптырап янына менеп барам... Апаң шушы хәбәрдән чирләп егылды. Реанимациядә ята».

Нәҗипнең колак төбендә генә нидер чыртлады, күз алдында ут бөркелде. Менә ни өчен сөенечен уртак итәргә теләп Фәридун абыйсы катына җитәкләп алып барган икән язмышы аны! Мөгаен, шул сәгатьләрдә «белгеч килүен» хәбәр иткәннәрдер аңа? Шул коточкыч шәфкатьсез мизгелдә хатыны чирләп аугандыр? Тукта! Нигә алай уйлады ул? Бәлки, язмыш аңа карата алай ук аяусыз түгелдер?.. Ул Фәридун абыйсына йотардай булып карады: «Гвардейский урамындамы? Өченче кат. Балконлы кояшлы як?!» Ул сораган саен, Фәридун баш кагып тора. Соңыннан икесе берьюлы әйтеп салдылар: «Утыз беренче йорттан ундүртенче квартир?»

Нәҗип ордерын чыгарып күрсәтте... Фәридун телсез калды. Нәҗипкә күтәрелеп карады. Бу караш!.. «Нигә, тәкъдир, уттан алып суга салдың мине? Тәүлек буе куанырга да форсат бирмәдең? Хатын, балаларны сөендерергә дә өлгермәдем!» — дип кыйналды ул соңыннан...

Фәридун сорашмады, аңлады, бер карады Нәҗипкә, батырып карады. Шушы карашы белән ул аны үтерде, бәреп екты, суйды, упкыннан түбәнгә ыргытты, язгы ташкынга төртеп төшерде, яшен булып сукты, тәмугның иң зәһәр, тавышланып, быгырдап кайнаган сумала казанына кул-аякларын бәйләп салды. Нәфрәт белдерергә гел-гел сүз кирәкми, нәфрәт өчен бер караш җитә. Әгәр сиңа намусын сатмаган һәм сатылмаган, шәфкатьле, мәрхәмәтле җан иясе нәфрәт утын төби икән — аңа чыдармын димә. Сабит арбасына утырып җырлый башлаган Нәҗип шул мизгелдә үзен үтәли күрде...

Күрде, сикереп торды, Фәридун Фазлыевны шәһәр советының мең хәсрәтле аяклар шомарткан тимер баскычында куып җитте. Иван Иванович кабинетына тарткалаша-тарткалаша алар бергә керделәр.

Шулай теләде Нәҗип, Фәридун ризалашмаса да, кат-кат ялынды. «Әгәр исән калуымны теләсәгез, Фәридун абый, сүземне тыңлагыз. Ордерны алыгыз. Сезне утка ташлап, хәләлегезнең җан кыючысы буласым килми», — диде.

Фәридун Фазлыев яшәгән йортны җимерәләр икән.

«Соңгы булып күченәбез, әгәр квартир бирмәсәләр, эш харап иде», — диде ул.

«Киереп тартып куелган язмыш сызыгы юк дип кем әйтә ала?!» — дип уйлады Нәҗип соңыннан, Наиләнең таудан тәгәрәгән ташлар кебек өстенә туктаусыз яуган авыр сүзләрен тыңлаганнан соң...

Бар ул язмыш, бар. Язмыш күңелне кысып бәйләп, кара чүпрәк аша нур кертмичә, сине сукмагыңнан алып бара, әйди, көчли, тарта, йолыккалый. Карышып кара син аңа, тартыл, зарлан, каһәрлә — артка чигә алмыйсың, уңга-сулга тартылырга әмәлең юк, баш бирәсең, муеныңны бөгеп барасың да барасың. Татар халкы, синең улларың язмыш иркенә тиз бирелгәннәр, үз төбәгеңнән, үз җиреңнән еракларга чәчелгәннәр. Аларның һәммәсе дә мондагы кысанлыктан, кысулардан, хаксызлыктан качып китмәгән ич; монда тормышны рәтләргә көче җитмәгәннән, каһәр суккан шахта базларына барып, җылы якларга китеп, кавын-карбызларга, яшәү җиңеллегенә алданган. Усал язмыш йөрткән аларны, илләрен оныттырган, телләрен ташлаттырган, күпчелек ата-бабасының каберен дә хәтереннән чыгарган. Күпме ил өлкәләрендә хәзер кара хәтерле татарлар?.. Балаларын чукындырып, аларга тузга язмаган исемнәр биреп яшәүче милләтсез, җирсез, хәтерсез маңкортлар күпме?.. Усал язмыш өерләп упкынга алып кереп барганда, аны кем тыйды?.. Ничек итеп? Кем уйлаган Фәридун Фазлыев ничәмә-ничә вакытлар тилмереп көткән фатир Нәҗип бичара кулына килеп керер дип? Җилкә тамырың сыекланса, язмыш һәрчак сине тар юлга кертеп сыный, аның ирегенә биреләсең икән, беттең дигән сүз!

Нәҗип Йосыф улы Нургалиевнең кыюлыгы җитәр, ярдәмче марҗаның ай-ваена карамастан, ул Фәридун Фазлыевны җитәкләп, Иван Иванович янына барып керер, үзенә язылган ордерны аның файдасына баш тартып, мэрның «көзгә уйлап карарбыз» дигән сүзенә ышанып, ярык тагарак янында утырып калыр дип кем уйлаган?! Икенче көнне өченче каттагы, кояшлы яктагы яңа квартирга Фазлыевны күчерешер, әйберләрен сөенә-сөенә ташыр, булышыр дип кем уйлаган?!

«Йөртә безне язмышлар» дип, туган ягын сагынганда җырлап җибәргән безнең шахтер бабайлар... Җырлар, мәкальләр, риваятьләр — язмышы конституцияләрдә берчакта да берегә алмаган татарның яшәү кануннары, безнең уртак терәкле уйлар. Татарның язмышы җиңел булмаган. Әйдә, без дә язмыш җиленә баш биреп, җилкәнсез, ишкәксез көймәләргә утырышып төрле якларга таралган татарларга да, таралачакларына да рәнҗемик... Авыр булса да түзик, «бүленгәнне бүре ашар, аерылганны аю ашар» дип зарлана-зарлана таралышкан кардәшләребез ничәмә-ничә гасыр аю-бүреләрне тукландырып торалар икән, ни хәл итмәк кирәк?! Нужа баткагыннан чыга алмаса да, туган төяген ташлап качмаган Нәҗип ишеләре дә бар ич әле аның үз арабызда!..

Наилә Нәҗипне аңламады, аңларга да теләмәде, иренең дәлилләре вак-төяк, чүп-чар булып күренде. Ничек инде, заман кешеләре бер-берсенең күкрәген изеп үзләренә юл салганда, кулыңа килеп кунган бәхет кошыннан баш тарт?! Бу бит диваналык, шыр тилелек... Бу, бу... Наиләнең зәһәр тавышы, Нәҗипнең колагында чиркәү чаңы гүләгән сыман, «бу-бу-бу!» ишетелеп торды. Черек саламлы эскерт өстендә Наилә әүлия, ак канатлы фәрештә булган икән әле!

Атаның яратканын белгән хатын-кыз ызгыш-талаш арасында балаларны арага кертә, калкан итеп куя. «Син, тинтәк, хайван, сары йорт хакында, монда җан тәслим кылган сабыйлар турында Ионыч әйткән сүзләрне ишетмәдеңмени? Колагыңа мамык тыккан идеңмени, дивана?.. Үз балаларын яратмаган, аларны санламаган ата да булдымы кеше?!»

Йөзен ертып, каршысына кереп баскач, кыюланып, Нәҗип Иван Ивановичка эш сорап та мөрәҗәгать иткән иде. Гомер юлында мондый адәми затны беренче тапкыр очраткан Иван Иванович егетне акыл ягыннан зәгыйфь санаса да, кызыксынып китеп, эш белешкәләп торырга кушкан иде. Моны ишеткәч, Наилә күтәрелеп бәрелде: төтене дөрес иде бүген хатынның! «Шыр дуракка, күрексез гармунга нинди эш бирсеннәр?! Әнә шул бакчага карачкы итеп куйсалар инде! Дөнья мәсьәләләрен ач каргалар белән хәл итеп яшә шунда, дөмеккән!»

Кирәк бит, алар шулай тарткалашып, бер як — ут кебек дөрләп, икенче як тоташ уттан ничек чыгарга белмичә утырганда, сак кына ишек ачылды һәм аннан кем керде дип беләсез?..

Кайда яшәүләрен беркемгә сөйләгәннәре юк, сары йортны адрес бюросында Америка шпионнары да таба торган түгел, ә ишектән, шакымыйча-нитмичә, көяз атлап, утта янмас, суда батмас Мәхмүт-Мудрый басып керде. «Юк, юк! — диде ул, Наиләнең бер якка талпынганын күреп.— Чәй кирәкми, тамагым тук, әнкәй яныннан әлерәк кенә гөбәдия ашап чыктым. Гөбәдиясе!.. Кештердәп тора! Бүген Минһаҗевны җирләдек бит, малай. Инфаркт кыра яшьләрне. Егерме тугызы тулган иде егетнең. «Заря» ресторанында дүрт ел директор булды, ә бавырының кылкасы да калмаган. Бавыр белән китмәде тагын, йөрәккә бәргән. Ә зиратта яшьләр ята тезелешеп!» — дип такылдады ул, хуҗаларның сырт йоны кабарганын сизенмәскә салышып.

Ачудан талагы кабарган Нәҗипнең бүген «зират», «үлем», «инфаркт» дигән сүзләргә һич исе китмәде, колагы балавызланган идеме, ник чукынып китми дөньясы, Минһаҗевларның ник кырык чөйләре кырылмый, үз кайгысы бүгенгә түгел, иртәгәгә дә җитәрлек әле аның. Наилә аксак чыпчык кебек бер урында сикергәләде, Мудрыйны кая утыртырга белмәде. «Мәхмүт җаным, әҗәт артыннан керүеңдер. Акчабыз бар барын, тик син әзрәккә түзмисеңме?» Мудрый җылы сүзләрдән эреп, үзенең әзгә түгел, күпкә күтәргә дә чамасы барлыгын белдереп кулларын җәйде. «Керүем аңа түгел, Наилә ханым! Яшәрлек чамам бар. Йомышым юк түгел түгелен».

Гаҗәп, бүгенге хәлгә төшкән хуҗаларда кемнең, нинди йомышы булуы ихтимал? Мудрый таралып яткан балаларның өсләрен рәтләде, каушаган хуҗаларны тагын бераз көттеребрәк: «Сезнең Латыйпов белән аралар ничек? Чама чамага туры киләме, әллә...» — «Изил Бәдретдиновичны әйтәсеңме? — дип сорады Нәҗип, сытык чыраена караңгылык чыгарып. — Ничек дип...» Наилә, ярдәм көткәндәй, иренә карап алды. «Ни булган Латыйповка? Әллә ул да кәкрәйгәнме?!» Нәҗип сүз өчен генә бирде бу соравын. Мудрыйның кычытмаган җирне кашып йөрүе тулышкан ачуын арттырды.

«Алпавыт булып китте абзагыз! Җир хуҗасы! Кыланмышын күрсәгез... Директор биргән «Волга»да кәпәренеп кенә юрттыра. Кояштыр. Күрсәгез танымыйсыз сез аны!»

Ярата Мудрый куе төтен җибәреп кешеләрнең башын әйләндерергә! Хуҗалар бик белергә теләп сорашсалар да, ул аларны өч нарат арасында байтак адаштырып йөртте. Завод кешеләренә дип Идел буеннан ике гектар ярым җир бирүләрен, шул җирдә дачниклар ширкәтен оештыруны Изил Латыйповка тапшыруларын Нәҗип белән Наилә аңларлык сөйләгәнче, үзе дә манма тиргә батты. Ниһаять, аңлашылды, керүе яхшылык артыннан йөрүе икән егетнең! «Идел буенда шәп итеп йорт

салып җибәрәсез. Рөхсәт! Яшә шунда, гөлчәчәкләр утырт, бәрәңге, кишер! Станция терәлеп тора, машинаң юк икән, башың ватылмасын, теке-теке поездда теркелдә! Мич чыгарсаң, кышын да анда яшәргә була! Утын хәсрәте юк, урманы өстеңә ишелгән! Латыйповка чабасыз да бүленеп беткәнче җир аласыз!» — дип сөйләп бетерүенә, Наилә пыскып җылап җибәрде. «Кем бирсен аннан безгә җир?» Мудрыйның кашлары өскә сикерде: «Әгәр Латыйпов белән вася-вася яшисез икән, ник бирмәсен?! Начальство үз кирәген алып бетергән, партбюро әгъзаларына да шобагага кадәр үк үлчәп биргәннәр, минемчә, читтән, ерганак тирәләреннән аның бирер чуты бар».

Наилә, ашыгып-кабаланып, күз алдыннан сихри күренешләрне үткәрде. Идел. Урман. Саф һава. Түтәлләрдә җәй буе кишер, шалкан үсә. Малайлар түтәлләр арасында тәгәрәп ял итәләр. Нәни генә йорт салып, мич чыгарып куйсаң... Сары йорттан котылырлар иде, ичмасам!

Хатынның Мудрый алдында мышкылдап торуын өнәмәгән Нәҗип кырку гына сорады: «Ни булды сиңа? Балавызыңны ник сыгасың?» — «Соң, бәгырь кисәгем, сине заводтан типкәләп чыгардылар. Кем бирсен сиңа җир?» — «Ә син? Нигә сиңа бирмәсләр дисең?» Мудрый шулай дип әйтеп өлгерүгә, Наилә тагын җылап җибәрде. «Мин — арбаның бишенче тәгәрмәче. Кирәгем шулхәтле генә. Мине куарга да күп сорамаслар. Нәҗип кайтканнан бирле юньләп эшкә чыга алмыйм. Моннан ике төрле транспортка утырып балаларны бакчага илтергә кирәк. Ярты көн үтә. Үз хисабыма ял алып авылга кайттым. «Соңгысы! — дип бирде мөдиребез. — Йә иреңне савыктырасың, йә бездән китәсең!» Кая ди ул бакча».

Мудрый алай тиз бирешә торган егет түгел, ул тә-тә-тә хуҗаларны һаман үгетләде. «Ятып калганчы, атып калыгыз. Син, Наилә, Латыйпов белән сөйләш!» Ни сөйләшсен ул андый ала күз белән!

Мудрый, үзара талашның җанлануын чамалап, үз вакытында чыгып тайды. Нәҗип белән Наилә пәрмә-пәр ызгыштылар, тавышка балалар уянды, ачу китереп, җир селкетеп поездлар үтә торды, аскы катта чыр-чу килеп исерек хатыннар җыр улады. Бирделәр кирәген!

Көндезге гауга төнлә тынып торса да, иртән ир хатынга, хатын иргә борылып карамады. Наилә балаларны дөбердәтеп врачка алып китте, аларны бакчага кайтарыр өчен больницадан белешмәләр кирәк иде. Нәҗип шәһәр советына чапты, «Сабит Йосыпович Нургалиев рекомендациясе белән» тагын Иван Ивановичка шалтыратты, шактый әрсезләнеп, кыюланып үзен кабул итүен үтенде. Өч-дүрт көн йөргәч, ниһаять, алар әзгә генә очраштылар. Дуамал, башсыз кеше белән кызыксына башлаган мэр ахирәт дустының энесенә шәһәрнең иң зур яшелчә базасында директор урынбасары булып урнашырга тәкъдим итте. «Гаҗәпләнмә, — диде ул, — директор урынбасары төшемле, җаваплы урын. Җөмләдән директор булып анда кәттә бер егет эшли. Элгәре сәнгать белгече булган, диләр, аспирантура тәмамлаган, шагыйрь! Аның кулы астында инженерлар, кибернетиклар, югары мәктәп укытучылары, хәтта бер доцент та барын белеп кит. Оттырмассың».

Әгәр Наилә белән аралары шулай киеренке булмаса, ул, мөгаен, ризалашыр да иде. Бүтәнчә кая бара аласың? Ичмасам, гаиләсенең тамагы тук булыр, эшкә һәм дөнья таләп иткән хәйләгә өйрәнер иде. Тик бүген, Наилә аны секунд саен аска изгәндә, «яшелчә базасына урнаштым» дип ничек кайтып әйтәсең?!

Алай да, арты белән күлгә чумган үрдәк кебек, яшелчә базасына кагылып чыгарга булды. База директоры — буйга үзе кебек озын, киңчә ак чырайлы, яхшы аргамак кебек башын югары чөйгән, укымышлы кыяфәтле урта яшьләрдәге кеше, Нәҗипнең киләсен белә икән. Ул Сабит Йосыповичны якыннан белүе белән дә мактанып куйды, эш хакында күп сөйләп тормады. «Төрлечә яшәп карадым мин. Якты дигән юллар ачык иде... Монда килгәч гап-гади хакыйкатьне аңладым: моңарчы мин гел ялварып, бөтен кешегә ялынып яшәгәнмен икән. Ә хәзер бөтен кеше миңа ялынып килә. Шул аерманы аңласаң, кил»,— дип сүзен йомгаклады. Нәҗип: «Рәхмәт, уйлап карармын»,— дип чыгып китте. Киңәшкә Фәридун Фазлыевка барды. Ул сүзне коры тотты: «Пычранма. Кер укытырга. Мәктәптә ир укытучыны ике куллап каршы алачаклар!» — «Укытучыларга берәр заман квартир бирелгәнен ишеткәнегез бармы, Фәридун абый?» Фәридун аптырап калды, Нәҗип аңа да: «Уйлап карармын!» — дип әйтеп, өенә кайтып китте.

Өйдә өермә, буран! Идән белән түшәм арасында Наилә яшен уйната. Башын иеп чыгып китә Нәҗип, башын иеп кайтып керә, кичергәннәрен тәртип белән хатынына аңлата, ике ара барыбер җылынмый. Наилә, Мудрый сүзләрен куәтләп, Нәҗипне Изил Латыйпов янына куа башлады. «Әгәр бакча артыннан йөрмисең икән, үзем йөрим! Латыйпов белән үзем сөйләшәм!» — диде ул бер кичне. Ни әйтсен Нәҗип, телен аркылы тешләп, моңсулык гомерлеккә йөгергән күзләре белән хатынын эшкә озатып, малайларны бакчага алып китте. «Әни нигә көн дә җылый?» — диде Искәндәр, әтисенең кулын ике учы белән кысып. Нәҗип җавап кайтармады.

Наилә, ирен кат-кат өркетергә маташса да, әлегә Изил Латыйповны эзләп чапмады, гарьләнде. Түбәнсенәсе килмәде, бер-бер бүтән җае килеп чыкмасмы дип, нидер өметләнеп көтте. Беркөнне, эшкә барырга җыенып урам як ишек катына чыккач, Ионычны очратты. Алар, берничә ир, борчылган кыяфәттә чыш-пыш нидер сөйләшәләр иде. Колагы торды Наиләнең, якынрак килде, тыңланды. Ионыч

күз кыры белән генә аңа карап алды, әңгәмә дәвам итте. Һәм Наилә, коты чыгып, шушы арада бульдозерлар килеп сары йортны җимерәчәкләрен белде.

Эше эш булмады, биш-ун минут саен профкомга чапты, ике көн рәттән сагалады Наилә Латыйповны, шәүләсен күреп калгалады, әмма профсоюз лидеры җир бүлү, су, электр үткәрүләр белән шулкадәр мәшгуль иде, койрыгын тиз генә бирәүгә дә тоттырмады. Ә сары йортта мәхшәр башланды! Ионыч, квартир саен йөреп чыгып, хуҗаларны кисәтте: «Тиз-тиз моннан таясыз! Кайда яшәгәнегезне чәчеп йөрмисез. Алай-болай судка-фәләнгә чакырсалар, җавабын таба белегез!» «Суд» дигәнне ишеткәч, карчык-корчык төенчеген төйнәп, үксеп җылашып, кая барырга аптырап, урын эзләргә кереште. «Җир-мазар алсак, палатка куеп булса да җәйне үткәрер идек. Көзгә кадәр вакыт бар, ничек булса да куыш әтмәлләрбез!» — дип сөйләштеләр Нәҗип белән Наилә. Эш җиргә терәлеп калды. Җир бердәнбер һәм актыккы өмет иде!

Җомга кичендә, хезмәткәрләр кайсы кая таралышып, тузан исе аңкыган коридорда Наилә Изил Бәдретдиновичны куып тотты, әрсезләнеп кабинетына ук барып керде. Изил орышмады, кабынмады, йөз сүрәнлеген куеп, бер елмайды, кергәч ишекне бикләп, ачкычны өстәл тартмасына ук салып куйды. «Гаҗәпләнмә, Наилә, бу гади саклык чарасы гына. Җир бүлә башлаганнан бирле ничә төн йоклаган юк, тәрәзә астыма килеп күмәкләп кычкыралар. Ришвәт китерәләр, коньяк кыстырып керәләр, обкомнан шалтыраттыралар. Туй үткәч — дөмбергә, юк бит инде җир, бетте, гөл чүлмәгенә салырлыгы да калмады. Күз ял итәрлек берәр кешегә зарыккан идем, сине күрергә булган икән! Бездә бит шул хәл: халык — сарык көтүе! Кәҗә тәкәсе кая бара, савылып шул якка ябырылалар. Бәлки, кәҗә тәкәсе дурактыр? Аны уйлаган юк. Дача дигән сүз таралуга, завод шашты. Адәм балаларын шултиклем комсыз, күремсез һәм көнче дип белми идем. Китте берсе өстеннән икенчесенең әләкләре, дәгъвалары! Донослар! Ярый, утыр син, термоста сөтле чәем бар. Рәхәт, сиңа җир кирәк түгел, болай хәл белергә кергәнсеңдер?»

Изил шкафтан термос чыгарып, куе зәңгәр чынаякларга чәй агызды. Наилә түзем генә күзәтеп утырды да йомышын әйтеп салды. «Түгел әле, Изил Бәдретдинович. Мин җир сорарга дип көтә идем сезне. Безгә дә өлеш чыгарырсыз дип ышанам». Ышанычын дәлилләргә көче юк иде хатынның, көчсезлектән ике бите яна башлады, тавышы калтырады. Латыйпов күтәрелеп бәрелмәде, бераз уен үлчәп торды, чынаякны Наилә алдына куеп, үгет бирергә тотынды. «Дача — байлык. Йорт-җире, җиһазы, һич югында, машиналы кеше дача артыннан чаба. Дача — кешенең тормышы көйләнгәнлеккә бер дәлил. Белүемчә, сезнең торыр җирегез юк, Нәҗибең дә эшләми шикелле, аны урнаштырырга да ашыкмыйлар. Шулаймы? Нәрсәгә сезгә дача?! Артык акчагыз кесә тырныймы?» Наилә Изил Бәдретдиновичка озак казынырга ирек бирмәде, юкса дилбегә аның кулына күчәчәк иде! «Дачаны сез тормыш йомгагы дисез... Ә без кешечә кыланмаска булдык! Без азактан, муллык дәлиле дачадан башларга телибез!» — «Синеке кеше төсле генә булмас инде!» — дип авыз ерды Латыйпов, эчә башлаган чәен читкәрәк эшереп. «Синеке» дигәндә аерым тыныш ясады. «Дөнья басты, Изил Бәдретдинович, теләгәнчә яшәү мөмкин түгел икән!»

Изил, өстәл артыннан кубып, Наилә янына күн диванга килеп утырды. «Син, Наилә ханым, ирен сатып йөрүче ачык авыз түгел. Сүземә кушылмассың да... Ә ирең — шыр тиле! Ничек сине кулына төшергәндер, акылыма сыймый. Яши белми Нәҗип! Асылда сине яратмый ул. Яратса, шултиклем җәфалар идеме?»

Латыйпов, Нәҗипнең гаеп-кыекларын, ялгышларын саный-саный, Наиләгә якынлашты, чиркандырып өшетеп тән тәнгә тиде, ләкин Наилә тартылмады, ул ике куллап диванга ябышкан, купмаска тотынган иде.

Җир кирәк аңа бүген! Җир!

Комсомолда тәрбияләнгән, профсоюзда азау теше ярган, меңнәрнең күңеленә рөхсәтсез кереп гадәтләнгән Латыйпов Наиләнең ни өчен йөргәнен ишек бавына тотынгач та белгән иде. Биленә кул салуга, сыгылып төште хатын, күз яшенә буылып Латыйповның тезенә капланды. «Ярый, — диде Изил, кипкән иреннәрен ялап. — Өч-дүрт сутый җир табармын. Монда бер четерекле нәрсә бар. Җирне без Зеленодольск райбашкармасы белән килешенеп алдык, рәсмиләштердек. Көтмәгәндә шул участок белән шәһәр советы кызыксынырга тотынды. Хәзер ике арада тартыш бара. Дөрес, безнең завод җирле советларга буйсынмый, төкермибез дә без аларга! Шулай да аларның бер-бер этлек кылырга җайлары бар. Бер мичкә балны бер кашык дегет боза! Шәһәр советы белән чыккан низаг-гауга халыкка мәгълүм. Шуңа күрә җир алып өлгергән кешеләр эшкә тотынырга базмыйчарак торалар. Көтәләр. Эшкә керешеп, агач утыртырсың, йорт сала башларсың, ә җирне горсовет тартып алыр! Инде биш-алты хуҗа, тәвәккәлләп, йорт җиткерә башласа, тиз-тиз тезеп агач утыртса, җирне бездән тартып алу читенләшә! Кыскасы, шарт мондый: мин сезгә җир бүлеп бирәм икән, сез икенче көнне үк йорт салырга тотынасыз, һәм эшне бик коры тотасыз! Шул очракта гына мин җәмәгатьчелеккә, халык контроленә нилектән сезнең гаиләгә участок бирелүен аңлата алам. Югыйсә гариза биргән дүрт йөз кеше җирдән күзен алмый! Җир синең исемдә булыр, җаныкаем».

Изил Ленин, Маркс, Брежнев, Суслов, Романов, Мжаванадзе, Черненко томнары тыгызлап тутырылган ялтыр-йолтыр шкаф янына килде дә әллә каян, арттан, йомшак поролон сырма тартып чыгарды, аны пөхтәләп, таслап идәнгә җәйде, чалбар төймәләрен ычкындырды һәм күзләрен зур ачып, куркынган өрәктәй калтырап торган Наиләгә: «Син ни көтәсең тагын?» — диде...

Латыйпов Наиләнең тән ләззәтенә шаккатып, Наилә җирәнеп, хурланып, икесе ике якка тәгәрәделәр. Наилә как идәнгә үк төште, аның җан ачысы белән кычкырасы, Изилнең ямьсез елтыраган бәбәкләренә төкерәсе килде. Ә теле бөтенләй бүтәнне, зарын сөйләде. «Кирәктер дә, кая инде безгә алай ашыгыч йорт җиткереп керүләр! Син андый авыр шарт куйма безгә, зинһар. Җәллә безне». Профсоюзның карашы, тавышы үзгәләнде: «Анысы инде, Наилә кояшым, ирең мазасы булсын. Ир исемен йөртә икән, шундаен дан хатынга өйләнергә җөрьәт иткән икән, Нәҗибең кайгыртсын! Кем сораса да, җавабың бер булсын: байтак еллардан син завод китапханәсендә эшлисең, җир сиңа мин әйткән шартларда бирелде. Бетте-китте».

Наилә өенә туры кайтмады. Тормышының бүгеннән нык үзгәрәсен ул бөтен тулылыгы белән аңлый иде. Тормыш, мәхәббәт, балаларга мөнәсәбәт кайсы якка борылып керер, ул бу хакта уйларга әлегә курка иде. Моңарчы табынган әдәп-әхлак кануннарын ул бүген таптап үтте. Ул җинаятьне авыру ире һәм чир алдында торган балалары хакына эшләде, бүтәнчә булдыра алмады. Үзгә юлны тапмады. Хәзер аның саф күңеленә хуҗа булып мәңге онытылмаслык, тәүбәгә килсәң дә юылмаслык авыр гөнаһ калды. Ул шул хәлендә, яшәгән җире сары йорт кына булса да, кайтып күренергә гарьләнде, юл уңаенда мунчага керде. Бик озаклап тәне күгәргәнче, сызлаганчы салкын су астында торды, аннан шау кайнар су җибәрде. Салкынны да, эссене дә сизмәде, тәне дә җаны кебек үк үзгәргән иде. Ул үз-үзеннән гафу үтенеп, ләүкәнең биегенә менеп, дулкын-дулкын чәчләрен күгелҗем юшкын ямьсезләгән түшәмгә тидереп торды...

Аның: «Изил Латыйповны эзәрлекләп вакыт үткәрдем, гариза язып, ялынып кергән идем, безгә җир бирделәр. Кайтышлый кызлар белән мунча кереп чыктык... Җирен бик мактыйлар»,— дигән көтелмәгән хәбәрләрен тыңлагач, Нәҗип хатыны сөйләгәннәрнең төбен дөп-дөрес аңлады. Йомышы төшкән хатын-кызларны кулы аша үткәрергә яраткан бәндәнең хикмәтләре хакында күптәннән чыш-пышлар йөри иде. Баш инженерның каенише булган ач күзгә кулы җитә алган кеше генә юк иде әлегә.

Төпченмәде, вакланмады, Наиләсен тукмап ташламады, куырылып, бәләкәйләнеп, җаны бер учка сыярлык булып калды. Йә, белде ди, сорашты ди, Наиләсе бәйнә-бәйнә сөйләп бирде ди. Ни үзгәрә? Бу заманда Нәҗип белән Наилә ни үзгәртә алалар?

* * *

Яши-яши һәр кеше власть белән очрашмыйча калмый, очраша, властьның көчен, аның кодрәтле хокукларга ия икәнен аңлау дәрәҗәсенә ирешә. Военкоматка чакыртып алып дурдомга ябарга әзерләгәндә, Нәҗип бу тыелгысыз дәһшәтле көчтән бер тапкыр котылган иде инде. Берлеккә котылса да, власть көченнән курку калды анда. Власть таянган гаделсезлекне, хаксызлыкны ачыграк күрде, әмма көчкә каршы бара алмады, ярым качып-посып, ярым битараф калып яши бирде. Власть көче гайрәтле кешеләрне дә чәнчелдереп төшерә, җаннарны вагайта, холыкларны бер калыпка салып, куркакка әйләндерә. Чөнки власть башына һәрчак куркыныч, кансыз, дәһшәтле кешеләр омтыла. Алар, көчлеләр, балтаны Изил Латыйпов кебек кан сөюче кигәвеннәргә, чебен-черкиләргә бирәләр. Власть башлыкларының мөгезенә кунган чебен дә кайчакта арысланга әйләнә, шулай яши. Моңарчы бу көч аннан ничектер еракта кебек тоела иде, хәзер язмыш аның арт сабагын укыта, ул бары тик Наиләсенең сафлыгын биреп кенә үзе өчен иртәгәге көнне яулап ала. Бүтәнчә аңа юл юк. Балта Изил Латыйпов кулында булса, Изил үзе Нәҗип белмәгән әллә кемнәр кулында.

Нишләмәк кирәк, шулай зур корбан биреп алынган бер кишәрлек җирне буш калдырырга ярамас. Чит-чите йөз атлам да булмаган җир өчен Наилә кешелеген ерткыч Изил алдына ташлады. Ә Идел-Чулман елгалары ярларының меңнәрчә гектар бәрәкәтле җирләре бер файдасызга сасып, корт үрчетеп ята. Бөек ахмаклыклар эшләнгән дәвердә кешенең туган җирен һәм үзен яклап бер сүз әйтергә дә хакы юк!

«Йорт, — диде Наилә. — Йорт салмасак, җирне бездән тартып алачаклар!» Квартирлары, машиналары, шкаф тулы бәллүрләре, калын-калын кесәләре булган күпләрне буш чыгымнардан коткарып, завод белән шәһәр советы тартышында алга чыгарга тиешле кеше Нәҗип булып калды. Йорт өчен Нәҗип үз-үзен сатарга тиеш. Артың белән киртә җимерә алмыйсың. Тик кемгә барып егылырга? Кемгә җанны кыйбатрак сатып булыр? Ул, йокы белән уяулык арасына чумып, үзе белгән бөтен кешеләрне уе аша үткәрә башлады. Ул белгәннәрдән иң көчлесе Иван Иванович иде. Әгәр абыйсы исеменнән йөрсә, мэр ярдәм итеп тә куяр. Ярдәменең әҗерен Сабит Йосыповичтан таләп итә башлагач, Сабит ни дияр? Иван Иванович властьның иң куркынычлы вәкилләреннән берсе, кәефенә ярамасаң, аңышмастан чәкәләштерсәң, Сабит белән аны юлдан тибеп кенә очырыр. Ярамый. Аңа якынаю куркыныч. Абыйсына да башны бирү ярап бетмәс. Аңламас. Гомерлек колы итәр. Фәридун Фазлыевта

булса икән көч! Юк шул, ул да Нәҗип шикелле үк көчсез, гаделләргә власть бирелмәгән, власть бүтәннәр кулында. Фәтхулла абзасына барып карыргамы? Бу юлы, элек тыңламаганнары өчен, йомшак сөйләп катыга утыртыр. Ул да баш бетәрлек шарт куяр...

Кемгә сатылырга? Нинди бәягә? Уе шадра Вафага барып җиткәч, тукталды. Вафа әрсез, карак, бур! Бүген аңа нәкъ шундый кеше кирәк.

Тартылган җәя бавы кебек гел киеренкелектә торгангамы, Нәҗип бәйләнчек чир хакында онытыбрак яшәде, күптән «йөрәк!» дип дерт итеп уянганы юк иде, бүген төн уртасында, сары йортны җимерергә теләгәндәй арлы-бирле поездлар үткәндә, ул хатынын төрткәләп уятты: «Үләм!» Наиләне караваттан давыл кубардымыни — очып идәнгә төште, ут кабызды, Нәҗип янына килеп баскач, дулкын-дулкын озын чәчен өскә чөйде һәм коры, җансыз тавыш белән сүзгә керешә: «Юк инде, аппагым, үлмисең. Үләргә рөхсәт юк. Җир алып эшкә керешергә дигәндә, башыңны җүләргә салып, ат тизәге тибеп йөрергәме?! Үлмисең, үтермим, рөхсәт тә бирмим. Мә, эч даруларыңны!»

Бүлмәгә валокордин исе таралды. Наилә шадра сөлге белән Нәҗипнең тирләгән муенын сөртте, беләзегеннән тотып тамыр тибешен санады, ничә икәнен әйтмәде. Нәҗип кинәт күзен ачып җибәрде һәм хатынының сыгылмалы нәзек билен, тулы, йомры балтырларын һәм нәфрәт тулган сихерле күзләрен күрмәс өчен ул борылып ятты.

**28**

Аны Вафа янына тиз генә үткәрмәделәр. Биш бармагына биш алтын балдак кигән, мыймылдап торган мут татар апасы, чатнатып, күзен дә йоммыйча: «Вафа Сафич в обкоме!» — дип кабатлады. Хәлбуки Вафа Сафич беркая да чыгып китмәгән, ул кабинетына кушып салынган аулак бүлмәдә башын юеш сөлге белән урап, үткән кичне онытырга тырышып, ахылдап утыра иде.

Гадәттә мондый хәлдә Вафа эшендә күренми торган иде. Бәхетсезгә гел вакытсыз дигәндәй, кичәге кунаклар арасында мөһим бер трестның бухгалтеры, күрер күзгә ипле, тотышы белән дә бик тыйнак бер ханым бар иде. Ханымның тол икәнлеге ачыклануга, Вафа ул якка карамаска, күз төшермәскә тырышты. Ханымны кыстамады, бокалын чәкештермәде, барыбер хәләле Шәмсия тол хатыннан көнләште. Шәмсия ханым, Вафа гап-гади «шадра тәре, көнлекче» чакта, көнләшүнең ни икәнен белми торган бәхетле хатын иде. Директор хатыны дигән дәрәҗәгә күтәрелгәч, күзе шарайды, шәһәрнең бөтен хатын-кызлары аның директор ире кочагына керергә чират торалар кебек тоела башлады. Кәттә хатыннарның шәп мебель артыннан юргалаганнарын ул белергә дә теләмәде. Иртән, Шәмсиясе йокыдан торып, сыртын игәүли, чыра пычагы белән җилкәсен кыра башлаганчы дип, Вафа чыгып ычкынды, иртәләрен ярата башлаган кофесын да эчеп тормады. Махмырдан газапланган ирне сүгеп игә китерергә азапланган хатын андый иртәләрдә ир күзенә аждаһа, җиде башлы дию булып күренгәнен беләме икән? Шәмсиясен аждаһа итеп күрәсе килми иде шадра Вафаның.

Күз-каш җимерелгән, танау чөгендер, муен тимгел-тимгел, авыздан сасы үләксәдән килгән ис тәме килә, укшыта. Нибуч, аулак бүлмәгә качып «обкомга барырсың»!

Кичә килсә, Нәҗип мыймылдык хатынның сүзенә ышанып, кара сарык сыман башын иеп, гафу үтенеп чыгып китәр иде: обкомда тек обкомда! Бүген инде — «юк!», көтмәсеннәр, ул төшеп калган чәкүшкә түгел, ул — җир хуҗасы Нәҗип, шул уч төбе хәтле кечтеки җирдән торып булса да үз хакын дауларга, дөньяда барлыгын расларга дип ният кылып чыккан кеше! Хәзер ул Наилә мыскыллаган, черек эскерт төбенә салып таптаган арыш чүмәләсе түгел, ул — киек каулап чапкан арыслан, ташбаш балыкларын буа төбендә йотучы чуртан, юлында очраган киртәләрне тибеп-тибеп аударачак баһадир! Шул җир бәрабәренә газиз хатыны Наилә сыткылы танау, камыт аяк Изил Латыйпов белән йоклап кайткан икән, Җир шарын үкчәләре белән тибә-тибә, «Мебель» кибетенә килеп кергән Нәҗипне бүгеннән тозакка төшерә алмассыз! Ул үткән төннән — замана кешесе, эшкә ашмас хыяллар тоткынлыгыннан ычкынган, әкияти мәгарәдән көнгә чыккан эшкуар! Вафалар төркеменә кушылырга ният кылган икән, бетте, аны юк-бар сүз белән шомарта алмыйсың бүген. Юлда килгәндә бер плитка шоколадны куен кесәсенә тыккан иде, шалт шуны бөрмә авыз, мыймылдык түш кулына! Елмайды, алтынланган йодрык язылды, вак-вак энҗе тешләр арасыннан тел очы күренеп калды. «Вафа Сафич мине үзе чакырды, ул минем яшьлек дустым!» — диде чатнатып Нәҗип. Моңарчы яшьлек дуслары юк иде аның, бүгеннән алары да булачак, беренчесе, әйдә, Вафа Сафич булсын! Кирәкле кеше, директор!

«Алай икән?» — дисә дә, алтын тешле камыр беләк Нәҗипкә сынап, шикләнеп карады. Егетнең үз-үзен тотышында каушау сизелә, әле алган сабаклары җитәрлек түгел, авыллык чыгып бетмәгән иде. Теләнеп килгән меңнәрне күз алдыннан үткәзеп, кешене бер караудa танырга гадәтләнгән ханым алданды, Нәҗипкә үзе артыннан барырга кушып, «Рәхим итегез!» дип елмайды.

Башы ярылырдай булып чатнаган Вафа, затлы чалбарына ак тастымал салып, өстәлдәге кара икрага һәм мәрсин балыгы телемнәренә карар-карамас утыра иде. Бер-ике чәркә коньяк җибәргәндә үтә шәп буласы иде дә, гомергә әртилдә уралып күнеккән Вафаның ялгыз тамагына иң татлы ризык та бармый

иде. «О, Нәҗип! Профессор!» Махмырдан тилмергән хуҗа өчен көтмәгәндә килеп кергән, сер сыярлык кунак — хәзинә! Хәзер ямьсез баш төзәтү гадәти кунак сыйлауга әверелә, санламыйча һич ярамый: бердән, Вафа кунакчыл хуҗа, икенчедән, заманында хуҗаны төрмәдән аралап калган кеше килгән! Коньяк тартмасы белән, ризык мул — сандугач теле генә юк, урын аулак, мыймылдык хатын ышанычлы, Газраил белән Җәбраил парлашып килсә дә, «обкомда, обкомда!» дип пичәт сугып утырачак. Обкомда кабинетлар йөз, Ариадна йомгагы кулыңда булса, эзләп тап Вафа Сафичны лабиринттан!

Егерменче гасырның җитмеш фәләненче елында замананың йолкышы, бәхетсезе, МВД тәкъдиме белән психик яктан тотрыксызлар исемлегенә теркәлгән Нәҗип Йосыф улы Нургалиев һәм кыюлыгы, тәвәккәллеге, елгырлыгы белән Казан хуҗалары арасында бердәй дан казанган Вафа Сафич очраштылар. Затлы коньяк тигезсезлекне оныттырды, баш ачылып, чигәләрдәге вак-вак чүкечләр тукылдавы бетүгә, Вафа Нәҗипне кочаклап ук алды: «Брат!» Кичә булса, Нәҗип үшән ат кебек башын иеп, тәҗел йомыш белән район начальствосы катына килгән бичара крестьян кебек ялган чокырын кашып, учына йөткеренеп, картузын учлап-йомарлап кыймыйчарак торыр иде, бүген, шалишь, «шали камыш-шайкамыш! Шайлатабыз кызыңны!..» Брат тек брат. Ул Вафаның бүлтәйгән бүксәсен дә, шадралары тигезләнгән шома битен дә, кысылып эчкә чумган ясмык күзләрен дә күрмәде, салса, эчте, мәрсин балыгының калын телемнәрен майлы иреннәре арасына шудыра торды. Бүген алар тигез, Нәҗип — Вафа белән бер сафка басарга ниятләп юлга чыккан егет!.. Ниһаять, карыннар тулды, сулыш алу читенләште, изүләре чишелде, табынга сүз килде.

«Нинди нужа йөртә сине? — дип сорады хуҗа.— Ничек яшисең? Кайда эшлисең? Ни хәлләрең бар?» — «Эшләмим. Яшәр җирем юк. Идел буеннан дүрт сутый җир бирәләр. Шунда эт оясы хәтле генә булса да куыш әтмәлләргә иде исәп».— «Йорт салырга ниятләгән акыллы баш әүвәл савым сыер сайлап ала».— «Сыер белән нишлим мин?»

Вафа шаркылдап көлеп җибәрде: «Сабый бала икәнсең әле һаман! Сыер — мал табарлык эш дигән сүз, имәрлек төшемле эш табасың да савасың гына! Кем үз акчасына ярда йорт сала?.. Хәзерге заманда эшсез йөргәнең өчен ыштаныңны салдырып сыек чыбык белән сугарга кирәк! Җүләр! Җүләр! Хәзер бит... акча агып килә торган чак!» — «Суктыр, кыйна, чабакла, өй корырлык такта-токтаңны гына бир!»

Вафа ясмык күзләрен йомып беравык уйлап торды да кинәт: «Миңа эшкә киләсеңме?» — дип сорады. «Кем итеп аласың?» — «Грузчик итеп алам. Гарьләнмә, холкыңны хәтерлим, эш сорап миңа һәр көн биш-алты кеше килә. Грузчик булып урнашыр өчен хәзерендә җиде-сигез меңне чыгарып салалар!» — «Ә директор булып урнашыр өчен күпме сәмән чыгарып салырга кирәк?» — «Минем урынга үрләмә, аңа синең баш җитми. Ә болай... егерме меңнән дә ким түләнми андый урын... Шикләнмә, мине бушлай, югарыдагылар чакыртып алды. Андый хәлләр дә була. Менә мин сине бушка яллыйм лабаса!»

«Кайчан да булса бер костырырсың!» — диде кунак, айнып. «Костырмам. — Шадра кеткелдәп көлеп җибәрде. — Вакыты җиткәч, эш сорармын. Болай гына куеныма алырга син минем үгәй малаем түгел! Ике уйлама, кил, урнаш. Яшә, бүтәннәргә дә ирек бир». Нәҗип Вафаның тирләгән беләгенә ике куллап ябышты: «Ни кушсаң да үтим! Соңгы чиккә килеп җиттем, бетәм. Ярдәмеңне кызганма, якты көндә адәм арасына чыгарга оялам. Хатын янына ир булып ятарга хурланам».

Кадрларны сайлый белә Вафа Сафич: хәзер аның кибетендә йөкче булып ике доцент, рестораннан куылган югары категорияле бер пешекче һәм баш механик янына физик Нәҗип Нургалиев тә килеп кысылды. «Һәй, кайда сез анда, доцентлар, повар белән механик кая олаккан? Менә бу чибәр физикка җиһаз сүткәндә калган такталардан бер машина сыртлап төягез дә... әй, бакчаң кайда диден әле? Әллә йоклаган инде?.. Эчкәч йокласа да ярый, бүтән чакта аек һәм хезмәткә әзер булсын!»

Механик белән пешекче сары йортны белмиләр икән, доцентларның булып чыкканнары бар, ахрысы, Нәҗипнең кайда яшәгәнен белгәч, бер-берсенә карашып көлеп куйдылар.

Нәҗип кичкә кадәр караватта аунады, коса-коса җаны чыкты, Вафа Сафич кебек баш төзәтеп рәхәтләнә алмый, Наилә кайтасы, балаларны бакчадан аласы бар. Грузчик булып ялланганын әйтергәме хатынга, юкмы?..

Наилә көндәгедән соңрак кайтты, балаларга бирәр саплы калач тоттырды, көмеш тәңкәләр бизәгән өр-яңа сумкасыннан йөз кырык ике сум акча чыгарып, бераз кыланып өстәлгә ташлады. «Профсоюздан, ярдәм фондыннан бирделәр». Нәҗипнең башы урталайга ярыла иде, моңарчы бер дә тәтемәгән «фондтан» нигә бүген баллы яңгыр яуганын тикшеренеп тормады. «Яхшы булган», — дип мыгырдады. «Балаларны Аккош күленә пионер лагерена озаталар, безнең малайларны да җәйгә шунда урнаштырырга урын бирәләр. Син ризамы?!»

Наилә, чит бусаганы атлап кергән сәер кунак сыман, чишенмичә, өс-башын алыштырмыйча, тузан баскан идәнгә карап утыра иде. Кинәт урыныннан купты да тәрәзә каршысына килеп тавышсыз гына җыларга кереште...

Иртән беренче сүз шул булды Наиләнең: «Латыйповның сине күрәсе бар, соңарма, кагыл! — диде. — Бакча хакында киңәшәсе бар бугай».

Балаларны Наилә алып китте, Нәҗип аптыраушта калды, Вафа белән очрашуның азагы бөтенләй онытылган иде. Ничек дип килешүләрен һич хәтеренә төшерә алмады.

Ахыр чиктә әүвәл башта Латыйпов янына кагылырга булды, троллейбуска утырды. Уң кулының урта бармагына эт тырнагы чыккан икән, шул җанга тиеп, тынычсызлап бара иде, тырыша торгач, эт тырнагын канатып, тамыры белән йолкып чыгарды. Башы әз-мәз рәтләнгән кебек булса да, җанын һаман нидер тынычсызлады, караса, сул кулының урта бармагына да эт тырнагы чыккан! Тешләп тарта торгач, анысы да тамыры белән йолкынып чыкты. Ага гына кан! Тырнак төпләрен баш бармаклары белән кысып тора, җанга һаман тынычлык килми! Аяк киемнәре кыса, аркасы кычыта, тамагы яна. Иелеп караса, ике аягына да сул туфлиләр кигән икән!.. Борылып кайтып, туфлиләрне алмаштырып кияргә кирәк иде, кайтмады Нәҗип, «Йә эшем уңмас!» дип шигәйде. Әле болай да Латыйповның аны бик күрәсе килеп тормыйдыр...

Ул, уйларын учына җыеп, үзенең кая һәм кем янына баруын исенә төшерде. Изил Бәдретдинович Латыйпов янына бара Нәҗип. Ике ир күзгә-күз очрашачаклар. Көндәшләр. Икесе дә Наиләнең упкынга баш түбән ташлануын беләләр. Әгәр хәзер Нәҗип, дуылдап барып кереп, профсоюз эшлеклесен кара яндырып тукмап ташласа? Бәлки әле, соң түгелдер? Наиләне упкын читеннән тартып алып булыр? Нигә аларга шулкадәр югары бәһагә сатып алынган җир?! Дачасыз яши алмаслар идеме? Вафа аны дача хуҗасы булган өчен ялламады лабаса?!

Карый Нәҗип: эт тырнагы атсыз бармакларына да чыккан... Ул аяусыз кыланып үткер тешләре белән эт тырнакларын чүпләргә тотынды... Троллейбустан төшкәндә, Латыйповны хәтерләп бармакларын йомарламакчы була, юк инде, йодрык йомарланмый... Вафа белән килешенүе, яллануы исенә төшкәч, Нәҗипнең гайрәте шиңде, Латыйповны тукмап ташлау уеннан кире кайтты. Әгәр кичә иртән, Вафа катына барып егылганчы очраса икән Латыйпов!.. Әле ул чагында, тукмап ташларга йөрәге җитмәсә дә, үзенең моңарчы сыенып яшәгән тыныч тормышыннан торып Латыйповның чыраен бозарлык тозлы-тозлы сүзләр әйтә алган булыр иде. Бүген хәленнән килми, чөнки бүген ул элеккеге Нәҗип Йосыф улы Нургалиев түгел, ул ике доцент, бер пешекче һәм баш механик белән ике тәртә арасына кереп баскан кол. Вафа Сафич дигән шадраның колы. Мыймылдык түшле секретарь колы. Нәҗип аша эш йөртүче югары сыйныф вәкилләре булган бик күпләрнең колы. Бүгеннән ул Наиләсенең дә колы...

Казна йортларына, мәңге бетмәскә сеңгән исле коридорга барып кергәч, ул үзенең шушы йорттан ничек-ничек куылуын, мыскыл ителүен уйлап, күңеле суык тешләгән камыр кебек җебеде. Профком ишеген ачуга, өстәл янында иелеп кәгазь караштырып маташкан Латыйпов кулына беренче килеп кергән көмеш акча сыман ялтырап килеп җитте, иңеннән кочып, аны шомарган кәнәфигә илтеп тә утыртты. Утыруга, Нәҗип кычкырып җибәрде, кәнәфинең кадагы чыгып тора икән, йомшак җиренә - кадалды...

Изил Латыйпов Нәҗипне камап, эләктереп алды, сүз әйтергә ара калдырмады. «Килдеңме? Шәп! Тиз сал йортыңны, җәһәт кылан! Сезгә илле тугызынчы кишәрлек. Юл якын дип зарланма! Тимер юл белән ике арада имәнлек! Имәнлек түгел — оҗмах бакчасы! Йөз, мең ел торачак ул имәннәр! Стена! Крепость! Балаларың, оныкларың аннан рәхәт күрәчәк!.. Идел буенда юк хәзер андый имәнлекләр!.. Поезд тавышы үтеп керү түгел, американнар атом бомбасы шартлатса да, имәннәр сезне саклап калачак. Участок түгел — хәзинә».

Нәҗип ни дияргә аптырады, канлы, көчсез бармакларын яшерергә тырышып: «Кая барсам да тимер юл сагалады мине! Җык күрдем мин аның тавышыннан!» — дип зарлангандай итте.

Сүзгә йөгерек Изил әңгәмәдә сүзне чуалтырга гаҗәеп оста иде. Бу юлы да ул, капылт борылыш ясап, Нәҗипне бөтенләй бүтән тыкрыкка алып керде: «Әгәр дача йортыңны күз ачып йомганчы өлгертеп, төтенеңне чыгарсаң, валлаһи дип әйтәм, директорга керәм, лабораториягә кайтаруларын сорыйм».— «Булмас,— диде Нәҗип, баш чайкап.— Психушкада учетта торучыны почтовый ящиккә алалармы соң? Арттыр, Изил, тик чаманы онытма!»

Латыйпов бу фикерне ишетмәде, Нәҗипнең бер алдына, биш артына төшеп сикергәләде. «Сүз бар! — диде ул, чыраен сытып.— Шуңа чакырттым!» — «Әйт»,— диде Нәҗип, юаш кына. «Без монда уйлаштык... Сине саксызрак кыланып чыгардык, ахрысы...» Нәҗипнең җайсыз тырпылдаган йөрәге кысылып алды. «Җирдә беренче булып йорт сала башлавыгызны баш инженерга җиткердем. Ул үз чиратында директорга әйткән. Сезне алда байтак чыгымнар көткәнен искә алып, без Наиләне китапханәдән баш инженерның секретаре итеп күчерергә ниятлибез. Мин, барыннан да элек, синең белән киңәшергә уйладым. Без — дуслар, син — Наиләнең ире, каршы килмәсәң, Наилә иртәгәдән Израил Моисеевичта эшли башлый».

Ниһаять, Изил бертуган апасының ирен — Израил Моисеевичны исеме белән атады. «Хезмәт хакы китапханәгә караганда ике мәртәбә артык. Квартал саен айлык зарплата күләмендә премия. Без монда профсоюз хисабыннан да әзрәк булышырбыз. Йә, сүзең ни?»

Изилнең соравы үтенеч булып түгел, боерык булып яңгырады. «Наилә ризамы соң?» — диде Нәҗип, иреннәренең калтыравын җиңәргә тырышып. «Риза. Гомере буе китап тузаны иснәп утырмас ич?! Эш җиңел булмас, утырышлар, киңәшмәләр булганда соңга калып та кайтыр. Үпкәләштән түгел, мыегыңа чорнап тор». Нәҗип йомшак кәнәфигә тагын да ныграк чумды, баягы кадак әллә бөгелде, әллә читкә авышты, — күмелде Нәҗип, башы гына күренеп калды. Изил шукланып аның чыгынкы арт чүмеченә чиертте. «Тәмам! Минем ашыгыч эшләрем бар». Нәҗип каударланып сикереп торды, үз теле белән явыз дошманына, көндәшенә рәхмәт укыды. «Ул... профсоюз хисабыннан дигән ярдәмне... озаклатма инде, Изил дус».— «Йә, йә, белмимме әллә? — диде Изил, үзенә сузылган юаш кулны ике бармак очы белән кысып.— Вакланмыйк! Без — кешеләр!»

Ишеккә кадәр озатып, ул дымлы учын Нәҗипнең түбәнгә салынган иңбашларына куйды да әллә шат, әллә явыз тавыш соңгы хәбәрен җиткерде: «Ә! Ни... Әйтергә онытып торам икән! Казна эше артыннан чабып ми тубал булган! Ни иде... Наиләне квартир чиратына беркеттек. Шактый сүзләшергә, тирләргә туры килде. Әмма ләкин мин сезне ел ярымда, һич югында, ике елда фатирлы итәм!»

Нәҗип телсез калды...

**29**

Үзгәрешләр икесенә берьюлы килде: Нәҗип алак-шалакланды. Элек аяк киеме чисталыгына аерым игътибар биргән кеше хәзер үкчәләре ашалып ямьшәйгән, баулары өзелеп-төенләнеп беткән, кара лайга манчылып каткан туфлиләрен кия дә рәхәтләнеп йөри. Таң туса бите аллангачы кырына торган ир хәзер йоны иләнгән щеткага әйләнгән ияген кашый-кашый ашый, җитү сакалына ябышкан бәрәңге кисәкләрен сөртергә онытып, фуражкасын алдын артка киеп чыгып китә. Кием-салым, өс-баш — иясенең кәефенә тиз яраша, иясенең кемлеген әллә каян кычкырып килә. Озын буй, өстә әллә кайчаннан искеләр арасында аунаган аксыл плащ, тезе сизрәгән лавсан чалбар. Урамда очраган сукбайлар, алкашлар, йолкышлар, болай гына исерекләр, ямьсез ис аңкыткан хатын-кызлар, бүтәннәрдән аерып, аңа күз кысалар, сүз каталар, үз итеп санауларын белдерәләр иде. «Син юньлерәк киенеп йөри аласыңмы-юкмы?!» — диде беркөн Вафа, йөзен чытып. «Миңа ярый!» — дип куйды Нәҗип, исе китмичә генә.

Наиләгә тәмле тел кайтты. Малайларын җырлый-җырлый сөя, бии-бии ашата, иренә «Нәҗибем» дип кенә дәшә, үзенә «Наиләм» дип мөрәҗәгать итүне сорый. Көне буе саллы-саллы тартмалар күтәреп, астан өскә, дүртенче, бишенче катларга чабып йөреп кайткач, тез буыннары йомшый, иң өсләре чиләнә, култык аслары тирдән әчи. Мондый чакта «Наиләм» дип юхаланасы килми Нәҗипнең, дөнья аклыгы күзгә күренми, усалланып малайларны да читкә тибәрә. Ә Наилә! Кайткан саен сумкасында малайларга күчтәнәч була. Искәндәр белән Рөстәм хәзер шоколадны бүселгәнче ашыйлар, кәнфиттән тамак төпләре сызлый, прәннекләрне идәндә алка итеп тибеп йөртәләр.

Бер юанычы бар Нәҗипнең, Наилә эшендә озак мавыга, әле утырыш була, әле җыелыш, әле җыелыш беркетмәләрен яңадан күз йөртеп төзәтеп чыкканнар, «кырыкмаса-кырык эшем көтеп тора, миннән башка нишләрләр икән алар, бичаралар, Израил Моисеевич мине гел мактый, «Син минем уң кулым!» дип атый», — хатынының бу сүзләренә ул ияләнеп тә килә... Хәтта эштән кайткан мәлләрдә Наиләнең өйдә булмавын, эшендә озаккарак тоткарлануын тели, кайта, ашый, «якаң ник керләнгән?», «нигә кырынмадың тагын?», «ник мунчага бармыйсың?» дип быктычланучы юк. Иң читене: авыр сүзләрне дә Наилә тәмле теле белән, көлеп-елмаеп, ире тирәсендә күбәләк булып очып тәкрарлый, шул сәбәпле сүзләрнең тәэсире тагын да авырлаша, Нәҗипне рәнҗетә иде.

Алар байтактан бер караватта йокламыйлар. Нәҗип кайта да, аннан-моннан чишенеп ташлап, идәнгә тәгәри, Наилә озаклап көзге каршысында бөтерелә, тәненең төрле җирләренә ислемайлар, кремнар, лосьоннар сөртә. Беркөн, балалар тирән йокыга талгач, поезд тавышлары тынгач: «Нәҗип, иснәп карачы, миннән җофар исе килә!» — дип дәшкән иде, Нәҗибе ухылдап борылып кына ятты.

Җофар исен белми иде Нәҗип, белергә дә теләми иде. Наилә Гөлнаралар белән бергә көнен саунада үткәреп, аның тәне дә массаж, бал кебек нәрсәләрне татыган иде...

«Ир — баш, хатын — муен» дигәннәр. Тату чакта бу гадел хөкем эшкә ярап тора, гаиләнең асылына шайтан хуҗа булып алганда, «ир-баш» кәбестә күчәненә әйләнә. Дошман ирдән дошман хатын утын түмрәне ясый. Үзгәрешен, аның сәбәпләрен яшереп тормады Наилә, яшерүне кирәк дип тә санамады, өйләнеп хатыныңа лаек тормыш кора алмагансың икән — үзеңә үпкәлә, аппагым!

Соңыннан, байтак вакыт үтеп, көннәр-айларның гына түгел, гомернең дә кадере калмаганда, Нәҗип идән мунчаласына, Наиләнең карышусыз колына әйләнгәч, уллары «әти!» дип түгел, «әй!» дип кенә кычкыра башлаганда, «әллә бу зинданнан ләхеткә күчәргәме?!» дип әйле-шәйле йөргән бер мәлдә, ул

адашып кына Фәридун Фазлыев янына барып чыкты. Хуҗа өйдә берьялгызы, көн шактый җылы булса да, җилкәсенә иске буй-буй халатын салып, ачык тәрәзә каршысына басып нидер уйлана иде. Ишек бикләнмәгән. Нәҗип шакып та, звонок шылтыратып та тормады, барды да керде. Аягын салганда, туфлиләренең җимерек борыннарын, сүтелгән җепләрен абайлап, күз күрмәс төшкәрәк, эчкә эшерде. Сүзсез генә кул бирештеләр. Сүзсез генә диванга барып утырдылар. Озак кына берни сөйләшмәделәр. Фәридун Фазлыев: «Апаңны больницага салып кайттым... Йөрәге менә сүнәм, менә сүнәм дип көчкә-көчкә тырпылдый. Йөрәкнең чын сызлануы әнә шулай була ул, Нәҗип туган!.. Мине төрмәгә илтеп тыкканда, апаң уникенче больницада хирургия бүлегендә шәфкать туташы булып эшли иде. Яраталар иде аны!.. Мин төрмәдә, җитмәсә, шул көннәрдә баш врач итеп бер исерекбашны китереп утыртканнар. Операцияләре ташка үлчим, туный бу тере җаннарны... Берсендә, операциядән соң, авыруның эчендә нәни генә кайчы калдырып тегә... Эчеп килгән икән, юньсез!.. Гаепне апаңа сылтыйлар, берчакта да шифаханәләргә кермәслек закон белән эшеннән куалар. Апаң тасма туку фабрикасына барып яллана. Үткән-сүткәндә игътибар иткәнең бармы: Кремль астында гына ул фабрика! Тавыш, тузан, хәрәкәт. Кышын суык, җәен эссе. Мин кайтканчы шунда эшләгән Фәридәм. Шуннан йөрәк авырулы каста булып чыкты, гомере буе мантымады».

Фәридун Фазлыев иң тирән кайгыларын уртаклашып, әз-мәз теләктәшлек, юаныч эзләп сөйләп торса да, аның сөйләгәннәрен Нәҗип колагына да элмәде, ишеттеме, ишетмәдеме — билгесез, аның ми тартмасы авыр уйлар белән болай да шыплап тутырылган иде. «Әле янымда Наиләнең җылы кулы бар дип яшәгәндә бирешми идем. Тәне янымда калса да, җаны еракка очып китте хатынымның. Шул екты мине. Шул харап итте. Яшәү тәмен югалттым. Каты авырганда «авыздан тәм китте» диләр бит, шуның кебек менә... Җаным зарыгып уңга-сулга каранам — юк Наиләм! Бергә торабыз анысы, балаларны карый, ярата да кебек. Ләкин аның тормышында мин әллә кайчаннан юк, күрми мине. Шуны сизеп яшим. Чит күләгә белән гомер кичерәм. Нишләргә? Ни кылырга?»

Фәридун Фазлыев, үз кайгысына баткан булса да, Нәҗипнең һәр сүзен ишетте, сүзләрен уйга әйләндереп күңеленә тезә барды. Түзем тыңлады, иң актыктан, егетнең шик-шөбһәләрен ачыклагач, йомгак ясап куйды. «Син, егет, күрәм, дөньяга баш бирдең. Авырлыкларны җиңәргә омтылмадың, алардан качарга тырыштың. «Мин алай, мин болай!» дип, адәм баласы күпме гайрәтләнмәсен, бу дөньяда ул ком бөртеге генә! Сахра җилләре ком бөртеген ары-бире куып йөрткән кебек, хәзерге заман кешесен власть ихтыяры, законнар чүп урынына очырта, тоталитар илләрдә, ягъни бездә, беркем дә үз язмышына тулаем хуҗа була алмый! Ил башына берәү менеп утыра да без шуның кәефен саклап яши башлыйбыз! Россия бер чакта да демократияне татыган ил түгел. Коллар иле ул! Рус философларыннан берәү — Николай Бердяев исемле акыл иясе болай дигән: «Ирекле булу авыр, җиңел булганы өчен адәмнәр кол булырга телиләр дә!» Язмышыңда коллыкны сайлагансың икән, үпкәләмә хәзер! Чакырдым мин сине, мәктәпкә урнаш, укыт, дидем. Эш табарга булыша идем. Ә син...»

Фәридун Фазлыев аңа акыл бирмәде, «аны эшлә, болай ит!» дип өйрәтмәде, мәгәр аның яныннан Нәҗип тынычланып, сабырланып кайтты. Ул теше-тырнагы белән эшкә ябышты. Ал-ялны онытты егет, көн сәгатьләре җитми башлады, төннәрен урлап-юллап бакча җиренә такта, бүрәнә, кадак ташыды. Вафа Сафичның боерыгын үтәп, аңа буйсынып, төрле шикле йомышлар үтәде. Үзенең ни эшләгәнен белеп бетермәде, иң гаҗәбе, белергә теләмәде, ачыкларга омтылмады, йокларга ятып, арыган - керфекләре ялганганда, элеккедәй татлы күк капусы ачылмады, кайгы хәбәрләрен тыңлаганда, йөрәге какмады, тәне ныгыды, тупасланды, элек дөньяга сөенеп тартылган күзләрен сыек томан каплады.

Әгәр күзен ачыбрак, зиһенен туплап караса, ул үзе яшәгән бәләкәй дөньяда да әллә ниләр туып алмашынуын, үзе катнашкан вак-вак эшләрнең дә баш китәрлек олы вакыйгаларга барып тоташуын аңлар иде. Сахра киң, офыклар ерак-ерак, ә Нәҗип Йосыф улы Нургалиев һаман ком бөртеге иде.

Ул тырышып-тырмашып, җан тирләрен чыгарып дача салып яткан тын уйсулык, асылда, шәһәрдә бик күп көчләрнең, бик күп югары дәрәҗәле кешеләрнең тартыш ноктасы иде! Тимер юл белән Идел арасында җәйрәп яткан, моңарчы кеше күзеннән читтәрәк булган уйсулыкка, уйсулыктан ерак түгел аулак йортка, кешесез болыннарда көрәйгән ала казларга мәхәббәте төшкән Иван Иванович хакында без бәйнә-бәйнә сөйләп үткән идек инде, шәт, иншалла, онытмагансыздыр. Әлеге бу җиргә профсоюз күркәсе Изил Латыйповнның, баш инженер зирәк Израил Моисеевичның, бигрәк тә генеральный директор Валериан Козецкийның бернинди мөнәсәбәте юк тыныч заманнар иде. Буш җирләрнең ял итәр өчен бик кулай булу ихтималы, ул тирәдәге коры, нарат исле һаваның сәламәтлек өчен уңайлыгы Израил Моисеевичның үтә сак колагына килеп ирешкәннән соң, ул бу җирне кулдан ычкындырмаска, ашыгыч эш йөртеп, уйсулыкны берләшмәгә беркетергә ниятләде. Бу эшне ул каенише Изил Латыйповка тапшырды. Козецкий белән киңәшмичә, аннан хәер-фатиха алмыйча эшкә керешергә ярамый иде, әлбәттә. Баш инженеры белән һәйбәт яшәгән, киңәшле эш йөрткән Валериан Леопольдович тәкъдимне бик теләп кабул итте. Ул да яңалыкларга үтә сизгер җитәкче иде, «кирәк булу ихтималы бар, халык, оешмалар дача җире алырга ябырылды, миңа атап ике участок тәгаенләп куегыз, алда күз күрер...» дип, тиешле үтенеч кәгазьләренә имзасын салды. Шәһәр советының, тимерьюлчылар һәм Зеленодольск райбашкармасы аша шушы җирне алырга йөрүләрен генеральный директор ул чакта

белми иде әле. Елгыр Израил Моисеевич, алда тартыш чыгасын искәреп, эшне тиз йөртергә боерды һәм моңарчы җизнәсенең һәр сүзен тормышка ашырып гадәтләнгән бурзай Изил Латыйпов, күргәнегезчә, эшне башлап та җибәрде. Нинди зур оешмалар, нинди кәттә кешеләр арасындагы көрәшкә тарыганын гамьсез, ваемсыз Нәҗип белми дә калды. Ул ярма ташлары арасына адашып килеп кергән бодай бөртеге иде...

Иван Ивановичның берләшмә директоры Валериан Леопольдовичка моңарчы да сырт йоны тырпайганы бар иде. Һич көтмәгәндә-уйламаганда арттан килеп пычак кадады Козецкий! Шәһәр активы Казан хуҗалыгының торышын тикшергәндә, Валериан Леопольдович сүз алып шәһәр транспортын, шуңа ялгап шәһәр башлыкларын тетеп ташлады. РСФСР коммуналь хуҗалык министрлыгыннан вәкилләр бар иде. Алар «Казан шәһәренең үрнәк чисталыгы өчен» Күчмә кызыл байрак тапшырырга килгәннәр иде. Байрак алган хуҗалар исеменә яңгыраган тәнкыйть сүзләрен күз алдына китереп карагыз! ЧП, гадәттән тыш хәл иде бу!

Бу «сыйнфый каршылык», бу талаш искиткеч нәни бер вакыйгадан башланды. Аңлашылсын өчен безгә үткән көннәргә кайтырга туры килер...

Дүрт-биш ел элек, әллә алты ук үтте микән, алар бер язда Матюшино ягындагы хөкүмәт дачаларына күршеләр булып урнаштылар. Иван Иванович балаларын иртә тараткан, аулак һәм тынлык ярата торган җан, атна эчендә күршеләрен дошман күрә башлады. Чөнки Валериан Козецкий, поляклар токымыннан булып, бала-чаганы үлеп ярата торган кешеләрнең берсе иде. Җәйнең иң матур көннәрендә улы-килене, ике балаларын ияртеп дачага чыгалар да җәй буе өлкәннәр белән мәш киләләр. Алты җан, арадан икесе шук малай, иртәдән кичкә кадәр бакча гөжләп тора, турникта атыналар, шаулап балыкка баралар, гөрләп кайтып керәләр. Кая ул тынлык! Сандугач тавышын ишетә алганы юк Иван Ивановичның! Хатынының көн-төн «убырлар»дан зарланып сукранганын тыңлап яшәргә генә кала! Җитмәсә, ул җәйдә Козецкийларга Ригадан өч балаларын ияртеп кунаклар кайтып төште. Ярамаганмы Балтыйк култыгында бу өч хулиганны асрарга, юк, алып кайтканнар җәфаларын, бакыр бугазлары белән таңнан тотыналар шауларга, җәһәннәмнең җиденче катына төшеп олагырсың...

Чуерташ атып Иван Иванович дачасының тәрәзәсен ваттылар — түзде, койма тактасын куптардылар — чыдады, капкага элгән йозакны алып китеп югалттылар — гауга чыгармады. Ә беркөнне түземе калмады, шартлады Иван Иванович, кырыкка ярылды...

Аның иң яратканы — әнис алмасы. Ал әнис. Исен ярата әниснең Иван Иванович, төсен, тәме дигәндә бөтенләй үлеп китә. Бакчада аңа иң затлы, иң кадерле, иң татлы сый — алланып, балланып пешкән әнис алмалары. Ул елда кыш суык килде. Инде яз җылынды дигәндә, алмагачлар ал чәчәкләргә күмелгәч, кичтән суытып, төнлә кар яуды да алма чәчәкләрен суык алды. Иван Ивановичның кадерлесе — әнис алмасында нибарысы егерме җиде яшел төймә яралды. Бер ботагы сау калган алмагачның, җитмәсә, ул ботак та Иван Ивановичның коймасы аша сузылып, күрше Козецкийлар ихатасында асылынып тора. Буш вакыты булган саен саный әнисләрне Иван Иванович, саный да юана: «Бишалтысын корт ашап, ике-өчесен җил койса да, атна кинәнерлек җимеш булачак әле бу юмарт агачта!»

Ризыкка язмаган икән быелгы алмалар, күңелне җирсетеп, авызга су китереп аллана башлаганда гына, Козецкий йортындагы бала-чагалар җыйнаулашып килгәннәр дә әнисләрнең сыңарын да калдырмыйча ашап бетергәннәр. Ботак очын сындырганнар әле, җитмәсә!.. Җиде яфрак чыгарган яшьяшь ботакны аямаганнар! Әй тузынды Иван Иванович! Әй җилкенде! Әйтмәгән сүз калмады! «Наданнар сез!» дип атады ул Козецкийларны, «ач бүреләр!» дип тамга салды... Кунаклары алдында читенсенгән Валериан Леопольдович дәшмәде, түзде, күршесенең җикеренүләрен күңеленең кара сандыгына салып куйды. Мәңге онытмаска... һәм моннан ары, җае чыкса-чыкмаса да, Иван Ивановичны тешләп уза торган булды. Казан урамнары пычрак икән, кадалып китсен, бер гаме юк Козецкийның шәһре Казанда... Әмма урам пычракларын ул җаваплы сессиядә мэрның чыраена атты!.. Алар дус-ишләре арасында, кулуарларда берсе хакында икенчесе әче анекдотлар, тозсыз гайбәтләр тараттылар. Инде менә маңгайга-маңгай бәрелешәләр, дача җирләре даулап, икесе ике яктан комарланып мәшһүр уйсулыкка килеп кергәч, берсенең дә баш бирәсе, юл сабасы килмәде. Канга кан! Ике арада астыртын, әмма кискен тартыш башланды.

Дөнья тәгәрмәче Козецкийлар, Иван Ивановичлар хакын хаклап туктаусыз әйләнә, көн вә төн туктамый, кара язмыш шушы туктамас иләмсез тәгәрмәчкә ике яктан Нәҗип белән Наиләне дә беркетеп куйды. Иван Иванович «Халык, шәһәр мәнфәгате өчен!» дигән утлы өндәмәләр чәчеп, җирне берләшмәдән тартып алырга омтылды. Валериан Леопольдович: «Эшче сыйныф — безнең илдә иң өстен сыйныф!» — дип, авызыннан социалистик очкыннар таратып, даны көннән-көн арта барган җирне үзендә калдырырга теләде. Кыскасы, шәһәребезнең абруйлы башлыклары бер кишәрлек җир өчен бер-берсен бугазлап ыргытырга әзер иделәр. Үтерергә ярамаганны белгәнгә, көрәштә заман һәм закон рөхсәт иткән алымнарны кулландылар. Һәр ике як төп корал итеп «эшчеләр сыйныфы, халык мәнфәгатен» сайлады.

Сүз арасында, Иван Иванович белән Басыйр Бариевичны аерата ярсыткан аерым фактларга күз ташларга да вакыт җиткәндер, мөгаен!

Тын уйсулыкка шәһәрдән дачниклар явы төшкәннең икенче җәендә Әнисә абыстайның уңган казлары ике ояга ундүрт бәбкә чыгардылар. Бүрекле бер ата, ике әнкә каз, ундүрт бәбкә. Саны ягыннан күп түгел түгелен. Мәгәр шуларны йөртергә дә урын калмады бу якта! Урам чирәменә куар идең, Әнисә абыстайлардан ерак түгел ике малай буй җиткереп, ундүртләре тулган көндә әткәләре тегеләрнең икесенә ике мотоцикл бүләк итте. Май башыннан июнь аена кадәр ике ташбаш, ике матай өч кәҗә бәрәнен таптадылар, ике песине үтерделәр, алар изгән бәбкә, чебешләрнең санына чыгарлык булмады.

Бәбкәләр саны сигезгә калды, арадан берсе — иң исәйгәне аксады. Алпан-тилпән йөрде дә югалды. Әнисә абыстай баш хастасы белән өч көн җәфаланды, казларын барларга күзе җитмәде, алар тимер юл аша үтеп урман авызына җим эзләп барып кергәннәр. Бер төн кайтмады Әнисә абыстайның казлары, иртәгесен өч бәбкәнең өем-өем мамыкларын яшен суккан имән астыннан табып алдылар. Әллә эт буган, әллә төлке ботарлаган, әллә усалларның усалы — ике аяклы ерткыч — кеше кул салган. Бәбкәләрнең азаккысын көзгә кергәч, бакчачылар урлап суйды. Күрүен күрмәде Әнисә абыстай, авылдашлары беравыздан дачникларны каргап, бөтен бәла-казаларны шуларга сыларга күнектеләр. Ул да: «Шулар гына харап итте казларымны, шулар гына!» — дип сөйләнеп йөрде, җае килгәндә хәбәрне улы — хөрмәтле Басыйр Бариевичка да җиткерде. Җир өчен талаш кызып кына килә иде, казларның һәлакәте Иван Ивановичка да барып иреште! «Җирдән куарга!» — дип боерды ул Басыйр Бариевичка, шелтә белән карап. «Ни кылыйк соң?» — дип, аның күзенә бакты Басыйр Бариевич, ялгыш утка төшкән яфрак кебек куырылып.

Дачниклар вак шакмакларга бүлгәләнгән җирне түтәлләр, сукмаклар, парниклар белән каплап, ашык-пошык алмагачлар, чия, кара миләшләр утыртып, карлыган, кура җиләге төртеп, җирне үз исемнәренә ныгытканда, Иван Иванович белән Басыйр Бариевич, иң алдынгы илдә яшәүче совет халкының ихтыяҗларын күздә тотып, гаделлек байрагы астында көрәшкә ташландылар.

Иван Ивановичта куәт бар, сүзе үтә — уйсулык кергән җирләрне, тирә-яктагы урман-кырлар белән берләштереп, Зеленодольск районыннан аерып, шәһәрнең Киров районына куштылар да куйдылар. Указ чыкты, гел уңайга кул күтәрергә өйрәтелгән ташкурчак депутатлар карарга закон көчен бирделәр, хәзер Әнисә абыстай яшәгән авыл, абыстайның җир биләмәләре, мәгърур имәнлек, аулак култыклар белән бергә, хөрмәтле һәм гайрәтле Иван Иванович карамагына күчтеләр. Форсат бар, законнар гадел, җай чыкты, күрсеннәр казанлылар рәиснең шәһәр хезмәт ияләре өчен янып-көйгәнен! Халыкка кирәк икән — Иван Ивановичның җаны фида! Шәһәр советы сессиясе чираттагы эшлекле утырышларының берсендә Әнисә абыстай налог түләмичә генә биләгән җирләрдә ял базасы, юллар, кемпинглар, көймә причаллары кору турында тантаналы карар кабул итте һәм бу чаралар шәһәрнең генеральный үсеш планына да кертелде. Бетте Валериан Леопольдович Козецкий! Совет власте хөрмәтле Иван Ивановичлар кулында чакта борыныңны бик чөя алмассың! Инде салына башлаган дача йортларын сүтәргә (арада иң беренче нәүбәттә төзелеп бетеп килгән Нәҗип Нургалиевнең йорты тар-мар килергә тиеш!), агачларны йолкып ыргытырга, түтәлләрне эз калмаслык итеп сөрергә дигән боерык язылды. Бульдозерчы, нәрәтен куен кесәсенә тыгып, машинасын кабыза ук башлады. Нәкъ шул иртәдә Мәскәүдән кунакка оборона министры килеп төште. Берләшмәнең хәрби аэродромында аны иярченнәре белән бергә Козецкий каршылады. О, Казан татарлары Мәскәү әһелләре дигәндә җитезләнәләр! Министрны Лаеш ягындагы аулак урманга кабан дуңгызы атарга алып бардылар. Ау гаять уңышлы булды, министр җәнаплары өч кабан дуңгызын, шул җөмләдән азау теше кер бәләге чаклы булып ян-якка сузылган ата чучканы мәтәлдерде. Китте тантана, китте бәйрәм, дуңгыз каны белән кулларын юып, ияк асты майларын дерелдәтә-дерелдәтә, учак тирәсендә «Әпипә»гә биеделәр. Учак тирәсендә бердәмлек, интернационализм рухы өстенлек итте. Хуш ис аңкыткан калҗалар шау күмердә куырылганда телләр тик торамы? Сүз арасында Козецкий үзенең кайгыртучан хуҗа булуын, завод эшчеләре өчен көне-төне тир түгеп яшәвен искәртте дә сүз дача җирләре, ял итүгә барып тоташты. Министр җәнапларына хуҗаларны мактарга җай чыкты, ул бу башлангычны кайнар котлады, һәм хуплау сүзләрен шул төндә үк Иван Ивановичка җиткерделәр. Шәһәр башлыгы мәҗлеснең уртасында булырга тиеш иде, Козецкий үчегеп аны чакырмады. Ачудан Иван Ивановичның теше сызлый башлаган иде, Мәскәү кунагының бакча җире белән кызыксынуын белгәч, аның тәмам һушы китте. Ул... юк, теш врачына түгел, сердәше, көрәштәше, ышанычлы көрәштәше хөрмәтле - Басыйр Бариевичка шалтыратты. «Тиз үк минем янга килеп җит!»

Нишләсен Басыйр Бариевич, хәләле җылыткан ятактан торып, Иван Ивановичны әчтән сүгә-сүгә киенеп, кабаланып, төче елмаеп, мэр янына барып җитте. «Вәт син әй! — диде ул, Иван Ивановичның шеш кунып ямьсезләнгән төксе чыраена карамаска тырышып. — Шәһәр башлыгы үз кул астындагы җиргә хуҗа була алмасын инде! Нинди заманага килеп җиттек. Өтек кенә директор кисәге бөтен дөньяны учында тотсын инде!» Иван Иванович аны туктатты: «Зар кирәкми миңа, анысы үземдә дә җитәрлек! Акыл бир миңа, фикер әйт! Юл күрсәт!»

Ахирәтләр, кара таңгача киңәшсәләр дә, җайлы карарга килә алмадылар. «Арага министр кадәр министр килеп кысылгач, монда ис чыгарып, төтен таратып кына хәл итә алмассың!»

Басыйр Бариевичның карлыгач оясы хәтле ачылган авызыннан министр дигән сүз чыгуга, Иван Ивановичның уйлардан авырайган зиһене яктырып китте. «Министр?.. Ә Шидловский Илья Ефимович?! Синең министрың юкмы? Хәзер ике министрны чәкештерергә кала!.. Ник элегрәк уйламаган без моны!.. Сине үзәк матбугатта нәрсә дип теттеләр? «Вагоннар станцада озак тоткарлана... Юллар җитешми... Чаралар күрелми... Тимерьюлчылар акрын кыймылдый» дип пешерделәрме?» Әле берни дә аңламаган Басыйр Бариевич Иван Ивановичка акаеп карап катты. «Шидловскийны сыйладыкмы? Сыйладык! Дуслаштыкмы? Дуслаштык! Мине өч тапкыр, сине ике мәртәбә үптеме саубуллашканда? Үпте!» — «Мине дә өч мәртәбә үпте! Мине дә!» — диде Басыйр Бариевич, җыламсырап. Министрның килүе исенә төшкән саен, аның күңеле тула, йомшара иде. «Министр янына барасың. Акча табасың. Бишьеллык планнарны үтәү максатыннан чыгып тимер юлларны киңәйтәсең. Һәм синең яңа юлларың нәкъ уйсулык аша үтә. Безгә булмаган икән, аларга да эләкмәсен! Бүген үк Мәскәүгә! Хәзер үк!.. Госпланны кузгатасың, проектны ашыктырасың... Үзең белән берәр дистә норка бүрек ал. Бикле капкаларны ач!»

Теш сызлаганда Иван Иванович чак кына җылы биреп затлы коньяк йоткалый иде, хәзер сызлауны да, кулындагы коньякны да онытты, өстәл янына сикергәләп барып җитеп, каләм-кәгазь алып, төзү, җимерү планнарын сызгалый башлады. Шәһәр башлыгының фикерен башта куанып элеп алган Басыйр Бариевич акылына да бер уй төште: «Ә имәнлек?! — дип кычкырып җибәрде ул, әрнеп. — Юлларны ишәйтәм дисәң, имәнлекне кисәргә туры киләме?!» — «Имәнлек җәлме сиңа, әллә безнең абруймы?! — дип күк күкрәтте Иван Иванович. — Шушы бәрелештә җиңелеп калсам, Козецкий нинди гайбәтләр таратмас! Имәнлек түгел, ярты күкне кыеп төшерергә кирәк дисәләр, мин анысына да кул куям! Чәнчелсен имәнлек! Әнә Америка өрәңгесе утыртсыннар! Биш елда дөньяңны баса!»

Иван Ивановичка кушылып, аның дәртен купайтып, «Шулай итәбез!», «Җиңәбез дошманны!», «Козецкийны кәҗәгә атландырабыз!» дип, Басыйр Бариевич нәгъръ орса да, иртәгесен, Шидловскийның холыксызлыгын, арты белән киртә җимерергә яратуын белгәнгә, Мәскәүгә барырга аягы тартмады. Ул заявкалар, үтенечләр, планнар белән беренче урынбасарын җибәрергә ниятләп, үзе «әллә нигә сырхаулап торам» дип, Иван Ивановичны шомартырга маташканда, шәһәр башлыгы мәсьәләне кабыргасы белән куйды: «Үзең барасың! Үзең җаен табасың! Җиңгән кешенең чире тиз үтә!» — диде.

«Ел уртасында миллионнарны каян тапсыннар!» — дип, дөньяны, дөньяның гаугасына сәбәп булган нәни генә кисәкчәсе, шул уйсулыкка мөгезсез сыер кебек барып кергән берләшмә әрсезләрен каргый-каргый эссе көннәрдә Мәскәү кабинетларын таптап, ялынып йөрергә туры киләсен күз алдына китереп, Басыйр Бариевич министрлыкка сәфәр чыкты. Йокы вагонында бер купеда Валериан Леопольдович белән янәшә туры килделәр. Юл буе сөйләшмәделәр, төшкәч, бер-берсенә күтәрелеп карамыйча, эшләпә читләрен калкытып алдылар...

Һәрберсе алты йөз тәңкәлек норка бүрекләр маяк булдымы, юлда ашаган-эчкәнен Мәскәүгә кайту белән оныта торган Шидловскийның кәефе әйбәт чак туры килдеме, Мәскәү Басыйр Бариевичны елмаеп диярлек каршылады. Әллә министрны озата барганда янып көлгә әйләнгән салон-вагон файдага чыктымы? Илья Ефимович татарларның юмарт кунакчыллыгын, чатакларны гаепкә алмауларын, хатынын бик сөендергән норка тунны да онытмаган иде,— песи булып килеп кергән кунакны кочаклап алды. Басыйр Бариевич кыюланып, кергән шәпкә планнарын сөйләп бирде, тотлыкмады, бүленмәде, кәгазьләрен өстәлгә чыгарып салды. Тын гына тыңлаган министр кәгазьләрне күргәч чыраен сытты. «Кирәкми... Принципта мин каршы түгел... Бүлекләрдә йөреп чык, минем фикерне җиткер... Казан тимерьюлчыларына, әлбәттә, ярдәм кирәк! Акча табарбыз!» —дип сүзне кыскартты.

Бер кешенең фикер ризалыгы меңнәрнең тормышына төзәтмә кертә, норка бүрекләрен кыңгыр салган мәскәүлеләр исәпләп-хисаплап, кысыр бюджетны ипләп-сипләп акча юнәткәндә, казанлылар бил буып тантана итәргә әзерләнделәр. Казанның иң зур, иң абруйлы Козецкий берләшмәсе яулаган җирләрне тартып алу хәзер чүп кебек булып күренде!..

## 30

Вафа Сафич Нәҗипне яратты. Шундый күндәм ишәкләрне яратыр дәрәҗәгә ирешкән иде ул. Карышусыз иде Нәҗип Йосыф улы Нургалиев, ни кушсаң, шуны эшли, кая җибәрсәң, шунда бара, сорашмый, төпченми, кызыксынмый. Телен озайтмый, яман сүз таралса, аңа катышмый, акчага хирысланмый, чыгарган өлешкә һәрвакыт канәгать, аз бирсәң дә, күп тамызсаң да, рәхмәт әйтеп ала.

Әгәр берәр кеше Югары авылда соңгы көннәрен үткәреп ятучы Йосыф карт белән аның Казанда гомер итүче улын якыннан белсә, алар арасында бик күп охшашлыклар, уртаклыклар табар иде. Аерма шунда иде: Йосыф карт шушы хәлгә килеп җитсен өчен колхоз шартлары кырык-кырык биш ел тырышса, Нәҗипне бөгеп салырга шактый кыска вакыт та җитте.

Мыймылдык ханым директор Вафа Сафич юк чакларда күзен уйнатып Нәҗип тирәсендә юргалады, ара-тирә: «Син бит дипломлы егет, укыган, буең-сының бар, кыяфәтең килгән, тырышып кара, аудар шул шадра пәрине! Үзең директор булып кал!» — дип пышылдады. Кызыкмады Нәҗип, мыймылдык ханым белән кыҗыр-быҗырга кермәде, моңсу күзле авылдашы Гөлгенәне дә, аңа биргән «хат язармын!» дигән вәгъдәсен дә онытты, басынкы гына яшәде, директор да, хуҗа да, бүтәннәрдән өстен булырга да теләмәде. Уй-фикерләре кыска, хыяллары бер көнлек иде аның. Наилә аны эш, мәшәкать белән күмеп ташлады. Дача йортын өлгертеп кергәннәр иде, Наилә: «Мунча!» — диде. Чолан кирәк булды аңа, кухняның да йорттан читтәрәк булуын теләде: «Ит кызган истән башыма ут каба, май исе затлы киемгә сеңә»,— диде ул.

Һәммәсен табарга, юнәтергә, җайларга, майларга, бөтенләй күз күрмәгән бәндәләр белән кул сугышырга, арка кага-кага аракы чөмерергә, вәгъдәләр бирешергә, алдашырга, күз буярга, ялган гуаһлык итәргә туры килә иде. Акча кирәк, акча!

Бер вакыйга Вафа Сафич белән алар арасын тагын да якынайтты.

Көннәрнең берсендә ерак Африкадан — Мисырдан — Казанның үзәк сәүдә базасына өч комплект җиһаз кайтып төште. Җиһаз тутырылган тартмаларны директорның да ачып карарга йөрәге җитмәде, һәр комплекты ундүртәр мең сум тора иде! Икесе кая китеп, кемнәрнең лаеклы түрен бизәгәндер, анысын шәһре Казанда беркем дә белмәде, мәгәр комплектның берсе Вафа Сафичка эләкте. Ул, үз чиратында: «Сораганыгыз кайтты!» — дип, хөрмәтле Иван Ивановичны сөендерде. Кибет директоры итеп эшкә урнашканнан бирле, ул, үзен бурычлы санап, Иван Иванович каршысында кыенсынып йөри иде.

Эшнең четерекле бер ягын хәл итәсе калды. Эш шунда иде ки, җиһаз гарнитуры төп-төгәл ундүрт мең сум тора иде. Үзен хөрмәт иткән шәһәр хуҗасы шул бәһагә җиһаз аламы? Үзен кешегә санаган кибет директоры шәһәр хуҗасына шулкадәр акчага гарнитур тәкъдим итәме? Яхшылыкка яхшылык эшләү чираты, ниһаять, Нәҗипкә килеп җитте. Өй җиткердеңме? Җиткердең! Чолан салдыңмы? Салдың! Мунчаң бар, кухняң балкып тора — яле, кайтар әҗерен, гражданин Нәҗип Нургалиев!

Директор тугры колын елмаеп, тәмле сүзләр белән коендырып үз катына чакырып кертте. «Менә,— диде ул, егеткә кәгазь-каләм сузып.— Дуслыкны ныгыта торган сәгать сукты. Шушы актка кул куеп, дөреслеген имза белән беркетәсең дә актта телгә алынган гарнитурны базадан алып, мин кушкан адреска илтеп тапшырасың».

Бер укыды актны Нәҗип, ике укыды, берни аңламады. Актта ике аягы сынган, пыяласы ватылган, бер ягын очлы кадак тирән ермачлаган ниндидер шкаф турында сүз бара иде. «Юлда килгәндә ясалган шул казаларны истә тотып, фәлән-фәлән иптәшләр катнашындагы комиссия гарнитурның бәясен өч мең дә җиде йөз илле сумга калдырырга дигән карар чыгарды» диелгән иде азакта. «Йә, сал имзаңны!» — диде Вафа Сафич, ашыктырып. «Минем ул гарнитурны күргәнем юк лабаса»,— диде авыллыгы һаман очып бетмәгән Нәҗип. «Әллә минем күргәнем бармы? Имзам ярылып ята. Ахмак! Синең кесәңә төп-төгәл өч йөз сум керә. Кул куйган саен өч йөз сумны тамызсалар, мин имзамны беләсеңме кайларга куяр идем!» — диде Вафа, ямьсез генә хихылдап.

Башың кергән җиргә гәүдә сыя, китте Нәҗипнең җүләр башы язгы ташкыннарда агып! Нәҗип, ике иптәшен ияртеп, базага китте. Анда көтәләр иде инде.

Алтынга сатып алынган, шәһре Казанга уравыч юллар үтеп, диңгезләр кичеп, тау-чокырлар гизеп, төргән кәгазьләренә тап та төшмәгән кадерле шкаф-өстәл-урындыкларны йөкчеләр кул очында гына йөрттеләр. «Әгәр черки кунган эз калдырсагыз да бәясен үзегездән түләтәм!» — дип кисәтеп калды Вафа Сафич. Дәү-дәү саллы тартмаларны, тулы чиләкләрне йөрткән кебек сак йөртеп, тоташ бакча эчендә күмелеп утырган кызыл кирпеч йортның өченче катына, Иван Иванович квартирына кертеп урнаштырдылар. Йөкчеләрнең миссиясе шуның белән тәмамланды. Тартмаларны бүтәннәр ачачак, тагын да ышанычлырак коллар җыячак. Аларны күрү Нәҗип ише күгәргән калайга түгел, Вафа Сафич кебек ышанычлы затка да насыйп булмаячак.

Наилә белән Сөмбелә сирәк-мирәк хат алышалар иде. Райкомның беренчесе итеп сайлангач, Сабит энекәшен эзләп тапты, Нәҗипнең әзер квартирадан баш тартуын белгәннән соң шартлар дәрәҗәгә җитеп, очрашуны көткән Сабит ярты сәгать тоташтан русча, татарча, чуашча, марича сүгенде. Төрле телләрдә сүгенергә ул Саратовтан өйрәнеп кайткан иде. Нәҗип карулашмады, уңына да, сулына да ияк кагып, баш игәләп, тик басып торды. Сабит Наиләне көтеп җиткермәде, «Ханнарга тиң булырлык хатын шушы чи тәбикмәк кулында череп ята бит!» — дип каргый-каргый, кунакханәгә кайтып китте.

Ялгышты бу юлы хатыннар белгече Сабит Йосыпович, аһ, каты ялгышты! Нәҗибеннән күңеле кайтканнан бирле Наиләнең итәген җил кайтарды, чибәр, сылу ханым баш инженер Израил Моисеевичтан шома гына директоры кулына күчте, Валериан Леопольдович аны үзенең референты итеп алды. Айлык хезмәт хакы, абруе артты Наиләнең, хәзер инде Гөлнаралар аңа баш орып керәләр, ялагайланалар, вак-төяк бүләк ташыйлар. Квартир чираты да күзгә күренеп алга сикерде, болай барса, алдагы елда каһәрләнгән сары йорттан котылачаклар. Саубуллашканда, Сабит абыйсы үткәндәге вәгъдәсен бераз яңарткан иде. «Шәһәр советында кирәк кешеләрне күреп сөйләштем. Достоевский

урамында бик престижный йорт өлгереп килә. Шуннан син диванага ике бүлмә тәгаенләнгән. Белешеп тор, җүләр булма, һәм безнең карабодай басуында көртлек ишле булсын дип телә!» — «Нигә?» — дип сорамады Нәҗип, ул хәзер шактый нык дагаланып килә торган ир иде.

* * *

Нәҗип яз саен каны алышынып, күзәнәкләре яңара торган хисле зат иде. Быел да шул хәл кабатланды, әмма яз аны гадәттәгедән ныграк яңартты. Каны ургылып-ургылып акты, элгәрге күзәнәкләре җир тетрәгәндәге тау кыялары кебек дөбер-шатыр килеп җимерелделәр, алар урынына яңа, яшь таулар калка торды. Уйлана торгач, соңгы ел ярымда башыннан кичергәннәрне бер дисбегә тезгәч, Нәҗип Йосыф улы Нургалиев анык бер йомгак ясады. Хыяллары җимерелеп, аста, иске салам эскерте төбендә җебеп калган көннән бирле ул Наиләсе белән туктаусыз көрәшеп килә икән. Кая карап атласа да, эреле-ваклы нинди эш майтарса да, аның эш-гамәлләре Наиләгә каршы юнәлтелгән була иде. Ах, дача йорты кирәкме сиңа?! Мә, ал! Күр! Яшә! Алмагачлар быел яңармадымы? Чукынсын, аларын йолкып ыргытабыз да яренгә яңаларын утыртабыз! Әһә! Күрәсеңме! Бөтенесе яңарды! Бакчада әлегә андый тук, нык яшь агачлар юк! Мунча сорыйсыңмы? Дөрес! Мөселман хатыны пакь булырга тиеш! Була! Әзер! Ал! Ләүкәсе сап-сары тактадан. Мунча алды сандык кебек. Чапчаклар юкәдән. Ап-ак. Көмеш сулы төпләре ялтырап утыра. Кер, чабын, тәнеңне дә, җаныңны да арула. Дачага җиһаз дисеңме? Боер гына! Камыш урындыклар, тирбәнчек көрси. Ишек өстендә Наиләнең зурайтылган фотосы. Нәҗип акча кызганмады, Ленин урамындагы антиквариат кибетеннән тумпак борынлы, йомшак иренле негрларның кара агачтан кырып ясалган сыннарын алып кайтып дача киштәсенә тезде. Зәвыксызлык диләрме? Төкер! Наиләсенә ошый! Аңа ошый икән, башкасы чукынып китсен!

Нәҗипнең рухын төшергән, ирлеген изгән бер нәрсә калды: квартир. Сабит абыйсы вәгъдә иткән йортның да җиденче катын өлгертеп килиләр. Ерак командировкадан әйләнеп кайтуга, Наиләнең чираты да бер-ике санга алга күчә... Сабит абыйсыннан котылып, квартирны Наилә алсын, дип теләп, шушы хәлгә ризалашып көткән Нәҗип беркөнне тәвәккәлләп Вафа янына керде. «Вафа Сафич, син миңа берзаман: «Фәлән кадәр акчаң булса, квартирлы итәм!» — дигән идең... Акча табам, квартир алып бирерлек чамаң бармы?» — дип сорады. Шадралары шомарып югалган, күзләре шешенке кабаклары - арасыннан күренмәс булган Вафа генералны күргән ефрейтор сыман турайды. «Акчаң гына булсын! Акча — терекөмеш ул, бетоннан койган буаларны да ера...»

Нәҗип акча җыя башлады һәм шул гадәте белән Наиләне шиккә төшерде. «Әллә берәр хатын янына иярләштеме бу йонкытыйк?!»

Нәҗип исә соңгы һөҗүмгә күчәргә әзерләнә, истә-оста югында ордер тотып кайтып, Наиләнең чыраена атып бәрергә җыена иде. «Мә, ал!» Бу хәлне ул мең тапкыр күз алдыннан үткәрде, йокысыз аунаган мәлләрдә — булачак шушы тантана белән юанып җанын тынычландырды. Акчаны тизрәк җыярга, мая тупларга кирәк иде. Ул Вафаның иң пычрак, иң әшәке йомышларын үтәде. Көн димәде, төн димәде, шимбә-якшәмбедә складта уралды, базага булышырга барды, бәйрәм-сәйрәмнәрдә бүтәннәр өчен кизүлек итте. Күбрәк түләсеннәр генә! Саранланды, балаларына кәнфит, прәннек кебек әйберләр алып кайтмый башлады. Шимбә-якшәмбеләрдә таңнан чыгып югала, кара төн уртасында кайтып егыла...

«Инде була, бәхет кошы безнең кулга куна!» дип йөргәндә, Вафа Сафичка учы-учы белән акча тапшыргач, көтмәгәндә һич уйламаганда җиһазлар кибетенең өлгер директорын кулга алдылар. Казан шау-гөр килде! Югары даирәләрдәге әшнәләренә, үзе күп яхшылык кылган түрәләргә аркаланып, аларның йолып алачакларына йөз тотып, үз эшен алып баручы тикшерүче майор белән дорфа кылана Вафа Сафич, сүгенә, яный, каргана. Майорның теңкәсенә тиеп бетә. Вафа Сафичны яклаучылар табылу ихтималын чамалап, тикшерүче эшне мөмкин кадәр кыска тота, өч ай дигәндә әйләндереп чыгара, директорны җиде елга ябып та куялар.

Нәҗипне дә шаһит сыйфатында дәшеп алдылар. Аңа кадәр мыймылдык хатын аңа таушалып, пычранып беткән кәгазь кисәге сузган иде. «Май кап. Акчаң югалмас. Күпмегә япсалар да, мин озак тормам. Телеңне урынында тот!» дип язылган иде анда. Нәҗип беркемне сатмады, белгәннәрен ачмады, ни сорасалар да: «Белмим, күргәнем юк, ишеткәнем булмады, катнашмадым», — дип, башын тилегә салып утырды. Аны судка чакырмадылар...

Ниһаять, сары йортның соңгы көне килеп җитте. Ионыч кичтән бөтен бүлмәләрне әйләнеп чыкты, шешәләр кузгалды, тустаганнар чыңлады, җылаштылар, көлештеләр, сукрандылар, вәгъдәләр бирештеләр, «мәңге онытмам!» дип кочаклаштылар. Нәҗип белән Наиләнең артык якын кешеләре юк иде. Алар бүтәннәргә ияреп коридорга чыгып былагайланып йөрмәделәр, Ионычка ике шешә сыра эчертеп озаттылар да эчтән бикләп кайгыда калдылар. Ир белән хатын арасындагы кискенлек бераз йомшады. Наилә дә ире, балалары белән кешечә сөйләшә башлады, кыланмады. Нәҗип, эчтән үртәлсә дә, тышка аны-моны чыгармады. Уйлаша, эзли торгач Фәридун Фазлыев исеменә барып җиттеләр.

Наилә: «Фәтхулла абыйларга кагылыйк», — диде. Нәҗип Фазлыевларга барып кайтуны яклады. Кат-кат йөргәнче дип, ике чемоданга сыйган әйбер-караларын тимер юл вокзалына саклык камерасына илттеләр, мендәр-юрганнарны Наилә китапханәдә бергә эшләгән Нина Морозоваларга ташыды. Дүртәүләшеп Фәридун Фазлыевларга киттеләр. «Ул квартирның яртысы безнеке әле уйласаң!» — диде Наилә, юлда барганда. «Әгәр алай сөйләшә торган булсаң, аларга эз дә басмыйбыз!» — диде Нәҗип, кырт кисеп.

Алар Фәридун Фазлыевны йорттан ерак та түгел нәни генә бакчада ак каен төбендәге эскәмия янында очраттылар. Утырмаган иде Фәридун Фазлыев, җете кызыл өч бөртек канәфер чәчәге тотып, хәсрәтенә буылып, аяк өсте басып тора иде. Ул үзен урап алган кешеләрне шактый озак торгач кына абайлады. Күрешеп, бер-ике сүз алышкач, ул кулындагы чәчәкләрне эскәмия башына таратты. «Шушында үлде Фәридә апагыз, шунда утырып җан бирде», — диде ул, коп-коры күзләре белән Нәҗипкә карап. «Кайчан?!» — диделәр Нәҗип белән Наилә беравыздан. «Ай ярым була инде», — диде Фәридун Фазлыев. «Нигә безгә хәбәр итмәдегез?» — диде Нәҗип, чын күңеленнән хафаланып. «Кирәк чакта сине табып буламыни? — диде Фазлыев.— Яшәгән урыныңны белмәдем. Эшеңә кергән идем, «судта» диделәр. Хәерлегә булсын!»

Алар, эскәмиягә утырышып, кыска гына сөйләшеп алдылар. Нәҗипләрнең йортсыз-нисез урамда калуларын ишеткәч, ул ашыктыра ук башлады. «Күченәсез дә киләсез. Бер башыма ямансу иде, ичмасам, күңеллерәк булыр»,— диде... Нәҗип белән Наилә, рәхмәт әйтеп, әйберләрен ташып та куйдылар.

Фәридун Фазлыевның һәр иртәдә сөеклесе Фәридә җан биргән эскәмия янына барып, йә кыр чәчәкләре, йә кан кызыл канәферләр таратуына Наилә күнегә алмады. Ярым бөкрәеп, юаш кына басып торган ап-ак чәчле ирне күргәч, ул, сүз әйтмичә, сүзен әйтә дә алмыйча, үрсәләнеп җылый иде... Былтыр лагерьдан малайларны: «Сезнең әтиегез псих! Сезнең әтиегез дурак!» — дип үртәп кайтарганнан бирле, алар балаларны яннарыннан читкә җибәрмәскә булдылар. Хатыны вафатыннан соң эшкә чыга алмаган, саулыкка туймаган Фәридун Фазлыев балаларга тиз ияләште, аларны ияртеп зоопаркка барды, киного алып керде. Алар зиратка да бергә барып кайттылар... Наиләне — тәҗрибәле, хәтерле һәм булдыклы референтны — генеральный директор Урал ягы шәһәрләренең берсенә алып китәргә җыенгач, Наилә кырыс һәм йомылган иренең иңенә кулын салды. «Командировкага соңгы кабат чыгам, моннан болай балаларны ташлап китеп йөрмим»,— диде. Нәҗип дәшмәде, чынлап уйлаганда ул Наиләнең сәфәрләренә тәмам битараф иде инде...

Ниһаять, Нәҗипнең бүген беркая барасы юк. Хатыны «соңгы командировкасына» китте. Нәҗип Искәндәр белән Рөстәмен төрткәләп уятты да алар иртәнге поезд белән дачаларына Идел буена барырга җыендылар. Нәҗип Фәридун Фазлыевны да чакырган иде, ул бармаска булды. «Апаң көтәдер, көн бик матур, зиратка кагылып чыгармын»,— диде ул, кыр чәчәкләре бәйләмен эскәмия янына илтергә әзерләнеп.

Бакчада озак юанмадылар Нәҗипләр, калкына башлаган түтәлдән бер-ике кыяк суган өзеп каптылар да яланаяк, чап-чап басып, куышып дачалар янәшәсендәге аулак култыкка су керергә төшеп киттеләр. Менә кайда икән ул дөнья рәхәте! Һава саф, тар булса да тирән сулы култык ярларында мең төрле чәчкә-үләннәр кабарып, талгын җилдә сизелер-сизелмәс кенә тирбәләләр. Күбәләкләр — җәйнең фәрештәләре — ал, зәңгәр, чуар канатларын селкеп, һава дулкынында иркәләнәләр. Култыкның теге ягында, бу якка элегрәк килеп урнашкан дача хуҗалары утырткан нәзек, яшь каеннарда сандугачлар тавыш биреп куя. Кыш, яз буе ярым караңгы складлардан, сөремле-корымлы урамнардан, түшәменнән су тамып торган базалардан башы чыкмаган Нәҗип тиз исерде. Җәй һавасы, тансык хуш исләр, күбәләк куып ары-бире йөгергән балаларының гамьсез чыр-чуы аны тәмам мәс итте. Күптәннән наз, иркәләү күрмәгән тәнен таратып чирәмгә сузылды, нык ук күтәрелеп килгән кояш аның куе керфек араларына сыеп бетте. Ул йокымсырады һәм «күк капусы ачылды». Ул дөньяны иңләп басып торган Наиләсен аермачык күрде. Ул шәрә тезләрен ялтыратып ят ирнең тезләрендә утыра икән. Ирнең кем икәнен ачыкларга тели Нәҗип, аера гына алмый!

Бер караганда Изил Латыйпов кебек тә була, икенче караганда Израил Моисеевичка әйләнеп тешен ыржайтып тора. Керфекләр тагын да ныграк кысылалар, кояш кача, ят ир директор Валериан Леопольдович Козецкийга әверелә. «Тезеңне капла, тезеңне!» — дип кычкырырга тели Нәҗип, авызы ачылмый. «Эх, Наилә, Наилә!» — дип кычкырып уйлый ул, яткан килеш. — Элек син минем акыл белән яши идең. Мин синең җаныңның һәр ымын, ишарәсен аңлый идем... Хәзер син ничә ир биргән акыл белән гомер итәсең?.. Кемнәр генә сине җитәкләп үз сукмагына тартып кертми?! Ничек итеп аңлыйм ди мин сине?!»

Ул сискәнеп китте, колагына балта чапкан, дәү агач ауган тавышлар ишетелгәндәй булды. Тукта әле, нигә болай ачык ишетелә бүген поезд тавышлары? Монда култык янындагы үзәндә тимер юл ыжгырганы ишетелми иде ләбаса!

Калкынды, әтиләренең йокылы-уяулы сөйләшкәнен балалар абайлаган, ахрысы, икесе дә аның янына килеп басканнар, әсәренеп, тыңланып көтеп торалар. «Әти! — диде Искәндәр, учын ачып.—

Мин бернәрсә таптым!» «Нәрсә, улым?» — Нәҗип күзен ачыбрак караса, улының нәни учында ялтырап, нурланып алтын балдак ята. «Каян алдың моны?» — «Мин аны әниемә бирәм, — диде үз уйларына чумган малай.— Ул балдакны ярата!» — «Каян беләсең? — дип сорады кинәт шигәеп Нәҗип.— Аның балдаклары юк ич!» — «Булмас! Бар! Ике кулында ике балдак. Икесе дә алтын. Сөенгән әни!» Нәҗип торып басты, балдакны тартып алып, күзенә якын китерде. Алтын! Билгесе бар... Наиләнең ике балдагы бар диген! Ник күрсәтмәгән ул аны Нәҗипкә? Нәҗип ничек күрмәгән? «Юк, улым, — диде ул, пошынган тавыш белән, — югалган балдакны әниеңә бирмә, без аны иясенә кире кайтарырбыз». — «Ә иясен каян табабыз?» — «Балдагы табылгач, иясе табылмый калмас».

Көннең чите кителде. Нәҗип интегеп, җәфаланып Наиләнең алтын балдаклары хакында уйлады. Ничек күрми калган ул аларны, ничек абайламаган?.. Малайлар балдакны тиз онытсылар, якыннан очып үткән дәү, чуар канатлы күбәләк артыннан йомылдылар. Нәҗип, тезен чәнчеп, учындагы балдакны вакыт-вакыт караштырып, ямьсез, өметсез уйлар чоңгылына чумды, янына ук килеп үлән чемченә башлаган кәҗәне дә күрмәде. Ак яулыгын татарча җилкәсенә җәеп салган, нык ук таушалган, бөкресе чыккан карчыкны кәҗә үлән кештердәткән тавышны ишетеп борылгач кына күрде. Карчык, кәҗә муенына салган сүс бауны арык бармакларыннан ычкындырмыйча гына, аның янына килеп чүгәләде, балалар ягына башы белән ишарәләп: «Улларыңмы?» — дип сорады. Нәҗип баш какты, эндәшмәде.

«Исәйгәнче балалар зур байлык, юаныч... Картлык һәркемгә килә... Әмма баладан уңмаган картлык — иң күңелсез картлык... Әйе, картлыктан алама нәрсә юк...» Карчык юл буе үзен урап килгән сөмсез, караңгы уйларыннан арына алмый иде булса кирәк, ул Нәҗип белән түгел, үз-үзе белән сөйләшә, бәхәсләшә, көрәшә иде, ахрысы.

«Әле ярый, Ходаның кодрәте киң — ул адәм баласын картлыкка иртә әзерләргә тотына. Озак әзерли ул аны картлыкка, кинәт килеп җитә торган Газраил белән көрәшергә әзерли. Адәм баласы картлыгын абайлап, сискәнеп, йөрәге ярылмасын өчен, Аллаһы Тәгалә әүвәл башлап аның нурлы йөзенә сызыклар сыза... Аннан иплән кенә күзнең нуры коела. Ниемә кирәк карт кешегә якты күз? Артка караса — үкенечләр, алда — кара пәрдә... Яшьлек тавышларын ишеттермәс өчен иплән кенә колакны балавызлый... Юынган саен үзеңнең әҗәл көткәнеңне искәрер өчен аяк тырнакларына сары тут төшә... Кул тырнаклары сына, ярыла башлый. «Ай-һай, дөнья!» — дип әйтеп баш чайкаган саен чәч коела. Ашыгудан, җитезлектән коры каласың, буыннарның егәре бетә... Мин элгәре бүрекле ата казымның тавышын чакрым ярымнан аера идем!.. Март башларында болдыр янына килеп бер кычкырсамы?.. Җилгә каршы килеп җитә иде тавышы!.. Хәер, каз асрау да бик читенләшкән иде. Мәшәкате күп аның, кош-кортның. Колагы катыланган, күзе күрмәс булган адәмгә кош-корт артыннан йөрү читен... Син шушы урыннан җир алган кешеме?.. Таныйм, таныйм. Сине танырлык егәре калган икән күземнең. Беренче булып йорт җиткездең... Чая егет дип йөрдем мин сине. Авыл халкы сине каргый, йортларга ут салабыз, дип яныйлар... Идел буе халкы бурлыкка күнеккән. Бурлык өчен аулак булган яхшырак. Ә миңа ни, карт пәригә, булса ни дә, булмаса ни... Моннан ун көн элек кәҗәмне йөрткәндә, балдагым шуып төшеп калды, югалды. Бармакларның егәре калмаган. Арыкланган алар, төс җуйган... Нигә булыр икән дип юрап йокы күргәнем юк. Баксаң, тимер юл буе агачларын кисәргә булган икән. Улым Басыйр... бәлки, ишеткәнсездер дә, Басыйр Бариевич дигән кәттә нәчәлник минем улым була! Шул әйтә: «Тимер юлларны киңәйтәбез, ишәйтәбез! Бакчаларны бетерәбез», — ди... Нәрсә сөйли идем соң әле? Ә-ә, имәннәрне искә алган идем. Шул балдакны миңа бүләк иткән кеше утыз җиденче елны язда утырткан иде аларны... И, куанып та йөргән иде. Көзен үзен өтермәнгә илтеп тыгып, эзен югалттылар. Хәзер менә, кырык ел үткәч, урманын кисәләр...»

Нәҗип әсәренеп, калтырап диярлек тыңлады карчыкны. Аның баягы халәте, төш белән өн арасындагы сизгерлек мизгеле китеп, таралып бетмәгән иде, карчыкның һәр сүзенә ияргән моңны, сагышын тирәнтен кичереп тыңлады. «Аллаһы Тәгалә адәм баласын картлыкка әзерләп, аңа тәүбәгә килергә вакыт калдыра. Берәүнең дә җанын кинәт кенә алмый!»

Нәҗип учын ачып карчыкка күрсәтте. Әнисә абыстай (бу ул иде, әлбәттә) башта балдакны күрмәде, күргәч искәрмәде. Ул, җанын авырайткан уйларын көч-хәл белән күтәреп, бу тирәдән еракта йөри иде булса кирәк. «Утыз җидедә агачларны утырткан кеше бүләк иткән иде балдагымны. Һи-и, җылы җанлы кеше дә иде, мәрхүм!.. Каз багып кына йөри идеммени мин, юк, имәннәр белән серләшә идем... Ни әйтсәм дә аңлый иде алар мине». — «Алыгыз балдагыгызны!» — диде Нәҗип, учын аңа таба якынайтып. Карчык баш чайкады: «Минеке түгел, түгел. Бу минеке түгел. Имәннәрне кырып, төпләрен ком белән каплаталар икән, балдак нигә инде?» — «Мин аны әниемә бүләк итәм. Мин таптым аны», — дип сүз арасына кысылды быткычланып Искәндәр. Нәҗип улының Наиләне телгә алуын, аңа тагын бер балдак бирергә ашкынуын өнәмәде, Искәндәрнең җилкә чокырына төртеп, аны читкәрәк какты. «Алыгыз, ал, апа».— «Юк, — диде Әнисә абыстай, учта нурланып яткан түгәрәк алтынга күз төшермичә.— Минеке түгел!» Ул кәҗәсен ияртеп култыкның Иделгә тоташкан башына китте. Нәҗип ике улын ике кулы белән җитәкләп, җилтерәтеп, култыктан бакчаларга үтә торган тар тыкрыкка сөйрәде. Тимер юл якынлашкан саен, балта-пычкы тавышлары, ишле кеше авазлары ачыграк һәм

усалрак яңгырады. Нәҗип адымнарын шәбәйтте, малайлар аның адымнарына өлгермәделәр, ул, кулларын ычкындырып, тавыш килгән шөбһәле якка берүзе ашыкты.

Ничек моңарчы күрмәгән ул? Ничек бу хакта беркем аңа хәбәр ирештермәгән? Баскыннар Обсерватория ягыннан урманны кисеп, агачлардан тазартып ук киләләр икән. Тиз тотканнар, бер дә ул белгән эшчеләргә охшамаганнар болар. Әллә монда да акчага хирыс, ял итүне оныткан әрмәннәрне яллаганнармы? Берләшмә бакчалары читенә җитәрәк, сулышы кабып, Нәҗип туктап калды. Йөрәге иске насос кебек калтырана, күкрәгенә сыеша алмыйча бәргәләнә иде. Унбиш-егерме метр киңлектәге агачлык хәвефле, ят тавышларга күмелгән: электр пычкылары күндәм генә агач кәүсәләрен тешләре белән умырып керәләр, көн яктысында ботак-сатак тураучы үткер балталар елык-елык килә, күлмәкләрен салып ыргыткан ир-егетләрнең юеш җилкәләреннән куе пар күтәрелә. «Сагай, сагай!» — дип кычкырган тавышлар тынып өлгерми, яшьтәш имәннәр әле анда, әле монда чайкалып торалар да фырылдап, колачларын җәеп, үләннәрне изеп, вак куакларны сытып, җиргә барып яталар. Бөтен җиргә пычкы чүбе, йомычка, суелган кабык, аракы катнаш тир исе таралган. Анда-санда чи ботакларны чыжылдатып учаклар яна. Арырак, имән аударучылар үткән урыннарда, озын арба таккан тракторлар, машиналар тукталган, шундый ук таза, шәрә тәнле ирләр бер буйга туралган имән кискәләрне ашыгып-кабаланып төйиләр, һау-һаулап бер-берсен ашыктыралар, дәртләндерәләр. Русча, татарча сүгенү сүзләре язгы рәхәткә күнегә башлаган сак колакларны рәхимсез кисә.

Нәҗип әүвәл бер-бер артлы, аркылы-торкылы ауган агачларны әрнеп күзәтте. Аннан соң гына, күз ияләнә төшкәч, кешеләрне аерым-аерым итеп, берәмләп аермачык күрә башлады. Үз күзләренә ышанмады, ышанырлык та түгел иде хәл...

Беренче итеп Нәҗип сары йортның «элекке коменданты» Ионычны күрде. Аның янында туктаусыз балта уйнаткан өч ир-ат та таныш иде аңа. Алары да Нәҗип белән бергә сары йортта сөрсеп ятып, шуннан сөрелгән ирләр. Кушсаң, имәннәрне генә түгел, имән-имән ирләрне дә турап чыгачак байгышлар. Гаделлеге өчен Митя Шороховны да шулар үтереп ташлаган дип сөйләделәр. Алар, өчәү укмашып, авыр карашлары белән үткән-сүткәнне капшап торсалар, яннарына якынаерга курка иде Нәҗип. Ионыч мәзәк кенә каш сикертте. «Баш бирмибез, балта безнең кулда!» дигән сыман, күзен челт-челт йомгалады.

Күз Ионычтан читкәрәк күчте, бер төркемнән икенчесенә барып ялганды. Имәнлек, имәнлек!.. Әле узган килгәндә генә Нәҗип, улларын имәнлек кырына бастырып: «Сез шушы имәннәр белән янәшә үсәрсез, балалар. Алар сезне, сез аларны саклап яшәрсез»,— дигән иде түгелме?.. Гаҗәп! Каян килеп эләккән монда Сабит абыйсына шашлык кыздырып яткан Самвел белән Гурген? Әллә алар түгелме? Күзе алмаштымы Нәҗипнең? Башы авырта, колагы чыңлый, аякларында көч калмаган... Юк, шулар! Нәҗипне танып, алар да балталарын күтәреп сәламләделәр. Вафа Сафичка хезмәт итүчеләр дә монда! Доцентлар! Пешекче! Баш механик! Алар Нәҗипкә карамаска, күренмәскә тырышалар.

Юк, юк, Нәҗипнең күзенә нидер булган! Ялгыш күрә! Тимерьюлчыларның профсоюз лидеры Исламнур да монда! Җир өчен тарткалашып йөргәндә, Исламнур белән Нәҗипне Изил Латыйпов таныштырган иде. Тукта, тукта! Мөнир ич бу! Авылын каргап чыгып киткән егет! Трактор янына баскан да ашыгып-ашыгып төпчек суыра. Ә арырак Гөлгенә белән аның ахирәте кара хатын ботак-сатак яндыралар шикелле! Алармы, түгелме? Хатыннарның битләре корымланган, тез турындагы оеклары тишелгән. Бөтен дөнья бәхетсезен җыйганмы әллә шушы урман?

Һа, бусы инде акылга сыймый! Мөмкин түгел! Нәҗип чирләгәндер, күзе Идел буенда калгандыр... Әллә төш күрәме? Саташамы?! Нәҗипнең әлҗе-мөлҗе күзе урман тунаучыларның иң кайнашкан ноктасына җитте дә туктады. Уртада УЛ басып тора иде. Аның кулында пычкы да, балта да юк, киемнәре дә таза; УЛ, күпсанлы музыкантларны берләштергән көчле оркестр дирижеры сымак, үкчәләренә басып бер урында зыр-зыр әйләнгәли, кулларын бутап кемгәдер кычкыра, өр-яңа зәңгәрсу чалбарының җиз-патрон төймәләре елтырый. Юк, юк, бу кеше Изил Латыйпов түгел! Булмас! Була алмый! Чире борылып кайткандыр Нәҗипнең, шуның касәфәтедер! Чир шаукымы гына ла бу! Изил Латыйпов — тимерьюлчыларга каршы көрәштә катнашкан, җир өчен канга-кан сугышкан кеше, хәзер шуларның мәнфәгатен яклап урманны кистереп ятсынмы! Аның монда җитәкче, иң кәттә кеше икәнлеге күзгә бәрелеп тора! Ул түгел. Бүген үк шәһәргә кайтырга да врачка күренергә кирәк. Фәридун Фазлыев: «Торымнан-торымга каралырга кирәк сиңа, Нәҗип туган, психик чарпалышлар эзсез үтми алар»,— дигән иде түгелме?

Ул исәнгерәп басып торганда, бакыр бугазлар, корыч күкрәкләр: «Әй, сагай, сагай!» — дип тоташ акырдылар. Иң биек булып күкрәп утырган имән, авыр уфылдап, аһылдап, УЛ дирижерлык кылган тирәгә авып төште, УЛ бер якка сикерде, сабан туе чабышкысы кебек, артын сикертеп Нәҗип янына килеп басты. Ялкын, төтен исе килә иде аннан. «Син дә безнең беләнме? Молодец! — диде ул, күзләрен нурландырып. — Ишеттек, ишеттек... Шактый акчаң янган икән! Ә монда!.. Тиз арада акча күрәргә була!»

Изил Латыйпов! Үзе! Шул!

Күзенә дә, колакларына да ышанмады Нәҗип, шаккатты. Аның Вафага акча биреп куюы турында, шадраның төрмәгә эләгүен беркемгә, хатынына да сөйләгәне юк лабаса! Димәк, Наилә аның тормышын, һәр адымын капшап, тикшереп йөри дигән сүз! Тикшерү өстенә шушы азгын каргага сөйләп тә бара икән! Күзләренә ышангач, колакларына да ышанырга туры килде. «Бу ни хәл? — дип сорады ул, тыныч булырга тырышып. — Агачларны кисәләр, җирне тартып алалар, син үзең утырган ботакны кисәсең түгелме? Хыянәт ич бу!» — «Ерунда! — дип авызын ерды Изил. — Рощаның хуҗасы юк, утырткан кешеләр беткән, агачлык беркем балансында да тормый. Кисәргә алынган кешеләр шушы кадәр байлыкка үзләре хуҗа! Аңлыйсыңмы, тинтәк?! Мин җиһаз фабрикалары белән элемтәгә кердем. Мала-а-ай! Агач бөтенесенә кирәк! Яртыдан артыгын Украинага, далалы төбәкләргә алтын бәһасенә аткарабыз! Калганын Каспий ягына, урмансыз өлкәләргә саттык! Бер бүрәнә, бер ботак әрәм булмас! Монда акча эшләп алырга була! Сал өстеңне, тот кулыңа балта! Мондый фарт гомердә бер килә!» — «Ә җир?» — дип ыңгырашты Нәҗип. «Җир? Татарстанда җир беткәнме?! Тотын балтага, тотын, дим мин сиңа!» — «Соң, үз җирендә татарга яшәр урын калмый лабаса! Күпме уңдырышлы җирләрне су астында калдырып, сулыкларда зарарлы корт үрчетәбез! Нефтьчеләр күпме җиребезне талады! Кара туфраклы басуларга гел кирәкмәгән заводлар китереп утырттык!.. Инде, шушы күз карасы кебек кадерле имәннәрне дә тунап бетерсәк!» — «Әй, син! — диде Изил, каралып.— Тый телеңне! Телеңнең авызыңа сыймаганлыгын анда бик яхшы беләләр! Чамалап! Йә балтага тотынасың, йә моннан таясың! Җир кирәк булган икән аңа, әтрәк-әләмгә! Табармын мин сиңа җир. Тай моннан, мәхлук!»

Нәҗипнең баш очында яшен чартлады, уйлары ми тартмасына сыя алмыйча кисештеләр, ул каршысында авыз ерып торган Изил Бәдретдинович Латыйповның яңагына китереп бәрде. Профсоюз куштанының күзеннән утлар чәчелде...

Нәҗип көч-хәл белән дачасына кайтып җитте, бикле ишек тирәсендә уйнап йөргән улларын күкрәгенә кысты һәм җылап җибәрде. Кульяулыгына дип кесәсенә тыгылса, кулы ят бер әйбергә кагылды. Ул алтын балдакны тартып чыгарды, аңа бер карап алды, булдыра алган кадәр еракка, киселүне көтеп җилдә калтырап утырган имәннәр арасына ыргытты.

**31**

Буйдан-буйга сузылган урман да, уйсулык читендәге бакча участоклары да әллә кайчан калын ком астында калып югалдылар. Идел төбеннән кудырылган ком катлавы өстендәге шпаллар әлегәчә күгәреп эшсез ята. Отчет бирелгән, орденнар алынган... Әнисә абыстайның вафатына да байтак вакыт үтте. Бу якларда хәзер казлар күренми!..

Ниһаять, Наиләнең чираты җитеп, Нәҗипләр яңа квартирга күчenделәр, «Соңгысы, соңгысы!» — дия-дия, Наилә командировкаларына әле дә булса йөри. «Йортка кердем!» — диде әрнеп Нәҗип, Ионычны бер очратканда. Квартир Наилә исемендә иде. Валериан Леопольдович Наиләне яңадан Израил Моисеевич катына кайтарды. Үзе референт итеп Мәскәүдән Казанга кайтарткан чибәр гөрҗи хатынын алды. Наилә күчешне авыр кичерде. Әгәр Нәҗибе бер-бер кыек сүз ычкындырса: «Квартир минеке! Синең ише чабата олтырагын куам да чыгарам мин!» — дип акырырга ярата. Күчеп әз генә яшәп калдылар, Искәндәрне милиционер җитәкләп китерде: «Гараж йозагына ачкыч ятатып, велосипед урлап чыкканнар!»

Фәридун Фазлыев киңәше белән Нәҗип кибеттән бөтенләйгә китте, шәһәр читендәге яңа мәктәпләрнең берсендә физика укыта башлады. Искәндәрне үзе укыткан мәктәпкә күчереп ияртеп йөртергә гадәтләнде. Коллектив әйбәт иде болай. Ир педагог буларак хуплап каршы алдылар. Көзен, ноябрь бәйрәмендә, бәйрәм тантанасында тәртип сакларга унынчы класс дружинниклары белән Нәҗипне дә җибәрделәр. Ул алып килгән егетләрне Ленин һәйкәленә якын гына урынга бастырдылар. «Җаваплы пост!» — дип кисәттеләр.

Вак рашкы кар сибәләгән көн иде. Мәйданга суворовчылар, гаскәриләр килеп кергәч, Нәҗип бик хафаланып уйлап торды: «Боларның берсе дә иген икми инде, чуен коймый, һәммәсенә май кирәк, ит!.. Нигә шулкадәр күп алар? Ә Мәскәү парадларында! Ел саен күпме офицер әзерлиләр! Илгә сугыш куркынычы янамаганда нигә шулкадәр акча, ресурслар түгеп чамасыз гаскәр тотарга? Германиядә, чехларда, венгрларда... Нинди акылсызлык бу?! Трибунадан яңгыраган лозунгларга бер дә туры килми ич болар! «Тынычлык, тынычлык!» — дибез, үзебез дөньяны атом бомбаларына күмдек. Океаннарда безнең су асты көймәләре, һаваларда хәтәр самолетлар!..»

Бу хакта Нәҗип укытучылар арасында гына түгел, укучылар алдында да ачыктан-ачык сөйләштерә башлаган иде. Нәтиҗәсе кызык булды: укытучыларның бер өлеше аннан күрәләтә читләште, укучылар, киресенчә, аңа ныграк тартылдылар. Төрле яктан яуган куркыныч сорауларга ул белгәненчә, туп-туры җавап бирергә тырышты. Теге чакта гаризасын кире алдырырга дип заводка килеп йөргән КГБ вәкиленең дәшми-тынмый гына директор кабинетына кереп барганын күргәч, аның кемне эзәрлекләп бу тирәдә иснәнеп йөрүе Нәҗип өчен хәзер сер түгел иде...

Аның башы әйләнеп китте. Ул, тотыныр нәрсә булмагач, як-ягына каранды да күзен йомды. Күзен ачканда, мәйданга байракчылар кереп килә иде. Тукта! Байракчылар таныш түгелме соң аңа? Әйе, әйе!.. Аның маңгае дымланды, аркасына салкын тир бәреп чыкты. Күз аллары караңгыланып, арт чүмеченә яшен китереп бәрде. Егылмаска, егылмаска дип ныгытты ул үз-үзен. Партия, хөкүмәт җитәкчеләренең дәү-дәү рәсемнәрен күтәреп, беренче сафта Ионыч, аның өч ахирәте, Гурген белән Самвел, Исламнур белән янәшә Изил Латыйпов, Гөлгенә белән кара-чутыр якут кызы киләләр иде. Самвел — Мжаванадзе, Гурген Алиев портретларын тотканнар. Ә Ионычның нык кулларында Брежнев үзе! Аның көрәштәшләре, тугры яраннары Черненко, Романов, Андропов, Громыко, Суслов, Рәшидовлар аннан әз генә түбәндәрәк тирбәләләр. Нәҗипнең кинәт көләсе, мәйданны яңгыратып: «Балта тоткан куллар кызыл әләмнәрне тотарга да мәҗбүр шул!» — дип кычкырасы килде. Башы әйләнде, тамагы янды, бугазын нидер кытыклады. Көләргә ярамаганын белсә дә, һич чыдар әмәле юк егетнең. Ярыла-ярыла, бүксәсе шартлаганчы көләр иде мөмкин булса... Бер түзде, ике, аскы иренен чәйнәп бетерде, ниһаять, чыдамады, колонналар өстендә чайкалган зур-зур портретларны янәшә баскан укучыларына күрсәтеп, шаркылдап көләргә тотынды. Трибунада гайрәтле кулы белән казанлыларны котлап торган иң зур җитәкченең чырае сытылды. Ул Иван Ивановичка ым какты. Иван Иванович үз чиратында офицерларның берсенә Нәҗипне төртеп күрсәтте. Нәҗип, ике ягыннан ике таза егет култыклаганда да тыела алмыйча, мәйданга яңгыраган сыек кына «ур-ра!» тавышларын басып һаман көлә, хихылдый иде.

Арча кырындагы сары йортка илтеп япканда да аның ирен читләреннән канәгать, бәхетле елмаю китмәгән иде әле. Бер үкенече калды: янәшәсенә баскан укучылары аның нилектән көлгәнен аңышмадылар!

Иртәгесен аны чакырып алдылар. Врач белән күрешеп, мәсьәләне ачыклыйбыз дип барса, ярым караңгы кабинетта аны хәрби кыяфәтле, гражданнар киеме кигән, кырыс танышы каршылады. Изил бүлмәсендә очрашканнары бар иде аларның. «Ни өчен бәйрәм вакытында тәртип бозып, ил тантанасын көлкегә алдыгыз!» — диде теге, явызланып. «Кызык ич! — диде Нәҗип, елмая-елмая. — Кемнәрнең рәсемнәрен кемнәр күтәреп бара бит! — Һәм ул кысан бүлмәне киңәйтеп тагын шаркылдады. — Түшен калай белән тутырган ахмакның портретын кем күтәреп бара диген!»

Танышы артыгын җентекләп тормады, Нәҗипне әллә ничә тимер ишек аша үткәреп, берьялгызын карцерга илтеп яптылар. Бәйрәм арасында аны чакырган кеше булмады, ашарына кертмәделәр, эчәренә бирмәделәр. Ул үз хакын таләп итеп ике йодрыгы белән тимер ишекне озак кына төйде. Бераздан ишек тавышсыз гына ачылды, сүзсез-өнсез кергән тап-таза ирләр Нәҗипне идәнгә егып салдылар да сул беләгенә бер-бер артлы ике укол кададылар. Ике атна үтеп Нәҗип телгә килгәч, аны өч кеше янына илтеп яптылар. Камерадашларының сүзсезлеген күреп, ул: «Нигә безне монда тоталар?! Ни гаебебез бар безнең?!» — дип, ишекне төя башлаган иде, таза-таза ирләр кереп аны эләктереп алдылар. Яңа уколлардан соң ул дүрт ай телгә килә алмады.

Дүрт айдан соң Нәҗип Йосыф улы Нургалиев, чак-чак исенә килеп, үзе белән ниләр булганын сөйләр чамага кайтканда, аны этап белән Томск ягына озаттылар, һәм шунда аның эзе югалды. Бу юлы балтаның кем кулында булуын беркем дә белми калды.

*1988 — 1989*
*Казан — Займище — Переделкино — Ислочь —*
*Малеевка — Пицунда — Коктебель*

Литературно-художественное издание

***Гилязов*** *Аяз*
*(**Гилязов** Аяз Мирсаидович)*

В ЧЬИХ РУКАХ ТОПОР?

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Гыйләҗев*** *Аяз*
*(**Гыйләҗев** Аяз Мирсәет улы)*

БАЛТА КЕМ КУЛЫНДА?

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.02.2008.
Форматы 84г108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы.

Офсет басма. Шартлы басма табагы 16,80. Шартлы буяу-оттиск 16,91.
Нәшер-хисап табагы 17,78. Тиражы 2000 экз. Заказ Т-144.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.